ISSN 0206-4189

# Казан утлары

1. 1994



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(855)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ


И. ЮЗЕЕВ. Мин фәрештә түгел... *Шигырьләр* . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Урланган ай. *Повесть* . . . . . . 8
РӘШ. ӘХМӘТҖАН. Безнекеләр шулай җан бирми. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 102
К. ФАСИЕВ. Безнең авыл мәзәкләре . . . . . . 109
Җ. СӨЛӘЙМАН. Казан елгасында су түгелләр. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . 126

Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан 130


ПУБЛИЦИСТИКА


Р. НИЗАМИЕВ. Ут һәм җыр *(Фәрит Яруллинның тууына 80 ел уңаеннан)* . . . . . . . . . . 135
Х. БӘДРЕТДИНОВ. Еракташы якыннарыбыз . . 142


БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП


Шәфкать нуры таратучылар . . . . . . . . . . 150


МӘСЬӘЛӘГӘ БЕР КАРАШ


М. ӘХМӘТҖАНОВ. Юкәдә икән чикләвек яки ничек итеп тарихны бозалар . . . . . . . . . . 153
Р. ӘХМӘТҖАН. Хыял һәм хакыйкать . . . . . 160


РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ


Туган җир җылысы . . . . . . . . . . . . . . 165


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


М. ВӘЛИ. Яңа исемнәр, яңа әсәрләр . . . . . . 168


ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ


Р. ӘМИРХАН. Газиз теленә, татар, төбәмәче алтатар! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177


КИТАП КҮЗӘТҮ


Ә. МОТЫЙГУЛЛИНА. Күгәрчен сөте?! . . . . 182

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть А. БАЯНОВА «Похищенная луна»; «Байки нашей деревни» Р. ФАСИЕВА; стихи И. ЮЗЕЕВА, РАШИДА АХМЕТЗЯНОВА, ДЖ. СУЛЕЙМАНА.
Перед XII съездом писателей Татарстана.
«Публицистика»: к 80-летию со дня рождения композитора Ф. Яруллина публикуется статья Р. НИЗАМИЕВА; статья Х. БЕДРЕТДИНОВА о крупных ученых-татар.
«Взгляд на проблему»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Как портят историю?», статья Р. АХМЕТЗЯНОВА «Желанное и реальное».
«К 70-летию Р. Тухватуллина».
«Литературная критика»: статья М. ВАЛИЕВА «Новые имена...»
«Актуальная проблема»: статья Р. АМИРХАНОВА «Береги свой родной язык».
«Библиография»: статья А. МОТЫГУЛЛИНОЙ.
«Слово читателя».
На наших обложках: картина художника Р. Загидуллы; известный ученый и писатель, президент Академии Наук Татарстана М. Х. Хасанов.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.12.93 ел. Басарга кул куелды 12.01.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108\ {}^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 044. Заказ Я-732. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Илдар Юзеев

* * *

Мин фәрештә түгел, бераз
Шәрабен дә каптым,
Яшьлегемдә адашып та йөрдем,
Гөнаһка да баттым.
Юк, шайтан да түгелмен мин,—
Әйттем исә кайттым,
Аның коткысыннан китеп,
Үз юлымны таптым.
Язмыш мине авыр юлда йөртте,
Уттан-суга салып,
Үрнәк түгел, миннән була —
Бары гыйбрәт алып...

*1993*

* * *

Җир йөзендә тәүге тапкыр
Шигырь туганнан бирле,
Шагыйрьләрне юк итүнең
Ысулы төрле-төрле.
Мәкер-яла белән урау,
Кисү, асу, яндыру,
Йөрәгенә төбәп ату,
Йортсыз-җирсез калдыру.

---

Илдар ЮЗЕЕВ (1933) — *шагыйрь, драматург; татар, башкорт, урыс телләрендә дөнья күргән егермедән артык («Мәхәббәт китабы», «Мәңгелек белән сөйләшү», «Гашыйклар тавы» һ. б.) китап авторы. Ул — Татарстанның Г. Тукай һәм М. Җәлил бүләкләре лауреаты. Казанда яши.*

Гөлдәй сулганнар әзмени
Зиндан эчендә ятып,
Бу дөньядан киткәннәр бар
Үз-үзен асып, атып...
Ядрәсез-нисез яралап,
Газапка дучар итеп,
Түшәгендә сүнгәннәр бар
Туксан-йөз яшькә житеп.
Үкенечкә җыры кала:
Якты, моңлы, борчулы...
Җан авазын юк итүнең
Юк бернинди ысулы!

*1993*

## Читләрнең үз бәясе

*«Татарлар елмаеп үлделәр»...*
Р. ЛАНФРЕДИНИ

*«Иң баштa Коръәнне Алишка суздым...
Ул, акрын гына торып, кулын Коръәнгә
салды һәм елап җибәрде...»*
ГОСМАН мулла сүзләре.

«Татарлар үлде елмаеп...»[1]
Читләрнең үз бәясе.
Биш минуттан — гильотина,—
Килерме елмаясы?
Таш бәгырь булу мөмкинме
Әҗәл янда дәшкәндә,
Милләтнең изге китабы —
Коръән бәхилләшкәндә?[2]
Киткән алар — бу дәһшәткә
Түзәргә кирәк ничек? —
Читләр алдында — елмаеп,
Коръән алдында үксеп...

*1993*

* * *

Кагылма, зинһар, ярама,
Ул хакта сүз кузгатма,
Төзәлмәслек җәрәхәткә
тоз атма...
Сулкылдар, ахры, йөрәгем,
Азга түгел, озакка,
Әрнесен, янсын, дөрләсен,—
боз атма...

---

[1] Җәлилчеләрнең ничек үлемгә барулары турында канатлы һәм бераз сәеррәк яңгыраган бу сүзләр мәгълүм истәлекләрдән алынган. *Ред.*
[2] Яңа табылган истәлекләрдән (Әнвәр Айдагулов һ. б.).

Сыгылсам да түзәрмен мин:
Вөжданым саф, йөз акка,
Егылмамын корган ауга —
тозакка.
Беркем дә сизмәс хәлемне:
Сабырлыгым — йозакта.
Әрнүләрем — гомерлеккә,—
озакка.
Бикле ул йозак ачылмас,
Бер генә дә сүз әйтмә.
Сорыйм: калдыр ялгызымны,—
озатма...

*1993*

* * *

Мин гашыйкмын, юллардагы
Карларга гашыйк,
Язлар килсә, елгадагы
Ярларга гашыйк,
Яр буенда дулкынланган
Талларга гашыйк,
Салмак агып, уйга салган
Салларга гашыйк,
Салларга карап калучы
Ярларга гашыйк,
Шушында бәхет табучы
Парларга гашыйк,
Сүнгән дәртне уятучы
Таңнарга гашыйк,
Табигатьне яратучы
Җаннарга гашыйк...
...Күзәт мәңгелек агышын,
Ярларга басып,
Гүзәл мизгелләр сагышын
Карарга ашык...

*1993, октябрь*

## Уйныйк әле быргыларны...

*Рифкать Исрафилга*

Йоклый вөждан, йоклый әхлак,
Йоклый акыл, саф мәхәббәт.
Ил йөзеннән сөрелгәннәр
Хозер Ильяс һәм Мөхәммәт.
Табигатькә хыянәтме?
Сулар качты, оят качты.
Ахыр заман — кыяматме?
Күңелләрне шайтан басты.
Йөрәкләрдә — боз катламы,

Кан аңкытып исә җилләр,
Кем коткарыр бу афәттән?
Илгә кирәк исрафиллар![1]
Бер гөнаһсыз булмасак та
Һәр гамәлдә, һәрбер эштә,
Булыйк сәнгать дөньясында
Исрафилдай бер фәрештә!
Уятыйк без туң мөхитне,
Җаны барның — моңы чыгар.
Булыйк сәнгать дөньясында
Исрафилдай быргычылар!
Уйныйк әле быргыларны,
Шайтан китсен башын иеп...
«Без барында күңелләргә
Кыямәт көн килмәс!» диеп,
Уйныйк әле быргыларны!

*1991*

## Табиб дустым ядкаре

*Фән докторы Әсфат Абдуллин истәлегенә*

Чыныккан җан булгангадыр,
Күнеккән идең тәмам:
Кая барсаң — каршы алды,
Озатып калды Яман.
Күпмеләрне йолып алдың
Яман чир зәхмәтеннән,
Йөзеңдә нур балкыр иде
Исәннәр рәхмәтеннән.
Чигенергә мәҗбүр иттең
Куркыныч яман чирне,
Тик дәвалый алмадың шул
Шәфкатьсез яман чорны.
Син — илләрдә, син — телләрдә,
Дәрәҗә — зур, киң — күңел...
Йоклый алмый көндәшләрең:
«Ни өчен ул... мин түгел?!»
Аларның хәйлә, мәкере
Үткәндер үзегенә.
Берәүгә дә сиздермичә,
Йөрәк ул түзә генә.
Кая барсаң ияреп йөргән
Көнчелек һәм хөсетлек...
Бер көнне без йөрәгеңнең
Ярылуын ишеттек.
Синең кебек изге затны
Инде кайлардан табыйк,
Күпләр гомерен озайткан
Кыска гомерле табиб?
Югалттык сине, авыр хис

[1] Исрафил — мөселман ышануынча, кыямәт көнендә сур — быргы өрү өчен билгеләнгән фәрештә.

Йөрәкне телә һаман.
Озак яшәргә ниятләп,
Озатып калды Яман...

*1992*

* * *

Безме? Без ул — яшь чакларда
Җирне туп итеп ордык,
Айга да «шлем кидердек»,
Кояшны буйсындырдык.
Барабан һәм күкрәк кактык:
«Килсә дошман теш кайрап,
Бездә, бездә — бүрек белән
Бәреп егарлык гайрәт!»
...Хәзер: «Ярый, Кояш бар!..» дип,
Сөенеп уянабыз,
Шлемсыз гына йөрүче
Айдан да оялабыз.
Читләр, бәлки, кызганасыз
Безнең хәлне күреп, сез?
Өлкәнәйдек, калдык хәзер
Ыштансыз һәм бүрексез.
Бу тормышны, табигатьне
Хәзер ничек көйләргә?
Калсын безнең җүләр яшьлек
Гыйбрәт итеп сөйләргә...

*1992*

* * *

Минем юаш табигатем
Сезгә бик ошый кебек...
Сез-бүреләр арасында
Мин яшим поши кебек.
Тик белегез: мин бик сизгер,
Тиз генә тоталмассыз,
Тешегезгә эләксәм дә,
Кабарсыз, йоталмассыз!
Сез йөрисез өер белән.
Мин бит үзем... бер үзем...
Тотсагыз да, йотсагыз да,—
Җирдә калыр... мөгезем!

*1993*

* * *

Нигә минем баш очымнан
Узып бара бу болыт,
Каян килә, кая бара
Кызыл-кара бу болыт?
Кемнәр миңа хәбәр бирә
Сискәндереп, таң булып,
Дөньядан шәһит киткәннәр
Йөри мәллә җан булып?
Ник килә бу кызыл болыт,
Карасына тагылып,
Яумас микән безнең башка
Кызыл-кара кар булып?
Караңгы көн, шомлы болыт,
Уем китте тагылып,
Кая барыр, кайда явар
Кызыл-кара бу болыт?..

*1993, октябрь*



## Әхсән Баянов

# УРЛАНГАН АЙ

ПОВЕСТЬ

*Жилле төндә җен-пәриләр*
*Күк капусын ачтылар.*
*Күк капусын ачтылар да*
*Айны урлап качтылар.*

Беренче бүлек

Бала чакларын сагынмаган кеше буламыни.

Әмма яшәүнең иң чыны — үз рәвеше һәм үз төсләрендә күренгән ялгансыз мизгелләр шундый кыска ара белән чикләнер дип кем уйлаган!

Җиде яше тулып җитмәгән кыз бала илле җидесе тулып узган апа хәтерендә әле дә очынып йөри. Кечкенә шәһәрнең авыл урамы шикелле ямь-яшел чирәмендә яланаяк йөгерә кыз бала. Йөгерә-йөгерә уйнап туйгач, велосипед дигән ысул белән сикергәләп, өенә кайта. Анда аны яңа сөенеч көтә.

Бер урынына өч басып кайтып керсә, өйдә — кунак! Бусагадан узышлый ук: «Дәү әти!» — дип пайпылдаган кызчык, кунакны кочаклап ала да, аннары аның күкрәгенә сыена. Билгеле инде, дәү әтисенең дә шатлыгы эченә сыймый. Сөекле оныгын күтәреп үк ала да, шапылдатып-шапылдатып сөя. Сөеп туйгач, яңадан идәнгә бастыра һәм җәһәт кенә өстәлдәге төенчегеннән йомырка чыгара — кызарып пешкән чия төсле йомырка. Шуны эләктергәч тә түбәсе күккә тиеп, кабат чыгып чабарга җыенган кызны дәү әтисе туктата:

— Ашыкма, кызым, тагын күчтәнәч бар. Исең китмәле тәмле кәнфит. Хәзер...— дип, кесәләрен кармаларга керешә.

Теге кесәсенә керә, бу кесәсен актара — таба алмый, янәсе. Озаклап актара, озаклап эзли. Бала сабырсызлана. Сабырсызланып, дәү әтисенең кулларын күзәтә. Юк кына бит, чыкмый гына, табылмый гына теге ис

---

Әхсән БАЯНОВ (1927) — *әдип. Дистәләгән проза һәм шигырь китаплары, драма әсәрләре авторы. Казанда яши.*

китмәле кәнфит. Кызның сөмсере тәмам коела, дәү әти үзе дә кара кайгыга бата. Нишләмәк кирәк.

— Кая гына куйдым икән, бигрәкләр дә шәп кәнфит ие. И-и, төшеп калды микәнни? И-и, хараплар гына булган икән.— Үзе һаман кесәсен айкый.

Түземе төкәнгән бала, авызын мелт-мелт итеп шыңшый башлагач кына, искиткеч зур куаныч:

— И-и, менә ләбаса, менә бит кайда гына икән — шушы кесәдә генә. Менә ул, мә, кызым!

Искиткеч дигән кәнфит — чуклы-чуклы, аллы-зәңгәрле, сарылы-күкле кәгазь белән төрелгән карандаш. Үзе карандаш, үзе кәнфит. Үзе уенчык, үзе ризык. Менә ичмасам чынлап та искитмәле күчтәнәч! Менә ичмасам шатлык өстенә шатлык. Ихлас күңелдән куанган кыз баланың бая гына еларга җитешкән йөзе, секунд эчендә үзгәреп, кояш төсле балкый. Сөенечен ул башка кызлар белән бүлешәчәк. Дәү әтисе килгәнне әйтеп, аларны да шатландырачак. Урамның бәхете бермә-бер артачак.

Шулай, дәү әти килеп бер көн кунак була. Тыныч кына, күңелле генә бер көн кунак булгач, икенче көнне, кызның терсәкләре, җиң очлары ямалган шакмаклы күлмәгенә карап, әйтә бу:

— Бик фәкыйрь яшисез, минем кызыма әйбәт кием дә бик эләкми икән. Бирегез минем кызымны үземә. Менә дигән итеп үстерермен,— ди.

Дәү әтиләренең тормышлары нык. Минзәләдән ерак түгел, Ык буенда дүрт ташлы тегермән. Шунда дәү әти тегермәнче ярдәмчесе. Авылда унике бүлмәле, ике катлы йорты... Кызга анда начар булмас. Аннары бит чит кешегә түгел, дәү әтисенә китәсе. Шуны уйлап, бирде кызны әнисе. Киттеләр — ямьле Ык буена, ике катлы йортта торырга. Авылга.

Анда дәү әтинең сеңлесе һәм аның өч ятим кызы (әтиләре вабадан үлгән) тәгәрәп йөри. Тамаклары тук, өсләре бөтен. Әмма аларны беркем карамый — барысы бергә тегермән әтләре хокукында сикерә-йөгерә үсәләр. Кая теләсәләр, шунда баралар. Буа артында турбина янындагы кайнап торган суга сикерәләр, кысла сөзәләр, тегермәнгә килгән төрле авыл кешеләренә ат коендырышалар. Ирекле, хөр тормыш.

Кыен ягы шул: дәү әти «хуҗа» дип зурлап атаган, күрше йортта торган бер абзый хатыны белән тату яшәми — бер дә юктан тавыш чыгарып, гел талашкан, ырлашкан көннәре. Берсендә бигрәк каты кычкырыштылар. Куыша-куыша дәү әтиләр өенә керделәр дә, җиде төн уртасында тып-тыныч йоклап яткан кешеләрне аягүрә басарга мәҗбүр итеп, чарыйчарый кычкырышырга, тарткалашырга, сугышырга керешә болар. Кызлар, алардан куркып, йоклаган җирдән сикерешеп тордылар да урамга чаптылар. Урамда кышкы төн. Чыпчык очса чыпчык куырылып җиргә егыла торган суык. Шундый салкын төндә яланаяк килеш карга бата-чума, йөгерә кызлар. Ярый әле, бераз баргач та — авыл. Авылның өенә барып та керәләр. Хуҗабикә балаларны мич башына менгереп җибәрә дә кулларына таяк тоттыра. Ә ник дигәндә, анысы соңрак беленә. Йоклап китә язгач, якында гына, кәбәркәдә генә — чи-чи килгән тавыш. Комаклар! Сикерешә, диварга ыргыла, мич башына менмәкче булып очыналар. Күрәләтә аларга азык буласың килмәсә, саклана бел. Һәм балалар, рәтләп йокламыйча, төн буе шул комаклар белән сугышып чыгалар.

Иртән иртүк дәү әниләре пималар күтәреп килеп җитә — өйгә алып китмәкче дә... Тик кызлар: «Кайтмыйбыз, кайтмыйбыз»,— дип чыр-чу килмәс диген. Тычкан-күсе белән сугышып яшәргә ризалар, ә җәнҗал күтәргән кешеләрне күрергә теләкләре юк боларның. Һәм тиз арада сабыйлар күңеленең дөрес сизенгәнлеге расланды, гонаһ шомлыгы.

Озак та үтмәстән, әлеге кычкырыша торган абзый белән апа күп итеп кунак җыйдылар. Ә балалар аларны күзәтә, тамаша кыла. Аңлашылмый торган телдә җырлый, бии, кычкыра, котыра кунаклар. Җырлый-җырлый, бии-бии, кычкыра-кычкыра, котыра-котыра аргач, йоклар-

га ята болар. Безнең җиде яше тулып җитмәгән кыз бала да өйгә кереп ята — ишек төбендәге тәрәзә янына, сандык өстенә. Тиз арада кыз йокыга да чума. Йокының иң каты чагында, җиде төн уртасында... Һич аңга сыя торган нәрсә түгел — тәрәзәгә кайсыдыр лом белән шул хәтле каты итеп тондыра ки, бөтен тәрәзә торган җирennән кубып, пыялаларының бөтен ватыклары кыз өстенә ишелеп тә төшә. Нәкъ менә шул хәерсез төннән башлап, ул үзгәрде һәм берүзе ике кешегә, ике төрле кешегә әйләнде дә инде.

Көндезләрен кайда да булса сулы чиләк күрсә, чиләкне ала да үз өстенә коя. Үзе дер-дер килә, калтырый. Төнлә исә, йоклаган килеш торып, өй буенча йөри. Тәрәзләрне ача, ихатага чыга. Өй түбәсенә, абзар башларына үрмәли...

Шушы чире беленгәч, кызны дәү әтисе кире үз өенә илтеп куйды. Ләкин анда хәл һаман элеккечә — атасыз өйдә байлык артасы түгел. Әнисе Гөлсара кызын үзенең Ерыклы дигән авылда яшәгән сеңлесенә илтергә мәҗбүр булды.

Нәгыймә атлы апа йомшак табигатьле, укыган кеше икән. Катылыгы бер генә яклап сизелде — кызны мәҗбүриләп укырга урнаштырды. Күрше авылдагы остабикәгә илтте. Абыстай татарча, урысча гына түгел, гарәп теле грамматикасын да укыта иде. Гарәпчәне бүтәннәр әйбәт үк укымый, ә безнең кызны укытучы апа: «Гарәп хәрефләрен, гарәп сүзләрен тиз отасың икән, бигрәк зиһенле икәнсең»,— дип, мактап туя алмый.

Мәгәр Нәгыймә апага кунак кыз белән тору бәйрәм түгел иде шул. Кыз һаман төнлә йоклаган килеш торып йөри, бикле ишекләрне, тәрәзәләрне ача, шкафлардан савыт-саба алып, аларны еш кына вата. Өй түбәсенә менеп, түбә кырыйларыннан — кәрниз өсләреннән атлый.

Шулай да Нәгыймә апасы, кардәш сеңлесенең начар ягына түзеп, әйбәт гадәтләрен хаклап, бишенче классны тәмамлаганчы исән-аман саклый. Бишенче класстан соң, шәһәрдә укысын дип, аны янә үз әнисенә кайтара.

Пароход белән кайталар. Иделдә төн. Нәгыймә апасы йокыга талгач, кыз пароходның иң өске катына — капитан күперчеге янына менеп, түбә кырыйлап атлый. Алдан артка таба, мөгаен, Айга таба. Күпмедер генә адым кала һәм кыз, күккә дип, су төбенә очачак!

— Тревога!

Капитанның кискен авазыннан уянган матрослар дәррәү рәвештә палубада җыелалар. Бирелгән боерыкларны үтәп, кем суга сикерергә әзер, кемнәрдер капитан янында кызны күреп, күз ачып йомган арада диярсең, кызны эләктереп тә ала...

Бу чирне кыз үзе теләп алмады. Бу чиргә аны язмыш үзе дучар итте. Аннан соң күпме сулар аккан, күпме гомер үткән. Чир инде күптән узган, онытылган кебек иде. Ләкин алай ук түгел икән. Ул бала чакта гына түгел, бөтен гомере буе ике кеше булып, ике төрле яшәгән икән ләбаса. Шушы хәл инде гомерне йомгаклый төшәргә, башкарылган эшләргә нәтиҗә ясарга һәм алардан канәгатьлек тояргa вакыт җиткәч билгеле булыр дип, кем уйлаган, кемнәр генә уйлаган бит!

Шушы аяу белмәс, шәфкатьсез хакыйкатьне — кем диген! — бердәнбер улы, сөекле улы аңлатыр, дигән уй анның башына бер генә тапкыр кереп караса икән лә!

## Икенче бүлек

Илле җиде яше тулып узган ананың сөекле улы — соңгы курсны тәмамлап килүче студент — институттан кайтып килә иде. Урам чатыннан узышлый аңа эндәштеләр:

— Миша, Миш!

Борылып караса, артында — дуслары — Гайса белән Костя басып тора. Урамның уртасына җиткән Миша, капыл борылып, иптәшләре янына килде. Очрашу шатлыгыннан көлешеп, кулбашларга суккалап күрештеләр.

— Нишләп әле син безне күрми башладың, ә?

— Гафу, җилкәдә күз юк. Үзегез дә атна буе сәлам дә бирмисез.

— Кичә сугылган идек, Анна апа, әллә кертәсе килмәде, сине өйдә юк диде.

— Кызыклырак идея бар мәллә?

Костя дигәннәре, арада бер-ике яшькә зуррак булу сәбәплеме, тәкъдимнәрне күбрәк ул кертә яки, башкалар тәкъдимен дә, гадәттә, хәл итүче ул була иде. Гадәт буенча сүз көтеп, Миша аңа текәлде. Костя, Гайсага күз кыскан булып, боргалана янәсе:

— Әйтик микән? Әллә...

— Әйтәсегез килмәсә, үзегезгә карагыз.

Борылып китә башлаган Мишаның җиңеннән эләктерде Костя:

— Яле, ул хәтле кәнфитләнмә, кызлар шикелле.

— Сөйләшәсегез килмәгәч...

Ясалма бәхәсне өнәмәгән Гайса ачыклык кертергә тиеш табып:

— Сөйләшәсебез килмәсә, махсус эзләп йөрер идекме? — дигәч, Миша тын калды.

Һәм шул рәвешле, Костяга тәкъдимен туп-туры ярып салудан башка нәрсә калмады. Ике дустының да җиңнәреннән тартып, аларны юл читеннән дивар кырыена китергәч, серенең иң кадерлесен диярсең, ярым пышылдап, Костя дус шуны хәбәр итте:

— Минем предоклар бүген шәһәрдә куна. Бакчада — аулак. Борын башына — берәр ярты. Йә, ничек? — Ихлас елмайган Мишага күз ташлагач, тагын шаяртырга тиеш тапты: — Шунлык кына рәтегез бардыр ич? Һич булмаса, Анна апаның чүлмәген ачып карарсың. Ә?

— Сезнең өчен андый гына югалтуга түзәрбез. Шулай бит, Иисус?

Гайса боларга караганда фәкыйрьрәк гаиләдән — мәктәптә җыештыручы булып эшләгән тол хатын улы булганга күрә, шаяру төсле әйтелгән сүзләрнең чын дөреслек икәнен белгәнлектән, чак кына кызарып куйды һәм шаяра алмыйча:

— Анлык кына стипендиядән калганы бар, — дип, сер бирмәскә мәҗбүр булды.

Сүз шуның белән тәгәлләнде дә. Кичке алтыда шушы ук урында очрашырга сүз куешып, һәркем үз юлын дәвам итте.

Мишаның, татарча әйткәндә, Мәлихнең корыны бушка әйләндереп кенә йөргән көне иде. Берүзе киногa кереп чыкты. Кайтышлый кибеткә керде. Гомумиләп әйткәндә, аның кесәсе болай юка түгел, дуслар белән очрашканда гына буш калгалый. Сәбәпләр шундый: аның әтисе районның эчке эшләр бүлеге башлыгы, әнисе — күренекле укытучы. Ай саен йөзәр сум акча биреп яисә җибәреп торалар. Масаерлык булмаса да, интегерлек тә түгел. Хәтта менә берничә ел инде, кичләр буе, ә кайчак исә төннәр буе карта уйнарга мөмкинлеге бар аның. Карта уйнарга сүз куешкан көннәрдә Мәлихнең йөрәге ярышка чыгасы аргамак шикелле җилкенеп тора.

Мәлих белә: аннан да дәртлерәк уенчы булса, шул Костя гынадыр. Күбрәк ул ота. Мәгәр Мәлихнең дә бирешәсе килми, аның да откан чаклары булмый түгел. Җиңүгә ешрак ирешү, өстенлек алу өмете көчәя бара. Бакчадагы аулак өй бүген, элдан бигрәк, әнә шул өмет аркасында күңелне алгысыта да инде. Көннең нинди матур сәгатьләре, күзгә күренмичә, акрын, бик тә акрын уза. Офыкка ашыкмыйча гына төшкән кояш ягына карап, Мәлих, ниһаять, иптәшләре янына юл тотты. Костя да ашыккан, очрашу урынына ярты сәгать алдан килгән иде. Гайса гына көттерде — нәкъ вакыты җиткәч кенә күрсәтте үзенең нурлы йөзен. Юньсез. Ике дус өченче дусны җиңелчә генә булса да шелтә белән кар-

шыламыйча булдыра алмадылар. Әмма Гайса: «Соңга калмадым бит»,— дигәч, сәбәпнең кичерерлек икәнлеге искә төшеп, әрепләшмичә генә, автобус тукталышына ашыктылар.

Бакча дигәне Кама елгасының искиткеч матур тугаенда иде.

Юлдан да, елгадан да ерак түгел. Хозурланасың килсә, дөнья күз алдында бөтен киңлеге һәм гүзәллеге белән ачык. Ләкин моның өчен дусларның вакыты тар. Автобустан төшкәч, шулай ук ашыга-ашыга атлап, бакчага барып та җиттеләр һәм тимер капка аша уздылар. Костя өй каршында үз эше белән мавыккан каравылчы абзыйга якын танышлар рәвешле сәлам биргәч, уңга борылдылар. Костялар дачасы капкадан соң ерак та түгел икән. Башта тимер рәшәткәле челтәр капкадагы йозакны, аннары ишек аркылы сузылган озын келәсе өстендәге асылмалы йозакны чылтырдатып ачкач, Костя тантаналы рәвештә кунакларның өй эченә рәхим итүен үтенде. Нәкъ зурларча, чын әдәп кагыйдәләре кушканча.

— Урнашыгыз, җаныгыз теләгәнчә. Үзегезне өйдәге кебек хис итегез.

Мәлих дачаның матурлыгы, ныклыгы һәм иркенлегенә таң калып дияргә кирәк, бер почмактан икенчесенә ташланды. Һәр бүлмәгә кергән саен бер җөмләсен кабатлый торды:

— Кара син боларны! Ну яшәп тә карыйлар икән. Хрущевның үзеннән һич ким түгел, валлаһи! Хрущев кызлары кебек, Кара диңгезгә төшке аш алдыннан су кереп кайтыр өчен самолетларыгыз да бардыр әле. Дөньяда иң зур урын эчке эшләр бүлеге начальнигыныкы дип йөрсәм, бөтенләй чепуха икән. Иң зур кеше — ул ресторан директоры икән, валлаһи, билләһи.

Шундый ук сүзләр белән өске кат бүлмәләрне әйләнде:

— Все это гениально хорошо. Минем әти генә ялангач большевик килеш калды. Бакчасы юк та юк, өендә дә футбол кырыдай бушлык. Анна апаның өе аныкыннан баерак, билләһи.

Баскычтан Мәлих шундый мәдхияләр белән төште. Мактау сүзләреннән авызы ерылган Костя:

— Сиңа ошагач, мин бик шат. Ярый, рәхмәт,— дип, зал уртасында сүзсез-хәрәкәтсез басып торган, каушап сөмсере коелган Гайсага ишек төбеннән эндәште:

— Сиңа ошамый әллә, Иисус? Нишләп телеңне йоттың? Ә-ә, сиңа завидно!

Гайса гаепле кеше сыман башын иде. Җитмәсә, Мәлих дус Костя сүзен җөпләгән була тагы:

— Конешно завидно, даже миңа.

— Ярый, рәхмәт. Өйдәгез, матурлыкның тәмен дә татып карыйк. Бераз закуска табыйк.

Шул ният белән бакчага чыктылар. Редиска, суган йолыкканда, Мәлих мондагы матурлыкларга да соклануын тыя алмыйча, баягы төслерәк такылдый бирде:

— Нинди идеаль тәртип! Чисталык! Нинди купшы булып алмалар чәчәк аткан. Ну, алма пешкәч, тагын бер чакырасың инде, Костя. Шулай бит?

— Тәртибегез шәп булса, карарбыз.

— Тәртибебез «биш»ле булачак. Шулай бит, Иисус?— Гайса җавап тапканны көтмичә, үзе дәвам итте: — Иисустан зарланасы юк. Тәртип — аның иң зур козыре. Шулай бит? Иң зур байлыгы.

Гайса өчен бу юлы Костя җавап бирергә ашыкты:

— Әлбәттә, һәркем үзенчә бай.

Бу сүзләрдән соң Гайса тәмам боекты. Сүзне икенчегә бору өчен ишек янындагы юынгычны тикшереп караган булды. Суы юк икән.

— Чиләк тапсак, мин су алып килер идем.

— О, молодец. Кухнядан үзең тап инде, шунда күз алдында гына ул.

Чиләкне, чыннан да, интекмичә генә табып, Гайса бакча урамына юл тотты. Моторлы кое ерак түгел икән. Сәдәпкә генә басасы. Ике-өч

баланың уенчык чиләкләр белән шунда су алып азаплануын күргәч, үзләренчә аларның бик зур мәсьәләләр хәл итеп мәш килүен бераз вакыт күзәткәч, Гайсаның күңеле күпмедер дәрәҗәдә күтәрелә төште. Уенчык чиләкләрнең су белән тулуын зур сабырлык белән рәхәтләнеп көтте Гайса. Сабыйларның үзләренчә бик җитди кыяфәт белән китеп барганын елмаеп карап калды. Шуннан соң гына үз чиләгенә су алды. Дуслар янына инде ул шактый төзек кәеф белән кайтып керде.

Редиска белән суган чистартуны үз өстенә алды. Костя пычак белән бер кәстерүл чыгаргач, эшкә дә тотынды. Редисканың яфрак-койрыкларын, суган тамырларын кисү ләззәте аның бая җимерелә язган күңелен тәмам тынычландырып, тиешле биеклеккә көйли алды. Өйгә ул яшелле-кызыллы чип-чиста ризык кына түгел, әйтерсең, шул төсләр сирпеп торган сөенеч тә алып керде. Ихлас елмайган хәлдә, савытларны өстәлнең нәкъ уртасына китереп куйды. Иптәшләр дә тик тормаган — аның керүенә өстәл түренә өч шешәне чыгарып бастырганнар, ипи кискәннәр һәм берәр рюмканы күтәреп тә өлгергәннәр. Әмма Гайсаның көйле кәефе мондый вак ихтирамсызлыкка гына игътибар итәрлек түгел иде. Үзенә урындык табып утыргач һәм үрелеп редисканың берсен эләктергәч, аны шатлыклы шатырдатып:

— Шәп нәрсә бит, ә? — дип куйды.

— Әле беркемдә дә юк, бездә генә ул! — дигән горурлык белән Костя рюмкаларга аракы койды.

Мәлих исә:

— Суларны син сипкәнсеңдер инде, — дип, дуска мактану өчен тагын бер җай тудырмакчы иде дә, мәгәр хуҗа кеше тост әйткәнлектән, аның алтын сүзе күмелеп калды.

— Әйдәгез, уңышлы имтиханнар хөрмәтенә, — дип, хуҗа рюмканы гадәттәгедән югарырак күтәрде. — Бер атнадан — безнең страда, страданиелар. Киттек.

— Мин монысына риза. «Биш»ләребез күбрәк булсын, — диде Гайса.

— Бишләләр күп булса, каршы килмәбез анысы. Тик ансыз да яшәп була, диплом гына бирсеннәр.

Бу сүзне Мәлих, кемнең ничегрәк укыганын җәһәт исенә төшереп, Костя тегермәненә су кояр өчен әйтте. Һәм, әлбәттә инде, Костя аны җөпләргә ашыкты.

— Дөрес, Гайса кебек «биш»ләләр артыннан куу безнең максатка керми. Повышенный стипендиясез дә яши алабыз. Ә иң главное, отличнога укыган кешеләр тормышта «ике»легә яши торган була, ди безнең әти.

— Мин монысына да риза, менә шушылай яши бирегез, — Гайса «шушылай» дигәнен әйткәндә, сул кулы белән өйнең дүрт ягын күрсәтеп, янә редискага сузылды.

— Сүз бетте, егетләр. Соңгы сессия хәерле бетсен өчен.

— Бетүе хәерле.

— Мин монысына да риза, шуның хөрмәтенә...

Үзенә күрә бәйрәмчә булган шундый гәптән соң бер шешәне матур гына бушатып та куйдылар. Аннары, Костя тәкъдиме белән верандага чыгып, преферанс уены өчен түгәрәк сызгаладылар да, һәм... башланды мәҗлеснең көн тәртибендәге төп мәсьәләсе. Тиешле биеклеккә җиткән кәефне бер кимәлдә тотар өчен залга керә һәм чыккалый торгач, әкертен-әкертен өченче шешә дә бушый язды. Кимәлнең киму мөмкинлеге аларны алга карап эш итәргә куша иде. Әле бит сәгать алты гына тулып килә. Көн бетмәгән, кич җитмәгән. Хәзердән хәстәрен күрмәсәң, озын кичнең караңгы һәм күңелсез узуы ихтимал. Бакчадан күп дисәң бер чакрым җирдә — поселок. Шундагы кибеттән тагы һич югы бер шешә алып килергә кирәк иде.

Гайса карта уенын юньләп белмәгәнлектән, почмактагы диванга кунаклап, тыныч кына китап укып, читтәрәк утыра иде. Билгеле инде,

эшсез утырган кешегә эш табу — үзе бер игелек. Ике дус аңа бер шешәлек акча суздылар да тегесе бик ялындырмый гына дүртенче шешәне дә алып килде.

Анысын киметү гамәленә Гайса катнашмагангамы, әллә элеккеләренең гайрәте беләнме, егетләрнең бу шешә тәэсиреннән телләре көрмәкләнә башлады. Запасның төкәнүе икенче кабат сизелгәндә, сәгать тугыз тулып, караңгы да төшкән иде инде. Кибет бу чакта — бикле. Хәлгә керерлек дус-иш монда юк. Ми сырларын селкетеп карарга туры килде: нишләргә? Ничек итеп кútәренке кәефнең югары дәрәҗәсен сакларга? Бичарадан ни чара? Уйлана торгач, Мәлихнең хыялы үткенрәк икәнлеге ачылды.

— Эврика! Булды, җай бар!

Гайса сагаеп, Костя сөенә язып, хыялга бай дуска карадылар. Костя урыныннан ук сикереп торды.

— Чынлапмы?

— Баш эшләсә, котылып булмый торган бәла юк.

— Соң, әйт алайса, нәрсә боргаланасың?

— Сез риза булмассыз дип куркам.

— Без барда курыкма. Выкладывай, нинди җай?

— Шушы бакчадан табабыз.

Моны ишеткәч, кул селтәп, Костя Гайса янына ук күчеп утырды.

— Тапкан ди берәү.

— Утлары кабынмаган йортлардан табып була бит?

— Булса ни?

— Ут кабынмаса, хуҗалар юк дигән сүз. Аларга кереп була, дигән сүз.

— Ә аракы?

— Кайсы өйдә булса да табылачак.

— Соң бар, тап та кил. Без риза, шулай бит, Иисус?

«Иисус» кул гына селтәп, аркасы белән үк борылып утырды.

— Нәкъ менә мин, нәкъ менә син дигән кеше юк бит әле. Иң чын гаделлек белән хәл итәбез аны.

Шушыннан соң Мәлих җәһәт кенә шырпы кабы әләктерде дә, читкә борылып, нәрсәдер сихерләргә керешге. Башын бер иеп, бер күтәреп, бераз азаплангач, дусларга борылды:

— Менә, кайсыбызга кыска шырпы чыкса, шул бара.

— Кая?

— Кая димени, утсыз йортка.

— Ишек җимерергәме? Тәрәзәме?

— Барган кеше үзе белә инде. Кирәксә, әфсен укысын.— Костя уйланып торган арада Миша аның йөрәгенә ялкын өстәргә ашыкты:

— Бармасак, аулак өй бетте. Шәһәргә элдерәбез. Әйдәгез.

Караңгы почмактан Гайсаның:

— Иң дөресе шул булачак! — дигән тавышы яңгырады.

— Карагыз, хәл итегез. Яки менә — шырпы, тартып чыгарыгыз.

— Әй лә, беткән баш беткән!

Костя кинәт сикереп торды да ут кабызды. Һәм тиз генә килеп, Мәлих кулындагы каптан өч шырпының берсен тартып та чыгарды. Шырпы озын иде. Шуны күргәч, Костяның тавышы тагын да көрәя төште:

— Әйдә, Иисус, синең чират.

— Мин мондый уенны уйнамыйм.

— Ниче-е-к!

Ике дусның берьюлы чәчләре үрә торды.

— Син. Ә син кем соң әле шул хәтле? Давай, шаяртма, тарт.

Икәүләп шактый ялынгач, аннары куркыта, яный торгач, һәм алай да файда чыкмагач, ниһаять, Гайсаның егетлек намусына кагылырга керештеләр:

— Трус несчастный, кем белән дус булып йөргәнбез бит, ә?

Шактыйга сузылган ярсу әйткәләшләрдән соң, Гайса ачудан, гарьләнүдән исерек адәм шикелле ярсыган иде инде. Икесенең каршына килде дә фикерен икесенең битенә берьюлы органдай, кискен итеп әйтте:

— Сез нәрсә, мине үзегез ише мародер дип беләсезме әллә? Карак дип, бандит дипме? Уйламагыз, мин сезнең ишегез түгел.

Костя белән Мәлих, айныгандай булып, чигенеп куйдылар. Беренче җавап Мәлих авызыннан чыкты:

— Әле шулаймыни? Без бандитлар, мародерлармыни! Карагыз сез аны — нинди матур сүзләр белә! Отличник! Яле, Костя, сорап кара әле, үзе кем икән ул?

Дустының ни уйлавын тиз төшенгән Костя, һич көттермичә, Гайса янына килде дә, бераз тын торганнан соң, шундый ук тынычлык белән аның колак төбенә кундырды. Гайса башта өнсез калды. Аннары шашкандай:

— Ерткычлар, бандитлар! — дип кычкырып җибәрде дә ишеккә ташланды.

Ычкына алмады — ике яктан ике дус эләктереп алдылар. Яңадан эчкә өстерәп керттеләр дә бая үзе утырган почмакка китереп бастырдылар. Гайса нишләргә белмичә торган арада баягыча ук тынычлык белән, бөтен нәфрәте тупланган таш йодрыгы белән, Костя аның икенче колак төбенә тондырды. Гайса гөрселдәп диванга каплангач, өстерәп аны идәнгә егып салды. Һәм аягы белән касыгына басты:

— Барасың. Барасыңмы, юкмы? Барасың!

— Хәшәрәтләр, ерткычлар!

Костя, инде нишлибез, дигән сорау белән Мәлихка карап алды. Тегесе кул белән ишарәләп:

— Хәзергә җитеп торыр. Аңларга нияте сизелми. Икенче төрле аңлатырга туры килә, — диде.

— Ничек итеп?

— Чынлап түгел, уйнап, яратып — дусларча. Гайса начарлык белән әйтелгәнне аңламый ул.

— Аңлатыбрак сөйләш дим мин сиңа.

— Сезнең мич артында мин бокс перчаткалары күргән идем. Син боксер бит.

— Бераз.

— Безгә күбе кирәкмәс тә, азы җитәр. Алып кереп буламы шуларны? Ике пар.

— Ничек булмасын ди, була.

Шул сүзне әйткәч, Костя зал ягыннан ашыкмыйча гына бокс перчаткалары күтәреп керде дә дустына текәлде. Нишлибез, янәсе. Сүзсез сорауны аңлаган дус нишләргә икәнен әйтмичәрәк калды. Костя перчаткаларны диванга ыргыткач, өстәл янына килеп, аракының калган өлешен ике чәй йомрысына бүлеп салды да:

— Исән булыйк! — дип, бер йомрыны дустына сузды.

Кабымлыкка куелган суганны шатырдатканда чырайларындагы баягы явызлык сүрелә төшкәндәй тойган Гайса, бер кулы белән күкрәген, икенчесе белән билен тоткан хәлдә, болар каршына килеп, адәмчә сөйләшмәкче, имеш:

— Бүгенгә җитте бит, булды, тынычланыгыз. Иртәгә мин үзем сезгә куярмын бөтен яртыны.

— Ә безгә бүген кирәк, иртәгә кирәкми. Шулаймы, Костя?

— Билгеле.

— Шушында бетсен. Мин китим. Җибәрсәгез, гафу итәрмен, врачка да бармам. — Бу сүзләрне әйткәндә, Гайса үзенең кан саркып торган авыз-борынын һәм күкрәген каплап куйды.

Мәлих өчен бу кадәресе яңалык сыман тоелып, ул гаҗәпләнүен Костяга күзләрен түгәрәкләндергән рәвештә бәян кылды:

— Кара син моны! Врачка бармакчы. Справка алып, ахирәт дусларын судка чакыртмакчы. Ну баш икән үзеңдә! Менә син аны йөр дус дип. Куеныбызда елан йөрткәнбез бит. Менә сиңа мә!

— Аерылыйк яхшылык белән, ишетәсеңме, Миша? Костя, ишетәсеңме?

— Миша ишетә, Костяның колаклары бар. Шулаймы, Костя?

— Ишеткәч, бик әйбәт. Йә, житте, иртәгә чаклы.

Гайса ишеккә таба узмакчы иде, Мәлихка монысы бөтенләй ошамады. Уң беләге белән юлны бикләп, дустын саксыз гына кире этәрде:

— Монда хәзер бәйрәмнең апогее калды. Син үзеңне шул биеклектән мәхрүм итмәкче буласыңмы?

— Кызыклар шулчаклы күп булды, житте. Моннан артыгы кирәкми дә.

— Кирәк!

Мәлихнең командир кискенлеге белән әйтелгән сүзеннән ике дус та, каушаган сыманрак тынып, үрә каттылар. Командир тагын нинди номер уйлап тапты икән, дип кызыксындылар бугай. Ялгышмадылар да, ахрысы. Мәлих, озак көттермичә, кичәнең «иң кызык» өлешен башларга тиеш тапты. Боксер перчаткаларының бер парын Гайсага сузып, кияргә боерды. Тегесе:

— Мин боксер түгел,— дигәч,

— Хәзер өйрәтәбез,— дип елмайды. Һәм Костяга баш какты.— Әнә безнең мастер, файдаланып кал, өйрәтсен.

Ләкин Гайса перчаткаларны якын да китермичә карыша биргәч, Мәлих Костяны ярдәмгә чакырды. Икәүләп һәм кычкырыша-кычкырыша, көчләп, тәки кидерделәр перчаткаларны. Мәгәр диванга егылган Гайса, перчаткалы кулларын аска яшереп, йөзтүбән капланды. «Өйрәнергә» нияте юклыгын ахыр чиктә шулай аңлатмакчы мескенең. Илла кая ул, Мәлих инде икенче пар перчатканы Костяга биргән дә, аның беләзек бавын бөтен формасын китереп бәйләп тә өлгергән инде. Ике боксер ярышка әзер, судья — Мәлих үзе. Чаң каккан аваз чыгарды судья.

— Кул бирешегез, хәрәмсез сугышырга дип.

Костя, залның нәкъ уртасына килеп баскан да, көндәшен көтә. Көндәш исә диваннан кубарга ниятләнми генә түгел, әйтерсең, боларны ишетми дә, күрми дә. Шул рәвешле, дус-ишне кызык мажарадан мәхрүм итмәкче. Итми генә торсын әле. Мәлихне үз сүзен үтәмичә кала торган кеше дип, ике сөйләшә торган егет дип белә бугай. Күпме гомер дус булып, тәки кемнең кем икәнен белә алмаган. Үзе бит әле отличник, группада иң акыллы, тәрбияле булып исәпләнә. Костяның әтисе бик дөрес әйтә: нәкъ үзе, билләһи, әйбәт укыган кеше тормышта начар яши торган була. Гайса да дуслар арасында үзен тиешле дәрәҗәдә тота белми, киләчәктә болай тиеш түгел, өйрәнә торырга тиеш кеше. Менә, жай чыкканда өйрәнә башласын. Мәгәр үз файдасын үзе белми бит юньсез, һаман кузгалыр нияте юк. Шуңа күрә, Мәлих дусты аның баш очына басып, дусларча диярлек тыныч эндәшә ләбаса:

— Тор, юләрләнмә, уен гына бит, үлмәссең бер уйнаганнан. Кешеләр әле гомер буе рингтан чыкмаска тырышалар. Әйдә, ну! Кемгә әйтәләр? Сиңа әй-тә-ләр! Си-и-ңа-а!

Дустын кочаклап торгыза алмагач, Мәлих янә ярдәмгә Костяны чакырды. Икәүләп тә куптара алмаганга, яңа фикергә килеп, Мәлих яңа команда бирергә тиеш тапты:

— Ярый, жаны теләгән елан ите ашаган, ди минем әни. Хәзер моңа елан ите ашатабыз. Яткан килеш сугышсын! — Шушы сүздән соң ул, ике бармагын авызына тыгып, сызгырды да командасын кабатлады: — Башладык!

Команда катгыйлыгына буйсынган Костя Гайсаның арт санына шундый итеп орды ки, тегесе, мөгаен, үзе дә сизмәстән, капланган жиреннән әйләнеп, кинәт диванга утырды:

— Сез нәрсә, котырдыгыз мәллә?

Костяның беренче «очко»сын кабул иткән судья, кул күтәреп:

— Бөтенесе дөрес, кагыйдә буенча! — дигән хөкем чыгарды һәм тагын сызгырып, ярышны дәвам итәргә боерды: — Көчеңне кызганма, Костя, ничек тиеш, шулай, лупи!

«Ничек тиеш, шулай» булганча, Костя «көндәшенең» ап-ачык яңакларына, күкрәгенә дөпелдәткәндә, мескен Гайса башларын чайкаудан, диванга тагын капланып яңадан торудан, ыңгырашудан башканы эшли алмыйча, үрсәләнүен, боргалануын гына белде. Ике-өч минутлык дөпелдәүләрдән соң исә, бөтенләй хәрәкәтсез калды. Костя шунда гына гәүдәсен турайтты. Судья тарафыннан көттермичә генә нәтиҗә ясалды:

— Беренче раунд — мастер Костя Малышев файдасына, алты — ноль! Нокдаун! Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты...

Гөнаһ шомлыгы диген, шунда үзенә үч иткәндәй, Гайса башын калкытасы итте ләбаса. Торды. Алпан-тилпән атлап, дуслары янына килде. Ләкин, ни хикмәт, Костяны түгел, судьяны тәпәләмәкче. Мәлих этеп җибәргәч егылмаска көче житеп, бөтен ярсуын җыйган хәлдә, янә Мәлихка ташланды. Бер кулыннан перчатка салынган — буш иде. Буш кулы белән Мәлихның күлмәк изүеннән элэктерде дә, уң кулы белән аның башына суккаларга кереште. Гүяки бокс дәвам итә. Мәгәр хәл әллә ни калмаган шул. Һөҗүм итүче үзе тиз арып, аяклары бөгелеп, нәкъ менә яраткан сыман итеп, Мәлихны җилкәсеннән кочаклады һәм шул хәлдә асылынып калды. Күпмедер шулай торгач, Мәлих хәлсез куллардан җиңел арынып, Гайсаны туп-туры итеп бастыргач, икенче раунд игълан ителде:

— Костя, дәвам ит. — Һәм баягы сызгыру. — Йә! Нәрсә, ни көтәсең? Тәпәлә!

Дусты, исереклек аркасында, яман боерыкка буйсынмаска кирәген башына китерә алмастан, нәкъ Мәлих кушканча һәм баягыдан да аяусызрак көч белән Гайсаның болай да канап торган кып-кызыл авызборынына, яңакларына, күкрәгенә, аркасына — кай җире туры килсә, шул төшенә сугарга, дөмбәсләргә кереште. Ләкин «кызык» бик үк озак дәвам итә алмады. Гайса капчык сыман лапылдап җиргә ауды да хәрәкәтсез калды.

— Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун! Нокаут! Намуслы ярыш Малышевның бәхәссез өстенлеге белән тәмам. Котлыйм, иптәш Малышев, зур җиңүең белән!

Мәлих Костяның перчаткаларын тантаналы төстә салдыргач, шушы ук ярдәмне Гайсага күрсәтергә булды — аның сул кулындагы перчатканы салдырып, дивандагысын үрелеп алды да перчаткаларның дүртесен дә күрше бүлмәгә кертеп чыкты. Шуннан соң стакан төбендәге соңгы тамчылар олы ләззәт белән йотылды. Аннары, зур эш төгәлләнгәндәй тынычланып, ымлыклар белән генә аңлашып, таң атканчы диярлек, кәрт белән мавыгып бәхет кичерделәр.

Бервакыт, тәрәзә аша алсу нур җепселләре сузылганын абайлап, баш күтәрсәләр, ни күрсеннәр, — җир өстендә инде таң атып килә ләбаса!

Күзләре идәнгә карыйсы итсә — һичбер хәрәкәт-мазар сиздермичә, Гайса ята бирә!

— Нокаут озаккарак китте түгелме? — дип Костяга сүз кушты Мәлих һәм карталарны җыйды.

— Нинди нокаут булсын, йокы симертә. Ә-эй, житте сиңа. — Шулай дип, Костя Гайсаны селкетеп куйды.

Гайса селкенмәде.

Костя аның сулышын тыңлап карады — терелек галәмәте сизелмәде. Шунда гына эшнең кай дәрәҗәдә икәнен төшенеп, күзләре шакмакланды. Беравык телсез калдылар. Йокыданмы, махмырданмы арынырга тырышкандай, Мәлих күзләрен, битләрен угалады, җилкәсен ышкыды. Ниһаять, ул елапмы, ыңгырашыпмы, көч-хәлгә сүз укмаштыра алды:

— Костя! — Ачыргаланып әйтелгән шул бердәнбер сүзнең мәгънәсе шул гына иде: «Нишлибез?»

Бу чакта аның кичке зирәклеге, төнге кыюлыгыннан җилләр искән иде. Боерыклар бирү түгел, ул инде үзе әмер көтә, һич югы — акыллы сүз, һич югы — киңәш. Юк бернинди сүз, киңәш ишетелмәде. Киресенчә, Костяның кичке һәм төнге исереклегеннән дә яманрак буталган иде башы. Ул да Мәлихнең үзе шикелле үк ыңгыраша, Мәлихтан хәтта арттырыбрак та җибәрә. Ыңгырашуы бүре сыман, шакал сыман улауга әверелә. Куллары белән өстәлгә, диварга суга-суга улапмы улый Костя. Нәкъ кичә Гайсаны кыйнаган ярсыну белән хәзер өстәлне һәм диварны кыйный.

— Нишләдек, нишләдек! Ни-иш-лә-де-ек!

Артык ук ямьсез улаудан, ахрысы, Мәлихнең башы кинәт чатнап, күзләреннән — әйтерсең ки бокс перчаткалары орылганнан — әллә нинди очкыннар чәчелеп, ялтырап узды. Аның хәлсез һәм уңайсыз мие бер мәлгә, елдырымлы төнге офык шикелле, яктыра язды. Хәлсез, уйсыз ми хәрәкәт таләп итте:

— Тот, күтәр! — дип, Гайсаның ике аягыннан эләктерде Мәлих, баш ягыннан күтәрергә Костяга ым белән аңлатырга тырышты. Тегесе һаман утын агачыдай торганлыктан, кычкырырга мәҗбүр булды. — Йә, ни көтәсең? Тиз, тиз диләр сиңа!

Улавыннан туктала алган Костя акрын гына, һавада йөзгән шикелле генә, тиешле җиргә килеп басты. Акрын гына иелеп, Гайсаның култык астыннан эләктерә алды. Күтәрделәр гәүдәне. Күтәргәч тә нишләргә икәнен төшенеп җитмәстән, Мәлих кузгалып киткән тарафка иярде Костя — ишеккә таба. Чыктылар ишектән. Кечкенә капканы уздылар. Урам шикелле җиргә чыккач, кая атларга икәнен белмичә, авыр-авыр сулап, бераз вакыт тагын аптырап тордылар. Акрын кыймылдау — үзеңне тотып бирүгә тиң. Инде яктырып килә — кешеләр күренә башлаячак. Озак уйларга вакыт юк — бирелмәгән андый мөмкинлек. Аяклар кая атлый, шул таба ашык. Шулай да үзләренчә дөрес хәл иттеләр дияргә кирәк. Ике йорт аша гына бакча буенда кечкенә капка бар — шунда юнәлделәр. Ах-ухларны тыярга тырышкан хәлдә, ул капканы да уздылар. Аннан ерак түгел исә — олы юл. Нәкъ менә шул юлга чыгу дөрес. Анда кемнәр генә узмый да, кемнәр кемне генә очратмый. Димәк, Гайса — шуларның берсе. Автомашина бәрдергәнме, хулиганнар кулына эләккәнме, кем белсен. Әйе, шулай булганы хәерле. Костя белән Мәлих та бер нәрсә күрмәде һәм ишетмәделәр. Бәладән баш-аяк. Юл читенә салдылар да Гайсаны, кулларын чалбарларына ышкый-ышкый, йөгерә-атлый китеп бардылар.

Бая чыккан капка, хәерлегә, әлбәттә, ачык калган икән. Тиз генә шул капкадан кереп, аны рәтләп бикләгәч, бакчага чумдылар һәм шундый ук җәһәтлек белән өйгә кайтып йомылдылар.

Күзгә мондый чакта йокы кермәячәге ап-ачык билгеле булса да, урын җәеп йокларга яттылар. Хикмәт диген, әллә хәмер узып җитмәгәнгә, әллә организмның чынбарлыктан качып котылырга сәләте житкәнгә күрә, тиз арада алар тирән һәм озак йокыга чумдылар. Төш вакыты җиткәндә генә күзләре ачылды. Мәлихнең күңелендә туган беренче теләге шул иде: кичәге хәлләр төштә генә булды. Нәкъ үзе. Бары тик төштә!

Мәлих бу минутларда шуны әйбәт сизә: Костяның күзләре шулай ук ачылган инде. Әйе, ачылган, тәмам ачылган. Әмма соңлабрак түгелме икән? Нәрсә уйлый икән Костя дус?! Һай алла, әйтерсең, аның ни уйлавын белми Мәлих. Кулны кисмәгә биреп әйтергә була, нәкъ менә Мәлих уйлаганны уйлый ул. Кичәге хәлләрне төшкә әйләндерергә азаплана. Бүтәнчә ничек булсын?!

Дустының күңел газапларын дөрес чамалаган Мәлих. Костя тормасмы дип шактый озак ятса да, тегесе кузгалмагач, ниһаять, башлап үзе торырга мәҗбүр булды. Торды Мәлих һәм баскан килеш, юрганың аркасына ябынып, дустына елмаерга тырышты:

— Әллә нинди төшләр кереп бетте,— дигән булды.

Дусты исә, әллә аны җөпләп, әллә чынны уйлап:

— Кошмар! — дип, башын янә юрган астына яшерәсе итте.

Их, шулай гына котылып булса икән!

Ләкин котылырга тырышу фарыз.

Мәлих, идәндәге буш шешәләрне кухня ягына чыгарып, газ плитәсе артына урнаштырды. Яңадан залга чыккач, өстәлне сыпырып куйды. Тәмәке төпчекләрен тышка чыгарып, аларны туфрак белән күмде. Әйтерсең, гөнаһны шулай күмеп була... Әнә бит, үз башыннан ук мыскыллы уй узып бара: «Мәче үзенең пычрагын шулай яшерә»,— дигән хәерсез уй. Их!

Өйдә Костя инде торган, чалбар-күлмәкләрен киеп азаплана иде. Чалбарның икенче балагын кигәндә, чайкалып, диварга бәрелде. Мәлихны күргәч, турайды. Мәлих шуны шәйләде: инде байтак мәшәкать чиксә дә, үзе һаман чалбардан гына, күлмәксез генә йөри икән. Монысы да аңларга теләмәгән сәбәп аркасында түгелме әле. Ярый, ни булса — шул. Аның каравы, бүлмә тәртипкә китерелгән. Кичә кич килгәндә нинди хәлдә булса, шул хәлдә кала. Инде китәргә, ашыга төшәргә вакыт.

Күлмәк бар бит әле. Ләкин шуны киеп караса, ике дус берьюлы тагын аптырап калды: Мәлихның шакмаклы күк күлмәге кап-кара кан. Һәм ул аны җәһәт кенә салып ыргытырга мәҗбүр булды. Ләкин ыргытып ни... Шуның белән эш бетәме әллә? Юк, бетми шул, бетми, шайтан алгыры. Һич югы алмаш күлмәк кирәк.

— Синең монда артык күлмәгең юкмы?

Шундый сорау белән Мәлих дустына зур ярдәм көткәндәй инәлеп карый. Тегесе, әйтерсең, юри ялындыргандай, көттереп кенә бирә җавапны:

— Хәзер, хәзер, эһе, булырга тиеш.

Костя веранда ягыннан джинсы материядән тегелгән ярыйсы ук иләмле күлмәк алып чыкты. Юарга салынган киемнәр арасыннан тапкан. Керлерәк икән дә, ярый, сайланыр чак түгел. Әйе. Киде Мәлих күлмәкне. Киде дә идәндә яткан канлы күлмәккә карап, тагын һушын җуйгандай катып калды. Ярый әле, Костя ярдәмгә килә алды. Янә веранда ягыннан газета алып керде дә күлмәкне шул гәзиткә төргәч, Мәлихка тоттырды:

— Мә, теләсәң кая куй.

Күп мәгънәле карашлар үзара тиз аңлаштылар. Хәзер инде юлга чыгасы гына калды. Бая Гайсаны чыгарган капкадан, кешеләр күзенә чалынмыйча югалу мөмкинлеге булса да, ул якка аяклары тартмаганлыктан, каравылчы капкасыннан чыгарга тиеш булдылар. Монысы хәерлерәктер әле: егетләрнең сау-сәламәт кыяфәттә, ап-ак икәнлекләрен, димәк ки, өйләрендә тәртипле кылануларын чамаласын каравылчы иптәш. Әйе, нәкъ әнә алар теләгәнчә, үз өе алдында тыныч кына агач шомарта каравылчы. Тыныч иптәшкә тыныч саубуллашу сүзе әйтелде. Иптәш, әлбәттә, аны-моны уйламастан: «Сау булыгыз»,— дип кенә куйды да кабат агачына иелде. Иншалла, шулай булыр — каравылчы миендә ике генә кеше теркәлеп калыр, өченчесе онытылыр...

Теләсә нинди очракта шулай булганы хәерле. Әйеме?

Автобус тукталышына капкадан соң сул якка барасы — ярты чакрым чамасы җир. Ул араны ярты кәррә сүз алмашмыйча уздылар. Ярты сәгать чамасы көтәргә туры килде. Анда да әңгәмә коруның хаҗәте чыкмады. Ниһаять, килде автобус. Кеше күп түгел — икесе бер утыргычка урнаштылар! Һәм кузгалды автобус. Ләкин ул иртә-таңда ятып калган Гайса янышнан узачак. Шуны хәтерләп, Мәлихның эче жу итте. Костяның да бите кызарып куйды. Бер-берсенең кызарганын сизүдәндер, икесе дә күзләрен аска төбәделәр. Мәгәр, хикмәт диген, күренмәскә тиешле куркыныч урынга җиткәндә, икесе дә күзләрен күтәреп тәрәзәдән карадылар. Алар калдырган җирдә Гайсә юк иде...

Шулай икәнне күргәч, күңелгә җиңеллек иңгәндәй тоелып китте. Димәк, һушына килгән дус. Һушына килгән дә, иртәнге рейс белән

кайтып китккән. Шунда дуслары янына сугылса ни була инде? Кичәге хәлләрне сөйләшеп, көлешә-көлешә кайткан булырлар иде ләбаса. Ярый, зыян юк, үз аяклары белән кайтып китүе дә бик җиткән.

Бу нәтиҗәдә ике дусның шулай ук сүзсез генә укмашкан уртак фикере иде. Уртак фикере, уртак теләге, уртак өмете...

* * *

Мәлих кайтып кергәндә, Анна апа бакчада помидор утырту белән мәшгуль иде. Әллә ни дөбердәмичә, хәтта гадәти булмаганча шыпырт кайтып керсә дә, Анна апа улының (үзенеке булмаса да, Мәлихны улым дип атый ул), әйе, Мәлих улының кайтып кергәнен эчке бер тоем белән сизеп алды. Бу тоем шактый озак вакытлар дәвамында зарыгып көтүләрнең соңгы мәлләрдә ешаебрак китүе аркасында барлыкка килсә кирәк. Төнге урамнан тәрәзәгә җил кагылса да сикереп тора Анна апа. Тәрәзәдән сөекле улын күрер. Ялгышкан, ымсынган чаклары күп булыр. Әмма алар исәпкә керми, онытыла баралар. Ник дигәндә, артык еш кабатланалар.

Капкадан бакчаны койма һәм йөз метр чамасы ихата аерып тора. Ләкин барыбер сизде Анна апа, күңеленең нечкә бер җепселе зеңләп, ишетелер-ишетелмәс авазны хәбәр итте. Ишетелер-ишетелмәс шылт иткән тавышны ишетте Анна апа. Һәм чокырга куелган помидор үсентесен күмәсе җирендә калдырып, очардай ашыгып, өйгә юнәлде. Ялгышмаган икән. Мәлих улы — өйдә. Изүләрен ычкындырып тора — күлмәген салырга һәм, мөгаен, ваннага керергә җыена бала.

— И бала, аптыраттың җанымны. Кайда йөрдең, кайда булдың? Исәнме үзең?

— Исән булмый тагы. Миңа ни булсын?

— Кайда йөрдең, кем белән?

— Костя белән, ял иттек.

— Әйтеп китсәң, телең корыр идеме? Төн буе күз йоммыйча, тәрәзәдән карап, урам әйләнеп иза чиктем. Синең исеңдә дә юк. Рәхәтләнеп ял итәсең. Карт нәнәңне интектереп, гөнаһ җыям дип тә уйламыйсың.

— Ярый, ярый, булды, Мам-Анна. Күз яшьләре артык.

Шул сүздән соң Мәлих, күлмәген салып, ваннага ыргытыйм дигәндә, Анна апаның күзе ят күлмәккә төште.

— Кем күлмәген киеп кайттың? Исереклек беләндер. Шулаймы?

— Ярый, бетте — синең эш түгел анысы. Костя белән алмаштык. Җитте, бар, эшеңне бел. Минем юынасым килә.

— Ризыклар әзер, плитәдә. Суынган булса, җылытырсың. Суганнарга түтәл ясап бирерсең, ашагач.

Бүтән чакта мең сәбәп, мең хәйлә табасы Мәлих бу юлы бакчага чыгарга бәхәссез ризалашты. Шактый ягымлы итеп:

— Бар, Мам-Анна, үземне тәртипкә китергәч тә чыгармын,— диде.

Яхшы сүз тансыклаган Анна апа тынычланып тиз генә бакчага юл тотты.

Кызык кеше Анна апа, күлмәкнең бик үк хәерледән киелмәгәнен каян сизә диген. Менә дигән күлмәккә бәйләнә. Ә тегесен күргәч ни әйтер? Ни әйтсә — шул. Берни эшләр әмәл юк. Гәзит төргәгеннән хәзер күлмәкне чыгарырга тиеш Мәлих. Юмыйча озак тотарга һич ярамас. Адәм баласының пычрактан тизрәк арынасы килүе бик табигый тойгы бит. Һич тә гаҗәп түгел.

Шулай итеп, күлмәкне чыгарып караса, күкрәк турысы гына түгел, хәтта кулбашларга чаклы буялган. «Юри буяган, ахрысы, хәсетле җан,— дип уйлады Мәлих.— Алай-болай кеше күрсә, минем хакта начар уйласыннар өчен. Мине мыскыл иттермәкче, кеше арасында дәрәҗәмне

төшермәкче. Әнә карагыз, әнә нинди ул сезнең актив җәмәгать эшлеклегез — группа комсоргы! Хулиган! Канга батканчы сугышкн! Беркатлы дивана — мине шул кыяфәттә көнгә чыгар дип белде микән? Үзең нинди кыяфәттә күренерсең әле, карарбыз. Алмаштырырга күлмәген булса, ярый. Анысы да проблемадыр, мөгаен. Шул килеш безнең компаниядә тигез хокуклы булып йөрмәкче».

Мәлих шундый уйлар белән күлмәкне кая куярга белмичә бераз торгач, үзенең аптырашта калуына икенче мизгелдә хәтта гаҗәпләнә язды. Менә инде, юк-бар нәрсә өчен интек син. Тот та ыргыт ваннага. Әнә бит Мам-Анна юасы керләрне шунда салган.

Канлы күлмәкне шул керләр өстенә ыргыткач, мәгәр башына икенче уй килде. Болай бигрәк ямьсез күренә икән. Мам-Анна кинәт күрсә, куркып, әллә ни уйлавы бар. Астарак ятканы хәерле булыр. Тоташ килеш бөтен өемне сабынлы суга салса, бәлки әле күренми дә калыр. Менә шушылай.

Мәлих канлы күлмәкне башка киемнәр арасына тиз генә күзгә ташланмаслык итеп урнаштырды. Ин өскә Костяның джинсы күлмәген җәеп куйды. Әллә кайдан сизелеп тора Костяның көчле гаилә әгъзасы икәнлеге. Аның белән аралашу дәрәҗәгә суга торган түгел, гәрчә укуы, өлгерүе бик тә уртача, ә кайчак аннан түбәнрәк булса да.

Күлмәкләр тиешенчә урнашкач, тәмен белеп, рәхәтләнеп юынды Мәлих. Әле кичә генә кырынган булса да, итальян бритвасы белән ашыкмыйча гына, ләззәт тоеп, шәпләп кырынды. Тагын юынды. Битләрен, күзләрен француз одеколоны белән лачма итеп коендырды. Һәм күңел хушлыгына бирелеп, тынычлап, озаклап тамак туйдырды.

Куш кул белән күзләрен каплаган хәлдә, диван артына баш куеп, тагын бераз оеп утырды. Баш-күз тәмам ачылгач кына, Анна апасы янына чыкты. Бу вакытта помидор чокырларының яртысы гына күмелмәгән һәм, күп дигәндә, ун чиләк кенә тирес китерәсе калган иде. Шулай да Анна апа озакладың дип сукранмады. Киресенчә, бик күңеле булып, матур-матур сүзләр белән мактарга ук тиеш тапты әле.

— Минем өчен генә түгел, үзең өчен дә. Үзең дә бик яратасың бит куагыннан гына өзеп алынган кып-кызыл помидорны. Үзең үстергән аерата тәмле була ул. Синең белән икәүләп сыйланырбыз. Алла бирсә.

Тирес җитәрлек китерелгәч, түтәл әзерләргә кушкач та кулына һич карышусыз көрәк алды улы. Эшен зарланмыйча дәвам итте. «Аз гына гөнаһы булса, күндәмләнә бала, басынкылана, — дип нәтиҗә ясады Анна апа. — Кисәтүсез читтә кунуыннан үзе дә уңайсызлана. Өметсез үк түгел икән, тәртипкә килер, төзәлер, алла бирсә». Утыртылган помидорларга улыннан су ташытасы иде дә, ярый инде, йә киреләнә башлар, дип уйлады. Эшләгән кадәресеннән канәгать булыйк. Бүтән чакта болай да ялындыра торган гадәте бар. Бакчаңны әрекмән урманы басса да гамендә юк. Күз тимәсен, күз генә тия күрмәсен.

Улының бүгенге тәртибенә сокланып бетә алмаган Анна түтәй суны чиләк белән үзе ташып сипте. Эш ул гөнаһ түгел, һәркемгә фарыз. Яшьме син, картмы — хәрәкәт ит, тормышның бәрәкәтле булыр, тәнең сырхаудан арына торыр.

Матур гына, тавышсыз-тынсыз гына җир казыган улына әледән-әле күз ташлап, канатланып кына йөрде Анна апа. Хәтта соңга таба, сулышы ешая төшкәч тә шатлыгы кимемәде. Әле озак, бик озак эшләргә дә риза булыр иде ул, ләкин менә кечкә чаклы ваннада керләр чылатасы, аннары кичке аш әзерлисе бар. Ашамыйча чыгып китсә, Мәлих улының тегендимондый җиргә сугыла торган һәм исерткеч суы белән мавыга торган гадәте сизелә башлады. Тамагы тук хәлдә чыкса, хәерлерәк була. Бәлки әле бүген чыкмас та — дәресләр әзерләргә кирәктер, имтиханнар борын төбендә. Иртәгә ял түгел — дүшәмбе, сәгать иртәнге сигезгә институтка барып җитәсе...

Анна апа помидорлар белән шулай эшен бетергәч, чиләк һәм сипкечләрне мунча янына илтеп урнаштырды да шуннан Мәлихка тырма әләктерә килде.

— Менә, улым,— диде ягымлы, назлы тавыш белән.— Булгач булсын, мамык сыман йомшак булсын туфрак. Монысы бетсә, менә шушында, янәшә итеп, тагын бер түтәл ясарсың. Кишер-чөгендер шикелле әйберләргә. Арсаң, керерсең, аш әзерләрмен.

— Ярый, Мам-Анна, син әйткәнчә булыр, борчылма.

Алмаштырганнармыни малайны! Мәлихның бүгенгедәй тәүфикълы чагын Мам-Аннасы хәтерләми дә бугай әле. Өметле икән бала. Моңарчы булган шик-шөбһәләр, борчылу-ухылдаулар һич урынсыз икән.

Анна апа өйгә шундый матур тойгылар белән керде. Яулыгын салып, алъяпкыч кигәч, җиңнәрен сызганып, ваннага узды. Ваннага җылы су җибәреп, чылата башларга дип керләр өемен кузгаткан иде, аскырак бер төштән сәер төс күзгә чалынды. Сәер төсне тартып чыгарса, ходай гына суккан икән, күндәм улының өр-яңа күлмәге — кап-кара кан! Сугышып йөргән икән ләгънәт төшкән нәрсә. Менә ни өчен майлаган каешка әйләнәсе иткән!

Йөрәк ярсуына чыдый алмыйча, бакчага йөгереп чыкты Анна апа. Чыкты да еландай зәһәрләнеп ысылдарга кереште. Дөнья яңгыратып кычкырыр иде, күршеләр ишетүе бар.

— Нишләдең, каһәр суккан нәрсә, кем белән сугыштың? Атаң ни әйтер, әниең ни дияр? Мине тиргәрләр, карамагансың диярләр. Әллә мин сине карамадыммы, әллә мин сине карамыйммы? Үземнән артык күреп, сине тәрбиялим, сине иркәлим. Ә файдасы кайда? Тәрбияләгән саен бозыла гына бардың, иркәләгән саен очына барасың. Инде нишләтергә сине? Мин нишләргә тиеш? Урталай ярылыргамыни?

Тиргәп, ысылдап аргач, баштагы сорау кабатлана:

— Кем белән сугыштың, кайда?

— Сугышмадым.

— Кыйнадылармы? Кемнәр?

— Кыйнамадылар.

— Ә кан? Каян чыккан соң кан? Күлмәгең нишләп шул көнгә төшкән? Ә?

— Шаярып кына... бокс уйнаганда. Иптәш малайның борыны канады да... Бөтен булганы шул.

— Ай-һай, шулай гына микән. Кеше борыны канаганнан синең күлмәгең шул хәтле пычрый димени! Ай-һай, хәерлегә булсын. Бу араларда бик азындың. Үз башыңа кыланмасаң ярый. Хәерлегә булсын, хәерлегә. Аны бит шул килеш калдырып та булмый. Юарлыгы да калмаган. Югач та таплар калачак. Шуны яңадан киярсеңмени?

— Юма, алайса, ыргыт. Мам-Анна, җитте, артыгын кыланасың.

— Артык ди сиңа. Син ул артык кылanучы, менә кем. Ходай гына каргаган икән, күрәселәр бар икән. Малай актыгы! Сизенә идем аны, хәерлегә түгел бу югалуларың дип. Менә, юраган юш килде.

Шул сүзләрне әйткәч, бераз күңеле бушагандай тоелып, Анна апа бераз гына тынып торганнан соң, исенә нидер төшкәндәй, баягыча ашыгычлык белән өйгә кереп китте. Ничек кинәт пәйда булса, шулай ук юкка да чыкты.

Өйгә кергәч, янә шул хәерсез күлмәкне күтәреп алды. Ни өчендер селкеп карады, төреп бакты. Чылатырга уйлап, берничә мәртәбә ваннага иелде, тагын турайды. Һәм күлмәкне алъяпкыч астына яшергән хәлдә, янә бакчага чыкты. Мәлих яныннан аңа һич илтифат итмәгән рәвештә, иреннәрен зәһәр кысып, күзләреннән очкыннар чәчә-чәчә, мунча буена узды. Керде мунчага. Мунча миченең капкачын, юшкәләрен ачты. Ачкач, ишек төбеннән вак-төяк утын алып керде. Каен тузына ут кабызды. Кабынган туз өстенә чыра һәм аннары вак утыннар өстәде. Ут барлык көченә дөрли башлагач, пычрак, гөнаһлы, шикле, шомлы күлмәкне шул

дөрләп торган ут иркенә тапшырды. Ялындырмыйча гына янды затлы тукыма. Кайчандыр аксыл булган күлмәк кара-куукылга әйләнде. Анна апаның бу төсне дә күрәсе килмәде. Һәм ул кисәүгач белән янган утны, күмерләрне бутый торды. Йөрәгендә мичтәге шикелле үк кайнарлык, эсселек тойган хәлдә, күңелендә дөрләгән ялкыннарны тыя алмыйча, каушый-каушый, калтырый-калтырый, кабат-кабат айкады. Кисәүләр кузга, кузлар вак очкыннарга, көлгә әйләнеп аска коелып беткәнче бутады. Ниһаять, мич эчендә күмер һәм көл әсәре калмаганны күргәч кенә, ярсуы сүрелә төшкәндәй тоелды. Мәгәр алай да мич идәненә аяк сузып утырган килеш, нәрсә уйларга белмичә, кабат өйгә таба атлады. Бу вакытта Мәлих ике түтәлне дә моңарчы һич булмаганча пөхтә, матур итеп ясаган, тырмалаган иде. Үзе инде өйгә кереп киткән. Анна аның бүлмәсенә баш тыгып карамыйча булдыра алмады — караватында аякларын селкетеп ята...

Ходай азагын хәерле кылсын. Хафалану-аһылдаулар шушының белән тәмам булсын. Ярабби, ярабби!

Кичке ашны ашаганда да, йокларга ятканда да бүтәнчә һәр икесенең берсе авыз ачып бер сүз әйтсә икән. Өй эчен моңарчы һичкайчан булмаганча, шомлы тынлык басты. Тынлык колакларда үзе генә чыңлый иде. Телевизор димәстән, радио димәстән, хәтта малай магнитофонын тоташтырырга да дәрман җыя алмады. Иртәнге ашны аннан-моннан гына капкалап, институтка ашыкты. тәрәзәдән карап озатканда:

— Иминлек бир, Аллам, азагы хәерле бетсен! — дип укынды Анна апа.

* * *

Көн буе һәм аннары төн буе йокы аралаш уйлаган бердәнбер уе шул иде Мәлихнең: битләрен-күзләрен шәплэп юган, бит-күзләрдә, авыз-борыннарда һич тимгел калмаган, элеккечә чип-чиста йөзле, якты чырайлы егет, иптәш егет, дус егет Гайса каршыласын иде аны. Каршылау артыграк өмет, анысының булганы юк һәм булмас та. Ә менә әле телгә алынган кыяфәттә аудиториягә кергәнен, шунда утырганын гына күрсәң иде. Зур нәрсә, артык зур максатмы шушы? Моңарчы гел шулай булды ләбаса. Гел әле хыялга әйләнгән рәвештә килеп керә иде Гайса дус. Гади, бик гади нәрсә — көше үз төсендә йөри. Уйласаң, шушы гадилек нинди зур максатка, теләккә, хыялга, алгысыткыч өметкә әйләнә белә икән. Моңарчы шушындый да теләк була дисәләр, Мәлих мәсхәрәле итеп елмаер һәм кул гына селтәр иде, мөгаен. Ә бүген, менә бүген!

Бүген ул, аудиториягә шундый теләк белән, йөрәге кысылып-кысылып куйганны сизгән хәлдә, күкрәк төбендәге сәер җилкенү-кымырҗауны тыярга әмәл тапмыйча, арып, хәлдән таеп килеп керде.

Кешеләр күп түгел әле. Һәр студент иптәшне күздән кичерү минутлык эш кенә иде. Ләкин юк, алар арасында күңел ашкынып эзләгән, моңарчы кадерсез булган, ә бүген дөнья бәясе торган кадерле дус күренми. Мәгәр артык ашкынудан файда көтмә. Тыныч көтә бел. Бүгенгесе көндә кая китсен ул Гайса. Аның бүгенгесе көндә һәм гомер буе сөеп, яратып башкарган иң олы эше менә шушында — институт бүлмәләрендә бит. Мәскәүгә, Парижга яки аннан да гүзәлрәк җирләргә барасыңмы, әллә шушы институтта калып торасыңмы дисәләр, ул шушы тыйнак, фәкыйрь институтны сайлаячак. Аның төп максаты — белем, белем, тагын бер кабат белем. Белемгә комагай ул Гайса. Биш ел буе укып, берме, икеме генә «дүрт»ле алса алгандыр, бәлки әле анысы да очраклыдыр. Барлык фәннәр — гел «биш»легә тапшырылгандыр. Менә шушындый кирәгеннән артык тырыш кеше ул — педант дисәң дә хәтере калмастыр Гайса дусның.

Озакламас, килеп житәр, житәчәк.

Ләкин күпме генә көтсә, ишектән күз аермыйча күзәтсә дә, кадерле дус күренмәде. Дәрес барышында ишекне ачар, укытучыдан гафу үтенер дә, баш иеп кенә, арткы урыннарга узар...

Ләкин ишек ачылмады.

* * *

Гайса — баянчы. Еш кына буш аудиторияләрнең берсендә концертка әзерләнгәндә, баян, җыр тавышлары ишетелә. Дәрес ташлап шунда китмәдеме икән дип, факультетның барлык ишекләрен барлап чыкты Мәлих. Тыңлап карады. Үзәге өзелгәнче, колаклары чыңлаганчы тырышып тыңлавына карамастан, таныш моң, күңелле сөйләшү, чыр-чулар колакка чалынмады.

Пошаманга бирелеп, урамга чыкты. Гайсаның кайда яшәгәнен ул белә. Шулайга таба юл тотты. Мәгәр биш-ун адымнан соң шып тукталды, чөнки башына кылт итеп яңа фикер килде: иптәш Райкин бит сабырлыкка чакыра. «Не высовывайся!» — ди. Ягъни: «Муеныңны бик сузма, кыскартулары ихтимал. Башларын артык югары күтәреп йөргән динозаврларның әнә җир йөзендә эзләре дә калмаган, ә күзләргә бәрелмичә яшәгән кандалалар мәңге тыныч, мәңге исән. Әллә Костялар факультетына барып килергәме? Юк, Костяны күрү куркыныч булмаса да, Мәлихнең аны күрәсе килми икән. Килми күрәсе һәм вәссәлам. Ник икән? Ник соң әле?

Җилкә кашый төшкәч, аңлашылды: кичә үзен бик ямьсез тотты бит Костя дус. Мәлих бары тик бокс кагыйдәләре буенча сугарга кушса, уенның тәртипле бетәренә ышанганга күрә генә судьялыкка алынса, ә Костя... Костя, дөньяга булган бөтен ачуын чыгаргандай, Гайсаны чын хулиганнарча кыйнарга керешә. Кагыйдәләрнең тамчысын да исәпкә алмыйча. Костяның ярсыган кыяфәте, ямьсез чырае әле дә күз алдында. Гайсаның канга баткан авыз-борыны күз алдында. Күз алдында, гүяки, җансыз капчык рәвешле аунап ята бирә Гайса.

Мәлихнең идеясе — кызыкта, уенда иде. Ә Костя? Уеннан узып, Костя уймак чыгарды. Бәдбәхет!

Мәлих Костяны эзләүдән баш тартты: «Ну их, к черту, миңа дисә, чәнчелеп китсеннәр».

Гамәлдә генә түгел, уйда да иптәшләреннән йөз чөереп, Мәлих дөнья кайгысын кайгыртырга кирәген исенә төшерде. Һәм үзе көн дә диярлек кереп йөрү гадәткә әверелгән җиргә — комсомолның факультет бюросы бүлмәсенә юл тотты. Ә менә анда ыгы-зыгы купкан иде.

Беренче хәбәр — Гайсаны үтергәннәр.

Икенче хәбәр — Костяны кулга алганнар.

Башка сүзләр дә булды, әлбәттә, күп булды. Әмма Мәлихнең колаклары аларны ишетергә теләмәделәр. Кемгә, нәрсә эшләргә кирәклеге хакында гәп корганда гына игътибарын җыя алды. Мәрхүмнең гәүдәсен факультетка куярга килештеләр. Ни әйтсәң дә бит Гайса уку отличнигы, үзешчән сәнгатьтә танылган музыкант. Аны белүчеләр күп, хушлашырга, соң мәртәбә күреп калырга теләүчеләр күп булачак. Сүз арасында Мәлихка да йомышлар кушылды. Җеназа вакытында, сабакташ буларак, группа комсоргы буларак, ниһаять, дус буларак, Миша Михайлов та, ягъни Мәлих иптәш тә сүз әйтергә тиеш икән.

Барча мөһим булмаган ваклыклар арасыннан тагын бер җөмлә кара төндә күкне урталай ярган яшендәй ялтырап узды: Шифаханәдә һушсыз яткан Гайса берничә минутка һушына килгән икән. Шул чакта аннан: «Кем кыйнады?» — дип сорап өлгергәннәр. «Костя, Костя Малышев үтерде», — дип, аермачык җавап биргән Гайса. Һәм бүтәнчә күзен ача алмаган, телгә килмәгән. Берничә минуттан йөрәге тукталган...

Факультетта Мәлихны менә нинди яңалыклар көткән икән бит. Ә ул аларны башка җирдә эзләгән иде.

Бу хәбәрләрдән Мәлихның өнсез калуын, коелып төшүен иптәшләре, әлбәттә, үзләренчә дөрес фаразладылар. Гайса белән Мәлих якын дуслар бит. Күпме бергә йөргән дустыңны шушындый фаҗигале рәвештә югалтып кара син!

Егет башын күтәрә алмыйча чыгып барганда, бюро секретаре кисәтеп калды:

— Ул хәтле үк бирешмә, Миша, үзеңне кулга ал. Әйбәт итеп чыгыш ясарлык хәлдә бул. Әзерлән. Иртәгә унда монда бул. Кайбер нәрсәләр турында киңәшергә, бергәләп оештырырга туры килүе бар. Аңлашылдымы?

Күзләренә килә язган яшь әчесен бармаклары белән сөртеп, Мәлих:

— Аңлашылды,— дип көчкә әйтә алды.

— Хәзергә ял ит, бар, сиңа рөхсәт.

Һәм китте Мәлих. Гәрчә кая барырга кирәклеге билгесез иде.

Урамга чыккач та яктырмады дөнья. Башында бернинди фикер, уй юк. Һичнинди фикер, уй катнашыннан тыш, аяклар үзләре генә каядыр атлый иделәр. Уй-фикерсез каядыр атлый торгач, бер мәлне ул өйгә кайтып җиткәнлеген сизде.

Үз бүлмәсенә узды. Курткасын салып караватка ыргыткач, музыка куйды. Иләмсез куәтле кычкыруларны бөтен көченә җибәрде. Тавышка чыдый алмыйча борглыланырга, сикергәләргә, колакларын каплап чайкалырга тотынды. Башы, зиһене тәмам түнгәч, чак кына хәл үзгәреп, котырып-котырып биергә керешге. Болай да иләмсез тавышларга үзе дә шашынып, кыргыйларча кычкырырга, ничә Костя улаган кебек уларга тотынды. Аның барлык бу кыланышлары күкрәк турысында таш булып каткан нииндидер куркыныч бер тойгыны томалау, күмү, юкка чыгару теләгенә тоташкан иде. Һәм ул биеде дә биеде, акырды да акырды. Ә музыка барча алама хисләрне, кеше күңелендә була торган барча ярсыну, ачыргалану, ләгънәт ору һәм тагын, тагын нинидер башка каһәрләүләрне өй эченә генә түгел, бөтен дөньяга чәчә бирде. Бии, кычкыра, улый торгач, бер мәлне хәлдән таеп, Мәлих караватына ауды — нәкъ кичә Гайсәауган төслерәк булып. Ауды да хәрәкәтсез калды. Колак төбендә йокымы, төшме аралаш — зәгыйфь кенә, сизелер-сизелмәс кенә шундый теләк зеңләгәндәй итте: шушылай яткан килештән бүтәнчә бер дә тормаска, кузгалмаска мөмкин булса икән лә!

Бу теләк караңгыда күзгә чалынмыйча калган очкын сыман гына җемелдәп, тиз арада юкка да чыкты. Мәлих әллә һуш җуйды, әллә йокыга талды. Вакыт көчен җуйды, чөнки мәгънәсен югалтты.

Бер мәлне... бу ни? Йөрәк яргыч куркудан, еланга басканда була торганча кот очудан Мәлих кинәт сикереп торды. Чырае, күзләре! Әйтерсең, аның өстендә менә-менә төшәргә дип балта күтәрелгән.

— Ау-уфф!

Шулкадәр йөрәк өзгеч иде бу тавыш — бакчада йөргән Анна апа шуны ишеткәч, җан-фәрманга йөгереп керде.

— Ни бар? Улым! Балакаем, ни булды? Нишләттеләр?!

Анна апаның үз күзләре дә кинәт өскә килгән куркынычтан диярсең, шашкандагы кебек аларган иде.

— Балам, балакаем!

Бүлмәгә шундый сүзләр белән кереп, шул сүзләрне тәкрарлыйтәкрарлый Мәлихны кочаклап алды. Бәби чактагыдай кочагына алып торгызды, каты-каты итеп сөйде, сыйпады. Башларыннан, чигәләреннән үбә-үбә үзе дә шыңшырга, еларга кереште.

Шуннан соң гына аңга килә язды Мәлих. Һәм шуны аңлады: аны куркытып уяткан нәрсә тынлык икән. Бөтен көченә дөбердәгән һәм кычкырган пластинка тавышы тукталгач, рәхимсез чынбарлык яңадан

кайткан, һәм кеше бөтен исәбе, максаты юкка чыгуын, тормыштан кача алмавын тойган һәм зиһен шул хәлгә мөнәсәбәт белдергән икән. Мөмкин булган һәм мөмкин булмаган дәрәҗәдә, бөтен көченә ачыргаланып, Мәлих үзе кычкырган икән. Әйе, аңлашылды. Тавыш һәлакәттән йола алмады. Көн кебек ачык: дөбердәп тиздән милиционерлар килеп керәчәк тә, кырт кисеп: «Киен! Атла!» — диячәк.

Шулай булачак!!

Мәлих калтырап, иңнәрен җыерып, бая биегәндәге төслерәк чайкалып куйды. Ләкин ишек тирәсе тыныч иде — беркем юк, адымнар ишетелми. Давыл узгандай тоелып куя. Әллә чынлап та узамы? Ник килмиләр? Ник алып китмиләр Мәлихны? Костя бит инде барысын да сөйләгәндер...

Милиция турында уйлагач, сәер хәл — Мәлихнның исенә әтисе килеп төште. Районның эчке эшләр бүлеге башлыгы Денис Иванович Михайлов Мәлихның, ягъни Миша Михайловның әтисе ләбаса. Әллә шундамы хикмәт? Бүтән чакта улының барын-югын белмәгән кеше әллә бүген килеп малаена ярдәм итәргә уйлаганмы? Шулай булса? Менә булыр иде бер гаҗәп!

— Мам-Анна...

— Әү, балам.

— Әтине әйтәм, эмведе начальнигы... әгәр теләсә, гаепле кешене коткара аламы?

— Нинди гаеп, балам, ни сөйлисең син?!

— Теләсә дим, булдыра аламы?

Сүзнең мәгънәсенә төшенә алмаган Анна апа инде кистереп җавап бирде:

— Әйе, әгәр дә теләсә. Нишләп булдыра алмасын. Закон аның үз кулында бит.

Мәлих амин тоткандай куш куллап күзләрен, битләрен сыйпап куйды һәм тирән итеп сулыш алды. Нәрсәнедер аңларга тырышкан Анна апа төпченмәсә, бәлки тынычлана да язар иде дә. Нишлисең, хатын-кыз вакланырга ярата.

— Ник алай сорыйсың улым?

— Юк ла, болай гына. Минем бер дус малайны кулга алганнар да... Шуңа ярдәм итмәсме дигән идем.

— Ә-ә, алайса булмас, теләсә кемгә ярдәм итмәс әтиең. Бик тә коры кеше, коеп куйган коммунист, намус колы диләрме? Шундый кеше синең әтиең. Законнан тайпыла торган түгел. Бөтен район белә моны.

— Иһһы, — дип кенә куйды Мәлих үз уеннан аерыла алмыйча.

Һәм башында туган уен эчендә калдырды. «Ә менә мине, үзенең улын якларга алынган түгелме соң? Мин бит, ни дисәң дә теләсә кем түгел аның өчен».

Шундый бәхетле уй аша күңеленә сабырлык иңде.

Иртәгә — җеназа. Чыгыш әзерлисе бар. Факультет бюросының группа комсоргына тапшырган йомышы үтәлмәскә мөмкин түгел. Андый хәл була алмый.

Бәхетле фикергә өлгәшкән бала, караваттан тиз генә кубып, юыну бүлмәсенә юл тотты. Юынгач, ашыкмыйча гына сөртенгәч, Анна апа иңенә кулын салды:

— Мам-Анна, әйдә, бакчага чыгыйк әле. Анда эш калгандыр бит?

Рәхәтләнеп көлеп җибәрмичә нишләсен Анна апа. Билгеле инде, сүз шул гына.

— Калмыйча тегс. Бакчада эшнең гомергә дә бетәсе юк инде аның. Бездән дә калыр әле. Әйдә, алайса, әйдә, сабыем. Бергәләп бераз эшлик тә, аннары үзең генә казырсың, минем аш әзерлисем булыр. Әйдә.

Җәһәт кузгалып, бакчага чыктылар. Анна апа әйткәнчә, бераз эшләгәч, һәм аннары ашап-эчкәч, кичкә хәтле шунда булдылар. Мәгәр, күңел инде үз урынына утырды дигәндә дә, Мәлих ара-тирә капка ягына

күз ташламыйча булдыра алмады. Күзгә кеше-кара чалынмады. Көн тыныч узды. Кич тә.

— Тыныч йокы, Мам-Анна.

— Тыныч йокы, балам, матур төшләр күр.

* * *

Урынга иртәрәк ятып, иртәгә әйтәчәк сүзләрен ачыкларга, ятларга тырышты. Әллә язып ук барыйммы дип уйлаган иде дә, бу фикердән кире кайтты. Әйтәсе сүзләр бар, күп икән. Исән чакта телдән әйтелми торган якынлык хисләрен хәзер әйтергә мөмкин. Ник шулай икән? Иң матур сүзләрен әйтергә ояла кеше. Начарларыннан алай ук оялмый. Юкса киресенчә булырга тиештер ләбаса?

Нәрсәдер дөрес түгел, нәрсәләрдер дөрес корылмаган бу тормышта. Әйе, соң булса да, уң булсын, үкенечле булса да, иртәгә Мәлих йөрәгендә кайнаган иң кадерле сүзләрен җиткерәчәк дусты Гайсага, гәрчә соңгарак калып булса да.

Шундый изге ниятләр белән йокыга талды, шундый изге хисләр белән уянып, шундый теләкләр белән институтка юл тотты. Мәетне китермәгәннәр иде әле.

Бюрога күтәрелде Мәлих. Секретарь белән кул биреп, ә бүтәннәр белән баш кагып кына исәнләште.

— Сүз әзердер? — дип, шунда ук эшкә күчте секретарь.

— Шулайдыр. Ничек килеп чыгар.

— Әйбәт булыр, ярый. Менә бит нинди фаҗига. Кем уйлаган! Дуслар! Бер-берсенә кул күтәрер дип...

— Шаярудан гына башланган нәрсә... ы-ы... — Артыгын ычкындырганын абайлаганга күрә, Мәлих тотлыкты, тәне эсселе-суыклы булып чымырдады. — Ы-ы, шул, уеннан килеп чыккан бәхетсезлектер, дип уйлыйм. Ничек инде чынлап булсын. Сез әйткәнчә, бик тә якын дус иделәр бит.

— Әйе шул, икесе дә кызганыч, киткәне дә, калганы да.

Бюро әгъзаларыннан булган бер кыз кулына кызыл тасмалар тотып керде. Почетлы каравылга басканнар беләгенә бәйләр өчен. Һәм шул-вакыт — телефон чыңы. Трубканы алган секретарь, ниндидер сүз ишеткәч, җәһәт торып басты.

— Астан шалтыраталар. Китергәннәр мәетне.

«Мәет ...» Нинди ямьсез, шәфкатьсез сүз! Шулкадәр килешми, ятышмый ул ике көн элек кенә җир шаулатып йөргән яшь кеше исеменә! Бүлмәдәгеләрнең сискәнеп куюы һич гаҗәп түгел. Битләре агарынып куйды кешеләрнең. Кайгы берләштерә кешеләрне...

Аска төшү белән Мәлихка яңа йомыш куштылар: җитәкче иптәшләрне чакырып килергә.

Мәет куелган залның читендәрәк, почмак артында кечкенәрәк бүлмә. Каравылга басачак кешеләр шунда җыела. Ректорны анда бюро секретаре үзе, ә проректорны һәм башкаларны Мәлих алып килде. Кызлар тиешле кешеләргә тасма бәйли тордылар. Секретарь, мәрхүмнең баш очына килеп, берничә секунд кына тынлык урнашканны көткәннән соң, җеназаны башлап та җибәрде.

— Барыбызга да авыр кайгы килде. Алдынгы студентыбыз, үрнәк дустыбыз, танылган музыкант, ә иң мөһиме, чын мәгънәсендәге намуслы иптәшебезне югалттык. Бу хәл белән аңыбызның килешәсе килми. Һәм һичкайчан килешмәс тә. Ләкин чынбарлык — аяусыз. Бүген без якын арада соңгы имтиханнарын тапшырып зур тормыш юлына чыгасы яшь кешене соңгы юлга озатырга мәҗбүрбез. Шуның өчен җыелдык. Мәтәм митингысын ачык дип белдерергә рөхсәт итегез. Беренче сүз — институтыбыз ректоры Камил Шәрипович Шәриповка.

Ректорның бюро секретаре сүзләренә тоташкан кыска чыгышыннан соң сүз кафедра мөдиренә бирелде. Ә аннары... аннары... Нинди тиз арада!

— Хушлашу өчен сүз бирелә Гайса Хафизовның якын дусларыннан берсе, группа комсоргы Миша Михайловка.

Мәлихның чырайдан чыккан, каушаган, боеккан кыяфәте кайгы зурлыгының бәхәссез галәмәте икәнлеге һәркемгә аңлаешлы һәм табигый тоелгандыр. Чыгышын кабат-кабат уйлаган булса да, хәзер, вакыты житкәч, әйтерсең, барлык фикерләрне кинәт җил очырды. Берничә секунд тел тирбәтә алмыйча интекте Мәлих. Ләкин җеназа халкы Миша Михайловның кем икәнен, көчле характерлы булуын яхшы белгәнгә күрә, ашыктырмады, сабыр гына көтте. Һәм ялгышмады. Үзенә ягымлы, ышану тулы күзләр карап торганын абайлагач, фикерләр яңадан җыйналды. Сүзләр үзләреннән үзләре дигәндәй тезелеп китте:

— Кайтарып була алмаслык авыр югалту. Яши генә башлаган, киләчәк уңышлары, матур эшләре хәзердән үк күренеп торган дусны югалту аеруча ачы икән. Тагын зур аяныч шунда, ул дошман кулыннан түгел, дус кулыннан китте. Без Гайса Хафизовны үзебезнең арада шаяртып Иисус дип йөртә идек. Ул чыннан да, Иисус Христоска охшаш булып чыкты. Аның үз Иудасы табылды. Дөнья яратылганнан бирле корбан булуларга чик куелмаган, хәзер дә дәвам итә. Кеше табигате үзгәрмичә кала. Ачы авырлык шуны мәҗбүри аңлауга бәйле. Аяныч, әйе, бик тә аяныч. Берни эшләп тә булмый, бер сүз әйтеп булмый. Шул гына сүз, соңгы сүз: «Якын иптәш, кадерле дус, хуш! Авыр туфрагың җиңел булсын».

Секретарь җеназаны ябык дип белдерүгә — музыка, чигәләргә туптуры бәрелгән кара җил... Кай арададыр табут урыныннан кубып, каядыр шуа, ераклаша башлады. Ә Мәлих селкенә, кузгала алмый. Каткан да калган. Чыгышлый секретарь килеп аркасыннан какмаса, бәлки берүзе үк калган булыр иде. Ярый әле килде иптәш секретарь, килү генә түгел хәтта күңелне дә тынычландыра язды:

— Шәп сөйләдең, Миша, молодец!

Аның кызу адымнарына өлгерә алмаса да, үз көенә генә булса да, Мәлих, урамга чыгып, саубуллашучылар төркеменә кушылды. Монда инде ул, әйтерсең, ышанычлы яклаучылар арасында. Аңа бернинди шикле караш ташлаучы юк. Мөгаен, инде булмас та.

Әйе, эти, эти кеше, ниһаять, үзенең улы барлыгын исенә төшерде диярга кирәк. Улы барлыкны исенә төшерү өчен җинаять ясарга кирәк булган, димәк. Ә бүтәнчә? Бүтәнчә мөмкин түгел иде бит. Моның өчен Костяга рәхмәт әйтергә туры килмәс микән?

Мәлих өйгә ярыйсы ук тыныч күңел белән кайтты. Анна апага Гайса белән ничегрәк хушлашканны кыска җөмләләр һәм кайбер ымлыклар белән хәбәр иткәч, кичке чәйгә утырдылар. Ләкин шунда... шул вакытта нәрсә? Ник, ник сикереп торды Мәлих? Әйе, үзе дә сизмәстән сикереп торган Мәлих тупас рәвештә кемнәрнеңдер ишек кагуын ишетте һәм колак яргыч ямьсез тавыш яңгырады:

— Именем закона!

Анна апа да баскан төштә катып калды. Аңына килә язгач, урамга чыгып, улы артыннан иярмәкче иде, ләкин инде анда беркем дә юк. Автомашина кай арада юкка да чыккан. Уңга сугылды Анна апа, сулга бәрелде — киң урам тарайды. Өйгә керсә, өй кысан. Ятса, йокы качкан. Үзе дә һәм мөгаен йөрәге дә туктар дәрәҗәгә килеп бөреште. Йоклар-йокламас, оер-оемас, аңлар-аңламас хәлдә почтага йөгерде. Ашыгарак төшелгән икән, шактый озак көтәргә туры килде. Шактый озак көткәннән соң гына ачылды почта. Керде Анна апа почтага. Телеграмма бланкысы алды һәм кәкре-бекре, гарип хәрефләр белән чуарланган кәгазьне оператор кызга тапшырды. Анда шундый сүзләр язылган иде:

**«Михайловой Марве Артемовне с Мишой случилась беда срочно приезжай.**

**Анна».**

Лаеклы ялга чыгарга мөмкин булганнан соң ике ел вакыт узса да, илле җиде яшьлек Марва Артемовна мәктәптә директорлык вазифаларын быел гына үз шәкертләренең берсенә тапшырган иде. Алтынчы-җиденче классларда исә әле дә рус теле һәм әдәбиятын укыта. Гомер буе җәмәгать эшләре алып барганлыктан, һәм аның тормышын көненә ике сәгать дәрес бирү генә тутыра алмаганлыктан, төрле оешмалар, төрле предприятиеләрдә төрле лекцияләр укый, мәктәпкәчә яшьтәге балалар йортлары һәм бакчаларына шефлык итә. Төрле җыелышларга, пленумнарга катнаша.

Бүген исә, Бөтен дөньяда тынычлык саклау фондына дип җыйган унсигез мең сум акчасын илтеп тапшырырга, дип көнел беркеткән иде. Монысы да беренче тапкыр гына эшләнгән эш түгел. Күптән түгел генә шушы фондка мең ярым сумлык заем облигацияләре биргән иде. Укытучы, тәрбияче икәнсең, балаларның киләчәген, илнең киләчәген кайгырту синең иң изге һәм иң беренче вазифаң бит. Гомер буе ул шушы мәсьәләгенә тугры булып калды — заманы кушканча, вөҗданы кушканча яшәде. Иманына хилафлык китермәде. Ләкин шушы иң изге бурычны үтәүдә тоткарлык килеп чыгар дигән уй аның башына бер генә мәртәбә кереп чыкса икән лә! ...

Әйе, үзенең намус эшен бу юлы теләгән вакытында үти алмавына бик тә көенде апабыз. Бу акчалар чынлап та сугыш куркынычын киметергә ярдәм итә дип белә иде ул. Аларның яңадан-яңа бомбалар, танклар һәм башка кораллар ясауга тотылуын, бигрәк тә югары урыннарда утыручыларга — сөяркәләре белән чит илләрдә типтергән һәм типтерәчәк бәндәләргә «ярдәм итү» икәнлеген ул белә идемени соң!

Мәктәпнең барча бүлмәләрен бер итеп кыңгырау шалтырагач һәм сөекле укучылары белән иртәгә чаклы саубуллашкач, уңышлы дәрес һәм алда торган күңелле гамәлдән канәгатьлек тойган Марва Артемовна, класс журналын күкрәгенә кысkan һәм тыйнак кына елмайган хәлдә, салмак адымнар белән укытучылар бүлмәсенә таба атлый иде. Аның белән бүген күрешеп өлгермәгән кызлар-малайлар гадәттәгечә сәлам биреп, исәнләшеп уздылар. Марва Артемовна аларның якты чырайларына үзләре төсле үк яктылык сирпеп, ихтирам белән җавап бирә барды.

Шулай матур гына атлый биргәндә, үзе тәрбияләгән шәкертләрнең берсе, яшь укытучы кыз, канатлы коштай җилпенеп, аңа каршы яктан атлый иде.

— Марва Артемовна, анда сезгә телеграмма! — дип, килгән тизлеге белән узып та китте ул.

«Нинди телеграмма?..» — дип сорарга ачылган авыз кире ябылырга мәҗбүр. Башка килгән шул сорау, әлбәттә, аның адымнарын тизләтте. Кайдан, кемнән? Мондый нәрсәнең күптән, бик күптән булганы юк бит инде. Бүтән шәһәрдәндер. Мәскәүдән булуы ихтимал. Укытучыларның бөтенсоюз киңәшмәсе кебек нәрсәгә чакырулары мөмкин. Республика мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыту алдынгысы сыйфатында илкүләм әһәмиятле киңәшмәгә катнашырга, ә икенче юлы Ленин орденын алырга аңа Мәскәүнең үзенә барырга туры килгән иде. Шундыйрак нәрсә микән? Хәзер инде орден югын юктыр. Булса, исәп кәгазьләре тутырткан булырлар иде. Ә менә киңәшмә дигәне дөреслеккә туры килә. Монысы бик тә ихтимал.

Шундыйрак хәбәр өмет иткән Марва Артемовна, журналны шкафка урнаштыргач ук, өстәл уртасында яткан телеграмманы җәһәт кенә үрелеп алды. Ачты, укыды һәм үз күзләренә үзе ышана алмады. Янында торган икенче бер укытучыдан укытып карады. Анысы исә, һич тайчынмыйча, Анна апа телеграммасын тантаналы рәвештә диярлек бөтен бүлмәгә яңгыратты: «С Мишой случилась беда срочно приезжай».

— Кем соң ул Миша?
— Улым, бердәнбер улым!
— Сезнең улыгыз бармыни?

Тиле сорауга иренен кысып куюдан башка җавап бирү артык икәнне аңлатып торсынмы? Юк. Марва Артемовна, телеграмманы кукрәгенә кыскан килеш, директор бүлмәсенә ашыкты. Ләкин анысы да, хәерсез, баягы мәгънәсез сорауны кабатламаса ни булган?

— Сезнең улыгыз бармыни?

Нишлисең, монысына аңлатма бирергә туры килде. Директор, бүтән төпченмичә генә китәргә рөхсәт иткәч, туп-туры өенә, аннары исә һич тоткарланмыйча аэропортка юл тотты.

Алабугага билетлар бетмәгән икән, телеграмма күрсәтүнең кирәге чыкмады. Аллага шөкер. Бик үк матур эчтәлекле телеграмма түгел бит. Теләсә кайда селкеп, уйнатып йөрерлекмени.

Алабугада булмаганга күпме вакыт узды икән?

Сугыш вакытында, әнисен җирләгәндә кайткан иде. Ә шуннан соң? Исәпләсәң исең китәрлек — шуннан соң бер генә мәртәбә дә кайтылмаган лабаса. Анна апа Казанга үзе сирәк кенә килгәли — малайдан азмы-күпме хәбәр китерә һәм, әйтерсең, шул җитә иде. Уйлап карасаң, хәзер инде ап-ачык аңлашыла: алай гына җитмәгән шул, һич тә җитмәгән. Моның өчен кем гаепле? Марва үземе? Ләкин сәбәпләр, сәбәпләр кем әйткәндәй, гафу итеlә торган иде бит. Гаепле кеше әллә ире — Денис Ивановичмы? Әллә ул да түгелме?

Түгел үк шикелле. Төп сәбәп бүтәндер кебек. Нинди сәбәп? Иң төп сәбәп шул — эш белән күмелү. Марва Артемовна дигән укытучының, мәктәп директорының тавык чүпләп бетерә алмас мәшәкатьләре, иҗтимагый дигән бурычлар, йомышлар, ыгы-зыгылар. Бөтен гомерне шулар тутырган, шулар биләгән — туган якны, туган йортны, хәтта бердәнбер баланы сагынырга, кайтып булса да күрергә вакыт җитмәгән. Малай үзе дә, ичмаса шушы көнгә чаклы бер генә мәртәбә диген, бер генә мәртәбә туган әнисенең ишеген ачып карасын икән лә!

Ә бит ана баласыннан йөз чөермәде. Киресенчә, янында тотарга, бер шәһәрдә, бер өйдә яшәргә тырышты. Ә малай? Нишләде малай? Турысы шул — качты. Туган әнисен ташлап качты!

Иреннән — Денис Ивановичтан аерылгач, күзем күрмәсен диебрәк, ахрысы, Марва тиз арада Казанга күчте. Бөтен гаилә — Марва, аның әнисе, Денис, Анна һәм Мэлс — бергә торалар иде. Марва киткәч, Денис бүтән квартирага күчкән иде. Марваның әнисе, Анна һәм Мэлс өчәү калдылар. Марва улын Казанда ныграк урнашкач кайтып алмакчы иде. Мәгәр моның өчен озак, бик тә озак җай чыкмады шул. Бүген кайтам, иртәгә кайтам, быел булмады, икенче елга әйбәт фатир булачак дип көтә торгач, өч-дүрт ел гомер узган да киткән — сизмичә дә калынган лабаса. Сугыш башланган еллар... Фаҗигаләр. Шулар тоткарлады. Чыны шул, киметә дә, һичнәрсә өсти дә алмассың.

Сугышның икенче елында кырыкка бер яшь тулмаган укытучы Марва Михайловнаны мәктәп директоры итеп куйдылар. Булачак коммунистка йомышларны алагаем йөкләү — гадәти эш. Ә Марвага, ихлас башкаруы сәбәпле, ул йомышларны баштан ашканчы төйиләр иде. Зарланмады Марва. Өйгә бары тик берничә сәгать йоклар өчен генә кайта ала иде.

Шундый көннәрнең берсендә, әлеге кебегрәк, телеграмма — әниең авыр хәлдә, дигән хәбәр килеп төште. Һәм нәкъ әлеге шикелле ашыгыч рәвештә, Марва юлга чыкты.

Өйгә кайтып кергәндә, әнисе шундый хәлдә иде — ул кызын танымады. Кызының исемен бер тапкыр да атамады. Каядыр башка дөньяга караган күзләре шулкадәр битараф иде ки, хәтта Марва үзе дә әнисен читсенгәндәй тоеп куйды.

Әйе, кызы анның чәчләреннән сыйпап кабат-кабат сүз кушса да, эндәшә алмады ана. Тиз арада дөнья куячагы күз алдында. Берничә көн анның баш очында булу фарыз. Ләкин Марвага бер көнгә генә бирелгән шул рөхсәт. Сугыш вакыты, бурычлар катгый, законнар каты. Әйтелгән мөддәттә урынында бул. Малаен житәкләгән Марва икенче көнне үк пристаньга төшәргә мәжбүр.

Дебаркадерга узып чиратка басуга ук, ни күрсен, таныш укытучылар — районлаш мәктәптән Смеловский һәм Маклашова дигән кешеләр. Яннарында яу хәтле балалар. Авылда уңыш җыюда катнашканнан соң Казанга кайтып баралар икән.

Мең ярым бала өч баржага — бишәр йөз кеше төялеп — кайтырга тиеш. Ике укытучы өчкә бүленә алмый бит инде, балалар белән өченче баржада кайтуны Марвадан үтенделәр. Әлбәттә, һич үгетсез риза Марва. Баржага биш йөз баланы — ягъни, биш йөз дә бер баланы, әйе, үз малае да бар бит әле аның! — кертеп урнаштыргач, дүрт яшьлек Мэлсны кайнап торган күч арасына кертеп җибәрде дә үзе тап-тар басмалар аркылы янадан ярга чыгып китте — балаларга паек алырга.

Кеше башына бишәр йөз граммнан исәпләнгән каравайлар туптулы бер арыш капчыгы булды. Күтәрерлек түгел. Өстерә, Марва. Һәм җан-фәрманга өстерәде Марва. Тирләп пешеп тә, ерак китә алмады. Бәхетенә күрә, атлы арба узып бара иде. Баржа турына чаклы шуңа салып килергә мөмкин булды. Ләкин яр аша тагын өстерисе. Тагын өстерәп, басмага житте. Аннан соң... нишләсен, кеше көлсә көлә инде, бүтән әмәл юк — басмага атланып, аяк салындырып утыр да тагын өстерә капчыгыңны. Тирләп-пешеп, ах-ух килеп, шуыш, шуыша бир. Бер, ике метр, өч, дүрт, биш! Араның яртысы узылды. Ләкин... Ләкин ун метрлы басманың нәкъ яртысына житкәч, такта сыгылып селкенергә, чайкалырга керешмәсә икән бит. Юк, селкенепме селкенә, чайкалыпмы чайкала такта басма. Бер мәлне чайкалып та китте, Марва исә, суга атылып төшмәс өчен мәчедән җәһәтрәк бөтерелеп, тактага күкрәге белән асылынган булып чыкты. Басма үзе дә мәче сырты төсле бөкерәйгән, тик өскә таба түгел, аска таба. Һәм чайкалуын, тирбәлүен белә. Ә капчык кулда — суга төшергә ашыга, үзе белән Марваны тарта. Капчыкны өстерәү түгел, инде суга мәтәлмәскә, үзеңне сакларга, үзеңне саклый алмасаң да балалар ризыгын ычкындырмаска тиешсең. Димәк, болай асылынып озак тора алмыйсың, ары, ары шуыш. Тагын, тагын. Шул ният белән бераз шуышмакчы иде, басма баягыдан да яман чайкалып, инде Марва очты... дигәндә, ниндидер бер аңлашылмас өлгерлек белән, ычкынды дигән капчыгын тотып кала һәм тигезлекне кире кайтара алды. Корсагы белән басмага яткан һәм ике кулы белән капчыкка чатырдап ябышкан хәлдә, үзе дә сизмәстән, иләмсез рәвештә чырылдап җибәрде:

— Бетәм, бетәм, ярдәм!

Ярый әле ишеттеләр. Басманың икенче очында малайлар күзгә чалынды. Шуларның икесе тиз арада килеп тә житте. Ике малай көлкеле кыяфәттә калган укытучыдан артык көлмичә, елмаешып кына, апаларына басмага янадан адәмчә утырырга булыштылар. Капчыкны да кай арада эләктергәннәр. Җай гына күтәреп, баржага таба атлап та киттеләр. Ләкин капчыкны күздән ычкындыру — куркыныч. Сакларга кирәк капчыкны. Малайлар баржага кергәч үк, ипиләрне бөтен хәлдә бүлешә башлаулары бар. Шуңа күрә, тагын бер күз ачып йомган арада сузылып, Марва артык ераклашып өлгермәгән аякларның бер балагыннан эләктерде дә, малайның гажәпләнүенә карамастан, торып басты һәм аннары малайның бишмәт чабуына ябышты. Курка, янәсе. Ярдәмгә мохтаж апаны малай, читкә этәрмичә, бер кулы белән капчыкны тотса да, икенчесе белән Марваны житәкләп атлады. Акрын-акрын шулай баржага тәки барып життеләр. Инде чак кына сулыш алырга мөмкин иде. Ләкин иркенләргә форсат юк. Бераз сулыш алгач та икмәкне бүлгәләргә, кискәләргә керешә Марва.

Сыгылып сынарга торган тар басмадан узу чаклы ук димәсәк тә, монысы да нык кына четерекле эш иде. Бу шөгыль ничәдер сәгать вакытны алды. Күтәрелеп караса, инде кояш баеп килә икән. Офык кып-кызыл, су өсте дә шул ук төстә. Шул төсне шәйләргә генә өлгерде Марва һәм хозурланудан үзен бик тиз мәхрүм итеп, барча балаларны берьюлы күздән кичерде. Куш канатын җәйгән чебиләр анасыдай бер урында әйләнеп чыккач, балаларга дүртәрләп рәткә тезелергә кушты. Тезелергә куллары белән ярдәм итәргә тырышты.

Баржа эче балалар белән шыгрым тулы. Кырмыска оясы шикелле. Син тезеп кара шуларны чиратка. Шулай да, ничек итсә-иттеләр, рәткә үк ошап бетмәсә дә ерак киләчәктә үзгәртеп кору дип аталган чор кибетләрендәге хәтле генә булган чират рәвеше урнашып, сүз аңлашырлык мөмкинлек туды, дияргә кирәк. Шуны чамалаган укытучы апа көр тавыш белән боерык бирергә тиеш:

— Строй, смирно! — Мондый команданы еш ишеткән балалар гадәт буенчадыр, күнде, үрә каттылар.

Һәм шунда ук икенче команда яңгырады:

— Вольно, стоять на месте. Тавышланмыйча.— Ә берничә секундтан адәмчә сүз: — Строго чират белән, бер кисәк икмәк аласыз да тыныч кына үз урыныгызга барып утырасыз.— Урын дигәне, әлбәттә, юк, идәнгә утыру хакында гына бара сүз.— Әйдә, башладык. Син, әйе, син — беренче ал менә шушы кисәкне.

Әллә ризык үзе юашлана төшәргә мәҗбүр итте, малайлар һәм кызлар бик үк этешми-төртешми генә, тәртип белән диярлек, ипи кисәкләрен ала тордылар. Һәркайсының кулга эләккән икмәккә нык текәлү аркасында абынып, сөртенеп куюларыннан чамалаганда, тәртипнең бозылмавы, хәтта соңга таба тынлык урнашуы укытучы тәртип саклаганнан гына түгел, чынлап та икмәкнең иң якын хыялга охшаш кадерле икәнлеген тоюдан иде.

Эш шулай көйле генә барды һәм дәвам итте. Инде бервакыт ипи өләшенеп бетә язды дигәндә, аһ итте Марва. Инде менә күр, такта өстендә өч кисәк ипи калган, ә чиратта — дүрт малай. Дүртенчесе, иң арттагысы — Марваның үз улы!

Йөрәге жу итте Марваның, тәне әллә ничек калтырый ук башлап, бөтен гәүдәсе, эсселе-суыклы булып, чымырдарга кереште. Нәрсә эшләргә, ни әйтергә балага? Юк, берни эшли дә, берни әйтә дә алмады. Шулай булды — өч малай үз чиратлары белән соңгы икмәк кисәкләрен алып үз юллары белән тиз арада башкалар арасына чумса, үз улы калды ымсынып. Әйе, шулай булды, шулай. Үзенә димәстән, бердәнбер улына, әйе, күз карасыдай күргән малаена өлеш чыгара алмады Марва. Башта шулай тиеш дип санады. Шулай гадел була дип уйлады. Ләкин... ул бер нәрсәне уйлап җиткермәгән булып чыкты — баланы ни дәрәҗәдә рәнҗетәчәген алдан күрә алмаган булып чыкты. Ана кеше... менә хәзер күр инде, күр, әле кайчан гына икмәк өелеп торган такта әрҗә почмагына сөялеп, боегып, малае басып тора...

Йөрәк сулкылдавын басар өчен дә, малайны тынычландыру нияте белән дә, ана кеше салмак кына килеп баласын кочаклыйсы иткән иде, тегесе кискен рәвештә читкә тайпылды.

Ике кулын алга таба сузган Марва үзенә һәм малаена инде сүз белән ярдәм итмәкче бугай. Һәм ул ни сөйләгәнен үзе дә аңламастан, бер-бер артлы сүзләр яудырырга кереште:

— И-и балам, балакаем син дә килгән иденмени, чиратка баскан иденмени? Ярый инде, гафу ит инде, балам, ачуланма. Ярый, ач булмабыз. Анна апаң биргән күчтәнәч — шушындый ук икмәк кисәге бар, курыкма, без дә сыйланырбыз.— Шулай дигәч, ул малаен янә кочакламакчы иде дә, мәгәр улы янә читкә тайпылды шул. Назга исе китмичә, керпедәй чәнечкеле булып калды.

Ярый, соңыннан йомшар, кичерер әле, дип өметләнергә генә хәзер... һәм көтәргә. Малайның тынычланганын, һәм тагын шундый ук мөһим нәрсә — буксир килгәнен көтәргә. Юл чыгарга.

Ләкин гел син теләгәнчә генә булса икән лә. Бигрәк тә сугыш йончыткан томанлы елларда. Әйе, рәтләп урнаштык дигәндә, көтелмәгән бәла — буксир юк. Килмәде буксир. Пристаньга яңадан төшеп белешкәч тә сөенерлек хәбәр ишетелмәде — якын сәгатьләрдә килмәячәк буксир...

Сәгать дигәннәре — тулы бер тәүлек. Әйтерсең, Марва Артемовна үзе гаепле, күз күтәреп карый алмый балаларга. Юаткан була аларны, кызык әкиятләр, мәсәлләр сөйләгән була. Һәм, әйтерсең, юана сабыйлар, шаярган, көлешкән була. Хәлнең шулай түзәрлек икәнен күргәч кенә, улы янына килә. Бер почмакта салкын идәндә малаен кочаклап утырмакчы иде, анысы барып чыкмады, малай терсәкләрен тырпайтып, тагын читкә тайпылды. Керпе дә керпе, Мэлс та керпе. Нишлисең бит, артык бәйләнчек булырга ярамый, бөтенләй торып ук китүе бар. Түзәргә генә кала. Һәм түзә ана кеше. Тынычланырга тырыша. Ләкин кайда ул тынычлану! Чак кына хәрәкәтсез торгач та, башына уйлар тула башлады. Кинәт үлем хәлендәге әнисе искә төшеп үзәкне өзде. Ни хәлдә икән? Исәнме әле? Оер-оемас зиһенгә сыек кына йокы томаны аша ерак та түгел бер өйдә хәрәкәтсез яткан әнисе күренә иде.

Күз алдында пәйда булып торган шул сурәтләрне тоныкландырып, таң атты. Малаен җитәкләп, әллә тагын әнисе янына йөгереп кайтыргамы дигән уй белән кабат-кабат талпынса да, канатлары салынып, кире чигенде Марва. Баржа тулы бала, аларны калдырып китү мөмкин түгел. Казанда шулай ук укучылар көтә, эш, директор...

Бурыч, бурыч тота бәндәне!

Төш җитте — сәгать уникe чамасы. Кинәт Марваның йөрәге чәнчеп куйды. Моңарчы булганча түгел, чынлап чәнчеде. Әллә шуннан, әллә бүтән нәрсәдән, сискәнеп китте. Авыртуның сәбәпләрен ачыкламакчы булса, моңа вакыт җитми калды, чөнки карашы яр буена текәлде дә... Күзләрен тутырып, авыртканчы тырышлык куеп карап торды. Анда, яр буендагы зиратка таба табут күтәргән ун-унбиш кешелек төркем атлый иде.

Ул! Ул! Аның әнисе! Бүтән кем булсын!

Йөрәккә кан савыла. Йөрәк сызлый. Йөрәк сызлавын басар өчен, малаен кысып кочакламакчы була, малай чәнечке-шырпыларын тырпайткач, нишләргә белмичә, чайкалып куя. Әнисенең күзән җыергандагы төсле чырае да тәэсир итми малайга. Әнисе кочагыннан кискен ычкынуы җитмәгәндәй, бүтән балалар арасына кереп үк югала.

Бала, аңлыйсыңмы соң син әниең күңелен?! Әнкәң күңелен никадәр кыерсытканыңны тоясыңмы? Ә Марва үзе? Аңлый идеме икән әнисенең нинди уйлар белән яшәгәнен? Менә хәзер нишли Марва — дөрес эшлиме? Ана каршындагы бурыч белән ил каршындагы бурыч... Кайсын шуның өстенрәк күрергә мөмкин соң?

Әлбәттә, зиратка аның әнисен алып баралар. Озатучылар кулында — таҗ-такыя, чәчәкләр күренә. Көзге айда да чәчәк тапканнар. Марваның әнисен ихтирам иткәннәр дигән сүз. Күршеләрдер. Ә Денис килдеме икән? Ә менә кызы, исән калган берданбер баласы, анасын соңгы юлга озата алмады...

Баржадагы балаларны ташлап китә алмады Марва. Гәрчә, бер карасаң, мөмкинлек бар кебек тоелса да. Чөнки бит барыбер тиз генә юлга чыга алмадылар. Буксир кич караңгы төшкәч кенә килеп җитте.

Инде менә — көтелгән юл. Баржа акыртынлап, агымга ияреп, алга шуыша китте. Минутлар, сәгатьләрне санайсы гына калды. Алар исә, билгеле инде, бик ашыкмадылар.

Төн җитте. Марва күзәтә барганча, караңгылык акыртын-акыртын сыеклана да башлады. Бер мәлне караса, таң атып килә икән. Күзләре

офыкка, күккә төбәлсә, анда — самолет! Самолет әле алга уза, әле артка китеп тагын куып җитә. Шунда ук төшенде Марва — баржаларны, өч баржадагы балаларны самолет саклап кайта икән! Менә бит ничек! Балаларны саклаучы Марва үзе генә түгел лөбаса! Каян белгәннәр диген! Менә бит нинди кадерле ул балалар! Алар хакында Марва гына түгел, ил кайгырта, ил үзе!

Ә Иделгә куркыныч яный. Таңгы күк йөзе, әйтерсең, ут белән чолганган. Ләкин кызыллык кодрәте генә түгел икән. Идел яна, чынлап яна. Фашистлар суга ягулык салып, ахрысы, ут төрткәннәр... Мөгаен, ут төрткәннәр. Югыйсә нишләп янсын ди су? Сап-салкын көзге су!

Янып торган су утрауларын читләтә-читләтә, сәгать чамасы барылгандыр. Бу мәлдә еракан шартлау, чатырдау авазлары да ишетелә иде. Бомба ташладылар бугай. Марва тоеп, төшенеп торганча, ят самолетларга безнең зенитчылар җавап кайтарды. Димәк, дошман самолетлары Казанга чаклы ук килеп җиткән булып чыга. Халык шомланмасын өчендер, бу хакта соңыннан да хәбәрләр имеш-мимешләрдән ары узмады.

Янгын эченнән чыккач, озак үтмәстән, самолет та күздән кичте. Балалар уянмады. Үзләренең нинди куркыныч астында йоклауларын алар сизмәделәр. Алар өчен Марва һәм тагын билгесез кешеләр җан аттылар, ут йоттылар. Марва көн яктырганчы тынычлана алмады. Ул һаман да каушый, бөтен гәүдәсе калтырый иде. Казан пристанена килеп тукталгач кына узды күңел бизгәге.

Балаларны ярга чыгарып тезгәч тә, мәктәпләргә шалтыратып, машина чакырды Марва. Башка укытучылар да балаларны шулай машина белән озаттылар. Машинага сыймаганнары белән үзләре трамвайга утырдылар.

Тирә-якта ут, үлем шәүләсе уйнаганда үзеңә тапшырылган йомышны син һич зарланусыз үтәргә тиеш. Ә Марва, күреп торасыз, үзенә кушылмаганны да намус белән үти белә. Һәм нинди югалтулар бәрабәренә!

Өйгә кайтып кергәч тә, улын ялгызы гына калдырып, кибеткә чапты. Ул кайтканда, чишенми-нитми яткан бала изелеп йоклый иде. Дүрт яшьлек бала ике тәүлек буе гел аяк өстендә диярлек басып торсын әле! Нинди авыр юлда, көзге Идел өстендә калтыраса да, еламады түгел, шыңшып та карамады сабый. Аның белән хәзердән үк горурланасы килә әнисенең.

Ләкин шул горурланырлык малайны адәмчә карарга, тәрбияләргә җай юк. Көн буена баланы өйдә ялгыз калдыра алмыйсың бит. Нишләмәк кирәк, эшкә аны үзе белән алып йөри торган булды Марва. Дәрескә керешли, кемгәдер калдырып торырга туры килә. «Тәрәзәсе», ягъни дәрессез сәгате булган нинди укытучы туры килсә, шул карап тора. Туры килмәсә, җайсызрак — Мәлс түзем холыклы булса да тыныч ук түгел, киресенчә, артык хәрәкәтчән, хәтта шук дияргә кирәк. Үзе генә калдымы, коридор буйлата чабарга, сикерергә керешер. Бөтен житдилеге белән барган дәрес вакытында класс ишеген ачар да көлә-көлә качар. Кайбер классларга шыпырт кына керер. Аның кергәнен укучылар күрсә дә, дәшмәскә, кызык итеп кенә күзәтергә мөмкин. Шулай, шыпырт кына керер дә Мәлс арткы парталарның берсенә елышыр. Менә сиңа кәмит. Пәрәме спектакль. Класс хихылдый, класс гөр килә. Хихылдый, гөрли торгач, укытучы игътибар итсә, күр дә тор — иптәш директорның үз малае! Балалар белән бергәләп көләргә генә булдыра ала укытучы. Һәм житәкләп илтергә тиеш була.

Укытучылар бу хәлне кызык итеп, малайның шуклыгын мактап кына сөйләшәләр, зарланмыйлар. Әмма директор дивана түгел бит, аңлый, дәрес бәя бирә, ләкин бернишли алмый. Уку сәгатьләре узганны күз күгәртеп дигәндәй көтеп алганнан соң гына, малаен җитәкләп өйгә кайта. Бүген шулай, иртәгә һәм ары табан шулай. Җиңел түгел, түзәрлек. Әмма

төрле киңәшмәләр, югары оешмалар бар шул. Әйе, аларны — җыелышларны, хуҗалык эшләре белән җан-фәрманга чабуларны кая куясың? Андый чакларда (әйтергә кирәк, шактый еш!) кая, кемгә калдырасың баланы? «Тормыш түгел, тәмугның үзе бу»,— дигән чаклары булмады түгел Марва Артемовнаның, булды. Ләкин җирдәге тәмуг мәңгелек түгел. Рәте табылды тагы. Бакчага урнаштыру өчен чиратка язылса да (чиратсыз урнаштыру хакында уйлыйсы да юк — дәвере икенче!), кайчан житә әле ул чират. Шул хакта уйлап аһ орган көннәрнең берсендә Анна Ивановна килеп төште. Һәм мәсьәләне ул хәл итте. Һәм, әйтергә кирәк, бик тә жиңел хәл итте.

Иң беренче хәбәр — Марваның әнисен җирләүләре хак.

Икенчедән, Аннаның кола ялан хәтле олы йортта ялгыз калуы борчылмаслык хәл түгел.

Ике-өч көн кунак булганнан соң Анна китәргә җыенды. Мәлссыз тора алмавын, сагынуын күзләрен сөртә-сөртә аңлатырга тырышты. Баланы үзе белән алып китәргә рөхсәт сорап ялварды. Ләкин бүгенге хәлдә Марваны үгетлисе бармыни? Үз хәле хәл бит аның. Моны Анна бик белеп сөйләшә. Ялваруның бушка китмәсен белеп ялвара. Артык өзгәләнмичә генә. Ләкин Марва да сүзен өзеп кенә әйтә алмый. Соңгы сүзне баланың үзенә калдыра.

Кичке чәй вакытында баласын бик әйбәт итеп, яратып сыйлаганнан соң, әни кеше аның янына терәлеп үк утырды да, сүзен зурларча житди итеп, туп-туры итеп әйтте:

— Улым, син ничек уйлыйсың... Анна апаң сине бик сагынган, синсез тора алмыйм, ди. Син инде зур бит, уйлап кара әле. Әйт әле, сиңа менә шушы өйдә яшәү әйбәтме, әллә Алабугадагы иске өебездәме?

— Мин үз өебездә торам.

— Монысы да үз өең, тегесе дә. Кайсында әйбәтрәк?

— Еракта, баржа артында.

Аңлашылды, үзенә кирәген интекмичә сайлады малай. Сөенеченнән Анна Ивановна кочаклап алгач, хәтта читкә тайпылырга уйламады да.

— И-и балам, балакаем, алайса, иртәгә икәү бергә китәбез.— Шулай дип, Анна малайны аркасыннан шапылдатып сөйде.— Китәбезме?

— Китәбез.

Әнисенең чырае шактый күләгәләнеп тагын да житдиләнә төшсә, Анна битенә исә кояш кунды. Шулхәтле шатланды, сөенеченә түзә алмыйча, баланы күтәреп күккә чөйде, кычкырып-кычкырып көлде.

— Әй улым да инде, әй акыллы да инде, әй зур үскән дә инде,— дип куанды.

Туган ана кич буе таш сын шикелле мәгърур кыяфәттә кала бирде. Иртәгесен пристаньга төшеп, соңгы пароходларның берсенә үз кулы белән утыртып җибәрде улын...

Дөнья буш калды, җан бушлыкка әйләнде. Аны бары тик көндәлек мәшәкатьләр, бетәсе килмәгән җәфа-борчулар гына тутыра алачак иде.

Берничә атнадан соң Марваны мәгариф бүлегенә чакырдылар. Анда яңа йомыш йөкләячәкләр.

Юдино станциясеннән чак кына арырак, Займище авылыннан уң якта, урман буенда пионерлар җәйләве бар икән.

Анда Казанның мәктәпкәчә яшьтәге балалары ял итә. Немец — Мәскәү капкасы төбендә. Кан коюлы аяусыз сугыш. Яралыларга Мәскәүдә урын житмәле түгел. Аларны Казанга җибәрәләр. Бер өлешен әлеге җәйләүгә урнаштырырга кирәк.

Моның өчен үзебезнең балаларны кире Казанга алып кайтырга туры килә.

Роно мөдире шулай ук — хатын-кыз. Фамилиясе Куницына иде бугай. Кыяфәтенә корыч ныклыгы биреп, ике канатын өстәлгә җәеп салды бу.

— Сез — коммунистка, баш тартырга хакыгыз юк.
Әйтерсең, Марва каршы килергә җыена. Кемнең кем икәнен белмичә сөйләшә иптәш мөдир.
— Кайчан? — дип кенә сорый ул.
— Иртәгә иртүк.
— Нинди поезд белән?
— Теләсә кайсы. Кайсын туктата алырсыз, шунысы белән.
Аңлашылды. Мөдирнең кискен кыяфәтенә һәм сүзләренә игътибар итмәстән, Марва торып та басты.
— Мөмкин булганны эшләрбез.
— Һәм мөмкин булмаганны!
— Әйе, һәм мөмкин булмаганны.
Саубуллашырга тиеш таптымы, юкмы, анысын ул хәтердә калдыра алмады. Таң белән торып, юлга чыкты.
Станциягә барып җитү кыен булмады. Йөк йөртүче поезд туктармы, юкмы дип бераз борчыларга туры килсә дә, ходай кушып, җайлы гына килеп тукталды поезд. Аннан соң өч-дүрт чакрым җәяү атлады. Тимер юл буеннан ерак түгел генә урман арасында — җәйләү. Аны табу һәм тану җиңел булып чыкты — яралы солдатларны носилка белән ташу башланган да икән. Шулар артыннан ияреп, Марва җәйләүгә барып керде.
Утар тулы кеше. Солдатлар җирдә ята, ноябрь салкынында...
Бәхеткә, дип әйтикме, ул елны көз озынрак килгәнгә, бу көн дә ямьсез үк түгел, тыныч иде. Җир — җир бит инде. Адәм баласы — барыбер кеше. Салкын аларга, сызлана солдат, ыңгыраша. Ә тавышсыз ятканнары... алары... Алла сакласын!
Солдатларны носилка белән ташый торган сестралар хәлдән тайган иде. Марва аларга ярдәмгә ашыкты. Ник килгәнен онытып язып, ким дигәндә бер сәгать буе яралыларны ташышты. Җирдә ике-өч кеше генә калгач, үз йомышы хәтеренә килде. Балалар йортлардан чыккан, күп булса ике-өч йөз метр ераклыкта, урман эчендә йөгерешеп йөриләр. Марва шунда юнәлде. Тәрбияче ике яшь кенә кыз бала (студент кызлар булып чыкты) Марваның ярдәмгә килгәнен белгәч, чырайлары яктырды! Кызлар тиз арада балалар уртасына басып, игълан яңгыратты:
— Безне алырга әнә махсус вәкил килгән. Хәзер аны тыңлыйк. Шаулашмый торыгыз.
Казанга чаклы — утыз чакрым юл. Бу араны узу сабыйлар өчен мөмкин булмаган хәл. Шуңа күрә поезд белән кайтырга тырышу сәбәбен искә төшерү мәҗбүри түгел дип, Марва юлның җайлы булмаячагын искәртергә һәм тәртипнең нык булырга тиешлеген генә аңлатырга тиеш тапты. Үзе белән таныштырганнан соң шулай диде:
— Хәзер без, балалар, бөтенебез бергәләп, рәт-рәт тезелешеп, тәпитәпи тимер юл буена барабыз. Тимер юлның куркынычлы икәне сезгә билгеледер. Әйе, бик куркыныч. Поезд тиз генә туктала алмый, шуңа күрә, бик тә, бик тә сак булыгыз. Гел безнең янда гына торыгыз, ерак китмәгез. Хәзер тезелешегез.
Марва Артемовна сөйләп бетерүгә, студент кыз:
— Команда, стройся! — дип боерык бирде.
Мыйкылт-мыйкылт атлап тезелешкән булдылар.
— Безнең арттан, шагом марш!
Киттеләр төшеп юл буена. Үзләренчә шау-гөр килгән көннәре. Шаярган, көлгән булалар. Сүзләре колакка керсә дә хәтердә кала торган түгел. Сугыш бармы аларга, юкмы, әти-әниләре интегәме, интекмиме — алар өчен барыбер кебек. Алар, гүяки, зурлардан бәхетлерәк. Монысы, әлбәттә, тышкы яктан гына шулай. Сабыйлар хәзер җылы өйләрдә әткә-әнкәләре канаты астында рәхәт чигәргә тиеш ләбаса. Ә алар көзге көндә ташлы тимер юл буенда, салкында сикергәләргә тиеш.
Тимер юл буена озак киленмәде — ара бик якын бит. Килеп җиткәч тә Марва, ике студент кызга балалардан бер минутка да читкә китмәскә

кушып, юлның нәкъ үзәгенә, бая гына куркыныч дип балаларга кисәткән төшкә таба атлады. Юлның нәкъ үзәгенә кереп, шпалларга баса-баса, арлы-бирле йөгренергә кереште.

Күпмедер вакыттан соң поезд гөрелтесе ишетелде. Колаклар шәмрәйде. Поезд ике-өч йөз метр арага җитәрәк, Марва кул күтәрде. «Тукталыгыз!» — дигәнне аңлатып, ике куллап, ишарә ясарга кереште. Әнә поезд килә, кычкырта-кычкырта, ажгырып килә. Әкеренәергә җыену галәмәте сизелми дә. Марва — ике арада. Поезд белән аның арасында — йөз метр, илле, егерме, ун... һәм Марва поезд астында калды дигәндә генә үзен-үзе читкәрәк ыргыта алды. Студент кызлар да, балалар да аһ иттеләр:

— Ай, ай!

Вагоннар, тәгәрмәчләр ярты гына метр читтәнрәк котырып әйләнә, шуыша, шәфкать белмәс каты агым булып шуыша. Күбесе — буш. Йөз, ике йөз бала түгел, ике мең кеше урнашырлык. Ләкин юк, тукталмый поезд, туктала алмый. Расписаниесе кушмый, закон. Гүләпме гүли: юл бир, кит, саклан!

Шалтырый-шалтырый, гүелди-гүелди, кычкырта-кычкырта узып китте поезд. Колак тондыргыч шау-шу, шәфкатьсез металл агышын, дөбердәү-калтырауларның барысын, барысын үз тәнендә тойган Марва поезд узып киткәч тә, кагылган казыктай, бер урында тора бирде. Студент кызларның берсе килеп аны иңеннән кочаклап куйгач кына һушына килә язды. Мәгәр алай да урыныннан тиз генә куба алмады, торган җирендә басып калды. Сөмсере коелган кызны хәттә юатырга тиеш тапты:

— Берсе туктамаса, икенчесе туктар. Менә күрерсез.

Шул рәвешле, бер, ике, өч поезд узды. Ә дүртенчесе тәки тукталды!

— Нәрсә кирәк, җаныгыз ике мәллә, нишләп акылдан язасыз? — дип акырган машинистка Марва шундый ук тупаслык белән җавап кайтарды:

— Күрмисезме әллә, әнә бит сабыйлар, салкын яланда кунсыннармыни? Казанга чаклы гына, утыртуыгызны сорыйбыз. Үзегезнең дә бардыр бит балаларыгыз?

Машинистның фәлсәфи бәхәскә вакыты да, теләге дә юк иде, әлбәттә. Тупаслыгын һич киметмичә акырды:

— Утырыгыз, тиз, бик тиз!

Тизлек дигәндә, тырышырга була — һәркем ашыга, күзгә җилдән, суыктан ышык эзли адәм баласы. Бу юлы баржаларга түгел, такта вагоннарга төялделәр. Ике йөз бала бер вагонга сыйды.

Күп булса ярты сәгать эчендә — Казан. Тукталды поезд. Һәм балалар шабыр-шобыр коелырга керештеләр.

— Тиз, мөмкин кадәр тиз!

Тиз коелдылар. Барысы да төшеп бетте. Балаларны колонналарга тезә башлаганнар иде инде. Санап унбишәр кешелек төркемгә аергач кына, хикмәт, сан тулмый, җитми бер бала! Марва, тагын кинәт ут төсле кабынып, вагон ишегенә ташлана.

— Әй, кем анда, кем вагонда, чык тизрәк, чык, китә бит поезд.

Поезд чынлап та кузгала, тәгәрмәчләр алга таба әйләнә, аларны кирегә бору мөмкин түгел. Тәгәрмәчләр ярты минут чамасы әйләнгәч тә вагон ишеге төбендә бер малай пәйда булды. Йоклап калган бичара!

— Сикер, тиз, сикер дим, курыкма, балам, балакаем! Минем өскә сикер, тиз!

Марва аңында, ничектер, аның үз малае, шулай нишләргә белмичә, адашып китеп барадыр төсле тоела иде.

— Сикер дим, улым!

Әллә шушы сүз тәэсиреннән, батырлык җыеп, сикерде бала. Әмма...

Әмма, Марва поезд артыннан иярә барышлый, җайсыз урынга туры килгәнен, артта гына кайнар су тулы чапчакка терәлә язып торуын,

кайнар суга егылып харап булу ихтималын аркасы белән шәйләп, ахры, күз ачып йомган арада алга ыргылды. Һәм малай белән бергә каядыр мәтәлде. Шунда да, уй иярмәс тизлек белән үз кочагындагы малайны кырыйгарак, тәгәрмәчләрдән дә, кайнар су тулы чапчактан да читкәрәк һәм алгарак этәрергә тырышып талпынды. Аңын жуйган дәрәҗәдә дә шул ният белән азапланган булып чыкты.

Һушына килгәч тиз төшенде: кайнар судан читләшәм дип алгарак ыргылганда, ул вагоннан әллә ни ерак тайпыла алмаган икән. Вагонның тимер баскычы аның ботына шулкадәр каты бәрелгән, ул кайнар су артына арыш капчыгы сыман дөпелдәп ауган. Инде күз ачып караса, малай аякка баскан, малай аның тирәсендә маэмай баласы сыман шыңшып бөтерелә, кулларыннан тарта, аркасыннан кочаклый, торырга куша.

Тәгәрмәчләр тизлеге белән килгән беренче уй: «Исән бит малай, исән!»

Әйе, күр әнә, ул инде коткаручысына үзе ярдәм итә. Апасының кулларыннан тарта. Шундый ихлас куллар тарткан вакытта, тәнендә җаны булган кеше нишләп торып басмасын ди. Әйе, торды Марва апасы. Ләкин... Уф! Уң аякның басасы килми. Авырта. Шулай да егылмаска көч җитте. Болай булгач, инде болай булгач, түзәргә кала. Тешләрен кысып, күзләрен йомып булса да түзә Марва. Сул кулыннан малай җитәкләгәнгә күрә, ярдәмнән файда табарга, авыртуны җиңәргә тырышып, ыңгырашып булса да кузгала. Тыйтак-тыйтак атлап, үзләрен көткән балалар төркеменә барып кушыла.

Инде барлык балаларның да исән икәнлеге ачыкланды. Аларны тагын бер кат барлагач кына, Марва, аксак-туксак атлап, вокзалда кизү торучы янына кереп, Ронога һәм тиешле мәктәпләргә шалтыратты.

Ике сәгатьтән бер машина килде. Берничә рейс ясап, балаларны таратып бетерә яздылар. Соңыннан, көтә көтеп тә машина кабат килмәгәч, калган ун-унбиш баланы трамвай белән озаттылар. Инде эш бетте дигәндә, караса, бая поезддан сикергән малай әле дә Марва янында икән.

— Син китмәдеңмени?

— Әһе.

— Өегез кай төштә?

— Камил урамында.

— Камил? Андый урам бармыни?

— Бар, апа, безнең урам.

— Комлев урамы түгелме?

— Әһе, Кумлев.

Ярый әле юллары туры килде. Трамвай белән көчкә илтеп җиткерде баланы Марва. Әбисе белән генә тора икән. Әтисе сугышта үлгән, әнисе тынычта вафат. Ятим бала... атасыз-нисез. Ә Марваның үз баласы? Марваның үз баласы әтиле-әниле килеш ятим. Ул да шушылай йончумы, боекмы икән?

Йөрәк кысылып куя, бөрешә йөрәк, күкрәкне кайнар кайгы тутыра. «Юк, болай ярамый, Мэлсны һәм Аннаны тизрәк Казанга кайтарырга кирәк.» Ләкин бер бүлмәле коммуналкада өч кеше яши алмый. Моның өчен яңа фатир сорау мәҗбүри. Ә бармы соң квартира? Төзеләмени яңа йортлар?

Сорауга җавап көтәргә туры килми.

Комлев урамыннан Маяковскийга чаклы, төнге караңгыда, аксый-аксый, ыңгыраша-ыңгыраша, көчкә кайтып җитте Марва. Иртән торуына аягы гөбедәй шешкән иде. Башта аякны кузгата алмыйча ятты. Селкетеп карады, күтәрергә тырышты, ләкин күтәрелмәде. Коточкыч авырта. Сөяк үзе сынмаган шикелле, бәлки чатнагандыр. Гәрчә анысы да сынудан хәерлерәк түгел.

Бөтен көчен җыйнап, караватка аякларын салындырып утыра алды. Бүлмә диварларына таяна-таяна, кухняга чыкты, анда тыныч иде инде.

Күршеләр, иртәнгелекне ашап, эшкә таралышкан. «Ярый әле ничек интеккәнне күрүче юк»,— дип уйлаган була Марва. Һәм үзенең акылсыз уена елмайгандай итә. Аяк сызлавы комачауламаса, бәлки чынлап елмаер иде. Ләкин аяк яна. Дивардан аерылсаң, бигрәк тә. Түзмәсәң, хет кычкыр да җибәр өй яңгыратып...

Түзәргә тырышты Марва. Тырышлык белән түзеп, зур кәстрүлгә су салды. Керосинкага куйды. Су кайнаганны сабыр гына көтте. Минутлар түгел, сәгатьләр узгандыр.

Синең ашыкканыңны сиздеме, шулай бит ул: ут акрын яна, су бирешмәскә, кайнамаска тырыша. Ә син көтүеңне бел. Ярый әле кешесе югалып кала торганнардан түгел. Су кайный башлагач та, кәстрүлне алып, беразын зур чәйнеккә агызды. Бәләкәй чәйнектә чәй пешерде. Бүлмәдә калган каты-коты ризык белән иртәнгелекне уздырды. Төшкелеккә бәрәңге пешерер.

Ә хәзер исә бүлмәгә кәстрүлне алып керергә кирәк. Тагын аксакла, тагын ыңгыраш, түз, чыда. Ә Марваны исә чыдамас, түзмәс димә, кәстрүлне ул барыбер алып керәчәк.

Алып керде дә. Тастымал чылатып, ботына япты. Артсыз урындыкка утырып, икенчесенә аякларын куйды. Тастымал суынганчы утырды. Суынгач, тагын, тагын җылы суга мана торды. Кәстрүлдәге су үзе суынгач, керосинкага куйды, җылытты. Ярты көн шулай узды. Бер көн, узды, ике, өч көн, бер атна узды. Бер атна ятты Марва. Бер ялгызы. Хәл белергә килүче булмады.

«Сәламәт чакта гына кирәк син кешегә. Сәламәтлегең югалса, кирәгең дә бетә икән»,— дип уйлады Марва. Тик яңадан: «Һәркемнең башында җан саклау кайгысы, ил язмышы. Аерым кешеләргә игътибар итәргә вакыт та, көч тә җитми»,— дип, үзен юатырга тырышты. Фикерләве, гамәлләре кебек үк, ихлас иде.

Аксавы бетмәсә дә, ыңгырашуны тыярлык хәлгә килгәч, мәктәпкә ашыкты. Урамда кешеләр алдында аксаклап йөрү җайсыз, дигән уй башына инде килмәде. Бу заманны гариплек белән гаҗәпләндерәм димә. Нинди дә тән кимчелеге булмаган кешене очрату үзе кыенрак хәзер. Шундый тойгы кичергән Марва әкренләп, үзенең зур максатына — мәктәпкә тәки барып җитте. Гадәттәгечә, укытучылар бүлмәсенә сугылмыйча, үз кабинетына керде. Утырды. Өстәлендә кечкенә кәгазь ята — тагын мәгариф бүлегенә чакыралар. Мөгаен, яңа йомыш әзерләгәннәрдер.

Бу юлы чак кына ялгышрак уйлаган иде. Укыту алдынгыларын һәм фронтка ярдәм итүдә актив катнашкан иптәшләрне җыйганнар. Бүлек мөдире нотык тотып, укытучыларның нинди эшләрдә катнашуын яңалык рәвешле хәбәр иткәннән соң, сүзен мисаллар белән ныгытты. Алдынгы укытучыларга, активистларга шәһәр Советы бүләкләрен тапшырды. Бөтен кеше каршында, башкаларга төрле грамоталар өләшкәч, Марвага аерым бүләк — сәгать бирде, аны кулына үк кидерде. Исемен генә кара син — «Слава» ягъни — Дан!

Данга, алкышларга, очрашу, кавышу шатлыкларына күмелгән якты тантанага — 1945 ел бәйрәмнәренә хәтле күпме кара минут-сәгатьләрне, көннәрне, айларны, елларны санады бу сәгать! Шатлыклар түгел, сагышлар, фаҗигаләр санады. Җиңү бәйрәменнән соң, күбесенчә тыныч, иҗади мәшәкатьләрне генә санар дисәк тә, ышаныч күпмедер дәрәҗәдә аклана килсә дә, тормыш барыбер тиз генә җиңеләя алмады. Тиз килгән афәтләр тиз китәргә чамаламады. Беренче нәүбәттә фатир тарлыгы сыйфатында кала бирде. Туган улы белән Анна һаман аерым гомер итүгә дучар килеш. Шөгыльләр, борычлар дигәндә, алары, киресенчә, арта гына барды. Мәктәпкә матди фонд һәм акча бирделәр. Фатир дигәнеңне оныта төш тә яңа бина төзетә башла — яңа мәктәп, иркенгә чыгар балаларны. Килер буын хакында, аларның якты, матур киләчәге хакында борчыл, кайгырт, эшлә, көрәш! Син каршы түгелдер бит шуңа?

Мәктәп директоры Марва Артемовна Михайлова башы-аягы белән төзелеш мәшәкатьләренә чумды. Аккан сулар, күмелгән елларның берсендә авылдан, дүрт бала ияртеп, әнисенең сеңлесе килеп төште. Бер бүлмәле фатирда — икеме-өчме ел газап чигү байтак уйлар уйларга, мөмкин булмаган максатлар өчен төрле бусагалар таптарга мәҗбүр итте. Шактый гына акыл да җыярга мәҗбүр итте шикелле. Ә бит шушы өйдә Аннага һәм сөекле улына урын тар тоелган иде!..

Шулай, кытлык еллар дип тормады, миннән яманрак хәлләрдә яшәүчеләр бар бит әле дип, намус сакларга калмады җай. Битенә чүпрәк капламаска, оялмаска, тиешле кешеләр каршына кереп басарга тиеш тапты — сорады, үтенде. Һәм җиңелде горурлык. Көн-төн дигәндәй йөри торгач, дүрт бүлмәле, дәверенә күрә ярыйсы гына әйбәт, якты фатир эләкте. Аны икешәргә бүлгәч, матур гына яшәп китәргә мөмкин иде, билгеле.

Мэлс, әй, юк, бу чакта инде Мэлхка әверелгән улы Казан педагогия институтына керә алган булса, ана белән бала, ниһаять, кавышачаклар һәм калган гомерләрен бергә уздырачак иделәр дә... Ләкин юк шул, тагын алар уйлаганча килеп чыкмады. Рус теленнән сочинениене икелегә язды Мэлс. Рус теле укытучысы улы...

Гаепне үзеннән күрмичә, хәрәмләштеләр, алдадылар мине дип, ачуланды, гарьләнде, тузынды Мэлс. Гарьлегеннән Казанга төкереп, кире Алабугага кайтып китте. Алабуга институтына кабул ителүе хакында Аннадан хат килгәч, шул хатта малаеның адәмчә исем алуын, ниһаять, Мәлих атлы нормаль кешегә әверелүен укып белгәч, бер сөенде Марва, бер көенде. Авыр сулыш алып, елмайгандай итте, аһ орып боегып йөрде. Исем алмаштыруның күлмәк алмаштыру түгеллеген, бәлки тирәнрәк кичерешләр белән бәйләнгәнлеген генә сизәрлек зиһен бар бит инде укытучы, тәрбияче дигән кешедә... Нәрсә белән бетәр, хәерле бетәрме бу үзгәреш, дип, озак уйланды ул. Бик озак. Менә инде шушы көннәргәчә...

Кесәсендәге хәерсез телеграмманы, инде ничәнче мәртәбәдер, укып, кабат-кабат укып, Марва яңадан сумкасына салып куйды.

Һәм шулвакыт аның самолетта баруы хәтеренә төште.

Самолет буталчык көннәрдән, гүяки, сикәлтәле, чокыр-чакырлы юллардан, нindидер упкын төпләренә дыңк-дыңк төшеп бәреләдә, икенче төрле хатирәләр арасына барып керә. Узган көннәр куе томан эчендә, эңгер-меңгер эчендә, караңгы тоннель уртасында сыман. Югарыда очкан самолет якты яз азагының мең өметле, миллион чәчәкле июнь киңлегенә түгел, әйтерсең, дөм кара тарлыкка алып бара иде. Анда югалган җаннарны, исән җаннарны һәм шулар арасыннан Мәлих улын таба алырмы, күрә, таный алырмы икән Марва? Таба алмас, тапса да таный алмастыр кебек. Исеме генә түгел, җисеме дә алмашынгандыр кебек.

Самолетның Алабугага якынлашуы чамаланган бер вакытта юл сумкасына билет белән бергә салынган телеграмманы янә кулына алды Марва. Меңенче кабаттыр, укып аңларга тырышты. Аңлый алмады. Мең кабат укыгач та төшенерлек сыман тоелмады. «Бәла»... Нинди бәла? Бәла генә булгач, түзәрлек була түгелме соң? Бәла генә булгач, кеше үзе исән дигән сүз була лабаса. Нindидер бәхетсезлеккә тарган дигән сүз. Бәхетсезлек килми торамыни кешегә? Аңа без күнеккән, бәхеткә генә күнекмәгән. Бәхетсезлекләрдән җиңеп чыга беләбез без — бөтен ил белән. Ә менә берәм-берәмгә килгәндә, кыенрак шул...

Самолет бүгенге көннәрдән хатирәләр караңгылыгына кырык биш минут эчендә алып керде. Кырык биш минут — бер дәрес. Бер дәрес бер сорауны ачыкларга җитә алмады. Бүгенге көндә кем көтә Марваны — барча өметләр җыелмасы булган Мэлсмы, фельетон героена тартым Мэлхмы, әллә нормаль бер гади кеше булган Мәлихмы?

Самолет, кыйгач-кыйгачлап, түбәнгә таба төшә башлады.

* * *

Кайчандыр бөтен гаиләләре белән ничәмә ел яшәгән йортны Марва көч-хәл белән генә эзләп тапты. Һәм шундый ук авырлык белән таныды. Таныш та, түгел дә. Коймадан эчтәрәк булуы туры килә. Ләкин монда таш койма юк, тимер, челтәрле койма. Урамга элеккечә чуерташ түшәлгән. Ләкин юл читендәге яшел чирәмнәр, бакча кебек шаулап утырган тирәкләр, каеннар кая киткән? Агач булып агач корыган, таш булып таш койма ауган... Шулай булгач, адәм баласы ничек исән йөрергә тиеш?

Ихатага керергәме, юкмы дип ятсынып торган арада, каршы як өйләрнең берсеннән карт кына бер апа чыкты. Ул, әлбәттә, таныш булырга тиеш. Марва аның каршысына бер адым атлауга, апа үзе дә, барган юнәлешен үзгәртеп, бу якка таба борылды. Марва аны башта таныгандай тойса да, таныш чалымнар таба алмады. Карчыкның сөйләнүе дә ят иде. Ләкин ят булса да, ярдәм итәргә теләве белән үз кеше сыман тоелды.

— Кемне эзлисең? Анна Ивановнаны түгелме?

— Әйе, Анна Ивановнаны.

— Шулайдыр дигән идем дә. Бик дөрес эшләгәнсең кайтып. Әйе. Син Марва Артемовнадыр бит?

— Сез мине беләсезмени?

— Белмичә тегә. Аня көненә мең тапкыр искә алгач үзеңне. Минем улымның әнисе укытучы, Казанның үзендә үк тора дип, мактанып туя алмый. Менә хәзер генә...

Яман хәбәрне чит авыздан ишетәсе килмичә, Марва сүзне тиз генә читкә борды.

— Безнең өй шушы микән?

— Менә инде, шушы булмыйча. Шушы, шушы. Бар, Аня сине ут йотып көтә. Шушы ике көн эчендә бөтенләй биреште, кара кайгыга калды.

Ә Марва, сүзне шунда туктатып, йортны күрсәткән өчен рәхмәт әйтте дә кызу адымнар белән ихатага кереп китте. Ләкин өйгә тиз генә керү насыйп түгел икән. Ишектә йозак иде.

Озакмы, түгелме, көтүдән башка чара юк. Анна кайтканчы, бакча тирәләрен әйләнеп йөрергә мөмкин, искә төшереп... Вармы монда элеккедән калган берәр нәрсә? Өйнең үзеннән башка таныш бернәрсә дә күренми. Бакчаны аерып торган хәзерге койма урынында элек келәтләр тезелеп тора иде. Бакчада зур-зур алмагачлар, чиядер, бүтән куаклардыр кабарып үсеп утырыр иде. Хәзер ничек икән?

Бәләкәй капкадан узам дигәндә, Анна күзгә чалынды. Анна үзе дә тиз таныды Марваны. Икесе дә, мөгаен, телгә алыначак авыр сүзләрне әз булса да соңгарак калдыру өчен, баскан урыннарыннан кузгалырга ашыкмадылар. Икесендә бер уй, бер тойгы...

Уф! Түз, йөрәк! Менә хәзер, берничә минуттан соң ук әйтеләчәк бит хәерсез сүзләр!

Элеккерәк вакыт булса, әллә кайдан ук: «Марва, кадерлем Марва!» — дип йөгереп киләсе Анна, каршында кем торганны ап-ачык күргән килеш, кузгалырга ашыкмады. Кулындагы чиләген җиргә озак һәм азапланып кына куйды, авыр эш диярсең. Чиләкнең аумасына ышанмагандай, ныклап утырткач кына, алай да курка-курка гына, якынлашты. Ун метр араны биш минут килгәндер. Бүтән вакыт булса, кочаклап аласы кеше, берничә сүз кушмыйча, уң кулы белән Марваның ике беләген капшап куйды. Һәм шунда ук елап җибәрде. Марва үзе дә йөрәккә таш булып урнашкан сүзне учлап кыскандай, тел тибрәтмәде. Хәерсез хәбәрнең нәрсә, нинди икәнлеген икесенең дә төшенгәнне сизелгәч кенә, Анна, күзләрен яулык очы белән сөртә-сөртә, алай да томанлы рәвештә:

— Менә, шушындый хәл инде, — дип куйды.

Тәгаен нинди хәл икәнлеге хакындагы сорауны Марва тагын эчендә калдырды.

Өйгә кергәч, зал уртасына урындык китереп куйгач һәм Марва утыргач та, сүз башлаганчы, ишек төбенә барып, Анна чукынып алды. Элек мондый гадәте юк иде. Картая-картая үзгәрә кеше. Тапкан бит әнә шәмнәрен дә. Элек болар юк иде.

Үзенең Марва өчен сәер гамәлен башкаргач, Аннага ихтыяр инде, хәрәкәтләре ныгып, күрәсең, тәвәккәлләргә булды. Марва каршындагы икенче урындыкка утырып, кинаясез һәм ымлыкларсыз гына хәлне аңлатырга кереште:

— Өч дус, исереклек белән сугышып киткәннәр дә... арттырыбрак җибәргәннәр. Кайтып кергәндә канга баткан иде. Ә бер иптәшенә бигрәк тә каты эләккән. Мескенкәй, үлгән...

Нишләргә мөмкин мондый хәлдә? Шул инде, күз яше, сулкылдау, сызлану. Ә Марва — таш кыя. Катты да калды. Нәкъ менә шушындый хәбәр көткән иде ул. Еллар буе шушындый хәбәр көтеп яшәде.

— Ә хәзер? Хәзер кайда ул?

— Кайда булсын инде, төрмәдә.

— Төрмәдә?

— КПЗ дигәннәрендә.

— Денис белән сөйләшмәдегезме?

— Барган идем дә, буш түгел дип, кертмәделәр. Өенә баргач, туры килмәде. Булмады шул, булмады. И-и, карый алмадым шул, тәрбияли белмәдем. Оятын кая куярсың. Сез җибәрә торган акчалардай, җилгә очты тырышлыкларым.

«Их, Анна, синдә генә булса икән гаеп!» — дигән фикерен сүзгә әйләндерә алмады Марва. Уе икенчегә күчкәнче, Анна пайпылдарга кереште:

— Җибәргән акчаларыгыз әҗәткә әйләнде инде болай булгач. Ничек түләрмен. Түләп кенә бетерә торган түгел бит. Кыяматкә алып китәрмен микәнни ул әҗәтләрне? Хәзер инде менә теләсә нишләтегез. Өйдән куып чыгарыгыз да сатыгыз өегезне. Мине дөнья буйлата озатыгыз. Мин шуңа гына лаектыр хәзер. Шул тиеш миңа.

— Аня, Анечка, тынычлан әле, ашыкма. Нинди өй ди ул, нинди әҗәт. Улыбыз бит, шуны уйлашыйк, нәрсә эшләргә, ничек ярдәм итәргә?

— Балакаем! Әйе шул, тәрбияли белмәдем. Бәләкәйдә сөеп туймалы түгел иде, зурайгач үзгәрде. Соңгы өч-дүрт ел эчендә башын кая куярга белмәгәндәй ашкынды. Эчеп кайта башлады. Әрләсәң, «Синең эш түгел, миңа инде унсигез тулганга фәлән ел!» — дип авызны каплый килде. Берни дә эшли алмадым инде, харап кына иттем балабызны.

Бу минутларда Мәлихныкыннан бигрәк, әйтерсең, Аннаның хәле авыррак иде. Әллә аны, әллә улын кызганудан, таш кыя, ниһаять, хәрәкәткә килде. Торып, Анна каршына килеп басты.

— Ул чаклы өзгәләнмә, Аня, бер-бер рәте чыгар. Миңа хәзер Денис Ивановичны күрергә кирәк.

— Әйбәт булыр иде, бик әйбәт булыр иде. Ничек тә коткарырга кирәк бит баланы. Югыйсә, ансыз яшәүдән миңа ни мәгънә?

— Булды, тынычланыйк башта, Аннушка.

— Рәхмәт, миһербанлы булуыңа рәхмәт. Әйбәт җанлы икәнлегеңне белеп иядәшкәнмендер инде үзегезгә. Үз нәсел-нәсәбемне онытып, шуңа күрә синең белән гомер иткәнмендер.

— Тынычландык, булды.

Бу сүз боерык сыманрак яңгыраганлыктан, Анна чынлап та пайпылдаудан шып тукталып, урыныннан торды һәм кухняга кереп китте. Ул арада, Марва Мәлих бүлмәсендәге әйберләрне күздән кичерәсе иткән иде, керә-керүгә авыз ачты да калды.

Нинди генә сурәтләр, кыяфәтләр юк монда! Диварның мөмкин булган һәммә төшендә нинди генә кешеләр юк! Күбесе бил тиңенте ялангач. Хатын-кызларның бөтенләй шәрәләре дә күп. Кеше тәнендә яшеренеп яткан нинди түбән инстинктлар булса, барысы — күз алдында.

Ул төсләр, буяулар! Әнә бер гыйбрәте кулына үз гыйбрәте хәтле микрофон тоткан да, өметсезлекнең ахыр чигенә житкән рәвештә авызын киергән, кычкыра, бөтен дөньяны сасытып акыра. Сурәт кенә хәлендә дә колак пәрдәләрен ертырлык тавыш белән бакыра. Ә сәхнәдә җырлаганын тыңласаң, колаклар тонудан, баш мие түнүдән читкә чабарлык зиһен чаткысы кала микән?! Йөгәнсезлеккә, оятсызлыкка ишарә рәвешле итеп, тиешсез җиргә асылынган бил каешы һәм аның чуклары — билнең иң түбән төшендә. Төшәсе килгән чалбарны өскәрәк күтәрәсе, ә бәлки аскарак шудырасы килә төсле. Ә шәрә тәненең төсе! Пычрак кызыл — кан бозыклыгы, җан кабахәтлеге, фахишлеге дә шул төстә тантана итә — төкерәсене китерә. Бу шакшыны башкалары алмаштыра. Фахишә кызлар, фахиш егетләр, зәңгәрләр, наркоманнар. Барча гариплекләр кыяфәтләренә, чырайларына язылган. Кычкырып, акырып торалар, укыйсы да, тыңлыйсы да юк — үзләре синең теләгеңнән тыш та дөньяга игълан итәләр. Әйе, рәсемнәрдә генә килеш тә яралар колакны! Ә үзләрен тормышта, чынлыкта тыңлап карасаң? Ул чакта инде нинди кыяфәткә керәчәгеңне алдан әйтү һич тә мөмкин түгелдер. Нинди ерткыч җанварга әвереләчәгеңне Ходай да чамаларлык түгелдер. Ә тыңлыйсың килсә, рәхим ит, әнә, пластинкалар шкафларның барча киштәләрен тутырган. Малай, мөгаен, шуларны тыңлый-тыңлый акылдан язган. Акылдан шушы ысул белән язуның өстенлеген шул кыргый авазлар һәм төсләр барлыкка китерде бит...

Бу сурәтләр, бу пластинкалар теләсә кемгә эләкми. Өр-яңа стиль белән яши алучы зирәк кешеләргә генә тәти алар. Чит илләр белән бәйләнештәге кешеләр белән аралаша алсаң, акчаң булса, җорлыгың, чаялык дәрәҗәң тиешле кимәлдә булса гына элгә сиңа болар. Мәлихнең, димәк, акчасы күп, астыртын көчләр белән аралашу осталыгы да җитешле булган. Башын кисмәгә куеп әйтә ала Марва, бу коллекцияләр арасында ул кайчандыр җай килгән саен, вакыт тапкан саен тыңлый торган һәм тыңлап һич тә туя алмый торган «комсомолка Гөлсара» һәм «Партизанка Гөлсара»ны таба алмаячак.

Эзләп мәшәкатьләнәсе юк. Ә менә акырбайлар музыкасын тыңласаң, әле кичергән уйларны, хисләрне чынлыкта тоеп расларга мөмкин булыр иде. Ләкин Мәлихның әнисе Марва уйнаткычны ничек көйләргә икәнен белми шул. Ярый, калып торсын. Монысы әһәмияткә ия нәрсә түгел. Зур шәһәрләрдә мондый тавышларны хәзер һәр өйдә ишетергә мөмкин.

Ә менә кечерәк калаларга көнбатыш сәнгате, аның иң гаугалы үрнәкләре килеп җиткәндер дип, һич уйламый иде Марва.

Улы бүлмәсеннән ул пычранып чыккандай тойды. Бу авырлык Казанда телеграмма алгач, аннары самолетта очкан чакта, аннары менә Анна Ивановна хәбәрен ишеткәндәгедән һич ким булмагандыр. Күңелдә хәвефле уйлар бермә-бер артты. Түземлек бир, ходай, ярылмасын йөрәк — барысы, барысы шул кечкенә йөрәккә шыпылдап тула лабаса. Түз, йөрәк, ярылма!

Анна төшкелекне бәйрәмчә мул әзерләсә дә, тамактан ризык бөтенләй үтмәде дисәң дә ялган булмас. Ашаган атлы булып бер йомыры чәй эчкәч тә урыныннан купты Марва.

— Мин барып карыйм әле, Денис Ивановичка дим.

— Бар, бар, Марвушка, ныклап, әйбәтләп сөйләш. Безнеке генә түгел, аның да улы лабаса.

— Хәерле юл телә.

— Уң булсын юлың.

Марва әкке эшләр бүлегенең кайда икәнен Аннадан ныклап сорашкан иде. Тегесе бик җентекләп аңлаткач, гомумән, үзенә хас кыю адымнар белән булмаса да, күзләре дөньяны томанлы итеп күрсә дә, шәһәр үзәгенә таба атлады. Кешеләрдән бүтән сорашмыйча гына, чамалап кына, йортларның ишек катындагы язуларын укыбрак булса да, артык интекмичә тапты тиешле йортны.

Монда инде көчсезлек сиздерергә ярамый. Мондый җирдә мөнәсәбәтләр — кырыс. Һәм үзеңне шулай тотмасаң, сине санга сукмаячаклар. Һәм Марва хәрәкәтләрне тоткарлаган барлык авыр тойгыларны бер тирән сулыш белән күкрәгеннән өреп чыгаргач, битләреннән амин тоткандай сыпырып төшергәч, ашыкмый гына ишек ачып, ныклы адымнар белән өч-дүрт кенә баскычлы эчке күтәрмәдән узды да, коридор буйлата «Кабул итү бүлмәсе» дип язылган ишекне эзли китте. Мондый бүлмәләрнең, гадәттә, коридор азагында булганын Марвага аңлатып торасы түгел. Һәм тәҗрибә алдамады.

Кирәкле ишекне тиз табып, кыю гына ачып керде. Алгы бүлмәдә — начальник ишеге төбендәге өстәл артында яшь кенә милиционер утыра. Исәнләшкәч тә йомышын әйтте Марва.

— Денис Иванович үзендәме?

— Бүген гражданнарны кабул итү көне түгел.

— Ә сез хәбәр итегез аңа.

— Анда хәзер үзебезнекеләр. Хезмәт вазифалары буенча. Аннан соң Денис Иванович райкомга китәчәк.

— Ә сез аңа әйтегез, кем килгәнне.

— Сез кем соң?

— Мин — Михайлова.

— Ничек? — Бу сүзне әйткәндә, милиционерның чырае яктыра төште. — Сез... Сез аның туганымы әллә?

— Әйе, бик якын туганы. Марва Артемовна Михайлова. Ике минутлык кына вакыт табуыгызны үтенә, диегез. Сездән шуны сорыйм.

Милиционер үрә катты. Башын чак кына иеп, чигәсен капшап алгач, начальник бүлмәсенә кереп тә китте. Тынлык. Ким дигәндә эчтә дүрт-биш минут торгандыр. Эш турындагы сүзләрне тиз генә бүлдерә алмагандыр. Әйе, нәкъ үзе. Баягыдан җитдирәк кыяфәттә чыкты.

— Хәзер алар тәгәллиләр. Тиздән чыгарлар. Алар чыккач керерсез. Утырып торыгыз.

Марва, милиционер чыккач, нишләптер аягүрә баскан булган икән. Инде яңадан утырырга мөмкин. Кабул итмим дип кире борган булсалар, нишләр иде. Аерылган ирләр күбесенчә кырыс кылана. Ә Денис Иванович төпле кеше. Гомер буе җитди булды. Бәләкәйдән үк дияргә кирәк.

Алар беренче тапкыр моннан... моннан төп-төгәл кырык ел элек танышканнар иде.

...Чистай шәһәрендә элекке, революциягә кадәр, ике гимназия — ир һәм кыз балалар гимназияләре булып, дөнья тынычлана төшкәч, аларны берләштергәннәр иде. Берләшкән шул гимназиядә тугызынчы сыйныфны бетергәч, авылдан махсус килгән бабасы Марвага кул сәгате бүләк итте. Гимназиядән чыкканнан бирле шул сәгать санады Марваның хезмәт елларын. Сирәк кешеләргә эләгә торган бүләк иясен, өр-яңа ап-ак сәгате текелдәп торган унҗиде яшьлек кызны Чистайдан ерак булмаган Катюма дигән зур авылга укытучы итеп җибәрделәр. Анда ул башлангыч мәктәпнең икенче сыйныфын укытты. Алар — кырык ике бала, алтышарлап, җиде партага утырганнар. Дәфтәр, кәгазь дигән нәрсә, ә иң мөһиме, китап дигәнең монда телгә дә алынмый. Карандаш-каләм, хәтта кара да юк. Марва сүзләрне класс түрендәге кара тактага яза, ә балалар аларны аспид дигән бәләкәй кара тактачыкларга күчерә — дәфтәр дә шул, китап та. Һәркайсының кулында — акбур.

Шулай уза иде дәресләр: тел, арифметика гына түгел, рәсем дәресләре дә.

Балалардан соң, үзләренең командировкалары белән, укырга дип бирегә булачак кызылармеецлар — армиягә чакырылачак егетләр килә. Алар белән дә өч сәгать эшлисе. Шуннан соң гына укытучылар көндезге ашка китә алалар.

Төштән соң, сәгать дүртләрдә наданнар килә — кырык кеше. Монысы — аеруча кыен шөгыль. Эштән сүз күбрәк. Көндезге дүрттән кечке җидегә чаклы утырасың, тәмам хәлдән тайгач, кичке сигезләрдә өйгә кайтып егыласың. Шуннан соң да әле иртәгесе дәресләргә әзерләнергә кирәк. Аннары, авылга килгәннән соң ай уздымы-юкмы, өстәмә вазифа — олыс Советы башкарма комитеты әгъзасы итеп үрләттеләр, житмәсә. Укытудан тыш, атнага бер тапкыр ул кич буе, ә кайчакларда төннәр буе кәгазьләр кыштырдатып утырырга тиеш. Гаризалар, отчетлар, шәхси эш документлары, белешмәләр... Күбесенчә, яза белмәүчеләр өчен үзенә язарга, исәпкә алырга, тиешле кешеләргә тапшырырга туры килә.

Тарткан атка, билгеле инде, күбрәк төйиләр. Марва бит бик кулай белгеч — рус телен дә, татар телен дә белә, чувашча, мукшыча аңлаша ала. Ә кешеләрнең күбесе ярдәмгә мохтаж. Бу бит — коточкыч афәтләре белән килгән 1921 ел. Ул елны җирдә үлән дә үсмәде, агач яфрак ярмады. Кара, вәхши дәвер...

Шулай көннәрнең берсендә башкарма комитет рәисе Марваны чакырып алды да, өстәл янына үзе ук китереп утырткач, алда тагын да аламарак хәлләр көткәнлеген тасвирлап сөйләде. Аяусыз ачлык көтелә, аңа хәзердән әзерләнә башларга кирәк.

— Мин сезне, комсомолец Денис Михайлов белән Чистай шәһәренә җибәрергә тиеш таптым. Яшерен эш. Икегез генә белергә тиешсез. Сандыкларда кыйммәтле әйберләр булыр. Шул әйберләрне Чистайга илтеп тапшырырга кирәк. Соңыннан алар бәясенә икмәк алу өчен. Ризамы син шуңа?

— Риза булмыйча инде.

— Рәхмәт, шулай диярсез дип ышанган идем дә. Юлга әзерләнегез.

Икенче көнне таң белән Марва чиркәү янына килде. Анда пар атлар җигелгән бричка тора. Башкарма комитет рәисе Марваны күрүгә, каршына ук килеп, бричка артында торган егет янына алып килде:

— Менә сиңа безнең алтыннан да кадерлерәк кызыбыз. Алтынны саклагандай сакла.

Егет мәгънәсе ачык булмаган ымлык кына чыгарып куйды. Денис атлы, егерме яшьлек егет шушы иде. Гәүдәгә Марвадан бер башка калку. Буе озынча булса да, йөзе түгәрәк. Хәрәкәтләре житез. Бер карауда ук: «Уңган егет булырга тиеш», — дип уйлап өлгерде Марва атлы унҗиде яшьлек кыз.

Ул да булмады, рәис белән Денис чиркәү эченә кереп киттеләр. Чыгулары да озакка сузылмады. Ахылдый-ухылдый зур сандык өстерәп чыктылар. Каршыларына йөгереп, Марва да күтәрешкән булды. Таш төялгән кебек иде сандык. Аны бричкага салу тагын да кыенрак булды. Әгәр дә чиркәүдән чыгып, ике кеше ярдәм итмәсә, күтәрә торган түгел иде. Бричкага менеп, Денис белән Марва тартса, астан рәис белән шул ике әзмәвер күтәрделәр. Сандык әйбәт кенә урнашты. Ләкин моның белән эш бетмәгән икән. Ирләр тагын чиркәүгә кереп, янә шушындый ук тагын бер сандык алып чыктылар. Анысы да урнашкач, ике каравылчы чиркәүдә калса, рәис бричкага менеп, арттагы сандыкка, Марва белән янәшә утырды. Денис түр сандыкка кунаклап, кулына дилбегәләрне алды.

— На-а! — дип, дилбегәләрне тарткалады.

Рәис:

— Исполкомга сугылыйк әле, — дигәч, йөкне урамның икенче чатына борды. Башкарма комитет ygарына кереп, сандыклар өстенә күп кенә итеп печән төяделәр.

— Атларга азык кирәк бит, — дигән булды рәис абый. — Ак булыгыз, бер җирдә дә тукталмагыз. Бигрәк тә — урман тирәсендә. Ял итәсегез килсә, кырда гына тукталырга мөмкин. Анда да кешеләр күренмәсә генә. Аңладыгызмы?

Бу юлы ымлыктан уза төшеп, егет:

— Аңладым, булды,— дип баш какты.

Марва да шул сүзне кабатлагач, рәис абый хәерле юл теләп калды.

Киттеләр.

Чиркәү алдында бричкага салган чакта ук, караңгы булуга карамастан, Марва сандыкларның һәр икесенең дә ат башы хәтле икешәр йозак белән бикләнгәнен шәйләгән иде. Хәзер шуларга күзе төште. Димәк, мондагы байлыкның бәясен чамаларга мөмкин. Соңыннан Марва үзе утырган сандык эчендә нинди әйберләр икәнен тәгаен белде. Сандыкларга йөзләрчә килограмм затлы нәрсәләр тутырылган иде — көмеш тәреләр, айлар, көмеш һәм алтын савытлар, вазалар, чынаяклар, тәлинкәләр...

Алар өстендә, рәис абый әйткәнчә, тагын да кыйммәтлерәк булган Марва атлы кыз утыра...

Боларның барысы өчен Денис исемле егет җаваплы, Марва, күрәсең, иптәшкә генә чакырылган. Һәрхәлдә, Марва да кирәксез түгелдер. «Сезгә, бары тик сезгә генә ышана алам»,— диде бит рәис абый, бричкага төягән чакта.

Атлар куганны көтмичә дә күңелне күтәрерлек юырта, чаба бирде. Ара — җитмеш биш чакрым. Арымасыннар гына инде. Шуны чамалап булса кирәк, Денис таулырак җирдә аларны тыя төшеп, атлатып кына барды. Озакламый, куркыныч җир — Бүре бистәсе дигән зур чокыр һәм шактый арага сузылган куе урман. Шунысы ярый, бу төшкә җиткәндә, көн яктыра башлаган иде инде. Әмма бөтенләй үк тынычланырга иртәрәк иде әле.

Сагаю дөрескә чыкты. Урман буеннан илле-алтмыш метр чамасы читтәрәк ике шәүлә калыкты. Саклап ятканнар, әлбәттә. Ләкин, атлап кына килгән арба тавышы ишетелми калгандыр, кинәтлек форсатыннан файдалана алмый калдылар. Денис алар белән очрашырга әзер иде. Пар шәүлә калкуы булды, Денис үзенең аяк астыннан нидер алып, Марвага сузды. Мылтык, берданка!

Марва сискәнеп куйганлыктан, аңа катгый төстә боерык бирде:

— Тот, нишләргә икәнен үзем әйтермен.

Шул сүзне әйтүе булды, икенче секундта атларны камчылап, бар булган көчләренә чаптырырга кереште. Атлар дулагандай котырып чаба — шәүләләрнең, әйтерсең ки, нәкъ өсләренә. Юлбасарлар аптырабрак калдылармы, бүтән сәбәп беләнме, шактый вакыт урыннарыннан кузгалмый тордылар. Әйе, күрсеннәр, гаҗәпләнсеннәр, алар качар дип уйлаган кешеләр туп-туры өсләренә килә. Чаба һәм якынлаша торгач, шәүләләр аермачык кешеләргә әверелде. Битләрен шарф белән каплаганнар. Димәк, танышлар, танытмаска тырышалар. Таныш булмасалар, төс-битләре хәтердә калмасын өчен шулай эшләгәннәрдер. Әгәр җайлы туры килсә, атларның тезгеннәреннән эләктерергә әзер болар. Ниятләре шуңа охшый. Берсенең кулында — винтовка.

Мәгәр Денисның өркергә нияте сизелми, һаман туп-турыга куа гына атларны! Тәгәрмәчләр дөбердәве, җил сызгыруы колакта әллә нинди чинаулар булып, уй-фикерне томалый, куркуны каядыр очыра. Җилдән тизрәк булып бричка оча. Юлбасарлар белән ике арада инде нибарысы — утыз метр, егерме, ун метр... Һәм Денисның йокымсыр табигатьне сискәндерерлек көчле тавышы, кискен боерыгы:

— Ат, тарт чакманы!

Марва күз ачып йомган арада торып басты һәм... юлбасарлар кызыл яулыклы чибәр кыз бала күрүгә беравык аптырап, таң калып тордылар бугай. Тиешле хәрәкәтне ясый алмый калдылар. Берсенең хәтта күтәрелгән винтовкасы түбән иелде. Ә Марва шул арада чакмага басты һәм мылтык тавышы тегеләрне тагын берничә секундка йөгерүләреннән туктарга мәҗбүр итте. Алар олауны коралланмаган дип уйлаган булса кирәк. Әмма алар югалткан бер-ике секунд эшне хәл итте дә куйды.

Секундлар эчендә, кинәт кырыйгарак каерылып, канатлы аргамаклар болар яныннан ажгырып узып та китте. Бераздан һушларына килсәләр дә, соңгарак калганнар иде инде. Хатаны төзәтергә ашыгулары шулай ук файда китермәде, алар ата башлаганда, Денисның яңа боерыгы Бүре бистәсен яңгыратты:

— Иел!

Һәм Денис үзе дә ятты, зиһенгә фикер килеп өлгергәнче, Марваны да үз янына аударып өлгерде. Бу мизгелдә өстә пуляләр сызгыруын, һәм аларның сызгырып-шакылдап бричка артын тишкәләүләрен аерымачык ишетергә, тоярга мөмкин иде... Никадәр генә явыз, зәһәр булмасын, бричка тактасын тишә алса да, әлеге сандыкларны тишә ала торган ядрәләр ясалмаган иде әле.

Атлар да әкияттәге туплардан калышкысыз булып чыкты. Денис бричка эченә чумгач та, дилбегәне тарткалый-тарткалый кычкырып, камчы белән суктырып куган кеше булмаса да, куркыныч хәлне әллә алар да сизделәрме, тизлекне һич киметмичә, ә киресенчә арттыра гына төшеп, чын тулпарча томырылып очуларын белделәр. Сынатмадылар малкайлар. Һәм, әлбәттә, егет белән кыз да төшеп калганнардан түгел икән. Әйе, алар да кирәк вакытта каушап калмадылар. Куркынычның күзенә карап узып киттеләр. Тагын шунысын искә алу ярыйдыр, Марва дәһшәт янаган минутларда көчле канатлар, ышанычлы куллар кочагында иде. Ядрә түгел, җил дә үтәрлек булмады. Шул канатлар ихтыярына буйсынгангамы, ятсынырга вакыт җитмәгәнлектәнме, Марва егеткә һич тартынусыз сыенган булып чыкты. Кыз шуны төшенгән мәлдә егет үзе дә һушына килде булса кирәк, ату тавышлары тынгач, беләкләрен бераз бушайтты. Мәгәр артта тавышлар тынганны сизгәч тә, арба дөбердәвен тыңлап, шактый ара тыныч ятып барды. Бер-берсенә елышкан булуларын сизмәгәнгә сылтау җае төкәнгәч, битләр кайнарлыгы тоела башлагач та читкә тайпылышырга бик ашыкмадылар. Алар өчен каушап, арба гына калтырый иде. Күпмедер вакыттан соң арба калтыравы шулай ук кимеп, тына, тынычлана язды. Куркынычның артта калганлыгын атлар, әлбәттә, сизде. Шул ук вакытта егет белән кызга да торып утырырга ымлаулары шул булгандыр. Атларның житезлегенә һәм зирәклегенә күңелләреннән рәхмәтләр әйткән егет белән кыз сүзсез сикереп тордылар. Чырайларында бернинди кыенсыну, оялу галәмәте юк иде. Хәтта киресенчә, һәр икесе үз урыннарына кабат җайлап утыргач, карашлары очрашты. Карашлар елмая, бер-берсенә шатлыклы нур сирпи иде.

Юлның калган өлешендә шик-шөбһә тудырырлык шәүләләр күренмәде. Чистай шәһәренә матур гына шакылдап һәм дөбердәп кердeләр. Катюма олысы башкарма комитеты рәисе кушканча, башта аның әтисе өенә тукталдылар. Рәиснең әтисе икенче рәис — Чистай районы җитәкчесе белән очраштырып, анысы исә, бричканы шәһәр банкына илтергә кушты. Ара ерак түгел иде. Үзе дә шунда барды. Эчкә кереп кем беләндер сөйләшкәндер, әлбәттә. Бераздан чыгып, банкның кырыйдагы зур тимер капкалары ачылды да, Денис йөкне ихатага алып керде. Һәм тиз арада ниндидер көчле адәмнәр сандыкларны җилтерәтеп алып та киттеләр. Банк дигән йорт ишекләреннән аларның гаҗәп җиңел узганын Марва кызык итеп карап калды.

Чистай рәисенең яңадан чыгуын ким дигәндә сәгать буе көтәргә туры килгәндер. Бу арада Денис атларга туйганчы печән ашатырга өлгерде. Ул бер ат янындарак торганда, Марва, аның үрнәгенә ияреп, икенче атны ашатты. Атларның баш кагып куюы, печәнне куллан тартып алулары кызык тоелып, Марва ихлас көлә, Дениска күз сала. Егет аңа шундый ук якты күзләр белән карап елмая. Уртача зурлыктагы коңгырт күзләр. «Татар егетенә охшаган», — дип уйлап куя кыз бала.

Үз вакыты белән чыккан рәис абый Марвага (нишләптер, егеткә түгел) ниндидер кәгазьләр тоттырды да, эшкә йомгак ясагандай итеп, рәсми тавыш белән шуны әйтте:

— Бөтенесе тәртипле килеп чыкты. Ә бу расписканы үзегезнең рәисегезгә тапшырырсыз. Шуның белән сезнең йомышыгыз үтәлде. Бетте, исән кайтып җитегез. Алла ярдәм бирсен.

Катюмадагы үз рәисләре дә шул сүз белән озаткан иде. Чиркәү һәм мәчет байлыкларын икмәккә әйләндерү кәсебен башкарганда, Алла ярдәменә таяндылар. Шуңа күрәдер, хәвефле, куркыныч юл хәерле тәгәлләнде.

Марва белән Денис юлда егет белән кыз икәнлекләрен тойганнардыр, әлбәттә. Ләкин сугышчан бурыч үтәгән ике яшь көрәшченең үзләрен сынаган беренче батырлыклары шушы икәнлекне алар башларына китерә алмадылар. Денис алда, ямчы урынында, Марва аннан арттарак печән өстендә, һәркайсы үз уйлары белән юл узды. Алда яңа сынаулар, яңа революцион йомышлар көтә иде.

Бричка эчендә мәҗбүри рәвештә кочаклашканга ничә ел узды икән? Исәпләү кыен түгелдер. Әйе, фаҗигале бетү ихтимал булган хәтәр сәфәрне бергә үткән егет белән кыз, очрашулар корып, дуслык, мәхәббәт йолаларын китереп тормадылар. Моның өчен аларның вакытлары җитмәде. Шул беренче очрашудан соң өч ел узгач кына, Денис мәктәпкә килде. Бу вакытта ул — район эчке эшләр бүлегенең оператив вәкиле иде. Галифе чалбар, гимнастеркадан, портупея... Ялтырап торган хром итекләр. Гәүдә зифалыгын арттыра төшкән, ефәк төсле кара чәчләре артка таралган. Коңгырт күзләренең теге чактагы тынычсыз кискенлеге генә кими төшкән. Үтә нәзек нур җепләренең җемелдәп, ялтырап куюында усаллык урынына каушау галәмәтләре генә чагылып куя.

Наданнар дәресенә, шуларның берсе сыйфатында килгән иде Денис. Дәрес беткәч кенә өстәл кырыена килеп басты. .

— Синең белән сөйләшергә кирәк,— диде.

Тавышы рәсми һәм катгый тоелганга күрә, Марва сагайды:

— Әллә берәр гаебем бармы?

— Гаебең юк.

— Әллә тагын берәр сугышчан бурыч үтәргәме?

— Шундыйрак җаваплы эш.

Шундыйрак җаваплы эшнең нәрсәдән гыйбарәт булуын ул кайтышлый урамда аңлатты.

— Мине Себергә эшкә җибәрмәкчеләр.

— Чынлапмы?

— Әгәр мин сорасам, минем белән Себергә китәргә риза булыр идеңме?

— Котыпка җибәрсәләр дә...

— Котыпка җибәрсәләр, иптәш була алыр идеңме?

— Иптәш дип... анысы...

— Ну, Котыпка минем белән бара алыр идеңме?

— Бара алыр идем.

— Шуннан да җитдирәк нәрсә булса? Шундый эш булса?

— Синең белән булса...

— Башка кеше өчен сөйләшмим. Үзем өчен сөйләшәм. Сүзем шул, Марва, шул иде сүзем...— Егет тотлыкты.

— Ишетәм, ишетәм. Соң? Тагынмыни? Тагын хәтәр юлга чыгабызмы?

— Хәтәр дип... Анысын белеп булмый инде аның. Шул инде... Әгәр син риза булсаң, гаилә корыр идек. Риза булсаң.

Марва өчен кинәтрәк сүз булгангамы, беразга тынып калдылар. Шактый баргач кына, Марва җиңелчә көлеп куйды:

— Бик тә җитди эш икән шул.

— Куркынычмы?

— Куркыныч, тик...

— Тик, тик...

— Синең белән булгач... Котыпка да бара алам, дидем бит. Аңлашылмыймыни?

— Аңлашыла. Төгәлрәк әйтсәң, тагын да яхшырак булыр иде.
— Төгәле шул — әйдә яшәп карыйк.
— Яшәп карыйк.
— Мин риза.
Килешүгә кочаклашу, үбешүләрсез генә кул куелды. Кочаклашу, үбешүләрсез генә дүрт-биш кунактан торган кырыс туй (кызыл туй, ягъни) уздыргач, «яшәп карый» башладылар. Икесенә бер кечкенә бүлмә таптылар. Беренче балаларына Энгельс дигән исем куштылар.
Ул чакта: район эчке эшләр бүлеге башлыгы Денис Иванович Михайлов ишеге төбенә һаман да укытучы булган Марва Артемовна Михайлова сыйфатында күрешү сорап, кабул итү бүлмәсендә шушылай озак көтеп утырырга туры киләчәк дигән уй башына килеп караса икән лә!
Менә монысы кызык килеп чыкты. Менә ичмасам бу — дөнья! Шулай килеп чыкты ки, менә ул көтә. Көтте. Инде милиция формасындагы кешеләр чыгып беттеләр бугай. Инде Марвага торып басарга вакыт, ишек ачарга. Ләкин ул кузгала алмый. Кизү милиционер егеткә хуҗасына караган маэмай күзләре белән карый ул. Егет, шул карашны аңлап, сүз әйтергә авыз ачканда гына, диварда кыңгыраучык зыңлап куйганга, авызы кире йомыла һәм егет җәһәт кенә ишеккә чума. Секунд эчендә кире чыга:
— Денис Иванович Сезне көтә.
Марва ишек төбенә килеп, ишеккә кул сузган иде, нишләптер кулы яңадан асылынып калды. Монысы ни икән, нинди хис, нинди кичереш? Нинди гамәл белән моны чагыштырырга? Иң охшашы шулдыр: парашют белән беренче сикерүче хәле белән чагыштыру дөресрәктер. Батыраерга тырышасың, һәм... куркасың. Җилкәнә катгый боерык бәреlә... Беткән баш беткән. Һәм син — һавада, теләсәң нишлә...
Кизү егет хәбәрен ишеткәч, Марва үзен нәкъ шул халәттә дип хис итте. Ачты ишекне, керде, атлады. Кеше, әйтерсең, үз авырлыгын җуйды. Шулай авырлыгын җуйган хәлдә, кайчандыр кадерле булган, ышанычлы дусты булган ят кешегә якынлашты. Аңын җуяр-җуймас килеш, Денис Ивановичка текәлеп, тынсыз, сулышсыз калды. Улмы соң бу? Улмы?
Хәзерге вакытта опалага төшкән юлбашчыларның берсенә охшаш. Шулмы әллә? Нәзек кенә җыйнак мыек, сүренкерәк коңгырт күзләр кысыла төшкән. Кискенлек тә, җылылык та сизелми. Кем соң бу?
Ни хәтле генә тырышып караса да, үзенә кирәкле кешене таба, таный алмады Марва. Ул утсыз да ялкын сирпеп торган көчле, житез хәрәкәтле кеше күрергә дип килгән иде бит. Ә аңа һичбер тойгысыз караган бу күзләр... Күзләр... Тукта, тойгысыз һәм тыныч сыман тоелган күзләрдә таныш очкыннар ялтырап куйды түгелме соң? Әйе, сизелә язды сыман таныш төсмерләр, сизелә язды кебек. Көмеш төсле мыеклар өстендә ят җыерчыклар гына комачау иткән бугай танырга.
Мөгаен, Денис Иванович та бераз каушаган булгандыр. Һәм шул сәбәпле урыныннан кузгала алмый торгандыр. Менә бит, бераз ис алгач, кузгалды, торып басты. Соңлабрак булса да, кайчандыр яраткан кешесен адәмчә каршыларга кирәген төшенде. Ике-өч адым алга атлап, Марва каршына килеп басты. Марваның кул биргәнен көтте. Ә Марва ни көтә? Көтәме? Марва нәрсәнедер ачыкларга тырыша.
— Син... Сез... Денисмы? Денис Ивановичмы?
— Сез — Марва Артемовна?
— Әйе, мин — Марва Артемовна.
Шуннан соң да кул бирешә алмадылар. Тик шунысына шөкер, телләре бераз чишелә язды.
— Бәлки, утырырсыз? — дип, бүлмә хуҗасы урын тәкъдим итә белде.
Марва, буй өстәл янындагы урындыкларның берсенә утыргач, хуҗа, өстәлнең икенче ягына чыгып, өстәл янына ук булмаса да, аның каршысына утырды. Берничә секунд тынлыктан соң, вакыты кысан булганлыктан, башлап үзе телгә килде:

— Исәнлек-саулыклар ничек. Әйбәтме?
— Моңарчы түзәрлек иде, рәхмәт.
— Әйбәт кенә килеп җиттегезме? Самолет беләндер?
— Самолет белән.

Сүз тагын төртелде. Болай кизү сүзләр белән мавыгыр вакыт бармы әллә!

— Сезнең миңа йомышыгыз бармы?
— Бар иде шул.
— Башлыйк, алайса.
— Ә сезнең миңа җиткерәсе хәбәрегез юкмыни?
— Минем? Каян килеп?
— Ай-яй! Менә ничек!

Ата кеше нинди бәхетле! Һич кайгысыз... Тып-тыныч, битараф хәтта. Җитмәсә, гаҗәпләнеп сорый ул:

— Миннән берәр хәбәр көтеләмени?
— Инде нәрсә әйтим? Шул алайса, хәтерегездә булса, безнең улыбыз бар иде.
— Ә-ә, менә ничек. Улыбыз... Хәзер дә бар ул.
— Кайда?
— Сез беләсез.
— Сез белмисез. Әйтим алайса, ул — шушы йортта. Менә шушы дивар артындагы «КПЗ» дигән зинданда.— Денис Иванович мәрмәр сынга әйләнгәч, сүзне тагын дәвам итте:
— Минем аны күрәсем килә.— Денис Ивановичның күзләре идәнгә текәлә.— Мөмкинме шул эш?
— Мөмкин түгел.
— Түгел? Шуңа да көчегез җитми?
— Судка чаклы, тикшерүче рөхсәтеннән тыш, очрашу рөхсәт ителми.

Марваның иреннәре көзән җыергандай булып, дерелдәп куя. Сүз әйтер өчен оеша алмый. Ә Денис Ивановичка, әйтерсең, барыбер. Улын кирәк эшафотка алып китсеннәр, гүя ки, мыеклары да селкенмәячәк. Әнә, утыра бит шулай. Иреннәре калтырамый һәм, мөгаен, күзләре дә әчетми.

— Бәхетле ата, нинди күңелле! — дип, инде мөнәсәбәт белдерергә мәҗбүр була Марва.
— Алай ук арттырмасагыз, яхшырак булыр иде.
— Сизүемчә, сезнең вөҗданыгыз тыныч.

Менә шушында мыек селкенеп куйды. Ата кешенең чыраена ризасызлык билгеләре чыкты. Ата кеше, кемгәдер ачулангандай, пошкырып куйды. Һәм аның үртәлүе, Марвага йогып, күзгә күренмәле галәмәтләргә әверелде. «А»ны әйттеңме, «Б»не әйтергә туры килә:

— Сез моңа ничек юл куйдыгыз? Милиция башлыгының туган улын аның җитәкчелегендәге кешеләр, аның үзе эшләгән йортка китереп ябалар. Дивар артында гына улы ыңгыраша. Атасы исә, ишетми генә түгел, ишетсә дә бәхетле булып яши бирә. Кайда, кайчан күрелгән мондый нәрсә? Һәм моны ничек дип исемләргә? Законга табыну белән генә аңлатырга буламы шушыны?

Денис Иванович — янә торатащ. Янәсе, ишетми, хәтта колак та салмый. Әмма ялгыша, күрә Марва, селкенә мыек төкләре, кысыла горур иреннәр, тартыла нерв кыллары, мыек төкләреннән һич ким булмаганча.

Әйе, сорау җавапсыз калмый торган дәрәҗәдә туры һәм кискен куелды. Ихтимал, болай булгач, хәлнең ничек килеп чыкканын аңлатмый ярамас...

Һәм Денис Иванович, дивар янындагы урыныннан кубып, өстәлнең икенче ягына, Марва утырган ягына чыкты. Кайчандыр аралары берни белән дә аерылмаган ир белән хатын өстәлнең капма-каршы якларында булырга тиеш түгел, дип уйлады, диярсең. Инде арада киң, озын өстәл түгел, ләкин нәрсәдер һаман бар. Кайчандыр туп-туры караган хатын

иргә кырыйдан карый. Кайчандыр бик якын булган дус еллар аръягыннан карый. Аңа жавап итеп, кайчандыр ышанычы, таянычы булган ире, шулай ук ерагаеп, үзенең рәсми урындыгына күчеп, каш астына яшеренә. Ләкин кырын күзләр күрә, сизә, өстәл өстенә ике кулын куйган Денис Иванович как тактаны сыпыргалап, юкка вакыт әрәм итә.

— Дөресен әйткәндә, монда үзенә күрә ялгышлык бар. Егетләр Мишаның (Мәлих дия алмый аның теле) миңа мөнәсәбәте барлыгын белмичә кулга алганнар. Икенче көнне әйттеләр:

— Миша икән Миша, Михайлов икән, Михайлов, азмыни шундый исемле, шундый фамилияле кешеләр. Шуңа күрә, игътибар итмәгәнмен. Өченче көнне допрос алганда гына беленгән.

— Ә билгеле булгач? — дип сабырсызланды Марва.

— Анда инде...

— Көчегез житмәде.

— Нинди көч? Закон көче хәзер. Минем бу очракта бернинди хокукым юк. Закон бөтен кеше өчен бер.

— Ансат икән, бик тә.

— Ә сез нишләргә кушар идегез?

— Коткарырга! Бердәнбер улың бит!

Үзе дә сизмәстән, йөрәк үрсәләнүенә чыдый алмыйча кычкырып жибәргән Марвага Денис Иванович тагын берни әйтә алмас булды. Үзе дә үртәлеп, тынды. Берничә минут сүзсез утырганнан соң гына яңа тәкъдим кертте:

— Хәзергә шушында тукталып торыйк. Миңа райкомга барырга кирәк, бюро утырышына. Теләсәгез, кич минем өйгә килерсез.

— Сезнең өйгә... Анда бара алмам шул. — Яшь хатын алдында утыра алмам диясе килмичә, шулай диде Марва.

— Бәлки Сез үзебезнең өйгә килерсез? Таба алырсыз бит?

Үчекләбрәк әйтелсә дә, шаяртуга тартым сүзгә хәтере калмыйча, Денис Иванович:

— Эзләп карарбыз, — дип, елмаерга тырышты. — Бәлки табып та булыр. Сез монда озак торасызмы әле?

— Мәлих белән күрешә алганчы.

Әңгәмәнең тагын житдигә әйләнүен теләмәгән Денис Иванович жавапны ашыгыч кайтарырга тиеш булды:

— Алайса шулай, элекке өйгә үзем сугылырмын. Кайчан?

— Мөмкин кадәр тизрәк, үзегез беләсез...

— Әйе, мөмкин кадәр тиз.

Урамга бергә чыксалар да юллары тиз аерылды. Денис Иванович үзәккә таба, ә Марва кирегә, елга ярына таба юл тотты. Кайчандыр аңа бик тә якын булган урамнарга хәзер күз дә төшми. Үз уйларыннан аерыла алмый Марва, уңга-сулга карамыйча, кешеләргә күз салмыйча гына кайтып жителде.

Ичмаса, Анна түземсезләнмәсә икән. Ризык өмет иткән маэмай кыяфәтендә туп-туры күзгә текәлде, хәбәр көтә:

— Ничек?

Их, бер сүз белән генә жавап бирергә мөмкин булса! Марва сораганны көтмичә үзе үк жәһәт кенә хәбәр итәр иде. Хәзер менә барып чыкмаган эшне, дөресен әйтеп, һич гаепсез кешенең күңелен янә бер тапкыр жәрәхәтлә инде. Тик әйтмичә дә булмый.

— Берничек тә түгел. Үзе монда киләчәк.

— Өмет бар алайса.

— Син беләсең ич Денисны — аяклы закон. Ай-һай, үгетләп кара син аны.

Өмет юк дәрәжәсендә дисәң дә, сөйләшмичә ярамый. Хәл шундый — тырышып карарга кирәк. Килсә әле. Әгәр килмәсә? Килергә тиеш. Сүзне әйттеме, Денис Иванович анысын үтиячәк. Димәк, көтәргә.

Аның бу өйдә булмаганына инде күпме вакыт икән? Кырык ел чамасы? Хәзер аңа бу өй ничек тәэсир итәр? Гомумән, яшь чакта яраган нәрсә хәзер килешерме? Ягъни, бу өйгә ник килгәненә үкенмәсме?

Шул фикер тугач та, Марва Мәлих бүлмәсенә кереп китте. Нормаль кешенең, бигрәк тә үтә җитди, кырыс кешенең монда җене котырырга мөмкин бит.

Диварга кнопкалар белән ябыштырылган теге сурәтләрне берәм-берәм куптарырга керешге. Кәгазьнең гаебе юклыгын белгән килеш, барыбер җирәндерә. Ямьсез, оятсыз, шәрә тәннәр чиркандыра. Ул кәгазьләрне Марва бармак очлары белән генә тотып өстәлгә җәя торды. Әле генә дивардан, почмаклардан карап торган һәм бозыклыкка, җенеси хәрәкәтләргә чакырган күзләр, кыланышлар инде күренмәс, ишетелмәс булды. Аларның барысын Марва, верандага чыгарып, шкаф түбәсенә куйды да тагын өйгә керде. Урнашкан тәртипнең нindirәк икәнлеген күздән кичерде. Шкаф ишекләренә һәм пыялаларга ябыштырылган төрле спорт төрләренә кагылышлы сурәтләрне, эмблемаларны куптару артыкка китәр иде, ләкин берсенең яңагына икенчесе типкән бәндәләр... Түзәргә туры килә, җилем белән беркетелгәнне куптару кыен. Аннары бит Денис Ивановичның боларны тормышның үзендә дә күп мәртәбәләр күреп, күзләре иярләшкәндер. Ярый, калсын. Ә тагын нәрсә?

Денис белән Марва бергә торганда, караватт түрдәрәк һәм чыбылдык эченә яшерелгән иде. Чыбылдык дигәннәре хәзер борын заман галәмәте булып калган нәрсә, ә менә караватны үз урынына күчерүдән зыян булмас. Элекке рәвешләрне күрү, яшьлекне сагыну дигән тойгы уятмасмы...

— Анна, Аннушка!

Анна көттермәде.

— Минем анда аш кайнап чыгасы иде,— дип, ишек төбендә тукталды.

— Әкрен уттадыр, берни эшләмәс. Шушы караватны гына күчереш әле, зинһар.

Аннаның үзенә дә элеккечә булуы ошый икән. Тиз арада бүлмә түренә күчте караватт. Аннан бушаган урындагы тузанны Марва сөртергә керешкәч, Анна кухняга ашыкты. Бераздан, көндезгелекне аннан-моннан гына капкалагач, инде дүрт күз белән Денис Ивановичны көтәсе калды.

* * *

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас. Шулайрак килеп чыкты. Марва белән Денис баладан икенче тапкыр да уңа алмадылар. Беренчесеннән — Энгельстан башланды бәхетсезлек. Мәктәптә бүтән алмаштырырлык кеше булмаганлыктан, Марваны бала туып ай узгач ук эшкә чакырдылар. Мәктәпкә кул баласы белән йөреп булмаганга, аны карарга яшь көнә бер кызны ялларга туры килде. Башта кыз ярыйсы гына тоелса да, тиз арада харап та итте баланы. Бер көнне Марва эштән кайтса, капка төбендә үк баланың ачыргаланып кычкыруы, үксеп елавы ишетелде. Дер калтырап өйгә йөгереп керсә, кыз кулында — бала. Шап-шап сөйгән була, «ә-ә» дип көйләгән, чайкалдырган була, ә бала үкси бирә. Кызның үзенең дә көй шыңшыймы, елыймы икәнен белерлек түгел. Өйгә керү белән Марва баланы үз кулына алса һәм юатырга азапланса да, газабы кимемәде баланың, тынычланырга җыенмады. Нишләргә дә белгән юк. Бала елый, кыз үзе дә чынлап еларга тотына. Анысы бераздан тына, ә бала төн буе чәбәләнеп, үрсәләнеп чыга.

Төнгелеккә аны бишеккә салдылар. Чиратлап тирбәткән булдылар, ә файда барыбер юк. Үкерә генә бала. Ул үксегәндә, ана күңеле ярсый. Күзләрне яшь томалый. Йоклый алмау белән бергә, зиһенне томалаган әрнү аркасында, бишекне ул катырак тартып җибәргән иде, бер мәлне

түшәмдәге ыргактан ычкынып, бәллү идәнгә лап итеп төште куйды. Ярый әле пружина читкәрәк туры килгән, югыйсә Марва үз баласын үзе үтерәсе булган икән. Шушы хәлне исенә төшерсә, йөрәге хәзер дә дерт итеп китә, тәне чымырдый.

Идәнгә егылып төшкәч, бала елаудан шып туктады. Тынычланды бала! Кулга алгач та шыңшымады. Әллә үлдеме дип, селкетеп караса, тере иде үзе. Урынга салгач, хәтта йоклап киткәндәй тоелды. Борсаланмыйча, үрсәләнмичә ята бирде. Ләкин барыбер нәрсә дә булса эшләргә, чарасын күрергә кирәк иде. Шуна күрә, Марва, таң белән торып башкарма комитет рәисенә хәлне елый-елый аңлатты. Рәис Марваның кем икәнен яхшы белә — ярдәм итәргә булды. Әйбәт кенә ат җиктереп, бер кеше яллап, бала караучы кызның үзе белән бергә, сабыйны Алабугага озаттылар. Дәү әнисе күзәтчелегенә бара, янәсе, тәрбияле булачак. Ләкин бала, шәһәр урамына кергәндә, соңгы сулышын ала иде инде. Дәү әнигә сабыйның мәетен тапшырдылар...

Соңыннан билгеле булганча, тәҗрибәсез кыз бер айлык балага бодай боткасы пешереп ашаткан булган икән!

Ул чакта Марваның кайгырганнары! Тик кайгырып ни, кулдан бер нәрсә дә килмәгәч... нишлисең.

Шулай Марвага үз баласын үзенә тәрбияләргә насыйп булмады. Укытуның, киләчәк буынны тәрбияләүнең сәяси һәм рухи әһәмиятен, ил каршындагы изге бурычның намус белән үтәлергә тиешлеген аңлаткач, тәкать тота алмады шул. Көн-төн дигәндәй, эшен элеккечә үк дәвам итәргә тиеш булды. Ата кеше шулай ук ярдәм итә алмады — анысы тагын өйгә кайтып керми диярлек. Тирә-якта — качкыннар, бандитлар, дошманнар...

Җир өстендә 1924 ел иде. Энгельс атлы беренче бала шул елда, көрәштә һәлак булды.

Шуннан соң Марва бала табу дигән нәрсәдән ваз кичәргә карар кылды. Икенче бала туганчы, ун ел узды.

Денисны эше буенча күчерүләре аркасында, берничә ел Чистайда яшәгәч, Марваның әнисеннән өйгә кайтуын сораган хат килеп төште. Кайтып керсә, әнисе зар елый — йә үзең белән алып кит, йә үзең монда кайт, дип ялвара. Моңарчы төпчек улы һәм килене белән тора иде. Бианасын килен эләккә асылынып хәлгә җиткергән.

Марва туган йортка кайтырга булды. Бер-ике елдан алар янына Денис та кайткач, өчәүләп шушында байтак вакыт матур гына гомер иттеләр. Матурлык һәм бәхетнең тере гәүдәләнеше буларак, 1938 елда икенче бала дөньяга килде. Инде ялгышырга ярамый, баланы карарга җитдирәк кеше табарга кирәк иде һәм табылды да андый кеше. Алар белән бергә, Анна яши башлады. Өйнен дә, күңелнең дә кинлеге җитәрлек иде.

Балага исем кушу шулай ук заманга муафыйк рәвештә башкарылды. Әниләре әллә чынлап, әллә шаяртып: «Энгелс дип кенә кушканга күрә әрәм булды бала, бер генә юлбашчыны аерып алгач, калган өчесе рәнҗегәндер, мөгаен», — дигән иде бер мәлне. Юлбашчыларны аермау, тигезләү, бәхиллләтү өчен уртак фикергә киленде: икенче балага Мэлс дигән бөек мәгънәле исем куштылар.

Озак еллар бүләге булган тансык бала, дөньяга килеп, үз исеме белән яшәп китте. Гаилә бәхетенең иң тулы чорын ядкарь итеп калдыру нияте белән, Денис сөекле хатынына ул чакларда тормыш матурлыгының тәгаен бер мисалы булган бүләкне — аяз күк йөзе төсендәге патефон һәм гаҗәеп яңгырашлы пластинканы нәкъ шул сөенечле, якты көннәрдә алып кайтты да инде. Кадерле бүләк үз төсе белән дөньяны гомер буе яктыртып торыр өчен шушы йортта күңелле яңгырап калды:

Туплар шартлый, җирләр тетри...
Йолдыз якты, төн кара.

Мылтык алып, кылыч тагып,
Ак бандага каршы бара
Комсомолка Гөлсара.

Батыр кыз әнисенең адашы булган өчен генә түгел, ә бәлки тәрҗемәи хәле белән дә якын иде Марвага. Бу якынлыкны, охшашлыкны Денис, әлбәттә, дөрес сизгән. Соңыннан да: «Бу Гөлсара нәкъ син инде, тик үлеп калуы гына туры килми»,— дип кабатларга ярата һәм чип-чиста урыс акценты белән булса да, аермачык аңлашылырлык дәрәҗәдә җырлап та куя иде:

Зур сугышта дошманнарның
Йөрәгенә ут сала.
Ләкин үзе... яраланып,
Киң далада ятып кала
Комсомолка Гөлсара.

Дуслар җыелган чакларда бу җыр башкарылмыйча калмый. Марва, ялгыз калганда, күбесенчә шушы җырны җырлап күңел юата иде.

Мәгәр дөнья, хәерсез, көтелмәгәнчә үзгәрә торды шул. Тормыш үзгәрешләре аркасында, бала унсигез яшенә җиткәндә, исемнең соңгы хәрефе фаш ителгәч (әлбәттә, бәлигъ бала монысын үзе хәл кылды), егет Мәлхка, ә аннары, гөнаһ шомлыгы, яңа хәреф иясенең дәрәҗәсе төшә башлагач, халыкча бик гади генә — Мәлих булып китте. Ләкин Мәлихны да таныш-белеш һәм дус-иш дигәндәй, кабул итеп бетермичә, Миша дип йөртә. Тирәлек тәэсире белән аның үз колагы да шушы соңгы атамага ныграк күнекте. Бүгенгесе көндә күпләр аны шул исеме белән беләләр дә.

Анна апаны әйткән дә юк, аның теле башка исемнәрне әйләндереп әйтә дә алмый иде. Денис Иванович өчен дә малае Миша икән. Шулай булган килеш, милиционерлары «Миша Михайловны» тотып китергәч, үз баласы икәнлеге башына килмәгән. Бәлки зиһенен исемнәрнең күпкәрәк китүе бутагандыр. Кем белсен.

Анна кунакны, тәрәзәдән күреп, капка төбенә үк чыгып каршылады. «Әйдә Денис Иванович, сине дә күрер көн бар икән, зарыгып беттек, рәхим ит» — дия-дия, өйгә алып керде.

Ниһаять — Ул! Ишек төбендә — Марва каршында басып тора. Граждански киемнән. Саргылт плащ, эшләпә. Коеп куйган интеллигент. Мондый кыяфәттә аны Марваның беренче күрүе. Ничектер, күңелгә якын булып китте. Күңелгә аз булса да җылылык иңде.— Хәерле кич, Марва,— дип Денис Иванович үзе дә, әйтерсең ки, нәкъ элекке күзләр белән карап елмайгандай итте.

— Хәерле кич, Денис!

Анна исә, беренче якты чаткыларны сүндерергә теләмәгәндәй, кунакны баягыдан да матуррак сүзләр белән чишендереп, киемнәрен чөйгә үзе үк илтеп элде. Иң түрдәге урындыкларны тәкъдим итте. Алгы бүлмәдә бераз утыргач та, кунак башка бүлмәләрне карарга теләк сиздерде. Бәлки, тиз генә сүзгә керешәсе килмәгәннәндер. Марва үзе дә хисләренең бераз тынычлануы, тигезләнүе, читләшкән күңелләрнең яңадан күнегә төшүе өчен төп сүзне хәзер үк башламау ягында иде. Күрәсең, ике як та бер төсле уйлый, хәзергә дөрес бара — кабаланмый, ашыкмыйлар, ашыктырмыйлар. Менә хәзерге Мәлих бүлмәсенә, ә дистә ел чамасы элек ир белән хатын булып яшәгән бүлмәгә керделәр. Күзләрдә якты төсләр тагын да арта төште кебек. Денис җыелган караватның нәкъ урта турысына килеп, хәтта шунда утырып та карады. Бу мәлдә Марва шкафтан нindидер пластинкалар барлый иде. Денис улының китапларын актарып торган бер вакытта өйдә музыка яңгырады.

Дошманнар күп иде тирә-якта,
Туплар шартлый иде кырларда.

Дошманнарга каршы икәү бергә киттек,
Үткен кылыч алып кулларга.

Синең атың алмачуар иде,
Минем атым тимер күк иде...

Денис сискәнеп башын күтәрде. Марва янына килде. «Беләм, хәтерлим» — дигәнне аңлатып, баш какты. Марва белән Денисны бәхетле иткән уртак җырларның берсе — шушы бит. Күбесе югалган инде, ә менә монысы, могҗиза белән, исән калган. Күңелле дә, моңсу да. Музыканың үзе генә түгел, аңа бәйле вакыйгалар, еллар моңы. Бергә кичелгән юллар...

Кайчандыр яшь кыз белән егет, кайчандыр ир белән хатын булган ике зат, ничәме ел аерым яшәгәннән соң, менә тагын иң бәхетле, ләззәтле, икәүсенә генә билгеле булган истәлекләр калган бүлмәдә очраштылар. Бу юлы очрашу сәбәбе бөтенләй бүтән төрле дә бит, нишлисең. Тәкъдир шушыннан артыгын бирмәгән, күпсенгән. Бәлки, шушысына да шөкер итәргә кирәктер әле.

Күңелле дә, ямансу да булган таныш җырны һәм хатирәләрне бүлдереп, залдан Анна керде. Кичке аш әзер. Ялындырмыйча гына залга чыктылар.

Өстәлгә нәрсә генә куймаган Анна Ивановна! Тозлы балык һәм кәбестәне әйтеп тормастан, табынны базарда гына була торган җимешләр, язгы чорда гына, авылда гына коела торган как, кисәкләргә бүленгән тавык, кызыл һәм сары винегрет... тагын әллә нәрсәләр бизәп, матурлап тора. Кай арада! Һәм шулар уртасында дип әйтик, соңгы елларның мәҗбүри атрибуты булган ярты кукраеп утыра.

— Әйдәгез әле, күңелегезгә нәрсә ошаса, тәрилкәләргә шуларны сала башлагыз. Җитешегез.

Анна чын мәгънәсендә кунак итә башлады. Аннары ул татарчалап:

— Теге әйберне дә тотасызмы соң? — дип, шешәгә ымлады да мәгънәле итеп елмайган булды. Үзенчә шаярта, янәсе. Бүгенге көнгә шунысы да җитеп торадыр, билгеле.

Дистә чамасы ел өйдә төп эшне башкарган, чынлыкта Марваның да, Денисның да ярты әниләренә әйләнгән кешене рәнҗетүдән, курку катыш ихтирам йөзеннән, алар аның сүзенә илтифатсыз була алмыйлар, әлбәттә. Икесенең дә йөзенә, сыек булса да, яктылык иңә. Марва чак кына елмаеп куйды хәтта. Элеккечәрәк гади генә:

— Бераз, бәлки, ярыйдыр, Анна хөрмәтенә, — дип, Дениска карады.

Марва өчен әңгәмәнең хәзергә шушы тирәдән читләшмәве, аз гына булса да куркыныч темага якынлашмый тору хәерлерәк. Денис та, мөгаен, шул ук фикердәдер. Әнә җөпләде бит хатыннар тәкъдимен.

— Соң, хатыннардан калышу килешмәс инде ул, — дип, шулай ук елмая төште.

Һәм шул сүз белән шешәне үз кулына алды. Бөкене ачты. Ә рюмкаларны аның алдына Марва куйды. Нәкъ элекке бәхетле чаклардагыча!

— Марва әйткәнчә, беренче тост Анна Ивановна хөрмәтенә. Исәнсау булсын, бәхетле булсын. Ул бит безнең икенче әниебез.

— Әй, рәхмәт, Денис Иванович, зур рәхмәт.

Шул рәвешле, күтәрелде беренче һәм аннан ары тагын берничә рюмка. Тора-бара күңелләр дә күтәрелә төште. Әйтерсең, оныткла язды очрашуның төп максаты. Һәркайсының эче тулы ут булса да, һәркайсының җанында баш калкытырга торган шомлы уй ятса да, һәркайсы йөрәк авыртудан кычкырып җибәрергә әзер булса да, уһәчләргә куллар белән басып, шул ачы авазны, шул агулы уйны томаларга тырыштылар. Һәркайсы аерым-аерым, ләкин уртак тырышлык белән сыйны кабул иттеләр. Әйтерсең, өйдә — элекке матур кичләрнең берсе. Әйтерсең, нәкъ элеккечә — идән бетереп, тәгәрәп сөекле уллары йөгереп йөри...

Житмәсә, Марва, элекке йокы бүлмәләренә чыгып, баягыча музыка җибәрде. Бу юлы да беренче мәхәббәт кабынган давыллы еллар авазы яңгырады:

Дан приказ ему на запад,
А ей в другую сторону...

Бар иде бит, бар иде лә ачлык-ялангачлыкны үчекләгән мәгънәле, хәзер билгеле булганча, матур, гәрчә үкенечле еллар! Ишетелә, яңгырый бит әле шул чорларда гына тулысынча аңлашылган көрәшле, фикерле, максатлы яшәү, җанның бөтен кәтүкләре дә әйләнеп гүләгән дәртле, мең өметле, иртәгә чыгасы кояш шикелле якты хыял, идеал дип йөртелгән иртәнге көн!

Әмма дөрес аһәң, бу юлы да, нишләптер, бик озакка җитми, бер урында әйләнә, ары китә алмый. «В другую, в другую...» — дип, баш миендә бөтерелә. Уйнаткычның энәсе бер сырда әйләнә. Һәм бу әле генә түгел, вакытлыча гына түгел ахрысы, гомерлеккә шулай булып чыкты.

«В другую, в другую, в другую... сторону!..»

Һәм ни өчендер күзләр әчетә. Әчетү яшькә әйләнмәсен өчен Марва күзләрен сөртеп куя, иреннәрен кыса. Һәм әнә Денисның да чыраена җитдилек кайта. Бераздан соң ул табыннан кубып, зал түрендәге креслога күчә. Нәрсә уйлый ул шушы сәер минутта? Шунысы хак, хатирәләр аның өчен дә көчен югалтып бетермәгән бугай.

Күпмедер вакыт ял иткәч, сулыш алгач, Анна табынны тәртипкә китерү шөгыленә керешсә, Марва ватык пластинка урынына тыныч авазлар гына ишетелерлек яңа пластинка куеп, Денис каршына килеп утырды.

— Нишләргә соң безгә?

Сорауның нәрсә, кем хакында булуы, әлбәттә, ап-ачык.

— Әйе, әйе, нишләргә мөмкиндер.

— Мин үтенәм.

Аптыраулы тынлык сәгать буе сузылгандыр кебек. Денис үзе өчен хәлиткеч мәсьәләне чишәргә тиеш иде. Моңарчы ул гомере буена бер генә нәрсәне дә үзе өчен файдалана белмәде һәм теләмәде. Дөресрәге, андый уйны башына да китерә алмыйча яшәгән кеше ул. Ә хәзер исә, Марва — аның беренче яраткан кызы, беренче хатыны — каршында ялварулы күзләре белән томраеп утыра. Инәлеп-инәлеп карый кайчандыр бик тә матур, бик тә якты, бик тә сөеп карый белгән күзләр. Әгәр «юк» — дисәң, елап җибәрәчәк, Денис хатынының нык күңелле, кыядай какшамас кеше икәнен дә белә. Мәгәр бу юлы бирешәчәк. Үтенечен, ялваруын кире каксаң, соңгы көннәргәчә кичермәячәк, күзгә күренмәячәк. Ләкин икенче як шулай ук чигенүне кичерә алмый бит. Бирелгән ант — присяга бар! «Ватаным өчен, халык бәхете өчен соңгы тамчы канымача көрәшергә ант итәм. Әгәр антымны бозсам, Ватаным, халкым мине иң кырыс җәзага тартсын».

Ант Денис Иванович Михаилов өчен ритуал гына түгел. Бу — аның үз иманы. Беренче куркынычларга ук аны шул иманы алып кергән иде. Марва белән бергә...

Шуңа күрә, көтелмәгән сорау туды:

— Марва, син үзеңне революционерка дип исәплисеңме?

Гаҗәпләнмичә нишләсен Марва.

— Ник алай сорыйсың? Беләсең ич.

— Тагын ишетәсем килә.

— Исәплим, әлбәттә.

— Бу юлга кереп китүеңнең сәбәпләре бар идеме, әллә агымга иярепме?

Сорауның болай куелышы тагын көтелмәгәнчә булып, икенчедән, ул бераз рәнҗетә торган тоелса да, бу минутларда түземсезлек эшне бозарга мөмкин иде. Шуңа күрә җавап җитди бирелергә тиеш.

— Минем бу юлга кереп китүем,— диде Марва мәгънәгә басым ясап,— тулысынча аңлы рәвештә булды.

— Тәгаен сәбәпләр, мин әйтәм, булгандыр бит?

— Сиңа сөйләмәгән идеммени?

— Сөйләгәнеңне хәтерләмим. Бәлки, онытылгандыр.

— Алайса, исеңә төшереп карыйм.

Денис креслодан диванга күчеп, хикәя дәвамында диван артына әле башын, әле кулын-беләген куеп, ахрысы, тойгыларга ук бирелеп утырды. Һәрхәлдә, хәбәр аңа кызык өчен түгел, ә бәлки фикер ныклыгы өчен кирәк иде. Бер сүзне дә ычкындырмыйча тыңлады. Анна исә, чәй әйберләре китерү шөгыленнән бүтәнне белмәгәндәй һәм белергә теләмәгәндәй, шым гына йөренә бирде. Аннары кухня ягында йомылды. Хикәянең үзенә килгәндә, анысы болайрак иде.

* * *

Марваның булачак әнисе Гөлсара кияүгә чыккач та, аның әтисе аларга (ягъни яшь гаиләгә) Алабуга шәһәрендә менә дигән өй салып бирә. Үзе Ерыклы дигән авылда тегермән хуҗасының ярдәмчесе булып кына эшләсә дә, зур хуҗа, язгы ташу вакытында урыныннан купкан турбинаны коткарам дип бозлар белән аккач, аның улы кәеф-сафа сөрүдән уза алмаганлыктан, чынлыкта үзе хуҗа иде. Тормышы мул, көйле. Аның ярдәме белән Марваның әти-әнисе дә интекми генә гомер сөрәләр. Әтисе — тимерче, һөнәрленең көне бар. Әмма нәрсәдер җитми аңа. Нидер эзләп, егерме биш яшьлек хатынын, дүрт баласын калдырып, каядыр китеп югала ул. Марваның дәү әтисе салдырган шушы йортны исәпләмәсәң, калдырган бөтен байлыгы — егерме биш сум акча ...

Дәү әтисе Марваның әнисен үз янына чакырса да, ире кайтуга өмет җуймаган әнисе өен ташламый, көтә. Балалар ач булмасын дип, сату өчен икмәк пешерә, прокатка машина алып кием тегә, бәйләү бәйли. Озын көннәр һәм төннәр буе шулай эшләп-моңаеп, ирен көтә. Ә ир күренми.

Ир унҗиде ел вакыйгалары эчендә кайный. 1918 елда ачлык кичергән Петроград эшчеләренә азык белән ярдәм итүче бригада комиссары итеп куела. Ил буйлата йөри торгач, Бөгелмә янындагы Бәйрәкә дигән авылга кайтып җиткән икән. Петроград өчен икмәк эзлиләр һәм тапканны җибәрә торалар. Бер мәлне әлегә шул авылда бер кулакның бик күп ашлык яшергәнен беләләр. Керә болар ихатага, абзар-кураны тентиләр. Табылмый икмәк, юк. Ә Марваның әтисе исә ындыр тирәсендә эзләнә. Һәм бер вакыт печән эскерте яныннан иптәшләренә кычкырып та җибәрә:

— Егетләр! Ашлык монда!

Егетләр шаулашып килгән арада каяндыр йорт хуҗасы килеп тә чыга һәм өч җәпле сәнәк белән комиссарның аркасына кадап та өлгерә. Сәнәк гәүдәне аркылы тишеп чыга. Комиссар баскан җиреннән егылып шул урында җан бирә.

Егетләр кулак абзыйны шулай ук баскан төшендә атып үтерәләр.

Унбиш яшьлек Марвага әтисе үлеме хакындагы шушы хәбәр килгәч, әтисенең эше аның эше булып әверелә. Ул — революция каһарманы кызы... Ачларга, изелгәннәргә хезмәт итү, аларның киләчәге өчен көрәшү, әтисе язмышын кабатларга әзер тору. Бөтен булганы менә шушы икән...

Ләкин соңгы вакытта фикерләр үзгәреп тора. Аның әтисе каһарман булганмы, әллә талаучымы, әйтү кыенлашты...

— Да-а,— дип сузып куйганнан соң, Денис та байтак вакыт бәлки шул хакта уйлана калгандыр.

Марва аны ашыктырмады. Шулай булуы дөресрәк иде.

Шактый озак уйланганнан соң гына, хикәянең очын югалтмыйча, Денис шундый сорау бирде:

— Әгәр без аларны хаклы дип исәпләсәк?

— Аңлап бетерә алмадым бугай.

— Революция ачны, изелгәнне яклап, гаделлек урнаштыру өчен ясалды. Ә без хәзер шул кагыйдәбезгә хыянәт итәбезмени?

— Хәзер күп нәрсә үзгәрде. Әхлак үзгәрде. Нәфес зурая бара — матур яшәп калырга әгъва бар.

— Бүтәннәр әшәке дип, без дә пычраныйкмы?

— Бер генә очрак ... Без бит бары тик бер генә очракта ... Җитмәсә, үзебезнең гаепне төзәтү йөзеннән.

— Вөҗдан ул бар яки юк. Чиста яки пычрак. Соңыннан аны чистарту ... Ай-һай. Ул бит күлмәк түгел. Ә балалар каршындагы гаебебез ... анысы гаеп микән? Вакыт җитмәү безнең аркадамы?

— Барыбер ... Икәү бергә булсак, вакыт табыла язган булыр иде. Ә без ... Ике малай да безнең вөҗданда.

— Алай гына микән?

— Өлешчә булса да җитеп арткан.

Денис үзен почмакка кысрыклангандай тойды бугай.

— Да-да, шайтан алгыры! — дип, үзенә хас булмаганча үртәлде, диванның бер төшеннән икенче төшенә шуышты.

Марва, аның хәленә керүне тиеш санап, тагын ашыктырмады. Көтте. Һәм Денис бераз тынычлана төшкәнне, нәрсәдер әйтергә җыенганны сизгәч кенә, кирәкмәгәнне әйтә күрмәсен дип, бүлдерергә ашыкты:

— Үтенәм!

Денисның тел төбендәге баягы сүзен бүлдереп дөрес эшләгәнлеген, Денисның икенче төрле фикергә күчә башлавын аның икеләнеп торуыннан чамалау җиңел иде. Әнә бит, икеләнүе чыраена ук чыккан:

— Алайса ... Алайса ... Әгәр үлгән егет гариза бирмәсә ...

— Үлгән егет? Гариза?

— Ну, әнисеме, туганнарымы ...

— Әле гариза юкмы?

— Әлегә юк. Булуы мөмкин — судка. Шуңа күрә ...

— Сөйләшеп карарга кирәк. Шулаймы?

— Һәрхәлдә, тырышып карау зыян итмәс шикелле.

— Мин риза. Иртәгә үк эзләп табам. Ә син — үзеңчә.

— Карарбыз.

Марвага шушы җитеп тора. Элекке иренең кем икәнен яхшы белгән Марва шушысына канәгать. Денис Иванович, димәк, кулыннан килгәнне эшләячәк.

* * *

Анна Ивановна әйтүенчә, Гайсаның әнисе күп еллардан бирле урта мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Анна Мәлсны беренче, икенче классларда укыганда озата бара, каршы ала торган иде. Баланы көткән араларда аз-маз сүз алмашырга да туры килгәне бар. Гади татар хатыны. Аннаның үзе кебек үк — дөньяга дәгъвалары зур түгел. Җан асрарга ризык, йоклап ял итәргә урын булса, шул җитә.

Мәктәпкә кояш белән торып юл тоттылар. Анда балалар күренгәләгәнче, класслар чиста, идәннәр юылган яки себерелгән булырга тиеш бит. Җыештыручының эше иртә бетә. Китеп барганчы, күреп калырга кирәк.

Мәктәпкә барып кергәч тә, Марва аскы катта төрле стендлар, күргәзмә әсбаплар карап калса, Анна бүлмәләр буйлап Гайсаның әнисен

эзли китте. Һәм озак көттермичә, урап та килде. Хәбәре шул: ханым тиз арада ҙска төшәчәк.

Марва сәгатенә карады. Дәресләр башланырга әле байтак вакыт бар. Ләкин монда юл өсте, рәтләп сөйләшеп булмас. Өске катта берәр бүлмәме, аулаграк почмакмы табу хәерлерәк булмагае. Аннага нәрсә, күнде. Өченче катка күтәрелделәр. Гайса әнисе җыештырган класс ишеге әллә кайдан күренеп тора — ачык. Коридорның азаккы бүлмәсе. Якынлашканда, нишләптер, адымнар акрынайды. Ничек итеп, җәрәхәтле ана күңелен рәнҗетмәслек сүзләр табарга?

Килгәнне сиздереп, Марва ачык ишекне шакып куйды. Эчкә уздылар. Исәнлек-саулык сорашкач, Анна аларны таныштырды. Хатынның исемен Марва үзе сорады — Халисә икән. Апа да, сеңел дә түгел, өлкәнрәк тоелса да, яшьтәш чамасыдыр. Шуңа күрә, Марва аның исеменә бүтән эпитетлар кушмыйча сөйләшергә тырышты. Беренче сүз итеп, ана кешенең чүпрәк сыгып шуны себерке таягына — лентяйкага каптыруын күзәткәннән соң:

— Халисә, бәлки бераз утырып торырбыз? — диде. Һәм үзе якындагы парталарның берсенә килеп утырды.

Себеркесен ычкындырмаган хәлдә, ике парта ара калдырып, Халисә дә утырды. Чыраенда чак кына гаҗизлек, нәрсәнедер аңларга тырышу сизелә иде.

— Мин үзем, гомер буе дигәндәй, укытучы, — дип башлады сүзен Марва. — Сезнең улыгызны укытырга туры килмәде. Туры килүе дә мөмкин иде.

Улы турында сүз чыккач, әни кеше, шундук елап та җибәрде. Күзләрен сөртим дигәндә, себерке сабы ычкынып, дөпелдәп төште. Өч хатынның өчесе дә кинәттән сискәнеп куйдылар. Ләкин Марва, фаҗига тойгысына ирек куймас өчен, сүзен дәвам итәргә ашыкты:

— Мин сезнең кайгыгызны уртаклашам, — диде ул ихлас күңелдән. — Ныграк булырга тырышыгыз инде, Халисә, артык өзгәләнмәгез ...

Рәхмәт әйтергә зиһене җитмәгән Халисә җавап урынына тагын сызланып кына куя алды. Әңгәмә бер генә яклы булып кала бирде. Шулай да хәлне дөрес аңлаган Марва Халисәнең каршына ук килеп басты.

— Аңлыйм, Халисә, шундый да зур фаҗига. Алла ярдәм бирсен. Шунысын да әйтим, бу зур фаҗига минем башка да төшкән кайгы. — Халисә күз күтәреп карагач, дәвам итте:

— Сезнең улыгыз белән минем улым бик якын дус булганнар бит.

— Сезнең улыгыз ... Мишамы әллә?

— Әйе.

— Ул урыс малае түгелмени?

Мондый сорауга гүяки җавап таба алмыйча, Марва сүзне икенчегә борырга тиеш тапты:

— Теге усал егет тә аларның дусты булган икән.

— Костяны әйтәсездер. Гайса аның исемен әйтеп үлгән.

— Үзем өчен дә фаҗига дигәнем шул, Халисә, ике дус сугышып киткәч, эчкелек аркасында, минем улым кыйналганны яклый алмаган. Моның өчен сездән мин гафу үтенергә килдем. Гафу итегез, Халисә.

— Гафу дип ни ...

— Мин үзем тәрбияче булмасам, бәлки игътибар итмәгән булыр идем. Һәркем үзе өчен үзе җавап бирә. Рәнҗетелгәннәрне яклау-якламау һәркемнең үз эше дип исәпләргә була. Ләкин бит мин — педагог. Беренче чиратта үз улымны чын кеше итеп тәрбияләргә тиеш идем. Ләкин чынлыкта алай килеп чыкмады. Менә минем улым кирәк вакытта үзенең дустын яклый алмаган, хулиганнан курыккан. Куркыныч каршында үзен ир егет итеп күрсәтә алмаган. Менә шуңа күрә бик җайсыз булды миңа, оялдым. Сезнең алда да бик кыен хәлдәмен. Шуңа күрә дә бу — сезнең хәлегезне белү өчен дә, гафу үтенер өчен дә килүем. Улым исеменнән

үтенәм, сез аңа кирәк чакта ныклык күрсәтә алмаган өчен ачуланмагыз. Икенче вакыт ул акыллырак булыр.

— Икенче вакыт дип ... алла сакласын дигез. Мондыйны бүтән аңа да, бүтәнгә дә күрсәтмәсен. Шулай диегез.

— Шулай дим, шулай. Бик дөрес әйтәсез, рәхмәт. Үзебезнең габебезне белеп, сезгә азмы-күпме ярдәм күрсәтмәкче идек.

— Ярдәм? Нинди ярдәм?

— Җеназа чыгымнарына ... таш куярга ... Акча байтак кирәк булачак бит.

— Институттан бераз ярдәм булыр дигәннәр ие.

— Җитәрлек булмый ул. Иш янына куш, бераз миннән ...

— Менә инде, рәхмәт төшкерләре ...

— Зинһар дип сорыйм, Халисә, карышмагыз инде, алыгыз.

— Ходайның изге бәндәсе икәнсез, рәхмәт яусын, тик кирәкми, аны кайчан түләп бетерермен.

— Юк, юк, әҗәткә түгел, бөтенләйгә, зинһар.

— Менә инде, нишләргә дә белмим, аптыраган.

— Бер дә аптырыйсы юк, минем улымнан, дусты Гайсага ярдәме дип белегез.

Шул сүзләр белән Марва акчаны Халисәнең алъяпкыч кесәсенә салды. Ә Халисәнең чынлап та нишләргә белми интеккән көне:

— Алла бәндәләре, бигрәк инде. Бер дә юкка шул хәтле акча бирәләр димени,— дип пайпылдады, үзенең әллә көләргә, әллә еларга җыерылган битләрен сыйпагандай итеп.

— Нишләп бер дә юкка булсын. Шундый зур югалту кичереп ... Әз булса да ярдәм булсын дип кенә. Мондый хәлдән беребез дә хали түгел, Алла сакласын.

— Рәхмәт инде, алайса, Ходай үзегезгә әҗерен кайтарсын, исән чакта да, кыямәттә дә.

— Шулай гына була күрсен,— дип, Марва китәргә җыенды.— Киткән артыннан китеп булмый, бик бетерешмәгез, түземлерәк булырга тырышыгыз инде. Исән чакта адәмчә яшәргә тырышыйк. Ярый, исән булыгыз.

— Сау булыгыз, рәхмәт яусын. Сезгә Ходай көтелмәгән җирдән бирсен.

Кузгалдылар. Әмма ишек төбенә җиткәч, Марва Халисә янына яңадан борылып килде дә сер әйткәндәй ярым пышылдап:

— Халисә, шуны сорарга онытканмын икән, гафу итегез, бер генә секунд. Әйе, сорыйсым калган,— диде дә, үзе тагын тотлыга язды.— Теге хулиган егетне әйтәм, аны судка бирерсез микән?

Ләкин Халисә җавапны һич зарыктырмыйча әйтеп салды:

— Юк инде, нинди суд ди ул. Мин андый эшнең рәтен белмим дә, шуның артыннан йөрсәм, бөтенләй бетәм дә. Үзләре карарлар, суд кешеләрен әйтәм.

— Бәлки ... Ну ... Болай, әгәр кирәк дисәгез, гаризаны үзем язышырмын дигән идем. Кирәк булсам-нитсәм, Аннаның өен беләсез, аның аша хәбәр итәрсез.

— Кирәк булмас, Алла боерса.

— Кирәк була калса гына дим. Рәхмәт әйбәт ниятегезгә. Исән булыгыз.

— Сау булыгыз.

Алар аскы катка төшкәндә, баскычлардан балалар күтәрелә башлаган иде инде. Ә тышта — шау-гөр. Яшәргә көч бирә торган ихлас бәхетле авазлар якты көнне яңгыраталар иде. Шулай да Марваның чырае килгән чактагыдан ныграк яктыра алмады. Берничә урам узганнан соң да ләммим сүз әйтмәвеннән гаҗизләнгән Анна хәлне аңлый алмыйча интекте:

— Әйбәт сөйләштегез ләбаса. Халисә үзе дә божья коровка. Рәхмәт әйтеп калды. Тагын ни кирәк?

Анна, үз соравына җавап алмыйча, тагын да сораулар белән дикъкетмәсен өчен Марва томанлырак фикер белән котылырга теләп:

— Үзем дә белмим, Анна,— дип кенә куйды.

Тагын бераз атлагач автомат телефон күреп, шунда тайпылды. Номерлар җыйды. Чыбыкның теге очында кирәкле кеше тавышы иде.

— Да,— дип эндәште металл аваз.

— Хәерле көн, Денис Иванович.

— Да, мин тыңлыйм.

— Мин автоматтан. Мөмкинме?

— Да, так, слушаю.

— Үзем күрергә тиешле ханымны күрдем. Бернинди гариза булмаячак.

— Я вас понял. До свидания.— Чуендай сүз. Анысы да кызганып кына әйтелде.

Шундый кырыс сүзләрне дә исәпләп файдалансыннар инде. Бар икән.

Шушы минутта Марваның җимерелгән кәефе актарылып ук чыгып, ул, бала-чага мисалында, борынын тарткалап куйды. Йөрәге авырта, ахры, алай-болай егыла күрмәсен дип, Анна үзен җитәкләгәч тә карышмады. Ярдәмгә ул чынлап та мохтаҗ иде. Өйгә көч-хәл белән, тәмам алҗап кайтып керде. Кайтып кергәч тә, аякларын салды да караватына, кичә үзе йоклаган урынга ауды. Капланып яткан килеш, нәкъ сабыйларча сулык-сулык еларга кереште. Анна нәрсә эшләргә, нәсә әйтергә белмичә басып торды-торды да, үз ягына чыкты. «Бушансын азрак»— дип уйлады ул.— Чуан тулып тишелсә, тәннең авыртуы кими. Хәерле булсын, исән булсын.

Марва үзе исә, ялгызы калгач, бөтенләй тугарылып, кычкырып ук еларга кереште. Үкси-үкси елады. Тамагына бернинди көч, ихтыяр белән тыя, җиңә алмаслык рәнҗеш җыйналган иде. Рәнҗеш — үзенә, иренә, заманына, тагын, тагын әллә кемнәргә, әллә нәрсәләргә. Һәм, ахрысы, тәкъдиргә рәнҗеш...

## Дүртенче бүлек

Марва телефоннан шалтыратканның икенче көнендә, иртә белән, кизү торучылар рапортыннан соң, Денис Иванович янына урынбасары Марсель Вәлитов керде. Константин Малышев белән Миша Михайлов эшен урынбасар үзе алып бара икән. Ул менә нәрсәләр хәбәр итте.

Беренче сорау алуда Малышев күрсәтмәсе шундый: Гайса Хафизовка без бернинди җәрәхәт ясамадык. Бокс перчаткалары киеп, шаярып кына, бокс ярышы уздырдык. Бераз гына уйнагач та, Хафизов егылды. Җиттеме, җиңелдеңме, дигәч, көрәшне дәвам итте. Тагын бераз тәпәләшкәч, тагын ауды. Һушына килгәч, безгә хәтере калып, кайтырга чыгып китте. Калганын без белмибез.

Бу уенда Михаил Михайловның катнашы нинди дигән сорауга: ул судья булды, дип җавап кайтарган.

Экспертиза нәтиҗәләре башкача күрсәтә. Кагыйдә белән тыелган урыннарга күбрәк эләккән. Җинаять корбанының бавыры, хәтта бавырдан түбән төшләре, хәтта бөерләренә кан сауган. Колак-борыннарны кагыйдәгә ярашлы рәвештә җәрәхәтләнгән дисәң дә, зарарланган башка урыннар җинаять эше кузгатырга мөмкинлек бирә.

Денис Ивановичтан фикер көтеп, Вәлиәхмәтов бераз тын торды. Ләкин башлык иптәш: «Шуннан соң?» — дигәндәй ым каккач, дәвам итте:

— Икенче сорау алганда, күрсәтүләр бераз үзгәрде. Экспертиза нәтиҗәләрен әйткәч, Малышев: «Без бераз гына салган идек, бәлки сугулар тиешсез урыннарга да эләккәндер»,— дигән чигенеш ясады. «Димәк,

Миша Михайлов та, судья буларак, кагыйдә бозган булып чыга?» — дигән сорауга «Әйе», — дигән җавап алынды.

Денис Иванович сорау алу белән канәгатьме, түгелме икәнен тиз генә сиздермәде. Уйлана калды. Вәлиәхмәтов турысын сорарга мәҗбүр:

— Нишлибез?

— Сорадыгызмы, Михайлов Малышевка тиешсез урыннарга сугарга команда бирдеме икән?

— Сорадык. Теге төшкә сук, бу төшкә сук, дигән команда бирелмәгән.

Бу җавапның Мәлих өчен уңай хәл икәнен һәм Денис Ивановичның нәкъ шуны ишетергә теләвен аның чыраена карап сизәрлек түгел иде. Киресенчә, кыя тагын да какшамастайрак ныгыды. Чырай мәрмәр килеш калды. Тагын көттереп кенә әйтелде фикер.

— Болай булгач, хәл үзгәрә бит?

— Әйе, Миша Михайловка кагылышлы әлеге детальләрнең искә алынуы мөмкин.

— Һәрхәлдә, аңа кагылышлы дәлилләр юк. Шулаймы? Мин сезне дөрес аңладыммы?

— Дөрес аңладыгыз, — дигәнен иптәш урынбасар сизми дә калды.

Мөгаен, бу очракта башлык фикере юнәлеш биргәндер. Ләкин ничек булса да бер, хәзер сүзне туры әйтергә җай туды.

— Шулай булгач, — дип, уйланган рәвештә әйтеп куйды башлык, — шулай булгач, яңа нәтиҗә сорала.

— Аңлыйм, аңладым, Денис Иванович. Нәтиҗәне ясарбыз.

— Миша Михайловтан, шулай да, шәһәрдән чыгып китмәсен өчен расписка алырга кирәктер.

— Шулай, шулай, Денис Иванович, алырбыз.

Шул сүздән соң китәргә дип аягүрә баскан урынбасарны Денис Иванович, кул изәп, яңадан утырырга мәҗбүр итте:

— Тагын бер сорау калган, Марсель Вәлиевич, җинаять корбанының ата-аналары белән сөйләштегезме? Алардан бармы гариза?

— Хафизовның әнисе бик динле хатын булмагае. Ахирәттә Ходай тиешлесен үзе карар, ди. Гариза язып, җәфаланып кына улымны кире кайтарып булмас бит, ди. Бүтән туганнары юк.

— Анысы — алар эше. Хәзер икенче нәрсә. Малышевка кагылышлы юнәлеш ничек, Хафизовның бакчадан үз аяклары белән чыгып китүе ышандырамы? Соңыннан хулиганнар кулына эләгү ихтималы ничек?

— Андый мөмкинлек тә күздә тотыла. Ләкин хәзергә андый фактлар юк. Киресенчә, Хафизовның медицина персоналы алдында ап-ачык әйткән сүзе бар. «Сезне кем кыйнады?» — дигән сорауга ул: «Малышев үтерде», — дип җавап биргән.

— Аңлашылды. Эшне дәвам итегез.

Кәгазьләрен тиз генә җыеп, урынбасар җәһәт чыгып китте. Шунда ук кизү милиционер кереп: «Сезнең янга керергә теләүчеләр бар иде, нишлисез, кертергәме?» — дип сораган иде, Денис Иванович кискен рәвештә кул селтәде:

— Юк.

Шуннан соң, ким дигәндә ярты сәгать терсәкләре белән өстәлгә таянган хәлдә, ике кулы белән башын учлап, хәрәкәтсез утырды. Бу минутлар аның өчен коточкын авыр мизгелләр иде. Ул үз гомерендә беренче мәртәбә тикшерүчеләргә үз ихтыяры белән юнәлеш бирде. Урынбасар моны сизмәде дисәң дә сизеп, әлбәттә, исенә төшерәчәк. Кайчан булса да, әйе, озакламыйча...

Нәтиҗәләрне төсмерләргә, ярым тоннарга бүлгәләмичә ясаган нәтиҗәсен уенда кабатлый-кабатлый, башын күтәрде. Өстәлдәге документларны тимер шкафка салгач, акрын-акрын ишеккә таба атлады. Кабул итү бүлмәсенә чыккач, кизү милиционерга:

— Мин эш белән авылга барып кайтам, сораучыларга әйтерсез,— дип, китеп барды.

Киткән җире исә нибарысы үз өе иде. Өендә берүзе ята-тора көн уздырды. Хатыны калдырган ризыкларны җылытып ашады, чәй кайнатып эчкән булды, душ коенган булды. Ләкин үзеннән җирәнү хисе күңелен һаман болгата иде. Хатыны кайтып хәл сорашкач та:

— Бөтенесе үз урынында ,— дип сырт кабартудан башка нәрсә эшләмичә һәм сөйләшәсе килмичә, кичке һавада йөрергә чыгып китте.— Сораучылар булса, мин — авылда,— дип өстәде.

Соң кайтты. Эшкә иртә китте.

Урынбасар белән кичәге очрашу нигезендә, Миша Михайловны ирекка чыгарганнар иде. Тагын ике хулиган кулга алынган. Шушы хәбәрләрне җиткергән кизүләргә Денис Иванович:

— Булды, искә алынды, тикшерүчеләр керсен,— дип, операция вәкилләрен кабинетка чакырды.

Гадәти, көндәлек эшләр дәвам итте, диярга кирәк.

* * *

Марва белән Анна иртәнгелекне ашарга утырганнар гына иде, тәрәзә аша нииндидер күләгә узды. Күзләре табынга төбәлгәнлектән, шәйләми калдылар. Күп тә үтмичә, күләгә тәгәенләшә башлады — күтәрмәдә, болдырда, ишек катында адымнар — дөп-дөп. Өйдәгеләрнең йөрәге дә дөп-дөп ...

Нәрсә дә булса уйлап өлгергәнче, ишек ачылды. «Ә» дигәнче, уйга килеп киткән өмет акланып та куйды. Ишек төбендә — ул, аларның сөекле уллары! Миша! Мәлих!

Хатыннар, эчәсе чәйләрен куеп, икесе берьюлы сикереп тордылар, ишек төбенә атылдылар.

— Әй, улым, улым! — дип, иң алдан Мәлихны Анна кочаклап алды.— Кайттыңмы, балам. Дөрес эшләгәнсең, рәхмәт. Менә бит ә! Әй, куркыттың да инде, котны очырдың. Ярый, курку белән котылгач, бик әйбәт. Хәзер акыллырак булырбыз. Шулай бит, улым? Шулай диген, балам.

Шул рәвешле, Анна пайпылдый-пайпылдый Мәлихны кочаклый да сөя, Мәлих ычкынган саен, тагын барып кочаклый. Марвага исәнләшергә дә чират җитми. Тик тора бер кырыйда ана кеше. Мәлих үзе дә әнисе янына килергә, исәнләшергә ашыкмый. Берәздән соң — Анна рәхәтләнеп сөенгәч, күңеле булганчы матавыклангач һәм:

— Йә, әниең белән исәнләш инде,— дигәч кенә, ана белән бала берберсенә якын килделәр.

Мәгәр кочаклашулар ул хәтле кайнар була алмады. Мәлих кул гына биреп, әнисе аның аркасыннан кочкач та каткан килеш басып торды.

— Йә, юын инде, бергәләп чәй эчик,— диде анасы, нишләптер тыныч кына һәм артык сөенеч сиздерә алмыйча.

Шатлык зур булса да, улының Аннага чын җылылык, ә үзенә салкынчарак мөнәсәбәт сиздерүе эчкә нииндидер шомга охшаш тоем барлыкка китерде. Йөрәккә бик кечкенә шырпы кадалгандай тоелды. Аны-моны сизмәгән малай һич тә уңайсызланмыйча:

— Юынам, хәзер,— дип, иң башта күлмәген салып атты да ванна бүлмәсенә кереп китте.

Ана белән нәнә, аның шабыр-шобыр юынганын тыңлап, елмаешып шатлык кичерделәр. Чәй онытылды. Марваның бая йөрәген чәнчеп куйган хәтер калу кебегрәк нәрсә дә тиз үк юкка чыкты.

Бәхетләләргә куаныч өстәп, Мәлих, тастымал белән сөртенә-сөртенә, алар каршына килеп басты. Анна шунда гына ана алмаш күлмәк кирәклеген төшенде.

— И-и, онытып торам лабаса балама, күлмәк бирергә. Хәзер, балакаем, бер генә минут.— Шулай дип, җәһәт кенә залдагы шкаф тартмаларын ачты да, тиз арада тиешле күлмәкне табып, Мәлихка сузды.

Калганы, сүзсез аңлашылганча, бәхетле эчемлек булган чәй янында матур гына сөйләшеп утырдылар. Марваның берничә мәртәбә кабатлаган сүзе шул булды:

— И котны алдың да инде. Үзең дә ... шулай ярыймыни.

— Ладно, мам, хватит об этом.

— Хватит, бик хватит. Моннан соң акыллырак булырсың.

Бәлки әле монысы хәерлегә булыр. Уеннан уймак чыкканын башта ук белеп тору файдага китәр. Улы анын сүзен кабул итәме, юкмы икәнен белмәгән килеш, ана кеше вәгазьне өсти торды.

— Дәүләт имтиханнары житкәч кенә ... Кот очты, институтны бетерә алмыйча кала дип. Бер калдымы, аннары суына ул. Калган эшкә кар ява. Әйбәт булды. Куркуыбыз кысыр булып чыкты. Безне бүтәнчә акылга утыртып булмагандыр, күрәсең. Дөресме, улым?

«Дөрес» — дип куйса, теле корымас иде дә бит, ләкин малай әнисенә кырын карап кына күз ялтыратты да, мәгънәсез рәвештә:

— Исән булсак, үлмәбез,— дип, елмайган булды. Шаярта бедә, янәсе.

Ашап-эчкәч, үз бүлмәсенә кергән иде, ядрәдәй атылып кире чыкты:

— Минем картиналар ... Кая куйдыгыз?— Әнисенә ачулы карап, ни өчендер ике кулын өскә күтәрде.— Синең эшме бу?

— Минем эш. Пычрак сурәтләргә карап, җаны әшәкеләнмәсен дидем.

— Кайда сурәтләр?

— Ертып аттым.

— Син мам, дура што ли, акылыңдамы?

— Аларны бүлмәгә бүтән кертергә рөхсәтем юк.

— Синнән кем рөхсәт сораган әле?

Кинәт телсез калган ана, урынынннан кубып, диванга көчте һәм читкә борылып, улына борылып карамас булды. Улы исә һаман үз хакын дәгъваламакчы.

— Шундый әйберне ертып ташларга! Хәзер аның бер-берсе ничә сум тора, беләсеңме шуны?

— Сатып йөрмәкче буласыңмы шуларны?

— Йөрисе дә юк, бүген әйтсәң, иртәгә йөз кеше килеп, кулың-иең белән йолкып алырга торалар.

— Сатсаң, бүлмәдә тотарга димәсәң ... Сүз бирсәң ...

— Бирәм, бирәм, тап кына, кайтар кире. Кайда?

— Чоланда, шкаф башында.

Атылган ядрәдәй, чыгып та китте малай. Һәм озакламыйча авызы колагынача ерылган хәлдә килеп тә керде.

— Молодец, мам, әрәм итмәгәнсең.

— Ә син сүзеңдә торырсыңмы?

— Һы, ярый, мам, карарбыз. Мин институтка. Анда исемлектән сызып ташламасыннар.

Малай, өйдә мең төрле сорау калдырып, чыгып та сызды.

Адым тавышлары тынгач, Анна татарчалап:

— Аллаһы Тагәлә акыл бирсен,— дип, чукынып куйды.

Марва:

— Шулай гына була күрсен,— дип, авыр көрсенде.

Хатын-кызга эш таба алмыйча интегәсе түгел бит, Анна кибеткә чыгып китте дә бөтен хәсрәт Марваның үз өстенә калды. Ә хафалы соруларның иге-чиге юк. Ничек дип, нәрсә әйтеп чыгардылар икән малайны? Бөтенләйгәме, әллә ... Алла сакласын.

Дениска шалтыратып карыйммы дип тә уйлаган иде дә,тик ул уйдан тиз кайтты — эшне бозып куюың бар. Денис Иванович тотынган икән,

бөтенесе тәртипле булыр. Адәм баласы шул инде ул, үз бәхетенә үзе ышана алмыйча интегер. Булганына шөкер итеп, кулдагының кадерен белү зарур югыйсә. Син дә шулай, юк кайгы белән баш ватмыйча, үз кирәгеңне кайгырт. Син бит монда гомерлеккә килмәгән, мәктәбең көтә, укучыларың. Алар Мәлих кебек сатулашмыйлар. Алла урынына күреп, ихтирам итәләр, авызга гына карап торалар, һәр сүзне күңелләренә сеңдерергә тырышалар. Тәкъдир шулай кушты ки, Мәлихны — үзенең бердәнбер баласын ана кеше үзе теләгәнчә тәрбияли алмады. Хәзер исә, ката башлаган буыннарны төзәтү — ай-һай ...

Мәктәп исенә төшкәч, Марва житез генә атлап, билет кассасына юнәлде. Алып та кайтты билетны. Кичке чәй вакытында шул хәбәрне улына җиткергәч, улы күз тимәсен, әдәпле генә:

— Шалаймыни, мам, нишләп алай тиз? — дип, күңел өчен булса да ризасызлык сиздергәндәй итте.

— Эш бит, балам.

— Пенсиягә чыкмадыңмыни әле?

— Чыктым да. Укытам әле. Эшсез тору читен бит.

— Ыһы.

— Иртәгә дим, самолетка бәлки озатырсың?

— Ә-ә, менә эш нәрсәдә икән. Минем, мам, иртәгә политэкономиядән консультация. Озата алмам инде, ачуланмассың.

Ни әйтсен ана кеше. Иреннәрен кысып кына куйды.

Чәй эчкәндә чәчәде. Чәчәгәч, йөткерә-йөткерә ванна бүлмәсенә кереп китте. Тамак төбе тәмам йөткертеп интектермәс булгач кына залга чыкты. Бу вакытта малай үз бүлмәсенә кереп киткән иде. Озакламыйча шул яктан күк күкрәвенә тиң шартлау-дөбердәү ишетеп сискәнде ана. Ике колагын берьюлы каплап, диванга баш тәрәде.

Иртәгесен самолетка аны Анна озатты. Алай-болай суд була калса, Анна өйгә телеграмма сугарга тиешлеге хакында сүз беркеттеләр.

— Эш урынына түгел, мәктәпкә түгел, өйгә, әлбәттә, өйгә җибәр телеграмманы, — дип, кабат-кабат кисәтте Марва.

— Ярый, ярый, борчылма, Марвушка. Синең өйдә булуыңа караганда эштә булуың күбрәк. Шуңа күрә, тегесен эшеңә җибәргән идем. Монысын, кирәге чыкса, өйгә җибәрермен.

— Онытма.

— Оныта буламы. Борчылма.

Шул арада эфир аша көр һәм матур хатын-кыз авазы пассажирларны самолетка утырырга чакырды.

* * *

Алабугада эшләрнең көйләнә язганын үз күзе белән күргәч, сәгать көндезге дүртләрдә үз өенә кайтып кергәч, инде үз урынына кайтырга тиеш булса да, мәгәр алай килеп чыкмады. Йөрәге буш өйдә җилкенеп куйды, тын бүлмә, әйтерсең, жуылдый иде. Моннан берничә көн элек юл чыкканда җан ничек ашкынса, хәзер дә шулай, үнәчне нидер кыса, күңел гүяки, нәрсәдер сизенә, гүяки аны монда да яман хәбәр көтә. Нәрсә, ни соң? Ләкин мондый яман шик белән килешәсе дә килми. Күңел, үз сизенүен җөпләмичә, әйбәт хәбәрләр көтә, матур үзгәрешләр көтә. Ялгызлыктандыр, дип уйлый Марва. Бүтән нәрсәдән булсын?

Алабугада нәрсәседер онытылып калды шикелле. Җанының бер өлеше шунда калды кебек. Улы белән, ире белән, Анна белән кайчандыр бергә яшәлгән бәхетле матур тормыш калды. Бәхетле матур тормышның моңга әйләнгән ядкәре калды. Анысы «Партизанка» һәм «Комсомолка Гөлсара» исемле җырлар язылган пластинка буладыр. Шуны уйнатып караганнан соң, инде күптән йокыга талган тойгылар кабат уянды бугай.

Үзәк өзелеп-өзелеп, шул көннәргә, элеке сөенечләргә кайтып килә башлады. Мөмкин түгел икәне дә билгеле, мәгәр билгеле булган көе шул булмаска тиешле нәрсәгә тартыла күңел — җилкенепме җилкенә...

Ул пластинка Мәлихкамы, Аннагамы, Денискамы кирәкле? Аларның һәр өчесе өчен ул пластинка — тишекле бер тиен. Әгәр дә Марва алып китәм дисә, аны беркем дә кызганмас иде. Ә бит әле тагын шунысы бар, пластинка — Денис бүләге, димәк, Марваның тәгаен үзенеке.

Менә шул җыр калган Алабугада. Әгәр аны алып кайткан булса, йөрәк бәлки болай җилкенмәгән булыр иде. Язмышның үзенә охшаш җырны тыңлап мавыгыр, юаныр иде. Ә болай исә бөтенләй чыдар әмәл калмады лабаса, ялгызлыкка түзә алмыйча, маэмай шикелле улап җибәрерсеңмени!

Битен-кулын югач, чак кына эчтәге ут сүрелә төшкәндәй тоелса да, күңеленең үз урынына тиз генә утырачагына ышана алмаган Марва, юл киемнәрен алмаштырып киенде дә урамга чыгып китте — мәктәпкә. Анда кешеләр китеп бетмәгән иде әле. Укытучыларның кайберләре кире килгән. Шулай ук бер башларына урын табылмаганга күрәдер, бәлки. Һәрхәлдә, тормышның бик тә кызыклы булуыннан түгелдер. Олыларның шулай. Ә балаларныкы ничек булыр, аларның күрәселәре алда әле.

Шулай да мәктәп коткара яза шул, менә Марвага җиңелрәк булып китте — укучылар исәнләшкәч, йөзенә хәтта елмаю галәмәтләре чыкты. Директор энекәш белән сөйләшеп утырганда исә элекке Марва — басынкы, тыйнак, тыныч Марва Артемовна — үзенә кайтты, үз асылына. Рәхмәт, мәктәп. Марваның бөтен тормышы элек тә синдә иде, хәзер дә шулай булып калды.

Иртәгесен исә, күңелнең үз урынына тәмам утырмыйча хәле юк, чөнки ул үз урынында — кара такта эргәсендә, өстәл янында. Патша да үз тәхетендә үзен болай бәхетле тоймагандыр, мөгаен. Ә Марва тоя. Күкрәгенә журналны рәхәтләнеп кыскан хәлдә коридор буйлап атлаганда, класс ишегеннән узганда ук шул хисне тоеп атлый. Башта инде бернинди күләгәле уй кала алмый, чөнки Марва Артемовнаны сәламләп, класс аягүрә баса. Шатлыклы ничәмә ничә күз аңа яшәү дәрте сирпи!

— Исәнмесез, кадерле балалар.

Бүтән чакта «кадерле» кадәресе әйтелми иде, әлбәттә. Ә бүген әйтелде менә. Тойгылар, хәерлегә күрә, уртак иде бугай. Балалар үзләре дә:

— Исәнмесез, Марва Артемовна, нишләп озак йөрдегез?! — дип сагыну сиздерделәр.

— Туры килде шул,— дип, ихлас сөенде апалары.— Шул арада сагынып өлгердем, сезсез күңелсез икән,— дип тә куйды.

Бүтән вакытта бу сүзләр әйтелмиләр иде. Шулай итеп, бүген эшкә аеруча зур теләк белән керештеләр — укытучы да, укучылар да.

— Башлыйбызмы? Дежур кем?

Дежур кыз торып: «Класста бөтен кеше дә бар»,— дигәч,

— Кай төштә калдык әле без? — дип сораган булды.

— Алмашлыклар, алмашлыкларда тукталдык.

Кабатлау дәресе иде, ул шулай дәвам итте. Марва Артемовна кара тактага барлык килешләрне тезеп, баш килеш турысына: сам, сама, он, она дигән алмашлыкларны язып куйды.

— Төрләндерегез.

Класс дәфтәрләргә иелде. Укытучы, бүтән эш юклыктан, дәреслек битләрен актаргалап, узган сәхифәләрне барларга тырышты.

Укытучы «сама» алмашлыгын үзе дип фаразлый. Һәм сез аны карагыз төрләндереп. Мөмкинме? Тормышта Марва һич тә төрләнә белмәде, гел үзе булып яшәде кебек. Ә чынлыкта ничегрәк икән? Уе ихлас — балалар белән мөнәсәбәте һәрчак әйбәт булды. Укучыларын ул яраткач, балалар аңа шундый ук ихтирам белән җавап бирә килделәр. Гомер буе шулай булды. Гәрчә кайбер хатирәләрне искә төшерсәң,

бүтәнчәрәк булырга тиеш кебек тоелса да. Гәрчә аның педагог хезмәте икенче төслерәк башланса да.

Атасыз калган гаиләнең хәле бит — бигрәк тә бөтен ил ачка интеккәндә. Дүрт баланың икесе үлгәч, Марваны әнисе үзенең бер Катя исемле танышына бала карарга җибәрде. Ана, җиде яше тулып кына килгән сабыйга, ике ир бала тапшырдылар. Берсе дүрт, икенчесе ике яшьлек. Билгеле инде, уйнап-көлеп, шаярып, аунап, мәтәлчек атып мәш киләләр. Марваның үзен дә алар исәбендә диярга кирәк. Ләкин уеннан уймак чыга башласа, тәртипне ул урнаштырырга тиеш. Җавапны ул тота.

Шулай бер көнне ике малай пыр тузып сугышып китте ләбаса. Мөлкәт өчен бара сугыш. Кайчандыр, бик электән калган сурәт бар иде. Торна төлкене, төлке торнаны кунак итә. Нечкә авызлы чүлмәктән үз сыен рәхәтләнеп эчә торна дус, ә төлке аның янында нишләргә белмичә өтәләнә. Шул сурәткә ике малайның һәркайсының да хуҗа буласы килеп, берсе икенчесен сурәтне тотып карау бәхетеннән үк мәхрүм итмәкче. Ике яшьлек Толядан дүрт яшьлек Коля мөлкәтне талап алды да, йортның икенче ягына ук чыгып качты. Рәнҗетелгән, таланган Толя чыелдап, абыйсы артыннан тыраклады. Алпан-тилпән килеп житкәч, абыйсын таламакчы. Кәгазьнең бер башыннан эләктергән иде, бер читеннән кәгазь умырылып та чыкты. Бөтен мөлкәт гадел хәл ителде югыйсә, икегә, яртылашка бүленде. Һәркем кулында — үз байлыгы. Мәгәр сугыш дәвам итә. Колаклардан, чәчләрдән тартыш, изүләрдән, якалардан, итәкләрдән йолкыш. Ул тавышлары, чинаулары! Суйган чакта кычкырган чучкадан яманрак чыелдыйлар, колак пәрдәләре ертылырлык. Марва түзә алмады. Үзенең дә каны кызып китеп, ике малайның икесенең дә җилкәсеннән эләктереп, ике кабак башны бер-берсенә бәргәләргә керешә. Шулай ул, янәсе, тәртип урнаштыра. Ике баш — дыңк, дыңк ...

Балалары өчен җан аткан Катя апа мич каршында камырмы баса, токмачмы җәя иде. Сугыш дәрте, тәртип урнаштыру гамәле инде аңа күчкәч, аның йөрәгендә ут булып кабынгындыр, күрәсең. Кулларын җилкәләрдән ычкындырырга өлгермәгән Марва өстенә ажгырып килүе булды, һәм күз ачып йомганчы, Марваның үз башы дыңк итте. Уклау! Уклау белән тондырган икән апа. Һәм кул ... кул «ә» дигән арада сөяксез шикелле асылынып төште. Уклау төшкән арада кыз үзенең уң кулы белән башын тотып өлгергән икән.

Инде Марва кычкыра, Марва елый. Малайлар секунд эчендә шым булды. Кайсы кай як почмаккадыр чумды болар. Ә минә кулның беркая кузгалырлык рәте калмаган, асылынган килеш — буйсынмый, күтәрелми ...

Катя түти кулны тастымал белән бәйләп, тиз арада Марваны әнисенә илтеп тапшырды.

Педагогика өлкәсендәге шушы беренче тәҗрибәне Марва хәтеренә еш китерә торган булды. Тәҗрибәдән шундыйрак нәтиҗә килеп чыга иде: әгәр дә балаларны ярәтса, тәрбияче тәртип урнаштыруның бүтән әмәлен тапкан булыр иде. Күрәсең, тәрбияче әйбәт педагог булып тумаган. Ә шул кеше гомер буе балалар укытты ...

Хәтеренә килгән уйлардан көрсенеп, укытучы апа бүгенге көнгә — бүгенге балаларга күз ташлады. Болар үз баласыдай якын кебек. Марваның шул ерак очрагыннан соң, һичбер укучысының якасыннан, җилкәсеннән эләктергәне булмады. Беренче сабакны шәкертләренә түгел, үзенә биргән булып чыкты.

Аягүрә басты Марва.

— Йә, төрләндереп бетердегезме?

— Бетердек, Марва Артемовна!

Ярты классның кул күтәрүен күреп, укытучы журналга карый. Белгеләре азрак булган укучыга туктала караш.

— Якупова, Әнисә, яле, чык әле. «Сам» дигән алмашлыкны төрләндер.

Әнисә атлы бала тиз арада тактага барлык килешләрне теркәп тә куя.
— Дөресме, балалар?
— Дөрес.
Бу алмашлык белән эш җиңел хәл ителгәч, көндәлдә: «Денисның хәле катлаулы түгел»,— дигән нәтиҗә чыга. Ә менә эш Марваның үзенә, «Сама» алмашлыгына җиткәч, «винительный» дигән килештә (татарча гаепләү килеше буламы икән инде бу?!) эш төртелеп калды. Такта янына чыкканы берсе «Саму»,— дип яза.
— Кем башкача уйлый?— дигән сорауга карата нибары бер генә кул күтәрелә. Нечкәрәк, озынча буйлы, коңгырт чырайлы ир бала. Бәләкәй чакта Мәлих та шушы төслерәк иде... Мәсгуть исемле малай. Бүтән укучылар язганнан юнәлеш килешне генә сөртте дә «Самое»— дип язып куйды. Һәм Марва апасына борылды:
— Башкалары дөрес.
Бүтән укучылар хәтта гаҗәпләнеп, укытучыга карадылар:
— Шулай дөресмени?— диешеп, ачыклык көттеләр.
— Күрдегез, бер генә кеше исендә дөрес калдырган.
Шушы сүзләрне әйткәндә, Марва апагыз уенда: «Гайса Хафизовка охшагандыр бәлки бу бала»,— дигән фикер яшен тамырыдай ялтырап куя. Бу фикерне ярый әле балаларның: «Ба-а!»— дип хор белән кычкыруы сүндерә яза.
— Молодец, Мәсгуть, утыр.
«Кыяфәтең Мәлихка да, Гайса Хафизовка да тартым, язмышың икенче төрле була күрсен»,— дип өстисе килсә дә, өсти алмый Марва. Уйлаганның барысын телдән әйтеп булмый шул. Бәхетле була күрсен бу зирәк малай!
Төрләндерү дәвам итте. Калган алмашлыклар белән кыенлыклар килеп чыкмаса да, уйда исә эшләр шома гына бара алмады. «Он» дигәндәге Денис белән Мәлих үзләре бөтенләй диярлек башларына китерә алмаган буталчык дәвергә килеп чыктылар. Иң дөрес һәм туры дигән юл адаштырды түгелме соң? Хәзер яшьлектәге кебек бричка төбенә чумып кына котылып калырга мөмкинме? Атлар куркыныч төштән тиз генә чабып коткара алырмы? Кайда алар, бармы чапкак атлар? Кайда хәзер, кайда икән яшьлек аргамаклары?!
Марваның бөтен гомере— мәктәп. Бөтен яшәгәне шунда калачак. Ә шуннан ары нәрсә? Шуннан ары, ягъни укулар тукталгач, башны кая куярга белмичә аптырыйсың. Ялгыз башка кайда да бер— таң ата да кич була.
Быел ялгызлыкны нинди дә булса санаторийга барып кыскартмакчы иде, ләкин ният җимерелде— Алабугадан тагын телеграмма килеп төште. Тагын юл, тагын Алабуга, Анна, Мәлих... Юанырлык бер генә сәбәп бар— судка Мәлих бары тик шаһит буларак кына чакырылган икән.
— Судка чаклы институтка сугыласы бар,— дип малай иртүк чыгып китте.
Ә суд көндезге сәгать икегә билгеләнгән иде. Имтиханнары бирелеп беткән Мәлихның диплом аласы гына калган. Тагын нинди эшләре бардыр. Мөгаен, хатын-кыз белән өйдә сөйләшеп утырасы килмидер... Икегә хәтле алты сәгать бар бит әле. Малайны аңлап та буладыр кебек.
Сәгать икене Марва үзе дә, Анна да җиткерә алмый интектеләр. Үзләре исә, шул ук вакытта, ул сәгать җитмәсә ярар иде дип, аһ итеп, көрсенә иделәр. Дөнья бит бу, кинәт үзгәрә торган заман— һич көтмәгәндә әлләниләр килеп чыгуы ихтимал.
Икеләнүләр, шомланулардан арган, кара кайгыга баткан ике хатын, вакыт җиткәнче үк, шәһәр үзәгенә таба юл тотты. Иртәрәк барудан да җиңеллек килмәде, әлбәттә. Озак кына урамда, аннары суд утырышы буласы залда көтәргә туры килде. Мәлих бу вакытта күренми иде әле. Судьялар чыгар алдыннан гына арткы урыннарның берсенә кереп утырды ул. Нәрсә уйлый, нинди хисләр кичерә икән?

Ә менә әнисе, никадәр генә үзен тыныч тотарга тырышса да, барыбер күкрәк үзәгенең калтыранганын абайлады. Калтырауның сәбәбен аңларга тырышты. Аңлый алмыйча интекте.

Дөрес, Мәлих монда шаһит кенә. Әтисенең биргән вәгъдәсе бар. Денисның әйткән сүзе бәхәскә мохтаҗ түгел, ул ничек әйткән, шулай булачак. Әмма да, шуны белгән килеш тә ышанып бетми күңел, өзгәләнә, бәргәләнә. Тизрәк кенә узсачы бу каһәр төшкән минутлар. Ходай язмасын мондый хәлне күрергә, дошманына да, бала аркасында суд бусагасын узарга бер генә анага да насыйп итмәсен. Әйе, беркемгә дә.

Ниһаять, көтелгән һәм көтелмәгән куркыныч аваз:

— Суд килә!

Зал аягүрә баса. Судьялар сәхнәдә өстәл янына тезелешеп утыралар. Кырый ишектән хөкемгә тартылучы егетне милиционер алып керә. Читлек кебек тар бүлемгә утырта. Марва судның башыннан азагына кадәр күзләрен шул егеттән аера алмады диярлек.

Хөкем йоласы тегә-бу дәрәҗәдә төгәл үтәлә торды. Судья утырышны ачты, тикшереләсе эшнең эчтәлеге белән таныштырды. Эш бик гади — бокс уйнаганнар, уен фаҗигале беткән. Җөмләләрне ничек кенә төрләндерсәләр дә, предмет үзгәрешсез кала бирде. Гаепләнүче булган Константин Сергеевич Малышев прокурорга да, адвокатка да бер төрле җавап бирә торды. «Сорау алу вакытында башкачарак әйткән идегез»,— дип туктатканда да югалып калмыйча:

— Факт бер үк, сүзләр икенче төрле,— дип җавап кайтарды.

Ниһаять, шаһит — Мәлих Денисович Михайлов чакырылды.

— Гражданин Михайлов, Мәлих Денисович чакырыла.

Арткы ишектән Мәлих килеп керде. Кызарган, каушаган. Әле берничә сәгать элек кенә бөтенләй бүтән кеше иде.

Марваның йөрәге кысылып, калтырап куйды. Һава җитмәгәндәй тоелгач, валидол капты. Күпмедер мизгелдән соң гына судья тавышы ишетелә башлады. Ләкин, сүзләре ишетелсә дә, судьяның да, бүтән сөйләүчеләрнең дә үзләре күренә алмады. Марва күзләре белән күрмичә генә һәм колаклары белән дә түгел, бары тик йөрәге белән генә тыңлый иде кебек.

Сорау:

— Делода сезнең исемегез ике төрле язылган. Бер җирдә Мәлих, икенчесендә — Михаил. Шуның кайсы дөрес.

— Икесе дә дөрес.

— Ничек алай, сезнең исемегез икәүмени?

— Паспортта — Мәлих, болай телдән Миша дип йөртәләр.

— Сез бу исемнәр язылган ике очракны да танныйсызмы?

— Таныйм.

— Делода сезнең милләтегез күрсәтелмәгән. Милләтегез белән сез татармы?

— Түгел.

— Русмы?

— Түгел.

— Алайса, милләтегез белән сез кем буласыз соң?

— Милләтем буенча мин — советский.

Залда — кызык итү ымлыклары. Судья һәм утырышчылар якты карашлар белән канәгатьлек хисләре алмашып алдылар хәтта. Судья үзе дә, бурычына туры килмәгәнчә, тойгылы нәтиҗә ясап:

— Чын советский гражданин, похвально,— дип куйды. Тойгысын халык күңеленә сеңдерер өчен бераз вакыт биргәч кенә, рәсми шөгылен дәвам итте.— Ярый, булды. Инде эшкә килсәк, Сез, гражданин Михайлов, Гайса Хафиз улы Хафизовны яхшы белә идегезме?

— Гайсаны институтта белмәгән кеше юктыр. Яхшы белә идем. Беренче класстан башлап бергә укыдык. Институтта да бергә. Якын дуслар идек.

— Безгә шунысы билгеле, якын дусыгыз кыйналганда, сез аны якламагансыз.
— Аны кыйнаучы булмады. Костя белән алар бокс кына уйнадылар.
— Һуштан язганчы уйнадылар, Гайсаның аңы киткәнче. Шулаймы?
— Бокста бу — гадәти хәл.
— Кагыйдәсез сугуларны күрдегезме?
— Анысына игътибарым җитмәгән, таныйм.
— Шулай тиеш дип таптыгызмы әллә?
— Тиеш дип түгел. Сизгерлек җитмәү аркасында гына.
— Чөнки шактый гына бәйрәм иткән идегез.
— Таныйм.
— Димәк, сез дустыгызны якларга тиеш тапмадыгыз. Судья буларак, вазифагызны дөрес башкармагансыз булып чыга. Шулаймы?
— Төгәл үк башкармаганмын булып чыга.
— Дустыгызның үлемен ничек кичерәсез?
— Фаҗига итеп.
— Үзегезне әхлакый яктан гаепле дип исәплисезме?
— Әхлакый гаебемне таныйм.
— Ә Константин Малышевка мөнәсәбәтегез нинди?
— Шушы көнгә хәтле дуслар идек.
— Дустыгызның җинаятен таныйсызмы?

— Зиһен томаланган вакыттагы хатасы дип саныйм. Гайса исән булса, үзе дә шулай дияр иде, ышанып әйтәм.
— Гайса Хафизовның исән чакта әйткән сүзе бөтәнчә.
— Мин үз колагым белән ишетмәгәнне раслый алмыйм.
Судья беразга уйланып калды. Прокурорга, адвокатка, аннары утырышчыларга күз ташлады.
— Шаһиткә, Михаил ... кем ... шаһит Мәлих Михайловка сораулар тагын булырмы?
Сораулар юк иде.
— Утырыгыз, Михаил Михайлов.
Сораулар һәм җаваплар ана кеше өчен шушының белән, гомумән, тәмамланды. Улының төшеп үк калган кеше түгеллеген төшенеп, эченә хәтта бераз җылы керде. Күрсәтмәләре гел дөрес булды малайның. Чырае башта йончу тоелса да, соңыннан эшлекле сыман рәвешкә керде. «Комсомол тәрбиясе,— дигән нәтиҗә чыгарды Марва.— Ходай кушса, югалмас бала».
Малышев соңгы сүздән баш тарткач, суд киңәшкә чыгып китте. Һәм озак та үтмичә, кире әйләнеп, берничә минуттан хөкем карары игълан ителде. Анысы да бик гади иде: гражданин Малышев Константин Сергеевич шартлы рәвештә өч елга ирегеннән мәхрүм ителә.
Шартлы рәвештә ... Бу ни дигән сүз?
Кемдер дөньядан киткән, үз теләге белән дия алмассың. Кемдер аны мәҗбүр иткән, сәбәпче булган. Кешене вакытсыз теге дөньяга җибәрүче — Малышев дигән җинаятьче. Ул иректә булачак. Гаделме соң бу?
Марваның моңа җавап бирерлек хәле юк иде. Гүяки улының исән калуы аны сөендермәде. Залдан чыгышлый, карашы белән малайны эзләгән иде дә, таба алмагач, тынычланды, бүтәнчә эзләнмәде. Малай, мөгаен, Костяны көтәр. Сак астыннан чыкканда, кайбер йолаларны үтисе булыр. Карасыннар инде.
Шундый фикер белән Марва Аннаны култыклады да, аннары артык хискә һәм сүзгә бирелмичә генә, уларын көтмәстән, кайту ягына атладылар.
Шулай да, урамга чыккач, Аннаның теле ачылды. Хәтта, әйтергә кирәк, теле телгә йокмый — сөйләп урынына сибә башлады сөенечле сүзләрен. Хәтта бу хәл Марва өчен гаҗәбрәк тә тоела иде. Күр , син, туган анага караганда, тәрбияләгән нәнә бәхетлерәк була ала икән!

Бәхетле Анна юл буе үзенең сөекле Мишасын мактап кайтты.

— Сөеп туймаслык бала иде бит ул, туа-тумыштан. Институтка кергәч кенә үзгәрде бераз. Шул Костя белән дус булу аркасында. Тегесенең акчасы күп — шул акчага икәүләп бозылдылар. Денис белән син җибәргән акчалар да җитәрлек иде югыйсә. Баланы бозасың килсә, аңа акча бир икән. Шулай килеп чыкты. Әйе, дөресе шул, ы-ы. Ну, ярый, Аллага шөкер, исән калдык. Моннан ары акыллырак булырбыз. Балабыз да утыргандыр инде акылга, ы-ы.

Икәүләп шундый карарга килделәр. Ләкин бит әле малай үзе бар. Ул ничегрәк уйлый икән? Бәлки, малай үзе дә шушылай фикер итә торгандыр. Бүтәнчә була алмас. Озак тормыйча кайтып җитәр дә, шунда тагын бер кабат аңлашырлар. Әйе, кайтып кына җитсен.

Ләкин хәл икенче төрлерәк бугай. Мәлих үзе фаҗигадән ул хәтле катгый нәтиҗә ясарга бик үк ашыкмый, күрәсең. Кайбер галәмәтләре хәзер үк шул фикергә ишарәли ләбаса.

Үз артларыннан бастырып ук кайтыр дип өметләнсәләр дә, беренчедән, монысы акланмады. Кичке ашка зарыгып көттеләр, күрсәтмәде малай нурлы йөзен. Аналар шатлыгы шуннан соң сүрелә төшмичә нишләсен.

Кич җитте, караңгы төште, юк малай. Төнге уникедә урамга чыгып эзләделәр, туктала-туктала тыңланып тордылар. Юк, ишетелмәде кадерле аваз. Еракта автомашиналар гөрелдәвеннән, якында яфраклар шыбырдавыннан, җил лебердәвеннән башка тавыш ишетә алмадылар. Кара кайгыга чолганып, өйгә кайткач һәм мендәргә аугач та йокыга чуму насыйп түгел икән. Бәхет урынына шул гына калды: менә хәзер тәрәзә төпләрендәге җил кыштырдавын тыңлап ят. Минутларны һәм йөрәк тибешенне сана. Чамала, инде сәгать уникеләр җиткәндер.

Ниһаять, ишек кактылар. Марва нәрсәләр уйлап өлгергәнче, Анна инде ишек катында иде. Тавышы еламсыр:

— Кем бар анда?

Ишек артында мыгырдык аваз:

— Мин, Мам-Анна.

Ишек төбендә кабынган ут яктысында малайның күзләре чагыла. Зифа тал чыбыгы сыман сыгылып-бөгелеп торган көнө.

— Уф, ашыйсым килә,— ди ул, бик тә иркә рәвештә.

— Хәзер ашарсың, бар, юын башта. Кухняга керерсең. Шул дәрәҗәгә җиткәнче эчергә соң, оятсыз.

— Ладно, Мам-Анна, ачуланма. Отмечать кына иттек. Костяның котылуын. Бетте, все. Шыш! — Марва улының алпан-тилпән ваннага кереп китүен күргәч, башын юрган белән каплады.

Малай! Менә ичмасам утырган акылга!

Төн буе йоклый алмыйча диярлек, борсаланып чыкты ана. «Азагы хәерле булсын! Хәерле булсын!» — дип кабатлый-кабатлый таң аттырды. Әллә йоклады, әллә юк, белерлек түгел, тойгылар арган, бөтен тән кыйналгандай ватылган иде.

Мәлих улы төш тирәсендә генә уянды. Кухняга чыгып, андагы бер шешә кефирны бугазыннан гына голт-голт йотканнан соң, юыныр алдыннан (күз тимәсен!) әнисе ягына чыгып сәлам бирергә тиеш тапты. Җитте зиһене!

Форсаттан файдаланып, Марва төнге маҗара хакында сүз кузгатмакчы иде дә, монысы артыгракка өметләнү булып чыкты, әлбәттә. Мәлихның койрыгын алай җинел генә элэктереп булмавын әнисе белеп бетерми иде шул әле. Залдагы кичтән җыелмый калдырылган әзер өстәлне күрергә теләмичә, кухняда аннан-моннан капкалагач, малай ашыкпошык киенергә дә керешә. Әни кеше моны сизеп, улы каршына үзе килеп басарга мәҗбүр иде. Килеп басты да, ялварулы күзләр белән карап, әйтерсең, зур үтенеч белән мөрәҗәгать итте:

— Улым, алдагы эшләр хакында киңәшәсе иде бит.

— Алдагы эшләр? И, мам, эшнең үзенә тотынгач та туеп бетәрбез әле. Хәзер, җай барда, ял итәргә кирәк.

— Ял дисәң дә, киңәшүдән зыян булмас иде.

— Мам, борчылма, минем барысы да хәл ителгән. Без бер айга походка китәбез, Ык буена.

— Ык буена? Анда ни бер? Санаторий бармыни?

— Анда — су, моторлы көймә, палатка, балык һәм башка кызыклар. Магнитофонны да калдырмыйбыз. Авыл тирәләрендә туктагач, культура учакларына сыенып җылынырга була. Шулай, мам, — дип, Мәлих җилкәсенә көрән, юка куртка салды.— Кызганыч, сине чакырып булмый!

— Ә мин ... Мин, улым, әллә җәйне бергә уздырырбызмы дигән идем. Мондамы, Казандамы.

— Акыллы кеше, мам, җәйне шәһәрдә үткәрми. Җәй көне Англиянең бөтен бер парламенты каладан кача.

— Шулаймыни, лордлар белән үк ярыша башладыкмыни инде?

— Ә ник ярышмаска? Без Америка тикле Американы куып җиттек бит. Узарга гына ярамый, ыштанның тишек икәне күренә. Ярый, мам, мине көтәләр анда.

Шулай дип, малай әнисе белән кул изәп саубуллашты да чыгып тайды. Әнисе тагын нидер әйтмәкче булган иде, авызы ачык килеш, сүз әйтеп өлгерә алмыйча калды.

Аралашу икенче көнне дә шушы дәрәҗәдән уза алмады. Өченче көнне исә, әйберләрен шактый зур ике сумкага тутыргач, шуларны күтәреп, ашыга-ашыга китеп барды малай — походка, ямьле Ык буйларына, бер айга. Канатлары каерылган ана, капка төбенә чыгып, ни әйтергә, нәрсә уйларга белмичә, улы күздән югалганчы карап кына калды.

Аннаның хәле бераз җиңелрәктер — өйдә, бакчада эше чыпчык чүпләсә дә бетә торган түгел. Кулдан килгәнчә Марва да ярдәм итеп карар, билгеле. Әмма көнне түтәлләргә су сибеп, бәрәңге әрчеп кенә тутырып буламыни. Анна, моннан тыш, кибетләргә чаба, сәгатьләр буе чират тора. Ипи чиратына иртәнге алтыдан чыгып баса бичара. Шуңа күрә уйланырга вакыты калмый һәм җаны тынычрак аның.

Ә Марва исә вакытын кая куярга белми. Ике көнгә сузылган бушлыкны «Комсомолка Гөлсара» моңы белән тутырырга тырышты. Тыңлый торгач, иске сорау яңарды: «Бу пластинка монда кемгә хәҗәт? Анна татар музыкасын аңламый, Мәлих өчен татарныкы ни, урысныкы ни, икесе дә — «анохронизм», аңа Битлзлар, Пинк Флоидлар, Роллинг Стоуннар һәм башка төр дөбер-шатыр булсын. Ә Гөлсаралар, ай! Монда ул — рисвай! Ләкин булмасын әле алай, Марва апагыз үзе өчен изге булган ул пластинканы сумкасына хәзер үк салып куйсын. Китәсе көнне көтмәстән».

Әйе, шулай эшләде ул — кемнәндер яшергәндәй, сумкасына каушыйкаушый салып куйды пластинканы.

Алабугада узган дүрт көннән соң күңеле тагын нәрсәдер эзли һәм ашкына башлагач, Казанга ашыкты. Мәгәр анда да бәйрәм көтми — ялгызлык дигән ачы көнкүреш көтә иде шул. Ярый әле юлда аз булса да ял итә җан — һичьюгы шуннан файдаланып калырга кирәк. Авыр булса да, юл яхшы, соңгысы гына булмасын.

* * *

Ай чамасы вакыт тыныч узды. Денис Иванович фаразлаганча, Марва канәгать булырга тиеш, аның үтенече үтәлде бит. Анна кош тоткандай шатлангандыр. Бигрәк тә Мәлих үзе бәхетледер. Ләкин алар бу шатлык-сөенечләрнең бер кеше исәбенә — Денис Ивановичның җан тынычлыгы бәрабәренә алмаштырып алынганлыгын, ай-һай, уйлыйлар микән?

Үзенең урынбасары Вәлиәхмәтов белән сөйләшкәннән алып, Денис Ивановичның күңеленә, иң ерткыч кырмыскалар оялый башлады. Акрын-акрын үрчи-үрчи, ишәя-ишәя, ояларын һаман зурайта тордылар. Монда урын иркен аларга — монарчы шикле бөҗәкләргә оя кору түгел, хәтта кереп карау җае булмаган чип-чиста иркенлек! Гүяки, шау чәчәк аткан бакчада кинәт килеп чыккан мөмкинлек! Азык мул — һичбер төше кителеп, яньчелеп карамаган сау-сәламәт олуг вөҗдан! Рәхәтләнеп кимерегез, мыжгый-мыжгый әврә килегез. Иң югары сыйфатлы диэтик ризык сезгә!

Район халык суды карарын республика югары суды расламады дигән хәбәр гаҗәпләндермәде Денис Ивановичны, чөнки барлык «Эш»ләрнең ак җеп белән тегелгәнен ул сизә, белә иде бит. Район масштабында милициягә, Денис Михайлов кул куйган документларга бернинди шиксез ышану гадәткә кергәнлектән, тикшерү машинасы салынган эздән бу очракта да җиңел генә узды. Хәзер инде менә эшне яңадан карарга кайтарганнар. Мөгаен, нинди дә астыртын сигнал киткән. Яман хәбәрне район халык судьясы җиткерде. Исәнлек-саулык сорашкач та турыдан-туры эшкә күчте. Һәм хәлне аңлаткач ук:

— Хәзер нишләргә мөмкин, Денис Иванович? — дип, киңәш сорады.

— Миннән нәрсә таләп ителә?

— Таләп дип, таләп ителмидер. Болай киңәш йөзеннән... Югарыда шундыйрак фикер... Тикшерүне, аннары судны, гадел булсын өчен, бүтән районга күчерү хакында сүз бара.

— Гаделлек дигән фикер югарыдан төшәме?

— Югарыдан, Денис Иванович.

Аңлашылмас нәрсә түгел, Денис Иванович өстенә күләгә төшә дигән сүз бу. Димәк, кемнендер юлында ул киртә була башлаган. «Туган-тумачалык» мөнәсәбәтләрен фаш итәргә җыеналар, димәк. Кемдер эш башланганда ук моны белеп эш иткән һәм форсаты җиткәч тә тиешле кешеләргә хәбәр күндергән. Алда — кадрлар мәсьәләсе тора, димәк. Законга Денис Иванович кебек берегеп каткан, мәгълүм идеяләргә беркатлы намус белән бирелгән кешеләргә хаҗәт беткән.

— Алло, сез мине тыңлыйсызмы?

— Тыңлыйм.

— Денис Иванович, сезнең мөнәсәбәт монa нинди булыр, шуны беләсе килгән иде бит.

— Кызганыч, минем бернинди фикерем юк.

— Гаделлек дип, эшне бүтән районга җибәрергә ризалашабызмыни?

— Карагыз.

— Гафу итегез, Денис Иванович, исән булыгыз.

Көн кебек ачык, кырмыска оясына таяк тыгылган...

Ә ике атнадан соң кабул итү бүлмәсенә Анна килгәнне хәбәр иттеләр. Башлыкның аны кабул итәргә «вакыты» җитмәде. Елый-елый шешенгән Анна кичке якта Денис Ивановичлар өе янындагы коймага сөялеп көткән иде. Көткән кешесе күренүгә, ышыкланган төшеннән чыкты да тагын елап җибәрде.

— Денис Иванович, җаным, коткар безне, Алла хакы өчен. Бердәнбер улыгызны, бердәнбер улыбызны тагын кулга алдылар бит. Чистайга алып киттеләр. Күрәләтә, үз кулым белән биреп җибәрдем. Талап алдылар. Балага чат ябышып, күлмәкләреннән эләктереп, ычкындырмаска тырышып өстерәлдем. Тигәнәкне йолкыгандай йолкып аттылар үземне. Карчыга чебеш типкәндәй генә алдылар да киттеләр. Денис Иванович! Миннән генә түгел, синең кулдан да тартып алдылар бит аны. Нәрсә карадыгыз соң? Кемнәр кулына биреп җибәрдегез, бердәнбер улыгызны? Читкә, читләргә! Кемнәр кулына! Денис Иванович, коткар улыңны, минем бердәнбер юанычымны, шатлыгымны, ышанычымны коткар. Алла хакына, Алла хакына, коткар!

Анна шул сүзләр белән Денис Ивановичның күкрәгенә капланды. Мәлихны кочкандай тоеп, аның әтисен кочты. Денис Иванович — әнисен-

нән өч яшьтә калган ятим — кинәт әнисе белән кавышкандай, аны шушылай әнисе кочаклап елагандай хис итеп нишләргә белмичә басып торды. Әйтерсең ки, әнисенең чәчләрен сыйпады. Шушы яшенә житкәч, кадерле әнисенең сөекле улы булу бәхете кайтты. Йөрәге сулкылдый һәм шул ук вакытта бу сулкылдау ничектер һич аңлашылмаганча татлы иде. Моңарчы ул дөньяда шушындый тойгы барын белмичә яшәгән икән. Бу, мөгаен, беркайчан да чыгу юлы тапмаган, нарасый чактан бирле бикле сакланган сабыйлык тойгысының, анага иркәләнәсе килү хисенең, кирәге чыкмаган хиснең тышка котылгысыз рәвештә бәреп чыгуы иде. Коймa буенда кочаклашып торган ике өлкән кешене күргәч, кемнәрдер сәерсенеп тә уздылар бугай.

Хәерле булсын, куркырлыктан узган инде. Мондый саф, һич гаепсез якынлыктан да оялсаң, дөньяда тагын бүтән нәрсә кала?!

Куллары арганчы тордылар шулай кочаклашып. Денис Ивановичның бернинди ымлык та чыгара алмыйча газаплануыннан сизенеп өлгергән иде инде Анна. Әйе, ул ярдәм итә алмый. Сәбәбен үзе беләдер. Ләкин ул аны әйтми.

Коймага сөялеп калган Денис Ивановичка Анна, чак кына алгарак тайпылып, бер метр чамасы ераккарак китеп карады. Инәлеп күз текәде.

— Бернинди чара юкмыни, Денис Иванович?

— Юк, Аннушка, юк.

Әйтерсең, көчсезлек билгесе булган шушы сүзне ишетү өчен генә килгән иде Анна. Шуны ишеткәч, әйтерсең ки, тынычланды. Тураеп, күзләрен сөртте.

— Мин хәзер кем өчен яшим инде дөньяда? Мин кемгә кирәк?

— Мин дә шундый хәлдә, Анна.

Аермачык ишеткәч тә ышанырлык түгел иде бу сүзләргә. Дөньяны кулларында тоткан, тормышның тәртибен саклаган иң көчле, шөһрәтле кешеләрнең берсе шушы сүзләрне теле барып ничек әйтә ала! Аннаны тынычландырмакчы, имештер. Янәсе, бөтен кеше мөшкел хәлдә...

— Их, Денис Иванович, Денис Иванович. Ярый, мин китим алайса. Марва Артемовна нишләр. Йөрәге ярылыр дип куркам, моны ишеткәч. Ул әле, мескенкәй, бер нәрсә белми бит. Бәхетле. Улым иректә ял итә дип, рәхәт яшәп ята.

Денис Иванович башын уң кулбашына таба чайкап кына куя. Тагын көчсезлек галәмәте. Кем уйлаган! Моңарчы аны белгән теләсә кемгә әйтсәң, шуларның берсе дә ышанырлык түгел. Дөресе шул. Адәмгә әйтсәң, адәм ышанмаслык хәл!

Фараз акланды — бер-ике атнадан район судьясы тагын шалтырата. Тавышы сизелерлек үзгәргән. Өзелергә торган иске җеп сыман — ышанычсыз.

— Кайбер хәбәрләр бар бит, Денис Иванович.

— Күңелсез хәбәрләр.

— Шулайрак, Денис Иванович, сөенерлек түгел. Безнең теге эшне Чистай районында караганнар.

— Соң?

— Карар икенче төрле.

— Эдуард Вәхитович, нишләп бу хәбәрне сез миңа җиткерәсез?

— Сездән килгән эш булгач...

— Күпчелек эшләрегез безнең аша килмимени? Хөкемне бит барыбер үзегез хәл иттегез, прокуратура белән бергәләп.

— Юк, мин җаваплылыктан куркып түгел, хәтта судья буларак та түгел, бары тик иптәшләрчә. Кемнәрнеңдер суны болгатканлыгын сизенәм. Сезгә нindидер чаралар күрергә, уяурак булырга кирәкмиме икән диюем. Кирәкмәгәнгә тыгыла дисәгез, гафу итегез.

Кайбер нәрсәләр аңлашыла төште, әлбәттә. Ләкин Денис Иванович, шактый үртәлсә дә, шикләренең кемгә караганын белмәгәнлектән, актанкарадан фикер белдерә алмады.

— Шалтыратуыгыз өчен рәхмәт,— дию белән чикләнде һәм, бүтән сүз көтмәстән, трубканы куйды.

Кемдер хәлне юри куерта. Кем өчендер форсат җайлы. Мондый җайны аңа, бәлки, озак көтәргә туры килгәндер. Морадына ирешәчәк тә түгел иде, әгәр гаепләнүчеләрнең берсе Михайлов фамилиясен йөртмәсә... Әгәр зур Михайловның утырган креслосы тарихи шартлар аркасында какшап шыгырдый башламаса... Мәсьәләгә шушылай кинрәк җирлектән карасаң, булачак вакыйгалар аермачык булып күренеп тора.

Үзенең бүгенге хәленә Денис Иванович шундый бәя бирде.

Ялгышмаган иде. Гөман ителгән бәла, соңламыйча һәм иртәләмичә, килеп тә житте, әлбәттә. Хат кыяфәтендә.

**«Райком бюросы әгъзасы иптәш Д. И. Михайловка Чакыру. Утырышның көн тәртибендә:**

**1. Урып-җыюга әзерлекнең торышы.**

**2. Район эчке эшләр бүлеге башлыгы Д. И. Михайловның персональ эше.**

**3. Төрлеләр.**

**Бюро».**

Хатны укып чыккач, Денис Иванович хәтта елмаеп куйды. «Нинди өлгерлек, нинди беркатлылык һәм... оятсыз турылык!» — дип уйлады ул. Ике-өч көнә көн элек башка килгән фараз тулысы белән акланачак.

Үз гомерендә аның үзенә бирелгән закон хәрефләреннән тайпылыш ясаганы юк иде. Соңгы очракны исәпкә алмаганда. Ләкин барыбер кызык бит. Елмаерга мәҗбүр иткән сәбәп шул: сыйныф мәнфәгатьләре сагында ул үзен сак торучыларның берсе дип исәпли иде, ә менә аннан да сизгеррәк, аннан да уяураклар бар икән ләбаса. Бигрәк тә житәкчелеккә соңгы вакытта килгән якын иптәшләр... Шуларның берсе — аның урынбасары...

Денис Иванович үз артындагы сәдәпкә басты. Бүтән чак булса, телефон аша үзе чакырыр иде иптәшне...

— Тыңлыйм, Денис Иванович.

Ишек ачып башын эчкә сузган кызү милиционерга ул Вәлиәхмәтовны чакырырга кушты. Тавышы гайре житди һәм рәсми иде. Бүтән чак булса, башкачарак әйтер иде ул.

Вәлиәхмәтов көттермичә килеп керде. Кыяфәтендә саклык һәм икеләнү билгеләре сизелеп тора иде. Утырды. Елмаерга тырышып, игътибар белән тыңларга җыенуын сиздереп, ике кулы белән урындык артын кочаклады. Иркенләп сөйләшергә мөмкинлеге бар, янәсе. Көннең бүген шактый кызу булачагыннан башламакчы иде, ләкин башлык иптәш ул тәкъдим иткән теманы кабул итмәгәнлектән, кем әйткәндәй, сүзне туптуры «үзебезнең сарык тәкәләре»ннән башларга туры килде.

— Эш менә нәрсәдә, Марсель Вәлиевич... Бүгеннән башлап, бүлектә житәкчелекне, контрольне... кайчанга хәтле икәнлеге соңыннан ачыкланыр... сиңа үз өстеңә алырга туры килә.

Сөенечен көчкә тыеп, ләкин күзләр ялтыравын барыбер яшерә алмаган урынбасар бөтен кыяфәте белән ихтирам белдереп, утырган җиреннән кузгалып, житди сорау бирергә тырышты:

— Аңламадым, Денис Иванович. Эш нәрсәдә?

— Шулаймыни? Менә алайса, укы.

Денис Иванович урынбасарга райкомнан килгән кәгазьне сузды. Вәлиәхмәтов, бөкерәйгән кыяфәттә өстәл янына килеп, кәгазьне алды да баскан килеш кенә бер кабат укыды, ике кабат, ләкин барыбер, гүяки, төшенеп житмәде.

— Соң... дөньяда булмый торган нәрсәмени инде бу?

— Минем тарихта булганы юк. Ә бу — кырык еллык тарих.

— Булмаса соң. Кем әйткәндәй, ярасыз батыр буламыни. — Денис Иванович сүз урынына җилкәсен генә җыерып куйгач, Вәлиәхмәтов

дәвам итте:— Минемчә, ул хәтле күтәрелеп бәрелергә ярамый. Әйтер идем, сезгә хас түгел болай. Күпме дошманнарны, җинаятьчеләрне җиңгән, каушамаган, курыкмаган кеше, хәзер... Хәзер килеп...

— Болар — башка төрле, корал тотып түгел, шаяра-көлә киләләр. Болары тагын да куркынычрак.

— Барыбер, болай ук курку — оят, җитди түгел, балаларча. Кеше көлдермәгез, зинһар, сорыйм, гафу итегез.

Денис Ивановичның кашлары җыерыла төшкәнне шәйләп, тыйлыкты урынбасар. Шуннан соң гәп җанлана алмады. Урынбасар үзе генә сөйләргә мәҗбүр.

— Райкомның беренче секретарен ал, әйе, үзебезнең Сәлим Сәлмәновичны. Бер карасаң, әүлия. Ныклабрак карасаң? Обкомнан ничәмә выговор күтәреп кайтты? Борыны түбәнәйдеме соң? Киресенчә, шелтә күтәреп, башын күккә чөеп кайта да, мондагы оешмаларны, колхозларны пыран-заран китерә. Үзеннән бер башка түбәнрәк иптәшләргә кайнар шелтәләр өләшә. Башка күп шелтәләр арасында аның бердәнбер шелтәсе эреп юкка чыга. Югары уңыш алынса, кучмә кызыл байраклар — районга, колхозга һәм башкалар, һәм башкалар. Котлаулар, бәйрәмнәр. Ә Сәлим Сәлмәнович исә — герой! Халык каршында йөзе ак, аңа зал аягүрә торып кул чаба! Так што, Денис Иванович, ашыгырга киңәш итмим сезгә. Мин сезне аңламыйм, аңларга теләгем дә юк.

Калганын инде үзегез карагыз дигәндәй, Вәлиәхмәтов, башын аска иеп, тын калды. Тынлык озакка сузылды. Хәзер Вәлиәхмәтовның әйтеләсе әйтелгән, бүтән үгетләре, нияте калмаган. Җитәкче кеше үзе акыл өйрәтсен.

Ләкин Денис Иванович авыз ачарга җыенмады. Һәрнәрсәнең чиге бар, әңгәмәгә нокта куярга вакыт. Шуны сизү аркасындадыр, ниһаять, Денис Иванович телгә килде:

— Мин сезне аңладым, рәхмәт,— диде ул, баштагы кырыслыгын киметә төшеп.— Ләкин сезгә мин әйткәнчә эшләргә туры килер. Алдагысын бюродан соң хәл итәрбез.

Әңгәмәнең төгәлләнгәнен аңлатып, ул урыныннан торды.

Көн саен райкомга ким дигәндә бер тапкыр сугылып чыга торган кешенең ул таба илткән эзләре суынды. Денис Иванович күренми башласа, үзе шалтырата торган Сәлим Сәлмәнович та аның телефон номерын онытты... Ике ара — тын. Давыл алды тынлыгыдыр, галәмәтләр шуны күрсәтә. Көннәр аяз торуга карамастан, күңелдәге барометр давыл ягына авыша бара.

...Эшкә вакытында килеп, вакытында кайта биргән Михайлов иптәш эчке эшләрнең берсендә катнашмавын дәвам итә. Әгәр дә хезмәткәрләр теге яки бу мәсьәләне ничек хәл итәбез дип керсә, аларны ул Вәлиәхмәтовка җибәрә. Бухгалтерлар керткән кәгазьләргә генә кул куя тора. Акча — четрекле нәрсә, җаваплылыкны бүтән кешегә аударырга ярамый.

Шул рәвешле, атна буе диярлек ул эшендә эшсез утырды. Шөгыльсезлектән интекмәс өчен иске документлар карап уйланды. Ә кырык еллык хезмәт юлында төрлесе булган — гыйбрәтләр дә, хикмәтләр дә.

Юл дигәнебез туган авылдан — шәһәр чаклы зур Катюма дигән авылдан башлана. Олыс Советы рәисе үз авылларындагы барча кыйммәтле әйберләрне төяп Чистайга җибәргән көннән. Авылга укытучы булып килгән Марва исемле яшь-яшь чибәр белән бричкага утырып чапкан чактан. Шуннан соң күпме гомер узган! Әйтерсең, пар атларда чабып кына узылган да куйган! Менә сиңа тормыш. Егерме ел Марва белән, калган егермесе — аннан башка. Менә пар атлар тукталды, тугарылды. Максатка җиттек дигәндә... Нинди дәһшәтле, коточкыч елларны имгәнми-нитми үткәч, кеше бүгенге ямьсез, рәнҗеткеч упкын каршына килеп чыгарбыз, дип кем уйлаган, кем уйлый алган! Башта шәпле аргамакларда, аннары тракторлар, автомашиналарда, соңгы чакларда исә җинел «Волга»ларда җилдерә торгач, җиңүләрдән җиңүләргә ирешә

торгач, шушындый оятсыз таркаулыкка килеп чыгарбыз, мәгънәсез ыгы-зыгыларга, ил мөлкәтен тарката-тарката, шаулаша-шаулаша бушлыкка, юклыкка таба шуыша барырга, тәгәри бирергә мәҗбүр ителербез дигән уй кем башына килә алган!

Пар атларда олысның барлык авылларыннан җыеп, ә кайбер очракларда талап алынган байлыклар тиешле урынга бик вакытлы тапшырылса да, затлы әйберләр, алтын-көмешләр бәрабәренә шактый икмәк сатып алынса, якыннан һәм ерактан кайтарылса да, кара кышның иләмсез олы корсагын тутырырлык була алмаган иде шул. Кыш көне үк ачыккан төбәкләр белән чагыштырганда беренче чорда корбаннар артык күп булмаса да, язга чыккач, барыбер, илгә килгән афәт бөтен кыргыйлыкларын эшкә кушмыйча калмаган иде. Халык тормышы, революция язмышы һәм Марва белән Денис язмышы да, гүяки, күктән иңгән куркыныч хәлгә — кара кышка, кара язга, кара җәйгә, кара көзгә — ач үлем вәхшилекләренә килеп чыккан иде.

Тарихта кыргыйлык белән тамгаланган егерме беренче...

Милиция хезмәткәре булып эшли генә башлаган Денис Михайлов дигән яшь егеткә олыс Советыннан үлемгә каршы көрәш бурычы йөкләнде. Вәхшилектән беренче хәбәр: кайбер авылларда адәмнәр бер-берсен ашый башлаган... Андый адәмнәрне тотып тиешле урыннарга озатырга кирәк. Иске Ильмово дигән авылдан тәгаен хәбәр: бер хатын үз балаларын ашый, имеш...

Дениска берничә кешелек отряд төзергә тәкъдим ителсә дә, ашыгычлык сәбәпле, ул башка иптәшләр эзләп тора алмады. Юлдаш итеп дошман ядрәләре аркылы бергә чыккан, инде сыналган кешене — Марва дигән кыз баланы сайлады. Кыз, каршы килмәгәе дип шикләнсә дә, кая ул, бер сүзсез риза булды чибәр. Һәм киттеләр. Дөрес, бу юлы пар атта түгел, сыңар ат белән.

Денисның билендә — маузер. Шуңа күрәдер, Марваның чыраенда курку галәмәте күренми иде.

Авыл уртасында тукталып, әлеге хатынны исеме белән атап, өенең кайда икәнлеген сорадылар. Арка урам дигән җирдә, зират очындарак икән. Җәяүләп шунда юнәлделәр. Денис бераз гына алдан, Марва ике-өч адым арттан атлады.

Килеп җиттеләр йортка. Өйалды идәннәре җимереләм, дип калтырый. Эчке ишек аркылы җылы пар бөркелә...

Шакымый гына керделәр. Хатын бер үзе. Миче дөрләп яна, казаны быгырдап кайный. Ятлар күренүгә, хатын, кулга эләккән ерткыч җәнлек сыман куркып, гүяки тешләшергә әзерләнеп, сагая калды. Дошманнарына ташланырга торган кыяфәтеннән, явыз күзләреннән үк хәлнең яманлыгы ялтырап күренде. Денис, ана һич сүз кушмыйча, диварда, казан янында эленеп торган озын саплы аш чүмечен алып, шуның белән казаннан ит кисәге эләктереп чыгаргач, күрәсеңме, дигән ым белән, Марвага карады. Күрмәскә иде дә, нишлисең, төшкә дә кермәскә тиешле җан өшеткеч нәрсәләрне өндә күрсәтә бит каһәрле тормыш. Үзен акылга сыймаслык тырышлык белән көчләп булса да, карады Марва һәм күрде, күрергә дучар ителде. Чүмечтә — бала кулы иде...

Денис почмакка кысрыкланган хатын кыяфәтле, дер-дер калтыраган җәнлекне изүеннән тотып аягүрә бастырды:

— Бу нәрсә? — дип, чүмечне аның борын төбенә үк китерде.

Ерткыч ана ымлык чыгармады. Кабат-кабат сораганны да, әйтерсең, ишетми иде. Бите балавыздан ясалгандай хәрәкәтсез иде, үлгән төсле иде.

Денис, шушы хәтле чиркандыргыч күренештән чырайлары җыерылган хәлдә, нидер әйтә ала бит әле. Марвага өйдә калып торырга куша бугай. Әйе, Марваны ерткыч хатын белән икәүдән-икәү калдырып, үзе ни өчендер чолан түбәсенә менеп китте. Ул да булмады, ишектән бала башы тотып керде. Баягы кул белән башны калын шәлгә төреп, Марвага сузды. Марва алмый торганлыктан:

— Тот! — дип, бөтен көченә акырды.

Шундый ук аяусызлык белән хатынга җыенырга кушты. Хатынга сәкедән алып сәләмә бишмәт кидерде дә, беләгеннән тотып, ишеккә таба селтәде.

— Атла! — дип боерды.

Шулай урамга чыктылар.

Марва, имәнгеч тәнгә тимәсен өчен, кулларын алга суза-суза гына атлап бара иде.

Ул чакта олыс Советында «Кеше ашаучылар белән көрәш комитеты» оешкан иде. Җинаять өстендә тотылган әлеге хатынны шул комитетка илтеп тапшырдылар.

Мондый җинаятьчеләр бу хатын гына түгел. Олыстан аларны Яңа чишмә дигән авылга озата тордылар. Аннан соң кая җибәргәннәр, нишләткәннәрдер — Денис монысын белмәде һәм кызыксынмады. Шунысы хак, ул адәмнәр моңарчы яшәгән төбәкләренә кире әйләнеп кайтмадылар.

Фаҗигаләр дәвам итә, ач үлем тантана итә бирә иде. Бөтен илдә. Мәетләрне арбага төяп, утын урынына ташлыйлар. Барысы бер чокырга күмелә.

Шундый көннәрнең берсендә Денис белән Марвага гаиләсез калган балаларны җыеп милициягә тапшыру бурычы йөкләнде. Тәгаен адрес белән тагын юлга чыктылар.

Яңа Ильмово дигән авылга килделәр. Күрсәтелгән өйләрнең берсе — салам түбәле башы кыйшаеп тора. Монда аларны балалар көтә... Әтиләре кайдадыр, азык эзләргә киткән җирдә, ачтан егылып үлгән. Әниләре элегрәк вафат булган икән.

Шул кешеләр өенә җиткәч, Денис Марвага чанада утырып торырга кушып, үзе өйгә кереп китте. Өйдә җан иясе барлыгы сизелми. Өй алларын, чоланны айкагач та шул ук хәл. Аптырагач, Денис яңадан өйгә кереп, бераз тыңланып торса, маэмай шыңшуына охшаш аваз ишетелгәндәй тоела. Мич башларын, кәбәрткәне тикшерә Денис, мич асларына үрелеп карый — юк. Ә бит тавыш ишетелде. Тын калгач, әнә тагын шул шыңшыган аваз. Инде каралмаган җир калмагач, мич авызына карап тора. Мич капкач белән ябык. Шуны ачып карасаң? Юри генә диярлек ачса, ике малай! Өч-дүрт яшьлек сабыйлар! Яннарында буш җамаяк, кашыклар аунап ята. Денисны күргәч, балалар маэмай балалары шикелле бер-берсенә елышып чыйнарга керешәләр. Денис аларның башта берсен, аннары икенчесен күтәреп, сәкегә утыртмакчы. Алар исә җан әчесе белән чыелдый башлый — кулга, биткә ябыша, тырнашалар. Үзләренә тотынырга курыкмалы — бөтен тәннәре, битләре тырналып, суелып беткән, кап-кара, пычрак. Ныклап караганчы ук күренеп тора: башларында бетләр йөгерә! Денис, балаларны ике култыгына кыстырып, Марва янына килгәч тә аңа бирмәкче, ә кыз, нишләптер куркып, читкә тайпыла һәм хәтта чәрелдәп җибәрә. Денис гадәтенчә җикереп куйгач кына, буйсынмыйча булдыра алмый. Чиркана-чиркана булса да, кулларына ала. Аннары үзе киеп килгән толыпка төреп, чанага урнаштыра.

Тиешле кулларга балаларны исем-фамилиясез тапшырмас өчен, күршеләрдән сорап, шуны ачыкларга туры килде. Сабыйларның берсе — революция яшьтәше, Семен исемле, икенчесе — Сергей. Фамилияләре — Собачкин. Дөньяга, яңа тормышка бер гаепсез сабыйларны шушы кушамат белән чыгарып җибәрергә ярамый бит инде. Марва белән икәүләп (озак уйлап торырга вакыт бармыни), кәгазьләргә балаларның фамилиясен авыл исеме белән Ильмов дип яздылар.

Шушы рәвешле, күпме авылларда булырга, күпме сабыйны коткарырга туры килде. Күбесе онытылды. Ә менә Семен белән Сергей Ильмовлар (Собачкиннар) бүгенге көнгәчә хәтердә саклана.

Кыяфәтләре, әллә фамилия аркасында, чынлап та маэмай балаларына тартым кебек иде...

Коткару миссиясе байтак вакыт эшләде.

Соңрак Марваны балалар өчен махсус ачылган ашханәгә олыс башкарма комитеты вәкиле итеп билгеләделәр. Анда Марва, барлык документларны язу һәм теркәү белән беррәттән, тирә-яктагы авыллар буйлап ашханә өчен азык эзли, табылган кадәресен кайтарып тапшыра иде. Икәүләп коткарган балалар йөзләр белән исәпләнгәндер... Хәзер исә менә үз балаларын коткарырга чират җитте. Ә монысы, ни әйтмәк кирәк, тагын да катлаулырак булып чыкты лабаса!

Денис атлы кыю егет белән Марва исемле чибәр кыз нинди авырлыкларны бергә кичереп, бергә уздылар. Ул чакларда исән калу үзе могҗиза иде. Түзелде — исән калынды, чөнки караңгы дәверләр кичкәндә, өмет якты, гаделлеккә, киләчәккә ышаныч нык иде. Хәзер исә якты заманда вөҗданнарга кара ягылды, өметләр каралды.

Әйе, хәрәбәләрдән яңа тормыш төзү батырлык иде һәм кешеләр шуңа ирештеләр. Ә хәзер? Хәзер! Максатка ирештек, идеалга барып җиттек, бөтен илдә бәхетле матур тормыш кордык дип әйтергә мөмкин була башлаганда! Бу ни хәл? Хәзер булганны җимерү, бүлгәләү осталыгына ирешәбезме? Нәрсә бу?

Үз-үзенә: «Сине бюро утырышына көтәләр, бар, бәлки шунда җавап табарсың», — дип, кузгалырга кушты Денис Иванович. Һәммә кешедән алданрак барып, үзен гаепләргә җыенган утырышны түземсезлек белән көтеп алды.

Бюро — барометр. Тормышның кай якка авышканын ул тиз сизә, дөрес күрсәтә. Карары нинди булыр, анысы бик үк мөһим түгел, гаепләнүче үзе нинди фикергә килер, шунысы әһәмиятлерәк. Сизенүенчә, нинди дә булса нәтиҗә ясарга туры киләчәк.

Моңарчы утырышка чаклы, гадәттә, Сәлим Сәлмәнович кичтән, йә иртән, эшкә яки өйгә шалтыратып, хәл белешә торган иде. Бу юлы кагыйдә үзгәрде, эндәшмәде иптәш секретарь. Моңарчы, гадәттә, бюро алдыннан иптәш Михайлов Сәлим Сәлмәнович кабинетына үзе керә, җитди сүз булмаса, һич югы кул кысып чыга иде. Кагыйдә үзгәрде — Беренче бүлмәсенә эчке эшләр бүлеге башлыгы сугылмый гына узды.

Бюро әгъзаларының һәркайсы үз урынын белә. Михайловныкы — озын өстәлнең урта төбәгендә. Ул инде үз урынында. Акрынлап, башка урындыклар да үз кунаклары белән кавышачак. Исәнләшүләр башлана. Алар элек шатлыклы була һәм Михайлов иптәш белән кул кысышу күбесе өчен дәрәҗә иде. Елмаеп исәнләшүләр болай да булмады түгел, булды. Күбрәге — колхоз җитәкчеләре. Ә беренче секретарь иптәш Габишев кереп утыргач, игътибар шул якка китеп бетте, дияргә туры килә. Утырыш башланганчы Габишев, үзе өчен әзерләнгән кәгазьләрне барлап утырганда, озын өстәлгә дә баш күтәреп күз салгалый. Шуңа күрә халык — сак, Михайловны күрмирәк тору хәерле. Өстәлнең каршы ягындагы буш урынга соңгарак калып килгән бер иптәш менә, Михайловны күрмичә, якындагы һәм ерактагы барча кешеләр белән ым кагып исәнләшсә дә, каршысындагы иптәшне күрмәскә тиеш тапты. Аннары исә, әлеге дә баягы алгы яктылыкка багып, шым калды. Бусы — арада иң яшь иптәш, комсомол райкомы секретаре — чама белән әйткәндә, Миша Михайловның яшьтәше буладыр. Дәвернең үз продукциясе... Сизгер, акыллы, ярашучан.

Колхоз рәисләре хисап биреп чыкканчы, аларның кайберләренә зирәк киңәшләр, кайберләренә чәнечкеле искәрмәләр, ә кайберләренә камчылы өркетүләр өләшеп чыкканчы, сәгатьтән артык вакыт узды. Шуннан соң, чакырылган кешеләрне утырыштан азат итү өчен Габишев унбиш минутлык тәнәфес игълан итте. Башкалар белән Михайлов та чыкты. Ләкин залдагы галәмәтләр коридорда да сизелә бирде. Михайловка коридор буйлап ялгыз йөрергә туры килде. «Мактаудан куркалар! — дип уйлады Михайлов иптәш. — Ярый әле, зынҗыр кидерергә башлары җитмәгән!»

Шундый фикер һәм тойгылар белән ул, тагын һәммә кешедән алда кереп, үз урынына сыенды. Кешеләр сирәгәйгән, гадәттәге унбер әһел генә калган иде. Шәхси эш ябык утырышта тикшерелә. Бу юлы да шулай, һәм тиз арада тынлык урнашуы да гадәти иде.

Көтелгән вакыт җитте — Габишевның тавышы көр:

— Утырыш дәвам итә, иптәшләр.— Сабырлык галәмәте, тыйлыгып тору. Утырдашларны киеренке хәлгә күнектерә төшү. Аска карап шактый ара сүзсез торганнан соң, баш калкыту һәм аннан арысы ныклы, корыч аваз: — Көн тәртибенең икенче пункты сезгә билгеле. Шундыйрак хәл. Республика прокуратурасыннан мөрәҗәгать алынды, кайсыдыр ки, районыбызның эчке эшләр бүлеге башлыгы иптәш Михайловка, хөрмәтле Денис Ивановичка кагыла.— Бу сүзләрдән урындыклар шыгырдап куя.— Хәлебез җайлы түгел. Үзебезнең бюро члены, өлкән иптәшебез, хөрмәтле дустыбызның тәртибен тикшерергә, бәя бирергә, билгеле бер карарга килергә мәҗбүрбез. Мәсьәлә аңлашыламы?

Урындыкларның таныш борчылуы. Һәм бераздан кыюсыз сорау:

— Эш нидән гыйбарәт соң? Бәлки, информация кирәктер?

Бу сорауның иясе — Ленин исемендәге атаклы колхоз рәисе Тимершин, чагыштырмача мөстәкыйльрәк иптәш.

— Информация дисезме? Ничек, иптәшләр?

— Шулай дөресрәк булыр, Сәлим Сәлмәнович. Тыңлыйк.

— Денис Иванович, ничек, бәлки башта үзегез аңлатырсыз?

— Юктыр, башта үзегез туйганчы тиргәгез, мин тоташтан җавап бирермен.— Михайлов, бу сүзләрне әйткәндә, елмаерга азапланмакчы бит әле.

Залга чынлап та кызыклырак булып китә, чынлап та елмаю, хәтта ясалмарак булса да көлешү ымлыклары ишетелеп куя, гәрчә сүзсез бу күренеш тә урындыклар шыгырдавы белән тәгәлләнсә дә. Ярый, юк ише түгел. Киеренкелек менә аз булса да кимеде төсле бит. Һәрхәлдә, чырайларда шом сыеклана төште. Ни дисәң дә, гаепле кеше, шаһитләргә һич үпкә сиздермичә, тел ачкычы бирергә тиеш иде бит. Әнә, Габишевның да сүзләре фаҗигале үк төсле түгел инде.

— Гаепләнүченең сүзе,— дип шаяруны дәвам итте секретарь,— әйе, гаепләнүченең сүзен исәпкә алмый булмый. Башка иптәшләрдән башлап карыйк. Монда Денис Ивановичның урынбасары, иптәш Вәлиәхмәтов чакырылды. Марсель Вәлиевич. Аны тыңлыйк. Шулай бит?

— Кирәк, кирәк,— диештеләр күтәренке күңел белән.

Иптәш Вәлиәхмәтов, димәк, әзер, әзерләгәннәр. Алай дисәң, теге көнне ихлас кайгырып, нинди кешелекле киңәшләр биргән иде. Бәлки тагын шул ук матур фикерләрен кабатлар? Ләкин әзерләүләре хак булса, аңа хәзер кыенгарак туры киләчәк.

— Әйдә, Марсель Вәлиевич.

Марсель Вәлиевичның кыяфәт — тыйнаклыкның нәкъ үзе. Чем кара чәчле, кара күзле, озынчарак чиста йөзле. Ияге ныграк очлы булуы гына композицияне бераз боза икән. Мәгәр болай да шәп — үзенчәлекле төс биреп тора. Үзенең күпме бергә эшләгән урынбасарына шушылай җентекле караве беренче мәртәбә шикелле. Вакыт җитмәгән. Хәзер мөмкинлек туды. Кара һәм тыңла. Һәм тыңлады Денис Иванович. Урынбасар тавышында гаепләү хикмәте сизелми иде.

— Мин, иптәшләр,— диде ул, һәм чак кына уңайсызланудан, ике бармагы белән күз читләрен сыпырып куйды.— Мин эшне ул хәтле драмага әйләндерү ягында түгел. Эш бит ул хәтле зурдан кубарлык түгел. Бәхетсез очрак дисәк, дөресрәктер. Потерпевший өчен дә, гаепле кешеләр өчен дә. Уеннан уймак чыгарган тиле малайлар. Усаллык белән түгел, диваналык белән. Тикшерүне мин үзем алып бардым. Мәсьәләгә ике төрле карарга мөмкинлек бар иде. Уен итеп һәм аңлы рәвештә эшләнгән җинаять итеп. Без урталыкны сайладык, чөнки уен дигәндә дә, аның азагы җитди. Төп гаепләнүче Константин Сергеевич Малышев... Сез беләсездер...

— Сергей Андреевич улы, беләбез,— дип, Габишев мөһер сугарга ашыкты.— Да, авыр хәл. Дәвам ит, Марсель Вәлиевич.

— Дәвамы шул инде аның, Сәлим Сәлмәнович, шаярунын фаҗига белән тәгәлләнүе. Шул сәбәп белән Константин Малышев гаепле дип табылды, суд шуны раслады. Ә Мәлих Михайлов дигәндә, ул бокска турыдан-туры катнашмаган, судья булып кына торган. Иптәшен яклый алмаган, уенны туктатырга акылы җитмәгән. Ләкин гаеп җинаять матдәсенә туры килми. Бу мәсьәләдә мин Денис Иванович белән киңәштем. Ул да шушы карашны дөрес дип тапты.

— Чөнки...

— Нәрсә «чөнки», Сәлим Сәлмәнович?

— Чөнки Мәлих Михайлов Денис Ивановичның туган улы.

— Денис Иванович үз улыннан баш тартырга җыенмый.

— Гәрчә үзе андый башка мисалларны белсә дә. Дөрес. Әйтер сүзегез тагын бармы, Марсель Вәлиевич?

— Минем бетте.

— Әгәр сораулар булмаса... Бармы сораулар?

— Бар, Сәлим Сәлмәнович,— дип, баягы мөстәкыйльрәк дигән иптәш, колхоз рәисе кузгалып куйды.

— Соң?

— Үзебезнең район суды карарына кем шик белдергән дә, кем җалоба язып җибәргән. Шуны беләсе килгән иде.

— Марсель Вәлиевич, сорау сезгә бугай.

— Анысы миңа билгеле түгел. Миңа билгелесе шул гына: безнең суд карары югары судта расланмаган. Кабат тикшерү өчен прокуратурага җибәрелгән. Прокуратура, үз чиратында, объективлык өчен дип, Чистай районына күчерергә тиеш тапкан. Әнә шундый механизм.

— Ә ни өчен, нинди нигезләргә таянып, хөкем карары яңача килеп чыккан?

— Малышев баштагы күрсәтмәләрен үзгәрткән. Михайлов команда биреп торды, җинаять корбанын үзе дә бер мәртәбә сугып екты, дип.

— Михайлов шуны таныганмы?

— Танымаса да... Тикшерү Малышев күрсәтмәсен дәлилле дип тапкан. Шундый хәл. Ләкин мәсьәлә ни өчен Денис Ивановичка кагыла, мин аңлап бетерә алмыйм. Бәлки сез аңлатырсыз?

— Давай, Марсель Вәлиевич, тыйнаклык күрсәтмәгез. Сез моны беләсез,— дип, җитәкче иптәш төзәтмә кертергә тиеш тапты.— Бик яхшы аңлыйсыз. Белгеч буларак, сез Чистайныкылардан ким дә түгелдер. Алар ачыклаганны сез дә ачыклый, дәлилли алган булыр идегез. Комачау иткән нәрсә — Мәлих Михайловның кем улы булуында. Шулай түгелме әллә? Әйдәгез, ахыргача гадел булырга тырышыйк.

Шулай түгел дип беркем дә әйтә алмады, хәтта бу юлы Вәлиәхмәтов та авызына су капты — туры мәгънәсендә. Өстәлгә минераль су куелган иде бит. Шуны үзе ачып, стаканга үзе салып, тулы стаканны төбенәчә чөмереп куйды.

— Сораулар тагын бармы? Юкмы? Ярый. Алайса, сөйләүләргә күчәбез. Кем сүз әйтергә тели?

— Миңа бирегез әле, Сәлим Сәлмәнович,— дип, тагын шул ук мөстәкыйльрәк кеше торып басты, нишләптер уңайсызлана төшеп. Һәм, уңайсызлануын җиңәр өчен генә булса кирәк, кызу сүз өстәде: — Әгәр мөмкин булса. Кирәкми димәсәгез.

— Мөмкин, нишләп алай дисез? Рәхим ит, алайса, Кәрим Галимович. Синнән башлыйк.

Кәрим Галимович уңайсызлануын җиңәр өчен тагын җилкәсен кашып куйды. Сүзләрен иптәш Габишев якламаячагын сизү аркасында бугай, кызара төшеп, тамак кыргалады. Ләкин үзе болай гаярь егет шикелле.

— Менә мин, уйлап торам-торам да, тагын бер уйлап куям әле. Бар иде бит вакытлар. Басудан ике йөз грамм ашлык алып кайткан өчен

хатыннарны тотып милициягә алып китәләр иде. Ул чакларда райком милициягә һич тә бәйләнмидерие. Ә менә хәзер бик төпченеп катнаша башладык, өйрәтә башладык.

— Син, Кәрим Галимович, ул вакытларны сагынма инде. Хәзер заман бүтән — демократия. Тәртип саклау органнары партия күзәтүенә күчерелде. Элекке хаталарны партия кабатламаска куша. Бу — безнең шәхси тыкшынуыбыз түгел, белеп, иләп сөйләш. Бу — партия линиясе. Без — шуны тормышка ашыручылар. Аңлашылдымы, Кәрим Галимович? Әйдәгез, ахыргача гадел булыйк.

— Дөрес әйтәсез, Сәлим Сәлмәнович, белеп сөйләшергә кирәк. Кемнең кем икәнен белергә. Без Денис Ивановичны белмибез мәллә? Әйдәгез, ахыргача аның кебек намуслы булырга тырышыйк.

Үз колакларына үзе дә ышанмаган Габишевның йөзендә күклекызыллы тимгелләр барлыкка килде... Ышанырлыкмыни — беренче секретарьның үзенә намус турында шик белдерәләр ләбаса, ә? Шулай түгелме? Аның белән шушылай шаярырга ярыймыни? Менә бит, кайберәүләрне артыграк азындырган булып чыга ул, эшләре әйбәт барган өчен генә мактап. Ялгышны төзәтергә беркайчан да соң түгел, төзәтергә туры килер, килер.

Ләкин каны артыграк кайнап өлгергәнлектән, ул беразга өнсез калып торды. Аннары гына сүрелә төшеп, тиешле микъдарда елмаеп, утырышны дәвам итте.

— Рәхмәт, Кәрим Галимович, сезнең мөнәсәбәт аңлашылды. Искә алырбыз. Шушындый караш та бар, димәк. Тагын кемгә сүз?

Үзенә чират җиткәнне сизгән комсомол секретаре кул күтәрде. Габишев аны тиз күреп, сүзне җәһәт һәм шәрехләүсез генә бирде бу юлы. Билгеле, яшь иптәш өлкән остазы каршында сынатмаячак. Һәм менә ул ишетергә теләгән сүзләр:

— Кәрим Галимовичның мавыгып китә торган гадәте бар инде аның. Көрәшче кеше бит, сабан туйларында бил алышкан. Хәзер дә шуны куа — кем хәрәмләшә, кем намуслы көрәшә, ул монда нык игътибарлы. Ләкин монда хәрәмләшүчеләр, аяк чалучылар юк бит, Кәрим Галимович. Барыбыз да честный кешеләр. Беренчедән, шушы. Икенчедән, Денис Ивановичны да нечестный дигән кеше юк лабаса. Хаталанган дип кенә әйтәбез. Яшерен-батырын түгел, хата дигәндә, анысы бар. Һәм хата бик җитди, чөнки бу — тенденция дигән сүз. Әгәр дә тәртип саклау органнары кода-кодагыйлык белән шөгыльләнә башласа, бүтәннәр өчен нинди сабак булыр иде бу? Бигрәк тә яшьләр өчен? Син үзең, Кәрим Галимович, колхозда кайбер кагыйдәләрне бозган кеше, бәлки сезнең өчен андый нәрсә азмы-күпме гафу ителә торгандыр. Ә тәрбия мәсьәләсендә башбаштаклыкка без юл куя алмыйбыз, әгәр дә киләчәк хакында кайгыртсак. Өченчедән, Сәлим Сәлмәнович бик дөрес күрсәтеп үтте, партия линиясе турында. Югарыдагы хәлләрне без беләбез. Илдә эчке эшләрнең кемнәр кулында булып чыгуын. Ул эшләр — дошман кулында булып чыкты. Дошман тотылды һәм атылды. Ләкин аның агентурасы бетте дип без әйтә алабызмы? Ул агентура бит югарыдан иң түбәнгә хәтле урнаштырылган. Шулай булгач? Әйдәгез, дөреслекнең күзенә туп-туры карыйк. Без кем белән эш итәбез? Әйдәгез, ахыргыча честный булыйк.

Сәлим Сәлмәновичның күзенә карап торган, һәр сүзен җөпләргә күнеккән бюро членнары, хәтта алар да ахылдап куйдылар. Сәлим Сәлмәнович булып, хәтта ул да уңайсызлана төшеп, иреннәрен кысты. Денис Иванович исә, үз каршында утырган яшь нотыкчыга, беренче мәртәбә күргәндәй, аптырап, үз күзләренә үзе ышанмыйча карап торды. Һәм күрде!

Яшь иптәш — чама белән Мәлихның яшьтәше. Чырасында таныш чалымнар юк түгел бугай...

Егетнең фамилиясе — Ильмов, Валерий Семенович. Бу кеше белән әлегрәк кызыксынырга кирәк булган лабаса. Соң булса да уң булсын.

— Сез, Валерий Семенович, Яңа Ильмово авылыннан түгелме?
Егетнең күзләренә гаҗәпләнү билгеләре чыкты.

— Яңа Ильмово? Юк, мин аннан түгел. Ә минем әтием шунда туган булган.

— Дүрт яшеннән башлап, детдомда яшәгән. Шулаймы?

— Шулай. Әнинең сөйләвенә караганда.

— Әниегез дөрес әйткән.

— Дөрес? Сез моны каян беләсез?

— Бик яхшы беләм. Чөнки сезнең әтиегезне мин, ачлыктан коткарып, балалар йортына үзем тапшырган кеше. Мин аны мич авызыннан тартып чыгардым. Суыктан куркып, шунда кереп посканнар иде, ятимнәр.

— Сез, сез... ни сөйлисез? Үз акылыгыздамы сез?

— Мин үз акылымда. Ә менә сезне алай димәс идем. Әтиегез миңа рәхмәт әйтергә кергәген, бәлки, белми киткәндер.

— Ул сугышта һәлак булды, инде аның истәлегенә күләгә төшермәкче буласызмы?

— Юк, һич тә. Ә менә сез... Аның өчен рәхмәтне матур итеп әйттегез. Ерак китәрсез, молодец!

Бюро утырышында уеннан уймак телгә шактый еш кергәләсә дә, көтелмәгәндә килеп чыккан әлеге хикмәтне уеннан чыкты дип кем әйтә алыр иде икән? Бусы ерак иде уен дигән нәрсәдән. Барлык иптәшләр, нәрсә әйтергә, хәлгә ничек бәя бирергә белмичә, шаккатып дигәндәй утырдылар. Утыра бирделәр. Әгәр Габишев үзе контрольне ычкындырса (ә бит булды, бер мәлгә ул да аптырап, кемгә карарга, кемнән ярдәм сорарга белмичә аптырап торды!), утырыш шушы җәнҗал сыман күренеш белән чикләнәсе иде. Озаграк интегеп, азапланыбрак булса да, ул үзен һәм аннары башкаларны тәртипкә кайтара алды. Шау-шуны кыңгырау чыңлата-чыңлата туктата алды.

— Гафу итегез, артыккарак китте,— дип әллә яшь иптәш өчен, әллә вакытсызрак сорау алган эчке эшләр бүлеге башлыгы өчен гафу үтенде дә, тагын утырышны дәвам итәргә тырышты: — Монда бер нәрсә бик дөрес әйтелде, чынлап та кемнең кем булуын белеп сөйләшергә кирәк. Яшь иптәш — кайнаррак, аңларга кирәк. Денис Иванович — безнең ихтирамлы кешебез. Шуны истә тотып сөйләшик. Хәзер кемгә сүз?

Сөйләргә ашыгучылар юк иде. Шуңа күрә, Сәлим Сәлмәнович үзе, хәлгә бәя бирү йөзеннән, башына килгән фикерләрен башкаларга җиткерү теләгендә кайбер фаразлар белән уртаклашырга мәҗбүр иде. Фикерләүләрнең мәгънәсе шулардан гыйбарәттер. Әйе, вакыт шундый, партия линиясе шундый. Эчке эшләргә партия күзәтчелеген формализмга әйләндерергә хакыбыз юк. Денис Ивановичның күпьеллык хезмәтләрен истә тотып, беренче юлга каты шелтә белән чикләнергә ярыйдыр. Исәп карточкасына язып, әлбәттә. Бәлки шулай килешербез? Ничек?

Бюро әгъзаларының барысы да «шушы фикер белән кушылабыз» дип ризалык белдергәч, йомгак ясар алдыннан Габишев Михайловкага мөрәҗәгать итте:

— Денис Иванович, ничек, сезне тыңлыйсы иде бит. Бәлки хәл тагын да аңлашыла төшәр иде?

Денис Иванович, әйтерсең, тып-тыныч. Битенең кәгазь төсле агарганлыгыннан гына бу тынычлыкның асылын чамаларга мөмкин булгандыр. Аңа төбәлгән карашларда да баягы гаҗизлек, аптырау галәмәтләре югала, сүрелә төшкән иде. Алар өчен хәзер иң кыены артта калды. Котылдылар дисәк тә ярыйдыр әле. Әйе, күңелләр бушанган, хисләр юашланган. Әнә кайберәүләр хәтта елмаерга азаплана. Теләктәшлек белдерәләр. Рәхмәт иптәшләргә. Ләкин Денис Иванович алар көткәнне әйтә алмас шул. Ялгышлык булды, гафу итегез, киләчәктә сезнең теләкләрегезне, туры тәнкыйтегезне истә тотармын, дип ант эчә алмаячак. Киресенчә, Денис Иванович, тагын бер кабат кешеләрне җайсыз хәлгә

куйды, дисәк тә ялгышмабыз, бәлки. Ләкин шунысы хак, ул торып басты. Һәм җаваплар урынына сораулардан башлады:

— Эшләр болайга киткәч, нәрсә әйтергә? Акланыргамы? Бу эшкә катнашым шуның хәтле генә дияргәме? Юк, моның кирәге дә юк, мөмкинлеге дә юк. Тәртип саклау кешеләре үз гамәлләренә карата шул дәрәҗәдә сак булырга тиешләр ки, алар хакында хәттә гайбәт сөйләрлек тә җай калмасын. Цезарь хатыны шикләнүләрдән азат булырга тиеш. Бу юлы шикләр чамадан артты. Димәк, сылтауга җай бирелгән. Минем гаеп. Гафу ителми торган гаеп. Аннан мин нәтиҗә ясарга тиеш. Беренче сүзем шушы. Икенче нәтиҗә өчен дә җирлек бар. Монысы тагын да мөһимрәк. Әйе, тормыш нык үзгәрде. Идея өчен көрәш тукталды, бетте. Шау-шу күп, идея сафлыгы турында чыгышлар — чик-чамасыз, шуның хакына җыелышлар, пленумнар, съездлар. Ә көрәш үзе юк. Хәзер һәркем диярлек ял итәргә, яшәп калырга җай күрде. Эшнең максаты хәзер бүтән — хезмәтнең идея хакына икәнлеге, җан таләбе икәнлеге, шуның белән бәйләнгән энтузиазм онытылды, читтә калды. Ялкынлы чыгышлар гына түгел, хезмәтнең үзе дә күз буяу белән аралаша, тормышта уңайлы позиция алу яки саклау өчен генә башкарыла хәзер. Сез монда искә алган намус категориясе дә әүвәлге эчтәлеген җуйды, ул хәзер икейөзлелекнең иң беренче билгесе. Икенче төрле әйткәндә, шул: партия үзе мещанлашты...

Бу сүзләрне ишеткәч, иптәш Габишев, үз колагына ышана алмыйча, коточкыч ялага бик зәгыйфь отпор гына биреп:

— Сез, сез, акылыгыздамы?! — дип кенә әйтә алды.

Бүтәннәр өнсез калудан файдаланып, гаепләнүче үз гаепләүләрен дәвам итте:

— Дәүләтнең эчке серләре ачылгач, корсагы ярылгач, барыбыз да борыннарыбызны тоттык. Корсактан чыккан җен барыбызны бер мәлгә зиһенсез калдырды. Менә шушындый егетләр үсеп килә.— Денис Иванович үз каршындагы егеткә карамыйча, кул белән изәп кенә күрсәтте.— Дөнья менә кемнәргә күчә. Алар килә безгә алмашка. Ишеттегез алар сүзен, чамалый аласыз. Шундый үзгәреш. Аңа күпләребез әле әзер түгел. Шундый кешеләрнең берсе мин үземдер. Һәрхәлдә, бу яңа шартларда эшләргә мин әзер түгелмен.

Денис Ивановичның сөйләүдән туктарга җыенмавын сизгән Габишев реплика ташларга мәҗбүр:

— Денис Иванович, сез би-ик читкә тайпылдыгыз. Көн тәртибенең үзегезгә кагылган өлеше белән чикләнсәгез, әйбәтрәк булыр иде.

— Гафу итегез, әйткәннәремнең барысы да үземә кагыла. Әйтәсе килгәнем шул гына — мин яңа шартларда эшләргә әзер түгел. Эштән азат итүегезне үтенәм.

Бу сүзләрне әйтергә ул берничә көн элек үк әзер булса да, нишләптер, барыбер каушады. Йөрәге дөпелдәвен тоеп, үзе дә урындыкка дөпелдәбрәк утырды. Гүяки, башкалар да шушы хәлдә иде. Бюро халкы — телсез. Авызлар ачылды да калды. Бер ара Габишев булып Габишев күзләрен угалап утырырга мәҗбүр булды. Шулай да үзен кулга алырга өлгерде.

— Да-а, хәлләр,— дип, баштарак кирәкле сүз табалмыйча интекте. Тик икенче мизгелдә һушына килеп, нәтиҗә ясады.— Да-а, Денис Иванович рәнҗеде.

— Ләкин сезгә түгел.

— Кемгә соң? Монда сезгә бит ул хәтле ямьсез сүзләр әйтелмәде, минемчә?

— Эш сездә генә түгел, ил күләмендә...

— Ах, менә ничек! Шулай шул, без төшенә яздык, сез партия линиясе белән килешмисез.

— Партияне идеясез калдыручылар белән. Арттырмагыз, киметмәгез дә.

Мондый ук куркыныч мәсьәлә хакында сүз куерту — Габишев өчен файдасыз, хәтта зарарлы иде, әлбәттә. Ул утырышны адәмчәрәк төгәл-

ләргә тиеш иде. Шуна күрә, бәлки ашыгыбрактыр, тәкъдимнәрне астан күтмичә, үзе кертергә кирәк тапты.

— Мин болай уйлыйм, иптәшләр. Денис Ивановичның соңгы тузынуын нервылар кузгалуы гына дип беләм. Эштән китү мәсьәләсен икәүдән-икәү сөйләшеп хәл итәрбез. Денис Иванович тынычлана төшкәч. Шулаймы? Тагын юкмы бүтән фикерләр?

— Юк, юк! — диештеләр иптәшләр, хәерсез хәлдән тизрәк котылу өчен.

— Ярый. Денис Ивановичның карт большевик икәнлеге һәркайсыбызга мәгълүм. Кырык еллык хезмәт юлы узган ветеран. Хезмәтләре партия һәм хөкүмәт тарафыннан лаеклы рәвештә танылган. Совет дәүләтен төзүдә, ныгытуда, киләчәк буыннарны тәрбияләүдәге уңышлары орденнар, мактаулы исемнәр белән билгеләнгән. Без боларның барысын таныйбыз. Шулай бит?

— Шулай, әлбәттә, шулай!

— Әмма турысын әйтик, дүрт аяклы ат та абына. Аның урынында булсам, бәлки, мин дә аныңча эшләр идем. Нишлисең, бала бит. Табигатьтән бирелгән көчле тойгы. Табигать законы, күрәсең, иҗтимагый кануннардан өстенрәк булып чыккан. Без моны аңлыйбыз, гәрчә аклый да алмыйбыз. Шулай бит? Чөнки мондый хәлдә үзебез закон бозсак, башкалардан ничек таләп итәрбез дөреслекне? Кыенлык менә шушы нәрсәдә, иптәшләр. Хәл бездән кырыслык таләп итә. Монда дөрес сүзләр әйтелде. Мин сезнең белән килешәм. Шулай, Денис Иванович, сезгә карата теләкләребез гел яхшылыкта. Ләкин сезнең баягы шәхсән фикерләрегезгә каршылык белдерәбез. Бөтенләй икенче яссылыктагы кечкенә фактлардан зур политик гомумиләштерү ясарга ярамый. Ярамый. Әйе. Бик тә куркыныч нәрсә бу, Денис Иванович. Моны истә тотыйк. Барыбызга да сабак булсын. Шулай бит?

— Шулай, шулай!

— Инде эш нәрсәдә калды?

Мөстәкыйль иптәшкә шаяртырга җай туды шулай.

— Эш выговорда калды! — дип кычкырып ук көлде ул.

— Көлке түгел, дөресе шул. Башка тәкъдимнәр булмады. Тәкъдим бер генә: республика прокуратурасы фикерен искә алып, җинаять эше тикшерүдә җибәрелгән принципсызлык өчен КПСС әгъзасы Денис Иванович Михайловка, исәп карточкасына теркәп, каты шелтә белдерергә. Кемнәр риза? Төшерегез. Каршылар? Каршылар юк. Тыйлыгып калучылар? Юк. Рәхмәт. Көн тәртибенең соңгы пунктына күчәбез. Төрлеләр. Кемдә нинди сүзләр, тәкъдимнәр?

Марсель Вәлиевич, ашыгыч эш барлыгын сәбәп итеп, Габишев рөхсәте белән чыгып китте. Чыгышлый, Денис Ивановичка күз карашы белән теләктәшлек сиздерергә өлгерде, дияргә кирәк. Иптәш Габишев аны утырышка әзерләгән, әлбәттә. Ләкин кеше ямьсез үк кыланмады, икесякка да ярый белде — молодец! Габишев үзе исә күбрәкне белә. Җөмләдән, Денис Ивановичның кайчан пенсиягә китәчәген. Эчке эшләр бүлегенә яңа шартларга туры килгән яшь иптәш киләчәген, кем киявенең, яки туганнан туган энесе куелачагын белә. Моның өчен югарыдан үзенә тиячәк әҗер микъдарын чамалый. Хезмәт юлында аның да бит әле бу эше соңгы баскыч түгел...

Утырыш тәмам. Денис Иванович тавышсыз-тынсыз гына чыгып китмәкче иде, аны Габишев туктатты.

— Денис Иванович, шулай килештек сезнең белән. Җаегыз белән сугылырсыз әле, яме. Иркенләп сөйләшербез, киңәшербез. Тик сез йөрәккә ул хәтле якын алмагыз. Исән булыйк. Эшләгез.

Шулай дигәч, секретарь җәһәт кенә ишеккә юнәлде.

«Эшләгез!» — Нинди тирән, мәгънәле сүз! Бөек юлбашчы сүзе бит ул! Моны ишеткәч, эшләмәс җиреңнән эшлисең инде...

Шушы уй белән чыгып барганда, аның колагына кемнеңдер борын сузганы сизелде. Баягы яшь иптәш, Валерий Семенович Ильмов. Маэмайныкына тартым борынын сузып, шәхси үче, ачуы барсыман зәһәрләнеп, үзенең эт җыймас сүзен ысылдап узды бу:

— Сезнең көннәрегез санаулы! — диде һәм тиз арада баскычка борылып, түбән таба теркелдәде.

Ышансаң-ышанмасаң, тәки әйтте шул сүзләрне. Һәм бөтен кыяфәте, тәки маэмайга охшаш икәнлеге бу юлы һич икеләнмәслек дәрәҗәдә күренеп, хәтергә уелып калды.

Әйе, вакыт үз эшен башкарган — бәләкәй көчек эт булып җитешкән. Менә ул инде тешләшә башлады. Хәзер нишләргә? Ачуланырга, рәнҗергәме аңа? Юктыр, алай кирәк түгелдер, аңлау хәерлерәктер. Хикмәт этнең үзендә түгел, аны өстерүчеләрдә бит. Кем өстерә аны! Чамаларга мөмкин...

Егет — үз дәвере баласы, токымына хас булганча, борыны исне яхшы тоя. Тугрылык белән хезмәт итәчәк һәм үзе дә шактый зур уңышларга ирешәчәк — төрле күргәзмәләрдә медальләр алачак...

Ә бит аның исеме әле күптән түгел генә ишетелә башлады. Кай арада яшьләр арасында лидер булып өлгергән дә, кай арада зур бюро әгъзасы булуга ирешкән! Җавап — баягы, хуҗасы көчле кешеләрдән. Ул үзенә яхшы хуҗа тапкан. Үз тәрбиясенә муафыйк рәвештә, бөтен бер буын яшьләрне үз мәктәбе аша уздырачак!

Ә Денис Ивановичка нәрсә кала? «Эшләргә!»

Эш дигәндә, анысы ничек булыр, ләкин шунысы хак, ул эш бүлмәсенә яңадан кайтты һәм үзенең көндәлек бурычларын җиренә җиткереп башкарырга тырышты. Бер, ике атна. Ә аннары... Көннәрдән бер көнне...

Ул көнне Денис Иванович бүлмәсендә төн буе ут сүнмәде. Көн яктыргач та януын дәвам итте. Ә иртә белән бүлмәгә җыештыручы апа керсә...

Юк, җыештыручы апа күзләренә ул-бу чалынмады әле. Урам як тәрәзә төпләрен сөрткәләп, сейфка, аннары өстәлнең түр кырыйларын сөртергә килсә...

— Әләй! — дип кычкырып та җибәрде апа һәм чыгып та йөгерде бүлмәдән.

Ишек артында утырган кизү милиционер:

— Нәрсә бар, ник кеше куркытасың? — дип сорагач, баягыдан һич ким булмаган курку белән:

— Денис Иванович идәндә ята! — дип ачы тавыш белән кычкырды.

Якын тирәдәге иптәшләр җыйнаулашып кергәч күрделәр: апаның сүзе дөрес иде. Бөкшәеп ята Денис Иванович. Янында гына — пистолет. Ярасы билендә иде. Кеше гадәттә йөрәгенә, яки башына ата. Ә бу — биленә, бөеренә. Шуңа күрә, төрлечә фаразларга, юрарга җай калды: бәлки үзе түгел, башкалар аткандыр. Бәлки бөер өянәге кузгалып, авыртуга чыдый алмагандыр да, бөер ташы теткәләнсен дип аткандыр. Ә ул таш заман каһәре дип атала торгандыр...

Кан эчендә яткан Денис Ивановичны тиз арада мең төрле сораулар белән больницага озаттылар. Анна исә шул ук көнне Марвага телеграмма җибәрде. Анда: «Срочно приезжай погиб Денис Иванович» — дип язылган иде.

## Бишенче бүлек

Алабугага кайткач, Аннадан акылга сыешлы бер хәбәр дә ишетә алмаганлыктан, Марва икенче көнне иртүк торып, милиция йортына ашыкты. Теге чактагыча, кабул итү бүлмәсенә керде. Кизү егет элекке таныш иде. Аннан сорашты. Анысы да ачык кына әйтә

алмаганлыктан, ни сорарга белмичә аптырап торганда, исенә нидер төшкәндәй, яшь милиционер үзе сорау бирде:

— Сез Денис Ивановичның элекке хатыны бит, әйеме?

— Әйе.

— Миша Михайловның әнисе.

— Әйе,— дип гаҗәпләнеп карады Марва.

— Менә монда бер хат. Кичә генә килде. Денис Ивановичка лично, диелгән. Улыгыздан. Кире кайтару өчен сезгә генә тапшырсам... Ярыйдыр бит?

Ни дә булса уйлап өлгергәнче үк, куллар хатка үрелде. Хатны алды һәм шунда ук чыгып та китте Марва.

Улы атасына хат язган! Улы! Әтисенә! Ниһаять! Ничәмә еллар буе бер шәһәрдә аерым яшәгән ата белән бала, димәк, бер гаилә кешеләре булып, үз кешеләрчә аңлаша ала икән! Димәк, аерым яшәсәләр дә, уртак уйлары булган. Ни сәбәптәндер, моңарчы сөйләшә алмаганнар, киңәшләре берекмәгән. Әкерен-әкерен читләшә барганнар. Ләкин менә исләренә төшкән — малайның атасы барлыгы исенә төшкән. Ләкин соңга калган шул, артык соңга калган. Хәзер инде менә сөйләшерләр иде, ешрак киңәшерләр иде. Хәзер менә әйтеләсе килгән сүзләр бар, ата гына юк...

Марва хатны юлда кайтышлый күкрәгенә кысып-кысып куя, мәгәр ачып карарга курка иде. Өйләренә кайтты. Мәлихның дәрес әзерли торган өстәленә утырды. Шунда гына, куркуын җиңәргә үзен мәҗбүр итеп, хатны ачарга булды. Җилем нык ябышкан, болай гына ачыласы түгел икән. Конвертны бозмас өчен кайчы белән кисәргә туры килде. Калтырый-калтырый, конверттан чыгарды хатны. Укып карады. Аңларга тырышты. Бер кабат, ике, өч кабат укыды, ләкин бернәрсә дә аңлашылмады. Аңлашылыр да иде, бәлки, әмма анда язылганнар ышанырлык түгел, ышанырга үзеңне ничек тә мәҗбүр итәрлек түгел иде. Укып-укып күзләре тәмам томаланыр дәрәҗәгә җиткән бер мәлдә Анна керде. Керде дә, ни өчендер:

— Сәгать унбер,— дип, киемнәрен алмаштырырга кереште.

Сәгать унбер? Ә! Җеназа башлана! Ашыга төшеп, Аннага иярергә туры килде.

Бакчада, урам витриналарында газеталар чуарланып кала. Аларга күз төшсә, газета битләреннән таныш сурәт карап озата. Егерме ел ярым яшәгәч, инде онытылган, бөтенләй ераклашкан кебек тоелса да, алай түгел икән. Денис Иванович сурәтләре Марваның күзләренә текәлеп нәрсәдер әйтмәкче шикелле. Бөтенләйгә, мәңгелеккә хушлашыр чак житкәч кенә аңлашылды якынлык. Алар асылда аерылмаганнар бугай лабаса. Әле дә якыннар икән алар. Нәрсә булды, ник икесе ике җирдә яшәделәр? Бергә яшәгәндә дә берләшеп бетә алмадылар. Ник соң?

Сәбәпләре булгандыр һәм алар житди булгандыр сыман тоела хәзер. Ләкин тәгаен генә атап булмый аларны. Ник соң? Тик бүген сәбәпләрне тәгаен әйтергә уңайсыз бугай. Ул хакта уйлау әхлакка хилафлык китерү булыр сыман. Әйе.

Мәрхүмнең гәүдәсе аның хәзерге фатирына куелган иде. Бүтән чакта монда аяк басарга көче житмәгән Марва бүген, һичнинди шартлы нәрсәләргә игътибар итмичә, эчкә узды. Һәм күрде: киң генә залда ул ята... Шундый тыныч, шундый таныш һәм кадерле...

Денис Иванович гомер буе тынгысыз булды. Марва өчен ул бөтен гомерен пар атта, бричкада, атларын бар көченә куган, чаптырган хәлдә күренә иде. Арттан дошманнар ата, аны яклап Марва аягүрә басып берданка чакмасын тарта... Атыш дәвам итә, алар чаба да чаба. Еллар арттa кала. Тирән чокырдан күтәрелгән юлбасарлар нәрсәдер кычкыра-кычкыра атсалар да, еллар буе максатларына ирешә алмыйлар иде. Менә хәзер... Хәзер ирештеләр, менә хәзер Денис гомерен өзделәр... һәм ул ята...

Һәм менә шып тукталды ярсыган атлар. Арбадан төште батыр егет, батыр ир. Менә ул ята — шундый тыныч, шундый ягымлы. Төсенә бераз сарылык иңгән, әлбәттә. Ләкин бер дә ямьсезләнмәгән. Түгәрәк бит, таман зурлыктагы тыйнак борын, җыйнак кына мыек. Газеталарда еш чыга килгән сурәткә — ил җитәкчеләренең берсенә тартым. Гел басылып чыга килгән ул сурәтнең инде газеталарда күптән күренгәне юк. Бүгенге газеталарда — Денис Ивановичның үз сурәте, беренче һәм, мөгаен ки, соңгы тапкырдыр...

Табут янында каравыл тору кай арада тукталып, кай арада матәм минутлары башланганын Марва сизми дә калды. Сөйләүләр башланды. Габишев фамилияле беренче секретарь, тагын фамилиясе истә калмаган берничә кеше чыгыш ясады. Әлбәттә, Денис Иванович мактаулы тормыш юлы узган. Йөрәкләрдә ул мәңге шулай сакланачак. Әйтерсең, кемдер мәңге яшәргә җыена.

Залда яңгырап торган төрле сүзләр, төрле чыгышлар, көр авазлар Марва өчен тоташ бер гүелдәүгә әверелде. Тоташ гүелдәүгә әверелгән авазлар тора-бара бер кеше сүзләре булып, Денис Ивановичның бердәнбер улы, соңгы юлга озатырга әллә килә алмаган, әллә килергә теләмәгән улы, ясалырга тиешле булган, әмма ясалмаган чыгыш булып ишетелә башлады. Барча мәгънәләр һәм мәгънәсезлекләрне томалап, алмаштырып, улның атага әйткән рәхимсез гаепләве булып дөньяга яңгырадылар. Әйтерсең, күктән инә иде ул сүзләр:

**«Хөрмәтле Денис Иванович!**

**Мин сезгә шушы рәвешле мөрәҗәгать итәргә тиеш түгелдер. «Кадерле әтием!» — дип язарга тиешлемендер, бәлки. Ләкин юк, тиеш түгелмен. Чөнки бит сез ата булу хокукына беркайчан да хаклы булмадыгыз. Мине башта айлар, аннары еллар буе күрмичә яши алдыгыз. Анна Ивановнага һәм миңа акча бирә торуыгыз белән ата булу вазифасы үтәлеп бара, дип уйлагансыздыр. Ләкин бит тудыргансыз икән, сез баланы карарга да тиеш. Карарга теләмәсәгез, суд аша алимент түләр идегез. Шулай күпмедер акча бирә килгәнегез өчен генә сезне әти дип атау бәхәсле булыр иде, әлбәттә.**

**Икенчедән, менә улыгыз дип саналган кеше җинаятьче хәлендә калды. Сез аңа ярдәм кулы суздыгызмы соң? Дөрес, башта нинди дер булышлык күрсәттегез шикелле. Беренче судта минем aклануым сезнең аркада булды сыман. Кешеләр шулайрак сиздерделәр. Ә икенче тапкыр? Икенче тапкыр да сез ярдәм итә ала идегез, мине коткара ала идегез бит? Әгәр теләсәгез, тырышсагыз, көчегез җитәчәк иде. Чөнки бит мине коткару бик җиңел, чөнки бит чынлыкта да шулай — минем кул тимәде потерпевшийга. Харап, бер мәртәбә диванга төртеп екканмын икән... Диванга төртеп екканнан кеше үләмени? Абсурд! Бөтен нигезләре шушы гына лабаса мине төрмәгә тыгучыларның. Факт дигәннәре чын булса да, ул исәпкә алынырга ук тиеш түгел иде. Чөнки мин төртеп екканнан Гайсага чебен тешләгән хәтле дә зыян килмәде. Ул Малышев диваналыгыннан һәлак булды. Судта мең мәртәбә кабатлаганча, мин дусны яклый алмаганмын. Бәлки эшнең шушы хәтле күпертеләчәген, үлемгә үк тоташасын белгән булсам, үлем әчесенең үземә үк әйләнеп кайтачагын чамалаган булсам, икенче төрле эш иткән булыр идем. Әмма бокстан үлгән кешене гомеремдә дә ишеткәнем булмаганлыктан, бу юлы да иртәгесен кайбер күгелҗем тимгелләр белән кеше елмаеп йөрер диебрәк уйлаган идем шул.**

**Әйе, ялгышлык зур, ләкин ул җинаять түгел иде бит. Мин яклауга мохтаҗ идем. Ләкин сез үз гомерегездә бер генә тапкыр туры килгән шушы изге бурычыгызны үти алмадыгыз. Намус, вөҗдан кушмый, янәсе.**

**Мин сезне яхшы аңлыйм дип беләм. Сез — Корчагиннар токымыннан. «Вөҗданда бер тап та булырга тиеш түгел, бер тап та!» — дип, ант эчкән кешеләрдән. Идея өчен кеше үз атасын, туган анасын сатарга һәм атарга хаклы. Тарас Бульба кебек, ата үз улына җәза бирсә, шул да була олуг**

батырлык. Башка туганнар хакында, якыннар, дуслар хакында әйтәсе дә түгел. Бигрәк тә — чит-ят кешеләр турында. Сезнең идеягә каршы икән, аны диварга терә. Шулай тиеш санадыгыз, дөрес дип яшәдегез. Шул идеягә тугры калу өчен үз улыгызны якларга тиеш тапмадыгыз, аның каравы, вөҗданыгыз чиста калды. Нинди бөек сафлык! Ләкин нинди үкенеч, фаҗига! Үзегезне кая куярга урын тапмыйсыздыр әле, баштарак мине якларга маташкан идегез ләбаса... Моның өчен үзегезне кичерә алырсызмы икән? Вөҗданда шушы авыр йөкне күтәргән хәлдә ничек яшәмәк кирәк! Әйе, сезнең кебек уйлаучылар, хәзер инде бармак белән генә санарлык булса да, калды бит әле. Сез шул кавемнән — соңгы могикан.

Сезнең ялгышыгыз — тарихи ялгыш. Теориягез утопия булып чыкты.

Сез, бөтен кешелекне вөҗданлы һәм намуслы итәргә мөмкин, дип уйладыгыз. Бөтен кешелекне көчләп оҗмахка кертмәкче идегез. Ә җирдә оҗмах була алмый икән. Кешелек тоташ кыя түгел, җанлы һәм чуар конгломерат. Адәм җиргә килүеннән башлап гөнаһлы. Кемдер барыбер акыллырак, өстенрәк булырга тырыша, камиллеккә омтыла. Кемнеңдер нәфесе зуррак, кемгәдер күбрәк кирәк.

Ничәмә еллар буе халыкны талап, бушка эшләтеп, изеп, матди һәм рухи байлыклар тупладыгыз — якты киләчәк хакына. Байлык шактый мул җыйналды — ил бәлеше кызарып пеште. Шул байлыкларны күбәйтә барган хәлдә, көннәр һәм еллар режимын кырыс саклаган хәлдә, бәлешне гадел генә, бик зурдан кубып булмаса да, тигез генә бүлешә торырга вакыт җиткән иде. Ә ничек килеп чыкты? Кем алданрак өлгерсә, шул йотарга керешге. Кем отты, шул йотты. Мең төрле хәйлә һәм оятсызлык белән түргә үрмәләгән әрсезләр ул бәлешнең өстенә үк менеп атландылар. Бәлешне умыра, кимерә башладылар. Кеше табигатьнең таҗы түгел, хайван булып чыкты. Әмма хайваннан комсызрак, аламарак.

Тирә-ягыгызга күз салыгыз, күпме, бармы хәзер сезнең кебек чиста адәмнәр? Андыйлардан хәзер Кытай коммунистлары дип көләләр. Алар хәзер политик һәм материаль капитал туплыйлар, урлыйлар. Караклыкның төрләре күп: чит илләрдән алынган лауреатлыклар, сатып алынган товарлар белән махинацияләр, валюта үзләштерү, ришвәтләр, исемле һәм исемсез бүләкләр бүлешү, югары посттагыларга дача йортлары төзү — чиге-чамасы юк боларның. Озакламый, җыйган байлыкларны законлаштыру өчен политик көрәш башлаячаклар — властька үрмәләячәкләр. Капитализм законнары урнаштырачаклар. Ил күләмендә җайлы позицияләр яулап калу өчен рәхимсез көрәш бара. Ә сез аларга юл сабасыз, чөнки көчегез җитми, сизми калдыгыз, алар өстенлек алды. Бөркетләр заманы узды, хәзер чебеннәр үрчи. Ил — чебеннәр кулында. Сез — аларның соңгы дошманнары. Сез — ноль!

Булачак хөкемдарлар сезне юлларыннан алып ташлар өчен башта мине төрмәгә тыктылар. Мине сәбәп итеп, үзегезгә тотыначаклар. Хәзер аларның сезгә тешләре үтәчәк. Сез, якламыйча, үзегезне харап иттегез. Бик сыналган ысул, ышанычлы механизм. Искергән фикерләрегез комачау итмәсә, сез моны аңларга тиеш идегез.

Менә хәзер яшәп карагыз инде иске әхлак кагыйдәләре белән. Озакка барырмы тыныч тормышыгыз? Сез шуңа лаек.

Барлык шушы күренешләрдән чыгып, нәтиҗә ясарга рөхсәт итегез: сез беркайчан да ата була алмадыгыз, соңгы вакытта аңа хокукыгызны ук югалттыгыз. Шулай итеп, без — чит кешеләр. Мин сезнең балагыз түгел, сез минем атам түгел. Үзегезгә таныш төстә әйткәндә, мин сездән, атамнан баш тартам.

Юлларыбыз бүтән һичкайчан да очрашмас дип беләм.

Хушыгыз.

Имзам — Михаил Михайлов.

13 август, 1961 ел».

Үз уйларына чумган Марва соңгы сөйләүчеләрнең барлык сүзләрен бер генә итеп ишетә башлады: «Сез — минем атам түгел, мин сездән баш тартам, баш тартам, баш тартам...»

Табут күтәрелеп, кешеләр урамга чыга икән инде. Марва, «көтү тойгысы» кебегрәк күмәк хәрәкәт агымына ияреп, үзенең дә урамга чыгып җиткәнен сизми калган. Табутны хәтта узып кителгән икән. Урам уртасында, халык арасында, табут чыгып килгән капкага карап, ул да тынып калган. Табут капкадан уза һәм... шунда кинәт коточкыч шартлау — көтмәгәндә күк күкрәгәннән дә катырак яңгыраган тавыштан сискәнде Марва. Бу сискәндергән шартлау белән мәсьәләнең хәл ителүен аңлады Марва: атага карата бала чыгарган хөкем карары — приговор! Литавраларның бер-берсенә кинәт шакылдап бәрелүе сыман булып, шул карар ишетелде, һичшиксез шул. Хөкем карарының игълан ителүе кебек, аның җиренә җиткерелүе дә бер шартлауга сыеп, урамны калтыратты.

Үзенә күрә бәлки шунысы гына хәерле очрактыр — кеше үзе бу тавышларны ишетми инде һәм аңа улының беренче һәм соңгы хатын укырга туры килмәде, дип уйлады Марва. Һәм шушы минутта үз йөрәгенең дә күпмедер бер өлеше үлгәнен, мәңге яңармас, терелмәс өчен югалганын тойды.

Зиратта туганнарына, якыннарына хушлашыр өчен вакыт бирелгәч, мәрхүмнең яшь хатыны, хатынның туганнары булса кирәк, тагын ике-өч кеше табутка иелде. Алар артыннан балчык өеменә тауга үрмәләгәндәй һәм шәүләдәй шуышып, Марва килде. Егылмас өчен табут тактасына тотынып, иренең маңгаеннан үпте. Бәлки, кемнәрдер аны танырга теләп, гаҗәпләнебрәк карагандыр. Ләкин кем карашы үзенә төбәлгәнен сизәргә тырышудан ул ерак иде. Аның өчен хәзер кем нәрсә күрсә, нәрсә уйласа да барыбер иде.

Кабер өстендә кечкенә тау күтәрелгәч, һәм Анна килеп култыклагач кына, үзенең дөньяда икәнлеген, әле исән булуын абайлады Марва.

* * *

Әнисе Гөлсара белән, Денис Иванович белән, Анна белән, сөекле баласы белән гаҗәеп матур тормыш башланган иркен һәм нык таш йорт ничек бәхетсез булып чыкты. Нинди ишле гаиләдән бары тик бер кеше калды сураеп — Марва. Бер ялгызы!

Кайсы вакыттан, нәрсәдән башланды икән өйнең бәхетсезлеге? Гаиләсен язмыш иркенә тапшырып ата кешенең өйдән чыгып китүеннән алыпмы? Әллә көннәрдән бер көнне әнисенә Марваның үлгән баласын китереп тоттырган чактанмы? Шуның аркасында йортны ходай каргаганмы? Кайчаннан башлап?!

Таркалу, мөгаен, Марваның әтисеннән үк башлангандыр. Башсыз гаиләнең ничек көн күрүе һәркемгә билгеле бит. Марваның дәү әтисе салып биргән, күпләр өчен бәхет сарае булырлык өйдән чыгып, каядыр китеп олаккан бит ата кеше. Дөньяга, илгә бәхет даулаган булып, чынлыкта халыкны талап йөргән! Шулай булгач, ничек итеп бәрәкәт калсын ди аның йортында!

Ике баласы ачлык елларына хәтле үк тифтән үлгән. Бердәнбер ир бала Ватан сугышыннан кайтмады. Шул ук сугыш вакытында йортны гына түгел, дөньяның үзен әнисе ташлап китте. Өйдә Анна белән Мәлих (ул чактагы Мэлс) кына яшәп калды. Хәзер исә, Анна яландай зур өйдә, ә Марва мәет чыккандай бушап калган дөньяда япа-ялгыз көн күрәләр.

— Йортны сатыйк та, күч минем янга, Казанга,— ди Марва Аннаның хәленә керергә тырышып.

Аннаның үз дәлилләре:

— Миша котылып кайтканчы, йорт ташлау килешмәс. Аның да өе бит әле бу. Исән генә кайтсын, үзе карар шунда,— ди ул.

Анна хаклы. Бәлигъ бала өчен аның әнисе хәл итә алмый. Шуны уйлап, Марва, Аннаны үгетләүдән тыйлыга. Анна исә, киресенчә, Марваның теге елларда ук Казанга күчүен ялгыш булды дип күрсенә.

Марва, үз чиратында, билгеле инде, ялгышлар дими, язмышлар дип уфтанып куя. Дөнья үзе кушты бит, бүтәнчә мөмкин түгел иде.

Тугыз класс белем белән соңга таба мәктәптә эшләү авырайгач, укуны дәвам итәргә, яки бүтән эшкә күчәргә кирәк иде. Нәкъ шул елларда, Денис Иванович Лаешка ГПУ бүлеге башлыгы урынбасары итеп күчерелгәч, Марва анда кече яшьтәге җинаятьчеләр мәктәбендә эшләргә тиеш булды.

Балалар укырга, эшкә өйрәнергә теләмәү генә түгел, ә бәлки мәктәпкә килмәскә үк тырышалар. Килсә, сораусыз китеп баралар. Тәртипкә чакырган буласың, тиргисең, янаган, куркыткан буласың. Куркытырсың син аларны, бар. Куркудан күптән узган алар. Үзең курык.

Марвадан шелтә алган малайлар бер көнне мәктәп капкасы төбендә ниндидер шикле кыяфәттә басып торалар иде. Укытучы апаларын көтәләр, мөгаен. Сизә Марва, укытучы апаларына сабак бирмәкче болар. Курыкканны сиздерергә ярамый, курыкмыйча да булмый. Ләкин өйгә кайтырга кирәк һәм апалары, шикләнгән, сизгән килеш, атлавын белә. Малайларның барын-югын исәпкә алмыйча, батырларча атлый. Якынлаша һәм... Һәм бервакыт — шарт! Мылтык тавышы. Ясалма мылтыктан ата болар. Ни булса шул, малайларның өсләренә ташланды Марва. Апаларының дәһшәтле рәвештә үзләренә таба йөгергәнен күргәч, болар үзләре торып чапмасмы. Менә китте куыш, менә китте чабыш. Малайлар йөгерә, апалары ажгырып килә. Малайларның күбесе койма аркылы икенче якка коела. Кайберләре өлгерә алмый, шул исәптән, мылтыклы малай. Коймага үрмәләмәкче. Ашыкмый торсын. Марва апасы аның чалбар төбеннән үк эләктереп, өстерәп тә төшерде, шар-шор акырта-акырта, мылтыгы-нисе белән, завучка илтеп тә тапшырды.

Мондый куркыныч уеннарны күп уйнарга туры килде. Шулай да Марва, уку елы тәгәлләнүгә, балаларны башка класска күчәрлек итеп әзерли алды. Бары тик ике малай гына имтиханнан качып, пароход белән каядыр киткән иде.

Эшне, әлбәттә, дәвам итәргә мөмкин иде. Ләкин ары табан белем җитмәячәген сизүдән, Марва укырга китүне артыграк күрде. Мондый карарга килүдә Денис Иванович белән мөнәсәбәтләр дә роль уйнады, билгеле.

Башта ук мәхәббәт шаукымыннан акыл җуярлык хәлдә өйләнешмәгәннәр иде бит. Бере-берсенә ышаныч хәл иткән иде. Ләкин ир белән хатын өчен ул гына җитми икән шул. Марва үзе генә сизеп яшәгән хикмәт менә нәрсәдә — ир хатыны буларак, Марва Денисны кызыктырмый башлады шикелле. Кызыксынмауны арганлыкка сылтап күпме яшәргә була? Аны исәпкә алырга мөмкин, әлбәттә. Анысы бар. Әмма да, әмма да, атналар, хәтта айлар буе иргә хатын кирәкми икән, бигрәк тә гомер кояшының әле күк түбәсенә күтәрелеп тә җитмәгән мәлендә, моны инде арганлыкка гына кайтарып калдыру җайсызрак була бара. Кимсеткеч сәбәпләрнең иң беренчесен үзендә күрә Марва. Аның холкы кырыс, әйтергә кирәк, ирләрчә нык. Ир җәнлек исә көчсезрәкне, иркәрәкне, үз ярдәменә мохтаҗракны тели, диләр. Шулаймы? Нәфисне, зифаны, чибәрне сөя, күзләре шундыйларга төшә диләр. Ә Марва? Марва калынрак гәүдәле булып чыкты шул. Бик үк ак та булмаган бите түгәрәкләнде. Борын, бигрәк тә күзләр ерактан ук чакырып торырлык түгел, бит зурлыгына карата бәләкәйрәк сыман. Мыекны искә алмаганда, Денисның гәүдә һәм бит төзелеше үзенеке дә шундыйрак, үзе дә беренче класслы чибәр түгел. Ләкин: «Әгәр ир кеше маймылдан да иләмсез булмаса, аны чибәргә исәпләргә кирәк,» — диләр бит. Ир кеше үзе маймыл дәрәҗәсендә булса да, гүзәлләрне эзли ул. Денис ничектер, мәгәр шунысы хак — һәрхәлдә, Марва өчен бәхәссез — Денисның соңгы еллар-

да күзләре читкә карый, чибәрләргә төшә башлады. Бәлки Марва туйдыргандыр, бәлки бераз аерылып торыргадыр. Сагына төшкәч, бәлки хәл үзгәрер. Шулай түгелме?

Бу сәбәп кенә җитмәсә, тагын да җитдирәге бар — халыкка югары белемле укытучылар кирәк. Лаеш район советы рәисе Исхаков дигән кеше аңа Казан педагогия институтына китәргә киңәш итте. Лаеш колхозы стипендия бирәчәк. Шулай булгач, тагын ни уйларга? Әйе, тотты да китте Марва Казанга. Керү имтиханнарын тапшырып кайткач, яңалыкны иренә курка-курка гына хәбәр итсә, я хода, ир һич каршылыксыз риза лабаса! Бөтен нәрсәне кадрлар хәл итә — ил укырга, укырга, укырга куша. Киләчәктә матур тормыш кору безнең уйларыбызда! Яңа тормыш төзү хакына, яшь буынның якты киләчәге хакына, бөек идеяләрнең чынга ашуы хакына намуслы ир, халыкның үз улы Денис Михайлов шәхси мәнфәгатьләреннән баш тартып торырга, вакытлыча хатынсыз яшәргә риза. Һәм, шул рәвешле, мәсьәлә җиңел хәл ителә. Кирәк көне килгәч, Марва институт ишеген, булачак бәхетләр ишеген бернинди икеләнүсез ачып керде.

Аны Кекин йорты дигән өйне биләгән тулай торакның унҗиде кешелек бүлмәсендә староста итеп сайладылар.

Көн саен иртән иртүк торып, Болак дигән елга буена чабасы. Ял көннәрендә — төрле өмәләр. Бакалда дигән җиргә, синтетик каучук заводы төзелешенә яисә пристаньгә, институтның ярдәмче хуҗалыгына — Казансу буена. Иртән иртүк унҗиде кешелек бүлмәне Марва тавышы уята: «Подъем!» һәм кызлар шыбыр-шыбыр караватлардан идәнгә коела, юынырга ашыга, аннан-моннан капкалагач, урамга чыга. Урамда Марваның икенче командасы яңгырый:

— По четыре становись! Тиз, тизрәк! Вперед шагом марш! Җыр башла!

Җырлый-җырлый атласалар да студентларны алда күңел ачу уеннары көтми, хәлдән тайганчы эш, физик хезмәт көтә. Кызларның зарланырга, шыңшырга хокукы юк. Марвага бигрәк тә бирелмәгән ул хокук. Ул — көрәшче, авызы тулы кан булса да, төкерергә ярамый аңа. Ул — староста, ул — җитәкче. Бүрәнәнең иң авыр башы — аның үзенә.

Бер көнне синтетик каучук заводы төзелешендә кирпеч ташыдылар. Җигүле ат дилбегәсен Марва үз кулына алды. Кызлар арбага кирпеч төйи. Арба килгән цех янына китә тора. Ләкин кеше түгел, ат түгел, хәтта арба үзе дә арый, күрәсең. Бер мәлне, арба ярты юлда таралды төште. Кызларны тагын рәткә тезеп, кирпечне кулдан-кулга биреп, ягъни конвейер дигән ысул белән цехка китереп җиткерделәр. Ялан куллар белән. Бияләй дигән нәрсәнең исеме дә юк иде ул чакта. Өйгә кайтыр вакыт җиткәч, исләренә килсәләр, һәммәсенең тиреләре суелып чыккан — кыпкызыл кан! Юарга солярка бирделәр. Юынгач исә мәйдан бетереп сикергәләргә кереште кызлар. Менә башланды бию, сикерү, ыргу — менә сиңа кордебалет! Мондый да чын, табигый бию, мондый да ачыргаланып кычкыру, чыелдауның бер генә сәхнәдә дә булганы һәм булачагы юктыр. Ходай күрсәтмәсен! Нинди, нинди агония!

Марва шушы агонияне туктатырлык тавыш белән кычкырырга тиеш. Һәм ул кычкырды да:

— Становись! Тиз, тиз, тизрәк! Алга, шагом марш! Җыр башла!

Атлап китәләр кызлар, җырлагандай итәләр, тик тавышлары җырдан бигрәк елауга тарта шул. Ә кичен икенче төрле бәйрәм оештырылырга тиеш. Күңел ачсын яшьләр, ял итсеннәр. Аларны бит тагын удар эшләр көтә.

Яз җитүгә Казансу буендагы ярдәмче хуҗалыкта яшелчә һәм бәрәңге җирләренә су сибәләр. Суны көянтә-чиләкләр белән елгадан ташыйсың. Һәркемгә кимендә егермешәр көянтә. Норма. Үтәми калу мөмкин түгел. Җилкәләр, кулбашлар суелса да, бөгелмә, сыгылма, сынатма, чөнки син — көрәшче.

Пристаньгә төшәргә туры килсә, тагын да яманрак. Тулай торакка кайткач, исәпләсәң, байтак кеше саны җитми. Арып калган, ятып калган, больницага озатылганнар. Әмма зарланма, сукранма, болар барысы да бөек җиңүләр хакына...

Шундый көннәрнең берсендә Марва аякларын көчкә өстерәп кайтып килә иде. Ишеккә таба алпан-тилпән атлаганда, кемдер аның җиңеннән тартты. Караса, Денис. Сөенеч, зур сөенеч бит инде. Ләкин шатланырга хәл юк. Хәтта елмая алмый интекте Марва. Денис аңлый, хатынының җилкәсеннән каккалый, тынычландыра.

— Ярый, ярый, түзик. Аның каравы, укып чыккач җиңәләер. Син бит молодец,— дип җитәкли ир сөекле хатынын.— Анда күрерсең, бүлмәдә, караватың янында капчык булыр — күчтәнәчләр.

Сөекле кеше сүзләрен аңлап ук бетермәсә дә рәхмәт әйтергә кирәген чамалап, хатын иргә рәхмәт әйтә. Һәм шуның белән бәхетле очрашу азагына якынлаша.

— Мин тагын килермен, озакламам, яме.

— Йә, Денис, көтәрмен.

Чама белән бер айдан соң аларны тагын шушындыйрак кавышу көтә. Кыш үтә, яз һәм... җәй!

Ләкин тукта, ашыкма җәйгә, нәрсәнедер онытмакчы, яшереп калдырмакчы бугай бит. Үзеңнән дә яшерәсе килгән, чынлыгына үзең дә ышанып бетәсе килмәгән кайбер очрашулар тагын булды түгелме соң? Булды шул, гөнаһ шомлыгы, булды.

Аякларга гер асылган дәрәҗәдә кайтып килгән көннәрнең берсендә ишек төбендә иптәш Исхаков — Марваны укырга җибәргән һәм колхоздан стипендия билгеләткән кеше, райсовет рәисе басып тора иде. Марва аның янына барып исәнләшкән мәлдә, кызлар, шактый мәгънәле хихылдашып, кызык итеп карап уздылар. Әле берничә минут элек кенә кыл кыймылдатырлык хәлләре булмыйча, ымлыклар белән генә диярлек сөйләшкән көннәре иде. Чак кына кырын эш сыман тоелган нәрсә күрүгә, арганлыклары онытылды. Марва янына сөяркәсе килгән, дип уйладылар, мөгаен. Әмма кызлар ялгыша иде, Исхаков, һичшиксез, эш хакында сорашачак, стипендиянең әрәм китмәвенә ышаныр өчен килгән булырга тиеш ул. Әнә, исәнлек-саулык сорашкач та мәсьәләне шулай куйды да бит. Ягъни, ашыкмыйча гына сөйләшәсе мәсьәлә бар икән — кайчан һәм кайда мөмкин булыр?

— Әйдәгез, алайса, бүлмәгә,— дип, җиңел хәл итмәкче Марва.

— Кызлар анда...

— Унҗиде данә генә.

Бу сүзне ишеткәч, Исхаков:

— Җыелышка куя торган мәсьәлә түгел иде шул,— дип көлде.

Иртәгә очрашырга, дигән фикергә килделәр. Иртәнге сәгать сигездә, нәкъ шушы урында. Нәкъ шул вакытта кызлар белән бергә чыкты да Марва: «Атлый торыгыз, куып җитәрмен»,— дигән булып, үзе тиешле урында басып калды. Иптәш Исхаков та көттермичә генә килеп җитте. Чырае кичәге кебек үк житди түгел, күзләрендә кызлар сизенгән шикле очкыннар ялтырап куядыр кебек иде. Шулай да Марва кунагын өйгә чакырмыйча булдыра алмады.

Бүлмәгә кергәч, кунак баягыдан да яктыра төшеп:

— Нинди чисталык, матурлык!— дип елмайды.— Нәкъ инде мәхәббәтнең үзе тесле.

Шулай булгач, чишенергә рөхсәт сорап, башта ни өчендер Марваның төймәләрен ычкындырышты һәм ике пальтоны да чөйгә үзе элде. Ишек төбендә басып калдылар. Марва нәрсә уйларга, ни әйтергә белми, Исхаков белә, ләкин әйтми, тыйлыгып тора. Ләкин сөйләшүнең кирәге юк бугай, тартынып, оялып тору үзе нәрсәдер аңлатса кирәк. Һәм шулай булды да ул. Ишек төбендәге кысанлыкта Исхаков Марваны башта бераз кочаклагандай итеп торды да, тагын берничә секундка сузылган гажиз-

лектән соң, көтмәгәндә, күтәреп үк алды. Күләргә дә, еларга да белмәссең. Кычкырсаң, коридордамы, күрше бүлмәдәме кеше булып, ишетүләре бар. Марва, әйтерсең, тулысынча Исхаков ирегендә. Исхаковка нәкъ шушы кирәк тә. Ул Марваны күтәргән килеш бүлмәнең нәкъ уртасына килде дә, аны караватларның берсенә яткырмакчы. Марва шунда гына сүз әйтә алды:

— Минем караватым түгел.

— Кайда синеке?

— Әнә, иң почмакта.

Исхаков аны күтәрергә яңадан иелгәч, бу юлы Марва, каршылык күрсәтмәү түгел, Исхаковның җилкәсеннән ике куллап үзе кочаклап алды. Тиз арада Исхаков, законлы сөяркә хокукында, үзенә тиешле гамәлне башкарырга керешкән дә иде инде.

Күкрәгендә аның кулларын тойгач ук, бөтен тәне ут шикелле дөрләгән Марва, калтырап үзен каядыр бушлыкка очкандай тойды. Бетте Марва, юкка чыкты, исән калган бөтен нәрсә — ул татлы катылык иде — куллар катылыгы, куллар ныклыгы. Менә ул куллар Марваның муенында, күкрәкләрендә, аркасында һәм аннан түбәндәге өлешләрдә. Нинди каты, нинди йомшак, нинди назлы куллар! Мондыйны Марва беренче мәртәбә тоя. Нинди бәхет, нинди рәхәтлек!

Шушы ук куллар Марваның өстендә калган эчке күлмәген салдырып ата. Һәм ир кеше үзенең ашкынуын, сөекле кешесенең бәхетен озаккарак сузу өчендер, Марваның тәненнән аерылып, караватка утыра. Утырган килеш, яңадан Марваның бөтен гәүдәсен сыпырып, түбән төшә... Куллар белән генә түгел, күзләре белән дә иркәли, назлый. Һәм аның бу хәрәкәтләре хәтта сүзләргә дә әйләнә алды.

— Кара син, кара, нинди гүзәл икәнсең син. Бу тән, бу гәүдә, гел мәхәббәт белән гомер итәр өчен генә, бер-бер артлы балалар тудыру өчен генә яратылган икән ләбаса. Ә бу төшең... нинди гүзәл, нәкъ гөләп чәчәге!

Шул сүзләр белән Ир кеше тагын Марваның күкрәгенә капланды...

Бу хәлләр чынлап булдымы соң, әллә юкмы? Көннәр буе Марва шуны ачыкларга тырышкандай уйланып йөрде. Башында сәер уй: адәм тәлендә ят җир дип йөртелгән нәрсә дә гүзәл була ала микәнни? Шулай диде бит Исхаков — матур диде, гүзәл диде, гөләп чәчәге диде.

Гаҗәптер, Марваның да Исхаковка шундый күзләр белән карыйсы килә икән. Ә ул, артык мавыгудан, ир кешенең ялангач тәненә бөтенләй дә карый алмаган икән.

Шундый сәер хис белән Марва яңадан Исхаковны көтә башлады. Сәерме? Сәернең дә нинди! Ул үзенең законлы ирен түгел, законсыз сөяркәсен көтә ләбаса! Исәпләсәң, исең китәрлек.

Ни булса шул, икенче очрашу...

Икенче очрашуны Марва барча теләкләре әзер хәлдә көтеп алды. Һәм ирешә теләгенә.

Бүлмәгә кергәч тә, һич тартынмыйча, ишекне бикләде. Өске киемнәрен салгач та, караватына ашыкты. Шунда килде дә анабыз Һава дәрәҗәсендә ялангач калды. Аннары хәтта сөяркәгә чишенергә ярдәм итте әле. Һәм аягүрә басып, сөяркәсенә текәлеп карады. Менә ул, ир кеше, бер кулы белән карават башына таянган да, басып тора. Ул инде бөтен нәрсәгә әзер. Көчле, гүзәл гәүдә. Денистан ярты башка калку, гәүдәсе генә бераз юкарактыр. Мыексыз, чип-чиста бит. Саргылт чәчләр. Әгәр йөккә узарга туры килсә, баланың кемнән икәнлеге аермачык күренеп торачак. Мәгәр Марва да риза — булсын, теләсә ни булсын. Бу бәхет хакына яшәүнең үзен дә корбан итәргә әзер ул. Риза. Әнә бит нинди зифа гәүдә... Ә түбәндәрәк!.. Марва тагын нәкъ теге көндәгечә, әйтерсең, һуштан яза. Хисләр татлылыгы аркасында, тезләре бөгелеп төшә. Һәм кинәт ике куллап ирнең биленнән кочаклап, караватка утыра. Секунд эчендә йомшак урынга ава...

Булдымы бу хәлләр, юкмы? Марва аларга үзе ул чакта ук ышанып бетә алмаса, билгеле вакыттан соң боларның бары тик кызык төш икәнлегенә үзен ышандыра алды. Исхаков тагын, тагын очрашырга тырышса да, Марва, бу хәлләрдән исән чыгуына шөкер итеп, өченче очрашудан баш тартты.

Денис килгәләп тора бит, күчтәнәчләр китергәли. Марваның арганлыгын, талчыкканлыгын искә алып, аны кызгана, интим дигән очрашуларга дәгъва кылмыйча гына, кайтып китә. Хатынының ни дәрәҗәдә талчыкканлыгын башына китерә алмый ул, бичара.

Ярый, ак тәүбә, кара тәүбә. Инде яз җитә һәм җәй!

Каникул вакытларында студентларны ялга өйләренә җибәрәләр. Ике айдан артык ир белән хатын тагын бергә. Һәм шул рәвешле, үзенә күрә бер төсле чират белән уза вакыт. Дүрт ел. Дүрт ел Денис хатынсыз, сукранмый гына гомер кичерә. Яңа тормыш төзүдә — бөек тарихи вакыйгаларда катнашкан хатын аңа аерым яшәгәндә дә ошый. Киләчәк хакына андый гына корбаннар биргәнмени ул!

Дүрт елдан соң үз үтенече белән Марваны Алабугага билгеләделәр. Әнием ялгыз дигәч, каршы килмәделәр. Гаилә хәле буенча аның янына Дениска да кайту мөмкинлеге туды. Менә шуннан соң булды да инде гомерләренең иң матур, онытылмаслык еллары. Нәкъ шушы йортта. Нәкъ шушы йортка больницадан алма кебек ир бала алып кайттылар. Нәкъ шушы йортта Мэлс дигән бала — көнеллэрдәге бөек уйлар, теләкләр символы булган тере куаныч — идәндә бөтерчек кебек бөтерелеп-бөтерелеп, ауный-ауный үсте. Энгельс шикелле бәхетсез булмады. Аннушка — бик яшь чакларында үзләре эшләгән Катюма авылыннан килгән таныш кыз — аны карарга шатланып риза булды. Ир белән хатын үзләренең бөтен сәләтләрен, барлык көчләрен җәмгыять файдасына багышларга мөмкинлек алдылар һәм шәхси мәнфәгатьләр белән иҗтимагый мәнфәгатьләр гармониясенә ирештеләр, фәлсәфәләрнең чын тормышчан булуын расладылар.

Бәхетле, тигез тормыш ике-өч ел дәвам итте. Ләкин шуннан соң... Шуннан соң, уф, көнеллэге иске шикләр янармаса ни булган да бит. Нишлисең, нишли аласың, йөрәккә гел боерык биреп кенә яшәп булмый шул. Боерыкларга ул буйсынмаска да тырыша, авызлыкны тешләп, үзе теләгән якка дулап чаба кайчакларда. Нәкъ шулай булды, янарды, берничә ел элек йөдәткән иске хис terелде. Ул тагын, ә бу юлы инде чын-чынлап, Дениска үзенең хатын буларак кирәк түгеллеген сизә башлады. Ир ризалыгы белән аспирантурага, белемне тагын да арттыра төшәргә дип, тагын Казанга китте дә, үзе исә туп-туры шәһәр мәгариф бүлегенә юл тотты. Рус теле укытучылары Казанда да артык түгел икән, һич авырлыксыз кабул иттеләр. Институт еллары белән чагыштырганда да сәеррәк тормыш башланды — ир белән хатын үз теләкләре белән тагын аерым яшәргә риза булдылар — аерылмадылар да һәм аннары инде бүтән кушылмадылар да.

Хикмәттер, законлы аерылышу таләп итмәде Денис. Ике елдан соң, ниндидер яшь хатын белән тора башлагач кына, төп йорттан китте. Марваның әнисе Гөлсара, Анна һәм Мэлс өчәү калдылар.

Әллә хәзер дә Казанда яшәгәнгә, Марва студент елларын ул хәтле өзелеп сагынмый. Ә менә мәктәптә (элеккечә әйткәндә, гимназиядә) укыган чаклары искә төшсә, йөрәге сулык-сулык итеп куя. Менә ичмасам бәхетле еллар!

Тугыз классны бетергәч, дәү әтисе ул чакта бик тә сирәк нәрсә — кул сәгате бүләк иткәч, түбәсе күккә тигән иде Марваның. Ничек ерак карый белгән бит аның дәү әтисе: «Син хәзер зур үстең, үзең кечкенәләрне укытырсың. Сәгать бик кирәк булыр. Укучыларыңның да, үз вакытыңның да кадерен белеп яшә», — дигән иде. Ләкин иң матур, чынлап кадерен белерлек вакытлар инде шул чакта ук артта калган иде...

Мәктәп елларында язылган дәфтәрләре шактый күп җыйналган. Китаплар да хәтсез калган иде. Ул китап-дәфтәрләр куелган киштә хәзер юк инде. Ә үзләре кайда икән?

Аннадан сорап белде: өй түбәсендә, ягъни чормада. Марва үсмер чактагыча җитезлек белән шунда менеп китте. Һәм чынлап та исәннәр — җеп белән бәйләнгән бер өем кәгазьләр!

Марва аларны үтә дә саклык белән актарырга керешге. Югарырак класслардан башлады — һәр дәфтәрне, һәр китапны актарганда, бәхетле елларның искиткеч матур хатирәләре яңара торды. Шулай ул, дөньясын онытып, ничә сәгать — әйе, минутлар түгел, сәгатьләр! — утыргандыр, анысы исәпкә сыярлык түгел иде. Саннар көчен җуйды. Ни дисәң дә, гомер эчендә табигатьтән бик тә азга, бик тә кыска вакытка бирелә торган татлы мизгелләр — үз вакытында кадерле беленмәгән мизгелләр — еракта, зәңгәр томаннар артында калгач кына аңлашыла икән ләбаса. Алар менә шушында, шушы дәфтәрләрдә генә җыйналып, сакланып калганнар икән. Йөрәкне сулык-сулык сызлатса да, ничектер, назлый да бу хатирәләр. Аһ! Аларны һич югы хәзер озайтасы, шушы көннәргә тоташтырасы иде. Һич югы калган гомерне — гомернең соңгы урамын — шундый хисләр белән узасы иде. Булса икән, шулай мөмкин булса икән., Калган гомер шушы хатирәләр өстендә чайкалып узса икән. Шушы хатирәләр ирегендә көймә шикелле тыныч кына аксаң икән. Аксаң да аксаң икән лә! Ага-ага шулай мәңгелеккә китсәң дә, мөгаен, үкенечле булмас иде. Ләкин...

Ләкин хәзер үк көймә нindидер каты бер истәлеккә дөп итеп төртелде дә инде. Уф! Күз алдында — сабый куллар төшергән беренче хәрефләр! Электр суккан сыман, йөрәкне кинәт авырттырып, тетрәтеп җибәргән нәрсә шул хәрефләр икән.

Мәктәпкә беренче мәртәбә барган ел. Беренче сызыклар, хәрефләр, иҗекләр, җөмләләр. Аннары икенче елгы беренче дәфтәр. Анысының тышлыгына — латин хәрефләре белән — укучы үз кулы белән язган хәбәр: «Икенче класс укучысы Мәрүә Артым кызы Гәрәева...»

Хәзер бу сүзләргә ышанасы килерлек түгел хәтта.

Ирексездән күзләргә яшь килә. Әллә тузан кереп, әллә югалган матурлыклар үкенеченнән әчетә күзләр. Әйе, ышансаң-ышанмасаң, булган бит менә шундый зур-зур хәрефләр белән тырышып-тырышып язган чаклар, кояшлы көннәрнең үзләреннән дә яктырак тойгылар, теләкләр. Булган лабаса! Инде бөтенләй булмагандыр сыман тоела башлаган иде югыйсә. Кул түгел, уй да барып җитә алмаслык ераклыкта калганнар сыман иде. Бөтенләй юкка чыккан төсләләр иде.

Бүгенгә Марва — Марва Артемовна Михайлова — дәфтәр тышлыгына үзенең кем икәнлеген үз куллары белән язып куйган сабый дәфтәрен аерып алып, башкаларын таралмаслык бәйләде дә аска төште. Ишектән чыккач, дәфтәрнең тузанын янә бер какты. Аннары, тузаннан тәмам арынган дәфтәрне күкрәгенә кыскан хәлдә, верандага керде. Дәфтәрне күкрәгенә кыскан хәлдә, диван артына баш куеп, истәлекләр дөньясына бирелде.

Диванда оеп, йокымсырап та кителмәде микән әле. Ләкин юк, бу аның сагышлы моңнар агышында, еллар агышында тирбәлүе иде. Үзе рәхәт, үзе елыйсыны китерә торган, җиргә бала чактагыдай ятып аунbackа-ауный елыйсыны китергән моңнарда чайкалуы иде. Шул агымга бирелеп, ул каядыр, күпмедер акканнан соң, сөекле дәү әтисе янына барып чыга. Сөекле дәү әти, ике кулын сузып, аңа бүләк бирә. Сүзләре бүгенге Марвага да аермачык булып ишетелеп тора: «Мә, кызым, истәлегем итеп сакла. Озын гомерең сәгатьләрен бер дә ялгышмыйча санасын, бер дә ватылмасын. Дистә-дистә елларың сине безнең белән бәйләп, тоташтырып торсын. Нәсел-нәсәп җепләре өзелмәсен. Безнең сәламнәрне, яңа дәверләргә, яңа балаларыбызга илтеп тапшыр. Аларга да ходай сәгать саннарына сыймаслык озын-озын гомерләр бирсен».

Дәү этисе сәгатьне иянһәренә-иянсәрләренә бүләк итәрсең дигән иде. Ә чынлыкта ничегрәк килеп чыкты соң? Үтер, хәтерләми Марва.

Икеме-өчме ел сәгать аның кулыннан төшмәде. Монысы истә нык саклана. Аннары? Аннары, кияүгә чыкканда, ул әле бар иде. Кайсыдыр шкафта ятты шикелле. Аннары бетте — чынбарлыкта түгел, хәтердә дә сакланмаган булып чыкты. Шунысы хак, сәгать югалган, юкка чыккан. Һәм аның белән бергә Мәрүә атлы чибәр кыз да югалган.

Мәгәр тагын шунысы бар, әгәр дә сәгать югалмаган булса? Аны кемгә бүләк итәргә мөмкин булыр иде икән? Әнисе Гөлсарага мәет хәлендә илтеп тапшырылган Энгельс исемле беренче балагамы? Әллә бүгенге көндә төрмәдә ябылып яткан Мэлска — Мәлихкамы? Әгәр аңа бүләк итсәң, нишләп миңа ватык сәгать бүләк итәсең, мондый ямьсез нәмәрсә белән әллә мине мыскыл итмәкче буласың, дип рәнҗемәс һәм бүләк сузылган кулны читкә тибәрмәс дисеңме?.. Уф!

Тукта, йөрәкне ярырлык итеп, тагын нидер шартлады — күк күкрәгән тавыштан көчлерәк яңгырады, Денис гәүдәсен урамга алып чыккач булган шартлау. Шул, тагын шул кабатланды. Хөкем карары, үлемгә хөкем! Бу юлы Мәрүә дигән кызчык вафат. Хөкем карары аңа. Һәм карарның җиренә җиткерелүе. Бер тавышта, бер үк шартлауда. Литваралар, бер-берсенә бәрелеп, колак саңгыраулаткыч тавыш чыгарган сыман, язмыш хөкеменең җиренә җиткерелүе Марваның җанында шартлады, мөгаен. Һәм — бөтен гомергә нокта! Хуш, Мәрүә, хуш, Артым кызы, хуш, Гәрәева!

Ә Михайлова Марва Артемовна исән. «Аh!» — дип кычкырып җибәргәч, үз тавышыннан үзе сискәнеп торгач ук, шул ачыкланды. Өйдә нәрсәдер эшләп йөргән Аннаның йөгереп керүе дә аның нindидер мәгънәдә тере икәнлеген күрсәткәндер.

— Ни булды, Марва, син нәрсә?

Гаепле кеше сыман, шулай күзләреңне яшер, Марва. Син бит, Анна каршында булмаса да, кем каршындадыр барыбер гаепле бугай. Сәгать югалткан өчен дәү этиеңнән гафу сорарга тиешсеңдер. Күптән үлгән кешедән ничек гафу үтенергә дисеңме? Ә син тап җаен. Шунсыз җирдә тынгылык таба алмассыңдыр.

— Ни булды, дим, Марва!

— Юк ла, болай гына. Тычкан дип торам, күземә әллә нәрсә күренеп киткәндәй булды.

— И-и, мин тагы йөрәген-фәлән тоттымы дип торам. Котны алдың.

Анна үз йомышы белән тагын чыгып киткәч, Марва өйгә керде. Шуны аңлады Марва: хак иде, җирдә ул Мәрүә булып яшәргә тиеш иде. Үзе булып яшәргә. Ләкин менә ап-ачык күренә ки, ул сәгать югалтканчы гына үзе булып алган да, аннан соң исеме белән бергә җисемен дә югалткан. Хәзергечә әйткәндә, шәхесен җуйган. Икенче кеше булып яши башлаган. Үзе булып яши белмәгәч, бүтән кеше булып, Марва булып чын яшәү белән яши алды микән соң ул? Моның чынлыгы ничегрәк?

Теләсә генә нәрсә әйтсәң дә, Денис аннан көчлерәк булган икән. Денис үзенә беркайчан да хыянәт итмәгән булып чыга. Денис булып яшәде, Денис булып дөнья куйды ул. Үзе булып яшәргә мөмкинлеге калмагач, иманына хыянәт итмичә, үз теләге белән дөньядан киткән. Аның үлемендә дә мәгънә бар булып чыга.

Ә Марва?

## Алтынчы бүлек

Кабат-кабат үгетләүләргә карамастан, Анна үз сүзендә торды.

— Миша кайтсын әле. Әйбәт кенә яши башласак, балаларын карармын. Өй тулы бала-чага белән тагын бер тапкыр шаулашып яшәргә хыялланам әле, — дип тәкрарлавын белде.

Марвага Казандагы ялгызак тормышына кайтудан башка чара калмады.

Өйгә кайтып кергәч тә, ни өчендер, йөрәге дөпелдәп куйды. Юл сумкасыннан вак-төяк кучтәнәчләрне каударлана-каударлана бушатырга кереште. Әйтерсең, ашыгыч эше, барасы җире бар. Кухняга кереп, суыткычны шак-шок итеп ачып-япты, әйтерсең, кемгәдер ачуы купкан. Әйтерсең, ачуын басар өчен генә, әйтерсең, каушый-каушый, чертләтеп шырпы кабызды. Кискенлекне сөймәгән күкерт очкыны кулга төшеп, үртәлүне янә арттыра төште. Кабынган газ өстенә мөлдерәмә тулы чәйнек кайнарга куелды. Хәзер нәрсә кала? Ә, бар икән шөгыль. Юынырга тиеш Марва. Шулай. Юынгач, зал ягына чыгып, китап шкафлары өстеннән шкатулка үрелеп алды да, азмы-күпме җыйналган бизәнү әйберләрен барларга кереште. Киемнәрне киеп тә, бизәнмәләрне тагып та караган булды. Сылу чакта солы капчыгы килешсә, хәзер исә алтын-көмеш тә матурламый төсле күренде. Киресенчә, көлкеле кыяфәт кенә бирә бугай. Бу юк-барны әрҗәсенә кире салып, бүтән кузгалтмаска кирәктер. Аңа монда бүтән нәрсә кирәк бит әле. Нәрсә соң? Нәрсәдер эзләп, Марва шкатулка эчен шалтыратты. Кулына иске сәгать эләккәч кенә нәрсә эзләгәне хәтеренә килде. Менә шушы бит — сәгать, «Слава» дигән сәгать. Бабасы биргән сәгать югалганны белгәч, монысының нindирәк хәлдә икәнен беләсе килгән иде. Монысы исән икән. Бәлки әле йөридер дә. Юк, борып-борып карагач та уклар селкенергә теләмәде. Димәк, төзәтергә кирәк. Монысы бик җиңел, әлбәттә. Бер квартал узгач та — остаханә. Хәзер үк барсаң да борып чыгармаячаклар. Әйе, ник сузарга? Хәзер үк барып кайтырга кирәк.

Марва, хәзергә сәгатен әрҗәгә салгач, кулына иске «Слава»сын тагып, ишек төбенә килгән иде, башы әйләнеп киткәндәй булды. Борында — нindидер татлы ис. Ә! Газ! Газ яна лабаса! Юк, янмый, ул сүнгән ләбаса. Кухня эче зәп-зәңгәр. Су кайнап утны сүндергән дә, чыжлап газ чыгып тора. «Уш бетте, бөтенләй акылдан язам, ахрысы»,— дип уйлап өлгерде Марва. Җитмәсә, форточка да ачылмаган. Әгәр йокларга дип яткан булса? Үкенер иде микән Марва? Үкенерлегең калыр идеме? Һәй лә, барыбер түгелмени хәзер?

Газны ябып чәйнекне күчергәч, юлдан соң чәй дә эчмәгәнлеге исенә төште. Иллә, ярый инде, бер җыенгач, йөреп кайту хаерлерәк булмагае. Шул ният белән ул сәгать төзәтү остаханәсенә китте.

Йөрәге кисәк-кисәк әле дә кагып куя. Моның сәбәбен беләсе килә. Сәбәп бер генәдер — ялгызлык. Дөрес, ничәмә ел бит инде, Марва өйдә берүзе генә яши. Ләкин моңарчы ялгызлыкның никадәр ачы була алуын белеп җиткермәгән, моны ул ныклап әле генә сизә башлады бугай. Чөнки кайдадыр якыннары — улы, ире барлыгын тоеп яши иде. Шул — кемнәрнеңдер булуы аңа күпмедер көч биргән икән. Ә хәзер? Хәзер әнә түптүгәрәк кенә ялгызлык килде.

Укучылар төрлесе төрле җирдә — каникулда. Марва Артемовнаның барын-югын уйламыйча ял итәләр. Апалары исә зур шаулы калада, дөбердәп колакларны саңгыраулаткан таш урам буйлап каядыр бара. Алны-артны карарга да вакыты юк аның. Урамның икенче ягында гына — остаханә. Ул шунда ашыга.

Урам чаты. Чыгып кал тизрәк! Машиналар шатырдый-дөберди бит. Ашык. Менә шулай, чыгып та җиттең бугай. Ләкин... Ләкин чыгып җиттем дигәндә, кинәт кенә, көн яктысы юкка чыкты.

...Яктылык яңадан барлыкка килгәндә, күзләре күрә башласа да, үзенең кайда икәнлеген аңламыйча, шактый озак баш ватарга туры килде аңа. Башка караваттагы кешеләр бу җирнең шифаханә булуын әйтсәләр дә, үзенең монда ничек эләккәнен шәфкать туташы килеп аңлаткач кына белә алды. Аны автомобиль бәреп еккан, аягы сынган һәм баш мие бераз селкенгән икән.

Больницадан ул бер айдан соң гына чыкты. Әгәр чак кына аксаклап йөрүен искә алмасаң, аяк төзәлде диярлек. Болай да таякка таяныр

вакытлар җитеп килгәндә, тәкъдир бераз ашыктыруга карамастан, моны-сы өчен бик аһ ормаска да мөмкиндер кебек. Ләкин яманрак нәрсәләр бар иде шул. Борчылырлык хәлләр бүтән иде.

Төннәрдән бер төнне кинәт нәрсәдер шакылдаудан уянып китсә, йә Хода, Марва — аяк өстендә. Өй бетереп йөргән икән. Шул фикер башка төшкәндәй айнытып җибәрде дә, хәлнең бүтәнчә булуына аз гына калган өмет белән, ут кабызды. Юк шул, ышанырга туры килә яман фикергә. Күр әнә, зал уртасында чәчелеп, кап-кара кыйпылчыклар ята. Язулы кыйпылчык ватылган нәрсәнең кайчандыр пластинка дип аталуын исбат итә. Идәндә чәчелеп яткан кара валчыклар — «Комсомолка Гөлсара» дигән җыр кисәкләре булып чыга... Хәзер син аларны җыеп кара. Төнге йокысын дәвам иткән килеш, аягүрә йөргән икән Марва — нәкъ бала чактагыча. Иске чир яңарган, кире кайткан булып чыга... Әллә Мәрүә терелдеме? Мөмкин микән шундый нәтиҗә ясарга?

Кыйпылчыкларны җыярга курыккан Марва тиз генә кире урынына барып ятты. Кояш яктысы белән уянды. Бүтәнчә торып йөрмәгән иде. Шулай гына булсачы, шулай гына була күрсәче — бер генә мәртәбә булган хәл кабатлана күрмәсен!

Күз яшьләрсез елаган Марва үзенә шундый теләкләр теләде. Шул теләкләрен шыңшый-шыңшый, пластинка ватыкларын җыйды, җыймый-ча кала алмады. Һәм шул валчыклар белән бергә, күнелендәге шомлы уйларын чиләккә коеп төшерергә тырышты. Сизүенчә, караңгы уйлары белән бергә, яшьлекнең, үсмер чакның, сабыйлык елларының ерактан аваз салган иң матур парчаларын да чүп әрҗәләренә чыгарып түгәргә мәҗбүр булды. Иң бәхетле мизгелләргә бәрабәр музыканы, өйгә кайт-кач, бер генә тапкыр да уйната алмады ичмаса!

Их, язмыш диген, язмыш. Нишләп шушы хәтле рәнҗетте соң әле ул Марваны? Кем каргады? Кем? Үз гомерендә бер генә кешене дә рәнҗет-мәде шикелле ләбаса. Кемне соң?

Әтисен ул рәнҗетә алмый, әтисеннән ул бер яшьлек вакытында аерылган. Әнисен дә рәнҗетмәде кебек. Тагын кемне? Юк, беркемне дә. Ләкин ни өчендер Алла каргады булса кирәк. Кайсысы — тәрелесеме, әллә мөселман Алласымы? Аларның кайсын рәнҗетте икән соң Марва? Ныклабрак уйлаганда, дөресен әйтергә мөмкин булыр иде, ләкин аны-сыннан ул курка. Марва дөреслекне сизә, ләкин аны үзеннән дә яшерә, үзенә дә әйтә алмый ул...

Берничә көн, юк, берничә төн әйбәт кенә узды. Атна, тагын бер атна...

Августның искиткеч матур, тыныч көннәре (юк ла — төннәре) иде. Искиткеч матур, тыныч һәм якты август төнендә Марва караватыннан торды. Залны әйләнде. Бернәрсәгә дә тотынмыйча, тоткарланмыйча, ишеккә килде. Ачкычны борып, ачты ишекне. Чыкты. Ишек төбендә — өскә таба тимер баскыч. Марва шул баскычтан менә башлады. Баскыч өстендә люк дигән тимер капкач, хәерсезгә каршы, йозаксыз иде. Марва, шул капкачны ачып, чарлакка үрмәләде.

Нәкъ менә шулай өскәрәк үрмәләгәч, биеккәрәк күтәрелгәч, кинәт дөнья үзгәрде дә инде. Дөньяны караңгылык басты. Каралуы, караң-гылануы җитмәгән, тарайды, бөтенләй кысанга әйләнде дөнья.

Җитмәсә, баскан саен аяк астында нәрсәдер шытырдап тешкә тия. «Нәрсәдер» дигәннең тиз арада хәерсез пластинка кыйпылчыклары икән-леге ачыклана. Аяк баскан саен таныш авазлар тапталып уала тора: «Тормышыбыз...» — четерт. «Матурланды...» — четерт. «Илебез...» — че-терт. Аяк баскан саен шулай, һәр аяк баскан саен!..

Аскы яктан тагын да яманрак тавышлар — кычкырышлар, талашлар ишетелә. Кычкырыш-талашлар, бәрелеш-тәпәләшләрне, этеш-төртешлә-рне ниндидер көйгә салып шаулаталар, җитмәсә. Чайкалышмы чайкала җир өсте. Җитмәсә, ниндидер җан ияләре булып бөтерелә, баш аркылы сикерә, ыргый, аугый, мүкәйли, шуыша, өстерәлә. Әйтерсең, бии, әйтер-

сеӊ, жырлый. Бу бию, бу җырлау «Бөгелә-сыгыла дер-дер ит» — дип атала икән. Бөгелә-сыгыла дер-дер килеп, котыра кара җан ияләре. Аларның да аяк асларында Марваның сөекле җыр өзекләре тапталып ахыр чиккәчә тетелә: «Илебез, илебез»,— дигән соңгы мәгънәләр юкка чыга. Кемнәр, кемнәр болар? Бераз карап торганнан соң аңлый алды Марва, бу биеклектә адәм балалары түгел, җен-пәриләр шаша-котыра икән. Котыра-котыра, алар адәмнең күген җимереп төшергәннәр. Адәм үзенең күк йөзеннән мәхрүм ителгән. Менә шуңа күрә кысан икән, шуңа күрә баш күтәрерлек тә урын калмаган — тәп-тәбәнәк өске як, чак кына тураерга теләсәң, башың тимер сыман каты нәрсәгә бәрелә. Адәмнең күген — Тәңресен харап иткәннәр. Күк булмагач, каян килеп исән калсын ди йолдызлар? Кайсы кай якка коелып, чәчелгән, тапталган, сүнгән алар. Бу биеклектә ай бар иде. Анысы хәзер кайда икән?

Бераз күзәткәннән соң, карлы-тузанлы өермә күзгә чалынды. Тик өермә шикелле бөтерелгән нәмәрсәләр — шул ук җен-пәриләр, кара көчләр икән. Шулар үзгәрткән икән дөньяны. Үзләре исә, таш коймалар белән уратып алынган тыныч кальга эченә бикләнеп утырганнар да, кулларына сәнәк хәтле чәнечкеләр тоткан килеш, табын уртасыннан нәрсәдер чәнчеп-чәнчеп алалар да, шуны үзләренең иләмсез зур авызларына дыңгычлый-дыңгычлый тутыралар. Нәрсә тутыралармы? Табында нәрсәме? Алларында, табын уртасында — Ай! Кара көчләр шуны, Айны — барча адәм затына мәңге-бакый җитә килгән яктылыкны — кискәли-кискәли эләктерә: каба, чәйни, йота-йота сикерешә, котырына лабаса. Алар айны кызарып пешкән бәлешкә әйләндергәннәр ләбаса!

Иң түрдә айның үзе төслерәк шома башлы шайтан утыра. Барча җеннәр, барча пәриләр шуның тирәсендә бөтерелә. Сәнәк хәтле чәнечкеләр белән ай кисәкләрен эләктерәләр дә, үзләре бер каба, ә теге шайтанга икене каптыралар. Шайтан авызы — капкадай олы авыз — җирнең үзен йотар дәрәҗәдә ачыла да куя, ачыла да тора. Ун тапкыр, йөз тапкыр, мең тапкыр — сан-исәпсез мәртәбә. Шайтан йотып өлгерә алмаган очракта кайбер калҗалар аяк астына тәгәри дә, аларны әүмәкләшә-әүмәкләшә вак җаннар талаша-талаша эләктерә һәм, башкалар кул сузып өлгермәсен өчен, чәйнәми-нитми йотып та җибәрә.

Ничәмә сәгать, юк, сәгать түгел, ничәмә көн, юк, көн түгел, ай, юк, ай түгел, ничәмә ел, әллә дистә, әллә йөзләрчә ел, гасырлармы дәвам итте икән бу вәхшәт? Бу тантана? Анысын бүтән кеше түгел, хәтта Марва үзе дә әйтә алмас иде. Марва үзенең иң төпкел күңел тирбәнеше белән шуны тойды — адәмнең күк гөмбәзен шушы җеннәр, шушы пәриләр, шушы шайтаннар җимерделәр. Адәмнәрнең аен шулар урлап, шулар йоттылар. Озакламый, айның соңгы кисәкләрен, йолдызларны сандыкларга, амбарларга, өр-яңа складларга тутыра башлаячаклар. Марва шушы кыргый хисләр тантанасын үз күзләре белән күреп, комсызлыкның, оятсызлыкның нинди дәрәҗәләргә җитә алуына ышанды.

Мәгәр азынуның соң чикләренә җитеп мавыккан кара көчләр, артык мулдан кубып, байлыкларны юкка исраф итә үк башладылар. Сәнәк хәтле чәнечкеләрдән коелган валчыкларның кайберләре, вак җеннәр кулына эләкмичә, ераккарак тәгәрәп, кайдадыр, нindидер томан араларында яңадан үсә башлап, кайберләре йолдыз, ә берсе ай шытымына әверелә язды түгелме соң? Әйе, алгы якта, гәрчә бик еракта, гәрчә сукыр лампа уты чаклы гына булса да, нindидер яктылык күзгә чалынды лабаса. Һәм, билгеле инде, Марва, һич вакыт әрәм итмәстән, шул айга таба атлап китте.

Алгы яктан сирпелгән яктылыкка таба күпмедер атлагач, чыраена нур сирпелеп, адымнары тизли төште. Яктылык көчәя барып, инде тәрәзә кебек нәрсә барлыгы сизелде. Өй тәрәзәсе кебек, җитмәсә үзе ачык. Марва интекмичә генә тышкы якка чыкты. Ниһаять, менә ул инде иректә, ниһаять — иркендә. Искитмәле матур киңлектә канатларын кошта́й җәеп, җир чите буйлап атлый китте Марва.

Алда бая дөрес юлдан алып килгән яктылыктан да матуррак, көчле, сихерле нәрсә балкый. Бу яктылык Марваның гомер буе хыялланган, гомер буе омтылган изге максаты икән. Марва биектән, ерактан үзен чакырган, гомер буе алгысыткан бөек яктылыкка таба кыю рәвештә атлап китте. Канатлы шикелле, очкан шикелле җиңел иде баруы. Соңга таба гына адымнар авырая төште. Акрыная төште адымнар. Нәрсәдер комачау итә иде. Комачау иткән нәрсә тавыш иде. Гомере буе алгысынган яктылык ягыннан ук, каршы яктан, ниндидер ямьсез тавыш килә. Башта күгәрчен гөрләве сыман ишетелгән аваз, әкертен-әкертен дөпелдәүгә әйләнә барды. Каршылык көчәйде. Шулай да Марва, үзенә каршы чәчрәгән ямьсез гөрелтене җиңә-җиңә, барыбер атлавын белде. Алга омтылышы шулчаклы көчле, аны туктата алырлык каршылык була алмыйдыр төсле иде. Әйе, гөрелтегә каршы барып, үҗәтләнә-үҗәтләнә атлый бирде Марва. Әнә, югарыдагы сихерле яктылык якыная да башлады инде. Тик, хәерсез, ары атларга җир бетте — аяк басарлык та калмады җир. Калган араны ничек үтәргә? Нишләргә? Канат, канат, адәм баласына канатлар бир, тәкъдир!

Тәкъдир аны ишетте — канатлар бирде. Менә хәзер, санаулы гына минутлар калды инде. Үзен гомер буе алгысыткан яктылыкка калган араны ул очып үтәчәк. Хәзер канатлар җилпенә дә башлады. Марва хәзер очып китәчәк — яктыга, биеккә!

Ләкин гел син дигәнчә генә булса икән лә. Хәерсез, түбәндәге гөрелтенең һич кимемичә комачау иткәне җитмәгән бит. Нәкъ шул яктан... бу ни? Коточкыч шартлау! Әйе, таныш, үтергеч шартлау! Денисны озаткандагы сыман. Гүяки, нибарысы автомобильнең хикмәтле шартлап куюы гына түгел. Әйтерсең ки, литавралар бәрелешеннән хасил булган шартлау, чатнау! Хөкем карарының җиренә җиткерелүен аңлаткан күкрәүле нокта.

Марва сискәнеп уянганын сизәргә өлгерми дә калды. Кая очканы аңына килеп җиткәнче, баскан җиреннән купты Марва. Әйе, ул чынлап та очып китте. Күңеленең иң тирәндәге бер тоемы ышандырып куйганча, ул барыбер яктыга таба очты.

Айга таба.

*1991—1992 еллар*



# ШИГЪРИЯТ

## Рәшит Әхмәтҗан



## Безнекеләр шулай җан бирми

* * *

И таралган татарлар,
Илегез эзли сезне,—
Кошка әйләндегезме,
Ташка әйләндегезме?

Татарчалап дәшкәнне
Барчагыз да аңлармы?—
Җаныгызда кан бармы,
Каныгызда җан бармы?

Канлы эзләр сөйләде:
Табаныгыз канаган.
Канлы эзләр калдырып,
Кайтырсызмы яңадан?

Илне уйлап елаудан —
Күзләрегез керфексез...
Җир читенә киткәнсез
Чукынудан өркеп сез.

«Оҗмах булыр» Туган ил —
Тәмуг булып тоелган...
Ни эзлисез шул гомер,
Анда төпсез коедан?

---

Рәшит ӘХМӘТҖАН (1941)—*шагыйрь, «Моңлану», «Йөрәк бәйрәме» h.б. китаплар авторы, Г. Исхакый бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Сезгә туган илләр — ни?
Кемнәр сезне җибәрми?
Бер-беребезне күрәлми,
Без үләрбез микәнни?

Ниләр сезне җибәрми,
Капкынгамы каптыгыз?—
Җимерегез, ватыгыз,
Туган илгә кайтыгыз!

Хәтта бүреләрне дә
Берни тоталмый бәйләп,—
Әгәр капса капкынга,
Аягын өзә чәйнәп...

## Туфан тавышы

Сез иртәгә ирек алырсыз!—
Сөякләрем гүрдә сизенә.
Илбасарның басып эзенә,
Тарих юлларыннан яу чабып,
Ирек яула, Кеше, үзеңә...
Сөякләрем шуны сизенә.

Бер генә көн кеше коллыкта
Яшәсә дә — аның ул көне
Каргалырга тиеш мәңгегә!
... Күтәрелә янган йортымның
Зәңгәр күккә кара төтене...
Каргалырга тиеш ул көне!

Илләреннән качкан аккоштан
Миңа сәлам китергән сыман
Гүр өстендә йөзә ак томан...
Тарих юлларыннан яу чапкан
Чичән ирләр, башлар исәнме?—
Мин монда да сезне сагынам.

Каршылыймы батыр бабайлар?—
Алар белән исән калганбыз.
Җидегәннән юллар өйрәнеп,
Рухларны саклап ялгансыз —
Ничә йөз ел килә алганбыз...
Алар белән исән калганбыз.

Ирек булса — булсын мәңгегә! —
Кеше теле, кошлар өнендә
Ишетелә бу сүз бүген дә.
Иректе бит бары бер көнгә
Йортыбызда алмас беркем дә...
Ишетелә кошлар өнендә.

Илгә ия булган чаялар —
Чичәннәрем, имин булыгыз.
Ураулы шул, бигрәк ураулы

Тарихларда калган юлыбыз.
Арытмыйча атны куыгыз,
Чичәннәрем, кыю булыгыз!

Кол калсагыз — мәңге минем дә
Сөякләрем сызлар гүремдә.

## Мамык мендәр

Туфан туган авылдан ул.
Һәм бераз охшый Туфанга.
Охшагандыр — бу дөньяны
Күз яше белән юганга.

Һәр әйткәне шигырь аның,
Нигә соң ул үзе язмый?
Менә тагын яңа шигырь
Сөйли миңа Зөфәр абзый:

— «Исләремдә исән тора
Туфан илгә кайткан көннәр.
И-и-и, ул көннәр... Мин шагыйрьгә
Бүләк иттем мамык мендәр.

Кайткан көннүк йолдызларга,
Ай-Кояшка ник менәргә?—
Йокласын дим, ял итсен бер
Башын салып шул мендәргә.

Уйлагандыр: «Халкым һаман
Кемнәргәдер билен бөгә.
Татарларым кол булганда —
Бу азатлык миңа нигә?!»

Кабат ташка әйләнгәндер
Шул чагында мамык мендәр.
И-и-и, шагыйрьнең бар гомере —
Айлы төннәр, кара көннәр...»

Сөйли шулай Зөфәр абзый.
Ул — Туфанның авылдашы.
Күз алдымда... мамык мендәр
Һәм... күгәргән зиндан ташы!

* * *

Кылыч булып узды кайнар җилләр.
Ярый, таллар алдан иелделәр...

Берсе генә ауды. (Тамыр калды).
Аннан шаулап җәйге яңгыр яуды.

Дөнья тып-тын. Мәйданыбыз тып-тын.
Тик мин күрәм: һәр тамчыда — упкын!

## Ялвару

Син кая качасың, кайларга китәсең?—
Кошлар бит кичә үк сайрады барсын да...
Ашыкма. Без икәү — бер агач бөресе
Һәм ике яфрагы идек бит асылда.

Кошлар шул кичә үк сайрады барсын да.
Артыңнан аларны очырып җибәрәм.
Ятларда көймә бар. Утырсаң әгәр дә,
Җилкәнгә — җил әрәм,
Җилкәнгә — җил әрәм!

Яшәрбез гомергә — беребез эсседә,
Беребез салкында йөрер гел калтырап.
Йә, шуның өченме, ялына-ялына,
Сөюдән инәлеп без алдык җан сорап?!

Тамырын өзгәләп, талларга тау ишеп,
Барчасын таркатып китәргә димәгән...
Мин сиңа кычкырам,
Мин сиңа инәләм:
Төшеп кал тизрәк, беркемне сөймәгән
КӨЙМӘДӘН!

## Йөри торгач, таптык эзләгәнне

Хәбәр итми генә, хәл белергә
Килдең нигә бу караңгы өйгә?

Ике болыт иңгән күзләреңә —
Карлы яңгыр ява йөзләремә.

Бозлар катар керфек-кашларыма —
Чыгыйк әле Кояш асларына.

Язлар үтте. Йөрик көзләремдә.
Мин эзлим дә хәзер, эзләмим дә

Җанның гомер буе табынганын,
Теләми дә бугай табылганын...

Җирдән көзнең алсу алмаларын
Ут тоткандай кулга алгаладың.

Пышылдадың иске исемемне:
«... Мин күрмәгән булсам бүген сине —

Сукыраер иде бу күзләрем.
Күпләр җуйды шулай үз-үзләрен...»

Җавап биреп җаным өзгәләнде:
«Йөри торгач, таптык эзләгәнне,
Йөри торгач, таптык эзләгәнне!»

Ике болыт иңгән күзләреңә —
Тамчылары тама йөзләремә...

* * *

...Дарга китерәләр. Сакчыларның
Кырыгында — кырык кылыч бар.
Ә кешеләр, мине соңгы кабат
Күрсәләр дә, барсы тынычлар.

Болай итеп хәтта Батыршаны
Озатмаганнардыр ләбаса!
Бар гаебем — яшәү. Әйтер идем,
Хөкемдарлар әгәр сораса.

Яши-яши дарга мендем. Үлдем...
Хәзер яклап беркем дәшмәсен.
Тавышыңнан мин уянып киттем:
— Үзем үләм, ә ул яшәсен!
Яшәсен!!.

Тавышыңның кайтавазы белән
Шигыремнең ахырын язгансың:
«Икебез дә һәр көн бер үләбез,
Кавышалмый калган яздан соң».

* * *

Татарның бәхете — таштан,
Таштан тора тоташтан.
Мең еллык канлы тарихы
Ташлар белән тоташкан.

Татарның китабы — таштан.
Таныш моң ишетелә.
Өстенә чиркәүләр салып,
Таш таулар ишеп кенә
Булмый үтереп. Барыбер
Таныш моң таба мине.
Күрәм — ташны су өстендә
Йөздергән Кол Галине...

Мин укыйм татар тарихын
Батмыйча торган таштан:
Безнең моң... күкнең җиденче
Катына хәтле ашкан!

* * *

Бик талчыктым каргыш тавышыннан,
Үзем генә беләм үз хәлемне.
Каһәреңне яудыр тагын йөз ел —
Йә, шуннан соң дөньяң үзгәрерме?

Башын кисеп, сары сакалыннан
Иделләргә тотып атмагансың!—
Аның башы шулай исән калгач,
Халык башы исән каламы соң?

Явыз Иван күптән дөньяда юк.
Бу гасыр да менә узып китә.
Бер җиңелү — сора, күпме тора?—
Ә башыңны кисү дәвам итә...

## Татар теле

Мин — татарның теле,
Сезне эзләп,
Канга батып беткән хәтере.
Бәлки сезгә: «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин бар, мин — тере!

Нигә, балам, юллар уртасында
Башмагыңа карап баш идең?
Чукынмадыңмәле? Җиде бабаң
Васыятен тапшырыр идем.

Күләгәләр төшкән күзләреңне
Күрим әле диеп иелсәм —
Кипкән иреңеңдә ярылып яткан
Сүзләреңдә әле мин исән:

— Синнән башка, дисең, яши алмыйм,
Төшкә керә соңгы көннәрем.
Сабый чакларымда бишегемне
Тирбәтергә нигә килмәдең?

— Ил коллыкта иде. Һәм бүген дә
Алтын сүзләремә юк кадер.
Дөньядагы исәннәрем белән
Исәнләшә алмыйм мин хәзер...

Исән сезнең диңгез! Бөтенегез
Аягүрә басар — шауласам.
Юлларыңа мәрҗән сибәм, балам,
Дулкын бәрелгәндә аумасаң.

Минем мәрҗәннәрдә — җиде бабаң
Васыяте шулай җемелди.
Җем-җем иткән нурлар күрсәң әгәр —
Әбиләрең шулай җеп эрли.

Тирә-якта, ятлар урлый-урлый
Йомгак урый — нурлар кимеми.
Өзелмиләр, чуалмыйлар алар —
Безнекеләр,
Безнекеләр шулай җан бирми!

Кил син, балам,
Кер син кочагыма —
Уйлый күрмә илдән китәргә.
Исән чакта исәнләшик әле,
Соң булуы мөмкин иртәгә.

Исәнләшик.
Мин халыкның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине: «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин — бар, мин — тере!

## Тарих китабыннан

Бер көнне үлем җәзасын
Тел кисү җәзасына
Алыштыралар. Баласы
Дәшәлми анасына...

Мәскәү урамнары шулай
Телсезләр белән тула.
Телсез калуның бу әле
Тик башы гына була.

Гасырлар уза... Кеше ни!—
Халыклар телсез кала.
Каршы сүз әйтсәң — әле дә
Телеңне кисеп ала.

Мин татар — тылмач буларак,
Ник тел кистереп торыйм!—
Туган телемне биргәнче,
Үлем җәзасы сорыйм.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Камил Фасиев**

# БЕЗНЕҢ АВЫЛ МӘЗӘКЛӘРЕ

**Безнең авылда кушаматсыз кеше сирәк булгандыр. Кешегә кушамат тора салып кына бирелмәгән. Ул кешенең холкын, йөзен, гамәлен, сөйләшү манерын һ.б. чагылдыра. Кеше нинди дә булса гадәткә сыймаган эш кылдымы — шуңа тәңгәл кушаматны авыл халкы аңа ябыштырып та куя. Һәм гомерлеккә.**

**Мәсәлән, Муллахмәт абзыйга, үсмер чагында малайлар белән тәпәләшкәндә башы белән сөзешкәне өчен, «Катыбаш» кушаматын биргәннәр. «Таз» Заһитның чәченнән кавык коелып торган. «Ака» Хәбибулла күзләрен тасырайтып, кеше малына кызыгучан булган. Сакал-мыексыз Әхмәтҗан — «Әби», кыска буйлы, чүрәкәй Салих — «Кузак», сажинлы атлап, сүлпән генә, вәкарьләнеп йөргән көтүче Шәех — «Хозер», үткер телле Шакир — «Әрем», артык симез гәүдәле Фатыйх — «Бояр», шадра Гариф — «Суер» дигән кушаматларга лаек булганнар. Югары очтагы Нурхәмәт Салихны, кирле-морлы сөйләнгәне өчен, «Кире Салих» диләр иде. Яз житеп, тауда чирәм ачылгач ул: «Китте таулар малларга» дип шатланган, коймага басып аулак өйдәге кызларны күзәткән малай-шалайны «Кем өстенә койма менгән?» дип куркыта торган булган. Безне, Фәсхетдин бабай исеменнән чыгып, «Пәси-песи» дип йөрттеләр.**

**Күп кенә кушаматларның нилектән бирелгәнен төгәл белү дә кыен. Мәсәлән,белмим, нигә түбәноч Заһитка «Козгын», Җаббар Әхмәтҗанына «Мороз», Гатага «Куян», аръяк Галимгә «Сандугач», Зәйнуллага «Бүре» кушканнардыр.**

**Ә менә кайбер кушаматлар кызыклы хәлләр белән бәйле.**

### Ак тәпи

Бу кушаматка укытучы Габделхак ия булды. Ул Сәйфелмөлек кызы Наиләгә бер-ике ел гыйшык тотып йөрде. Кышын, язын ничек булгандыр, ә җәен-көзен һәр кичтә ул түбән очтан югары очка сәяхәт кыла. Әлбәттә, караңгы төшкәч, кеше-кара күрмәсен дип. Әмма аякларында теш порошогы белән агарткан брезент ботинкалар. Моңа ул әһәмият бирмәгән.

Имакай чокырындагы кечкенә өйдә яшәүче Сарыйм карчыгы (башкача исемен әйтмиләр иде) караңгыда ялтырап торган ак тәпиләр хәрәкәтен даими күзәтеп тора икән. Кызыксына торгач, иренмичә, ул тәпи-

ләрнең кайсы капка янында туктаганын, күпме вакыт торганын да ачыклый.

Тәпиләр кемнеке? Карчык бик озак шуны белә алмыйча иза чигә. Ниһаять, көн саен, авыл буйлап каранып йөри торгач, мәктәп янында кешеләр белән сөйләшеп торган Габделхак аягында ак ботинкалар күрә.

— Бәрәкәт,— ди ул шаркылдап көлеп.— Габделхак энем, караңгы төшкәч югары очка менеп-төшеп йөрүче син икәнсең ләбаса! Нигә шулай озак интегәсең? Бер барганда Наиләне алып ук кайт инде.

Тиздән Габделхак шулай эшләде дә. Бик шәп туй уздырып гаилә кордылар. Тик шуннан соң мөгаллимне халык арасында «Ак тәпи Габделхак» дип, ә мәктәп балалары «Ак тәпи абый» дип йөртә башладылар.

## Тавык Габделхак

Чибәр, акыллы, әдәпле һәм эшчән егет иде Тәхәү Габделхагы. Матур җырлый иде. Ватан сугышына кадәр берничә ел бригадир булып эшләде. Әмма, бер дә кимчелексез кеше булмаган кебек, аның да кушамат тагарлык ягы табылган. Сөйләгәндә дә, кешене тыңлаганда да «так, так», дип тору гадәте бар иде.

Бервакыт ул Әюпләр капкасын ачып керә.

— Сәкинә абыстай, Әюп абзый өйдәме?

— Юк шул, энем,— ди Әюп хатыны. Габделхак уйга калып бер урында таптанып тора.

— Так, так. Алай икән. Так, так. Кая китте соң?

— Урманга, каен себеркесенә дип киткән иде.

— Так, так. Ярый алайса. Кайткач идарәгә сугылсын әле. Так, так.

— Карале, энем Габделхак, нигә гел тавык кебек такылдыйсың?— дип сорый исе киткән хатын.

— Шулай ычкына инде, җиңги. Минем кушаматым да Тавык бит,— ди Габделхак, кыткылдап көлеп. Так, так...

## Пики шестак

Пожар сарае янында Шиап, Котлый, Зәкиҗан һәм Мингали азартланып кәрт уйныйлар. Дуракка. Кайсы чирәмгә кырын яткан, кайсы бүрәнәгә утырган. Ә без, берничә агай һәм малайшалай, уенны күзәтәбез.

Уен тәмам кызып, кульминациягә җиткән. Шиап бер генә кәрт тотып авызын ерып утыра. Аның кулдашы Котлый инде кәртләрен салып бетергән, гасабиланып һәм шул ук вакытта, иптәшенең кәпрәйгән кыяфәтенә карап, отуларына ышанып утыра. Мингали кулдашы Зәкиҗан Шиапка каршы нинди кәрт белән чыгарга белмичә аптырый. Әллә кузыр вәлитен биреп карыйммы дип торганда, Шиап артында басып торган унике яшьлек Исхак:

— Әй, Шиап абзый, Шиап абзый, кем инде уен ахырында пики шестагы тотып кала?— димәсенме!

Бетте, кәефе кырылды Шиапның. Аның ерткычтай ярсынып, кызарып-бүртенүен күрү хәтәр иде. Ул кәртен атып бәрә һәм кинәт борылып, Исхакка җилтерәтеп «ямый».

— Малай актыгы, уенны боздың, чукынчык,— дип каршыдагы өенә айкала-чайкала кереп китә.

Шыңшып җирдә тәгәрәп яткан Исхактан көлеп без:

— Менә сиңа кирәк булса пики шестагы!— дип үчекләдек.— Шуннан калды «Исхак-пики шестак».

Егермедән узган Хаҗи исемле егет аръякта мунча чаклы гына йортта карт анасы белән очны очка ялгап яши иде. Атасы гражданнар сугышында алган яралардан арына алмыйча, озак чирләп түшәктә ятып үлгән. Өлешләренә тигән җирне Ялак Байгурага биреп, Хаҗи үзе шуның батрагы булып йөри. Барлык байлыгы — бер кәҗә.

Хөсникамал абыстай улын өйләнергә кыстап, көн саен колагын ашый:

— Яшең җиткән инде, улым, башлы-күзле булырга вакыт. Килен булгач, кешечә яши башларбыз шәт. Икәүләп эшләп сәрмая җыйсагыз, ат алыр идек, җирне үзебез эшкәртер идек. Ялгыз агач өй булмас, ялгыз егет баемас, диләр бит.

Хаҗиның җавабы һаман бер:

— Җанымны кыйнама, инәй. Минем кебек хәерчегә кайсы кыз кияүгә чыксын?

Хаҗи, әлбәттә, өйләнү турында хыяллана, тик матди хәлнең начар булуына кимсенә, шуңа күрә кызлар тирәсендә чуалмый. Ничек тә булса кытлыктан чыгу турында кайгыртып йөри торгач, ул беркөнне әнисенә әйтә:

— Инәй, мин Әмриккә китәм.

— Бәракалла, ничек китәсең, нинди Әмрик ул?

Хаҗи бармагын идәнгә төзәп күрсәтә:

— Әнә шунда, җирнең теге ягындагы илгә китәм.

Коты чыккан карчык үксеп елый башлый:

— Әстәгъфирулла, җир астында нинди ил булсын? Җәһәннәм тишегенә төшеп югалмак буласыңмы?

— Җәһәннәм түгел, бик бай диләр ул илне, бер-ике ел эшләп, мал җыеп кайтам. Тик беркемгә әйтми тор.

Анасы күпме генә ялынып-ялварып карамасын, Хаҗи үзенекен итә, өйдән чыгып китеп хәбәрсез югала. Мескен Хөсникамал абыстай бер ялгызы кәҗә сөте белән тукланып, күршеләр ярдәме белән көн күрә, зарыгып, ачы күз яшьләрен түгеп улын көтә.

Авыл халкы Хаҗи турында сорап интектергәч, ул улының наказын бозарга мәҗбүр була.

— Югалды шул, балакаем. Әллә нинди җәһәннәм астындагы Әмриккә киткән иде. Хаты-хәбәре килми. Юллык акчасы да юк иде бит, бәлки барып та житмәгәндер. Ходаем, үзең сакла, харап кына була күрмәсен инде.

Тирә-күрше карчыкны юатырга тырыша:

— Бик ерак диләр шул Американы, хат озак йөридер. Артык кайгырма, үзеңне бетермә елап. Кайтыр.

Чыннан да ике елдан Хаҗи кайтып төшә. Мыек үстереп җибәргән. Тик өс-башы искитәрлек түгел, шактый таушалган шакмаклы пальто һәм соры костюм кигән. Башында салам эшләпә. Шатлыгыннан нишләргә белмәгән анасына шикәр-чәй белән чәчәкле ак яулык тоттыра. Тик нигәдер аларның берсендә дә Америка тамгасы күренми, авыл кибетендәге кебекләр.

Билгеле инде, шул арада җыелып өлгергән күрше-күлән ничек йөргәне, нәрсә эшләгәне, күпме акча алып кайтуы турында сораша.

— И, туганнар, бик авыр булды бару-кайту, — ди Хаҗи тыйнак оялып. — Анда да гади кеше байый алмый икән. Шактый акча җыйган идем дә, күбесе юлга китте.

— Ярар, бәбкәм, шөкер акчасына, туйлык булса, иншалла, шул җиткән. Әнә артурам Фаррах сеңлесе Миңсылу гел синең турыда сорашып тора диләр, алып кайт инде үзен. Ходай кушса, ач булмабыз. Кәҗәбез, шөкер, ел саен ике бәрән китереп тора.

Дөрес әйткән икән анасы — Миңсылу егетнең тәкъдимен кире какмады.

Бераздан Хаҗиның да сере ачылды. Ул ике ел буена Бөгелмә элеваторында гына йөкче булып эшләп яткан икән. Ләкин барыбер, үзе баемаса да, исеме баеды — «Әмрик Хаҗи»га әйләнде.

## Шатун Фатыйма

Кушаматны исемнән аера белмәү кешене шактый уңайсыз хәлгә төшерә икән.

Авылны арлы-бирле урап, кагылмаган капка калдырмыйча белмәмдә йөргәне, йомыш табып, якын тирәдәге авылларга да тиз генә барып кайткалаганы өчендер күрәсең, иреннән яшьли тол калган чая Фатыймага «Шатун» дигән кушамат биргәннәр. Минем аның башка исемен ишеткәнем булмады. Һәрвакыт «Шатун кергән иде», «Шатунны очраттым», «Шатун сорады», «Шатун Керкәлегә киткән», «Шатун Нажия белән талашкан» һ.б. дип сөйләшәләр иде. Кайчакта мин аңламаган «ирсәк» дигән сүз дә ишетелгәли иде.

Бервакыт ике йомырка тотып, конфет алырга дип кибеткә керсәм, анда шул апа басып тора, ә кибетче күренми.

— Хәмит абзый юкмыни, Шатун апа?— дип сораган идем, ул минем колактан эләктереп алды.

— Әбәү, Песи малае, син дә мине рисвай итмәк булдыңмыни әле, җүнсез! Шатун түгел мин, мулла кушкан исемем бар. Фатыйма апаң булам. Шуны колагыңа киртеп куй, сантый!

Шул арада складтан килеп чыккан Хәмит абзый шаркылдап көлеп җибәрде. Мин яшь тулы күзләремне әле берсенә, әле икенчесенә текәп, ни әйтергә белмичә катып калдым. Бераздан ишеккә борылган идем, Фатыйма апа беләгемнән тотып туктатты.

— Кара син аны, тиз генә таймакчы була. Йә, сытылма, әнә Хәмит абзаңа йомышыңны әйт. Ә бусы сиңа миннән,— диде дә кесәсеннән ике прәннек чыгарып бирде. Кибеттән конфет алгач, мин оятымнан нишләргә белмичә, башымны иеп, өйгә кайтып әнигә үпкә белдерәм:

— Сез нигә «Шатун» да «Шатун» дип әйтәсез, ул матур апаның исеме Фатыйма икән ләбаса?!

## «Әссәламегаләйкем!»

Безнең авылда пәһлеван гәүдәле, кап-кара мыегы, өреп тутырган туптай мускуллары белән Карахмәткә ошаган «Барышник» Закир бар иде. Аның яраткан шөгыле, хәзергечә әйткәндә, хоббисы — ат алмаштыру иде. Ел саен кимендә ике тапкыр — язгы сөрү-чәчүдән соң, аннары урып-җыю эшләре бетү белән, ул атын чаптырып авылдан чыгып китә дә, икенче көнне бик өшәнгән, кабырга сөякләре тырпаеп торган, башын җиргә тидерә язып, йокысырап атлаган атка утырып кайта.

Закирның нәүбәттәге бу хурлыгын күргән урам халкы шаркылдап көлеп кала. Җил капканы ачып ишегалдына кергәч, хәчтерүш атка җирәнеп карап, хатыны төкеренә-төкеренә ирен тирги, балалары шыңшый башлый. Хуҗа кесәсеннән берничә кәгазь акча чыгарып күрсәткәч, бер бәйләм клиндер, конфетлар, такта чәй тоттыргач кына йорттагыларның күңеле йомшара.

Бер-ике атна чамасы вакыт узганнан соң, ахшам алдыннан Закир яңа атын җигеп урамга чыга. Ат шактый аруланган, йөрешле, башы тезген белән дугага күтәрелеп бәйләгән килеш салмак кына атлап бара. Кибет

янына житәрәк хужа, анда жыелган кешеләргә карап һәм дилбегәсен нык тартып, «Әссәламегаләйкем!» дип дәшүе була — менә хикмәт! — әле күптән түгел генә жаны чыгарга торган хәйван, бөтен көченә ярсып, тыя алмаслык булып чабып китә.

Бу әкәмәтле тамашаны авыл халкының беренче генә күрүе түгел. Закирның һәр яңа аты белән шундый метаморфоза була. Башка авылга кергәндә дә очраган кешегә хужасы «Әссәламегаләйкем!» дип сәлам бирә һәм атын дулатып, тамашачыларны сокландырып узып китә. Дөрес, атның гайрәте авылны чыгу белән бетә, «Әссәламегаләйкем»не әйтмәсәң, ничек тә чаптыра алмыйсың. Хәер, Закирга анысы кирәк түгел, тирә якта дан казаныр өчен һәм бер атны икенчегә алыштырганда азмы-күпме табыш алыр өчен аңа урамнарны жилләтеп узу житкән.

Ничек соң начар гына ат тиз арада юртакка әйләнә икән? Халык шуңа аптырап баш вата. Ниһаять, серне ат хужасының күршесе Нәби ача. «Әссәламегаләйкем, әссәламегаләйкем» дигән көчле тавыш ишеткәч, ул: «Кемне шулай каршы ала икән Закир абзый?» — дип ярыктан карый. Күрсә — галәмәт: Закир атын авызлыклап, тезгенен тартып тоткан да, шул сүзне кабатлый-кабатлый камчы белән яра. Ат, чыдый алмыйча ярсып, үрле-кырлы сикеренә, ә хужа һаман кыйный. Юлга чыгар алдыннан ул атка гел шулай сабак бирә икән. Вәт кайда хикмәт...

* * *

Шул рәвешчә өйрәтелгән аты белән Закир колхозга керде. Колхозның беренче рәисе итеп, авылның иң ярлы кешесен, гомере буе ат күрмәгән, жир сөрмәгән-чәчмәгән көтүче Хозыр Шәехне куйдылар. Рәис булып алгач та ул атка бик сирәк утырды, жәяү генә йөрде, хәтта район үзәге Шөгергә дә тәпиләп кенә бара иде. Моңа тагын сәбәп — аның сул кулы ничектер кәкрәеп каткан булуда. Уң кулы белән ул чыбыркыны шәп шартлата, тик дилбегә тотарга, ат жигәргә-туарырга гажиз. Ә кучер йөртергә әле өйрәнмәгән, тартынган күрәсең.

Беркөнне аны тагын райүзәккә чакыралар. Жәяү генә китәргә жыенганда, аңа бригадир Габделхак ябыша:

— Син нәрсә, Шәех абзый, тагын жәяүләп кенә бармакчы буласыңмы? Юк инде, колхозыбызны хур итмә, кеше көлдереп йөрмә, аякларыңны да жәллә. Менә мин сиңа матур гына ат жигеп бирәм, курыкма, рәхәтләнеп утырып бар.

Бригадир тәкъдимен башкалар да куәтләгәч, рәис артык киреләнеп тормый, тәвәккәлләп, Закир атын жиккән тарантаска утырып юлга чыга. Ат чыннан да күндәм икән, әкрен генә юырта, текә Сугышлы тавын да атлап кына төшә. Дилбегәне бер кул белән дә тартып тотасы юк. Шәехнең кәефе шәп, тарантаска кукраеп кырын яткан килеш авылга керә. Бакса, өченче йорт капкасы янында ике ир кеше басып тора, сәлам бирергә кирәк.

— Әссәламегаләйкем! — дип кычкыруы белән, я Хода, бу нинди әкәмәт?! — шундый нәзакатьле сүзне ишеткән ат, кинәт дуамал ыргылып, жанфәрман дулап китә. Бу афәтне көтмәгән ваемсыз Шәех тарантастан мәтәлеп төшә. Аның кулыннан ычкынган дилбегә, көпчәккә уралып, берничә йортны узгач атны туктата.

Ярый әле, Шәехкә әллә ни булмаган, янбашы гына бераз авырткан. Гарьлегеннән ул ат янына бармый да, кире борылып, Габделхакны ата-анасы белән сүгә-сүгә Тимәшкә жәяүләп кайтып китә. Ә атын Сугышлыдан бер малай кайтарып куя.

Икенче көнне Шәех янына Закир керә.

— Бәлагә очрагансың дип ишеттем, кордаш, — ди ул. — Кара син аны, колхозга кергәч тә онытмаган икән биргән сабагымны минем алаша. Үзеңне дә әйтер идем, хәчтрүш, атта да йөри алмагач, нинди персидәтел инде син?

Әйе. Хәзер Шәехнең персидәтеллеге ташка үлчим генә булды, йөкне Закир аты хәтле дә тарта алмады. Озак та үтми — аны төшерәләр, ул яңадан авыл малын көтәргә керешә.

Ә рәис итеп тагын бер ярлы вә салмышны — Пакрый Шиабын куйганнар иде.

## Җанлы багана

Хәмер белән дуслашу аркасында Шиап абзыйның шактый көлке һәм хәтәр хәлләргә очраган чаклары булды.

Әле колхозга кергәнче була бу. Кышкы үтә салкын көннәрнең берсендә Бөгелмә базарында эшләрен бетереп, «яхшы гына» салып алгач, ул кичкырын туры алашасын җигеп кайтырга чыга. Юл уңае Иске Печмәндәге «шинкарь» да тагын бер «чәкүшкә»не бушатып ала һәм толыбына төренеп чанага яткан килеш, юлын дәвам итә.

Иске Печмән белән Дурасу арасында кышын да туңмый торган елга бар. Гөнаһ шомлыгына, шуның күперен чаптырып узганда чана, берьякка салулап китеп, дүрттән берсе генә калган баганага бәрелә дә, йокымсырап яткан Шиап елгага очып төшә. Суда айкалып лач чыланган һәм айный башлаган юлчыбыз, көч-хәл белән үрмәләп, ярдан өскә күтәрелә һәм күпер чатына килеп басуы була — тәмам юешләнеп беткән озын толыбы бозлы панцирьга әйләнеп ката.

Ә хуҗасының төшеп калуын «күрмәгән» ат инде китеп барган.

Аяк атлау түгел, кыймылдарга да гаҗиз калган Шиап бер урында калтыранып һәм әҗәлен көтеп озакмы басып торгандыр, ниһаять, Иске Печмән ягыннан атын чаптырып Дурасу урысы Степан күпергә килеп керә. Аның да чанасы салулап башта теге бердәнбер баганага, аннары тагын «иkенчесе»нә сугыла, тик бусы җиңел генә «сынып» елга үзәненә барып төшә.

Моны шәйләгән Степан хәйран кала. «Бу ни хәл,— ди ул,— монда багана күптәннән юк иде ләбаса!» Атын кире борып аска караса — ниндидер карачкы ыңгырашып ята. Куркып-шикләнеп булса да, Степан ярдан төшеп, бозланып каткан кешене сөйрәп чыгара һәм аның Шиап икәнен таный.

Туры алаша авылга кайтып капка төбендә кешнәп җибәргәч, Хәтимә абыстай ирен каршы алырга чыкса — чана буш. Хуҗа да юк, бер әйбер дә юк. Шиапны биш көн эзлиләр. Бөгелмәдән, тирә як авыллардан сорашып инде тәмам өмет өзгәндә, мич башында җылытып, мунча кертеп, көмешкә белән дәвалап яткырган шабрасын Степан өенә кайтара.

Шатлыгы белән бергә ачуы чиктән ашкан хатынының:

— Кайларда югалып йөрдең, кабахәт җан?— дигән соравына ул:

— Менә Степанда кунак булдым,— дип җавап бирә.

— И, оятсыз бәндә. Без монда күз яше түгеп, үлек гәүдәңне генә булса да тапмабызмы дип эзләнәбез, ә ул, исерек тәре, күршедә генә качып яткан икән.

— Йә, күп чәпченмә, карчык. Бар әле, тиз генә бер ярты алып кайт. Дусны сыйларга кирәк.

Нишләсен, Хәтимә абыстай кибеткә йөгерә.

## Корбан даруы

Корбан абзыйны авыл халкы «ат докторы» дип зурлап йөртә иде. Берәр атның җилкәсе яки сырты камыт-ыңгырчак тиеп яраландымы, аягы сындымы, эче киттеме — Корбан ниндидер сыеклык сөртеп яки эчертеп төзәтә. Башка мал-туар чирләсә яки яраланса да ул

ярдәмгә килә. Үзебезнең Тимәштә генә түгел, тирә-күрше авылларда да аны яхшы беләләр. Һәм «ат докторы» дип кенә түгел икән әле.

Бервакыт капка төбендә сөйләшеп утырганда аңа сорау бирәләр:

— Карале, Корбангали, син Иске Печмән урысын үлемнән алып калгансың, дип сөйлиләр. Ничек булды ул, ә?

Корбан рәхәтләнеп хихылдый. Ул кыстатып тормый, үзе кылган әкәмәтләр турында сөйләргә ярата.

— Үзем дә аптырап торам әле бу эшкә, җәмәгать. Шулай берчак Бөгелмәдән кайтышлый шул Печмәндәге танышым Николайга керсәм, ни күзем белән күрим, уфылдап, җан бирергә житешеп караватта ята. Тәмам бетеренгән, хатыны үкереп еларга керешге, кырмавык кебек ябышты. Курбан дарагуй, ди өзгәләнеп, пужалысты спасай, ди, сиңа гына ышаныч калды, ди, больнис не помогал, терелтә алмаслык яман чир дип әйттеләр, ди.

Мескен Николай үзе шардай күзләрен миңа текәп ята, Христосына ялвара диярсең. Мин нишли алам? Кеше бит ул, ат түгел. Шулай да кырт кисеп аның өметен өзәргә ярамый. Мич башына куйган төрле үләннәр төнәтмәсе исемә төште. Бик үтенеп килгәннәргә биргәләгән идем, файдасы булды бугай. Ярар, ни булса булыр, барыбер үләргә тора, хет күңелен юатыйм, дип уйладым. Ладно, дидем маржасына, приезжай, берәр чарасын күреп карармын, дип кайтып киттем.

Гөнаһ шомлыгына, икенче көнне мине Шөгергә ветпунктка чакырдылар. Киткәндә хатынга әйттем: Печмән маржасы килсә-нитсә, мич өстендәге шешәнең әнә тегесен биреп җибәр, дидем. Тәки килгән бит теге, шатланып шешәне алып киткән. Кайткач карасам, йа Ходай, минем пумалабаш икенче шешәне тоттырган бит маржага. Ә анда ачытырга куйган ат сидеге. Мал-туар яраларын төзәтергә генә ярый,— Корбан үзе шул урында кеткелдәп җибәрә, аннан бигрәк, тыңлаучылар шаркылдап көләләр. Хәлнең хәтәр буласын сизеп, кайберләре шомлана да.— Мин,— дип дәвам итә Корбан,— кәнишне, бик нык шүрләдем. Хатынга да каты әләкте. Николайны агу эчертеп үтергәнсең, дип бәйләнүләрен, судка тартуларын көтәм. Чөнки аның үлгән булуында шигем юк инде. Шулай хафаланып бер ай чамасы йөргәннән соң, чәй эчеп утырганда, тәрәзәдән баксам, капка төбенә җиккән ат килеп туктады. Ә чанада бер хатын белән толып якасын күтәреп кигән бер ир. Утырган урынымда катып калдым, зиһенем югалды. Бетте баш, дим, мине аристовайт итәргә милиция китергәннәр.

Менә ишектән маржа килеп керде. Бәрәкалла, ачу-нәфрәтнең эзе дә юк, күзләре матур елтырый, авызын колакларына житкереп ерган. Җәһәт килеп өстемә сарылды, битләремне ялый башлады. Үзе һаман бер сүзне кабатлый: «Ой, Курбан, дарагуй» да, «Ой, Курбан дарагуй!» Күзем бусагада басып торган кешегә төште. Бәй, Николай бит! Таный алмаслык булып тазарган, мыек астыннан елмаеп карап тора! Исем-акылым китте, бу могҗизага хәйран калдым. Сагынып көткән туганым диярсең, шатлыгымнан нишләргә белмичә, кочаклап алдым үзен. Ә ул елый-елый: «Спасибо, брат Курбан, спаситель, лутчий доктор», дип пышылдый.

— Ну, җен дә икәнсең үзең, Корбан. Докторлар кулыннан килмәгәнне эшләп куйгансың бит, малай. Менә сиңа «ат докторы!» Соң теге урыс бүләк-фәлән бирдеме?

— Бирмиме соң? Бер капчык бодай оны, бер тәпән бал, бер сарык түшкәсе, потка якын акмай алып килгән иде. Көмешкәсен әйтеп тә тормыйм инде...

## Мороз малае

Ни сәбәптәндер, түбәноч Әхмәтҗан абзыйга «Мороз» кушаматы такканнар. Аның ике улы бар — берсе Салихҗан, икенчесе Шәрифҗан. Егерменче елларда Бөгелмә шәһәрендә көзге ярминкә бик шәп уза иде. Әхмәтҗан абзый да уллары белән барган. Ун яшендәге

Шәрифҗанны ат-арба сакларга калдырган, атасы белән абыйсы ярминкә әйләнергә китәләр. Әлбәттә, Шәрифҗан да түзеп тора алмый, якындагы кибетләргә, прилавкалардагы байлыкка кызыгып карап йөри башлый.

Кирәк бит, малайның бер ачык прилавкада өелгән хуш исле кызыл алмаларга күзе төшә. Хуҗасы күренми. Ул, як-якка каранып ала да, тиз генә бер алма чәлдереп, арбасы янына юнәлә.

Шулвакыт ул «Мороз!» дигән көчле тавыш ишетә. Борылып караса, эшләпә кигән бик зур гәүдәле бер агай «Морозов!» дип кычкырып, җәһәт атлап аңа таба килә. Шәрифҗанның коты ботына төшә, ул балавыз сыгып йөгерә башлый. Тик теге кеше аны куып җитеп якасыннан эләктерә.

— Нигә елыйсың, малай? Кая чабасың?

— Абзый,— ди Шәрифҗан калтыранып,— зинһар җибәр, мин бүтән урламам... ы-ы-ы...

— Нәрсә урладың?

— Менә бер алма. Сатучысы юк иде... ы-ы-ы.

— Ә нигә миннән качасың?

— Мороз дип кудың бит.

— Мороз? Шәйтан алгыры, син дә Морозов мыни?

— Әэ, мин Мороз Әхмәтҗан малае.

Агай шаркылдап көлеп җибәрә һәм Шәрифҗанны башыннан сыйпап, юата.

— Мин сине кумадым, маңка малай, кирәгең бер тиен, елап йөгергәнгә күрә генә тотып алдым. Ә Морозов — минем дус кешем. Мин аны эзләп кычкырдым. Әнә ул үзе дә.

Каршыга көрәк сакаллы, күпереп торган чәчле кеше килеп баса. Алар, үзара русча сөйләшеп, малайга төртеп күрсәтә-күрсәтә көлешәләр. Татар агай Шәрифҗанга аңлатып та бирә:

— Мин аңа, менә тагын бер улың табылды, дидем. Син Сергей Морозов улы булырга ризамы?

— Ю-ук!— ди Шәрифҗан шыңшып. Мин Мороз Әхмәтҗан малае.

Агайлар тагын көлешәләр.

— Молодец алайса. Тик атаңнан аерылып йөрмә, юкса башка бер Мороз алып китәр үзеңне.

Аннары агайлар Шәрифҗанны алма өеме янына алып киләләр, ике эре алма сатып алып кулына тоттыралар. Татар агай базар мәйданын ярып кычкырып җибәрә:

— Мороз Әхмәтҗан!

## Миннулла чабаталары

«Мороз» Шәрифҗан мәһабәт таза, чибәр һәм эшчән егет булып өйләнгән генә иде — Бөек Ватан сугышы башланды. Ул абыйсы белән фронтка китте. Икесе дә кире кайта алмады. Яшь килен Хәлимә кайнатасы йортында торып калды. Бик тә чая, үткер телле, уңган хатын иде. Сугыш елларында бригадир йөген тартты.

Көне-төне эш артыннан чапканга күрә, аның чабаталары бер атнага да түзми, асты тишелеп, чукланып бетә. Чабаталарны Әхмәтҗан абзый үзе үрә һәм, налог, заем кебек түләмнәрне азмы-күпме җиңеләйтер өчен, Печмән базарында сата. Келәтендә аның һәрчак унлап пар чабата эленеп тора.

Беркөнне Хәлимә кайнатасыннан яңа чабата сорый. Тегесе әйтә:

— Әле күптән түгел генә ямап бирдем бит, килен.

— Әй, сөйләп утырасың тагын! Ямавың ике көнгә дә җитмәде. Менә кара үзең, киярлеге калганмы моның?— дип Хәлимә башак иләгенә әйләнгән чабаталарын картның борынына ук төртеп күрсәтә дә идәнгә атып бәрә.

— Тукта, турсайма әле,— ди Әхмәтҗан абзый.— Гел генә яңаны кияргә мулла кызы түгел лә син. Искесез яңа булмас. Чабаталарның кая киткәнен беләсеңме. Китер, тагын тиз генә рәтләп бирим.

— Инде, әткәй, мулла кызы булмасам да, бригадир башым белән ун кат ямаган чабата киеп йөрмәм. Кешедән оят,— дип Хәлимә тыз-быз чыгып китә.

Сәгать тә узмый, ул шыгырдап торган сап-сары яңа чабата киеп кайтып керә һәм, масаеп, билен боргалап ишекле-түрле атлап уза, сүзсез генә учак тирәсендә кайнаша башлый. Купшы килененең кыланышына хәйран калган карт аның аякларына карап сорый:

— Кайдан алдың?

— Миннулла абзыйдан.

— Алай... Күпме түләдең соң?

— Тәңкә ярым.

— Һе, кыйбат алган, комсыз. Мин Печмәнгә барып та бер сумга гына сатам. Йә, күрсәт, нindирәк икән.

Хәлимә чабаталарын салып кайнатасына тоттыра. Карт аларны капшап, бәргәләп-суккалап карый да идәнгә ыргыта.— Миннулла да чабата үреп маташкан була. Бу килбәтсезләр илле тиен дә тормый.

Кулларын биленә терәп, серле елмаеп торган килен кайнатасы янына килеп утыра һәм хәйләсен ачып сала:

— Ачуланма инде, әткәй. Чабаталарны мин келәттән генә алып кердем.

Әхмәтҗан абзый корт чаккандай сискәнеп китә, йөзе бер агара, бер кызара, килененә зәһәр тасыраеп карап ала һәм бераз башын иеп утыргач, Хәлимәнең аркасыннан сыйпап әйтә:

— Ай-һай, җен икәнсең, килен. Рәхмәт, карт тилегә акыл бирдең...

## Сыйпый да елый, сыйпый да елый

Ногман агай кызы Нәҗибә сәеррәк холыклы иде. Карап торырга сылуның сылуы, эшкә уңган, өлгер. Һәркемгә ягымлы мөгамәләле. Әмма артык тынгысыз, кыбырсык. Кешегә чем-кара күзләрен текәп, беренче тапкыр күргәндәй сынап, озак карап тору гадәте бар. Эш белән мәшгуль булган чагында да, тик торганда да авызы ерык була, гел эчтән көйләп-такмаклап, юктан-бардан балаларча кулларын чәбәкләп, кеткелдәп көлүдән туктый алмый. Шуңа күрә баштарак чибәрлегенә һәм эшчәнлегенә сокланып, күз салып йөргән авыл егетләре дә соңрак аның кыйланышларын ошатып бетермәделәр, акылга җиңелрәк дип санадылар.

Ә кызның яше инде егермедән узган, кияүгә бирергә вакыт. Ата-анасы, авылда кияү табудан өмет өзеп, кайгырып торган көннәрнең берсендә боларга Бөгелмәдән илле яшьләрдәге танышлары Шәяхмәт, Керкәлегә барышлый хәл белешергә туктый. Ул вак-төяк белән сәүдә итүче хәлле кеше. Ике ел элек хатыны үлеп, тол калган. Балалары юк. Сүз арасында кунак хатынсыз яшәүнең авырлыгы турында да әйтеп куя.

— Нигә өйләнмисең соң алайса?

— Икенче кат өйләнергә кыенсынып торам шул. Бала-чагалы тол хатын алырга теләмим, ә кыз кеше килмәс.

— Һи, килмиме соң! Карт түгел бит әле син, теләсәң кайсысы кинәнеп барыр.

Ата-анасы кунак белән сөйләшеп утырганда Нәҗибә, эш табып, мөлаем елмаеп, күзләре белән кунакны йотардай булып, берничә тапкыр почмактан түргә йөреп уза, сәкегә җәйгән ашъяулыкка әле бер, әле икенче ризык китереп куя. Моны күзәтеп торган Шәяхмәт, әллә шаяртып, әллә чынлап:

— Алай дисез дә бит, үзегез менә бу кызыгызны миңа бирер идегезме?— дип әйтеп ташламасынмы!

Менә сиңа кирәк булса — иске авыздан яңа суз. Ата-ана аптырап кала. Ә кыз, кунакка утлы күзләре белән атып, пырхылдап почмакка кереп китә.

Нәҗибәнең кыланышыннан тәкъдимгә каршы тормаячагын төшенеп алган Шәяхмәт инде җитдиләнеп җавап бирә:

— Әйе, кызыгыз миңа бик ошады. Бәлки мине кияү итәрсез?

Кара син аны, чынлап сорый түгелме соң? Һе, нигә бирмәскә кызны? Күптән белгән ипле кеше, җегәрлеге бар кебек, япа-ялгыз зур йорт биләп яши, азып-тузып йөрми, байлыгы да җитәрлек. Аннан да кулай кияүне каян табарсың? Сорап килүчеләр дә күренми бит әле!

Шул рәвешчә бераз уйланып торгач, ата-ана кызны дәшеп ризалык сорый. Кыз исә, шатлыгын кая куярга белмичә, уңай җавап бирә. Ике көннән Шәяхмәт Керкәледән кайтышлый Нәҗибәне атасы-анасы белән бергә Бөгелмәгә алып та китә. Шунда никах укытып туй ясыйлар.

Өч-дүрт ай узганнан соң, ата-анасын сагынган Нәҗибә, бик шәп ат җиккән чанага утырып, туган йортка кайта. Танымаслык булып тазарган, битләре ут кебек янып тора, шәһәрчә купшы киенгән. Үзе бер туктаусыз көлә, тик элеккечә түгел, тыйнаграк, үз бәһасын белебрәк. Кочаклашып күрешеп, кызлары алып килгән күчтәнәчләр белән сыйланып чәй эчкәндә, сорашу, хәл белешү башлана.

— Нигә ялгызың гына, кызым? Кияү килә алмыймыни?

— Ул Чыршылы базарына китте. Сезгә бик күп сәлам әйтергә кушты.

— Рәхмәт инде. Хуш, ничек торасыз, канәгатьме?

— Канәгать, әткәй. Бик әйбәт яшибез, җитешмәгән нәрсәбез юк, Аллага шөкер.

— Кияү абижайт итмиме, яратамы үзеңне?

— Шундый ярата, һи-һи-һи, шундый ярата. Күлмәгемне салдырта да, итәгенә утыртып сыйпый да елый, сыйпый да елый, һи-һи-һи.

— Әстәгъфирулла,— ди анасы хәйран калып. Бигрәк ярата икән алайса, рәхмәт төшкере. Яткач та шулай итәме?

— Әйе, әнкәй, шулай ярата, һи-һи-һи.

Эшнең асылын шәйли башлаган Ногман агай башта көрсенеп куя, ә аннары, астыртын гына елмаеп, кызыннан сорый:

— Дус-ишләрегез бармы соң? Кунаклар килгәлиме?

— Күп, әти, дусларыбыз еш килеп йөриләр, ямансылап торырга бирмиләр.

— Яшьләре дә буламы?

— Булмаган кая,— ди беркатлы Нәҗибә.— Шәяхмәт сәфәргә киткәндә, аулак өй ясыйбыз, күңел ачабыз, һи-һи-һи.

«Алар да сине яраталармы?»— дип сорамакчы булса да, Ногман агай уңайсызланып, телен тыеп кала.

## Намазны боздырырсың!

Хәйрулланың Идияттән әҗәткә ун сум акча алуына шәт инде ярты ел булгандыр. Бирми дә бирми генә бит, мәртәт. Урамда очратып сораган саен: «ярар, түләрмен, әз генә көт инде», дип тизрәк сыпырту ягын карый. Идият әллә ничә тапкыр аның өенә дә керә, тик һәрвакыт Хәйрулланың сәке өстендә намазлык җәеп утырган чагына туры килә. Тәрәзәдән Идиятне күрү белән намаз укырга керешә икән, хәйләкәр. «Мәчеттә күренгәне юк үзенең, кара син аны, диндар кеше икән»,— дип уйлый Идият. Бик озак көтеп утыра ул ишек янындагы эскәмиядә, намазны өзәргә базмыйча әдәп саклап. Аннары түземлеге җитмичә, күңелдән сүгенә-сүгенә кайтып китә.

Бу көнне кергәндә дә Идият бурычлы кешесен намазлык өстендә күрә. Сәлам бирүенә каршы теге күзләрен акайтып кына ала. Бер утырып, бер басып, кулларын йә колакларына күтәреп, йә тезләренә куеп мыгырдана, дога укыган була. Сәҗдәгә киткәндә хәтта кирәгеннән артык озак башын күтәрмичә ята.

— Хәйрулла, бетерәсеңме инде намазыңны? Акча кирәк иде бит.

Намаз укучы башын борып тасырая да, тагын турсаеп бер ноктага текәлә. Ниһаять, Идият тә пырдымсызлана, озын таягы белән Хәйруллага төрткәләп, бер сүзне кабатлый.

— Йә, бетер инде. Сине көтеп торырга вакытым юк. Намаз вакыты да түгел ләбаса, ни өйлә, ни ахшам. Кыланып утырма, акчаңны түлә,— дип теңкәсенә тия.

Тәкаты корыган Хәйрулла, намазлыкка утырган килеш, кыбырсынып куя һәм җикеренеп кычкырырга мәҗбүр була:

— Чукынма, Идият, майттыпыр, намазны боздырасың!

## Кунакчыллар

Әйе, Идият кунакчыл кеше иде. Шуңа күрә дә якын күреп, ашкачәйгә чакыручылар күп була. Күршесе тимерче Ишми дә, дәшә бер мәлне. Тик сые бигрәк сыек була — яртылаш бушаган «чәкүшкә» дә, кара ипи белән яшел суган. Кайнар бәрәңге дә куймаган.

— Нилектән бик коры тотты әле бу Ишми? Хәле юк дисәң, алачыкта азмы-күпме акча эшләп тора. Хатыны саран күрәсең, күзгә дә чалынмады,— дип үз-үзенә уйлана Идият һәм моннан ары кереп мәшәкатьләмәскә карар бирә.

Озак та узмый, Идиятләрдә тагын әйбәт кенә сыйланып саубуллашканда Ишми, ничектер уңайсызланып, йөзгә карамыйча гына әйтә:

— Безгә дә кергәлә, күрше.

— Рәхмәт, Ишмөхәммәт,— ди Идият.— Мин сиңа бер гыйбрәтле мәзәк әйтим әле, авырга алма. Сарбай белән Акбай дуслашып, көн саен күрешеп яшиләр, ди. Чабышып-уйнап аргач, аерылышканда Акбай Сарбайга әйтә икән: «Иртәгә безгә кунакка кил. Хуҗам басуга тирес чыгара, артыннан ияреп йөрербез...»

## «Мин дә китәм!»

Шакирҗан мулланың бер гадәте халыкны туйдырып бетерде. Мәчеттә намаз уку тәмамлану була — ул, мескенләнеп, үз язмышыннан сукранырга керешә. Сәбәбе дә бар, әлбәттә. Тормыш хәле бик шәптән түгел, имам дәрәҗәсенә тәңгәл килми. Безнең авылга аны әллә кайдан китереп куйдылар. Яңа гына Бохара мәдрәсәсен тәмамлап указ алган, диделәр. Яше утыз биш-кырык тирәсендә, хатыны, ике баласы бар.

Халык аңа йорт салырга, ат сатып алырга ярдәм итте, авыл советы күпмедер җир бүлеп бирде. Янәсе, әйдә, мөхтәрәм хәзрәт, мәчеткә кереп көненә бер кичке намаз, атнага бер җомга гаете уздырып кына, хәерсадакага өметләнеп кенә яшәмә, иген игеп, мал асрап көнеңне күр, балаларыңны туйдыр. Син әле яшь, җәкле кеше, остабикәңне дә крестьян эшенә җик — мәхәллә халкы шулай уйлады.

Нишләмәк кирәк, муллага башка чара калмаган иде. Сүз дә юк, җиңел түгел аңа. Һәм гарьлек тә. Мулла башың белән, гади мужикка ошап, таңнан торып чабата ки дә, кичкә кадәр сабан сөр, чәч, чүп ута, печән чап, урак ур, көлтә бәйлә, ындырга ташып чабагач болгатып

суктыр, имеш! Тавык чүпләп бетермәслек икән бу крәстиан эше. Кеше яллап эшләтер идең — ашатырга, түләргә кирәк. Өстәвенә Совет власте ялчы тотучыга кырын күз белән карый. Ничек зарланмассың мондый язмышка?!

Бу җомгада да, дога кылып, таралышырга дигәндә, мулла мәчет картларыннан беразга кузгалмый торуларын үтенә. Һәм, төрле аятьләрне кабатлый-кабатлый гомуми вәгазь сөйләп алгач, шаккатырлык белдерү ясый:

— Мин авылыгыздан китәргә карар кылдым, җәмәгать. Үзегезгә мәгълүм, имам-хәзрәтләр — Аллаһтәгаләнең җирдәге ышанычлы вәкилләре, Мөхәммәт пәйгамбәрнең варислары. Аларга иң изге вазифа-ислам динебез сагында тору, аның барча кануннарын вә йолаларын гамәлгә ашыру вазифасы йөкләнгән. Мөхәммәт Галиәссәлам мулланы хөрмәт итәргә, дини эшләрен бүлдермәскә, дөньяви мәшәкатьләрдән бушатырга, иминлеге турында кайгыртып торырга, бөтен кирәк-ярагын тәэмин итәргә кушкан. Иллә-мәгәр үкенеп, күңелем әрнеп әйтергә мәҗбүрмен, җәмәгать, нигәдер сез пәйгамбәребезнең васыятен оныттасыз. Олуг хәзрәт Габдрәхим Утыз-Имәни дә авылыгызда ярлы тормыш кичергән. Ә мине күрегез инде — хәерченең хәерчесе, валлаһи. Башка авыл хәзрәтләре затлы киенеп, чабыш атларга утырып йөриләр. Йортлары дисәң — хан сараемыни! Тамак туйдыру кайгысын белмиләр. Ә минем адәм рәтле чапаным, туным да юк, атымны җигеп чыгарга оят. Мулланың урыны — мәчет, җәмәгать. Ә мин басуда газап чигәм. Гыйбадәт кылырга, дин гыйльме эстәргә ара калмый, хәтта биш вакыт намаз укырга өлгерә алмыйм. Җиремне сөрергә, чәчәргә, урырга булышмыйсыз, ягарга утын китермисез, садаканы да тиенләп кенә бирәсез, юк, җәмәгать, болай яши алмыйм, күп түздем инде. Китәм!

Мәчет халкы башларын аска иеп, тирән уйга калып, ни әйтергә белмичә тыңлый мулланың озын монологын. Чыннан да, ни диярсең? Китмә инде зинһар, хәзрәт, бөтен гозыреңне үтәрбез, хуҗалык эшләреңнең барысын да үзебез башкарырбыз, сәдаканы да мулрак бирербез, дияр идең — болай да авыр йөк өстенә тагын авыр йөк тартасы, аның өчен эшләп җилкә чертәсе, үз балаларыңның авызыннан өзеп, әзергә-бәзерне көтеп ятучыларны туйдырып торасы килми. Хәер, бирмибез түгел бит инде — акчасын да, сарык тиреләрен дә, җеназа кием-салымнарын да бирәбез, өйдән-өйгә сыйлап йөртәбез. Шул җитми микәнни? Ярый, китә бир, дүрт ягың кыйбла дисәң — тагын яхшы түгел, мулласыз яшәү килешми. Совет власте да муллаларны кысмый, мәчетләргә тими бит әлегә...

Шундый уйга чумып, озак кына тынлык саклап, аптырашып утырганда, арткы рәттән:

— Җәмәгать, мин дә китәм! — дигән тавыш яңгырый. Борылып карасалар — вәт әкәмәт! — «зимагур» Самат басып тора. Өстендә чиккән якалы зәңгәр күлмәк, билендә чуклы тасма, аякларында хром итек, башына кузыйрыгын артка әйләндереп картуз кигән. Каян килеп чыккан соң әле бу? Авылда тормый, Донбасста шахтер булып эшли, елына бер тапкыр кайтып, тәрәзәләренә каккан такталарны куптарып өенә керә дә, бер атна авылны, урман-кырларны урап йөргәннән соң тагын китеп югала.

— Бәрәкәт, кайчан кайттың әле син? — дип сорыйлар аңардан, көлешеп.

— Төнлә кайтып төштем. Менә бергә җыелган урында үзегез белән күрешим, дип кергән идем.

— Әле кайтып өлгергәнең юк, китәсеңдәме?

— Китәм, җәмәгать, иртәгә үк китәм. Стансага барып каршы алмадыгыз. Кайтсам, ни күрим: ихатам җимерек, ишегалдын кычыткан баскан, йорт түбәсендә салам черегән, яңгыр үткәрә. Тәрәзә пыялалары ватылып беткән. Үпкәм зур сезгә, авылдашлар, оныткансыз пролетарыгызны, шул йортымны да карамагансыз. Китәм дигәч китәм, гаепләмәгез.

Саматның кырыс һәм җитди тонда «чыгышын» мәхәллә халкы, хәйран калып, нишләргә белмичә катып утырган мулла каршында шаркылдап көлүдән көчкә тыелып, тыңлый һәм чын мәгънәсен, кемгә ишарә ителгәнен яхшы аңлый. Кешеләрнең мәчеттән шулай бер-берсенә төртешә-төртешә рәхәтләнеп көлешеп чыгуы гадәттән тыш гаҗәп күренеш иде.

Шуннан ары Шакирҗан мулла авызыннан сукрану сүзләре ишетелмәде.

## Аяклы келәт

Борыннарына ис кереп, башлары әйләнә башлаган малай-шалайларның күңелен борчып интектергән нәрсә Хисмәт келәте иде.

Кичке уеннан соң һәрвакыт дүрт-биш кыз-кыркын шунда кереп бикләнә. Хәзерге су сату ларегы чаклы гына келәткә ничек сыешканнардыр. Алла гына белә. Үзләре тиз генә йокламыйлар, җырлыйлар, чырчыр көлешәләр, әкият сөйләп укмашып яталар. Ә «егетләр»не кертмиләр, шуңа боларның эчләре поша, ачулары кабара.

Бу усаллардан ничек үч алырга, дип уйлап-киңәшеп йөри торгач, үсмер буйдаклар бик шәп чара табалар. Кызларның тәмле йокыга чумуларын көтеп торалар да келәтне ике як астына таза киртәләр тыгып күтәрәләр һәм ындыр артына чыгарып куялар.

Таң аткач Хисмәт сеңлесе Миңсылу ишекне ачып чыкса — берни аңламыйча катып кала һәм тетрәнеп тавыш сала:

— Кызлар, хур булдык. Ятрәк торыгыз, келәтебез аякланган!

Бәрелә-сугыла, күзләрен ертып ишектән чыккан кыз-кыркын бу могҗизаны күреп чинаша-чинаша, кеше-кара күрмәсен дип, җән-фәрман өйләренә элдертәләр.

Келәтнең юкка чыгуына аптырап калган Хисмәт, Миңсылуның йөгереп кайтуын күргәч, хикмәтне аңлый, сеңлесенең йомшак җиренә бер-ике сыптыра да, ат җигеп, келәтен сүтеп алырга китә.

Келәт урынына кайтып утыра, янә кызлар куышына әйләнеп, егетләр йөрәгенә ут салып тора башлый.

## Мунча сые

Каршыбызда гына, зират кырында торучы Хәлфетдин абзый карчыгы белән һәрвакыт безнең мунчага йөриләр иде. Үзебезнекеләр чабынып-юынып чыккач, күршеләрне дәшеп, мунчадан соң чәй эчертеп җибәрәләр иде әти белән әни.

Бу көнне дә Хәлфетдин абзый безнең мунчадан тотен чыкканын шәйләп ала. Хозурлы хыялга бирелеп, вакыт җиткәнне көтә. Әмма, нигәдер, бүген чакыручы бик озак күренми. Хәлфетдин абзыйның эче поша башлый. Ниһаять, түземлеге тәмам бетеп, ул урамга чыга һәм капка янындагы бүрәнәдә тәмәке тартып утыручы Салих абзыйны күрә. Янына килә, исәнләшеп сорый:

— Бүген дә мунча якkансыз икән, Салих. Сөяк-саякны йомшартып алу яхшы булыр иде. Үзегез юынып бетмәдегез мени әле?

Бу сүзләргә Салих абый аптырап кала, чөнки бүген мунча ягылмаган. Әти белән әни өйдә юк, Сугышлы Барый абзыйларда кунакта. Абый белән Зәйнәп җиңги үзләре өчен генә атна уртасында мунча ягып мәшәкатьләнмәгәннәр. Ни әйтергә хөрмәтле күршегә? Бер мизгел уйлап торгач, Хәлфетдин абзыйның җорлыкны яратучан, шаяртуын күтәрүчән кеше булуын искә алып, Салих абый аның белән мәзәк кылып алырга сылтау таба.

— Әйе, без юындык инде,— ди ул. Менә сезне дәшәргә чыккан идем, бер папирос кына тартып алыйм дидем. Килегез, рәхәтләнеп чабыныгыз. Пары да кызу, җылы суы да күп.

Хәлфетдин абзый кинәнеп өенә кереп китә һәм тиздән Минҗамал абыстайны ияртеп килеп тә җитә. Тик мунча алдында чишенеп эчкә керсәләр — мунча суык.

— Бу ни эшең, карт тиле? Нигә якмаган мунчага алып килдең?— дип җикеренә башлый Минҗамал абыстай, дер-дер калтырап.

— Салихтан сораштым бит, карчык. Яктык, үзебез юынып чыктык, бик тә кызу, диде. Кара син аны, алдаган икән, явыз. Аннары, ягылганын үз күзем белән күргән идем ләбаса.

— Күргәнсең, пычагым! Әйдә, йәтрәк ычкыныйк моннан. Кешефәлән күрмәсен тагы.

Шулвакыт Хәлфетдин абзыйның башына бер уй килә: туктале, янәшәдә, ызан аша гына Матша Гарифның мунчасы бар лабаса. Төтен шуннан чыкмадымы икән?

— Син, карчык, чак кына утырып тор,— ди дә, ул Гариф мунчасына юнәлә. Ишеген ачып җибәрсә — менә бәхет!— аннан эссе һава бәреп тора. Картның кул селтәп дәшүен күргән карчык, тирә якка каранакарана, йөгереп килеп җитә. Алдакчы Салихка үч итеп, алар рәхәтләнеп чабынып-юынып чыгалар.

«Болар нигә суык мунчада озак чуалалар икән» дип, исе китеп һәм үпкә белдерүләрен котеп, пошынып торган Салих абый, карт белән карчыкның кызарган битләрен сөлге белән сөртә-сөртә, уфылдап әкрен генә кайтуын күреп, тагы гаҗәпкә кала.

— Мунча әйбәт булдымы, Хәлфетдин абзый?

— Һи, энекәш, әйбәт булмаган кая! Бик кыздырып яккансыз, рәхмәт яусын үзегезгә,— ди карт берни булмагандай, ачык елмаеп. Ә Минҗамал абыстай бер сүз дә әйтми, ерык авызын яулык очы белән каплаган, күзләре генә хәйләле елтырый.

— Бик шәп чабындык, Салих, хәтта хәл бетте, тамак кипте. Чәй эчмичә өйгә кайтып җитеп булмас ахыры.

— Әйдәгез, рәхим итегез, кадерле күршеләр,— ди Салих абый, бер гөнаһсы да юк кеше булып.— Көтеп торабыз, Зәйнәпнең самовары әзер. Ләкин ничек суык мунчадан парланып, тиргә батып чыгу мөмкин икән?— шуңа тиз генә төшенә алмады мәзәкче.

### «Зыянлылар»

Авылга килгәндә дә, барышлый да Шөгер һәм Лениногорск районнары «начальниклары» һәм Казандагы минем дус-ишләр безнең йортка тукталмый китмиләр иде. Әтинең сые һәрвакыт әзер, әнинең казаны һәм самавыры көн буе суынмый. Әти кунаклар белән шаяртып, төрттереп сөйләшергә ярата. Аның гомере буе эчен пошырган һәм ачуын кузгаткан нәрсә күп кенә «җитәкчеләр»нең, бодайны арыштан, кәҗәне сарыктан аера белмәгән килеш, колхоз эшләренә тыкшынып, теләсә нинди мәгънәсез боерыклар биреп, комачаулап йөрүчеләр булды. Шуның өчен ул аларны ачы тәнкыйтьләүдән дә тартынмый торган иде. Ә тегеләр тыңлыйлар, бәхәсләшәләр, акланалар һәм шул ук вакытта, картның сүзләре хакыйкатькә якын икәнлеген шәйләп, танырга мәҗбүр булалар.

Шулай берчак «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Шәмси Хамматов белән Төзүче инженерлар институтының кафедра мөдире Абдулла Шәйдуллин хәл белешергә, миннән сәлам тапшырырга дип, әти янына керәләр. Якты йөз белән каршы алып чәй эчәргә утыргач, әти боларга сорау бирә:

— Нинди йомыш үтәп йөрисез соң?
— Минә райондагы эшләр белән танышырга килдек,— ди Шәмси.
— Тикшеренәсез, күрсәтмәләр бирәсезме?
— Әйе, ярдәм дә итәбез.
— Алай икән, вәкилләр ызначит. Өйрәтеп, әмер биреп йөрүче акыллы башлар биниһая ишәеп китте шул. Ничек атыйлар әле күп белдекле, фәһемле кешеләрне?
— Галимнәр, интеллигентлардыр инде.
Әти күзләрен хәйләкәр елтыратып ала, исе киткән булып сорый:
— Бәрәкәт, «интилеэтләр» диденме?
— Юк ла, бабай, белмәмешкә салынып, безне хурламак буласың ахры. Малайларыңа да тел тидерәсең. Интеллигентлар татарча зыялылар була.
— Әһә, монсы аңлашыла төшә, «зыянлылар» икән. Дөрес тә бит, файдасыннан бигрәк зыяны күбрәк.
Кунаклар уңайсызланып, бер-берсенә карашып алалар, ни әйтергә белмичә аптырап торалар.
— Ну, бабай,— ди Шәйдуллин,— мине усал телле кеше диләр, ә син бигрәк тә кычыткан телле икәнсең.
— Берүк үпкәләмәгез инде, оланнар, шаяртып әйтүем. Бәрәкәтле зыялыларны да күргәнем бар. Тик ялганнары, кәжүнни акча туздырып, акыл сатып, теләсә кая борын тыгып йөрүчеләре күбрәк шикелле. Әйткәнем сезгә кагылмый, мөгаен, яхшы ният белән килгәнсездер. Аннары, бу заманда ачы телле булмыйча да мөмкин түгел. Гаделсезлеккә ачу килә, телемне тыя алмыйм. Ике көнгә бер сельсоветка яисә правлениегә кереп тиргәшеп кайтмасам, җаным тыныч булмый.
— Ничә яшьтә соң син бабай?
— Мин үзем яшь әле, тик минә кызым гына картайды, житмешкә җитеп килә.
Табында шаркылдап көлешү яңгырый.

## Сарыкны кем суйган?

Бервакыт Миннәхмәт абзыйның сарыгы югала. Көтүче Шәехне гаепләр иден, аның басуда бер генә малны да калдырып кайтканы юк. Димәк, авылга кайткач, кемнеңдер сарыкларына ияреп кергән дә, пычакка эләккән аңгыра хәйван. Сарыкны кем суеп ашаганын тәгаен белү кыен. Шулай да төрле имеш-мимешләр рәтендә Хапиз авызыннан чыккан шик өстенлек ала:
— Бу Мингали эше булырга тиеш!
Моңа ышанмасалар да, авыл советы рәисе Котлый белән тагын бер-ике кеше Мингали йортына кереп карарга, эзләнергә мәҗбүр булалар, тик җинаять кылуда гаепләрлек нәрсә тапмыйлар.
Әлбәттә, бу гаделсезлеккә Мингалинең ачуы куба. Аннан да бигрәк хатыны Мәхбүҗан хурланып елый. «Нигә соң әле бу Хапиз миңа ябага»— дип уйлана Мингали.— Аңа бер начарлык та эшләгәнем юк бит. Үзенең бүрене янмый микән?»
Икенче көнне бәрәңге күмәргә кәтмән сораган булып, Мәхбүҗан Хапизларга керә, үткер күзләре белән каранып алганда этләре янында яңа гына кимереп ташланган сарык тоякларын күрә һәм кайтып иренә сөйли.
— Һәй, кабахәт нәстә, үзенең җинаятен дә иплән яшерә белмәгән, юньсез,— ди Мингали.— Ярар, карчык, син шауламa, акылга утыртыйк әле үзен.
Берничә көн узгач, кичен Хапизны ул үз өенә чакыра:
— Кер әле, Хафиз абзый, сөйләшеп утырырбыз,— ди ул үпкә-ачуның тамчысын да сиздермичә.

Керә Хапиз. Мәхбуҗан өстәлгә ит белән бавыр тутырып зур табак һәм кружкаларга салып шулпа куя. Мингали бер «чәкүшкә» чыгара.

— Син,— ди хуҗа,— юкка минем гайбәтне сатасың, күрше. Дуслыкны бозмыйк инде юк-бар белән. Миннәхмәт сарыгын урлаучы мин түгел. Әмма ләкин итсез яшәмибез. Менә әле генә сарык суйдым. Әйдә, сыйланыйк бер рәхәтләнеп.

— Гафу итә күр инде, дустым, ялгышканмын,— ди кунак, бер-бер артлы ит, бавыр кисәкләрен шулпалап йота-йота.— Ай-һай симез булган сарыгың.

— Иң симезен сайлап суйдым. Әйдә, син тартынып торма, үз сарыгыңның итен ашаган кебек аша.

Ашап-эчеп туйгач, Хапиз рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгала. Мингали аны фонарь кабызып озата чыга, чолан идәнендә тәгәрәп яткан сарык башын яктырта. Хапиз анда үз тамгасын таный, күзләре шар була, тыны кысыла, ярсып кычкырып җибәрә:

— Бәрәкәт, минем сарык башы бит бу!

— Соң, әйттем ләбаса, үз сарыгыңның ите кебек аша, дидем.

— Каһәр, суккыры, кайчан урладың?

— Бүген. Нәкъ синеңчә эшләдем. Көтү кайтканда үз сарыкларыма кушып керттем дә суйдым. Син әле сарыкларыңны барларга өлгермәгәнсеңдер.

— Мәлгунь икәнсең, карак актыгы!

— Тагын ялгышасың, Хафиз абзый. Минем беркайчан да кеше малына тигәнем юк. Бусын да яла яккан өчен ачу итеп эшләдем. Синең кебек яшереп та маташмыйм. Мин әле урлаган сарык ите белән хуҗасын тыгынганчы сыйладым. Ә син Миннәхмәттән сарыгыңның башын да кызгандың. Йә, нишләмәк буласың хәзер? Судка бирәсеңме?

Тәмам аптырап һәм хурланып калган Хапиз башын иеп бераз таптанып тора да, кулын селтәп чыгып китә. Иртән таңнан торып, ул сарык түшкәсе белән тиресен Миннәхмәткә илтеп бирә. Мингали дә калган итне хуҗасына кертә.

## Кендек кемгә тиде?

Бигрәк тә кызу канлы, дуамал кеше иде Гайнан агай. Әллә нинди сылтаулар табып, йортында атна саен бер җәнҗал чыгармаса, күңеле булмый. Хатынының һәр эшеннән гаеп эзләп, бәйләнеп кенә тора. Еш кына аңа кул күтәрә. Дөрес, Рәхимә дә җебегәннәрдән түгел, ире сүз кузгатса — чәчрәп тора, бер сүзгә каршы унлап зәһәрен таба, тукмый башласа, кулыннан ычкынып, теләсә нәрсә белән тондыра да, улый-улый, урамга йөгерә. Моны күргән кешеләр белә: ул шулай, елый-елый, чишмә буйларын әйләнеп кайтыр да, берни булмагандай, йорт эшләренә керешер. Ә авызын кыйшайтып сәкедә утырып көткән ире, урыныннан кузгалыр да, Рәхимәнең калку җиренә генә кагылып, абзарга чыгып китәр.

Ни сәбәптәндер, бүген тагын Гайнаннар өендә давыл куба. Өй эчендә талаш-бәрелештән соң Рәхимә, үкереп елап, ишегалдына атыла, ә артыннан Гайнан куа чыга. Һәм тиз генә капка янына барып баса. Урамга чыгып котылу юлы киселгән Рәхимә, качар урын табалмыйча, әле тегендә, әле монда сугылып йөгерә. Шул арада Гайнан җирдә яткан тимер кендекне күреп ала да хатынына тондыра.

Кирәк бит, бу мизгел Рәхимәнең ишегалдында бу тамашаны карап торган бозау яныннан чабып узган чагына туры килә. Кендек бозау маңгаена эләгә һәм аны җиргә ега. Күзләре шар булган Гайнан бозау янына килеп чүгәли һәм ярсып кычкыра:

— Нәрсә катып калдың? Пычак китер йәтрәк!

Бозауны суя Гайнан. Рәхимә, кыйналган чактагыдан да ныграк ачынып елый-елый, ирен тирги:

— Харап иттең бозауны, котырган эт!

— Үзеңдә гаеп, аңгыра баш,— ди Гайнан.— Алдыңны-артыңны чамалап чабарга кирәк иде. Шул бозауны да күрмәскә, күзең чыкмагандыр бит!

Ир белән хатын бер-беренә карашып торалар да, шаркылдап көлеп җибәрәләр.

Тик озакка булырмы икән бу солых?

## «Травиата»

Утызынчы елларда татар «зыялылары» арасында, гасырлардан килгән исемнәрне чит күреп, балаларга яңа, «цивилизацияле» исемнәр кушу гадәткә кереп киткән иде. Маркс, Энгел, Илис, Владлен, Карл, Земфира, Клара, Марс, Джонс, Альбина, Рафаэль, Долорес, Радий, Сталина, Рифа, Феликс, Диана, Ганслар гына түгел, Илкам (электрлашкан коммунизм), Ардинат, Трактор, Фаворит, Индустрия, Аристта, Ракета, Рево, Ариоза, Франтик, Грация, Мимоза, Медем, Фея, Ялкын, Таң, Памир кебек исемнәр йөртүче егетләр-кызлар күбәеп китте.

«Зыялылар»га ияреп, гади кешеләр дә шул моданы үзләштерә башлады.

Бервакыт авылга кайткач, мине бәбәй туена чакырдылар. Яшь хатын (исемнәрен әйтмим әле) кыз тапкан икән. Баланы күреп алгач мин:

— Исеме ничек гүзәлнең?— дип сорадым.

— Травиата куштык,— диде әтисе.

Мин, авыз ачып, аптырап калдым. Хур иткәннәр ич кызларын. Әйтергәме бу хакта, әллә тынып торыргамы? Юк, әйтмичә ярамый.

— Травиата дигән сүзнең мәгънәсен беләсезме соң?

— Ник белмәскә, беләбез. Бер опера шулай атала.

— Ялгышкансыз бит, дуслар. Беренчедән, сезнең кызыгыз опера түгел. Икенчедән, кеше исемнәре белән аталган опералар бар анысы: «Евгений Онегин», «Кармен», «Иван Сусанин», «Алтынчәч», «Җәлил», «Самат» һ.б. Ә «Травиата» хатын-кыз исеме түгел, ул «типтереп яшәүче хатын» дигән мәгънәне аңлата. Алыштырыгыз кызыгызның исемен.

Күзләре шар булган ата хатынына усал карап:

— Кайдан казып чыгардың шул исемне, тиле баш?!— диде дә, авыл советына йөгерде.



## Җәүдәт Сөләйман

### Казан елгасында су түгелдер

Казан елгасында су түгелдер,
Кургаш тулы ярлар арасы.
Киң дә түгел, чоңгыллар да тынган,
Ничек аны ары чыгасы?

Матәм чорын ачып беравык,
Күтәрелде тарих пәрдәсе,
Төер булып бәрде тамакка
Уналтынчы гасыр ядрәсе.

Юк, булмаган берлек: төгәл җавап,
Ике яктан килгән бер татар,
Түбәтәй бер — фикер-акыл төрле,
Шул ук сәбәп бүген — шул хәтәр!

Санлы түгел, саллы булсак икән,
Алтын түгел байлык — зыялы!
Шул вакытта кыл да сыймас рәткә
Дары тулы базлар сыярмы?!

Ә бүгенгә — сорау өсте сорау,
Йә, кайсыгыз белә җавабын?
Биш татарның булешмичә, бердәм,
Бармы берәр йорт-җир корганы?

...Кис тә яндыр: түзә — сабыр,
Умырткасы булса — камыр,
Шәҗәрәдә мәллә шаукым,
Шартлауданмы тузган акыл?
Чәчелгәндер, очкан фикер,

---

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) — *галим, Казан университетының теоретик кибернетика кафедрасы доценты. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә.*

Әле башы калган, шөкер,
Калган гәүдә, яралы тел,
Җанмы соң бу, әллә соң көл?
Ясалып бетмәгән дәүләтем,
Өлгереп җитмәгән милләтем,—
Иртәрәк тузган шул таш чүлмәк,
Алтын ук булмаган ул, димәк,
Селтәмик барын да Урдага,
Гаеп бар бүген дә уртада.
Буаргамы дисәң бер-берсен,—
Тукмаргамы дисәң бер-берсен,—
«Йоклаганмы, үлгәнме»,— дисең?—
Күз ачып та өлгерәлмисең!

Теле — чарлаган пәке,
Каезлый безнең рәтне,
Ерак бармый, үз итеп,
Татарын ята тетеп...

Казан елгасында су түгелдер,
Кургаш ялгый ярлар арасын,
Кин дә түгел, чоңгыллар да тынган,
Насыйп микән ары барасы?

## Курай моңы

Ә курайда моңлы ла уйнадың,
Өзеп-өзеп өрдең җанымны,
Таш йортларга башкорт моңы үтте,
Юкәләргә акты сарылып.

Балдай куе, салмак бер көй иде,
Курайчысы чыккан исемнән,
Ә курае канга сеңгән, эреп,
Шуңадыр ла йөрәк җилсенә.

Аһ, бу көйгә чумып-йөзеп булыр,
Канатланам, сөям-сөеләм.
...Өфеләрдән кайтып барыш, очып,
Чалкан ятып курай көенә.

## Ник сорыйсың, телеп йөрәгем?

Яныбызда гына тал-тирәк,
Тал-чыбыкның кайсы пешерәк?
Бергә чакта юк шул кадер-сан,
Кабат кайтсаң иде, багалмам.

Бергә чакта юк шул кадер-сан...

Яныбызда гына тал-тирәк,
Былбыл тавышлары бик сирәк.
Былбыл җыры миңа бер булсын —
Тик соңгысы гына булмасын.

Тик соңгысы гына булмасын...

Яныбызда гына тал-тирәк,
Күңел өчен тагын ни кирәк?
Ник сорыйсың, телеп йөрәгем,
Тәңре алды миңа кирәген...

Ник сорыйсың, телеп йөрәгем?..

## Милләтпәрвар дустым Илсур истәлегенә

* * *

«Дошман сигез, без тугыз»,— ди шагыйрь,
Шагыйрь сүзе хагын хактыр да,—
Ник соң әле бирдек шул тугыздан,
Мылтык терәп, берсен атырга!

Ялгышлык та түгел, юк, язмыш та,—
Бу — мәңгелек сугыш: төн йә көн!
Кизәндең син, дошман, иманлеккә,
Иманлекне кыру ниятең!

Кизәндең син, дошман, киләчәккә,
Милләтемнең алып асылын,
Татар-йортның имән субаена
Ут атырга җитте акылың!

Ядрәң тиде, әмма максатыңа
Ирешмәдең, дошман, бел шуны!
Ядрәң белән безнең күңелләрдә
Мәңге үлмәс иттең Илсурны!

* * *

«Кыйгак, кыйгак, каз кычкыра»...
Җырың һаман күңелдә,
Бүген таңга ал нур түгел,
Аккош каны түгелгән.

Каз кычкыра: «Кыйгак, кыйгак»,
Уятырга теләптер,
Иртән күккә ашты кояш,
Ул шул синең йөрәктер.

Бәллүр чаңдыр күк гөмбәзе —
Юк түзү чыңлавына,
Алып китте язмыш, төреп
Яфраклар буранына.

* * *

Шигырь дәрьясында йөзгән
зур кораблар —
Тарих ләме йоткан,
бик тирән...
Корабларны күмгән дулкыннарда
Бата-калка йөзә моң көймәм.

Ишетелми калмас кораблардан бер-бер аһәң...

Дәрья бүген шадра көзге кебек,
Аягүрә йөрми дулкыннар,
Әле чыгар, дулап, җил-давылы,
Ыржаерлар әле упкыннар.

Дәрья бит ул, дәрья ярсып тора...

Асты-өскә килеп дәрьяның,
Күтәрелер төптән кораблар...
Китап башы түгел, ә дәвамы
«Йосыф җыры» булыр, «Пар атлар»...

Кемнәр моңы сеңгән икән Кол Галигә?

Мин көймәне шуңа чыныктырам,
Җилкән булсын аңа моң-зарым,
Әйдә, давыл, ула! Үкер, упкын!
Сыналырга тиеш елларым...

Корабларның юлын
бер күрәсе иде,
Дулкын күмгән корабларда
бер йөзәсе иде...

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Быел, 1994 елның беренче яртысында, Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды җыелырга тиеш. Шул уңайдан редакция язучыларга берничә сорау белән мөрәҗәгать итте:

***1. Язучыларыбызның XI съезддан соң үткән биш елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?***

***2. Әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләрдән Сез канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары ни дәрәҗәдә үтәлде?***

***3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?***

***4. Алда торган съезддан Сез нәрсәләр көтәсез?***

***5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?***

Түбәндә редакциягә килгән беренче җавапларны тәкъдим итәбез.

## Әмирхан Еники:

1. Укыр нәрсә күбәйде, укуым бик әкренәйде, шул сәбәпле барсын да укырга өлгерә алмыйм... Күрәм, журнал битләрендә зур-зур әсәрләр чыга тора — мин шуңа беркадәр көнләшеп тә һәм гаҗәпләнеп тә утырам. Димәк, әдәбиятыбыз яши, хәтта рухи яңара да бугай — бирсен алла!..

2. Дөнья бик нык үзгәрде. Элекке без белгән Язучылар союзы да, китап нәшрияты да юк инде... Исемнәре калса да, җисемнәре бөтенләй башка хәзер... Кыргый базар мөнәсәбәтләренә күчеп маташу аларны коточкыч авыр хәлгә куйды. Нәшрият, мәсәлән, тирән бөлгенлеккә төште, китап чыгару елдан-ел кими бара... Язучылар берлегенә килсәк, ул хәзер бик зур, бик матур бер буш бинага әйләнде. Аның эчендә утыручылар бәлки нидер эшли дә торганнардыр, әмма, миңа калса, язучыларны ул үзенә тартмый да, кызыксындырмый да... Каләм ияләре хәзер үзләренә кирәкне читтән эзлиләр. Дәүләт тирәсенә елышу, номенклатурага эләгергә тырышу кайберәүләрне аеруча мавыктыра булса кирәк... Мәгәр мин моны берлек җитәкчеләренең гаебе димәс идем. Бу — заманыбыз кәсафәте.

3. Безгә иң кирәге әдәби фонд иде. Әмма ни үкенеч, фондыбыз сүнде, бетте, үлде дияргә дә була. Аңардан күргән игелекне сагынып искә төшерергә генә калды: кая китте ул Дубултылар да Пицундылар?!. Яңадан тергезеп булса иде үзләрен! Мөстәкыйль Татарстан халыкка рухи вә мәгънәви ризык бирүчеләрен саклый һәм кайгырта алачакмы, әллә инде без яңа байларның күзләренә карап, кул сузып торырга тиеш булачакбызмы?

4. Алда торган съезддан, белмим, нәрсә көтәргә дә. Съезд килеп җиткәнче вакыйгалар кайсы якка табан авышыр да, нинди үзгәрешләр китереп чыгарыр — намәгълүм! Шуңа күрә алдан юравы бик читен.

5. Безнең Союзны Сталин оештырган иде. Озак еллар ул төзеп калдырган системага яраклашып яшәдек. Хәзер кемгә, нәрсәгә яраклашырга?.. Иске система җимерелде, яңасы туа алганы юк. Әгәр дә ки базар мөнәсәбәтләре, ниһаять, урнаша калса, язучының да яшәү шартлары бөтенләй башка булачак дип фараз кылырга кирәк. Аңа инде иске Союзыбыз заманындагы шикелле власть канаты

астында, шуның биргәненә шөкер итеп, язып кына ятарга туры килмәячәк... Киресенчә, химаясыз калу нәтижәсендә, ул үзенең ижади һәм ижтимагый мәнфәгатьләрен теше-тырнагы белән үзе якларга тиеш булачак. Ничек итеп, берлеккә оешыпмы, әллә һәркем үзе белгәнчәме? Ахыр чиктә безгә дә илһамланып язганнарыбызны гади товар итеп сатарга туры киләчәк. Ләкин безнең бит әле хәзергә Шәрәфләр, Кәримовлар, Хөсәеновлар кебек «товарыбызны» сорап, әйбәт бәя түләп алырга әзер торучы милли нәширләребез юк лабаса!.. Янадан Әшрәфжан, Фәрвәз дуслар каршына мескенләнеп барыргамы? Алар нишли ала — югарыдан биргәнне күтәп ятучылар?!

Кыскасы, без әнә шундый буш урталыкта калдык. Алдагы съездыбыз менә шул бушлыктан чыгу юлын эзләргә мәҗбүр булыр, ахрысы... Мәсьәләләр күп җыелды, фикер каршылыклары да житәрлек, сүз күп, бәхәсләр дә кискен булыр дип көтәргә кирәк. Тик исән-сау барып житәргә язсын!

## Әхсән Баян:

1. Безнең татар әдәбияты ничәмә-ничә еллар инде үзенчә бер рәвешен саклый — гүя йөге кыек төялгән арба: жайсызрак утырсаң, катырак жил иссә, аварга тора. Борылмалы, яисә таулырак төшләрдә куркыныч арта. Дистәләрчә еллар буе каләм ияләре гамәлдәге сәясәтнең мөридләре булып килделәр. Ни кызганыч, хәлләребез хәзер дә шул чама булуда дәвам итә.

Моның сәбәпләре бар, әлбәттә. Сәбәпләр житди. Әгәр дә дөнья икегә ярылса, ул ярылу язучы йөрәге аша уза, дибез бит. Чорга хас омтылышлар һәм чирләрнең күбесе — безнең йөрәкләрдә. Алар теге яки бу рәвештә әсәрләрдә барыбер чагылмыйча калмый.

Мәгълүм елларда — яңа гадел җәмгыять төзү өчен көрәш кырларында язучы турыдан-туры катнашты, каләмне штыкка тиңләп, ихлас, саф күңел белән. Соңгы елларда, халыкның сүнә язган идеалы янадан калыккач, кояш астында үзебезгә ходай тарафыннан бирелгән лаеклы урыныбызны даулыйбыз. Мондый хәлләрдә йөрәге таш булмаган кеше битараф кала аламыни!

Табигый рәвештә, сәхнәнең иң алдына — авансценага публицистика чыкты. Үз вәкаләтләреннән узып, проза һәм поэзиягә күчте. Шушы синтетик жанрда (моның әлегә үз исеме юктыр) уңышлы гына әсәрләр барлыкка килде һәм алар тиешле бәяләрен алдылар.

Шулай да бу хәлнең килешеп булмый торган ягы бар. Әдәбиятны әдәбият иткән төп жанрлар, сәнгатьнең асыл сыйфатлары, әйтергә кирәк, аның кеше дигән үз предметы гомум игътибардан һаман да читтә кала бирә. Сәнгатьнең табигый хасиятләренә туры килгән, аның таләпләренә җавап биргән әсәрләр сирәк күренә. Күренгәннәрен күрмәмешкә салышу кагыйдә төсе алган. Тәнкыйть, әүвәлдән килгән гадәтенчә, бер генә колагы белән тыңлый, бер генә күзе белән карый. Аның ярдәме аркылы, әйткәнебезчә, поэзиядә рифмалы публицистика, ә прозада сюжетлы (ә еш кына сюжетсыз) җиңел беллетристика өстенлек итә.

Бу сыйфатларның, законлы төс алып, киң таралуына, үзебездәге социаль заказлардан тыш, соңгы елларда А. Солженицынның түбән сәнгатьле сугышчан иҗаты да сизелерлек йогынты ясады шикелле.

Әйтәсе килгән фикерем шул: җыелып утырган арбабыз аумаса гына ярар иде.

2. Унберенче съезд карарлары дигәндә дә сүзем шушы төслерәк. Тормышка ашыру өчен кабул ителгән карарлар, йөкләмәләрне безнең хәятта минем әллә ни күргәнем булмады.

3. Әдәби фонд? Аны базар йотты. Татарстан хөкүмәте аны үз канатына сыйдыра алмады. Авторлык хокукларын саклау оешмаларын булдырмыйча торып, бу мәсьәлә тулысынча хәл ителә алмаячак. Икенчедән, өлешчә юлга салу мөмкинлеген шунда күрәм: идарә аппаратындагы бер штат берәмлеген әдәби фондка бирү, ягъни түләүле директор булдыру. Хәзергә бу вазифа җәмәгатьчелек тәртибендә үтәлә. Ә бушка эшләгән кешедән зур эш таләп итү җайсыз.

4. Алда торган съездан яңа карарлар, яңа йөкләмәләр көтәм...

5. Идарәнең яңа составы һәм аппараты — югары оешмалар ярдәме белән — китап чыгару эшен юлга сала алса, күпләребез өчен шул житеп тә торыр иде, дип саныйм.

**Әхмәт Рәшит:**

1. Яңарыш жилләре башкалалардан регионнарга, гадәттә, соңрак барып житә. Илленче еллардагы атаклы «оттепель» — жылыну чорын гына искә төшерегез. Рус әдәбиятында И. Эренбург, Г. Николаева, В. Дудинцев кебек язучыларның күләмле, бөтен жәмгыятькә тәэсир итәрлек әсәрләрен генә телгә алыгыз. Ул чорда татар әдәбияты халык күңелен кузгатырдай темаларга кыюсызрак, як-якка каранып алынды. Әлбәттә, азмы-күпме уңышлар булды — анысын инкяр итәргә ярамый. Нигездә, яңарыш шигъриятебезгә кагылды. Шул дулкында бөтен бер төркем — Фәйзуллиннар буыны шагыйрьләре күтәрелеп чыкты. Яшьләр өлкән һәм урта буынның Н. Арслан, С. Хәким, Г. Афзал кебек вәкилләре ижатына да сизелерлек йогынты ясадылар. Бу ялкын торгынлык еллары жилләрендә дә сүнмәде. Психологик яктан да, ижат тәжрибәсе жәһәтеннән дә үзгәртеп кору чорына язучыларыбыз әзер булып килделәр. Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, А. Гыйләжев, Г. Ахунов тормышыбызның әле моңарчы әдәбиятта чагылыш тапмаган катламын күтәрергә жөрьәт иттеләр.

Иң мөһиме — Октябрь инкыйлабыннан соң кагылып-сугылып килгән тарихи жанр тернәкләнеп китте. Н. Фәттах «Итил суы ака торур» романы һәм «Кол Гали» трагедиясе белән беренче буразналар сызган булса, тора-бара аның дәвамчылары да жиң сызганып эшкә керештеләр. Язучыларның XI съездыннан соң М. Хәбибуллинның, Батулланың, Р. Мөхәммәдиевнең, Ж. Рәхимовның, Ф. Латыйфиның зур күләмле әсәрләре пәйда булды. Татар халкының үзаңын уятуда аларның роле әйтеп бетергесез зур. Чөнки мөстәкыйльлегебез өчен көрәш сафына безнең баһадир бабаларыбыз һәм Сөембикә, Колшәриф, Япанчы, Батырша, Мирсәет Солтангалиевләр кебек шәхесләр кушылды.

Икенче шатландырган нәрсә — әллә никадәр рухи мирасыбызның, ниһаять, халкыбыз арсеналына кайтарылуы булды. Бу изге эштә «Казан утлары», «Идел», «Мирас», «Татарстан», «Аргамак» журналлары һәм башка басмалар гаять әһәмиятле эш башкардылар. Иң сөендергәне — Гаяз Исхакый кебек бөек шәхесебез ижатының яңадан кайтарылуы.

Ике съезд арасында шатландырырлык әдәби вакыйгалар байтак булды. Иң әһәмиятлесе — Татарстан Язучылары сафы сан ягыннан гына үсеп калмый, әдәбиятыбыз яңа сыйфат үзгәрешләре дә кичерә.

2. Соңгы елларда әдәбият мәйданы сизелерлек киңәйде. Өр-яңа журналлар һәм газеталар чыга башлады. Ләкин шул ук вакытта базар икътисадына бару шартларында Татарстан китап нәшриятының мөмкинлекләре шактый тарайды. Заман таләпләренә жавап бирердәй ныклы полиграфия базасының булмавы, кәгазь һәм тышлык материалларына кытлык, сыйфатлы типография буяуларының житенкерәмәве, тәжрибәле кадрларга мохтажлык әдәби продукция чыгаруга тискәре йогынты ясый. Шуның өстәвенә, китап сату һәм таратуның канәгатьләнерлек дәрәжәдә алып барылмавы. Китап сәүдәгәрләренең порнографик һәм детектив әдәбият белән мавыгуы бүгенге көн өчен кирәкле житди әдәбиятның тез астына суга. Нәтижәдә, язучылар, сәнгатебезнең башка әһелләре кебек үк, матди авырлыклар кичерергә мәжбүрләр. Бу юнәлештә житәкчеләребезгә һөжүмчән эш алып барырга кирәктер. Һәрхәлдә, теләсә нинди жәмгыятьнең тарих каршындагы бәясе сөрелгән жир гектарлары, алынган уңыш, терлекләрнең баш саны, заводлар һәм фабрикалар житештергән продукция күләме белән генә түгел, әдәбият һәм сәнгатьнең торышы, халыкның рухи халәте белән дә билгеләнә бит.

3. Әдәби фонд Россиядә 1859 елда язучыларга һәрьяклы матди-көнкүреш ярдәме күрсәтүне күздә тотып оештырылган. Патша заманнарында да мохтажлык кичерүче каләм әһелләре булган, әлбәттә. Бүгенге тотрыксыз чорда исә аның кирәклеге әллә ничә мәртәбә артты. Бу аеруча милли телләрдә ижат итүче язучыларга кагыла. Татар язучыларыннан кайсының гына алпавыт утарлары булганы бар соң? Якын киләчәктә дә андый мөмкинлек күренми әле.

Әдәби фондтан башка яшәү мөмкин түгел. Газета-журналлар редакцияләре, радио һәм телевидение, концерт оешмалары, театрлар, нәшриятлар — үзебезнекеләре дә, чит илләрдәгеләре дә — Татарстан әдәби фондына, безнең авторларның хезмәтен искә алып, билгеле күләмдә акча күчерергә тиешләр. Моның өчен тиешле оешмалар белән эшлекле элемтәләр урнаштырырга, башкалар тәжрибәсен өйрәнергә кирәк.

Аннан, элекке СССР Язучылар Союзына буйсынган ижат йортларында безнең дә өлешебез бар лабаса — үзебезгә тиешлене даулап алырга кирәк.

Әгъзалык керемнәреннән генә әллә ни мая тупланмас — әдәби фонд башында булган мөмкинлекләрне эшкә жигәрдәй эшмәкәрләр утырсын иде.

4. Дөресен генә әйткәндә, аллә ни көтмим. Язучылар берлеге Сталин заманнарында иҗат әһелләрен билгеле бер идеологик кысаларда тоту өчен уйлап чыгарылган ясалма оешма ул. Ә иҗат исә һәркемнең индивидуаль эше. Бердәнбер өметем — XII съезд мәгълүм дәрәҗәдә милли туплануга, кайбер иҗади ориентирлар билгеләүгә этәргеч булыр, бәлки. Җыелырбыз, зарланырбыз, таралырбыз... һәм һәркайсыбыз үзенчә дәвам итәр.

5. Иншалла, татар әдәбияты талантларга мохтаҗлык кичерми. Алмаш әзерләү мәсьәләсендә дә тернәкләнеп барабыз шикелле — яңа исемнәр күренгәли тора. Мин, кабул итү коллегиясе әгъзасы буларак, киләчәккә ышаныч белән карыйм. Яшьләребезне иркәләмичә генә, шул ук вакытта башларына да бик сукмыйча, булганын күреп һәм танып, ә иң мөһиме, аларга тиешле рухи һәм матди шартлар тудырып үстерергә кирәк. Язучыларыбыз, гомумән, социаль яклауга мохтаҗ. Ә тамаклары тук, өсләре бөтен булса, калганын алар үзләре эшләр. Язучылык эше — һәркемнең намус эше. Директивалар, күрсәтмәләр бирү бу очракта артык.

## Зөлфәт:

1. Шигырь мәсьәләсенә килгәндә, ким-хур булырдай дәрәҗәдә түгелбез дип саныйм. Халтурасы да, гадәттәгечә, житәрлек булды, болгавыр заманда «мода» ясарга тырышу да аз түгел. Әмма, ни генә әйтсәң дә, йотылып укырдай шигырьләрдән дә мәхрүм яшәмәдек — Аллага шөкер!

2. «Канәгать түгел!» дип кенә әйтер идем дә, кыргый базарның башыбызга нинди афәтләр китергәнен бик яхшы күреп торам. Кем белә, ахыры, бәлки, яхшыга да булыр әле... Чын шигырьне кырыс шартлар сыный лабаса... Хәер, бусы да ике яклы пәке шикеллерәк — базар оятсызлыкка бик маһир.

3. Миңа калса, язучылар әдәби фонд тирәсендә тупланырга тиеш. Фонд исә бу яман чорда әдәбиятны коткару белән шөгыльләнергә тиештер.

4. Съездтан барыбыз да күппе көтәбез. Иң мөһиме — әдипләрне хәерчелек чоңгылына төшермичә саклап калу. «Халык! Әдәбият!» — дигән буш шигарьләргә кайтып калмасын иде бу җыен.

5. Иң мөһиме — финанс ягы. Талантсыз байлар үз китапларын үз акчасына да чыгара алыр, әҗере дә аз булмас. Талантлыларны яклыйсы иде! Нигездән хәл ителәсе төп мәсьәлә шул булырга тиештер.

## Госман Садә:

1. Идел елгасы һаман үз юлы белән сабыр-талгын гына агып килгән кебек, татар әдәбияты да соңгы биш ел эчендә аллә ни кискен-текә борылышлар ясамады шикелле. Аның үзен кораб белән чагыштырсак, ничектер ул капитаны булып та капитансыз йөзә сыман тоела. Бәлкем, бер яктан әйбәттер дә. Ни дисәң дә, ничәмә-ничә еллар буена әдәбият партия кушканны гына үтәп килде. Шунысы куанычлы, нәкъ менә шушы елларда ул югарыдан әмер биреп торучылардан котылды. Хәзер, аллага шөкер, ничек иген уңышын арттыру, ничек нефть чыгару турында әсәрләр язылмый.

Бу елларда әдәбиятыбызда, гомумән, бөтен татар гавәмендә олуг вакыйга — ул да булса Гаяз Исхакый исеменең илгә әйләнеп кайтуы, дисәм, күпләр килешер бу фикер белән. Әлеге чорда сандык төбендә, чорма башында яткан әсәрләргә дә юл ачылды. Мәсәлән, Ибраһим Сәлахов, Гурий Тавлин романнарыннан халкыбыз социализм концлагерьларындагы коточкыч хәлләрне укып тетрәнде. Мөсәгыйть Хәбибуллин белән Батулла да халык күңеленә хуш килерлек тарихи әсәрләр иҗат иттеләр. Ике съезд арасында Солтангалиев турында да гүзәл әсәр пәйда булды. Ул Башкортстанда да, Төркиядә дә уңыш казанып өлгерде. Күрәсең, әсәр язмышы да кем кулы белән язылуга карап бәяләнә.

Бу елларда публицистик-сатирик әсәрләр аеруча яңгыраш алдылар. Әйтик, халык телендә Фәнзаман Баттал, Зөлфәт Хәким һ. б.ларның исемнәре еш кабатлана. Шул ук вакытта торгынлык елларында кыюлыклары белән дан алган кайбер каләмдәшләребез нигәдер авызларына су каптылар.


2. Язучыларыбызның XI съездын коммунистлар партиясенең XXI съезды белән чагыштырасы килә. Әгәр партиянең әлеге мәгълүм съездында коммунизм турында миф кабул ителсә, безнең XI съездда да шуңа охшашлырак карарлар кабул ителде. Мәсәлән, безнең үз иҗат йортыбыз күптән гөрләп эшләргә тиеш иде инде бу вакытта. Әдәби газетабыз да чыгарга тиеш иде. Тагын әллә ниләр, әллә ниләр... Менә бит, властька омтылучылар авызыннан нинди асыл сүзләр очып чыкмас. Ә без, алла коллары, шул куык вәгъдәләргә ышанып, уч төпләребез кызарганчы кул чабып утырган булдык. Уч төпләребез кызарганга бүген йөзебез кызара.

Җиңеллек алып килмәде бу еллар. Китап чыгаруы да кыенлашты. Мескенлеккә табан тәгәри язучы халкы. Язучысы мескен халык үзе дә мескенләнә. Менә шуны һич кенә дә истән чыгармаска иде!

3. Әдәби фонд иң әүвәле гади язучы турында кайгыртырга тиеш. Хәзергә исә ул аерым бер төркемгә генә хезмәт итә кебек.

4. Алдагы съездданмы?.. Язучылар сайлап куйган рәис каләмдәшләренең ышанычын акласын иде.


5. Бөтен татар халкына җитмәгән бер сыйфат — ул бердәмлек булмау. Бу исә язучыларга да кагыла. Әсәрләргә, авторның нинди урындыкта утыруына карап түгел, ә чын асылына карап бәя бирергә өйрәнсәк, әдәбиятыбыз да алга китәр, бердәмлегебез дә ныгыр. Моннан барыбыз да — язучылар да, укучылар да, гомумән, халкыбыз да отар гына!



Рашат Низамиев

# УТ ҺӘМ ҖЫР

ФӘРИТ ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН



*Заманның ниндиi генә чоңгылларына эләкмәсен, кагыйдә буларак, зур талант ияләре үзләренә тигән гомердә әйтәсе сүзләрен әйтеп өлгерәләр. Гаҗәп хәл: Тукайга моның өчен нибары 27 ел вакыт җиткән.*

*Композитор Фәрит Яруллин үзенең «Шүрәле» балетын Тукай яшендә тәмамлый һәм Бөек Ватан сугышына китеп бара. Ул сугыш кырында, дөресрәге, яхшылык һәм яманлык дуэлендә үтерелде. Үлем аны асылда тән көрәшендә генә җиңде. Ромен Ролланның бик тә мәгънәле сүзләре бар: «Иҗат итү, димәк, үлемне үтерү...» Әйе, Фәрит Яруллин үзенең иҗаты белән үлемне җиңде. Аның шәхесе һәм иҗаты безнең арада яши. «Шүрәле» балеты моңнары илдә генә түгел, Азия, Европа, Америка халыкларына кадәр барып җитте...*

Тормышта «беренче» сүзенә ифрат олы мәгънә салынган. Беренче орден. Беренче мәхәббәт. Беренче китап... Китапның беренче битләре мавыктырмый икән, кеше аны укып тормаска да мөмкин. Менә ни өчен театрлар, яңа сезонны ачканда, кайсы спектакльне беренче уйнау мәсьәләсенә һәрвакыт игътибар бирәләр.

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры, гадәттә, үзенең сезонын һәр елны «Шүрәле» балеты белән башлап җибәрә. Быелгы яңа сезонда да шулай булды. Мин моны модага ияру, инде «урыслашып» бетә язган театрыбызга милли төсмер бирергә тырышу гына димәс идем. Асылда бу — беренче татар балетын иҗат иткән Фәрит Яруллинның рухына, иҗатына, талантына олуг хөрмәт билгесе. Чөнки «Шүрәле» моңнары милли музыкабызның визит карточкасы ул.

Тарихны һәм күренекле шәхесләребезне өйрәнү дигәндә без, дөресен әйтергә кирәк, шактый ялкау халык. Милләтнең йөзек кашы булырдай күренекле шәхесләребез тарихта булган, күп булган! Дөрес, патша самодержавиесе һәм соңрак тоталитар совет хакимияте аларның күбесен «сызык»ның теге ягына чыгарып ташлады. Язмышларын өйрәнү түгел, кайберләренең хәтта исемнәрен әйтергә дә ярамый иде. Юкса, милләтебез йолдызлыгында әллә ничаклы данлы исемнәр балкый: Кол Гали, Сәйф Сараи, Колшәриф, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Мирсәет Солтангалиев, Җамал Вәлиди, Һади Атласый һ. б. Беләбезме, яхшылап өйрәндек һәм халыкка житкердекме

милләт өчен җан атып торган, хәтта үлемнән дә курыкмаган каһарман йөрәкле шушы шәхесләребезнең тормышын, язмышын, кыйбласын? Бәхәсләшмим, соңгы елларда байтак сәхифәләр язылды бу хакта. Әмма болар гына аз әле, аз! Күренекле шәхесләр дөньясын күтәреп, без милләтебез язмышын да югарырак күтәрәбез. Халыкта милли горурлык, ватанпәрвәрлек хисләренә юлны киңәйтәбез.

Сүземнең башы бит шүрәле, дигәндәй, уйларым Фәрит Яруллин хакында иде ләбаса!

Ләкин сүзнең очы барыбер шушы мәсьәләгә барып тоташа. Кем соң ул Фәрит Яруллин, нинди кеше булган ул? Нинди уйлар, иҗади ниятләр белән яшәгән? Милли сәнгатебездә нинди эз калдырган? Батырчылык итеп әйтәм: милләттәшләребезнең күбесе моны юньләп белми. Беренче татар балетын язган бу композиторның гомере фаҗига белән чорнап алынган. Уйлап карасаң, бу фаҗигада халкыбыз язмышы да шактый ачык ярылып ята. Үткәнгә карап гыйбрәт алыр нәрсәләр бар.

Минем уемча, һәр татар әдибе үз халкының күренекле бер улы хакында нинди дә булса әсәр — поэма, пьеса, роман, повесть яисә биографик жанрда нәрсәдер язып калдырырга бурычлы. Бу — телеңне, тарихыңны, милләтне саклау, халкыңны киләчәккә әзерлерәк төстә уздырып җибәрү өчен кирәк. Мактану булып яңгырамасын, Фәрит Яруллин турында биографик әсәр язарга тотынганда мин иң элек әнә шундый борчылу-уйланулар дингезеннән дә этәрелеп киттем.

Эш барышында Фәрит Яруллинның үзен һәм иҗатын якыннан белгән йөзләгән кешеләр белән әңгәмә үткәрү, хатлар алышу, тарихи чорны өйрәнү, Казан, Уфа, Киев, Мәскәү h. б. шәһәр архивларында эзләнү хәлләренә тукталып тормыйм. Бу — үзе бик зур тема, аерым сөйләшүне сорый.

Кыскасы, 4—5 ел дигәндә 15 табаклы кульъязма китап әзер иде. Аны Татарстан китап нәшриятына тапшырдым. Рәхмәт, ул «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән тиз арада басылып та чыкты*. Анда композитор, солдат, гражданин дигән сыйфатларны үзенә берләштергән Фәрит Яруллинның туган сәгатеннән алып гомеренең соңгы минутына кадәрге сәхифәләре шактый җентекле, тәфсилле язылган. Шушы нәрсә минем эшне җиңеләйтә, композиторның биографиясен һәм иҗатын кабат сөйләп чыгудан коткара. Менә шуңа да мин игътибарны читтәрәк посып яткан, күрер күзгә бәрелеп тормаганрак мәсьәләләргә юнәлтмәкче булам.

**Беренчесе.** Фәрит Яруллин турындагы шушы биографик роман-хроникага нибары 9 мең чамасы тираж бирелде. Нәшриятка үпкәләмим. Аларның дәлиле үзләренчә шактый дөрес иде: «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән чыккан китапларны укучы бик алмый, алар киштәдә бөялеп ята, янәсе. Диссертация хезмәтенә, Казанда яшәп алган Зинин, Бауманнар биографиясенә генәябышып яткач, шулайрак буласы көн кебек ачык, әлбәттә. Миңа калса, нәшрият тарафыннан әдипләргә заказ бирү (әйдә, искечә яңгырасын!), бу сериянең ныклы планын булдыру житеп бетмәде шикелле. Мин әле хәзер дә уйланам: күптән түгел арабыздан киткән корифейлар — Нәкый ага Исәнбәт һәм Бакый ага Урманче хакындагы китапны кем язар яисә кем язарга җыена икән соң? Болар икесе дә — татар рухи-мәдәни дөньясының аяклы тарихлары иде ләбаса! Үзләре исән чакта сөйләтеп, тарихыбыз сәхифәләреннән кыйммәтле мирасны, вакыйга һәм мәгълүматларны алып кала белдек микән? Минемчә, бу эш эшләнмәде шикелле.

Әгәр кулыма рус телендә чыккан бер китап килеп эләкмәсә («Чистопольские страницы». Татарское книжное издательство, Казань, 1987), бәлки, мин тираж хакында сүз куертып та тормаган булыр идем. Анда 1941—43 елларда Татарстанның Чистай шәһәрендә эвакуациядә булган күп кенә совет язучылары һәм сәнгать эшлеклеләренең шигырь, хикәя, повесть, көндәлек, хат һәм истәлекләре туплап бирелгән. Сүз дә юк, китапны төзүче, аңа кереш мәкалә һәм аңлатмалар язган Г. С. Муханов зур һәм кирәкле эш башкарган. Мин аның бу хезмәтен һич кенә дә юкка чыгарырга теләмим. Әмма китапның яхшы бизәлеш белән яхшы сыйфатлы кәгазьдә чыгуы, барыннан да бигрәк аның 45 мең данә белән дөнья күрүе, дөресен әйтим, мине сагайтып җибәрде. Мәскәү күңеленә хуш килердәй тема булса, совет идеологиясенең ул чактагы умырткасын тәшкил иткән «интернационализм» мәсьәләсенә багышланса, андый басмаларга бездә һәрчак кәгазе дә, тиражы да мулдан табылды. Үзебезнең милли әдәбият, халыкның рухы-мәдәнияте өчен үтә кирәкле басмалар исә, яшерен-батырын түгел, бу җәһәттән кысрыклауга дучар ителә иде. Шөкер, соңгы елларда без бу хаталардан арына киләбез.

---

* Рашат Низамиев. Фәрит Яруллин. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1990.

**Икенчесе.** Муханов әзерләгән әлеге китапта шактый кызыклы, гыйбрәтле мәгълүматлар бирелә. Әйтик, Бөек Ватан сугышының беренче елында ук Казан, Чистай, Алабуга, Берсут, Печище һ. б. урыннарга Мәскәү, Ленинград, Белоруссия һәм Украина якларыннан 200 ләп әдәбият-сәнгать әһелләре эвакуацияләнә. Дөрес, илнең кырыс көннәрендә аларның берсе дә тик ятмый: каләм белән дә, физик көч белән дә тылга һәм фронтка ярдәм итәләр. Рәхмәтле булыйк үзләренә. Сөлге буе исемлекләрдә безгә бик таныш исемнәр дә күп очрый: П. Антокольский, В. Бахметьев, Д. Бедный, В. Бонч-Бруевич, Я. Купала, В. Лебедев-Кумач, С. Маршак, А. Фадеев, Б. Пастернак, Л. Леонов, Л. Ошанин һ. б. Моны, гомумән, бу күчешләр һәм урын алмаштыруларны дәһшәтле көннәр, ижади шәхесләргә хөрмәт, талантны саклау җәһәтеннән караганда аңлап та, аклап та була. Әмма менә мондый күренешне ни дип аңларга, ничек аңлатырга: хәрби кием кигән Татарстан әдипләрен, сәнгать осталарын поездлар Көнбатышка, фронтка — сугышның ут эчендә кайнаган нокталарына ташый... Алар арасында язучылардан Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Нур Баян, Рахман Ильяс, Абдулла Әхмәт, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәт Садри, Нәби Дәүли, Салих Баттал, композиторлар Фәрит Яруллин һәм Хөснул Вәлиуллин, рәссам Харис Якупов, режиссер С. Өметбаев, артистлардан Гали Надрюков, Диллүс Ильясов, Фаикъ Камал, Галия Кайбицкая, Рәшидә Җиһаншина, Мөнирә Булатова... (Бу исемлек чиксез озын, керми калганнар мине кичерә күрсен!) Көнчыгышка, тыл эченә кайтучы эшелоннарда исә куенына бронь кәгазен бөкләп салган зыялылар, «өлкән туган» вәкилләре.



*Ф. Яруллин (уңнан беренче утырган) Ульяновск хәрби пехота училищесында.*

Менә шундый парадокс: берәүләр ут эченә кергән, икенчеләре уттан ераклашкан!

Хәер, биредә ул кадәр аңлашылмаслык нәрсә юк. Мондый парадоксны совет чынбарлыгы, империянең шовинистик асылын оста яшерә белгән сәясәт, башка халыкларга кимсетеп карауда шомарып беткән большевиклар хакимияте тудырды. Гаделлек хакына таныырга кирәк: совет империясе бер яктан канлы-төрмәле террор белән куркытып тотса, икенче яктан ул үзендә яшәп яткан халыклар өчен чагыштырмача «йомшак» империя дә иде. Ни өчен дигәндә, Октябрь революциясеннән соң байтак халыклар акрынлап мәктәпле, әлифбалы булды. Безнең өчен исә иң зур «прәннек» — Идел-Урал, Татар-Башкорт дәүләтчелеге проектлары аша узып, Казан губернасы чапаныннан котылып, сытыла-кысыла булса да «Татарстан» сүзе кергән милли автономия бирелмәгәнгә күтәрелү иде! Бу хәл каһәрләнгән, изелгән, элек-электән читкә кагылган, кайчандыр дәүләтчелеген

югалткан татар халкының мәдәни, милли-азатлык хыялларына, һичшиксез, якты өмет уты салды. Хәтерлик: сугышка кадәр Россиянең байтак шәһәрләрендә татар театрлары эшләп торды. Мәскәүдә Татар опера студиясе, татар клубы бар иде. Менә-менә Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәреләргә тора. Казанда исә беренче тапкыр буларак татар милли опера театры оеша...

Менә шуларның барысын да каһәр суккан сугыш өзеп ташласын әле! Ватанны, Сталинны фашизм афәтеннән сакларга кирәк. Асыл табигате белән сугышчан, батыр, куркусыз татар уллары ике дә уйлап тормыйча әнә шулай фронт мәхшәренә ташланганнар, билгеле. Аларның бу фидакарьлегенә көләгә ташлау — зур гөнаһ булыр иде. «Сталин өчен!» дип утка керүчеләр — ул чакта миллионнар. «Бүгенгә кыен булса, иртәгә рәхәт яшәрбез» фәлсәфәсе, гаделсез патриотизм шаукымы каннарына сеңгән.

Татарны өстәгеләр сыйпап, мактап, зур көрәшләргә һәрчак рухландырып торганнар. Ләкин бу халыкка карата чын мөнәсәбәт беркайчан да үзгәрмәгән: ирек бирсәң, алар хәтәр, шуңа да алар бетәргә, кырылырга, сан ягыннан кимергә тиешләр. Кырым татарларын Сталин, юк-бар сәбәп табып, туган җирләреннән куды, асты, кисте, токымнарын бетерергә теләде. «Халыклар атасы» мондый вәхши эшкә керешердәй сәбәпне бик җиңел уйлап тапты: янәсе, бу халыкның кайбер вәкилләре немецлар ягына авышкан икән. Әгәр бу логика белән барсаң, югыйсә рус халкын да ул чакта туган җиреннән (?) сөрергә кирәк булган лабаса! Ни өчен дигәндә, Сталинның бик яраткан рус генералы Власов дивизия һәм полклары белән тулысынча Гитлер ягына күчте — бу тарихи факт.

Яхшыга булсын, безнең татар халкы — аның кызлары һәм уллары — фашизм афәтен җиңүгә тылда да, фронтта да үзләреннән зур өлеш керттеләр. Ул чакта илнең азатлыгын яклаганбыз икән, бүгенге көндә Татарстанның азатлыгын, мөстәкыйльлеген яклап көрәш барганда безнең мораль яктан да, хокукый яктан да хакыбыз бик зур. Тарихи яктан гадел һәм дөрес.

**Өченчесе.** Фәрит Яруллинның сугышка китеп баруына бик күпләр гаҗәпләнәләр һәм кемне дә булса гаепләргә ашыгалар. Бу бик аңлашыла. Чөнки оркестр составындагы гап-гади музыкантларны, кордебалеттагы биючеләрне, массовый күренешләрдә катнашучы күпчелек артистларны, композиторларны, ул чактагы хәрби кануннар нигезендә, бронь белән тәэмин иткәннәр ич. Ни өчен соң яшь һәм талантлы композитор Фәрит Яруллин гына әлеге хокуктан читтәрәк калган? Әллә ничә төрле юраулар, уйдырмалар бар бу хакта. Кайсына гына керешсәң дә сүзнең очы, телисең-теләмисеңме, Татарстан Композиторлар союзының ул чактагы җитәкчелегенә кайтып кала. Җитәкчелек пирамидасының иң биек ноктасында композитор Нәҗиб Җиһановның утыруы да яхшы мәгълүм.

Иҗади дустын саклап калуда композиторлар рәисе ниләр эшләгән, нинди адымнар ясаган соң? Дөресен әйткәндә, бу хакта бернинди документлар сакланмаган. Бары тик имеш-мимешләр генә йөри. Үзе исән чагында Нәҗиб ага Җиһанов белән аның эш бүлмәсендә 3—4 сәгать чамасы сөйләшеп, бәхәсләшеп, фикер алышып утырдык. Мин, әлбәттә, Фәрит Яруллинның сугышка ничек, ни рәвешле алынуы турында да сүз кузгаттым. Әмма рәтле-башлы, анык кына җавап ала алмадым. Кыскасы, бик тә томанлы, буталчык, сер белән уратылган тема бу.

Алдан ук әйтеп куясым килә: Ф. Яруллин белән Н. Җиһанов Мәскәү консерваториясендә бер чамадарак укыганнар, аралашып яшәгәннәр, беренче татар операсын һәм балетын иҗат итүдә янәшә торып эшләгәннәр. Алар икесе дә — татар халкының күренекле композиторлары, сәнгатебездә тарихи эз калдырган шәхесләр. Яруллин халыкчан моңнары белән әсир итсә, Җиһанов музыкадагы техник осталык, югары симфонизм үрнәкләре белән дан яулады. Китапны язганда, менә шуңа күрә дә, татарның ике күренекле шәхесен ачыктан-ачык чәкәштерәсе килмәде минем. Юкса кулымда байтак кына хатлар, истәлекләр, телдән ишеткән хатирәләр дә бар иде. Әмма бу нәрсәләрнең күбесе шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле булуы да ихтимал ич, шуңа күрә мин аларны архивымда гына калдыруны мәгъкуль санадым.


Шулай да бер дә икеләнмичә әйтә алам: ике композиторыбыз арасында «Моцарт һәм Сальери» варианты, һичшиксез, булган! Фараз итәрлек нәрсәләр җитәрлек. «Шүрәле» балеты сәхнәгә чыгып кына яткан чакта аның авторын, дөресрәге, талантлы яшь композиторны саклап калу мөмкин булгандыр. Теләк җитмәгән, күрәсең. Гражданин рухлы, илдәге хәлнең җитдилеген аңлаган Фәрит Яруллин исә югары органнарга мөрәҗәгать итеп тә тормаган. Кемнәрдер тылда калганда үзенең генә сугышка китеп баруын ул авырдан кичергән, билгеле. Якын

дусларының берсенә: «Тылда намуссыз яшәүгә караганда, сугышта көрәшеп үлүең артыграк»,— дип әйткән икән, мона инде уйланырлык урын бар.

Тагын бер хикмәти аклану: турыдан-туры утка, фронтка барып кермәсен өчен, Композиторлар союзы хәрби комиссариат аша Фәритне хәрби училищега җибәрү мәсьәләсен кайгырткан икән!? Дөрестән дә, Фәрит Ульяновск пехота училищесына килеп эләгә. Хәрби ант кабул итә. Хәрби тормышның авыр баскычларын узып, дүрт айлык курслардан соң, кече лейтенант погоннары тага. Алга таба — Сталинград яны сугышлары, яралану, хәрби госпиталь... Аннары Курск дугасы, Смоленск һәм Витебск юнәлешендәге дәһшәтле сугышлар... Сугышның иләмсез авызы кеше гомерләрен, хәрби кадрларны үзенә йотып кына тора. Фронтта, бигрәк тә пехотада урта буын командирларга кытлык, шуңа күрә кече лейтенант Яруллинны тылга, иҗат дөньясына җибәрмәскә тырышулары бик табигый ул чакта. Композиторлар рәисенең Фәритне училищега тәгаенләве, беренче карашка, бик дөрес кебек. Ләкин кече офицер погоннары белән аның кул-аякларын богаулап куюлары шома-астыртын эш йөртүгә дә бер ишарә булып яңгырый.

Без боларны белеп торыйк. Ләкин, алда әйткәнемчә, музыкабыз күгендәге ике йолдызны һаман саен чәкештереп тору дөрес булмас. Башка милләтләр каршында безгә үз дәрәҗәбезне саклау кыйммәтрәк.

**Дүртенчесе.** Фәрит Яруллин язмышына яңача караш ташлар вакыт җитте булса кирәк. Бөек Ватан сугышы — кан коюю, вәхшилек көрәше генә түгел, халкыбызның талантлы улларын үтерү мәйданы да булды. Без элегрәк, 200 дән артык геройларыбыз бар, дип мактанырга, горурланырга ярата идек. Бу сугышта татарның иген игәрдәй күпме игенчесе, сукса тимер өзәрдәй күпме эшчесе, таланты ташып торган күпме зыялылары солдат киеменә төренде дә, Ватанны якларга дип, ут эченә китеп барды. Күпләр, бик күпләр әйләнеп кайтмады, яу кырында башын салды... Сент-Экзюпери әйткәнчә, ә бәлки һәр кешедә Моцарт үтерелгәндер?..




*Белорусь, Рыленки туганнар каберлеге. Бирёдәге ташларның берсенә Фәрит Яруллинның да исеме уеп язылган.*

Яруллинның Казан каласыннан сугышка китеп баруы, канкойгыч бәрелешләрдә катнашуы — фаҗига! Рояль клавишларында уйнасы бармакларның мылтык курогына басарга тиешлеген бүтәнчә ничек аңлатасың? Музыкантка, композиторга, нечкә хисле кешегә мылтык, пычак, автомат тоттыр инде менә! Иҗади шәхес өчен моңардан да зур фаҗиганең булуы мөмкин түгел.

Уйлап карасак, фаҗиганең төбе, тамыры тирәндәрәк ята. Ул һаман да бер мәсьәләгә — кайчандыр Болгар иле, Казан ханлыгы белән тарихларга кереп калган дәүләтчелегебезне югалтуга кайтып кала. Патша самодержавиесе тирә-

юнендәге барлык халыкларны, мәмләкәтләрне ут һәм корал белән яулап алды, үзенә буйсындырды. Татарның язмышы да Рәсәй атлы илнең ике башлы каракош тырнаклары астында басылып калды. Менә шулай берничә гасыр яшәдек. Рәсәй империясе аннары, мәгълүм булганча, совет империясе булып оешты. Бөек Ватан сугышы көннәрендә гаҗәеп бер парадокс килеп чыкты: күп кенә милләтләр белән бергә, без — татар халкы — заманында үзебезне яулап алган «өлкән туган»ның ил чикләрен сакларга дучар ителдек! Рәсәй-совет империясенә хезмәт итеп, без болай да бик күп көчләрне, талантларыбызны читкә сибеп ташлаган идек инде. Болар бар да туган телебезне һәм милли йөзебезне югалту хисабына барды лабаса.

Бөек Ватан сугышы безнең милли генофондка тагын бер тапкыр китереп сукты! Нәрсә, сугыш җәһәннәменә китеп барган татар кавемнәре бу сугышта татар халкы мәнфәгатьләрен яклап көрәштеме әллә? Юк бит, уртак Ватанны саклыйбыз дигән булып, без ирексездән империя мәнфәгатьләрен яклаучы солдатларга әвереләдек. Хәер, моның идеологик шаукымы, интернационалистик җирлеге бик уңышлы әзерләнгән иде шул.

1941 елда минем әтине дә сугышка алалар. Ярты Европаны гизеп, сынар кулын югалтып, ике елдан соң туган авылына кайтып төшә ул. 23 яшьлек солдат-егет хөрмәтенә идән астыннан бер «ярты» да чыга. Бераздан, хисләнеп китеп, койма рәшәткәләрен коча-коча елый егет: «Сынар кул белән мин кемгә кирәк, ничек яшәрмен??..» Хәзер менә кайта-кайта уйланам: минем әти совет чикләрен саклап түгел, безне — туачак балаларын саклап сугышның алгы сызыгында йөргән, ахрысы. Ә теге «каракош» һаман сагалап тора икән: Җәүдәт исемле бертуган абыем хәрби училище тәмамлады, очучы булды, хәрби задание үтәгәндә самолетта янып та үлде... Милләт файдасына булса, мин аны бу кадәр үк кызганмас та идем.

Дәүләтчелегебезне яңадан торгыза алсак, халкыбыз тормышында фаҗига һәм үкенечләргә урын аз калачак. Үз халкыңның бәхете өчен көрәшү, киресенчә шәһит китү — менә монысы ичмасам чынлап та горурлык булыр иде.

**Бишенчесе.** «Шүрәле» балетының язмышы метаморфозалардан тора. Сәхнәгә менә-менә куелам дигәндә генә сугыш аны бер селтәнүдә туктатып калдыра. Сугыштан соң исә композиторлар Власов һәм Фере балет партитурасын «эшкәртү», инструментлаштыру эше белән шөгыльләнәләр. Мавыгып, кызып китә торгач, хәтта берзаман авторлыкка дәгъва кыла башлыйлар. Музыка тарихында эшкәртү традицияләре бар анысы, ләкин балетта бер әсәрнең өч авторы була алмый инде, монысы — гайре табигый хәл.

Ни генә булмасын, әллә ничаклы киртәләрне узып, «Шүрәле» балеты СССР сәхнәләренә күтәрелә. Мәскәү, Ленинград, Киев, Харьков, Одесса, Львов, Рига, Таллинн, Ташкент, Алма-ата, Дүшәмбе, Уфа, Чиләбе, Саратов, Улан-Удэ, Новосибирск һ. б. шәһәр театрларының репертуарына үтеп керә. Алай гына да түгел, илебезнең иң атаклы театрлары аны Англия, Франция, Көнбатыш Германия, Италия, Канада, Япония тамашачыларына да күрсәтә. Болгария, Румыния, Чехословакия, Польша, ГДР, Монголия театрлары исә балетны үзләре мөстәкыйль сәхнәләштерәләр.

1985 ел. Швециянең Гетеборг шәһәрендә фигуралы шуу буенча Европа чемпионаты бара. 12 мең тамашачыны сыйдырышлы «Скандинавум» спорт сараенда ленинградлы Елена Валова һәм Олег Васильев «Шүрәле» балеты музыкасына нигезләнгән ирекле программа башкаралар һәм чемпионатның алтын медален яулыйлар.

Уйлыйм-уйлыйм да шаккатам: «Шүрәле» балетының менә нинди данлы, шанлы чаклары булган!

Алда әйткәнемчә, хәзер ул үзебезнең опера һәм балет театрында гына куела килә. Нигә соң татарның дәрәҗәсен күтәрә торган шушы талантлы әсәр бүгенге көндә башка төбәкләрдә, БДБ һәм чит ил сәхнәләрендә бармый? Юкса йөзне кызартмаслык, теләсә кайсы балет әсәре белән ярыштырырлык көчле сәнгать әсәре ич ул!

Моның үзенә күрә сәбәпләре бар, билгеле. Татарстанга «автономия» дигән күлмәк-ыштан кидертеп, заманында аның рухи-мәдәни мөмкинлекләрен шактый чикләделәр. Анысыннан да бигрәк, әгәр өстән яки Үзәктән махсус күрсәтмә булмаса, үз белдегең белән генә ерак китә алмый идең. Сәнгатьтә зур эшләр майтару өчен акча дигәнең дә бик кирәк. Икътисад улагыннан агып торган акчаларның иң зур өлеше ул чакта Мәскәүнең төпсез кесәсенә китә торды. Бүген исә җөмһүриятнең икътисадый хәле катлаулы, тотрыксыз.

Һәм, ниһаять, иң авырткан җирләрнең берсе — балет сәнгатендә милли кадрларыбызның житәрлек булмавы. Менә шуның өчен дә опера һәм балет

театрыбыз милли йөзен югалтты диярлек, татар музыкасыннан ераклашты, «урыслашып һәм европалашып» бетте. Моның сәбәпләре һаман да бер тирәгәрәк кайтып төшә. Безне илле-алтмыш елдан бирле автономия кысалары буып торды. Республикаң икенче-өченче сортлылар рәтендә йөргәч, юрганыңа карап аягыңны сузасың дигәндәй, милли культурага үсеп-күтәрелеп китү өчен тиешле шартлар тудырылмады, нигилистик караш чәчәк атты, киләчәк турындагы өметләр бастырылды. Симфоник оркестр, опера һәм балет театры өчен милли кадрлар әзерләү мәсьәләсе кулдан ычкынды. Үзебездә перспектива күренмәгәч, игътибар җитмәгәч, булган кадрларыбыз да читкә янсә Мәскәүгә китеп барды, бар талантын башка халыкка хезмәт итүгә багышлады.

Менә шундый хәлләр. Фаҗига һәм югалтуларыбызның тамыры еракта кирәк. Ләкин дөньялар нык үзгәрде. Рәсәй зур тетрәнүләр кичерә. Менә шушы яңа шартларда Татарстан мөстәкыйльлеген игълан итте, акрынлап чит илләр белән турыдан-туры элемтәләр булдыруга ирешті. Кардәш-тугандаш Төркия белән бәйләнешләребез аеруча күркәм, нәтиҗәле. Икътисад өлкәсендә генә түгел, мәдәни элемтәләр юнәлешендә дә өр-яңа юллар, мөмкинлекләр ачыла. Бу җәһәттән мин «Шүрәле» балетына икенче гомер, икенче сулыш бирер чаклар килеп җитте дип саныйм. Мәдәният министрлыгы бу мәсьәләгә игътибар итми калмас, шәт.

* * *

Узган елның җәендә гаять күренекле вакыйга булды: Фәрит Яруллинның туган ягында — Мамадыш районының Кече Сон авылында аңа багышланган музей ачылды. Моны Яруллиннар музее дип атасак та ярый. Чөнки экспонатларның байтагы халык музыканты, «Тукай маршы»ның авторы Заһидулла ага Яруллин турында да сөйли. Бу гаиләдән тагын Мирсәет Яруллин дигән композиторның үсеп чыгуын да әйтсәк, йолдызлык тагын да түгәрәкләнә төшә.

Музейның зурлыгы, бизәлеше, андагы экспонат һәм паннолар муллыгы таң калырлык. Татарстан дәүләт музееның фәнни хезмәткәрләре Венера Дәүләтшина һәм Роза Галимҗанова бу йортның эченә җан өрүдә, эчтәлек һәм бизәлешне фәнни нигезгә салуда күп көч куйганнар. Аларның хезмәтенә, талантына рәхмәт. Бу музей әле бик күпләргә сәнгать тәрбиясе бирәчәк, нур чәчеп торачак.

Тагын бер нәрсә турында әйтеп китми булмас, ахры. Музейдагы витриналарны яктырту өчен өстәмә рәвештә электр чыбыгы сузалар. Электрүткәргеч бу чыбыклар агач бүрәнәле диварга кадак белән беркетелә. Менә шушы ялгыш аркасында сентябрь аенда чүт кенә янгын чыкмый кала музейда! Дөресрәге, утның кабынып, көч җыеп яткан мәлендә музейны саклаучы Камил Якупов йорт-музей эченә килеп керә һәм чиләк-чиләк су ташып ялкын телләрен тиз арада сүндереп өлгерәләр. Хикмәти хода: кашагалар, тәрәзә пәрдәләре, мүк кисәкләре янып төшкән, әкиятләр китабының да карарлык җире юк. Ә менә шулар уртасындагы рамлы киндер рәсем, шәмаил һәм Коръән китабы исән калган! Сәнгать һәм дин байлыкларының әнә шулай исән калуын могҗиза дими ни дисең инде.

Фәрит Яруллинны да сугыш уты ялмап йотмакчы булган әнә, ләкин ул шушы дәһшәт эченнән «Шүрәле»се белән исән-аман чыкты. Инде менә ут аның иҗатына һәм хәтер йортына тагын бер тапкыр кизәнмәкче булган... Табигатьнең без белмәгән ниндидер серле көчләре бу юлы да Яруллин тудырган хәзинәләрне саклап калды. Мин монда тирән символик мәгънә күрәм: игелек кылган, яхшылык нурлары чәчкән шәхесләрне юкка чыгару мөмкин түгел икән. Андыйлар яши, халыкка хезмәт итә, безнең белән киләчәккә бара.

Казан—Кече Сон
1993, ноябрь

## Хәмзә Бәдретдинов

# ЕРАКТАГЫ ЯКЫННАРЫБЫЗ

**Хәтәр елларда язмыш чыбыркысы милләттәшләрне төрле кыйтгаларга куып тараткан. Әмма татар кешесе билен бирмәгән. Таш астыннан яктылыкка бәреп чыккан яшел үсенте сыман, тормышта үзен күрсәтергә, танытырга омтылган. Халкыбызның асыл уллары бик күп төбәкләрдә яшиләр. Үз көчләре белән түбәннән күтәрелеп, үҗәтләнеп, фән дөньясында да үз сүзләрен әйтәләр. Моңа мисаллар җитәрлек.**

**Бу язмам әнә шундый мәртәбәле шәхесләрнең берничәсе хакында булыр.**

## Татлы шикәр әчесе



Даишев Мидхәт Исхак улы — техник фәннәр докторы, профессор, Краснодар политехника институтының шикәрле матдәләр технологиясе кафедрасы мөдире.

Мидхәт ага тынгысыз кеше. Вакыты гел юлда үтә. Россиядә генә дә 92 шикәр заводы бар, ә БДБ илләрендәген кушсаң, 318 гә җитә. Бу катлаулы производствода бер-бер кыенлык чыктымы, Мидхәт аганы чакыртып алалар.

— Әле генә егерме көн йөреп кайттым,— дип каршылады мине Мидхәт ага.— Ташкент, Фрунзе, Казан, Буа, Мәскәүдә булдым. Ә тиздән Киевка, гыйльми совет утырышына чыгып китәм, бер докторлык диссертациясе турында үз фикеремне әйтәсе бар.

Сүзгә Мидхәт аганың хатыны Ләлә ханым кушыла:

— Безнең Мидхәт «Ашыгыч ярдәм күрсәтүче» кебек ул, билләһи. Чөнки илнең барлык заводларында шикәр чималын аның схемасы буенча эшкәртәләр бит. Тик менә соңгы сәфәрләрдән бераз күңелсезләнебрәк кайтты әле...

— Вак-төяк кыенлыкларга гына түзеп була, анысы,— ди Мидхәт ага. Буада эшләр шәптән түгел әле. Технология бозыла. Чөгендер, шикәр дип җан атып йөрүче Фәрит Садриевны төп эшеннән читләштергәннәр. Менә дигән баш инженер бит ул. Күңелен сындырганнар егетнең. Бу турыда Мәскәүдә дә әйтеп чыктым әле, белеп торсыннар. «Роспищепром»ның бүлек начальнигы урынбасары Хатыйп Хаҗиәхмәтович Баталов — безнең милләттәш, әйткәннәремне игътибар белән тыңлап торды. «Кадрлар үзгәрмәсә, Буа заводында эш бармаячак»,— дигәч, уйланып калды.

— Республикада буалылар алдынгы саналалар бит.

— Заводны шикәр күтәрми. Алар чүпрә исәбенә яшиләр.

— Ә Фәрит Садриевны сез көчле инженер буларак хөрмәт итәсезме?

— Әлбәттә! Эзләнүчән кеше ул. Шикәр алу технологиясен камилләштерү максаты белән Краснодарга кадәр килеп чыкты. Бергәләп тәҗрибәләр үткәрә башладык. Хәзер менә, Фәрит тәкъдиме буенча, шикәр чөгендерен теплица шартларында үстереп карарга исәп...

СССР таркалу нәтиҗәсендә күп проблемаларны уртага салу, вакытында күтәреп чыгу авырлашты. Галимнәрнең иҗади трибунасы — билгеле бер тармакка караган журналлар чыкмый башлады. Шулай итеп, фәнни-техник информация

алмашуга юл ябылды. Югыйсә, шикәр заводлары берничә дистәдән артмаган Венгрия, Бельгия, Италия, Германия, Франция кебек илләрдә бу өлкәгә караган журнал даими чыгып килә.

Мидхәт ага Даишев «Шикәр промышленносте» журналында үзенең фәнни-актуаль мәкаләләре белән актив катнаша иде. Кызганыч, бу журнал 1988 елда чыгудан туктады. Бер Мидхәт ага өлешенә генә дә 24 фәнни ачыш туры килә. Аның хезмәтләре һәр заводта гамәли кулланышта.

Мидхәт Исхаковичның хатыны — Оренбург кызы Ләлә ханым да пенсиягә чыкканчы шикәрле матдәләр технологиясе кафедрасында эшли, техник фәннәр кандидаты була, студентларның яраткан укытучысына әйләнә. Инде хәзер бердәнбер кызлары Наилә әти-әнисе сукмагыннан бара. Институттан ул шикәр промышленносте инженер-технологы дигән белгечлек алып чыга, аспирантурага укырга керә, тиздән кандидатлык диссертациясе якларга җыена.

Мидхәт ага житәкләгән кафедрада элеккеге Союзның төрле өлкәләреннән Краснодарга килеп, ак шакмаклы шикәр дөньясының хикмәтләрен өйрәнеп китәләр. Чит илләрдән укырга җибәрелгән студентлар да бихисап — кафедрадагы дөнья картасының кызыл флаглар белән чуарлануы шуңа ишарә. Вьетнам, Мали, Сириядән аспирантлар бар монда. Ә Болгариягә профессор М. Даишев үзе барып кайтты. Студентларны күршеләрнең шикәр промышленносте белән таныштырып йөрде. Белгечләр янында тәҗрибәсен уртаклашып, лекцияләр укыды.

— Шикәр белән шулкадәр дуслашып китәрлек кебек тә түгел идем,— дип шаярта хәзер Мидхәт Исхак улы.— Инде хәзер татлы кристаллар дөньясыннан аерылып китеп булмас. Остаз-укытучыларым техник фәннәр докторы, профессор, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Социалистик Хезмәт Герое Павел Михайлович Силин белән техник фәннәр докторы, профессор Исаак Федорович Зеликманның варисы булып, баллы шикәр әчесен гомер буе татырга туры килә.

Мидхәт Даишев Бөгелмәдә туган. Аның әтисе — бухгалтер булып эшләүче Исхак абзый: «Мин шагыйрь Габдулла Тукай белән таныш идем»,— дип сөйләргә ярата. Гаиләдә өченче — төпчек бала булып дөньяга килгән Мидхәткә ундүрт яшь тулганда Ташкент якларына күчеп китәләр. Шунда ул урта мәктәпне тәмамлый. Индустриаль институтка укырга керә. Әмма Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, укуын өзәргә туры килә. Аны заводка эшкә җибәрәләр, соңрак ул армиягә алына. Җиңү көнен ул Чехословакиядә каршылый. Сугыштан соң янадан институтка кайтып шикәр-крахмал-патока производствосы технологиясе кафедрасының беренче курсында белем ала башлый. Сусыл чөгендердән шикәр ясау могҗиза булып тоела аңа. Моның серләренә төшенү өчен, ай-һай, нинди белем, тәвәккәллек кирәк. Тагын шунысы да бар: шикәр ясый белүче инженер теләсә кайсы тармакта эшли ала. Ул — киң колачлы белгеч. Уку дәверендә шуны аңлап тоемлагандырмы, Мидхәт Даишев институт аспирантурасында калырга берсүзсез ризалыгын бирә. Фәнни житәкчесе И. Зеликман житәкчелегендә тәҗрибәләр үткәрә башлый. Студентларга дәресләр бирә. Әмма ике елдан соң шикәрчеләр кафедрасы ябыла. Сәбәбе — Ташкент тирәсендә чөгендер үстерүне отышсыз диеп табалар, моңарчы эшләп килгән дүрт заводның капкасына йозак салалар да төп игътибарны мамыкка юнәлтәләр. Инде нишләргә? Аптырагач, Мидхәт ага Фрунзе шәһәренең органик химия институтына барып урнаша. Шикәр алу серләрен өйрәнүне дәвам итә. Ләкин аңа ике ел буена фатир бирмиләр. Фәнни житәкчесе Исаак Зеликманга рәхмәт, Мидхәт ага чарасызлыктан бәргәләнеп йөргәндә, үзе яшәгән Краснодар шәһәренә чакыртып ала. Азык-төлек промышленносте фәнни-тикшеренү институтының шикәр бүлегенә эшкә урнаштырга ярдәм итә. Исаак Федорович вафат булгач исә, Краснодар политехника институтының шикәрле матдәләр технологиясе кафедрасында вакансия ачыла. Мөдир эзли башлыйлар, конкурс игълан итәләр. Бәйгедә кырык ике яшьлек техник фәннәр кандидаты Мидхәт Даишевны да катнаштыралар һәм аны кафедра белән житәкчелек итү өчен иң лаеклы кандидат дип табалар.

Шулай итеп, 1967 елдан башлап, ир белән хатын эшкә бер сукмактан йөриләр. Бергәләшеп студентларга белем бирәләр. Икәүләшеп, төннәр буе утырып, диссертация язалар. Ләлә ханым фәннәр кандидаты булу турында хыяллана, Мидхәт ага доктор исемен алу өчен тырышлык куя. Ниһаять, икесе дә үз дигәннәренә ирешәләр. Тик менә Мидхәт Даишевка диссертациясен ике мәртәбә якларга туры килә. Чөнки Киевта гыйльми совет утырышында фәнни эшне мактап сөйләгән бер иптәш югарыга шикаять сырлап җибәрә. «Бу караңгы шәхесне ак шикәрчеләрнең якты җәмгыятенә уздырырга ярамый»,— дип яза ул. Мидхәт агага үзенең хаклыгын икенче кат Мәскәүдә расларга туры килә.

Хак эшнең ахыры барыбер әйбәт бетә. Кырыс тормыш дәрьясын кичкәндә, профессор Мидхәт Даишев шушы хакыйкатькә әллә ничә тапкыр инанган. Шуңа күрә ул студентларын да мөстәкыйль булырга өйрәтә, фикер кылычларын курыкмыйча кисештерергә өнди, диплом эшен язганда төп җаваплылыкны үз җилкәләренә күтәрергә куша. «Бүгенге студентка зур ышаныч белдерергә кирәк, ул — килер көннең производство тоткасы, фәнни хезмәткәр, ул — ил хуҗасы»,— ди Мидхәт ага Даишев.

## Затлы нәсел дәвамы



— Бигиев кирәк иде?

— Кайсысы? — Тау-металлургия институтының кадрлар бүлеге мөдире мөлаем гына елмайды да, бармагын бөгә-бөгә санарга керешә: — Иң өлкәне — Бигиев Әбдерәшит Мусиевич. Корыч эретү производствосы кафедрасы мөдире. Профессор. Техник фәннәр докторы. Вахит Әбдерәшитович — аның улы. Техник фәннәр кандидаты. Шул ук кафедрада доцент. Рәйсә Әбдерәшитовна — аның кызы. Техник фәннәр кандидаты. Инженерлык кибернетикасы кафедрасында доцент. Галия Әбдерәшитовна да өлкән Бигиевның кызы. Химия фәннәре кандидаты. Новосибирск университетында доцент.

Гаҗәп! Бигиевлар бөтен гаиләләре белән фәнни эшкә чумганнар икән! Аларның кайсы белән дә кызыклы әңгәмә корырга мөмкиндер. Әмма мин алдан ук профессор Әбдерәшит аганы күрергә исәпләп килгән идем. Тик ул институтның «Яшьлек» ял базасындагы дачасына китеп барган икән. «Корыч металлургиясенең физик-химик нигезләре» дигән темага уздырылачак унынчы Бөтенсоюз фәнни конференциясендә чыгыш ясау өчен доклад яза, диделәр.

Әлеге тын почмак Магниткадан җитмеш чакрымнар арырак, «Якты күл» дигән санаторий янәшәсендә, ерактан киртләч-киртләч күренгән Урал тавы итәгенә урнашкан иде. Табигать хозурында шортыдан гына, тыгыз мускуллы, төз гәүдәсен кояшта чыныктырган Әбдерәшит агай белән танышабыз. Кеше — китап әкрен генә ачыла бара, ачыла бара...

Ул Новосибирск өлкәсе Чанов районының Зур Тебис авылында 1917 елның 23 декабрендә дөньяга килгән. Әтисе Муса абый белән әнисе Зөлһирә апа исә тумышлары белән Пенза өлкәсенең Кикено авылыннан. Язучы Заһир һәм дин фәлсәфәсе белгече Муса Бигиевларның туганнары. Столыпинның аграр реформасын хуплап, 1906 елда Себергә чыгып китеп, татар авылын эзләп табып, яңа җирдә көн күрүчеләр. Алар, коры кул белән генә килгәнлектән, хуҗалыкларын тиз генә аякка бастыра алмаганнар. Бер тамыр җәйгәч инде, тормышлары көйләнеп киткән. 1929 елда инде алты ат, берничә тай, унбиш сыер-бозау, иллеләп сарык асраганнар. Ит сатып, ау белән шөгыльләнеп, гаиләдәге җиде баланы матур гына киендерә башлаганнар. Колхозлашу шаукымы кергәч, ишек алдындагы малларның санын киметергә уйлаганнар. Шуннан: «Сез күмәк хуҗалыкны күңелегез белән кабул итмәдегез»,— дип, Бигиевларны гаепли башлаганнар. Ир белән хатынны, аларның ике улларын, киленнәрен, оныкларын Томск өлкәсенә чыгарып җибәргәннәр. Ә уналты яше тулмаган өч балага — Әбдерәшиткә, Баригә, Маһирәгә авылда торырга рөхсәт иткәннәр. Алар Уразбай җизниләре белән Мәрзия апаларында калганнар.

Ике елда өчәр классны тәмамлап укыган Әбдерәшитне Кадыйр абыйсы Магнитогорск шәһәренә чакыра. Килә бу.

Икенче көнне Кадыйр институтка алып бара Әбдерәшитне. Анда әңгәмә уздыралар. Яшь кенә укытучы русча гариза яздыра. Аны шундук тикшереп тә чыга. Карасалар, гариза кызыл кара белән чуарланып беткән. Хәтта «металлургический» сүзендә дә ике хата киткән. Менә сиңа булачак металлург. Нинди хурлык!

Әбдерәшит башын аска иеп кенә урыныннан күтәрелә, аудиториядән чыгып китә башлый. Ә укытучы аны туктата:

— Борчылмагыз. Күчереп язгыз.

— Әй, булмый ла миннән!

— Русча язарга үзем өйрәтәм мин сезне, курыкмагыз!

Үҗәт егет өч еллык рабфакны ике елда ерып чыга. Сугыш башланыр алдыннан институтны тәмамлый. Дипломны гел «биш»ле билгеләренә генә яклап, июль башында заводның икенче мартен цехына инженер булып эшкә килә. Әмма бер ел үткәч, илне дошманнан саклауны изге бурыч санап, үз теләге белән сугышка китә. Ленинград божрасын өзүдә катнаша. Курск-Орел дугасы бәрелешләрен башыннан кичерә. Карпат тавында яраланып, госпитальдә дәвалангач, Мәскәү хәрби округына җибәрелә. Бусы инде 1945 елның май аенда була.

Берничә көнгә генә аны ялга Нугайбәк районының Париж исемле керәшен татарлары авылында яшәүче сөекле хатыны Мария Васильевна янына җибәрәләр. Үзе сугышка киткәч, Рәйсә исемле кызы да туган бит әле аның. Өзелеп күрәсе килә үзләрен!

Кайтып кергәч ул шаккатып кала. Кызы ничек үскән.

— Абый, исәнме? — диеп кулын суза Рәйсә әтисенә.

— Кызым, мин синең әтиең бит!

— Юу-ук, әнә минем әти,— дип бала Әбдерәшитнең стенага эленгән фотосына төртеп күрсәтә.— Ә син — абый.

Кызына тәмам ияләшеп беткәч кенә солдат тагын китеп бара. Хезмәт срогын тутырып, бер елдан гына әйләнеп кайта. Армиядән кайткан егетне танышлары күтәреп алалар. Кайда да менә дигән эш тәкъдим итәләр. Рәхим ит, сайла!

Әбдерәшит Бигиев 1946 елның 1 сентябреннән Магнитогорск металлургия институтында ассистент булып эшли башлый.

Бер көнне металлургия завод директоры Григорий Иванович (имтиханнар вакытында ул кабул итү комиссиясе рәисе итеп сайлана) яшь белгечтән кайбер нәрсәләр хакында сораша:

— Без икебез дә бер профессия кешеләре икән. Сез хәзер нинди фәнни эшләр белән шөгыльләнәсез?

— Мин технолог.

— Беләсезме нәрсә, Бигиев: бездә яхшы сыйфатлы корыч эретүе бик авыр. Чөнки камил технология юк. Исәп-хисаплар дөрес ясалмаган. Менә нәрсә белән кызыксынырга кирәк сезгә!

— Яхшы. Бу темага ныклап тотынырмын.

Шулай итеп, Әбдерәшит Бигиев «Корычны ничек эретергә?» дигән мәсьәләгә чишелеш эзли башлый. Фәнни журналларда берничә мәкалә бастырып чыгара. Ә кайбер сызымнарын Носовның институтта укый торган улы Дмитрийга биреп җибәрә:

— Бу кәгазьләрне әтиеңә күрсәт әле, яме. Карап чыгып, фикерен әйтсен иде.

Директор исә ассистентка күп акыл сатып тормый, очрашкач, хезмәтенә карата бер генә җөмлә белән бәя бирә:

— Дөрес юлдан барасың, энекәш, шулай эшлә!

Әбдерәшит, өлкән житәкченең киңәшен тотып, сәгатькә карап тормыйча, эшли дә эшли. Берникадәр мәгълүмат туплагач, кандидатлык диссертациясе язу турында да хыяллана башлый. Мәскәүгә барып, аспирантурага имтихан тапшырып кайта. Кафедра мөдире, профессор Трубин белән сөйләшеп көн үзәгендәге теманы ачыклап чыга.

— Сезне фәндә нәрсә кызыксындыра? — дип сорый аннан Георгий Константинович.

— Ике мәсьәләгә тукталдым мин. Корыч эретү процессындагы исәп-хисап һәм корыч агызу белән кызыксынам.

— Металлны агызу белән шөгыльләнүчеләр бездә житәрлек. Ә менә исәп-хисап белән берәүнең дә озак итеп утырасы килми. Эшне башлыйлар да ташлыйлар. Моңа беркемнең дә түземлеге житми.

— Диссертациягә бу теманы алырга мөмкинме соң?

— Мөмкин генә түгел, бик кирәк!

Күпләр галимнең хыялын аңлап бетермиләр шул. Завод директорлары, план куган булып, фәнни лабораторияләрдә эшләнгән яңалыкларны производствога кертергә ашыкмыйча тормыйлар. «Бу нәрсә барып чыгармы икән?» — дип, кан калтырап торалар. Андый чакларда Әбдерәшит Мусиевич 1939—1952 елларда Магнитогорск металлургия заводы директоры булып эшләгән Носовны исенә

төшерә. Карап торышка төмсә күренгән бу кешенең көч-гайрәте ташып тора иде. Сынаулар үткәргәндә ул җаваплылыкны һәрчак үз өстенә ала иде. Фәнне тәҗрибә ясап карамыйча алга җибәреп булмаганны аңлап эш итә иде дип, Әбдерәшит ага аны сагынып куя:

— Әгәр Григорий Иванович хәзер дә производствода эшләсә, әллә нинди могҗизалар ясар идек, билләһи!

Галимнәрнең ачышлары бик соңлап кына гамәлгә аша шул. Хәтта министр да: «Сезнең идеяне бик тормышка ашырыр идек тә, акча юк бит»,— дип Бигиев каршында акланудан узмый. Ә дәүләт программасына кертелгән, финанс ягыннан ныгытылган ачышларның кәгазьдә генә калуы файдагамы соң!

Болар турында уйласа, данлыклы исемнәр, орденнар белән бүләкләнгән профессор Бигиев җан тынычлыгын югалта. Әмма төшенкелеккә бирелми. Тавышын күтәрмичә генә теге яки бу иптәшкә болай диеп чыгып китә:

— Сез 74 яшьлек Бигиев белән шаярмагыз. Әгәр аның кәгазьдәге ачышын производствога кучерергә гомере җитмәсә, улы барлыгын онытмагыз. Әгәр инде улым Вахит та моны очлап чыга алмаса, артта ике оныК үсеп килә. Алар сезгә тынгы бирмәячәкләр. Сез металлургия мәсьәләләре белән барыбер шөгыльләнәчәксез!

Киләчәктә металлургиядә революция булачагы котылгысыз, ди галим. Иртәме-соңгы технология барыбер тамырдан яңартылачак. Моның сәбәбе бер генә: 250 яшьлек домна мичләре, мартеннар заман таләпләренә җавап бирми. Әйтик, домнага составында 55—60 процент тимере булган руда кирәк. Табигатьтә мондый бай руда бик булмый. Шунлыктан, токымнарны баета торган фабрика төзү мәслихәт. Өстәвенә, чуен эретә торган мичләргә күмерне дә кокска әйләндереп бирәләр. Бу — бик кыйммәткә төшә торган процесс. Димәк, домнадан, тау-баету һәм коксохимия производстволарыннан «качуын» хәерле. Аларны күп камералы бер агрегат белән алыштыру отышлы. Аны шундый талымсыз итеп эшләргә кирәк: теләсә нинди рудага, ташкүмергә риза булып «яшәсен», тиешле катнашмаларны кабул итә алсын. Корыч та шундый ук күп камералы агрегатта коелырга тиеш. Иң хикмәтлесе: моның өчен инде сәгатьләр кирәкми, минутлар да җитә. Мичтә барлыкка килгән газга да урын табылачак — ул тимер-томырны эретүдә кулланылачак. Ә шлак халык хуҗалыгына ашлама һәм төзелеш материалы итеп җибәреләчәк.

Әбдерәшит Бигиевнең бу технологиясен 1975 елдан бирле төрле урыннарда хуплап киләләр. Хәтта шушы идеягә таң калуларын да яшермиләр. Бу уңайдан кара металлургия министрлыгының беренче урынбасары Борисов бервакыт Бигиевкә: «Моның өчен сезгә үзегез исән чакта ук һәйкәл куярга кирәк!» — дип әйткән. Тик Әбдерәшит Бигиевнең идеясе һаман тормышка аша алмый. Завод директорлары: «Бездән киләчәкне сорамыйлар, бүген планнарны үтәсәң — шул җиткән»,— дип кенә җибәрәләр.

Баксаң, Габдерәшит Мусиевич Бигиев сигезенче дистәне ваклап бара икән инде. Иҗат һәм үз теорияләренне гамәлгә ашыру өчен каян шулкадәр көч табарга кирәк...

Профессор мөлаем гына елмая да, әйтеп куя:

— Хатынга рәхмәт инде. Ярты гасыр буе Мария мине аңлап яшәде. Укытучы дипломын тотып хурланмыйча өйдә генә утырды, сыкранмыйча өч балабызны тәрбияләп үстерде. Мине гаилә мәшәкатьләреннән тулысынча азат итте. Илнең металлургия заводларын аркылыдан-буйга иңләргә мөмкинлек бирде. Чит ил металлургларының эше белән кызыксынып, Швеция, Германия, Чехословакиягә дә барып кайттым. Әгәр Мария өйдә шартлар тудырмаса, ун китап та яза алмас идем. Аларның күбесе металлургия заводлары технологиясенә кагылышлы. Югары уку йортлары студентлары өчен ике дәреслегем бар. Аның берсен испан теленә дә тәрҗемә иттеләр.

Бигиевны чит илдә дә беләләр. Менә бер мисал: металлургия буенча Магнитогорскида уздырылган күргәзмәгә килгәч, Америка профессоры Роберт Пелке Әбдерәшит аганың өенә сугыла. Тәрҗемәче ярдәмендә алар дүрт сәгать сөйләшеп утыралар. Бигиев шакката: Көнбатышта яшәүче корыч белгече аның бөтен хезмәтләре белән таныш икән.

— Сезнең журналлар безгә килә бит,— дип елмая Пелке.— Нинди китапларыгыз барын компьютер барысын да хәтерендә тота.

— Без дә русча, немецча, инглизчә чыккан фәнни журналлар белән танышып барабыз. Мөһим дип саналганнарын тәрҗемә иттереп тә алабыз. Игътибарга лаеклы мәгълүматларны карточкага теркәп куябыз. Тик безгә компьютер булышмый. Каләм исән булсын!

Икесе дә көлешеп алалар. Аннары кунак тагын сорап куя:

— Сезнең кадрлар чит ил заводларында да яхшы эшлиләр. Теоретик, практик яктан әзерлеклеләр. Ничек укытасыз сез аларны?

— Китап буенча.— Бигиев шүрлегенә үрелә дә, «Туктаусыз корыч кою процессы», «Корыч металлургиясе» дигән дәреслекләрен алып күрсәтә.

— Боларны бүләк итә алмыйсызмы?

— Рәхим итегез! Автограф язып бирәм...

Япониядәге бер профессордан да хат килгән икән. Ул: «Әгәр сез каршы килмәсәгез, Магнитогорскига тәҗрибә уртаклашырга барыр идем»,— дигән. Бигиев ризалыгын белдереп шундук җавап җибәргән. Килсен! Үзара аралашу кешене ярлыландырмый, киресенчә, рухын гына баета бит ул.

Җитмеш яшен тутырса да, Әбдерәшит ага Бигиев һаман эзләнә, дөньяны колачларга теләп, егетләр кебек янып-көеп йөри. Аның җиде дистәдән узган гомере турында уйлыйм да, картлык, ял хакында сорау бирәм.

— Яшәгән саен фән дингезендә тирәнрәк йөзәсең икән аны,— ди ул.— Күз тимәсен, саулыктан да зарлана алмыйм әлегә. Рәхәтләнеп бакчада җир казыйм. Йөгерәм. Кышын чаңгыда, тимераякта шуам. Сиксәнгә җитсәмме?.. Тулсын әле сигез дистә, ни эшләргә икәнен шунда карарбыз!..

## «Капитал» тышлыгына төпләнгән Коръән



Ялга чыгуга, ул гаиләсе белән Сочига китеп барды. Эш мәшәкатьләреннән бераз онытылып торырга теләп, бу юлы сызым-кәгазьләрен дә үзе белән алмады. Кесәсенә бары тик адреслар язылган блокнотын гына салды. Чөнки Мәскәүдә яшәүче Вениамин дигән егеткә хат язасы бар иде. Ни өчен дигәндә, унҗиде яшьлек бу егет, поезд көпчәге астында калып, ике аягын тиң өздергән дә, бәхетсезлеген җиңеләйтергә теләп, эчүгә сабышкан. Хәзер ул көн саен кибет ишеге янына барып, фуражкасын җиргә куеп утыра да бер яртылык акча җыя икән. Ә аннары инде онытылып йөрәк яраларын дәвалый. Менә сиңа яшь егетнең яшәү рәвеше!

Бу турыда Ильяс Зиннуровка «Советская Россия» газетасы хәбәрчесе борчылып сөйләгән иде.

— Ильяс Юнысович, сез Веня белән охшаш язмышка тап булган кешеләр бит. Әллә хат язып карыйсызмы үзенә? Бәлкем, файдасы тияр, ә...

— Яхшы.

Диңгез буенда ял хозурына чумган көннәрдә дә ул биргән вәгъдәсен онытмады. Вакыт күплектән файдаланып, Вениаминга үнике битлек хат язып җибәрде. Китап сүзләрен күчермәде, билгеле. Үзенең тормыш юлы турында язды. Тормышка карата үз фәлсәфәсен белдерде. Аныңча, кеше гомеренең кояшы баеганчы яктылы-караңгылы мизгелләр адым саен очрап, чиратлашып тора. Якты дөньяда рәхәт тә, михнәт тә җитәрлек. Әгәр инде үзеңдә кыенлыкларны җиңәрлек көч туплый аласың икән, тигезлекне югалтмыйсың икән, син — кодрәтле вә бәхетле шәхес дигән сүз.

Гомер йомгагын сүтеп карасаң, ниләр генә баштан кичмәгән. Ильяс әле бишектә чакта ук ул туган йорт өстендә инде болытлар куерган. Колхозга кермәгәне өчен, әтисе Юныс абзыйны авылда кулакка санап, сөргенгә җибәрергә теләүчеләр табыла. Әмма куштаннар кара ниятләрен тормышка ашырып, хисетле ләззәт алырга өлгермиләр. Горур табигатьле Юныс абзый караңгы төндә чанага пар атын җигә дә, хатыны Галияне, балалары Йосыф, Локман, Зөләйха, Мохтар һәм юрганга төрелгән нәни Ильясны утыртып ерак юлга кузгала. Барнаулга кадәр шулай баралар. Аннан соң Караганда — Магнитогорск тимер юл төзелешенә килəләр. Утсыз, сусыз казармада яшиләр. Җитмәсә, монда мәктәп тә юк икән. Башлангыч классны бетергән Сәрвәр исемле бер казах «мөгаллиме»

белән балаларны укыту буенча килешү төзелә. Хәреф танырга өйрәнәләр. Карандаш белән яза башлыйлар. Ә инде эш, мәсьәләләр чишүгә килеп житкәч, көймәләре комга терәлә. Шуннан Сәрвәр тимер юлның мәгариф бүлегенә барып чын укытучы җибәрүне сорый.

Картала шәһәрендәге интернат-мәктәптә җиденчене бетергәч, Ильяс Магнитогорск каласындагы индустриаль техникумга укырга керә. Нинди группага эләгә диген әле?! Сталин премиясе лауреаты Володя Захаров белән бергә укый. Ул елларда исә Володяны бөтен шәһәр белә. Чөнки Татарстан улганы Мөхәммәт Зиннуров (Апас районының, Кормаш авылыннан), Иван Семенов белән бергә эшләгән шушы егет илнең атаклы корыч коючылар «өчлегенә» керә. Аларның хезмәт уңышлары хәтта язучы Александр Фадеевны да битараф калдырмый. Ул металлурглар турында әсәр язу өчен Магниткага килә. Володяларда фатирда тора. Аның белән бергә трамвайга утырып заводка йөри. Фадеев корыч-чуен коючыларның хезмәтләрен бөтен нечкәлекләре белән өйрәнә, технология, ярыш, төрле вакыйгалар турында мәгълүматлар җыеп, берничә калын дәфтәр язып тутыра. Володяның техникумга укырга керүенә дә Фадеевның катнашы бар.

Техникумны тәмамлагач, Ильясны Чиләбе металлургия комбинатына җибәрәләр. Егеткә 18 яшь тулган чак. Төс-бит чибәр. Буй — шәп. Көче ташып тора. Җиң сызганып, беренче мартен цехында корыч коючы ярдәмчесе вазифасын башкара. Берничә айдан соң аны мастер итеп куялар.

Ә бер көнне... Сыек хәлгә китерелгән корычны агыза торган улакны урнаштырган чакта бәлагә дучар була. Терәк ычкынып китә, егет алты метрлы биеклектән егылып төшә. Өстенә берничә тонна авырлыктагы тимер убылып төшә.

Белгечләр хисаплавынча, бер миллион тонна металл эшкәрткән вакытта, уртача, бер кешенең гомере өзелә икән. Ягъни бер елга 150 ләп металлург теге дөньяга китә. Яна, пешә, кысыла, җәрәхәт ала. Очраклылыкмы бу? Әллә инде законлаштырылган бәла-казамы?

Менә унсигез яшьлек Ильяс та 1958 елның 15 январь төнендә тимер йөге астында кала. Цехтагылар арлы-бирле йөгерешәләр. Кран чакырталар. «Ашыгыч ярдәм күрсәтү» машинасын көтеп изаланалар. Ильяс үз аңында, ул инде өметен өзгән:

— Тимер тузаны канга эләгәчәк... агуланудан котылу юк... Бәхил бул, әнкәй!

Әмма яшь йөрәкнең туктарга уенда да юк, сәгать кебек эшли. Ләкин Ильясның гарип булып яшисе килми. Шифаханәдә ул табибка ялвара:

— Зинһар өчен бирәр төрле агу бирегез миңа!

Классик көрәш белән шөгыльләнүче баһадир егетне нишләтте язмыш, нишләтте?!. Ике аяксыз килеш ничек яшәмәк кирәк!..

Егетне бер бүлмәле яңа фатирның ак җәймәле караватына алып кайтып салалар. Шулай итеп, газиз әнисе Гатия апа тәрбиясендә аяксыз тормыш башлана. Газета кыштырдатып, радио тыңлап үтә Ильясның кадерле көннәре. Яналыклар белән юанып, ул үзенең бөкән хәлендә калуын уйламаска тырыша. Ә бер көнне эфирда яңгыраган «Соңгы хәбәрләр» Ильясның сүнеп барган өметенә якты нур өсти. Мәскәүдә протез ясый торган фәнни-тикшеренү институты бар икән лабаса! Нигә әле шунда барып ясалма аяклар куйдырып кайтмаска? Очучы Маресьев шул хәлендә әнә самолет белән күккә дә күтәрелгән ич. Ул бу фикерен хәл белешергә килгән завод җитәкчеләренә дә житкерә. Алар кичекмәстән башкалага хат язып җибәрәләр. Комсомол өлкә комитеты да институтка шундый ук үтенеч белән чыга. Озакламый Мәскәүдән ике үтенечкә дә унай җавап килә. Шуннан соң металлургия комбинатының партия оешмасы секретаре Виктор Афонин, Ильясны кулына күтәреп, траптан самолет салонына меңгерә. Юл уңаенда Казанда бер тукталыш ясап, Мәскәүгә очалар.

— Без Чиләбедән ике Зиннуровны көткән идек,— дип шаяртып каршы ала мәскәүлеләр.— Ике хатта да бер үк егет турында сүз барамыни?

— Әйе,— дип җавап кайтара озатучы,— әгәр егетне аяклы итеп чыгарсагыз, без бик рәхмәтле булыр идек.

— Сау егет булып кайтуы үзенә бәйле,— диләр табиплар.— Югыйсә, бездә еллар буе кыл да кыймылдатмыйча ятучылар да бар. Урын-җир чиста, бүлмә җылы, тамак тук, кием-салымны юып торалар. Менә шушы рәхәтлек кайберәүләрне ялкаулыкка өйрәтә. Протезларын кочаклап, түшәмгә төкереп ята бирәләр.

Ярты ел эчендә әллә нинди кыенлыкларны җиңеп, сыңар таякка таянып, Ильяс Чиләбегә кайтып төшә. Баштарак күрше-тирәләрнең кызганулы карашларын күңеленә бик авыр кабул итә. Көндез урамга чыкмас була. Төннәрен генә

саф һава сулап кергәли. Әкренләп күнегә башлый, үзенә төбәлгән күз карашларына игътибар итмәскә өйрәнә.

Ильяс, кул белән идарә итүгә көйләнгән «Москвич»ын кабызып, политехника институтына еш бара башлый. Металлургия факультетына имтиханнар тапшырып, кичке бүлектә укырга керешә. Бер үк вакытта эшкә дә урнаша. Комбинатның проект бүлегендә сызымчы вазифасын башкара. Дөресен генә әйткәндә, заводта дөнья җимертеп эшләгәндә, ул кәгазь сызгалап-бозгалап утыручыларга көлемсерәп кенә карый, юкны бушка уздыручылар дип саный иде. Баксаң, бөтен казанышлар баш миендәге уйны карандаш белән кәгазьгә төшерүдән башлана икән ләбаса!

Егерме ел буе аз гына хезмәт хакына эшли. Бу хакны аңа өендә генә утырса да түләячәкләр югыйсә. Әмма хикмәт акчадамыни! Иң мөһиме — аңа кешеләр белән аралашырга кирәк. Вакытка да үзе хуҗа: яшь конструктор фәкать үзен кызыксындырган эшләргә генә алына. Чын иҗат белән шөгыльләнә башлый. Ахыр чиктә корыч эретә торган мичләр ясау, аларны камилләштерү белән мавыга. Союздагы барлык металлургия комбинатларын әйләнеп чыга. Ике атна Болгариядә эшләп кайта. Ильяс Зиннуров үз өлкәсендә 130 лап ачыш ясый. Биш фәнни китап бастырып чыгара. Аның җитәкчелегендә илле басма табаклы мичләр атласы — затлы китап дөнья күрә.

Мәскәүдә диссертация яклап, техник фәннәр кандидаты дәрәҗәсе алган Ильяс Юныс улы Мәскәүнең металлургия институты профессоры Леонид Евгеньевич Никольский белән бергә, «Электр ярдәмендә корыч эретә торган мичләрне проектлау һәм җиһазлау» дигән дәреслек язарга керешә. Ул хезмәт — металлургия буенча югары уку йортларында укучыларга адреслана.

Бүгенге көндә Ильяс Юныс улы Зиннуров — металлургия фәнни-тикшеренү институтында өлкән фәнни хезмәткәр. Ул хәзер үзенең кәгазь битенә төшерелгән идеяләрен гамәлгә кертү белән мәшгуль. Ә бу эш көйле генә бармый. Уйлап табучы конструктор адым саен каршылыкка очрап тора.

Мәскәү Кремлендә металлургия министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре каршында Ильяс Зиннуров, тирләп-пешеп, үзе уйлап чыгарган яңа мич проектының өстенлекләрен исбатлый. Аның өстенлекләре шунда: экологик яктан зыян китерми, продукциянең сыйфаты яхшырак була, мичне карап тору өчен эшче куллар да күп кирәкми...

Шулай итеп, әкренләп эш кузгала, Чиләбегә төрле заводларның инженерларын чакыртып алалар, гыйлемле белгечләрдән вакытлы иҗат коллективы оештыралар.

Һәрчак яңалыкка омтылган Нососибирск металлурглары Чиләбедә яңа төр җиһазлы мич монтажланганны белгәч, тыз-быз килә башлыйлар. Ике арада иҗади хезмәттәшлек урнаша.

Кытай белән дә элемтәләр җайланып килә. Алар Зиннуровның даими токта эшләүче мичләрен хуп күрәләр. Институттан ярдәм сорыйлар. Монысы инде — дөнья базарына беренче адым.

Ильяс әфәндесенең өендә булганда аның фәнгә кагылышлы бай картотекасын кызыгып карыйлардыр. Анда бөтендөнья металлургия институтларының конструкторлык бюроларының ни белән шөгыльләнгәннәре теркәлгән. Галим күңелендә чит ил белгечләре белән ярышырлык җиһазлар эшләү теләге туу бик табигый, чөнки ул бай мәгълүматлы заман белән бергә атлый.

Ильяс әфәндесенең китапханәсе дә бик күркәм. Киштәләрдәге энциклопедияләрнең, фәнни монографияләрнең, матур әдәбият әсәрләренең исәбенә чыгарлык түгел.

— Балачакта китапка сусап үстек бит, — ди Ильяс әфәнде. — Өйдә нибары Карл Маркcның «Капитал» тышлыгына төпләнгән бер Коръән бар иде.

Ул Металлурглар районының китап сөючеләр җәмгыятенә җитәкчелек итәргә дә өлгерә. Бу өлкәдә дә күпләр хуп күрерлек яңалыклар уйлап таба. Ул Россия «Китап» җәмгыятенең идарә әгъзасы итеп сайланган, рухын баетырлык шөгыль таба ала икән, димәк, ул бәхетле! Ильяс әфәндесенең гаилә бәхете дә түгәрәк. Хатыны Флюра ханым белән чөкердәшеп гомер итәләр, өч кыз үстерәләр.

Сочидан Ильяс әфәнде Мәскәүгә, ихтыяр көчен җуеп, өметсезлеккә бирелгән Вениаминга озын хат язды. Үз мисалында, кырыс тормыш вакыйгаларын уйгамәле белән сипләп, мәгънәле итеп язды. Күрешеп, гаплашеп утырырга да ризалыгын белдерде. Әмма хат-җавап алмады. Урман эчләрендә урман, дигән кебек, кеше күңеле дә катлаулы шул. Хәерлегә юрыйк...

# ШӘФКАТЬ НУРЫ ТАРАТУЧЫЛАР



Рәсемдә: *татар эшмәкәрләреннән бертуган Рәфис (уңда) һәм Нәфис Кашаповлар.*

**— Тарихта яхшы мәгълүм: татарның бай эшлекләләре гомер-гомергә халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгәннәр. Әдип, мәгърифәтче, китап бастыручы сыйфатында алар аң-белем тарату хәрәкәтендә актив катнашканнар. Октябрь революциясеннән соң мондый традициягә канлы нокта куелды. 70 ел узгач, яңа җилләр исте. Бүгенге заман яңа кешеләрне, яңа шәхесләрне тудырды. Сез, татар сәүдәгәрләренең яңа буыны буларак, химаячелек, меценат-иганәчелек традицияләрен яңартып җибәрдегез. Кайберләрен генә искә төшерик: татар дөньясы өчен бик тә кирәкле дини вә тарихи китапларны 1 миллион 40 мең тираж белән бастырып ил күләмендә, Европа, Азия илләрендә, АКШта бушлай тарату, Чаллы матбагасының өстәмә тиражлары, «Ак бүре» киностудиясен оештыру, мохтаҗларга ярдәм, мәчет төзүләргә акча бирү һ. б. Мондый игелекле эшләрегез өчен халык исеменнән рәхмәт сезгә! Бүгенге усал, кырыс, рәхимсез заманда акчасын «читкә ташлаучылар» әллә ни күренеп тормый. Сәүдәгәрләр арасында сез беренчеләрдән булып диярлек шәфкатьлелек, игелек үрнәге күрсәттегез. Моның «чишмә башы», тамыры, сәбәпләре, рухи нигезе кайдан килә икән?**

### Бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар:

— Кешенең табигате шулайдыр инде, без барыбыз да әти-әни, әби-бабаларның күпмедер сыйфатларын үстерүче, дәвам итүчеләр. Әтинең бабасы Сәгъдиев

Кашап (1880 елда туган) революциягә кадәр урта хәлле крестьян булган, иген иккән, үз тырышлыгы белән хәйран байлыкка ирешкән. Хуҗалыкка килсәк, таш амбар, таш койма, саман кирпечтән мал өе, ихата һәм абзар-кура тирәләре талчыбыктан үрелгән, 8 җанга алтыпочмаклы йортлары булган. Ул чакта да, әлбәттә, авылда кешеләр бер-берсенә булышып яшәгәннәр. Үз көче белән көн күреп яткан менә шушы гаиләгә утызынчы елларда, ягъни колхозлашу башлангач, кулак дигән тамга салалар. Авылның чабатадан «түрә» булган кайбер адәмнәре, Кашап кулакны Себергә куарга дип, кешеләрне көнсәгә чакырта башлый. «Менә сез Кашапта ялчы булып эшләгәнсез, шул хакта кәгазьгә кул куегыз»,— дип, төрлечә үгетләп, куркытып карыйлар. Тегеләр исә: «Без бит аңа дуслар-авылдашлар буларак ярдәм иттек, ул нинди кулак булсын...»,— дия-дия кәгазьгә кул куюдан катгый баш тарталар. Кыскасы, бернигә карамый аны һәлакәттән яклап-коткарып калалар.

Безнең бабай, ягъни әтинең әтисе Шәрифулла агай да хезмәт кешесе булган, бәхетен хезмәттә тапкан.

Әтиебез Рафаэль шулай ук эштән беркайчан куркып тормады. Кирәксә кулына балта тотты, кирәксә шофер булып машина руле артына утырды. Кем генә килеп сорамасын, ярдәм итүдән беркайчан баш тартмады. Соңгы вакытларда хәтта иске-москы рам, кабина, двигатель-мазар детальләреннән җыйнап, колхозга машина бүләк итте.

Нәселдән килгән менә шушы сыйфатлар безгә дә күчкән, күрәсең. Ялгызрак карт-карчыкларга кечкенәдән үк ярдәм итәргә ярата идек. Су ташу, кар көрәү, утын яру кебек эшләр безнең өчен үзенә күрә физзарядка иде. Ә бит зур эшләр майтару өчен дәрт, сәламәт тән, физик күнегүләр белән дус булу да бик кирәк.

Безнең буын коммунистик идеология йогынтысында тәрбияләнеп үсте. Муллык булачак, диделәр, анысы әле күпмедер бар иде. Кешелекле яңа буын, яңа кеше тәрбиялибез, диделәр. Менә монысы чын-чынлап әкият булып чыкты! Без, игезәк ике туган, совет армиясе хезмәтенә киткәч, хыял белән чынбарлык арасындагы аерманы бик тиз күреп алдык. «Дедовщина», ягъни уставтан тыш мөнәсәбәтләр чәчәк атып өлгергән иде. Иң көчле, иң гадел армия, дип өйрәтә килделәр безне. Баксаң, ул — яңа килгән яшьләрне кыерсыту, аларның шәхесен таптау, гаделсезлек мәктәбе икән. Башлап кем урлагандыр, белмибез, бездәге җиде казарманың бер ишеге юк иде. Менә шушы ишек өчен гел көрәш, урлашу, низаг, бәрелеш барды. Бәхетсез ишекләрнең җидесе тиң урыннан-урынга гел «күченеп» йөрделәр. Беренче ел хезмәт иткәннәрнең бүреген, шинелен, каешын, итеген урлаулар тәмам кәефне кыра, гайрәтне чигерә иде. Татарстаннан килгән егетләрне кыерсыта башласалар, милләте нинди булуга карамастан, без беренче чиратта ярдәмгә ташлана идек. Спорт белән дус булуның кирәклеген менә шул чакта ук аңлап өлгердек.

Инде менә байтак сулар акты. Хәзер без чынлап торып сәүдә эшенә җигелдек. Тормыш безне чыныктырды, көчле булырга, көрәшә белергә өйрәтте. Дөресен әйтик, химаяче булу безгә дан өчен кирәк түгел. Халыкка, милләткә, киләчәк көнебезгә ихластан файда китерәсе килә.

Әмма, тәҗрибә туплый торгач, милләттәшләребезгә әйтер сүзебез дә бар. Мисалдан башлыйк. Казанда дәүләтчелегебезне җимергән илбасарларга һәйкәл бар. Казан каласын Иван Грозный дәһшәтеннән яклап сугышкан үзебезнең каһарманнарга да һәйкәл салырга вакыт, дидек. Моның өчен, ни әйтсәң дә, акча кирәк. Хәтер көне уңаеннан, менә шушы һәйкәлне торгызу өчен, без җәмгысы 150 мең акча салган идек. Күптән түгел ишеттек: әлеге һәйкәл өчен бүгенге көндә халыктан нибары 500 мең сумнан артыграк акча җыйналган икән. Бик аз бу. Безгә бит милләтнең рухын, хәтерен, аңын уятырга вакыт. Мондый уникаль һәйкәлне салу — бөтен халык һәм дәүләт эше.

Бездә, Татарстанда, узган ел эшмәкәрләр съезды үткәрелде. Менә шул чакта, әгәр мөмкин икән, ачыклыйсы булгандыр: дәүләт бюджеты күпме икән дә, эшмәкәр-бизнесменнар бюджеты күпмегә тарта икән? Хәзерге заманда акча күпмедер дәрәҗәдә власть дигәнне дә аңлата. Ә акчаны дөрес итеп файдалана белү кирәк. Әйтик, АКШта бизнесменнар акчаның билгеле бер өлешен иҗтимагый институтлар, турыдан-туры аның проблемаларын хәл итүгә тоталар. Һәм бу дөрес: әллә ничаклы бюрократик аппараттан, идарә структураларыннан котылырга мөмкин. Шунысы да бар, эшмәкәрләр белән сәнгать әһелләре бергә атлаганда, киләчәк өчен янәшә торып көрәшкәндә генә җәмгыятьне һәм рухи, һәм икътисади яктан алга таба үстерү ышанычлырак булачак.

Зарлану дип уйламагыз, без, чыннан да, милләт мәнфәгатьләренә байтак хезмәт, акча салдык. Без әле юл башында гына. Ләкин, бер Кашаповларга гына

карап тору, фәкать алардан гына ярдәм көтү дөрес булмас иде, дуслар. Йөкне бергәләп тарту отышлы. Хәзерге яңа шартларда безнең милләттән дә байтак кына яңа эшмәкәрләр, сәүдә осталары, бизнесменнар үсеп чыкты. Татарстан һәм элекке СССР шәһәрләре саен байтак алар. Менә шуларга дусларча, туганнарча мөрәҗәгать итәсе килә: халкыбызның киләчәген бергәләп кайгыртыйк, мохтаҗларга бергәләп ярдәм итик! Моның өчен безгә вакыт та, тарих та, ходай да, дәүләт тә рәхмәтле булыр...

Әңгәмәдәшләр — **Рашат НИЗАМИЕВ, Шаһинур МОСТАФИН.**
*4 ноябрь, 1993 ел.*

**Редакциядән.** 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган каһарман бабаларыбыз истәлегенә һәйкәл төзү өчен акча җыю дәвам итә. Акцияне оештыручылар — «Татар-Информ» мәгълүмат агентлыгы һәм «Татар иле» газите редакциясе.

**«Гаделлек» акциясе дәвам итә! Милләттәшләребезгә аның махсус счетын искә төшерәбез: МФО 265005 Р/с 700161/700764 в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани.**

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕНӘ

(МӘХӘББӘТ ХАКЫНДА)

Сөю — ел буе үсә торган бердәнбер гөл.
Д. ДЖЕБРАН.

Табигать безне мәхәббәт өчен генә дөньяга китергән.
А. ЧЕХОВ.

Шатлык һәм бәхет — мәхәббәт балалары.
М. ПРИШВИН.

Ике йөрәк бергә кушылгач, җирне дә алтынга әверелдерәләр.
Японнан.

Сөю — өченче кешегә керергә тыелган храм.
Рус халык сүзе.

Дөнья белән сөю һәм ачлык идарә итә.
И. ШИЛЛЕР.

Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яши.
Татар халык сүзе.

Ныграк яраткан саен безнең тормыш киңрәк, тулырак һәм күңеллерәк була.
Л. ТОЛСТОЙ.

Әмма ләззәтле дә соң йөшерен газап, йөшерен яну!
Г. ТУКАЙ.

Һәрбер яраткан кеше — үзенә күрә алла.
МОПАССАН.

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,
Ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта.
Һ. ТАКТАШ.

Мәхәббәт — табигатьнең иң зур поэзиясе.
НОВАЛИС.

Сөю булмаса, дөнья боз белән капланыр иде.
Д. РУМИ.

Мәхәббәт — яхшылыкка кушылу һәм аның эчендә югалу теләге.
Д. ЛОНДОН.

Иң зур бирнә — мәхәббәт.
Ш. ГАЛИЕВ.

*Җыйнаучы һәм тәрҗемә итүчесе* — **Равил ГАБДУЛЛИН**

Мәхмүт Әхмәтҗан

# ЮКӘДӘ ИКӘН ЧИКЛӘВЕК, ЯКИ НИЧЕК ИТЕП ТАРИХНЫ БОЗАЛАР




Әкрәм Бейешнең «Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше»* дигән китабын укыгач, автор белән бәхәскә керү уңайсыз, хәтта мөмкин түгел, чөнки монда полемика предметы юк. Китапның иң зур өлеше һичбер документларга, фәнни чыганакларга нигезләнмәгән, уйдырмалардан, легендалардан тора. Минемчә, моны һәрбер объектив фикер йөртүче галим генә түгел, гади укучы да әйтер...

Шундый тәэсир кала: моңа кадәр кайбер башкорт зыялыларының бармактан суырып алган «хезмәтләренә» Әкрәм Бейеш үзенекеләрен өстәгән һәм шуларны бер тәртипкә-системага китерергә тырышкан. Ләкин система урынына, татарларны бер дәлилсез тоташ сүгү опусы туган.

Башкортстан хәлләрен шактый яхшы беләм, дисәм, хакыйкатьтән ерак китү булмас — шул гүзәл илдә туып үстем, урта белем алдым. Язмыш Казанга укырга китергәч тә Уфа, туган якларым белән тыгыз бәйләнештә тордым һәм әле бүген дә торам. Ел саен диярлек кайтып йөрим. Үз җиремнең шатлыкларына сөенәм, кайгыларына көенәм. Соңгы елларда азатлык җилләре көчәя башлагач, Башкортстанда милли хәрәкәт киң колач алды. Халыкларның үз республикасы, аның тарихы белән кызыксынуы артты. Бу бик әһәмиятле, чөнки үткәннәрне белү суверенитет, бәйсезлек өчен көрәштә стратегик юлны дөрес сайларга ярдәм итәчәк. Объектив шулай: әгәр башкорт халкы бу көрәштә татар белән берләшсә, бер сафта барса, һичшиксез җиңәчәк (бу хакта мин 1992 елның ноябрь санында «Сөембикә» журналында язып чыккан идем. Кара: «Бергә булсак — җиңәрбез»). Бу — аксиома. Кызганыч ки, кайбер башкорт туганнар моңа капма-каршы позициядә торалар, бергәлек потенциясен югалталар, үз халкына иксез-чиксез зыян китерәләр. Зәйтүнә Ханова, Саимә Гыйззәтуллина, Равил Исламшин, Марат Колшәрипов, Рәшит Шәкүров кебекләрнең тарихка бармак аша гына карауларын ничек тә аңларга була әле. Әмма Сәрия Миржанова, Нәҗибә Максютова кебек күренекле галимнәрнең, Булат Рәфыйков кебек абруйлы язучыларның шул тайгак юлдан барулары, бик йомшак итеп әйткәндә дә, үкенечле...

Сүземнән бераз читкә китеп булса да, психологик халәт (установка) һәм мотивлар турында кыска гына әйтмәкчемен. Кешедә ныклы, көчле эчке ышану (бу турыдан-туры дөньяга карашка бәйләнгән) — психологик халәт була. Шуның аркасында, кайберәүләрнең тирә-юньне генә түгел, тарихи фактларны да объектив итеп түгел, психологик халәт кушканча күрүе мөмкин. Моның мисаллары — адым саен. Әкрәм Бейештә формалашкан психологик халәт ярылып ята: татар халкына соң дәрәҗәдә дошманлык, нәфрәт. Әнә шуңа күрә татарларга бәйле һәр фактны автор бары тик кара сөзгеч аркылы үткәрә. Акны кара дип раслау юлына баса. Уртача күләмле китабында татарлар адресына 160 лап

---

Әкрәм Бейеш. Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше. Өфе, «Китап», 1993, 352 бит. Тиражы 30 мең.

мәртәбә кеше күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән пычраклар ата. Татар турында бер генә уңай сүз дә әйтми. Һәм бер генә сөйләгәне дә документларга нигезләнмәгән! Без мона кадәр, татар тормышын, тарихын белми торып, казакъ Чокан Вәлиханов, белорус язучысы Иван Чигринов, яһүд кешесе Аркадий Крупняковка (Ч. Вәлиханов — «Избранные произведения», И. Чигринов — «Плач перепелки»; А. Крупняков — «Марш Акпарса») безнең хакта булмаганны язганнар дип үпкәли идек. Әмма татарны шактый әйбәт белүче Әкрәм Бейеш белән чагыштырганда, алар гөнаһсыз аккошлар гына булып күренәләр...

Һәммәбезнең эшчәнлеге теге яки бу мотивка яки берьюлы берничә мотивка бәйләнгән була. Хәтта күршенә кунакка керүнең дә сәбәбе бар, әлбәттә. Бейеш әфәнде дә китапны мотиварсыз язмаган. Бүтәнчә мөмкин дә түгел. Китапның эчтәлегеннән аларны якынча санап та чыгарга була. Менә алар: башкорт халкының бүгенге хәленә тирән борчылу; башкорт халкы күңелендә татар халкына нәфрәт формалаштыру; тарихны белмәү яки белергә теләмәү аркасында, ялгыш нәтиҗәләргә килү; татар халкыннан, аның тарихыннан үлеп көнләшү, тар күңеллелек; Мәскәүнең «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән мәкерле сәясәтенә, балык кармакка эләккән кебек, кабу.

Китапта әйткәннәрне тезис формасында санап та чыгып була (алар ярылып ята): дөньяда татар дигән милләт юк; монгол армиясенең төп гаскәре явыз татарлардан торган, татарлар көнчыгыштан монголларга ияреп килгәннәр дә, җирле халыклар эчендә эреп беткәннәр, татарларның үз җирләре юк; үзәк аларга автономияне дә башкорт эшмәкәрләренең үтенүе буенча гына биргән; татар гомер буе башкортның иң явыз дошманы булган һәм ул бүген дә шулай, башкортка дошманлык татарның бозык канында, башкортлар бик борынгы, олы тарихлы, мәдәниятлы, күп санлы халык; татар кырып торганга гына, башкортның саны кимүгә барган; руслар татарларга караганда әйбәтрәкләр, әмма торабара алар да башкортка карата татарлар үткәрә торган сәясәтне тормышка ашыра башлаганнар; башкортның үз заманында зур, куәтле дәүләте, ханнары булган, аларны татар килмешәкләр юк иткәннәр, бүген шушы милли дәүләтне аякка бастыру өчен көрәш бара. Укучым, мин монда бер генә сүз дә үземнән өстәмәдем, һәммәсе — авторныкы...

Югарыда санап кителгән мотивларның һәрберсе бик көчле, шуңа күрә алар психикага чамадан тыш нык басым ясыйлар. Ә билгеле ки, хисләр акылга хуҗа булганда, аек фикер йөртү кыенлаша. Боларны мин түгел, фән әйтә... Мәсәлән, татарны бик начар итеп күрсәтү өчен, автор аңлы рәвештә төшенчәләрне буташтыру кебек олы гөнаһка бара. 13 биттә: «Татарлар, каршылык күрсәткән һәр урындагы кебек, бөтен Башкортстан буенча аяусыз кан коярга тотынган», — ди. Бейеш монда юри гафу ителмәслек ике зур төгәлсезлек җибәрә: беренчесе — монголлар яу чапканда язылган рус елъязмаларында сүз монголлар турында бара. Ә «татар-монгол игосы» дигән тәкъбир шактый соң, XIX гасыр уртасында гына фәнни әйләнешкә керә. Моны автор беләдер кебек, әмма аның бурычы башка — татарны хурлау. Бу өлкәдә ул рус шовинистларыннан да уздырып җибәрә. Икенчедән, ул чакта да, Октябрь революциясенә кадәр дә Башкортстан дәүләте булмаган, шуңа татарларның (әйдә, авторча булсын ди) бөтен Башкортстанны канга батырулары мөмкин түгел. Сорау туа: нинди җирләрне тәшкил иткән соң Башкортстан дәүләте? Текстта бу хакта сүзләр бар, әмма фәнни дәлилләр генә юк. Әкрәм Бейеш Сәлим Тәрҗемән, Ибне-Фадланга мөрәҗәгать итсә дә, алар башкорт дәүләте турында бер ни дә язып калдырмаганнар, ни генә әйтсән дә алар — галимнәр бит...

Татарстанда яшәүче татар халкы башкортларга, башкорт халкына тирән хөрмәт белән карый, аны чын күңеленнән ихтирам итә. Татарстанда 20 мең чамасы башкорт яши. Ә безнең президент аппаратында, җаваплы эштә Ишембайда туып үскән башкорт кызы Фирдәвес Бәширова (ире фамилиясе) эшли. Башкортлардан Казанда бик абруйлы рәссамнәр (мәсәлән, Абрек Абзгильдин, Рәшит Имаш зур галимнәр (мәсәлән, Казан технология университеты профессоры Наил Ганиев) яши, алар үз ана телләрен дә онытмыйлар. Гомумән, Казанда кешенең милләтен тикшермиләр: Уфага барып төшүең була, синең ата-бабаң белән кызыксына башлыйлар. Татар халкы лексиконында «килмешәк» (Әкрәм Бейешнең иң яраткан термин-төшенчәләреннән берсе) төшенчәсе юк. Татарстанда 90 милләт кешесе яши, сорагыз шулардан, милләтне тикшерәләрме татар илендә? Махсус әйтәм: башкорт халкы бай тарихлы бик үзенчәлекле борынгы халык. Теле, моңы бик матур һәм бай. Әнә шул халык исеменнән башкаларны кимсетү, хурлау егетлек түгел.

Әкрәм Бейешнын «дәлилләү алымнарына» шаккатарлык. Мәсәлән, 11 биттә: «400 мең кешелек гаскәрнең иң күбесе башкорт атлыларыннан торган».— ди, шуннан чыгып, ул чакта башкорт халкынын саны 2 миллион булган ди. Анын белән бәхәскә кермичә генә, Владимир Чивилихиннын 1982-84 елларда басылган роман-эссесенә мөрәҗәгать итмәкче булам («Память» романы күп телләргә тәрҗемә ителде. Аңа бәя бирүчеләр арасында галимнәр дә бар). Роман авторы Чыңгыз—Бату армиясе 150 мең кешедән артмаган, һәр сугышчынын өч аты булган (алмашка), чөнки шуннан артык кешене дә, атларны да туйдырырлык азык булмаган ди. Моңа әле ышанырга була...

Әкрәм Бейеш, татар тарафыннан Мисырга сатылган кешеләр (алар арасында башкортлар да күп булган, ди) ул илдә хакимлек иткәннәр, аларны мамлюклар дип атаганнар, ди. Башкорт җитәкчеләренең исемнәрен китерә. Тагын шул: Бейеш белән һичбер бәхәскә керми, Олжас Сөләймановның «Аз и Я» дигән, бөтен дөньяны шаулаткан хезмәтенә күз салыйк. Китап болай ди: «Кыпчак кабиләләре шулкадәр көчәйгәннәр ки, алар Мисырга бәреп кереп, дәүләт башына утырганнар. Пиреней ярымутравына, Франциягә барып чыкканнар. Наполеонның лейб-гвардиясендә хезмәт иткәннәр. Мәскәүдә аларнын каберләре табылды. Кыпчаклар — без ул, дала кешеләре» ... Мин бу фикергә аңлатма бирүгә алынмас идем. Чөнки болай да һәммәсе ачык.

Әкрәм Бейеш Алтын Урданы монголлар дәүләте дип күпме генә расларга тырышмасын, бөтен дөнья шуны белә: Алтын Урда — татар дәүләте, безнең дәүләт. 1993 елның җәендә Казанда анын 750 еллыгына багышланган халыкара конференция узды. Анда катнашучылар бу бөек татар дәүләте тарихын һәрьяклап анализладылар. Алтын Урданың башкаласы — Сарай-Бату, Сарай-Бәркә шәһәрләре үз заманында иң зур һәм затлы кала булганнар. Бу дәүләтнең 100 ләп шәһәрләрендә акчалар сугылган. Мәдәният, әдәбият бик алга киткән. Алтын Урданың күренекле шагыйрьләре әсәрләрен Казанда нәшер итеп торган «Мирас» журналы ай саен диярлек бирен бара. Аларны кем дә монгол теленнән тәрҗемә итеп тормый, чөнки шул чорның татар телендә иҗат ителгәннәр алар! Инде бу дәүләтнең чикләренә килгәндә, ул түбәндәгечә: тарихи заруриллык аркасында, Алтын Урда дәүләте җимерелгәч, анын хәрабәләре өстендә Себер, Казан, Әстерхан, Кырым ханлыклары (Нугай урдасы да) төзелгән. Алар һәммәсе дә татар ханлыклары. Инде Алтын Урда яшәүдән туктагач, Башкорт дәүләте төзелмәгән икән, моның шулай ук тарихи сәбәпләре булгандыр. Үкенечле ки, әлеге китапның авторы Алтын Урданы хурлау өчен, «башкорт галиме» (ул моны ишетсә, кабереннән сикереп торыр иде) Риза Фәхретдиннең түбәндәге сүзләрен китерә: «Чыңгыз хан балалары фәнгә, мәдәнияткә, мәгърифәткә хезмәт итмәгән; алар үзләре җимергәннәрнең йөздән бер өлешен дә кире тергезмәгән». Мөгаен, бу шулай булгандыр да, чөнки сүз монголлар турында бара. Әмма болардан чыгып, Әкрәм Бейешнын ясаган нәтиҗәсе исләр китмәле: «татарлар башкорт мәдәниятенең бөтен булган казанышын юкка чыгарган», имеш. Алтын Урда таркалгач, әгәр Әкрәм Бейешкә ышансак, башкортларны казан татарлары юк итеп барганнар. 27 биттә мондый «мәгълүматлар» китерелгән: «...Ирек сөяр башкорт халкы татар золымына баш имәгән, гасырлар буе көрәшне туктатмаган... Исәпсез озак вакытлар буена аяусыз кыру аркасында башкорт халкы ун мәртәбәгә кимегән». Өстәп шуны гына әйтәсе кала: бу хакта бер төрле дә документлар юк, һәммәсе уйлап чыгарылган. Иң гаҗәбе шул: Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынгач та, Казанда ир заты бөтенләй суеп бетерелгәннән соң да, татарлар үзләренең үтерү халәтен ташламаганнар, шуны дәвам итү өчен башкортның үз җиренә күчеп утырганнар икән ләбаса! Ә без, мәхлүклар, татарларның патша властьлары кысуыннан, миссионерлар золымыннан качып китүләрен генә белә идек. Бер мисалы — минем туган авылым Нәсибаш. Аны татар иленнән качып-күчеп килгән 11 гаилә нигезләгән (1759 елда); күрше Каратаулы башкортларыннан җир сатып алганнар, шул хактагы документка ике як та, Уфа вице-губернаторы, баш землемеры да кул куйган... Авторга моның кебек документлар да билгеле булырга тиеш, чөнки алар Уфа архивларында саклана...

Башкортларнын рус дәүләтенә «вассалитет булып керүләрен» автор күккә чөеп мактый. Монда безнең эшебез юк, урыс әйтмешли, «каждому — свое». Җаны теләгән, елан ите ашаган. Әмма бу очракта да автор: «патшага тугрылыклы хезмәт итеп дәрәҗә алган мөрзаларны-алпавытларны» да «типтәрләрне» «тешләмичә» үтә алмый (34 бит). 37 бит тулысы белән «килмешәкләрнең», беренче чиратта, татарларнын «пычрак битлеген ертып алуга» багышланган. Алай гына мени: типтәрләр татарлардан аерылып торганнар, тик хәзер генә күпләре үзләрен татар итеп таныганнар икән. Их бу татар шельмаларны, үз милләтләреннән баш

тартмыйлар бит, ә? Әмма хөрмәтле укучы, шуның белән эш бетте дип, нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. 41 биттә мондый «ачышлар» ясалган: «Татар ханнарының хөкеменнән котылу башкортка һичбер җиңеллек китермәгән... бу җәһәттән руслар күп нәрсәне татардан алган... Алтын Урда кул астындагы төрле җирләргә таралган татарларның гамәлдә үз территориясе булмаган. Татарстан АССР территориаль автономиясе көрәшне белмәгән татарларның үз таләбе буенча төзелмәгән... башкорт эшмәкәрләренең соравы буенча гына төзелгән». Күпме зәһәрлек, наданлык бар бу сүзләрдә! Аларда бер генә дөреслек тә, тарихи документларга таяну да юк. Мәсәлән, татарларга Алтын Урда кул астында яшәү ихтыяҗы булмаган, чөнки, бөтен дөнья тарихчыларының раславына караганда, Алтын Урда — татар дәүләте. Икенчедән, татар халкы 450 ел буена бертуктаусыз үзенең бәйсезлеге, дәүләтчелеген торгызу өчен көрәшкән. Бу хакта документлар бик күп, әмма язманың күләме аларны китерергә мөмкинлек бирми. 1905 елгы революциядән соң татарлар әллә күпме газета-журналлар, китаплар чыгарганнар. Театрлар эшли башлаган, Казан, Уфа, Җаек, Орск, Троицк, Оренбур кебек шәһәрләр татар мәдәнияты үзәкләренә әверелгәннәр. Минемчә, болар авторга да мәгълүм... Өченчедән, Татарстан АССР кемнеңдер соравы буенча түгел, нәкъ Башкортстан кебек үк, Мәскәү әмере белән төзелгән. Үзәкнең уе-карары башта түбәндәгечә була (бу хакта документлар бар!): «Ык елгасыннан алып Уфа, Стәрлетамакка кадәр (бу ике шәһәрне дә кертеп) булган территориядә (болар — татарларның компактлы яшәгән җирләре) референдум үткәрелгәч кенә, әлеге җирләрнең Татарстангамы яки Башкортстангамы керүе хәл ителәчәк, халык теләге искә алыначак». Әмма Мәскәү аңлы рәвештә провокациягә бара: татар белән башкорт арасында даими низаг тудыру өчен, халык белән дә, аларның җитәкчеләре белән дә киңәшми, әлеге территорияне кертеп, 1919 елның 20 мартында Башкортстан автономиясен төзи. Бу вакытта Казан губернасында аклар белән сугышлар бара... Бер кемгә дә сер түгел: Башкортстан хөкүмәте Оренбурдагы бер авылдан Уфага күчеп килгәнче, бу шәһәрдә, гомумән, башкортлар яшәмәгән. Ул — татар шәһәре була. Болар һәммәсе дә китап авторына билгеле, әмма ул юри чынбарлык, документлар белән исәпләшми, чөнки алар аның схемасына туры килмиләр, ялган концепциясен челпәрәмә китереп ваталар. Бейешнең тарихи очеркы, башыннан алып ахырына кадәр, аерым максатларга хезмәт итүче сәясәт кенә. Әмма бу сәясәт каш буйыйм дип, күз чыгаруга бик тартым. Чөнки Бейешнең китабы, иң беренче чиратта, Башкортстандагы татар милли хәрәкәтенә каршы юнәлдерелгән. Шул көрәшне идеологик яктан ныгыту, аклау өчен язылган бу китап. Кызганыч ки, Уфада татар телен, мәдәниятен көчле кысу бара. Башкортстан Конституциясеннән «татар теле — дәүләт теле» дигән маддәне алып ташлау, нәшриятта татарча китаплар басылмау (татарлар сан ягыннан башкортлардан күбрәк), радио-телевидениедән татарча тапшыруларның бик аз булуы һ. б. — шуларның кире какмаслык мисаллары. Башкортстанда 1 миллион 300 меңнән артык татар, Татарстанда исә 130 мең чуаш яши. Радиобыз көн дә диярлек чуаш телендә тапшырулар алып бара. Концертлар бирә. «Сувар» дигән зур форматлы республика газетасы чуаш телендә чыга. Дистә еллар буена Татарстан Язучылар берлегендә чуаш секциясе эшләп килде. Ә менә мин туып үскән Салават районында татарлар башкортлардан сан буенча аз гына ким булсалар да, район газетасы бары тик рус һәм башкорт телләрендә генә чыга. Эш кәгазьләре дә, вывескалар да — башкорт телендә...

Сүз дә юк, Татарстан Башкортстан җирләренә дәгъва ясамый, андый ихтыяҗ да юк. Әмма Бейеш кебекләр бертуктаусыз татарларның хисләрендә мәкерле уйнасалар, тарихларын фальсификацияләүне ташламасалар, Уфа татарларының 1919 елда үткәрелмәгән референдумны хәзерге көндә үткәрүләре бик тә ихтимал. Ә моның ни белән бетәсен бүген берәү дә фараз итә алмый.

Легенда тудыручыларның хыялый уйлары, фантазияләре иксез-чиксез булса да, чынбарлыкта алар сабын куыгы кебек шартлый торалар. Мисалы: 50 биттәге «пассаж» «Башкортларның хан нәселен татар-монгол илбасарлары тоташ үтереп бетергән». Сорау: булмаган ханлыкның ханнары буламы?! Монысы гына җитмәсә, укучыга тагын яңа «күчтәнәч»: завод салу өчен урысларга башкорт җирләрен татарлар сатып яткан икән бит (62 бит)... менә шундый икән татар килмешәкләре! Пошел! диясе генә кала. Монсы да аз икән, белегез: татарлар белән бәйле урыслар да начарлар икән. Мәсәлән, Казан губернаторы А. В. Волынский башкортларның санын икеләтә киметү өчен (әлбәттә, татар коткысына бирелү шаукымы бу!) эш башлаган. Урыс күрше әйтмешли, чем дальше в лес, тем больше дров. Әйдә 72 биткә күз салыйк әле: «Руслар мишәр белән татарны (әһәмият бирегез: янәсе алар аерым ике халык) һәрвакыт шымчы итеп

файдаланган». 73 бит: Урыс: «...мишәрләргә үзләре басып килеп утырган башкорт җирләрен биргән, типтәр һәм әтәмбәйләрне (бобыли) ... башкорт халкын кыруда ихлас катнашканнары өчен бүләкләп куйган». Әлбәттә, татарның җан дусты урыс булуы балигъ адәмнәргә генә түгел, хәтта бала-чагага да мәгълүм: 1552 елда Явыз Иван бөтен татар ир затын юри генә, шаярып кына суйган ич! 94 бит: мишәрләр башкорт явына кушылу урынына, «үз отрядлары белән башкортларга каршы чыкканнар» (мәсәлән, 1755 елда)... Пугачев восстаниесе вакытында мишәр старшиналары патша гаскәрләрен яклаганнар» (105 бит). Шундый кешеләр була, эче, башы авыртса да, йокысы туймаса да, хатыны белән ызгышса да, акчасы бетсә дә, яңгыр яуса, яумаса да, күршесен гаепли. Әкрәм Бейешның хәле дә, кызганыч, нәкъ шундый...

Автор хаклы рәвештә Салават Юлаев белән горурлана. Мин моны чын күңелемнән хуплыйм. Салаватка якташлык хисләрем (аның туган авылы Юлай-Шаганай безгә 20 чакрым тирәсе. Хатыны Әминәнең туган авылы — Калмаклар — безгә 5-6 чакрым гына булыр) йөрәгемә көч, дәрт бирә. Салаватка районда беренче һәйкәлне бүтән берәү дә түгел, ә Нәсибаш татарлары куйды! Әмма объектив булу өчен, шуны да искә төшерик: әгәр Дм. Фурманов «Чапаев» дигән роман язмаса, без легендар Чапайны белмәс яки бик аз белер идек. Чөнки гражданнар сугышында Чапаев кебекләр аз булмаган. Әгәр рус язучысы Степан Злобин Салават хакында тирән эчтәлекле, эмоциональ яктан көчле роман язмаган булса, мөгаен, башкорт халкының бөек улы, гаскәрбашы, шагыйре Салават Юлаев хәзерге дәрәҗәдә шөһрәт казанмас иде. Болар — сүз уңаеннан гына... Әкрәм Бейеш ни генә әйтмәсен (мәсәлән, ул татар һәм башка килмешәк халыклар русларга кушылдылар ди, кара: 114 бит), Пугачев армиясендә татарлар да бик күп хезмәт иткән. Аларның да беренче дәрәҗәдәге кыю җитәкчеләре булган. Шул хакта документлар да җитәрлек сакланган. Тик аларга таянып китап язучылар гына булмаган... Шулай да, соңгы елларда күренекле язучыбыз Туфан Миңнуллин «Канкай улы Бәхтияр» дигән трагедия язды. Табигый ки, татар телендәге ул әсәр рус дөньясына үтеп керә алмады. Әгәр шундый китапны үз вакытында рус әдибе язган булса...

Нәфрәт, дошман күрү өстенә, вөҗдан тезгенең дә ычкынса, «дошманыңа» әллә ниләр әйтергә була икән. Китапның 131 бите нәкъ әнә шундый: «озак гасырлар буена хакимлек иткән татарлар, башка халыкны аяусыз кырып, сан ягыннан үзләре туктаусыз үскән. Рус дәүләтенең власте астында алар башкорт кебек кырылмаган. Гомумән, саннарын нык арттыру белән бергә, татарлар Башкортстанда да бик күбәйгән». Әй, Бейеш әфәнде, шуны да белмисез мени: Санкт-Петербург татар сөяге өстендә тора. Сәбәп: руслар арасында ташчылар булмаган диярлек, татарлар әйбәт ташчы-төзүчеләр булганнар. Петр патша аларны фин сазлыкларына китереп тутырган. Күбесе шунда эшләп, үлеп калганнар. Бу хакта язучы, драматург, олугъ артистыбыз Габдулла Шамуков «Казан утлары»нда язып чыккан иде. Петр Беренче Иранга каршы сугыш алып барганда төп көч татарлардан торган. Югалту искиткеч зур булган. Мондый мисаллар бик күп. Диссертация язганда, мин күп кенә татар авылларында булып, икенче бөтендөнья сугышына киткән татарларның 70-80 проценты яудан әйләнеп кайтмауларын белдем (алар күбрәк пулеметный расчетта, ПТРда хезмәт иткәннәр. Ә иң зур югалтулар шунда була). Мәскәүдәге фәнни җитәкчеләрем моны белеп, шаккаттылар. Татарның тарихы бөек җиңүләр, фаҗигале җиңүләрдән, коточкыч югалтулардан тора. Бу яктан ул Россиядәге бердәнбер халык, әмма без, кайберәүләр кебек, бер вакытта да елап утырганыбыз, фальсификация юлына басканыбыз юк. Моңа безнең вакытыбыз юк. Без эш аты, иҗат утында янабыз. Шуңа күрә кайберәүләрнең бүрәнә аша бүре куып, татар халкына пычрак атуы җирәнгеч хисләр генә тудыра...

Әйтмичә булдыра алмыйм: Бейештәге кебек башка халыкларга патология дәрәҗәсенә җиткән күралмаучылыкны моңа кадәр ишеткәнем дә, укыганым да юк иде. Бу хакта Татарстанның берничә халык язучысы белән дә сөйләштем, алар да шулай диделәр.

Әйдә, тагын авторга сүз бирик. Китабының 172 битендә ул болай яза: «татарларның бөтен корткычлык эшенә карамастан, башкортлар тимер осталыгын югалтмаган». Гаҗәп хәлләр: йорт саен йөреп, татарлар башкортларга тимер белән эш итмәскә, дип кисәтү ясап йөргән икән ләбаса. Русча әйткәндә, «при затемнении разума до чего оказывается можно додуматься. Просто чудеса и не более»... 180 биттә дә «ачыш» зур: «Татарлар башкортларны йотарга, үз милләтенә кушарга тырышкан». Ялганның да ялганы, әлбәттә. Бүген Башкортстанда татарларга карата әнә шундый сәясәт үткәрелсә дә (югарыда без аның төпле

мисалларын китердек) әмма бу тырышуларның нәтиҗәсе нуль булачак, чөнки һәр халыкка үз теле газиз. Бу — бәхәссез. Башка җирләрдә хәлләр ничектер, әмма мин туган авылда революциягә кадәр дә, 80 еллар башына кадәр дә, бер генә егетебез дә башкорт кызына өйләнмәде. Хәзер дә бу хәл юк дәрәҗәсендә. Нәтиҗәне укучы үзе ясар инде...

Китапның 187 битенә күз ташлыйк әле, нинди «ачышлар» бар икән: «Башкорт автономиясенең хас дошманы булып баштан ук татарлар калкып чыккан» икән. Монда бер генә төгәлсезлек бар: татарларның башкорт автономиясенә каршы килүен дәлилләүче бер генә документ та юк! Тагын алга киттек тә, 196 битне ачтык ди: «рус, татар, чуаш һәм башка күчеп килгән крестьяннар... башкортны бетереп, калган-поскан җирен басып алырга ярсып киткән... Алар башкортны өендә дә, урамда да, юлда да, кайда туры килә шунда үтергән, тоташ өй эче, авылы белән юк иткән!..» Болардан соң рус, татар, чуашларны һ. б. вәхшиләр дип атарга мөмкиндер. Тик шунсы гына: бу хакта да рәсми чыганакларны таба алмассың! Ә менә башка төрле документлар бар: сәнәк сугышы вакытында (1918 ел) 14 башкорт авылы кешеләре «кызыл Нәсибашка» (безнең авыл) ябырылып килгәннәр, «ирләрен сәнәккә алабыз, хатыннарының имчәкләрен кисәбез!» — дип ярсыганнар, авылның дүрт ягыннан кереп ут салганнар. Бәхеткә, Блюхер армиясенең бер батальоны (командиры Туманов) халыкны коточкыч афәттән коткарып калган. Үткән үткәндә калсын, авылдашларым башкортларга ачу тотмыйлар, үзара дус яшиләр.

Әкрәм Бейешкә «күктән саннар алу» бер ни дә тормый, фантазиясенең иге-чиге юк: аныңча 1917 елда башкортларның гомуми саны 1 миллион 400 мең кеше тәшкил иткән. 1917—1922 елларда башкортларның 57 проценты һәлак ителгән. Монда бәхәскә керүе кыен, әмма автор китергән саннарны расларлык дәлилләр күренми. Укучыдан гафу үтенеп, тагын бер шактый озын өзек китерәм. Мин аның эчтәлеген үз сүзләрем белән әйтеп бирсәм, күпләр ышанмас иде, чөнки муафыйкъ акыл моңа сәләтле түгел... 295 биттә китерелә торган өзек менә шул: «Башкорт мәдәнияте, иң элек әдәбияты, башкорт язма телен гамәлләштерү (сүз 1924 ел турында бара) белән татар мәдәниятенең басымыннан котылган. Ләкин бу хәл башкортны татар дошманлыгыннан коткармаган. Олысыннан алып кечесенә кадәр бөтен татар башкортны данлы тарихы, үз теле, милли үзенчәлеге һәм милли горурлыгы булган өчен, һәм, гомумән, дөньяда яшәгән өчен мәңге дошман күргән һәм шул дошманлык һич тә бетми торган ажарлы бер үчкә әйләнгән». Шуны гына әйтә алам: бу сүзләрне дәлилләрлек бер генә факт та, документ та юк! Һәммәсе дә ялган! Мөгаен, автор үзенең татарларга булган мөнәсәбәтен шулай читләтеп күрсәткәндер. Китапның эчтәлеге нәкъ шул хакта сөйли. Миңа рус шовинистларының яһүдләр хакында язган пычрак китапларын укырга туры килгәне бар. Аларны Бейешнең татар халкына булган нәфрәте белән бөтенләй чагыштырып булмый. Шовинист булсалар да, аларда күпмедер оят бар, ә бу китапта — юк. Автор шулай ук бүгенге башкорт мәктәпләренең һәм алардагы укучылар санының кимүе турында борчылып яза. Бу очракта аны аңларга була. Әмма бу процесста «явыз татарның» бер катнашы да, гөнаһы да юк. Киресенчә, элекке СССРда, бүгенге Россия Федерациясенең бер генә төбәгендә дә күрелмәгән хәл Башкортстанда булды: бик күп татар мәктәпләрен көчләп, бүтән телгә, ягъни, башкортча укытуга күчерделәр. Бу хакта ун меңнәрчә ризасызлык хатлары Уфага, бигрәк тә Мәскәүгә явып торды. Әмма «кара эш» дәвам иттерелде. Безнең райондагы татар мәктәпләре (алар 7) моның белән ризалашмыйча, русча укытуга күчтеләр.

37 еллар мәхшәре илебез халыкларын гына түгел, бөтен дөньяны тетрәтте. Татар иҗат интеллигенциясенең 90 проценты (русларда 10 процент) юк ителде. Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Галәү, Ш. Усманов, Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими, Ф. Сәйфи-Казанлы, Һ. Атласи, Х. Габәши, М. Крыймов, Н. Хәким, Г. Нигъмәти кебек йөзләрчә татар зыялылары Ежов, Берия җәлләдлары тарафыннан җәзалап үтерелделәр. Башкорт халкының ул еллардагы югалтулары шулай ук зур булды. Бу ике республика, хәзер билгеле булганча, җәзалаулар үткәрү полигоны итеп махсус сайланган. Моңа җирле халыкның мөселман кавеменнән булуы да тәэсир иткән дип уйланыла. Шуңа күрә башкортны күпләп юк итүне «татар шагыйре» (рәсми яктан татар шагыйре саналдымы соң ул?) Сәйфи Кудашка гына кайтарып калдыру хакыйкатькә туры килә алмый. Мин бу олы әдипкә тел тидермим, чөнки кулымда бер төрле дә документлар юк. Ә «тегe хатын шулай әйткән иде» алымы белән эш итү көлке һәм көенечле нәрсә...

Бу мәсьәләгә махсус тукталмаска да булыр иде, чөнки татар халкының кайчан, нинди шартларда, нинди компонентларда оешуы, барлыкка килүе белән

галимнәр арасында шик тудырмый, ул мәсьәлә хәл ителгән. Бу хакта безнең кулдагы документлардан тыш, кытай, һинд, фарсы, гарәп, европа чыганаклары күп. Дөнья татарны бөек дип атый. Әмма без моңа карап масаймыйбыз. Башкорт халкы төрле компонентлардан барлыкка килгән кебек, татар канында да күпләр каны ага. Мәсәлән, шуларның иң көчлесе кыпчаклар (бу яктан башкортларга туганлыгыбыз шактый якын) болгарлар, фин-угыр кабиләләре һ. б. Кайбер галимнәрнең татарны болгар компоненты белән генә чикләргә тырышуы тарихи дөрес түгел. Болгар дигәннән, аларның теле шул ук татар теле бит. Нурихан Фәттахның «Шәҗәрә»сен укыгач, көнчыгыш татарлары, болгарлар кебек үк, Урта диңгез тирәләреннән килеп чыкмадылар микән дигән уй туа. Чыннан да кытай белән монгол арасында яшәгән, теле белән генә түгел, антропологик яктан да бөтенләй аларга охшамаган татарлар ул якларга ничек, кайдан килеп чыктылар икән? Киләчәктә тарих моңа җавап бирер дип ышанырга кирәк. Татарлар мәсьәләсендә Әкрәм Бейеш рус шовинистларының: «ерак көнчыгыштан килгән татарлар русның мәңге дошманы булды, шуның өчен Казан ханлыгын юк итү табигый күренеш», дигән позициясен үзенчә яклый. Аныңча, «Себер, Кырым, Әстерхан, Казан ханлыкларында татарлар, мишәрләр аерым-аерым төркем булып барлыкка килгәннәр (316 бит). Болай дип сөйләнүләр фәнни яктан бөтенләй дөреслеккә туры килми. Монда татарларны бер-берсенә каршы куеп, таркатырга тырышу кебек мескен сәясәт кенә ята. Бүтән бер ни дә түгел!

Китапның 320 битендә автор тагын башкорт мәктәпләренең ачы язмышына туктала. Ул әйткәннәр нигездә дөрес. Әмма авторның: «республикада башкорт мәктәпләре рус һәм татар мәктәпләре күргән игътибарны күрми», дип әйтүе белән ул хаклы микән? Бәлки, автор башкортча укытуга көчерелгән татар мәктәпләренең хәлен күз алдында тоткандыр? Сүз уңаенда, Татарстанда да бу өлкәдәге хәлләрнең мактанырлык булмавын әйтергә була. Моннан 2—3 ел элек кенә Казанда бер генә татар балалар бакчасы да, мәктәбе дә юк иде. Бу тенденция район үзәкләренә, зур авылларга да үтеп керде. Татарларның 43 проценты, катнаш никахта торып, башка милләтләргә, шул җөмләдән башкортларга да (Уфадагы туганнарым үрнәгеннән чыгып әйтәм) балалар үстерәләр. Әнә шуңа күрә татар балаларының нибары 7 проценты гына үз ата-анасы телендә укый һәм сөйләшә. Бәла шунда, моның өчен конкрет кешене гаепләве дә авыр. Хәлләр шулай... Татарларның күп булса, дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Бу да сәясәт: еракларга «гасыр төзелешләренә» ун меңнәрчә татарларны җыр-музыкалар белән озаттык, алар урынына, КамАЗ, Түбән Кама төзелешләренә шулкадәр үк урыс һ. б. халык килеп тулды.

Әлеге китапның соңгы юллары менә мондый «пафослы», «аккордлы» сүзләр белән тәмамлана: «башкорт җиде гасыр элек татар явы җимергән милли дәүләтен торгызырга тиеш». Тарих, шул җөмләдән халыклар, милләтләр тарихы безгә буйсынмый торган закончалыкларга кайтып кала. Бейеш күпме генә акны кара итеп күрсәтергә тырышмасын, тарих шуны белә: татарлар бервакытта да башкорт дәүләтен җимергәннәре юк. Чөнки андый дәүләтнең дөньяда булганы да юк. Ә татар дәүләтен ике мәртәбә: беренче мәртәбә — монголлар, икенче мәртәбә — руслар җимергән, юк иткән. Беренчесендә бу эшне Бату хан, икенчесендә Явыз Иван «башкарган». Шулай булуга карамастан, татар халкы монголларга да, русларга да үч тотмый, кайберәүләр кебек ялган тарих язарга алынмый. Бер генә татар язучысы да, тарихчысы да авыз ачып башкортка начар сүз әйткәне, язганы юк. Минемчә, Әкрәм Бейеш өчен генә башкорт халкына ачу тотмыйбыз һәм тотмаячакбыз да. Чөнки аерым кеше әле милләт дигән сүз түгел, кем әйтмешли, аттан ала да, кола да туа... Татар халкы хакында Әкрәм Бейеш язганнар, югарыда әйткәнемчә, ялганнардан, тоташ фальсификациядән тора. Объектив килгәндә, татар халкының тарихы башкорт халкы язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Монгол да, урыс та безне туздырган. Тоталитар система чорында интеккәннәребез дә гел уртак... Чынбарлык шуннан гыйбарәт: татар халкы, югары мәдәният иясе буларак, бу интеллектуаль байлыгын барлык башка төрки халыклар, бигрәк тә башкорт туганнар белән уртаклашкан. Казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак һ. б. халыклары моның өчен татар халкына тирән рәхмәтләрен әйтәләр. Бүген дә Казагыстан, Урта Азия республикаларында меңнәрчә татарлар ихлас күңелдән шул илләргә хезмәт итәләр. Татарның мең еллык язма әдәбияты бар, революциягә кадәр татар телендә җәмгысы унбиш меңгә якын исемдә китап басылган. Калган төрки халыкларда исә шул чор эчендә 600 исемдә чыккан. Татар халкына килгәндә, аның башкорт туганнарына төрле өлкәләрдә күрсәткән хезмәте иксез-чиксез зур. Шул ук вакытта башкорт экстремистлары арасында: «татарларны куарга!» дигән лозунглар яңгырый. Мин

аларга урта гасырлар тарихының гарәпләргә багышланган өлешен укырга тәкъдим итәр идем. Анда мондый сүзләр бар: «маврлар (гарәпләр) Пиреней ярымутравыннан киткәч, Европа 500 елга артка тәгәрәде». Кыскасы, ут белән шаярырга ярамый. Уфа татарлары өчен Башкортстан — туган ил. Тарихи чыганакларга караганда, башкортлар кебек үк, татарлар да бер үк вакытта Урал тавы итәкләренә, Агыйдел буена килеп утырганнар. Явыз Иван Казанны алгач, Казан татарларының бер өлеше элек Көнчыгыштан килгән татарларга өстәлгәннәр. Моны башкорт дәүләтен басып алу дип атау тарихи чынбарлыкка туры килмәү генә түгел, гаять аянычлы әхлаксызлык та.

Һәм соңгысы. Мин — татарның бер улы гына, шуның өчен халык исеменнән сөйли алмыйм. Әмма татар халкы, фальсификациягә корылган һәм милли низаглар китереп чыгаруга сәбәпче китабы өчен, Әкрәм Бейешне Гаагада урнашкан халыкара судка бирсә, хөкемгә тарттырса, һич тә гаҗәпләнмәм.

Рифгать Әхмәтҗан

# ХЫЯЛ ҺӘМ ХАКЫЙКАТЬ

Уфада чагыштырмача зур тираж белән күренекле тел галиме һәм тарихчысы Әкрәм Биешевнең (Бейеш) «Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше» дигән китабы басылып чыкты. Безнеңчә бу әсәр башкорт тарихын яктыртуда өр-яңа бер этап. Бу китап турында бер «шаулап алсак»та бер дә артык булмас. Чөнки ул шуңа лаек.

Ә. Биешев мәсьәләгә элекке стереотиплардан кырка баш тартып килә. Китапта моңарчы яшерелеп яки махсус рәвештә игътибардан читтә калдырылып килгән бик күп фактлар, мәгълүматлар китерелә. Шулар нигезендә урыс яулапалуларының башкорт вә бүтән халыкларга бернинди файда китермәве һәм китерә алмавы кире кагылгысыз рәвештә исбат ителә. Ә. Биешев конкрет шартларда өстен сыйныфлар эксплуатациясе «сыйнфи төс түгел, милли төс алган» дип расльй. Әгәр башкортлар үз җирләрендә башкаларның тыкшынуыннан азат булып яшәсә, «башкорт хуҗалыгы торгынлыкны белмәс һәм крепостной коллыктагы кыргый Рәсәйнекеннән бер дә ким үсмәс иде, урыс тарихчылары башкорт җәмгыятен гомумән объектив үсеш законнары тәэсиреннән читкә куя һәм аның этәргеч көче итеп кансыз урыс колониаль сәясәтен күрсәтә», ди. Китапта башкортларның озак гасырлар дәвамында күчмәчелектә калуы урысларның аларга нормаль хуҗалык бәйләнешләры корырга бирмәвеннән килгәнлеге бик ачык яктыртыла.

Гомумән Ә. Биешев башкорт халкының тирән милли фаҗигасен бик ачык вә әтрафлы итеп күрсәтә алган. Аның язганнары яктылыгында «урыс-башкорт дуслыгы» идиллиясеннән берни дә калмый.

Башкорт милләтенең Октябрь революциясеннән соңгы язмышын яктырткanda да Ә. Биешев кырыс хакыйкатьтән читенми: ул Ленинның һәм большевикларның милли мәсьәләдә алдакчы һәм икейөзле булуларын, бер нәрсә сөйләп, икенче нәрсә эшләүләрен ышандыргыч мисалларда тасвирлап бирә. Монда аеруча шуңа игътибар итәсе килә: Ә. Биешев, кайберәүләр шикелле, бөтен бәлане И. Сталинга якмый, большевистик милли сәясәтне формалаштырган кеше В. И. Ленин үзе икәнлеген шәрран яра әйтеп сала.

Китапның азакк өлешендә урысларның «кеше хокукларын» милләт хокукына каршы куеп, милли кимсетүләрне акларга маташуы хурлык белән тамгалана. Чыннан да, кеше язмышы милләт язмышы белән аерылгысыз бәйләнгән һәм «кеше хокуклары» милләт хокукларын читләтеп түгел, шул хокуклар аркылы гына гамәлгә ашырыла ала бит!

Китапта башкорт халкын саклап калу өчен бәйсезлекнең мотлак кирәк булуы тирәнтен нигезләнә.

Бүгенге чорда кешелеккә экологик кризис яный. Шул шартларда, ниһаять, халыклар арасында чын дуслык, тату, мәдәни мөнәсәбәтләр, чын интернационализм урнаштырасы иде. Чын интернационализм бүтән халыкларның милли горурлыгына хөрмәт дигән сүз ул. Ягъни дөньядагы барча халыклар мәңге яшәсен, мәңге яшәргә тиеш... дигән принцип милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсендә төп иман, дөрес, сәламәт төшенчә булсын. Әлбәттә, халыклар, милләтләр мәңге яшәмәячәк. Монда халыкларга мөнәсәбәт турында сүз бара. Бу урында барыбызга да мәгълүм затның — Ф. Энгельсның бер сүзен искә төшерү урынлы: «милләтара мөнәсәбәтләр ахыр чиктә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек булырга тиеш». Әйтик, бик сирәк кеше генә (уртача ун меңгә берәү) йөзгә җитә. Ләкин бу хәл безгә һәрберебезнең йөзгә җитүен теләргә һәм шул теләкне тормышка ашыру өчен кулдан килгән бөтен нәрсәне эшләргә комачауламый. Без чирләгән, авыр хәлдә калган, бәла-каза, афәтләргә тарыган кешегә һичсүзсез, шартсыз ярдәм итәбез. Шуның шикелле үк, бетү, югалу алдында торган милләткә бүтән, яхшырак хәлдәге милләтләр милли үзенчәлекне, миллиятне сакларга реаль ярдәм итәргә тиешләр. Тик шул тәкъдирдә генә башкорт халкы шикелле, милләт буларак югалу чигенә якынлашкан халыкларга ары табан яшәү һәм үсүнең, тәрәккый итүнең реаль шартларын булдыру мөмкин булачак.

Кызганыч ки, көчлеләр һаман милләтара көрәш ысулын тота һәм, кызганыч ки, башкорт (милләте) вәкиле Ә. Биешев тә шул әхлак тарафдары.

Гаҗәп хәл, ләкин факт!

Ә. Биешев татарларны, башкортлардан үзгә буларак, читтән килгән, килмешәк (килмешәк сүзен ул йөз тапкыр кабатлый), халык дип бара. Янәсе, татарлар, инде формалашкан бер этнос буларак, Бату хан яулары белән яисә шулар артыннан күченеп килгән һәм, Идел буе халыкларын кырып, үзләре шунда ныгып урнашкан. Ә. Биешев кенә түгел, күп урыс һәм кайбер бүтән тарихчылар да наданлык аркасында яклаган бу теориянең, объектив анализлаганда, тотып карар җире дә юк. Шактый ышандыргыч чыганаклар күрсәткәнчә, Бату ханның Көнчыгыш Европаны яуларга килгән гаскәрендә ике катлам аерылган: чирүнең үзәген тәшкил иткән вә каты дисциплина белән ныгытылган монголлар (монгол сүзе үзе «төп колонна» дигәнне белдерә) һәм алар кул астындагы татарлар. Яуның татар өлеше монгол өлешеннән (төрле чыганаклар буенча) 4—5, 9—10, хәтта, 20 тапкыр күбрәк булган. Татарлар Бату гаскәренең алгы сафында барган, иң башлап алар сугышка кергән, төп монголлар исә хәлиткеч мизгелдә генә бәрелешкә катнаша торган булган. Бусы дөрес. Ләкин (татар сүзе каян гына килеп чыкмасын), Бату гаскәрләрендәге татарлар бериш халык, бер «милләт» кешеләре булмаган. Татар сүзе бу чорда монголлар яуга җибәргән һәрбер кабилә-кавем вәкилләрен белдергән һәм ул «татарлар» бик төрле элементлардан — «кыргый» (Чыңгыз яклы булмаган) монголлардан, төрле төркиләрдән, тунгус-маньчжурлардан торган масса, «талпа»* булган. Әгәр ул татарлар бериш халык булса, Бату походка чыкканнан соң озакламыйча үзара сөйләшеп, гаять зур күпчелек тәшкил итәрәк, монголлар хакимиятен бик тиз бәреп төшерерләр иде бит! Тик ул татарлар бик төрле-төрле тел-төркемнәр массасыннан гыйбарәт булганга күрә генә монголлар алар өстеннән хөкем йөртә алган. Монголлар «татарлар» составына яу барышында җиңелгән дошманнарны да бик теләп кертә торган булган. Бату ханның «татарлары» арасында шул ук башкортлар, мордвалар һәм, хәтта, урыслар да булганлыгы мәгълүм. Бу нәрсә Ә. Биешевкә дә мәгълүм булмый калмагандыр. Нигә соң ул һаман татарларны кайдадыр (ә шулай да кайда соң, Әкрәм әфәнде?) формалашып, күченеп килгән халык дип расларга тырыша? Ә менә шуның өчен: имеш башкортның милли территориясе бар, ә татарныкы юк, ул милли җирен югалткан халык (19, 24, 29, 41, 185, 275 битләр) һәм шуңа күрә аның территориягә хокукы юк һәм ул территориаль автономия теләмәгән, дип яза. Әмма башкортка килгәндә дә, ул да бит «килмешәк». Ул Арал белән Балхаш тирәләрендә яшәп, Көньяк Уралда X гасырдан башлап кына һәм төрле элементлардан — кыпчак һәм угыз төркиләреннән, монгол телле һәм тунгус телле кабиләләрдән, фин-угырлардан укмашып тәшкилләнгән. Башкорт кабиләләренең исемнәре үк шуны күрсәтеп тора: катай (монгол телле борынгы кытань-кидань кабиләсе), унгар (венгрлар), кыпчак, сальют (монголча сәлҗугут — «сәлҗүкләр»), бөрҗән (монгол ыруы Борҗигин, шул ырудан

* Талпа сүзе урыс сүзе түгел: ул монгол телендә сугышка кергәндә дошманга каршы алдан җибәрелгән әсирләр төркемен белдергән (монголлар шундый ысулны еш кулланган).

Чыңгыз хан чыккан) һ. б. Башкорт сүзе үзе борынгы төрекмән-угыз диалектындагы бәш + кур «биш түгәрәк, биш табын, биш кабилә» һәм фарсыча шул ук мәгънәдәге пәнҗ кәрдә сүзләренең кушылып китүеннән пәйда булмыштыр.

Хәзерге татар халкы да Урта Иделдә, Ука елгасыннан алып Агыйделгә кадәрге киң мәйданда X гасырдан Биләр (Бүләр) шәһәре нигезләнүдән алып, әкренләп төрле компонентлардан формалашкан халык. Һәр халыкның милли мәйданы — аның этнос булып формалашкан җире була һәм әйтелгән җирләр — татарның милләт мәйданы.

Бу урында шуны әйтергә кирәк: Көнбатыш Европа әһелләре Алтын Урда заманында ук татарларның территория мәсьәләсенә гаҗәп дәрәҗәдә гамьсез, ваемсыз караганлыгын билгеләп үткәннәр. Бу гамьсезлек хәзер дә дәвам итә һәм моны Ә. Биешев бик дөрес тотып алган. Болгар мәсьәләсендә котырып бәхәсләшкән татар белгечләре, татар милли туфрагы турында ләм-мим сүз әйтмиләр.

Ә. Биешевның татарны «җиргә хаксыз» дип күрсәтергә тырышуын, татарны батырып, башкортны калкытырга теләвеннән дип аңларга мөмкин. Мондый фикер аның китабында татарлар турында әйтелгән бүтән сүзләрен укыгач, ныгый төшә. «Татарларның башкорт илен... аяусыз кыруы», «татар деспотизмының кансыз хөкеме», «татарлар яулап алынган алдынгы халыкларның мәдәни тормышына катнаша башлаган, үзләре артык берни өстәп алмаса да», «300 еллык татар изгенлегендә башкорт халкының 10 тапкыр кимүе» (27 бит), «Татар хөкеме китергән искиткеч зур зыян» (49 бит), «Күп гасырлар буе хакимле иткән татарлар, башка халыкларны аяусыз кырып, сан ягыннан үзләре туктаусыз үскән» (131 бит), «татарлар, табигатьләренә хас булган бөтен агрессивлык белән» (180 бит һ. б.) гыйбарәләрне укыйсың да аптырашта каласың. Күп гасырлар буе бергә-бергә уртак табыннан ашап, бер үк җырларны җырлап яшәгән якын кардәш төрки халыкка карата мондый авыр сүзләр яудыру өчен бик күп фактлар, көчле дәлилләр китерергә кирәк иде бит! Хәлбуки, алар юк.

Гадәттә һәрбер халык, һәрбер кеше кебек үк, гаепсезлек презумпциясе белән файдалана. Ә. Биешев, күрәсең, татарларга карата гаеплелек презумпциясеннән чыгып фикер йөртә. Ягъни ул татарлар эшләргә мөмкин булган һәрбер яманлыкны инде эшләнгән дип әйтергә ашыга.

Ә. Биешевның сүзләре башта ачу китерә, аннары аның үзенә карата кызгану уята (башкортларның татарга кушылу хәтәре чыннан да булганга шундый сүзләр әйтә бит ул) һәм ахырда көләсене китерә. Менә укып карагыз: «Олысыннан кечесенә тиклем бөтен татар башкортны данлы тарихы, үз теле, милли үзенчәлеге һәм милли горурлыгы булган өчен һәм гомумән дөньяда яшәгән өчен мәңге дошман күргән һәм шул дошманлык һич тә бетми торган ажарлы үчкә әйләнгән» (295 бит). Моны укыгач көләсе дә килми башлый. Чөнки Ә. Биешевның максаты фаш була. Юкәдә икән бит чикләвек! Юк, Әкрәм агай, ничек теләсәгез дә, барыбер ызгышмыйбыз, талашмыйбыз, әрепләшмибез! Татар күңелендә башкортка карата ажарлы үч әгәр дә ул язганча икән, нишләп соң йөз меңнәрчә татар-башкорт гаиләләре бар? «Ажарлы үч» алу өчен кияүгә баралар һәм кәләш алалармыни? Татарлар Салават Юлаев белән, ә башкортлар Муса Җәлил белән горурлана икән, нигә моңа сезнең эчегез поша? Тарихи һәм гуманистик хакыйкать шуннан гыйбарәт: татарлар һичкайчан үзләре яисә дәүләтләре исеменнән башкорт булганы өчен башкортка явызлык итмәгән, татар белән башкорт һичкайчан бер-берсенә каршы корал күтәрмәгән!

Ә. Биешев татар сүзе чыккан саен диярлек аңа әшәке сыйфатлар тага, һәрхәлдә берәр начарлык якмый калмый. Мондый гамәле татарга карата нәфрәт уяту теләгеннән чыга димичә мөмкин түгел. Хәлбуки, татар белән башкортның аеруча (тик бу икәүгә генә хас) уртак мәнфәгатьләре булу — объектив хакыйкать һәм татар-башкорт берлеген тормыш үзе таләп итә. Бәс, шулай икән, башкорт җанатары Ә. Биешев үз мәнфәгатьләренә каршы килә, утырган ботагына балта чаба.

Аннары шуны да әйтергә ярыйдыр, чын күңелдән башкорт халкына ярдәм иткән, башкорт теле яшәсен дип эш күргән татарлар да аз булмаган бит. З. Вәлиди гаскәрендә, мәсәлән, татар офицерлар һәм солдатлар шактый күп сугышкан. Ә. Биешевның китабында рәсемнәре бирелгән кайбер кешеләр, әйтик Ильяс Алкин, чыкылдап торган татар. Шунысы характерлы: Ә. Биешевның татарларга яккан гаепләре һавада даими асылынып кала: алар конкрет фактлар белән ныгытылмый (һәм ныгытыла да алмый). Ә кайбер очракларда мәгънәсез гаепләү килеп чыга. Мәсәлән, гражданнар сугышы чорында Уфада эшчәнлек күрсәткән (үзенә күрә атаклы) коммунист Шәмигулов башкорт автономиясенең хас дош-

маны булган. Ә. Биешев аны «башкортны эчтән җимерү өчен башкорт булып язылган» татарларның берсе итеп күрсәтә. Ләкин ул Шәмигулв башкортның гына түгел, татарның да хас дошманы, мәсәлән, ул татар мәктәбен бетерү, татарча укытуны туктатып, балаларны беренче класстан урысча укытуны таләп иткән һ. б. Ул, дөресен әйткәндә, татар да түгел, башкорт та түгел, «большевик» кына. Шәмигулов кебекләр өчен татарны гаепләүнең мәгънәсезлеге күренеп тора.

Ә. Биешев асылда, чебенне арыслан итеп күрсәтергә тырыша. Менә урыс арасында, әйтик Елец урыслары белән Орел урыслары арасында («Урлау» хикәясендә Н. С. Лесков язганча) «дошманлык» булган. Татар белән башкорт арасындагы «каршылык» менә шул бер милләт эчендәге каршылашулар тирәнлегендә генә бит! Чөнки татар белән башкортка дошманлашырга объектив җирлек юк! Татар да, башкорт та бер үк шартларда яши. Шулай булгач, нигә бер-беребезне хурлашырга икән?

Бу урында авторга: «Кешегә бәла теләгәнче, үзенә бәхет телә!» — дигән татар-башкорт мәкален искәртәсе килә.

Кайбер татарлар, чыннан да, башкортны татар халкының бер өлеше дип карарга тели (шулмы «аҗарлы үч»?). Мин үзем дә «нигә ике-өч аваз аермалыгын саклау өчен генә шулкадәр тузына икән бу башкорт?» — дип уйлап һәм сөйләп куйгалыйм. Әмма ләкин шуны өзеп әйтергә кирәк: урыстан үзгә буларак, татарлар башкортларга карата хәйлә-мәкер, куркыту-өркетү, үтерү-кыру алымнарын кулланмаган. Моны алай түгел дип беркем дә исбат итә алмас! Һәм әгәр интернационализм ул бүтән халыкның патриотизмын хөрмәт итү икән — без Ә. Биешевның һ. б. патриотизмын хөрмәт итәбез, тик алдау-арттыруларын гына кичереп бетермибез. Һәм татар иҗтимагый оешмаларының башкортларга үз телен-динен саклау юлында ярдәм итәргә әзер булуларын белдерүе очраклы түгел. Ә. Биешев исә торып-торып гаҗәп сүзләр тондыра. Мәсәлән, имеш, урыслар татарлар сүзенә карап башкортны кысканнар. Ә. Биешев тагын Татарстан АССР башкорт сәяси эшлеклеләре таләбе буенча оешкан дип раслый. Татарның үз патриотлары булмаган, имеш!

Болар барысы да, инде әйткәнебезчә, Ә. Биешевның милләтара аяусыз көрәш сәясәтен хуплаганлыгын күрсәтә.

Усал сүзләрне без дә әйтә беләбез. Рәхим итегез: заманабызның төп тенденциясе халыклар арасында аңлашу булган хәлдә Ә. Биешев якын кардәше татар халкының борын төбендә йодрык уйната. Һәм бөтен көче белән аңлашуны булдырмаска тели.

Ә. Биешев, күрәсең, «башкорт милли җире» төшенчәсе башкортларның язмышын хәл итүдә зур уңай сәбәп, ниндидер өстенлекләр таләбенә нигез булыр дип исәпли. Ләкин бит «борынгы башкорт милли җирләрен» башкортларга беркем дә кайтарып бирмәячәк, һәм бу дөрес тә. Чөнки җир үлеләр өчен түгел, тереләр өчен кирәк. Мин шәхсән (сәясәтче түгелмен, бәлки ялгышамдыр) берәр милләтне саклау максатында шул милләт үзе баш, үзе түш булган җир тәгаенләнеп, милләт вәкилләре карамагына тапшырылу ысулы кулланылуны бик ихтимал дип саныйм. Әмма ләкин ул тәкъдирдә билгеләнгән җирнең зурлыгы, микъдары халыкның җан исәбенә карап кына билгеләнә ала. Ягъни башкортларга хәзерге Башкортстанның (табигый шартларны искә алып) өчтән бере генә тиячәк. Чөнки XX гасырда бер дәүләт чикләрендә азчылык тәшкил иткән бер халыкның нинди дә булса «тарихи хокуклырга» таянып, зур күпчелек өстеннән хөкем йөртүе мөмкин түгел!

Ә. Биешевның ысулына хас булган тагын бер якны әйтмичә булмый. Ул да булса бик шикле чыганакларга мөрәҗәгать итү. Шундыйларга М. Өметбаевның «тарихи» уйдырмалары, башкорт дастаннары һәм аның каһарманнары һ. б. керә.

М. Өметбаев (һәм аның кайбер элгәрләре, шул хисаптан татар тарихчысы Хисаметдин Болгари да) тарих язганда фәнни тәнкыйтьчәнлек принцибын бөтенләй исәпкә алмаганнар, аларга, мәсәлән, Искәндәр Зөлкарнәй (Александр Македонияле) Башкортстанга килеп кальгаләр корган дип яисә атаклы фарсы-таҗик шагыйре Г. Җами Татарстанда үлгән дип язу берни дә тормаган. Билгеле, аларның «башкорт шәһәрләре» турында язганнарына да чынлап ышанып булмый.

Башкорт эпосы, мәгълүм ки, үз телендә нигездә XX гасыр башында гына язып алынган. Аның теле шактый дәрәҗәдә шул чордагы укымышлылар телен чагылдыра. Һәм андагы барлык сүзләрне дә» борынгы башкорт теленнән килә» дип раслау мөмкин түгел. Башкорт дастаннары гаҗәп дәрәҗәдә «борынгыча». Анда дәүләт дисциплинасы, бердәм илдәге бердәнбер патшага буйсынып эш итү шәрәфе, ил чикләрен саклау, тел-дин өчен тору һ. б. кебек үскән дәүләтчелек

атрибутларын чагылдырган төшенчәләр юк диярлек. Конфликтлар примитив һәм беркатлы: гыйшык, гаилә, арысланны кем үтергәнлек турында бәхәсләр һ. б.— болар бит ыругчылык һәм кабиләчелек заманыннан. Азмы-күпме оешкан дәүләт өчен ерткычлар белән көрәш — проблема түгел... Башкорт эпосын укып, ул шундый фаҗигале язмыш кичергән халыкныкы дип әйтүе дә авыр. Шуңа карамастан, Ә. Биешев бу дастаннарда алга киткән дәүләтчелек, гөрләп торган сәүдә һ. б. чагылышларын күрергә тели. Шикле чыганакларга мөрәҗәгать итеп, шулардан алынган «мәгълүмат»лардан үзенә кирәгенчә бинилһая чамасыз нәтиҗәләр чыгарса да, Ә. Биешев халык тарихы иң ачык вә тәфсилле рәвештә чагылган чыганакка — телгә (белгечлеге буенча телче булса да) мөрәҗәгать итми. Бу хәл аңлашыла да; тел мәгълүматлары авторның татарлар турында әйткәннәрен тулысынча юкка чыгара. Мәгълүм ки, татар һәм башкорт телләрен, төрки уртаклык өстенә, тик аларга гына хас булган меңнәрчә изоглоссалар* берләштерә. Башкорт телендәге вокализм системасы Урта Иделдән килгән (борынгы татар теленнән дисәм, Ә. Биешевның каһәре килер дип куркам): шуңа күрә Р. Г. Кузеев хәзерге башкорт теленең төп чыганагын борынгы Болгар дәүләте җирлегендә дип бара һ. б. Бу фактлар һич кенә дә дошманлыклы мөнәсәбәтләр турында сөйләми, алар гасырларга дәвам иткән дуслык вә хезмәттәшлек нәтиҗәсе һәм шаһиты.

Дөрес, берара башкортлар татар дәүләте кул астында булган. Ләкин алар ул чакта тулы үзидарәгә ия булган һәм татарларның аларны, урыслар шикелле, якадан алырга мөмкинлекләре дә, хаҗәтләре дә булмаган. «Татар игосы» — урыс тарихчылары уйлап чыгарган нәрсә икәнлеге торган саен ачыла бара.

Ә. Биешев китабында бик шикле нәрсәләрне чын дип ышандырып раслау очраклары әйтелгәннәрдән тыш та күп әле. Шундыйларга, мәсәлән, борынгы башкорт ханлыгы булу, Кол Галинең «әйле башкорты» булуы, монголларга каршы башкорт-болгар гаскәре оештырылуы, башкортларның XIII гасыр башында ике миллионга җитеп, «татар хакимлеге чорында ун тапкыр кимүе» турында язганнары керә: Боларның кайберәүләре татлы хыял җимеше булса, икенчеләре татарларга кара ягу өчен уйлап чыгарылган әкиятләр, ахры.

Барлык әйтелгәннәр үз урынында дөрес булса, шунысы да хактыр: Ә. Биешевның бу китабы — үз туган телен кайнар яраткан кешенең шул телнең әкренләп бетүен сизеп язган әсәре. Ул, бер яктан, хыял һәм уйдырмалар белән тулган булса, икенче яктан, хөкемдарлар тарафыннан тырышып яшерелеп килгән тирән дөреслекне зур көч белән ачып бирә торган документ, тарихи документ. Бу китапның кыйммәте һәм әһәмияте авторның теләк вә мәнфәгатьләреннән читкә чыга. Бу китап шуңа дәлил: юк, беркем дә «үзе теләп», ирекле баштан икенче телгә күчми, «үзихтыярлы күчү» — ул инсафсыз, намуссыз сәясәтчеләрнең уйдырмасы гына! Һәр халык соңгы мөмкинлеккә кадәр, җан ачысы белән диярлек, үз телен — мәдәниятен сакларга тырыша. Ә Биешевның китабы шуңа шаһит.

* Изоглосса — бердәй тел күренеше.

# ТУГАН ҖИР ҖЫЛЫСЫ...



Бу айда күренекле әдибебез, халык яратып укыган бик күп хикәяләр һәм повестьлар авторы, оста каләм иясе, нечкә күңелле язучыбыз Рафаил ага Төхфәтуллинга 70 яшь тула.

Р. Төхфәтуллин мәктәптә укыган елларында ук әдәби иҗат эше белән кызыксына башлый. 1948 елда «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында аның «Сабакташлар» исемле беренче хикәясе басыла. Хикәяләре тупланган беренче җыентыгы «Таныш гөрелте» 1954 елда дөнья күрә. Шул вакыттан бирле узган дүрт дистә ел эчендә әдип берничә пьеса, йөздән артык хикәя һәм дистәгә якын повесть иҗат итте, рус һәм татар телләрендә бик күп китаплар бастырып чыгарды.

Язучының күпчелек әсәрләре сугыш һәм сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган. Аларда шул кырыс чорга хас реаль чынбарлык һәм кеше язмышлары тасвирлана, хезмәткә, җиргә, яшәү шартларына мөнәсәбәттә авыл кешеләренең тормышчан, тулы канлы образлары, кызыклы, үзенчәлекле характерлары сәнгатьчә гәүдәләнеш таба. Әдипнең авыл темасын яктырткан күп кенә хикәяләре һәм бигрәк тә «Авылдашым Нәби» (1957), «Йолдызым» (1962), «Тамчылар ни сөйли» (1964) кебек повестьлары татар прозасының алга таба үсүен, камилләшүен күрсәткән, тормыш материалын сәнгатьчә анализлауда татар прозасына яңа төсмерләр, сыйфат үзгәрешләре алып килгән әсәрләр буларак бәяләнә.

1959 елда Р. Төхфәтуллин Әлмәткә күчеп килә һәм биредә үзенең күпсанлы хикәяләрен, шулай ук «Агымсу», «Җиләкле аланнар», «Китә казлар», «Акбүз ат», «Чатта очрашу» исемле повестьларын иҗат итте.

Рафаил ага Төхфәтуллин — Ватан сугышында катнашкан һәм сугыш кырында ике мәртәбә авыр яраланган әдип. Күрсәткән батырлыклары өчен ул «Кызыл Йолдыз» ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән.

Өлкән яшьтәге әдип бу көннәрдә дә киеренке иҗади тормыш белән яши. Республиканың газета-журналларында аның исеме әледән-әле күренгәләп тора.

Олы юбилее уңаеннан редакция күренекле әдипне кайнар котлый һәм журнал укучыларга танылган тәнкыйтьчеләрнең аның иҗаты турындагы кайбер фикерләрен тәкъдим итә.

### Фәрвәз Миңнуллин:

Ихтимал, кайбер кешеләр әле дә хәтерлидер: Рафаил Төхфәтуллин әдәбият дөньясына үзенә зур өметләр баглатып һәм гомум игътибарны тартып, әгәр шулай әйтергә яраса, шаулап килеп керде. Ул — беренче хикәяләре белән үк өлкән әдипләрнең хәер-фатихасын алган, аларның игътибарын җәлеп иткән кешеләрнең берсе. Мондый бәхет теләсә кемгә эләкми. Әгәр Р. Төхфәтуллин шуңа лаек булган икән, димәк, бу тикмәгә түгел инде...

* * *

Беришле язучылар безне күккә карарга, матурлыкны югарыдан, биектән эзләргә чакырган заманда Р. Төхфәтуллин тота да үз юлы белән китә. Ул гүзәллекне тормыш төбеннән күтәреп чыгара, укучыларны җиргә карарга, әйбәт кешеләрне ат караучылыр, балта осталары арасыннан эзләргә өйрәтә. Ул Фазылҗан («Җәйге чилләдә») һәм Хөсәен абзыйлар («Елга аръягындагы йорт»), Нәби кебек гади кешеләрнең замандашыбыз дәрәҗәсенә күтәрелгән мөлаем образларын тудыра.

* * *

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә хезмәткә, хезмәт кешеләренә мөнәсәбәт, гомумән, принципиаль бер төс ала. Кешенең кадере, зурлыгы, бәясе аның хезмәткә мөнәсәбәте, ничек эшләве белән билгеләнә. Шул ук Фазылҗан абзыйларны, Хөсәен абзыйларны без, барыннан да бигрәк, эш кешеләре булганнары өчен хөрмәт итәбез. Гөлзифа кече яшьтән үк эш яратып, эшләп үсә. Шул нәрсә аңарда сабырлык, ныклык тәрбияли, иң кыен вакытларда, Давыт кебек, сыгылып төшмәслек көч бирә. Нәби кешене иң әүвәл хезмәт белән сыный, эшләтеп карый. Атка камыт киертә алмый алҗыган лекторны яки Нәбигә печән өяргә булышкан Рәмзияне хәтергә төшерегез. (Үз вакытында «Правда» газетасы «Авылдашым Нәби» повестеның нәкъ әнә шул өзекләрен сайлап баскан иде.) Гайнетдин абзыйның шәһәрдә укый торган төпчек кызы Фәүзияне алып багыгыз («Туган якларым»); болай чибәрнең дә чибәре инде, югыйсә. Аңарга булган мөнәсәбәтне карагыз: аксөяк булганга, кара эшкә чирканып караганга өнәмиләр бит кызны. Кыскасы, Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә хезмәткә мөнәсәбәт этик һәм эстетик категория дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Һәм моның тамырлары ерактан килә бугай...

## Ибраһим Нуруллин

Алтмышынчы елларда Рафаил Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» исемле хикәясе (повесть дип тә атарга ярый) басылып чыгу әдәбиятыбызда үзенә күрә бер вакыйга булган иде. Тәрҗемәсенең кыскартылып «Правда»да дөнья күрүе дә моңа ярдәм итте булса кирәк.

Әмма повестьның басылып чыгуын вакыйга ясаган төп нәрсә — бәрәкәтле тел һәм сәнгатьчә осталык белән тудырылган Нәби образы. Рафаилнең бу героен бер сүз белән сыйфатларга кирәк булса, мин Әмирхан Еникинең бер хикәясе исемен файдаланып, «матурлык» дип әйтер идем. Гыйлемдар шәкертнең Ә. Еники матур итеп күргән шадра битле, гарип күзле анасы кебек үк, Нәби дә тәскә-биткә чибәр түгел... Әмма Нәбинең җаны, күңеле матур, эш-гамәле күркәм.

Нәбине бүтәннәрдән аерып тора торган төп сыйфаты — хезмәт сөючәнлек. Алны-ялны белми эшләвеннән дә бигрәк, һәр эшне яратып, пөхтәләп, гүзәллек кануннары кушканча эшләве матурлый аны. Хезмәт сөючәнлекнең Нәбине аеруча бизи торган ягы шунда: эш аның өчен азмы-күпме байлык туплау, кесәсен калынайту чыганагы түгел. Ул әҗерен һич өмет итмичә яратып эшли.

Тагын шунысын да әйтик, Нәби образында гәүдәләнгән әхлак принциплары һич тә юктан бар булмаган, күктән төшмәгән. Алар, беренчедән, татар халкының гасырлар буена эшләп чыгарган әхлак кагыйдәләреннән килә. «Күрше хакы — алла хакы» дигән мәкальне хәтерлик. Икенчедән, алар совет идеологиясенең органик элементы булган коллективизм идеясеннән үсеп чыкканнар, дөресрәге, шул икенең бергә кушылышыннан туганнар.

Р. Төхфәтуллинның бөтен иҗатын тикшереп, анализлап зур хезмәт булдыруны аның иҗаты буенча диссертация яклаячак яисә аның турында китап язачак кешеләрдән көтеп калам. Мин исә әдәбиятыбызда Әмирхан Еники янына куеп караганда да күп югалтмый торган Рафаилебез булганга куанычымны белдерәм һәм аңа яңадан яңа иҗат уңышлары телим.

## Рифат Сверигин:

Рафаил Төхфәтуллинның иҗаты бәхетле язмышка очрады. Аның әдәбияттагы беренче адымнары җәмгыять һәм әдәбият тормышында күтәрелеш, үзгәреш елларына туры килеп, иҗаты тиз чәчәк атты. «Авылым

хикәяләре» циклына кергән хикәяләре (1959) һәм «Йолдызым» повесте (1960—1961) дөньяга үзенчәлекле карашлы, сизгер күңелле авторның килүен хәбәр итте.

Сугыш һәм сугыштан соңгы чор кыенлыкларын айлар-еллар буе үз җилкәләрендә күтәреп, түзгән һәм җиңеп чыккан колхозчылар — яше-карты, һич көтмәгәндә, китап битләрендә үзләрен, якыннарын, танышларын күргәндәй булдылар. Югыйсә, батырлык, гүзәллек, матурлык әллә кайда — еракталы тылсымлы әдәбият дөньясында гына булып, әйләнә-тирәбездә, күршеләребездә яшидер дип башыбызга да китерми идек. Бу әсәрләрнең геройлары Нәби, Гөлзифа, Кашшафларны без көн дә очратабыз, шулар белән бергә эшлибез, нечкәләбрәк уйласаң, аларның холыклары, килеш-килбәт, рәвешләре үзебезгә дә охшаган түгелме соң? Бермәлгә укучылар аптырау катыш сәерсенү белән шундыйрак хис кичерделәр. Бигрәк тә әдәби персонажларның шул дәрәҗәдә укучыга якын торуы һәм аларны күптән белгән кешең кебек танып алу тойгысы гаҗәпләндерде.

* * *

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләренең күңелне әсир итәрдәй көче нәрсәдә? «Йолдызым» һәм «Авылдашым Нәби» (1957) повестьларының гаҗәеп эчке мәгънәсе, романтикасы, сизелер-сизелмәс серлелеге, кешенең матурлыкка таба омтылышы белән аралашуындамы? Тормыштагы гади хәлләр, гади кешеләр хакында яза бит ул югыйсә. Гадиләрнең матурлыгы, бөеклеге нидән гыйбарәт? Боларны аңлату бигүк җиңел түгел.

Тәнкыйтьчеләр Рафаил Төхфәтуллин иҗатының буеннан-буена үтә торган туган як матурлыгы, туган як җылысы, хезмәт кешесенә хөрмәт, аны олылау хакында күптәннән сөйләп киләләр. Дөрестән дә, язучы иҗатының нигезенә шулар салынган.

* * *

Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендәге уңай геройлар, барыннан да бигрәк, күңел сафлыгы, күңел байлыгы, халыкчанлык кебек иң олы, күркәм сыйфатлар белән билгеләнәләр. Иң алгы планга кеше хисләренең, уйларының эчкерсезлеге, самимилеге куела. Мондый геройлар, әлбәттә, укучыда мәхәббәт уятмый кала алмыйлар.

Р. Төхфәтуллин һәртөрле гаделсезлек, хаксызлык, кеше күңелен рәнҗетү кебек күренешләргә үтә сизгер. Ул яхшылык белән яманлыкның традицион бәрелеше һәм яңалыкның һичшиксез җиңеп чыгуы рәвешендәге артык гадиләштерелгән, примитив схемадан чыгып эш итми — тормышның катлаулылыгын күрә һәм җәмгыять үсешендә, кешеләрнең мөнәсәбәтләрендә котылгысыз очрый торган һәртөрле уңайсызлыклар, драматик моментлар аның игътибарыннан читтә калмый.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Мансур Вәли

# ЯҢА ИСЕМНӘР, ЯҢА ӘСӘРЛӘР...

- Ике яшь әдип үлде
- Хикәятә аерым игътибар
- Бездә кемнәр бар?

Әдәбиятыбызның проза тармагындагы яшь көчләр турында сүз башлаганчы, алар иҗат иткән кайбер әсәрләр хакында фикер йөртергә керешкәнче, мәсьәләгә турыдан-туры бәйләнеше булган шундый бер борчулы хәлне искә алмый мөмкин түгел. Соңгы ике ел эчендә татар әдәбиятының проза жанрыннан әле чагыштырмача яшь саналган талантлы ике язучыбыз китте. Кире кайтмаска, бөтенләйгә... Сүз фаҗигале төстә әрәм булган Фәрит Гыйльми һәм Альберт Сафин турында бара.

Болар икесе дә телне яхшы белүче, нечкә тоючы, тормыш күренешләренә карата сизгер күңелле һәм инде чын мәгънәсендә әдип булып житлегеп килүче иҗатчылар иделәр. Фәрит Гыйльми әле үткән елны гына безнең журнал укучыларын «Зәйтүнәкәй, акчарлагым» хикәясе белән куандырды. Кыска гына күләмле шушы бер хикәядә без соңгы еллар авылының чын тормышын һәм аның олы трагедиясен — бигрәк тә авылда калган яшьләрнең фаҗигасен күрә алдык. Колхозда бары тик центнерлар һәм тонналар артыннан гына куучы, шуңа ирешә калсалар бөтен җирдә макталучы бүгенге түрәләрнең асылда ни рәвешле яшәүләрен һәм аларның чынлыкта кем икәнлекләрен, аларның яшьлек матурлыгы, сафлыгы, аның олы максатлары белән көчле бәрелешен күрдек без бу язмада. Кызганыч, әсәрдә әлеге конфликт яшь кыз өчен үлем белән тәмамланды... Әмма бу әсәрне укыган кеше күңелендә өмет уты барыбер сүнми. Чөнки әле тормыш дәвам итә. Бүген халык желегенә төшкән, үзенең бик якындагы киләчәген уйлый алмаган түрәләр дә бер заманны мескен хәлдә калачак бит! Гаделлек урнашачак бит әле! Кемнең ниләр кылганын халык искә төшерәчәк әле.

Ф. Гыйльми хикәясе белән аерылышканда укучы күңелендә әнә шундый кичерешләр кала. Алар — бүгенге тормышта меңләгән кешеләр тарафыннан расланa алырдай хисләр.

Альберт Сафинның «Юлда» исемле җыентыгына кергән хикәяләре дә хәтердә озак сакланырлык. Арада иң кыскасы «Исәнме, әни» дигән хикәя шикелле. Берничә биттән генә торган шушы әсәрдә яшь буын вәкилләренә хас булган күңел катылыгы, якын кешеләренә карата битарафлык тәэсирле күренеш аша нечкә ачылган. Аны бер мәртәбә укып чыккан кеше онытa алмас. Ул күңел түренә, гүяки йөрәк ярасы булып урнаша, гел әрнеп йөри.

Әйе, әнә шундый югары сәнгатьчә әсәрләр яза алган бу каләм ияләре хәзер безнең арабызда юк инде. Татар әдәбиятының болай да шактый сирәк булган яшь прозаиклары сафы алардан соң тагын да бирешә, хәлсезләнә төшә. Мондый хәл күңелсез уйларны да көчәйтә. Ләкин, алмашка килүче яңа көчләр турында сөйләшә башлаганчы, әйдәгез әле, менә бу хакта да уйланып алыйк.

Табигать тарафыннан бирелгән шактый зур талантлы менә шушы ике каләм иясе нишләп соң татар әдәбиятының атаклы, көчле хикәячеләре булып китмәделәр? Әйдәгез, чагыштырудан курыкмыйк: урысның Антон Чеховы әнә 44 яшендә бу дөньядан үтсә дә, үзеннән соң дистә-дистә том әдәби әсәр һәм бик күп

санлы башка кызыклы язмалар калдырган бит. Безнең талантлы егетләребез дә шул яшькә житкән иделәр, ләкин нишләп соң алар бик аз әсәр калдырдылар??

Юк, бу сорау — аларга гына кагыла торган сорау түгел! Бу — бүгенге татар әдипләренең барысына да, һәммәсенә дә кагыла торган сорау.

Билгеле, бередә «моның җавабы күптән билгеле бит инде!» дип мәсьәләнең үткенлеген киметергә тырышучылар яисә «аларның үзләрендә гаеп!» дип бу сорауның милли мәдәният өчен ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңламамышка салынучылар яки чынлап та аңлый, төшенеп житә алмаучылар да табылырга мөмкин. Чөнки торгынлык елларында алга килеп баскан үткен проблемаларны күрмәмешкә салышып урап үтәргә, яисә инде аны бик тә шомартырга, ай-һай, остарып беттек без! Хәтта үзебезнең яшәү яки үлемебезне хәл итәрдәй мәсьәләләрне дә күрмәскә өйрәндек без ул елларда. Аның шаукымы әле хәзер дә бик көчле.

Шуңа күрә бередә безнең ике хикәячебезне урысның атаклы әдибе белән янәшә куеп карау бик тә кирәк! Ике төрле савыттан алынган ике тамчы сыман — Чехов язмышы һәм безнең ике яшь әдип язмышы — ике халыкның ике төрле язмышын аерымачык күрсәтеп, кычкырып тора.

Безнең әдипләрдә — күп гасырлар буе колониядә яшәгән, үтә нык изелеп яшәгән халык язмышы, шундый кешe холкы. Милләтнең талантлы вәкиле дә барыбер ярымкол хәлендә. Бүгенге тормыш чынбарлыгы аны әнә шундый хәлгә куя.

Шуның өстенә: талантның тиешенчә бәяләнмәве дә килеп кушыла. Ягъни бездә, татарда, яшьтән үк язу сәләте сизелгән кеше бары тик ижат эше белән генә шөгыльләнә алмый. Үзенең осталыгын бары тик шушы юнәлештә генә камилләштерә һәм әсәр ижат итеп, милләтне, укучыларны сөендерә алмый. Татар әдәбиятының үлемсез саналырга тиешле әсәрләре тумыйча ук кала. Шартлар булмау, ижатка олы ихтыяж күренмәү аркасында...

Бу ике хикәяченең трагик язмышы турында уйланган вакытта тагын шуны да басым ясап күрсәтмичә булмый: безнең матбугат әлегә кадәр «кыскалыкта — осталык» дигән принципка каршы тора. Ягъни матбугатыбыз әлегә кадәр бары тик күләм өчен генә түли! Димәк, без авторларны күләм куарга үзебез үк мәжбүр итәбез! Ә әсәрнең сыйфаты өчен түләү кая?!! Язучының чын осталыгына, олы талантына бәя бирү кая?! Хикәячеләр нишләргә тиеш? Ә бит Тукай һәм Исхакыйлар, Чеховлар чорында бу һич тә алай булмаган! Шуңа күрә ул заманда талантлар табигый рәвештә ачылган. Димәк, безгә хәлне бу җәһәттән тиз арада төзәтү сорала.

Проблеманың тагын бер ягы бар. Торгынлык елларында һәм әле соңгы елларда да без үзебезне тагын да ялкауландыра, рухи яктан үшәнләндерә торган мондый сүзне дә әйтергә бик яратабыз: «Һе, аларда бит ул! Син агайне, алар белән чагыштырма! Аларның хәл бөтенләй башка!» янәсе. Менә шулай диеп, шушындый бер тылсым белән үз-үзеңне юату, үз-үзеңне тынычландыру... Юк! Хәзер инде безгә дә: «Аларныкы кебек булсын!» — дияр чак житте! Булсын! Татарда да зур талантлы әдипләр әдәбиятка бөтен көчләрен салып ижат итсеннәр! Үз көчләрен тормышның вак-төягенә түкмәсеннәр.

Бүген без сагынып искә алган ике язучы да кыска жанр осталары иделәр. Дөресен әйткәндә, күпмедер дәрәҗәдә, алар безнең игътибарсызлыгыбыз корбаннары да булдылар. Димәк, чын талантны гадел бәһаләү, аның кадерен югалтмау турында безгә ашыгыч рәвештә үк эзләнергә һәм аның юлларын табарга кирәк!

Уйлый китсәң, күңелсез фикерләр байтак кына җыела шул... Житмешенче елларда зур гына өмет уяткан яшь прозаикларыбыз да хәзер, егерме ел үткәннән соң, әдәбиятның бу иң авыр йөген төпкә жигелеп тартучылар булып әверелмәделәр. Ул елларда гомум соклану белән каршы алынган талантлы прозаик Азат Ганиев тә ике-өч повестьтан соң (яхшы әсәрләрдән соң!) шактый гына пассивлашты. Хәер, аның яңа китабы, ниһаять, чыгып килә дигән хәбәр бар. Азатча үзенчәлекле, диләр аны. Көтик. Бергәләп куанырга язсын!

Аның белән бергә әдәбият мәйданында күренгән Марсель Гали һәм Әхәт Гаффар да, Янарыш чоры килгәч, прозаик буларак ничектер тыныбрак калдылар шикелле. Дөресрәге, алар ижади яктан үзгәреш кичерде бугай. Әхәт үзенең публицистикада көчлерәк икәнен сизде, ә Марсель Гали кыска хикәя жанрын уңышлы иярләде дияргә була. Ләкин, әлеге дә баягы, һаман бер сүз дигәндәй: бездә ул жанрга тиешле игътибар булмаса, килгән авторлар да анда озак тора алырлар микән? Кыска күләмле әсәрләргә күләм буенча гына гонорар бирү «хикәя язмагыз сез» дип әйтү белән бер бит инде ул!

Әйе, безнең бүгенге чынбарлыгыбызның объектив һәм субъектив кануннары әлегә әдәбиятны үстерүгә булышмый. Ләкин аңа карап кына халыкның, милләт-

нең рухи ихтыяҗлары бетми, югалмый! Безнең татар укучысына бүген укырга әдәби әсәрләр кирәк. Хәтта әле бик кирәк! Менә шушы бушлыкны ничек тутырырга? Югыйсә безнең халык көн-төн телевизор экранынннан күрсәтелә торган Америка фильмнарына иялөнеп бетәчәк. Андагы кебек сугышырга, алдашырга, урлашырга, булганны җимерергә һ.б. әшәкелекләргә бик тиз өйрәнәчәк ул. Әгәр әдәбият-сәнгать әһелләре бүгенге көндә татар милләте өчен рухи һәм әхлакый бушлык хасил итсә, шуңа канәгать булып торса!

Әдәбиятыбызның һәм, аерым алганда, андагы яшь көчләрнең уңышлы үсүе өчен мөһим тагын бер мәсьәлә бар әле. Сүз матбугатта әдәби әсәрләр һәм публицистик язмалар нисбәте турында бара. Яшь иҗатчыга караш, аның хезмәтенә реаль ихтыяҗ сизелү дә шуңа бәйле. Минемчә, кайбер житди генә басмалар бүген публицистика белән артыграк мавыга. Чоры да шундый: кычкыру, ярсу, өндәү — боларның һәммәсе инде тормышта болай да чамасыз күп. Хәзерге кеше алардан ничек итеп качарга, кая кереп котылырга белми! Бүгенге кеше үз яшәвенең көе киткәнгә, гармония бозылганга изалана, аптырый. Ә мондый эчке халәттәге кешегә исә әдәби әсәр күбрәк тәэсир итә. Образлы сүз ярдәмендә бүгенге кеше күңеленә үтү җиңелрәк. Киң катлау укучылар үзләре дә әдәби әсәрләрне яратарак төшәләр. Минемчә журналларның бүген ничек таралуы, ягъни тиражы әнә шул хакта сөйли.

Ә менә икенче яктан караганда, Яңарыш еллары килгәч, әдәби журналларның портфеле шактый югары төште дип беләм. Моның сәбәбе нидә?

Беренчедән, үзгәреш чоры башлангач, милләтне һәм җәмгыятьне борчыган үткен мәсьәләләр көн тәртибенә куелды. Алар турында уйлану һәм язу байтак зыялыларыбызның акылын, вакытын биләде. Икенчедән, китап басу һәм матбугат эшендә дистә еллар буена чарлана килгән тәртип бозылу сәбәпле, китапларның дөньяга чыгуы вакыт ягыннан нык тоткарлана башлады. Ә бу исә иҗатчы кешегә зур тәэсир ясый, аны чыгырдан чыгара. Өченчедән, нәшриятлар һәм газета-журнал редакцияләренең матди яклары бик нык кысылу аркасында, әсәрләргә гонорар түләү нык кимеде. Каләм иясе элек повесть яки роман бастырып, шулар хисабына тормышның очын очка ялгый алган булса, Яңарыш елларында аның каләм хакы көлке дәрәҗәдә аз килеп чыга. Иҗатчы башка чыганак эзләргә, читтә эшләргә мәҗбүр була. Димәк, тагын әдәбиятка зыян.

Әле тагын житди бер фактор бар. Соңгы елларда дөньяның рәте китү сәбәпле, бөтен җирдә сугышлар һәм зур социаль конфликтлар күбәю аркасында, иҗат кешесенең дикъкате ирексездән шуларга юнәлә. Аның игътибары таркала, уйлары чәчелә, сибелә. Тулаем яшәеш турында «тотрыксыз» дигән тәэсир көчәя. Байтак язучының күңелендә эчке ышаныч кими, киләчәккә өмет какшый... Болар әдипне эчтән җимерә, какшата, аның рухи энергиясен кимәтә, хәлсезләндерә.

Саный китсәң, сәбәпләр тагы да булырга мөмкин. Ләкин хәлнең авыр булуы ачык. Хәер, бүгенге тормыш, бер-ике даирәдән кала, берәүгә дә җиңел түгел.

Әмма төп хикмәт шунда: мондый авыр чорда кеше күңеле тотрыклылык нигезләрен бигрәк тә нык юксына. Безнең татар укучысы да үзенә көч бирердәй рухи азыкны бик көтә. Бу — милләтнең олы рухи ихтыяҗы.

Ә соңгы елларда матбугатта безнең игътибарны җәлеп итәрдәй нинди яңа исемнәр һәм кызыклы әсәрләр күренде соң? Алар татар укучысының зиһенен нинди яңа уй-фикерләр, хис-кичерешләр белән баетты?

Яңа исемнәр дигәндә, иң башта Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче Факил Әмәк хәтергә төшә. Бу автор матбугаттагы беренче адымнарыннан ук эшкә шактый киң колач белән тотынды. Аның шигырь һәм пародияләре дә, эпиграммалары да булды, шулай ук әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм шаян хикәяләре дә күренде. Укылган язмаларның һәммәсе диярлек хәзер дә хәтердә тора. Минемчә, менә шушы нәрсә үзе үк байтак мәгънә сөйли. Димәк, ул чакта Факил Сафин исеме белән язган бу автор истә калырдай кызыклы язмалар чыгарган.

Күптән түгел Факил Әмәкнең беренче китабы да басылып чыкты. «Соңгы көз» дип исемләнгән ул. Җыентыкка, шул исемдәге повестьтан тыш, шактый гына хикәяләр дә тупланган.

Кереш сүзендә автор безнең игътибарны үзенең юмористик хикәяләренә юнәлтсә дә, остазы дип Фаил Шәфигуллинны санавын һәм аның юлыннан барырга теләге барлыгын әйтсә дә, шуның өчен күп көч салуын белдерсә дә — ул хикәяләрнең повестька караганда йомшаграк килеп чыгуын әйтмичә үтеп булмый. Әйе, Факилнең хикәяләрендә матур һәм җиңел тел бар, юморга бик якын күренеш-ситуацияләр тасвирлана — ләкин аларны укыганда, ничектер, яңалык тойгысы кичермисең. Шартлап, чатнап киткән юмор очкыннарын аз табасың. Икенчелек тойгысы кала, остазга иярү сизелә.

Хәер, Факил Әмәкнең юмор язу һәм бастыру мөмкинлеген беркем дә чикли алмый. Мин монда китаптагы юмористик хикәяләрдән чыгып кына әйтәм. Каршы чыгучылар табылса, рәхим итсеннәр. Ләкин шунысын да искә алыйк: авторыбызның үз холкы-табигате дә юмористларча түгел шикелле...

Ә инде бу китапта төп урынны биләп торган «Соңгы көз» повестена килгәндә, биредә эшләр бөтенләй башкача. Монда инде без чын мәгънәсендә үзенчәлекле иҗатчы белән очрашабыз. Әсәрнең беренче битләрендә үк моңа ышанабыз да.

Татарның яшәгән нигезе авыл инде аның. Хәзерге көндә милләт буларак исән булуыбызның да, туган телебезне саклап кала алуыбызның да, әхлакый яктан чистарак-сафрак булуыбызның да һәм әле әйтеп-санап бетерелмәгән башка бик күп яхшы сыйфатларыбызның да нигезендә, төбендә авыл һәм аның тәрбиясе ята. Әлбәттә, бүген күрсәтергә мөмкин булган байтак кына җитешсезлекләрнең дә: мисал өчен, кешегә заманча чослык җитенкерәмәү, бер-береңә белән килешеп һәм җайлап эшли, көн итә белмәү, бер-береңә ярдәм итмәү, җитәкчелек эшенә бик атлыгып тормау, аңа авыр өйрәнү һ.б. нәрсәләр дә авылга бәйле шикелле.

Факил Әмәк тә үз повестена җирлек итеп авылны ала. Ә кайсы яктан күрсәтә соң автор бүгенге авылны? Яшь язучы анда нинди көчләр бәрелешен күрә? Хәзерге көрәшләрнең эчтәлеге анынча нәрсәдән гыйбарәт?

1993 ел дәвамында «Казан утлары» журналы алып барган әдәби дискуссиядә катнашучыларның күбесе Фоат Садриевнын «Таң җиле» романына тукталган иде. Сөйләшүдә шул әсәр уңаеннан бүгенге авыл хәлләре шактый ачылды, андагы байтак социаль тенденцияләр төсмерләнде. Укучылар әсәрне байтак кына яктан тулыландырды, аның фикер сөрешен кинәйтте. Факил Әмәкнең «Соңгы көз»е әлеге романга күпмедер аваздаш дияргә дә була. Ләкин бу әйбәт мәгънәдәге аваздашлык. Ике җитди авторның бүгенге авылдагы конфликтларга багышлап ике җитди әсәр язуына һәм бер-берсен һич кенә дә кабатламавына «яхшы»дан бүтән бер сүз дә әйтеп булмый.

Повесть болай башланып китә: колхоз рәисе Тимерхан әле яңа гына көньяктан кайтып төшкән. Ялдан. Аңа кадәр ул «... башта Казанда зур җыелышта булды. Аннан Мәскәүгә, РСФСР Югары Советы сессиясенә очты. Сессия беткәч, өлкә комитетының рәхим-шәфкате белән пайтәхеттә, ин зур түрәләр өчен салынган шифаханәдә сәламәтлеген ныгытып алды... Шифаханәдән чыккач Кырымга, ял йортына юллама тоттырдылар...»

Менә шушындый сүзләрне укыгач, ничәмә еллар буе бөтен ил халкы күз текәп торган җитәкчеләр күз алдына килә. Колхоз, район, өлкә һәм ил җитәкчеләре... Гүяки Тимерхан (җитмәсә әле үзенең исеме белән дә!) әнә шул бөтен түрәләрнең бер җыелма образы буларак укучы хөкеменә чыгарылган.

Әсәр идеясе җанлы тормыш, тере кешеләр аша ачыла. «Гөлчирә, күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп, әрнү катыш гаҗәпсенеп, иренә карады. Әгәр Исрафилдә ирлек горурлыгы дигән нәрсә булса, хатынының шушы минутта аны җаныннан чыгарып атканын сизәр иде ул...

— Нәрсә булганын аңламый азапланасыңмыни соң?!— диде хатын көтелмәгән зәһәрлек белән.— Менә кара, күр!— Ул изүен чишеп җибәрде...»

Яшь әдип сурәтләгән шушы кыска гына бер күренештә дә ничә кеше һәм ничә төрле көч бергә, тыгыз тупланган!

Монда ире тарафыннан яклана алмаган хатынның көчле нәфрәте ташый. Юк, бу нәфрәт хатынны көчләргә маташкан колхоз рәисенә генә түгел. Әлеге нәфрәт Гөлчирәне яклап берни эшли алмаган Исрафилгә дә! Ачуның менә монысы әле иң куәтлеседер дә. Ни өчен дигәндә, үзен дә һәм үзенең хатынын да яклый алмаган әнә шундый җебегән ирләр үсендерә бит инде теге рәис ишеләрне...

Хәер, андый Исрафилләрнең бүген кол хәлендә булуын искә алсаң, бәлки, ул колларның гаебе кими дә төшәдер. Кол хатынына колбиләүченең кул сузуы гаҗәп түгел кебек бит инде ул...

Менә шулай! Әдәби әсәр үзенең бер күренеше белән генә дә безнең яшәүне ни дәрәҗәдә тирәннән яктырта. Кемнең кем икәнен әйтә дә бирә! Теге киң таралган мәзәктәге шикелле инде: илнең «хуҗалары» тирес түгә, ә «халык хезмәтчеләре» машинада гына җилдерә!

«Соңгы көз» авыл тормышын күп яклап колачлый. Биредә рәис тирәсенә укмашкан куштан белгечләр дә, райондагы һәм Казандагы элек сабакташ булган җитәкчеләр дә бар. Шулай ук гомер юлларын әле яңа гына башлаган яшүсмерләр дә һәм алар арасында без күреп үткән хатынның чибәр кызы Рәхилә дә. Биредә колхоз рәисенең шома ерткычлыкларына каршы торырга тырышкан, баш бир-

мәскә теләгән яшь мәктәп директоры да... Монда икенче бер яшь түрә тарафыннан шактый гына «талкынган» кызны үзенә хатынлыкка алган авыл советы рәисе дә. Колхоз хуҗасының шәһәрдә аерым фатирда типтереп, юлдан язган үз малае да...

Санадык, санадык та, хәзер инде барысын бергә җыеп карыйк — артык күпкә китмиме соң? Кимчелек ачу, җитешсезлек күрсәтү белән без болай да еш мавыгабыз түгелме соң?!

Юк, «Соңгы көз»не укыганда андый тәэсир тумый. Киресенчә, безнең халыкны, бигрәк тә гади халыкны, әнә шундый коллык халәтеннән чыгару өчен әле, ай-һай, күп кирәк! Хәтта үзенең газиз хатынын көчләүгә дә ризалашкан һәм каршы бер сүз дә әйтә алмаган кешеләрне, чыннан да, Кеше итү өчен әле никадәр көч салырга кирәк булачак безнең милли әдәбиятка, безнең матбугатка!

Монда әле ярдәмгә Фәнзаман Баттал сатирасы да, Зөлфәт Хәкимнең ачы итеп көлүе дә, Фоат Садриның соңгы романы сымаң киң колачлы әсәрләр дә кирәк булачак. Гамил Афзалның иҗат ялкынын инде әйткән дә юк!

Әйе, Факил Әмәк бу повесте белән укучы каршындагы имтиханны уңышлы тапшырды. Аның иҗатына хас уңай якларны бергә җыйнап карасак, мондый нәтиҗәгә киләбез: автор заманча үткен мәсьәләләр күтәрә. Әсәр безнең тарафтан бик мавыгып, бирелеп укыла. Аның повестендагы геройлар тормышчан, җанлы — тере кеше сыман күз алдына киләләр. Әсәрнең сюжеты киң колачлы, аңа бик күп вакыйгалар сыйган. Яшь каләм иясенең язу теле дә ипле ага. Диалоглары тыгыз һәм үзенчәлекле. Төбәк сүзләре әсәр тукымасында табигый яшәү таба.

Шул ук вакытта повесть безнең күңелдә уяткан кайбер теләкләрне дә әйтми булмый. Әллә инде замана чире чагыла: бу повестьта да тормышны өзек-өзек сурәтләү, фрагментарлык теңкәгә тия. Автор, болай эшләп, киңлеккә ирешмәкче, әлбәттә. Ләкин әйбәт агышлы реалистик проза алымы булгач, әлеге фрагментарлык белән килешүе кыен. Алар бер-берсе белән ярашмый шикелле. Җитәрлек дәрәҗәдә уйланган булса, минемчә, әсәр тоташ агымга да әйләнә алыр иде.

«Соңгы көз»нең төп герое, тискәре тип Тимерхан үлеме дә төрле уйлар кузгата. Бер яктан караганда, күпме әшәкелек эшләгән әнә шул типның ахырда зират коймасында асылынып калуы, шулай үлүе дөрес тә шикелле. Повестьның логикасы укучыны шуңа алып килә иде. Бөтен әсәр буена Тимерханга ачуы кабара килгән укучы моңа, бәлки, канәгать тә калыр... Әмма бу мәсьәләнең без искә алырга тиешле тагын бер мөһим ягы бар бит әле.

Тормышта һәм безнең күз алдында никадәр җинаять эшләгән кешенең болай очраклы рәвештә генә үлүе бездә нинди фикер калдыра соң? «Күпме җинаятьләр кылсаң да, барыбер бер килеп дөмегәсең син. Ә без синең белән көрәшеп маташмыйбыз, кулыбызны пычратмыйбыз», — дигән нәтиҗәме?!

Ай-һай, укучыда мондый фикер уяту, аңа хәзер шундый әхлакый сабак, тәрбия бирү тормышыбызны яхшыртырга булышыр микән?! Мин моңа бик тә нык шикләнәм.

Сүз уңаенда әйтеп китик: бер аксакал әдибебезнең моннан шактый еллар элек басылган әсәрендә дә күп әшәкелекләр эшләгән берәүне, әсәр соңында, ат тибеп үтергән иде. Бик яхшы язылган ул әсәрнең менә шушы урыны ничектер күңелгә ошап бетмәде. Менә хәзер биредә яшь авторда да явызлыклар эшләүчегә карата шундый караш чагыла. Ике әсәрне бергә алып караганда — нәрсә, нинди күренеш бу? Табигатьнең бөек фәлсәфәсеме, әллә безнең коллык психологиясеме? Килешергә, баш иярга өндәүме? Минемчә, авторлар соңгысына якынрак шикелле... Әйе, түзү, чыдау безгә хас инде ул!

Әмма Факил Әмәкнең әлеге повесте яшь прозаиклар иҗат иткән иң уңышлы әсәрләр рәтенә керә. Бу авторның иҗат дөньясы белән саубуллашкан вакытта аңа даимилек, язу куәсе телисе килә. Чөнки тормышта темалар, проблемалар күп. Каләм иясен яңа каһарманнар көтә.

Сиксәненче елларның ахырыннан башлап уңышлы рәвештә яза һәм басыла килүче икенче яшь прозаик — Флүс Латыйфи. Аның хикәяләр белән бер повестьтан торган тәүге китабы «Кырагай» 1988 елда дөнья күргән иде. 1992 елда автор «Ак-карага тимәскә» дигән яңа җыентык чыгарды. Үткән 1993 елда исә «Хыянәт» исемле романы китап булып басылды.

Яшерен-батырып түгел: моңа кадәр исемен ишетмәгән һәм үзен күрмәгән бүтән автор булса, аның шундый аз вакыт эчендә өч җитди китап бастырып чыгаруына шактый гаҗәпләнгән дә булыр идек. Ул язган әйберләрнең сыйфатына карата да шундук шик уяныр иде, мөгаен. Тумыштан ук скептик чырай алган кайберәүләр бигрәк тә тантана итәр иде. Әнә ич элеккерәк елларда, Язучылар берлеге яшь талантлар эзләгәндә, «Бездә 700ләп язучы бар» дигән сүзгә ироник төстә елмаючылар табылды. Шуның кадәр язучы буламыни, янәсе! Эшләгәч,

зләгәч, оештыргач — була иде шул, була иде! Биредә дә шуның шикелле. Без Флүс Латыйфиның вакытлы матбугатта дөнья күрә килгән язмаларын укып белгәч, аның нәрсәгә сәләтле икәне күз алдына раслана килгәч — бер-бер артлы диярлек басылган өч китап бездә гаҗәпләнү тудырмый. Киресенчә, әдәбиятка чагыштырмача соңрак килгән бу каләмдәшебезнең беренче уңышларына без сөенәбез генә.

Хәзер инде ул язган әсәрләргә күчик. Яшь прозаик үз иҗатында кайсы як, нинди сыйфатлар белән алдыра.

Ф. Латыйфиның беренче китабы өчен иң типик бер хикәяне алыйк. Аның исеме «Чүчинкә». Аңлагансыздыр, төшенгәнсездер — биредә сүз авыл җирендә генә киелә торган аяк киеме турында бара. Ә ул чүчинкәгә нинди фәлсәфә сыйдыра алган соң автор?

«— Мәскәүдән килгән группаның башлыгы doktormy, кандидатмы... Өстәвенә яшь тә, чибәр дә ди...»

Хикәя әнә шул хәбәр белән башлана, вакыйгалар шуның аркасында куера. Чөнки коллективта, нигездә, хатын-кызлар эшли. Алар арасында яше кырыкка житсә дә кияүгә чыкмаган Эльвирочка да бар. «Ничек итсәм итәм, бу докторны үземә каратмый калмыйм,— ди ул хезмәттәшләренә, уенын-чынын бергә кушып».

Юк, хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Шушы уңайдан без һәрбер камил әйбернең гади тоелуын да искәртеп үтик әле. Ә әсәргә күз салсак, Мәскәүдән килгән тикшерүчеләр группасын Эльвирочканың элеккеге сабакташы Фәсхетдин җитәкләве мәгълүм була. Алар кайчандыр институтта бергә укый башлаганнар, шунда бер җай чыкканда, Эльвирочка Фәсхетдинне киногa чакырган. Ә тегесе — «авыл гыйбады» — киногa ак чүчинкә киеп килгән! Шәһәрдә! Моңа бик тә гарьләнгән Эльвира ул чагында Фәсхетдин яныннан тая. Дөресрәге, аны алдап китеп бара... Инде менә еллар үткән. Эльвира һаман ялгыз, ә Фәсхетдиннең гаиләсе дә бар, яраткан эшендә дә ул хөрмәтле кеше.

Менә шундый эчтәлек. Гади, әмма һич тә искерми торган мәгънә.

Әйе, чын татар укучысы чүчинкәле Фәсхетдиннәрне дә, кәпрәеп йөреп ялгыз калган Эльвирочкаларны да яхшы белә. Беренчеләре халыкны, илне туендыра, киендерә. Иң авыр эшләргә дә алар бара. Дошман килсә дә илне якларга дип иң алгы сызыкка алар барып баса, күкрәген куя... Ә икенчеләренең исеме Эльвирочка гына булмаска да бик мөмкин. Боларның җенесе ир-ат булуы да бар. Исемнәренең дә модный, заграничный булуы мөмкин... Ләкин аларның холык-табигатьләре нәкъ менә бу хикәядәге кызныкы сыман: алар гадилектән курка, чиркана, болар ялтыравыкка, купшылыкка мөкиббән! Андыйлар читнекенә генә баш ия. Болар данлы һәм дәрәҗәле адәмнәрне генә күрә, санлый... Гадилек — болар өчен иң зур начарлык сыман кабул ителә.

Әмма татарның милли психологиясе бу карашны кискен кире кага. Ул эчкерсезлекне, риясызлыкны, беркатлылыкны шәхеснең иң яхшы сыйфатларыннан дип саный. Кызык — ә безнең белән күрше яшәүче милләттә «простота — хуже воровства» дигән сүз бар. Менә бит ул ничек: аларча — урлашсаң, кеше таласаң да ярый, тик син гади генә булма! Күргәнебезчә, без биредә ике төрле караш, ике төрле фәлсәфә бәрелешен очратабыз. Ә киңрәк алып караган чагында, Бөек Шәрык һәм Көнбатыш фәлсәфәләре — ике төрле яшәү, уйлау рәвеше бу.

«Рустик» һәм «Кырагай» хикәяләрендә дә Ф. Латыйфи безнең татар укучысы күңеленә хуш килә торган бу фикерне үстерә, дәвам итә. Югарыда әйткәнебезчә һәм кайберәүләр уйлаганча, биредә һич тә тарлык, татарлык түгел — ә безнең милләтне гасырлар буена тотып, саклап торган асыл сыйфатлар хакында сүз бара. Эльвирочкалар холкы инде болай да көчәеп бара. Ул тенденция — татарны бетерәчәк, туздырачак көч. Ә безгә ата-баба юлыннан бүтән юл юк. Аны бары тик замана сыйфатлары белән тагын да ныгыту гына кирәк.

Авторның әсәрләре үзебезнең халкыбыз сыман гади, ләкин тәэсирле сөйләмгә, тормышчан күренешләргә һәм кешеләргә таяна. Яшь әдипнең теле кичерешләр һәм күренешләрне ипле генә тасвирлап бирсә дә, хикәяләрнең агышы тыныч елга шикелле җай гына сузылып китсә дә — болар берсе дә әсәрләрдә сүлпәнлек, сайлык тудырмый, укучыны үзеннән читкә этәрми. Чөнки болар безнең авыл яннарындагы ямь-яшел чирәмлек шикелле, талгын гына агып яткан инеш кебек, тал-тирәкләрнең зифа ыспайлыгы сыман гадилек. Әнә шул табигать күренешләре, никадәр генә карасаң да, һич туйдырмый, ялыктырмый бит. Ә күпме көчәнеп, баш ватып төзелгән таш биналарга яисә һәйкәлләргә исә озак карап тора алмыйсың. Ни өчен? Чөнки алар — җансыз!

Шуның шикелле, Латыйфи әфәнде дә әдәби әсәрләрен безнең гап-гади татар тормышыннан алып иҗат итә. Гадилеккә бөеклек бирергә омтыла. Икенче китаптагы «Көмеш беләзек» тагын бер мәртәбә шуны раслый.

Монда да сюжет җебе гап-гади чуар тавык «аягына уралып» сүтелә башлый. «Бу тавык — үзенә иптәшкә дип калдырганы. Авылда бердәнбер чуар тавык әле ул, җитмәсә. Бөтен күрше-тирәнеке озын торыклы, юан ботлы таза ак тавыклар. Инкубатор тавыклары. Элегрәк Җиһан да шундыйларга кызыккан иде. Тик ата-бабадан калган нәселне юк итәсе килмәде. Гомер буе шушы талымсыз чуар тавык белән көн күргән, ләбаса. Аннан инкубаторныкыларның сәер ягы да бар икән: йомыркасын теләсә кая салалар, чөрләмиләр, утырмыйлар, чеби чыгармыйлар. Әллә нинди кысыр тавык алар. Чын тавык кебек тә түгел.»

Бу өзекне укыганда уйлый башлыйсың: бередә сүз тавык турындамы соң, әллә хәзерге кешеләр хакында фикер йөртәме автор?

Сәнгатьле әсәрнең теле дә шундый инде аның. Андагы күренешләргә кат-кат мәгънә салынган була. Бередә дә без шул хәл белән очрашабыз. Кешелекне, милләтне киләчәктә дәвам итә алырдай затлар хакында әнә шулай сүз башлый автор. Әсәрдә гадилек һәм аның артындагы күп мәгънәлек, табигыйлек һәм образлылык бергә үрелә. Хикәяләү рәвешендә реальлек һәм тылсым кушыла. Ләкин бөтенлек саклана, сәнгати дөреслеккә зыян килми. Әсәрдән мондый идея чыга: олылар күңеле безнекенә караганда күпкә баерак, тирәнрәк. Анда әллә никадәр мөһим хакыйкатьләр ята, алдагы юлларда, киләсе елларда безгә бик тә кирәк буласы рухи хәзинәләр бар анда. Шуңа күрә безгә ул рухи-әхлакый хәзинәләрне яхшылап үзләштерергә, киләчәккә үзебез белән алып китәргә кирәк.

Әлеге хакыйкать «картлар турында артык еш язасыз» дип гаеп ташлаучыларга ышанычлы җавап шикелле дә яңгырый. Безнеке сыман болганчык елларда, чыннан да, картлар тәҗрибәсе икеләтә, өчләтә кыйммәтләнә түгелме соң?!

Флүс Латыйфи үзенең көчен повесть жанрында да сыный. Аның һәр ике китабында да бу төр әсәрләр бирелгән. Ләкин аларда шундый кызыклы үзенчәлек күзәтелә: беренче китаптагы повесть бераз сыеграк, ә хикәяләр көчлерәк булса, икенче җыентыкта инде хәл киресенчә — бередә урнаштырылган ике повесть үзләре генә дә мәгънә ягыннан да, күләм буенча да иң зур урынны алып торалар. Кыскасы, авторның күләмле әсәрләр иҗат итү буенча осталыгы арта бару күз алдында.

«Ак-карага тимәскә» дигән повесть безнең әдәбиятта моңа кадәр тасвирланмаган өлкәне — республика радиосында эшләүче журналистлар тормышын күрсәтә. Вакыйгалар торгынлык чорында бара. Яшь журналист Рәис йөрәгендә Гаделлек белән Ялагайлык, Намус белән Алдашу канга-кан килеп бәрелешә. Югарыдагыларга ялагайлану буенча озак еллар буена зур тәҗрибә туплаган куштаннарның әле яңа гына университет тәмамлаган яшь кешене нинди хәйләләр белән үз юлларына кертергә маташуы әсәрдә кискен күренешләр аша бирелә. Гаделлек өчен көрәшеп йөргән Рәиснең повесть ахырында каты кыйналып, хастаханәгә эләгүе исә теге түрәләрнең һәм күпсанлы ялагайларның әле һаман да шулай яши бирүләрен раслый. Мондый азак, әлбәттә, укучыны да сискәндерә, аның тынычлыгын ала. Чыннан да, демократия чоры башланса да, әле безнең тирә-юньдә никадәр гаделсезлек эшләнә бит. Димәк, Рәис кебек сатылмый торган журналистлар, көрәшчеләр әле күп кирәк безнең милләткә.

Ф. Латыйфиның икенче повесте — «Тәгәрмәчсез арба». Игътибар итегез: автор үз әсәрләренә исемне бик тә уйлап куя. Бередә дә исем башта ук көйсез, авыр тормышны искә төшерә. Сугыштан соңгы елларның яшүсмере — әсәрнең төп герое. Аның бәгырь әрнүләре, җан газаплары, бөреләнә башлаган мәхәббәт хисләре китапта битттән биткә озата бара. Һәм аңа җылы, кешелекле хис ияргә. Ә инде повесть ахырындагы менә бу юллар: «Сагынам да уфтанып куям: бөтен тормышым тәгәрмәчсез арбага охшаган икән ләбаса! Һаман да шул тәгәрмәчсез арбаны сөйрәп яткан чагым...»

Бик күпләребезнең хәле, эчке халәте, бөтен язмышы диярлек чагыла түгелме соң әсәрнең соңгы һәм моңлы аккорды булган әлеге юлларда?!

Авторның менә шушындый уңышлары турында сөйләгәннән соң, аңа булган кайбер теләкләребезне дә җиткерәсе килә. Татар зыялыларын борчыган бүгенге рухи һәм әхлакый проблемаларга кыюрак үтеп керсен иде ул. Югыйсә, чыннан да, безнең татар әдәбиятының иң күп әсәрләре авыл тормышына багышланган. Моны без унай факт буларак билгеләп тә үттек. Ләкин бит хәзер шәһәрдә дә миллионлаган татар яши. Анда безнең укучы бик тә кызыксына торган зыялылар мөхите, алар тормышы бар. Флүс Латыйфиның дөньяны күрү һәм тасвир алымнары татар зыялыларының бүгенге яшәвен оста һәм тулы чагылдыра алыр иде. Мин бәлки ялгышамдыр: ләкин ни өчендер шулай тоела — Флүс Латыйфи хәзерге көндә бүгенге татар зыялылары турында яңа роман язадыр шикелле.

Иң башта мәкаләләр, аннары хикәяләр язып каләм чарлаган, шуннан соң повесть жанрында да көчен сынаган һәм матур гына нәтиҗәләргә ирешкән Ф. Латыйфиның романы дөнья күрде дигән идек. Осталыкка акрынлап һәм ашыкмыйча, каударланмыйча баруы аркасындадыр, күрәсең, уңышлар бу өлкәдә дә сөенерлек килеп чыга. «Хыянәт» романы турында матбугатта бары тик уңай фикерләр генә әйтелде.

Юк, роман безнең милләтнең үткәне белән хәзергесен генә тоташтырмый. Анда бер елга буенда янәшә яшәү тапкан, янәшә гомер иткән ике милләт кешеләре күрсәтелә. Урыс егете Александрның татар кызы Гөлйөземгә мәхәббәте әлеге әсәрдә күп кенә киеренке вакыйгаларны бер җепкә терки. Әнә шул мәхәббәт хисе романның буеннан буена укучы игътибарын җәлеп итеп тора.

Безнең кайбер тарихи әсәрләрне уку зыялылар өчен генә кызыклы булса, шулай итеп тарихи роман үз даирәсен үзе үк тарайтса, биредә исә авторның мавыктыргыч хикәяләү рәвеше һәм бүгенге әдәби телнең казанышларына нигезләнгән матур, сыгылмалы сөйләме тарихи тема эченә киң катлау әдәбият сөючеләрне дә алып керә. Аларны тарих эчендә күрше авылда йөргән шикелле иркен һәм кызыклы сәяхәт иттерә. Әсәрдә укучы өчен писихологик һәм бүтән төрле киртәләр, каршылыклар тумый.

Кайберәүләр менә шул сәбәпле әсәрнең танып-белү ягыннан әһәмияте аз диярләр бәлки. Әмма аларга җавап итеп без шуны әйтик: тарих әдәбият эчендә эреп бетми икән, ул коры бер фән булып кына кала. Ә әдәби әсәр тукымасында эреп бетә алса, тарих үзенә мәңгелек яшәү таба ала. Киләсе гасырларда да җанлана ала, яши ала. Әдәби әсәр ул үлми торган тормыш тудыра, иҗат итә.

Флүс Латыйфи романының да төп уңышы әнә шунда. Хәер, житди бу әсәр турында галимнәр дә, тәнкыйтьчеләр дә аерым тукталып фикер әйтерләр әле. Әдәби иҗатка чагыштырмача күптән тотынмаган авторның юл башында ук мондый уңышка ирешүе бездә бик еш очрый торган хәл түгел бит.

Проза өлкәсенә яңа авторлар бөтенләй уйламаган-көтмәгән яктан да килеп керә. Әнә, Зөлфәт Хәким татар эстрадасы йолдызы булган җирдән, бер дә кыенсынмыйча, прозаик дусты Нияз Акмал янәшәсенә сикереп төште. Ни өчен бу ике исемне янәшә куябыз: чөнки алар икесе дә бер үк елларда проза китаплары чыгардылар. Һәм шәп китаплар чыгардылар! Ләкин биредә безнең сүз, яңа автор буларак, Зөлфәт Хәким әсәрләре турында гына.

Укучы бу исемне иң башта «Татарстан яшьләре» газетасында күрде шикелле. Күрде һәм аның язганнарын шундук ошатты. Моны редакция дә тиз чамалап өлгерде. Зөлфәтнең язмалары бер-бер артлы тезелеп китте. Арада сирәксирәк кенә тозсызраклары яисә артык тупаслары, начар «ис килеп» торганраклары очраса да, уңышсызлары һәм барып чыкмаганнары күренмәде. Кыскасы, бүген минем уйлавымча, юмор һәм сатира өлкәсендәге беренче урынны Гамил Афзал алса, икенче урын Фәнзаман Батталга эләксә, өченче урын, һичшиксез, Зөлфәт Хәкимгә тиеш! Әгәр дә моңа шикләнүчеләр табылса, алар юмористның өр-яңа әсәрен — «Агымсуда ни булмас...»ны укып карасыннар! Әлеге сатирик романның беренче юлларында ук кояш жиз тазга ошатыла, ә күктәге болыт исә, колак чистартырга дип иске матрастан йолкынган мамыкка тиңләнә. Биредә авыл исеме дә гади генә түгел — Җырыклы. «Алты керәшен авылы уртасында яшәп тә әле һаман чукынмаган татар авылы», — ди моны автор. Әсәрнең тәүге битендә үк күренгән беренче герой — милиция капитаны Миңлебаев та — бу авылның кичә сугышкан егетләрен эчтән генә сүгә-сүгә: «Мин сезне чукындырам!» — ди-ди килә. Күрәсез, оста юморист кулына эләккәч, ни куркыныч сүзләр дә бүтәнчә балкый башлый: көлдерә, зиһенне һич уйламаган тыкрыкларга алып керә.

Татар дөньясында бик сирәк кунак булган бу сатирик роман фантастикага һәм халык иҗаты әсәрләренә нигезләнгән. Әмма аны укыган чагында үз авылыңдагы кәмитләр искә төшә. Милли юмор һәр адымда тормышчанлыгын, халыкчанлыгын раслап бара.

Менә Су анасының бер үтенечен генә тыңлап багыгыз:

«— Ә-ә-ә, тагын бер үтенечем бар икән сиңа... Анысын әйтергә оялам.

Мәрданша, өметләнеп, тезләре белән аңа таба шуышты:

— Әйт, әйт, оялма! Мин бит сиңа ят кеше түгел! Әйт инде, оялма!

Су анасы бу үтенечен дә әйтергә батырчылык итте:

— Нуретдинегезгә әйт, елгага бүтән печ итмәсен!»

Күрәсез, автор ситуацияләр белән бик тә кыю эш итә, юмор дилбегәсен ышанычлы кулда тота. Шуңа күрә әсәр бер түмгәктән икенче түмгәккә гаять оста «сикерә».

Яшь язучыга теләк төсендә шуны гына әйтәсе килә: авыл һәм көнкүреш темасында яхшы ат уйнаткан сатира каләмен, бәлки, бүтәнрәк сферада да сынап карарга дыр ана? Мәсәлән, әле өр-яңа дөнья — бүгенге шәһәр тормышы бар, хәзерге сәясәт кешеләре... Сатира өчен менә дигән каһарманнар күренеп үк тора түгелме соң. Шундый сатирик романнар тагын да язылсын иде дигән теләк бу.

Әйе, халкыбызның талантлар чишмәсе, хәзер сирәгрәк булса да, каләм ияләрен һаман тудырып тора. Әдәби иҗатка озак еллар буе мәхәббәт саклаган шәхесләр үрләрен әкрен-әкрен генә яулый бирәләр. Яшь прозаик Мансур Шаһимәрдән дә әнә шундыйлардан. Моннан күп еллар элек аның бер хикәясе «Идел» альманахында басылып чыккан иде. Безнең бик таләпчән әдибебез Нурихан ага Фәттах та әлеге хикәяне матбугаттагы чыгышында билгеләп үтте. Шуннан соң бу авторның төрле жанрдагы язмалары республика матбугатында күренгәләп торды. Ә менә 1992 елда автор «Казан утлары»нда үзенең зур күләмле беренче әсәрен бастырды. «Кеше күңеле — карурман» дип исемләнгән ул повесть.

Мансур Шаһимәрдәннең көче нәрсәдә? Моны ачыклау өчен башта аның повестеннан өзек укып алыйк:

«Ә сәгать ярымнан соң инде кичке тын һавада Әргәннең исерек тавышы яңгырый:

— Кияү-ү-ү! — һәм аны очкылык тотып куя.

— Әкрен, Вафатдин абзый, шаулама, — дип карый Габделбәр эсселе-суыклы булып, як-ягына каранып. Әмма Вафа аның саен катырак кычкыра...»

Менә шушы кыска гына өзектә чын язучы сәләтенең байтак яклары чагылып ала. Монда ике төрле холык-фигыль дә ялтырап китә. Монда әлеге холыкның бер сүздәге төгәл бирелеше дә бар. Һәм шунда ук чын, кызыклы, каршылыклы тормыш үзе дә! Аны инде бүтән бизисе дә, арттырасы яки киметәсе дә юк! Моны бары тик ничек булса шулай кабул итәргә генә кала... Һәм тагын шуңа карап уйланырга, фәлсәфәсен чыгарырга.

Билгеле, әле Мансур Шаһимәрдәнгә әсәрне кора белү осталыгы җитми. Ул үзенең күп санлы каһарманнарын бер «уенга» берләштерә, оештыра белми. Әмма алар — аның әсәренә кергән кешеләр — һәммәсе дә диярлек кызыклылар, гыйбрәткә һәм мәгънәгә ияләр. Аннан соң авторда тел стихиясе шактый куәтле. Аның шомармаган, ялтыратылмаган сөйләү һәм язу рәвеше үзенчәлекле һәм кызыклы. Ул җанлы тормышны әнә шул җанлылыгы, кызыклылыгы белән әсәргә кертеп җибәрә ала... Шуна күрә аның повестен укый башлагач, ташлап булмый. Әллә нинди зур вакыйгалар һәм мәгънәләр тапмасаң да — мавыгып укыйсың. Кызыклы чынбарлык, үзенчәлекле тел-сөйләм агышы тота, күрәсең.

Күптән түгел үткән семинарда өлкән әдипләр аңа байтак кына киңәшләр биргән иделәр. Хәзер инде яшь авторның әнә шул теоретик сабакларны язу өстәле янында, үзең генә газаплана-газаплана үзләштерү чоры башланды бугай. Ягъни йөрәгең белән күзгә-күз калып, иҗат дөньясы серләрен ачу һәм осталыкка өйрәнү дәвере.

Әйе, уңышлы гына иҗат итүче яшь прозаикларыбыз бар. Ләкин аларның бөтенесе турында да биредә сүз алып бару мөмкин түгел. Ә менә югарыда сөйләгәннәргә кыскача йомгак ясарга тырышсак, нинди нәтиҗә килеп чыгар икән?

Иң беренче нәтиҗә,мөгаен, шундый булыр: соңгы елларда әдәбиятка килгән яшь прозаиклар үз әсәрләрен нәкъ менә татар халкына карап һәм аның күңелен, җанын күз алдында тотып язалар. Элеккерәк елларда кайбер яшь прозаиклар иҗатында чагылган «әдәби космополитизм» боларга хас түгел.

Аннан соң болар иң элек традицион һәм реалистик прозаның озак еллар буе сыналган алымнарына таяналар. Тел-стиль ягыннан да алар татар теленең табигый, халыкчан агышына йөз тота: бер әдәби чара өстенә икенчесен өеп «мөгез» чыгармый, «яңача булсын!» дип һәм бары тик шунын өчен генә баш ватып көчәнми. Болар иң башта укучының күңеленә үтүне максат итә, төп көчләрен шуңа юнәлтә. Ә аның фикер, зиһен ягына түгел.

Мондый сыйфатлар, һичшиксез, хупланырга тиеш. Чөнки татар әдибе өчен иң беренче һәм иң төп укучы булып татар халкы тора.

Билгеле, аларның юл башлау вакыты замананың да авыр чорына туры килде. Бүген тормыш кыенлыклары аркасында хәтта җитди генә әдипләр дә иҗаттан тукталып тора бит әле... Әмма яшьләр үзләрендә иң элек милләтебезнең олы рухи ихтыяҗын тойсыннар иде. Әчке омтылышлары, изге омтылышлары аларга иҗатта иң беренче һәм төп таяныч булсын иде! «Татар халкы» дигән олы маякны алар һич кенә дә югалта күрмәсеннәр!

Гомумән, «татар милләтенең рухи һәм әхлакый үсеше өчен!» дигән теләк, әнә шул омтылыш бүген безнең барыбыз өчен дә уртак максат, уртак юнәлеш булсын иде! Әнә шул чагында гына безнең һәммә эшебез алга бара алыр.

■

# ГАЗИЗ ТЕЛЕҢӘ, ТАТАР, ТӨБӘМӘЧЕ АЛТАТАР!

Сакаллы шундый мәзәк бар. Бер кавказлы (милләте мөһим түгел), урыс теленнән Ходаның һәр бирмеш көнендә «2»ле алып кайтучы улына ачуланып болай дип кычкырган, имеш:

— Сколко тебе можно говорит, «тарильке», «вильке», «бутильке» всегда пишутся без мягкого знака, «корол», «фасол», «парол» — с мягким знаком!

Бездә дә шуңа охшашрак хәл күзәтелә бит әле, җәмәгать. Бер ише сүзләрнең язылышы күпчелек очракта (ләкин һәрвакыт түгел) дөрес булса да, укылышы, әйтелеше кайчагында гайрәтне чигерә торган. Мисаллармы? Алар буа буарлык. Мин үзем шәхсән татар теле белгече түгел. Әмма телебезнең сафлыгы, камиллеге, сыйфаты сагында арысландай торырга, хәвеф янаганда беренче булып чаң сугарга тиешле зыялыларыбыз дәшми бит. Дәшкәләсәләр дә, без көйгән яссылыкта тел тибрәткәннәре юк. Бу мәсьәләдә битарафлык гомумән бик көчле. Шушы чыгышларга кытлык безнең ише профессиональ булмаганнарны, ягъни һәвәскәр лингвистларны да кулларына каләм алырга мәҗбүр итә. Тукайча ук булмаса да, дәшмәде дип бирмиләр ошбу җиһанда мәртәбә, дияргә генә кала.

Әлбәттә, язма һәм сөйләм телебездәге чатаклыклар хәттин ашкан. Аларның барысы турында да язу мөмкин дә түгел һәм безнең вазифага да керми. Ләкин күңелне һәрдаим тырнап торган берничә момент турында үз сүзебезне кистереп әйтмәсәк, гамәлгә сыймастыр. Бәлки, бу фикерләрдә белгечләребез дә берәр «рациональ бөртек» табар. Анык күренеп, ярылып торсын өчен әйтәсе килгән уйларны аерым бабларга, моментларга бүлүне тиеш таптык.

Беренче момент. Мәгълүм булганча, күпчелек терминнар, сүз тезмәләре, әйләнмәләр һ. б. безгә урыс теле аркылы керә. Бу фактны беркая да куя алмыйсың. Мәсәлән, сыйфат белән исемнән торган кайбер сүзтезмәләрне алыйк: документальный фильм, музыкальная программа, актуальное интервью, монументальное искусство һ. б. Беренче сүзләр сыйфат, икенчеләре — исем. Һәр фасылда (род, сан, килеш) ярашкан бу ике сүзнең бәйләнешен урыс телендә «согласование» диләр. Хәзер инде сүзтезмәләрне татарчалаштырабыз: документаль фильм, музыкаль программа, актуаль интервью, монументаль сәнгать һ. б. Бары тик шулай гына. Димәк, охшашлык (аналогия) буенча без генераль директор, феодаль җәмгыять, универсаль магазин (кибет), радикаль реформа, либераль хәрәкәт, идеаль модель һ. б. дип язарга тиеш булабыз. Булабыз, ләкин еш кына менә хилафлык кылабыз, дөресрәге, ана телебез кануннарын тупас бозабыз. Хәлбуки, хәзер гәзит-журналларда атлаган саен феодал җәмгыять, материал кызыксындыру, идеал тәрбия, либерал эшлекле һ. б. дип язалар. Хәтта кайбер телче профессорларыбыз да шулай дип яза һәм сөйли. Бәлки, мин ялгышамдыр, әмма болайга китсә, без «кардиналь чишелеш» урынына «кардинал чишелеш», «генераль директор» урынына «генерал директор» дип әйтергә тиеш булабыз. Ә бит без беренче очракта «кардинал»ны, икенчесендә «генерал»ны күздә тотмыйбыз. Рациональ тәкъдимне «рационал тәкъдим», панель йортны «панел йорт», эмбриональ үсешне «эмбрионал үсеш» диик, булмаса. Тик менә урыста «нормальный человек» дигән әйтем бар, аны нишләтәбез? Тәрҗемә кылсак, «нормаль кеше» килеп чыга. Безне шул борчый: «нормал кеше» дип яза калсак, үзебезнең нормальлегебездә шикләнә башламаслармы икән? Татарга ярамаган тагын, дисәк, әйдәгез алайса, оптимал срок, музыкал сәләт, индивидуал план, фронтал проекция, глобал эш дип сөйлик, мәктәп балаларын да юлдан яздырыйк.

Икенче момент. Күп кенә көндәлек басмаларыбызда хәзерге көндә халыкара «секретарь» сүзе урынына «сәркатип» дип язалар. Бик хуп. Гарәп-фарсы сүзе ул, бабаларыбыз рәхәтләнеп кулланган. Ләкин бит бу сүз «къ» белән түгел, «ке» белән языла. Кятиб, китап, көтепханә, мәктәп, сәркә(я)тип сүзләре бер тамырдан. Аларның нигезендә «язу» мәгънәсе ята. Мәсәлән, мәктәп — яза торган урын. Сәр — баш дигән сүз (сәргаскәр — гаскәр башлыгы). Искә төшерик: «Мәҗ(е)лестә төлке кятиб, бүре рәис» (М. Гафури). Димәк, дөрес язарга һәм әйтергә тиеш икән, сәркәтиб, һич югы сәркәтип, яки сәркятипне кулланырга тиеш булабыз. Ләкин «сәркъатип» һич кенә дә дөрес түгел.

Шул ук тема белән бәйләнгән инкарь, дөресрәге, инкяр сүзе (кире кагу мәгънәсендә) турында. Аны да бозып, һәрвакыт диярлек «инкъарь» дип сөйлибез. Фидакярне дә «фидакъарь» дип бугазлыйбыз. Монда да «къ» тупас хата. Шул ук сүзне тәкбир, тәкрар турында да әйтергә мөмкин (биредә дә «къ» телебезне бозу булып тора).

Өченче момент. Соңгы вакытларда «ошау» белән «охшау» сүзләрен рәхәтләнеп бутау китте. Урыс сүзләре белән аңлатсак, беренчесе «нравиться», икенчесе «быть похожим»ны белдерә.

Ләкин юк шул. «Миңа бу җыр бигрәкләр дә охшый», «күңеленә охшаган — елан ите ашаган», дип сөйли бирәбез. Бер бик популяр җырчыбыз «ошый» сүзен гомумән дә белми ахры, гел «охшый» дип тәкрарлый... «Мәхәббәт» белән «мәһабәт» сүзләрен бутау да гөрләп чәчәк ата. «Мәһабәт» дигән сүзне хәзер кәбисә елларында гына ишетәсең.

Тагын мондыйрак мисаллар. Атаклы гына дикторыбыз экономика мәгънәсендәге «икътисад» сүзен гел «игътисад» дип кыерсыта. Мескен икътисад бик рәнҗи торгандыр инде. Аннары җәмгыятебезнең каймагы сөйләмендә «игътибар сүзе урынына «ихтибар» бик популяр булып китте. Һай бу сакаулыклар! Аннары тагын бер мөгез чыгардык. Җөмһүриятебезнең көнчыгыш төбәкләре сөйләмендә, диикме, «нормаль» «л» авазы урынына еш кына нимеснең «ди лампе» дигәндәге кебек йомшак «ле» кулланыла. «Алай да була» дигәнне «аляй да буля» диебрәк җиффәрәләр. Халык сөйләменә дәгъва белдереп булмый, әлбәттә. Әмма дипломлы зыялыларыбыз, бик популяр җырчыларыбыз телендә бу инде сәеррәк яңгырый. Әлеге чир хәзер эпидемиягә әйләнде. Гомер буе кешечә «л» белән җырлаган җырчыларыбыз да тиктомалдан кисәк кенә сакауланып киттеләр. («Армас микән кульың, тальмас микән кульың, ишкәкләрне ялгыз ишкәндә».) Пәһлевандай ир-ат, алыптай сынын катырып, бала-чага кебек сакауланып җырласын инде.

Шул ук бабка тагын бер-ике мисал индерик. Иң популяр гәзитләребезнең берсенең исеме тумышыннан ук дөрес язылмый. «Метрикасы» дөрес тутырылмаган, димәк. Сүз «Шәһри Казан» турында бара. Гомер-бакый шәһре Болгар, шәһре Казан булган атамалар онытылып, ниндидер шаукым белән кисәк «Шәһри Казан» булып киттек...

Урысча «окружающая среда» сүзтезмәсен татарча язу мәсьәләсе. Гадәттә бу тәгъбирне «охрана окружающей среды» белән бәйлиләр. «Окружающая среда»ны исә нинди генә шәкелләрдә язмыйлар: ул әле «әйләнә-тирә мөхит» әле «тирә-як мөхит», әле «тирә-юнь мөхит»... Ләкин хикмәт шунда, гарәп сүзе булган «мөхит» (мохит) үзе әйләнә-тирә дигәнне аңлата («океан» дигән мәгънәсе дә бар). Димәк, без «охрана окружающей среды» дигән урыс тезмәсен «әйләнә-тирә тирә-юньне саклау» дип тәрҗемә кылабыз булып чыга. Әллә соң, мин әйтәм, адәмчә генә «тирә-юньне саклау»га гына күчәбезме? Кыска да, татарча да.

Гади халык арасында бик күренми, ә менә төрле катлау вә сорт зыялыларыбыз арасында илләә дә мәгәр бер кыюсызлык галәмәте көчәеп китте. Алар үз сүзләрен, теләкләрен һич кистереп, турыдан бәреп әйтмәсәләр, сак кына, читләтеп кенә: «Мин Сезне, Фәлән Төгәневич Фәсмәтәнев, чын күңелдән 60 еллык юбилеегыз белән котлыйсым килә!» — диярләр. Боларның әйтәселәре, телиселәре, котлыйсылары бик килә, тик нигәдер базмыйлар. Соң инде, килсә, әйт аны кистереп, кем комачаулый, нәзберекләнмә ул кадәр. «Дип әйтәсем килә», «ышанасы килә, — дип тә кеше көлдермик инде. Телебез сыртына мәгънәсезлекләр йөге аннан башка да мул төшә бит.

«Чәчтараш» сүзе журналистик әйләнешкә кереп бара. «Парикмахер» мәгънәсендә. Килешле генә, ин мөһиме, саф татарча. Элек актив кулланылган. Ләкин монысын да бозмасак иде. Ул бит бүген генә уйлап чыгарылган сүз (неологизм) түгел, гомер-гомергә «сачтараш» булып йөргән. Тукайда да болай бит: «Тотса баштан сачтараш, шалтыр да шолтыр йон ага!»

Атабыз Адәмнең хәләле анабыз Хаува турында. Адәм Галәйһиссәламнең исемен бозып язарга каләм әһеленең әлеге кыюлыгы житенкерәми. Ләкин аның

кәкре кабыргасыннан ясалып, җан өрелгән анабыз Хауваның исемен суепмысуялар: «Һава», имеш. Бер журналга мәкалә биргәндә, күнелем сизенеп, «Һава» дип төзәтә күрмәгез, дию емә «ярар, ярар», дип җавап биргәннәр иде. Әмма басылып чыккач, шаклар каттым: минем Хаувамнан тагын Һава ясап куйганнар. Гөнаһка батмыйк инде, дуслар! Ошап бетмәсә, «Хава», «Хәва», «Хәуа» языгыз, тик «һ» белән генә имгәтмәгез.

Мәгърур «һ» авазыбыз фаҗигале көннәр кичерә. Катыйльгә әйләнгән «х» авазы аның нечкә муенына пычак ышкып, иртәле-кичле ясин укый. Телевизорны кабызыгыз, радиоалгычны тоташтырыгыз, хәтта ки үткне ялгагыз — бар дулкын, тирбәнешләрдә «х» «һ»нен җанын кыя: хәм, кахарман, хава (кирәк вакытта юк!), хөнәр, хич... Укып карыйк: «Ибрахим хәм Махирә хәр көн диярлек шәхәргә килеп, хаман саен базар бәхаләрен белешәләр». Күренекле әдипләребез, олпат зыялыларыбыз, елгыр журналистларыбыз — һәмәсе дә диярлек шул юнәлештә эшли. Әллә бу җүнләп әйтеп тә булмый торган каһәр суккан хәрефне алфавиттан ук чыгарып ташлыйсы иде! Бигрәк интегәбез бит...

Хөрмәтле дикторлар, атаклы конферансьелар, сүз осталарыбыз уку-сөйләмендә дә байтак «күләгәле» мизгелләр бар. Өлешчә ул турыда әйттек тә инде. Әмма монысында икенчерәк мотивлар. Нигә инде аны атлаган саен әдәби «белән» бәйлеген койрыгы кыелган «белә» белән алыштырырга? Игътибар итик: «Энем белә сеңлем белә: без бөтен класс белә Габдула Тукайның «Кәҗә белә Сарык» әкиятен укыдык». Боларны бутау нинди мәгънәсезлекләргә китерә! Җитмәсә, «белә» дигән бәйлегебез «белү» дигән исемнең хәләл милкенә дә кул суза.

Аннары тагын милләтебезнең сүз осталары сәхнәдән, телевидениедән, радиодан үз шивәләрен алга сөреп, Сибгат урынына «Сибагат», эре урынына «ире», мәйдан урынына «майдан», тилгән урынына «тилегән», берәр кая урынына «берәр яры» дип сөйләмәсеннәр, җөмләләрен «дагын», «дәген» ише чуалган койрыклар белән алай ук тырышып бизәмәсеннәр иде. Ник дисезме? Һәр диктор радио-телевидениедән үз төбәге диалектында сөйли башласа, «гуд гудлаган куцат» килеп цыкмагае. Аннары «гурласына капты, путалакка бакты, баккан килеш катты» кебек «җәүһәрләр»гә дә ерак калмый инде. Теле ачылып кына килә торган сабыйларыбыз, әдәби ана телен үзләштерергә омтылган яшьләребез өчен сүз осталары да үрнәк булмаса, тагын кемнәргә генә өметләнергә кала соң?

Тел осталарыбыз вә дикторларыбыз авызыннан чыккан «конкурс» дигән матур яңгырашлы сүз бер яктарак торсын инде. «Дирижер» сүзе дә вак мәсьәлә, югыйсә, «е» урынына «о» гына әйтәсе дә бит. Ә менә Япония, Ямашев, Яруллин, Явлинский кебек атамаларга, фамилияләргә килгәндә, эш җитдирәк. Нигә инде аны «Татар җыры — 1992» бәйгесендә җинеп чыккан артистка «епон» магнитофоны тапшырырга? «Япон»нықын бирергә дә, вәссәлам. Гомумән, аерым татар дикторлары һәм сәхнә осталары «я» хәрефенә башланган сүзләрне кулланганда аптырабрак калалар. Грамоталы урыс Япония, Ямашев, Яруллин, Явлинский, Якир, пятак дип язса да, «я» басымсыз сузык булганга, Епония, Емашев, Ерул-лин, Евлинский, Екир, петак дип укый һәм сөйли. Ләкин бит татар теле мондый кагыйдәгә буйсынмый, шуңа күрә безгә авызны чалышайтуга хаҗәт юк. Миңа калса, «Дбилиси» дигәне дә татарча яңгырамый.

Гәзит-журнал битләрендә «Авзалова» кебек язылышлар еш күзгә ташлана башлады. Бу фамилияне йөртүчеләр гафу итсен, Афзалдан килгән нәсел булгач, һич югы «Афзалова» дип язарга кирәктер бит инде. Гамил Афзалыбызны гына Авзал дип яза башламасалар ярар иде!

«Икән» белән «микән»не бутау геометрик прогрессия белән үсә. Бу темага аерым бер мәкалә язарга мөмкин. Хәер матбугатыбызда «Нигә килмәде микән ул?», «Гали анда нишләп утырды микән?» кебегрәк җөмләләргә багана саен юлыгасың. Аянычы шунда: бу буталыштан күренекле әдипләребез, журналистларыбыз да имин түгел. Җырлап карыйк: «Нигә генә микән синдә генә микән, синдә генә микән күңелем!»

Зыялы милләттәшләребез телендә «ул» урынына «выл», «вал» дип сөйләшү дә эчне пошыргалап куя. Гади авыл кешесенә үпкәләп булмый инде. Ә менә үзәк театрыбыз сәхнәсендә «Нәрсә дип әйтә выл?» яки «Юк инде выл» дип «җиффәрү»ләрне ни белән аңлатырга да белгән юк. «Ул» урынына «выл» язылсын дигән берәр закон кабул итәсеме шунда? Булмас инде выл!

Сузык авазлар яки яңгырау тартыклар алдыннан килә торган яңгырау тартыкларны урысчалатып саңгырауга әйләндереп сөйләшү күренеше дә колач җәя. Бер мәшһүр җырчыбыз «тизерәк әйләнеп кайтыгыз» урынына, «тизерәг әйләнеп кайтыгыз» дип җырлый. Бик әйбәт, ник әлләни димиләр кебек сүзтез-

мәләр сәхнәдән дә, радио-телевидениедән дә яңгырап тора. Аннары кайбер дикторларыбыз «Татарстанның халык артисты» дип үтерәләр иде. Болар шәһәрдә үскән, татарчалары такы-токы булганнарның гына «казанышы» түгел, хәзер авылдан чыккан артистларыбыз да татар телен фильтрлап, «Ирек абый, Николайга ник алай дип әйттең?» кебегрәк сөйләп азапланалар.

Урыс теленнән «уптым илаһи» диярлек алынып, татарчага калька рәвешендә генә оялаган сүзләрнең исәбе-хисабы юк. Аларның язылышы (урысча шулай булганга күрә генә) татар теле кагыйдәләренә бөтенләй туры килми. Нигә дип без сүзтезмә (үзем дә алдарак сыкранып кына бергә яздым), сууткәргеч, күпсанлы, сусаклагыч, ашкайнату ише сүзләрне бергә язарга тиеш әле? Урысчасы бергә язылганга күрә генәме? Хәсән Сәрьян мондый мөгез чыгарулар белән күп көрәште мәрхүм, тик нәтиҗәсе генә булмады. Мәсәлән, аш кайнату процессы, аш кайнату органнары дип язасы урынга без, телебезне мәсхәрәләп һәм кемнәргәдер ияреп, ашкайнату процессы, ашкайнату органнары дип үҗәтләнәбез. Махсус терминология, имеш! Әллә соң моннан ары «вареньекайнату», «сарукайнату», «көмешкәкайнату» дип кенә шапылдатабызмы?

Татар фамилияләренең, отчестволарның -ов(а), -ев(а), -ин(а), -ович, -овна һ. б. суффикслары-кушымчалары белән язылу мәсьәләсе. Кем әйтмешли, татарларда -ов, -ев та, -ич, -мич тә юк. Урыска бара ул. Әйтик, Иван-ов (сын), ягъни Иван улы, Петров-а (дочь), ягъни Петр кызы. Шведка да үзләренчә бата: Карлсон, ягъни Карл малае. Ә татарга бу ниемә! Харис-ов сын була димени? Харис малае ич ул. Габит-ов-а дочь та юк, Габит кызы гына бар. -Ович, -евич дигән нәмәрсәләр дә безгә ят. Күптән түгел генә Рәис Сәфәров дигән милләттәшебез Әмин әфәнде Минһаҗны «ович»лардан котылу зарурилыгы турындагы тәкъдименә каршы төшкән иде (Шәһри Казан, 1993, 18 май). Янәсе болай: «...бу өлкәдә сүз куерту бер дә кирәкми. Исем-фамилияләрнең хәзерге әйтелеше инде традициягә әйләнгән, нәселдән нәселгә килә. Урысларга үч итәм дип (?), әллә нинди «ислах»ларны уйлап чыгару мәшәкатьле, чыгымлы, кирәксез эш. Ике хәрефле «ЫЙ» кушымчасы аркасында миллионнарча паспорт-документларны миллион сумнар хисабына алмаштыру үзе ни тора!»

Әлбәттә, бу мәсьәләдә көчләү, басым ясау килешә торган эш түгел. Һәркемнең үз фикере, үз иманы бар. Тик ни бит әле, агай. Традиция, дигәннән, без соңгы дәверләрдә чамадан тыш төшерергә дә, болайрак сөйләшергә дә хәйран һәвәсләнеп, каешланып җиттек: «Ул уже давно теге эшеннән увольняться иткән». Может, традициягә әйләнгәч, боларыннан да баш тарту килешмәс. «Урыска үч итү» дигәне нәрсә икән тагын? Үзеңнең асыл, ата-бабалар исеменә кайту кемгәдер үч итү була микәнни? Татар бит гасырлар буена үз исемен йөрткән, -ов, -ев, -ин кебек галәмәтләрне башлыча ревизия һәм переписьлар вакытында, гаскәргә алганда, паспорт-фәләннәрне биргәндә ана урыс администрациясе көчләп таккан. Сез татарның мәчеттә теркәлгән «метрика»сында Сабиров, Гарипов дип язганнар дип беләсезме әллә?

Паспорт-документларга киткән расход, дигәннән, болай. Әүвәлән, Татарстан гражданнарының иртәме-соңмы барыбер яңа үрнәк паспортлары булдырылачак. Саниян, юньле-башлы илләрдә паспорт дигән нәмәрсә бөтенләй юк, кирәк вакытта» загранпчный»ны гына бирәләр. Салисән, кешенең үз гомерендә бер генә мәртәбә булса да исем шәрифләре дөрес язылган документ алырга хакы бардыр бит инде! Аннары, миссионерлык традициясенә тугърылык саклыйбыз, дип, Гилязутдинов Сайфульмулюк Тазутдинович булып йөргәнче, бәлки Сәйфелмөлек Гыйлаҗига гына туктаырга тырыргадыр. Үрнәкләр җитәрлек: Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Мәҗит Гафури, Мирсәй Әмир, Бакый Урманче, Риза Ишморат... Ни өчен «Гыйлаҗи», ә «Гыйлаҗетдинов» түгел, диярсез. «Гыйлаҗетдин» — анда гарәпчәме-фарысчамы-татарчамы, һәрхәлдә, мөселманча, ә -ов суффиксы урысча. Соң атка дуңгыз койрыгы такмыйлар лабаса! Йә Гилязутдинов (анысы да ташка үлчим, әлбәттә), йә Гыйлаҗетдин. Шуңа күрә Сәфәров дип язу үзе үк дөрес түгел, ут белән суны кушып булмый, шулай да «Сафаров» белән беркадәр килешергә мөмкин. Ул үзе дә төпле генә мәкаләләренә имзаны әүвәл шулай дип куя торган иде, ләкин тәнкыйтьләгәннән соң төтене кыйшайды. Хәер, анысын үзе белә торгандыр.

Хатын-кызларыбыз исемнәре турында да берничә сүз. Ни үкенеч, безнең иң милли композиторларыбызның берсе, моң алиһәсе Мәсгудә ханым һаман да нигәдер Шәмсетдинова булып йөри. Иң дөресе, матуры һәм җыйнагы Мәсгудә Шәмсетдиния булыр иде югыйсә. Тарихи мисаллар: Фәхрелбанат Сөләймания, Зәйнәп Хәсәния, Маһруй Мозаффария булса, ятышлырак.

Күптән түгел генә бер популяр гәзитәбезнең икенче битендә «Төркиягә белем өстәргә» дигән баш астында күләмле генә мәкалә басылган иде. Башын-

дагы хата очраклы киткәндер инде. Өстәтер сиңа белем Төркия, мөстәкыйль дәүләт ич ул! Шушындый ялгыз бер сүз белән генә дә дәүләтара мөнәсәбәтләргә күләгә төшерүең бар. Чөнки дөресе — эстәргә. Аерма бер хәреф, ә мәгънә ничек үзгәрә. Менә бит ул тел дигәнең! Шул ук гәзитебез аннан әүвәлрәк инде беренче битендә мондый баш астында бер мәкалә биргән иде: «Гата Камский — шахмат алиһәсе». Монысының механик хата булуы шикле. Соң, егетләр, «алиһә» хатын-кыз аллага, яисә мәхәббәт алласына карата гына кулланыла бит ул! Урысчасы «богиня» була. Рөстәм абзый улын «богиня шахмат» дип атаганнарын ишетмәгәндер әле, ишетә калсамы...

«Кая» белән «кайда» шактый бутала башлады. Берсе юнәлешне, икенчесе урынны белдерә бит инде югыйсә (урысча «куда» һәм «где»). «Син кайда барасың?» дию, әлбәттә, телне бозу ул. «Ничек» һәм «нинди» белән дә шундыйрак хәл («мин сине ничек яраттым...»).

Хәзер без атлаган саен «бала тудыру», «бала тудыру йорты» дип сөйләшәбез. Бик тупас бит бу, егетләр, бернинди дә әдәп кысаларына сыймый. Бу инде, гафу итегез, хатын-кызга карата «буаз» сүзе куллану белән бер. Баланы тудырмыйлар, ә «табалар» бит аны. Һ. Такташ та әнисенә карата болай дип язган иде: «Ярый әле мине тапкансың!» Чын татар песи, эт, сарык турында сүз алып барганда да «тудырды» димәс, ә «китерде», «алып кайтты» дияр, анысын да уңайсызланыбрак әйтер. «Тудыру» — урысча «рожать» сүзеннән ясалган калька гына.

Вокзалларда, трамвайларда татарча игъланнарны ишеткәндә колаклар шиңә. Шул хәлгә калдык микәнни соң инде без, җәмәгать! Алардагы акцент шулкадәр көчле ки, мәгънәсенә урысчасын тыңлаганнан соң гына төшенәсең («сак булагаз, ишэклэр ябала»). Татарның мәркәзендә дә телебезне шулай пычаксыз суйгач, чит җирләрдән ни көтәсең? Әллә соң бу махсус кылына торган мәсхәрәме!

«Ярымай», дөресрәге, «ярым ай» мәсьәләсе. Берәү болай дип язган: «Җирнең ямен, суның тәмен саклап, ярымайлар күккә омтыла...» Ягъни сүз мәчет манарасындагы ай турында бара. «Ярымай» — «полумесяц»тан калька. Йә әйтегез әле, кайсыбызның мәчет шпилендә ярым (ярты) ай күргәне бар? «Ярым» булса, урталай киселгән тәлинкәне хәтерләтер иде. Хәлбуки, мәчет манарасының ае урак формасында. Шуңа күрә, кайбер иптәшләр, адәм ышанырлыграк булсын диптер инде, «чирекай» (?) сүзен уйлап таптылар. Язылышына гына карагыз сез аның, ичмаса, «чирек ай» булсын иде. «Тулыай» дип бергә язмыйбыз шикелле бит. Ә укылышы урысча «чирикай»ны хәтерләтә. Урыста «четвертьмесяц» сүзе юк, монысы тулысынча үзебезнең казаныш. Айның «беренче чиреге», «соңгы чиреге» дигән сүзләр бар барын, ләкин монда мәчет аеның ни катнашы бар? Безнең әби-бабаларыбыз беркайчан да «ярымай», «чирекай» дип сөйләшмәгәннәр. Димәк, иң дөресе гап-гади «ай» сүзе булыр. («Мәчеткә ай кую».)

Озын сүзнең кыскасы: бу темага кереп чумсаң, ерып чыгам, димә. Мең дә бер кичләрең бер кырыйда торсын.

Әйдәгез, дуслар: телче галимнәребез, әдипләребез, шагыйрьләребез, журналистларыбыз, радио-телевидение хезмәткәрләребез, сәхнә осталарыбыз, гомумән, барлык зыялыларыбыз вә милләтпәрвәрләребез, туган телебезне сафландыру һәм үстерү юлында кулга-кул тотынышып эшлик, ата-бабаларыбыздан калган мөкатдәс мирасыбызны киләчәк буыннарга исән-имин килеш тапшырыйк. Икенче юлыбыз юк... Сәнгатьчәрәк итеп әйткәндә,

Газиз телеңә, татар,
Төбәмәче алтатар!

**Равил ӘМИРХАН,**
тарихчы

Китап күзәтү

# КҮГӘРЧЕН СӨТЕ?!.

Гаять катлаулы чорда яшибез. Каләм ияләре өчен аеруча зур сынаулар заманы. Шуңа күрә тормыштагы һәм көнкүрештәге үзгәрешләрнең иң әһәмиятлеләрен сайлап алу, аны укучы кызыксыныплык сәнгать әсәре биеклегенә җиткерү өчен көч тә, сабырлык та таләп ителә.

Узган ел китап кибетләрендә Нияз Акмаловның иҗат җимеше — бер повесть һәм өч хикәяне берләштергән «Күгәрчен сөте» исемле җыентыгы пәйда булды.

Китапны кулга алу белән укучы күңелендә туган беренче сорау: бармы соң ул күгәрчен сөте? Ул нинди төстә? Аны кем очраткан? Кем тапкан? Уй җепләре халык авыз иҗатында кулланыла торган тәгъбирләргә дә барып ялгана. Гомерен татар халкының рухи байлыгын җыюга багышлаган галим Нәкый ага Исәнбәт «күгәрчен сөте» фразеологик әйтелмәсенә мондый аңлатма бирә: «1. Тырнакка ак төшү; 2. Аракы; 3. Муллык, ризык-нигъмәт.» Ләкин Н. Акмалов әсәрендәге «күгәрчен сөте» югарыда саналган мәгънәләргә тулысынча тәңгәл килми. Автор бу төшенчәгә кешенең тоткан урыны, бәхет эзләү һәм аны табу кебек фәлсәфи фикерләр сала. «Бар бит ул күгәрчен сөте, бар! — ди гомер буе ятимлектә үскән, соңыннан Хәбир белән тормыш корып бәхетен тапкан Лиза.— Кемгәдер кирәк булуыңны, кадереңбулуны тоеп яшәүдер ул күгәрчен сөте».

Җыентыкның чын йөзен ачучы, үтемлелеген билгеләүче әсәр — «Күгәрчен сөте» повесте. Язучы катлаулы сюжетка корылган бу әсәрендә тормыш өчен мөһим булган проблемалар күтәрә, четрекле мәсьәләләрне чишү юнәлешендә капма-каршылык юлын сайлап, укучыны вакыйгалар арасына бөтереп алып кереп китә һәм аның белән бергә чыгу юлларын эзли.

«Күгәрчен сөте» берничә планлы әсәр, үз эченә шактый катлаулы вакыйгаларны сыйдырган. Биредә Балтамак авылында гомер кичергән Әхмәтгали карт һәм аның балаларының язмышы, төрле шартларда яшәү рәвешләре тасвирлана. Алар характерының эволюциясе мавыктыргыч итеп бирелә. Әйтик, Сталин үлү вакыйгасына бәйләп атасы үз улын: «Кеше елаганда — еларга, кеше көлгәндә — көләргә кирәк, улым»,— дип өнди, әмма соңгы чиктә, нәкъ шушы юлбашчы урнаштырган тәртипкә каршы килеп — авыл мулласына әверелә.

Әтисе белән бер йортта яшәүче Әхсән дә Әхмәтгали сызган буразнадан чыгарга теләми. Аның авыл мулласы белән бер түбә астында яшәвен гаеплиләр. Бу урында Әхсәннең ныклы характерга һәм ихтыяр көченә ия булуына ышанабыз. Үзен тәрбияләп үстергән атасыннан ул мулла булган өчен генә баш тартырга җыенмый. Әхсән образы аша язучы тәҗрибәле психологлар гына аңлата алырдай каршылыклы характерны, гаять чуалчык язмыш иясен күз алдына китереп бастыра. Бу образның эш-хәрәкәтләрен бирүгә караганда аның эчке дөньясын, рухи халәтен ачуга күбрәк игътибар ителә. Нәкъ менә шушы бунтарь йөрәкле, эчке халәтенә башкарган эшләре туры килеп бетмәгән Әхсән образының әдәби әсәрдә калкып чыгуы аның киләчәктә үз күңеле теләгән, җаны тарткан эш белән шөгыльләнәчәк кеше булачагы турында сөйли. Билгеле, бу повесть 70 — 80 нче елларда басылып чыкса, күпкә отышлырак булыр иде.

Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең иң актуале — борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне, традицияләрне саклап калу һәм киләчәк буыннарга тапшыру. Әдәбиятыбыз классиклары Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев тарафыннан күтәрелгән башлам Н. Акмалов повестенда дәвам иттерелә. Буыннан-буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм традицияләр вакытлар узу белән һич тә әһәмиятен югалтмый, аларның кыйммәте арта гына бара. Язучы каз өмәсенә аерым туктала. Повестьтагы Әхсән образы буыннарны бәйләүче, борынгы йолаларны торгызып, аны халыкка барлык нечкәлекләре белән ачып салуга армый-талмый хезмәт итүче итеп ачыла. Бәйрәм кичәсенә җыелган халыкның рухи халәтен,

омтылышларын нечкә күнелле Әхсән кичерешләре аша биреп, автор үтемле юлны сайлаган. «Ул бары тик шуны гына тойды: халык аның сүзен йотлыгып тынлый, рәхәтлектә изрәп, нидер көтә...» «Айсылу ахирәтләренә, яшьлек дусларына күз төшерде. Алар барысы да тын калган, йөзләрендә моң-сагыш. Кайберләре күз яшьләрен яшерми дә». «Әхсән жизнәсенең йөзенә дә игътибар итте: кияү кеше аны бик тә бирелеп тынлый, карашы, кыяфәте белән теләктәшлек белдереп, җөплəп утыра сыман». «Әхсән янә бер таныш караш шәйләп алды: көлеп, шатлыктан балкып, елмаеп утырган бу яшь кызны ул әле күптән түгел генә карлы сукмакта, чишмә юлыннан кайтып килешендә очраткан иде. Укытучы кыз...»

Бәйрәмдә Әхсәнгә теләктәшлек белдерүчеләр белән беррәттән, халык алдында аңа каршы чыгып, Әхсәнне кайчангыдыр бурычын түләмәүдә гаепләүче Ильяс образы килеп керә. Аның урынсыз биргән соравы аркасында Әхсәнгә шактый гына вөҗдан газабы кичерергә туры килә. Билгеле, тормышта Ильяс сыман аны-моны уйламыйча сорау бирә торган типлар очраштыргаласа да, әдәби әсәр герое иткәндә аны тиешле дәрәҗәдә гомумиләштерү урынлырак булыр иде. Әлегә бу персонаж катнашкан эпизодларда ышандыру көче житеп бетми.

Әхсән Сабирҗановның эшен тикшерү өчен Казаннан комиссия килеп төшә. Аның составында Әхсән энесе Хәбирнең балачак дусты Таһир Корбанов. Фәнни эше барып чыкмагач, ул атеистик темага мәкаләләр язып, көнне-көнгә ялгарлык акча эшли. Яшәү өчен көрәштә батып калмаска теләп, ул үзен үстергән халыкның тарихи үткәнен сызып ташлаудан, милли аң үсешенә балта чабудан да чирканмый. Н. Акмалов үз әсәрендә Таһир Корбанов кебек образ иҗат итеп, андый типларның шәхси тормышта да, җәмгыять өчен дә кирәксез кеше булуларын исбатлый.

Таһир белән көрәштә җиңеп чыгарга тиешле итеп тудырылган Хәбир образы фаҗигаләргә тарыган язмыш буларак бирелә. Хәбир Казанда төзүчеләр институтында бераз белем ала, соңыннан Армия сафларында хезмәт итеп кайтып, Мәскәүдәге архитектура институтын бетерә. Аннары латыш кызы Лизага өйләнеп, үз теләге белән Әфган җиренә, мәчетләр төзекләндерү эшенә китә. Менә хәзер ул кечкенә кызы Розалияне ияртеп (хатыны Лиза әфган җирендә снаряд кыйпылчыгы тиеп үлеп кала), туган якларына кайтып бара. Поездда очраклы танышкан юлдашы, кызы авырып киткән Хәбиргә ярдәм күрсәтә, хәтта кунакханәгә урнашуда да булыша. Юлдашы калдырып киткән сумка өчен Хәбиргә берничә көн сак астында да утырып чыгарга туры килә. Бу образны язучы рухи төшенкелектә итеп сурәтли. Солдатка китәр алдыннан чегән хатыны аңа: «Синең гомерең буе җан әрнүе эзәрлекләр. Бәхет синә, күгәрчен сөте сыман, аз-азлап кына тамар...»,— дигән була, шул сүзләр аның үкчәсенә басып килә. Әмма сабыр, инсафлы, ярдәмчел Хәбиргә үзе кебек мәрхәмәтле кешеләр очрый.

Авторның яратып тасвирлаган образлары — хатын-кызлар. Бу катлау персонажларны тормышчан һәм гаилә даирәсендә сурәтләгәндә генә тәэсир көче арта төшә. Шушы кагыйдәгә нигезләнеп язучы тудырган Сажидә образы — аның иҗат уңышы. Әдәбият тарихында Кол Галидән башлап Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Бәширов һ.б. тарафыннан оста/ап сурәтләнгән хатын-кызлар образларын Н. Акмалов та өйләнеп үтә алмый. Сажидә үзендә хатын-кызларга хас барлык уңай сыйфатларны туплаган. Ул — иренең тугры хатыны, йортның тырыш килене, колхозның уңган сыер савучысы, йомшак күңелле ана булу белән беррәттән, кешеләргә ярдәмчел, туганлык тойгылы, тыйнак, сабыр холыклы. Нәкъ шушы сыйфатларга таяну язучыга аның эчке дөньясында барган кичерешләрне, каршылыкларны ачарга мөмкинлек бирә: «Башкасын үткәреп җибәрә алган, ә менә монысын — соңгысын күтәреп бетерә алмаган: иренең йөзендә ниндидер кара шәүлә барын, шуны үзеннән яшергәнлеген, күрсәтмәскә тырышуын күңеле белән сизгән ул.»

Шушы ук гаилә әгъзалары булган Гөлчирәтти, Айсылу, Лизалар гадәтилекләре, самимилекләре белән игътибарны яулаcа, Минзилә образына язучы ныклабрак туктала. Ул гаиләдә бәхетсез, чөнки ире үз вакытында аны фатир белән тәэмин итә алмый. Яшәү шартлары булмаудан туган канәгатьсезлек ир белән хатын арасында булган мөнәсәбәтләргә дә йогынты ясамый калмый. Тормышта булдыксыз иреннән арыну өчен Минзилә башка шартлар эзли башлый. Очраклы рәвештә генә танышкан кешесе — Саттар белән күрешә. Гомерендә ышанычын, таянычын таптым дип өметләнеп йөргән Минзилә аның фатирына очраклы гына килеп чыгып, хыялларының чәлпәрәмә килүен аңлый. Ул «күгәрчен сөте»ннән мәхрүм кала.

Повестьта образлар саны күп булуга да карамастан, аларны ачу өчен язучы һәрберсенә аерым якын килергә тырышкан. Әсәрдә уйланып һәм ни өчен килеп керүе ачыкланып җитмәгән берничә эпизод бар, минем карашымча. Хәбир ресторанда утырганда, аның өстәле янына таныш булмаган кыз килеп утыра. Ләкин аны Ахо күчеп утырырга мәҗбүр итә. Шунда ук кызның икенче өстәл артында бер егет белән гәп корып утыруын күрә Хәбир. Ә икенче көнне әлеге егет кереп, кыз аның акчасын урлап чыкканлыгын әйтә. Егетне кызганып биргән күпмедер күләмдәге ярдәмен искә алмаганда, бу вакыйга әсәр калыбына ябышмый.

Шушы ук ресторанда Хәбиргә Минзилә белән дә кызыксынып алырга туры килә, ләкин аның ниндидер чит ир-ат белән күңел ачып йөри алуына ышанып бетә алмый. Ә Саттар сыман кешеләрне без Минзилә белән бергә ял йортында эзләп табабыз. Бу типтагы ир-атларга акча да, яшәү шартларының барлык мөмкинлекләре дә тудырылган. Әмма аларны тормыш бертөрлелеге канәгатьләндерми. Әсәрдә китерелгән Минзилә, Фәридә Рәшитовна да, фатирында күңел ачучы ханым да — һәммәсе үз-үзен генә яратучы Саттарның корбаннары. Тик әсәр буена болытлар өстендә йөзеп йөргән Саттарның нинди зат икәнлеген финалда гына әйтеп үтүгә укучының исе дә китми: бу үткән эшкә салават дигәндәй генә тоела.

Йомшаграк язылган уртакул әсәрдә югарыда саналган төгәлсезлекләр бәлки сизелмәс тә иде, ә биредә аны күңел кабул итми. Әсәрнең финал өлешендә туган төшенкелек, соңгы ноктага якынлашкан саен, ахырзаман рухы тудыра. Яхшы әсәрнең финалы да көчле, истә калырлык булып тәмамлансын иде. Соңгы аккорд оптимистик рух белән бирелсә, әсәр күпкә уңышлырак булыр иде.

Хәзер инде хикәяләргә килик.

«Бер кашык дегет» хикәясендә балачакның бер мизгелен искә төшерердәй вакыйга тасвирлана. Язучы укытучы һәм укучы арасындагы конфликтны, аның чишелешен үзенчәлекле яктан ачып сала. Яшь, тәҗрибәсез кыз Сөембикәнең шәһәрдән авылга килеп, мәктәптә эшли башлавы, максат куеп үз укучыларын өйрәнүе, шактый авыр характерлы малайның күңеленә үтеп керә алуы һәм аны кызыксындырган дөньяны аңлап, аңа теләктәшлек күрсәтүе сурәтләнә.

Укытучы тарафыннан сайлап алынган «Корыч ничек чыныкты» романына анализ вакытында Сөембикәнең яңа заманнан артта калуы, тоткарланган фикере бу әсәрне яңача, вакыт таләпләренә туры китереп бәяли белмәве ачыла. Аның күзен укучы Наять ача: «Попның онына тәмәке салу батырлыкмы? Ул бит аны өенә дәрес бирергә чакырган!..»

«...Он бит ул, ипи! Ипигә тәмәке салу батырлыкмы? Сезнең ашка таракан салып китерсәләр, сез үзегез нишләр идегез?» — дигән сүзләр Сөембикә алдында «Сез безнең остаз була аласызмы?» кебек яңгырый.

Әсәрдә язучының балалар дөньясын яхшы белүе, алар психологиясендәге мавыктыргыч сыйфатларны урынлы сайлавы, тирә-якка балалар күзе белән каравы, аларның сөйләм һәм фикерләү үзенчәлекләрен төгәл ачып салуы күренә.

Хикәя шома гына укыла, ул төрле сүз уйнатуларга бай. Ә инде әсәрнең тәрбияви көченә килгәндә, мәсьәлә шактый катлаулана төшә. Яңалыкның үзеген тәшкил иткән, яңача фикерләргә, уйларга өндәргә тиешле әдәбият укытучысы заманчарак үрнәк бирсә, яхшырак булмас идеме икән?!

«Ким, гырлама!» хикәясендә Н. Акмалов эчүчелек белән шөгыльләнүче Кимга Марта кушаматлы этнең йогынтысы турында сөйли. Тормышта эчүчелектән генә ямь табып яшәгән Кимга хатыны да, баласы да, якыннары да бернинди йогынты ясый һәм начар гадәтеннән биздерә алмыйлар. Биредә язучы кешелек дөньясы кануннарын бер якка этәреп, тәрбияви көчне икенче җирлектән эзли. Шуның нәтиҗәсе буларак, эт телгә килеп, хуҗасына мөрәҗәгать итүе язучының фантастик элемент кулланып булса да, нидер үзгәртергә теләве кыю адым дип кабул ителә. Икенчедән, этнең эчүчегә генә эндәшеп, моның башка кешеләргә ишетелмәве, Кимның эчә-эчә акылына зәгыйфьлек килгәнлеген күрсәтә кебек.

Җыеп әйткәндә, Н. Акмалов җыентыгында тормышта, көнкүрештә сирәгрәк очраган, гаҗәбрәк тоелган күренешләр тупланган. Әмма язучы биредә бүгенге көннең иң четерекле, иң катлаулы яклары хакында фикер йөртергә тырыша. Җыентыкта куелган проблемалар, темалар бик төрле. Ләкин ничек кенә булмасын, укучыга тәкъдим ителгән китап идея һәм эстетик яктан бөтен, фикри һәм фәлсәфи яктан эзлекле.

**Әлфия МОТЫЙГУЛЛИНА,**
педагогия институты аспиранты

# УЙЛАРЫБЫЗ УРТАК БУЛСЫН!

Соңгы егерме ел дәвамында мин чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребез язмышын өйрәндем. Шул максатта байтак өлкәләрне, республикаларны йөреп чыктым, Идел-Уралның һәм Себернең татар авылларында яшәүчеләр белән аралаштым, элекке СССРның төрле тарафларындагы шәһәрләрдә гомер иткән халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары белән таныштым. Эзләнүләр нәтиҗәсендә татар диаспорасы турында күп кенә язмаларым барлыкка килде, аларның бер өлеше заманында бик зур кыенлык белән вакытлы матбугатта дөнья күрде, икенче өлеше соңрак аерым китаплар рәвешендә дә басылды.

Милләттәшләребез әллә кайларга сибелеп-чәчелеп гомер кичерә. Татарның халык буларак саклануы һәм үсүе аларның яңадан тарихи ватаныбызга җыелуына бәйләнгән. Бу бик катлаулы һәм читен эш, әмма язучы шул хакта хыялланмый яши алмый. Кемнәргәдер гыйбрәт, кемнәргәдер үрнәк бирер өчен, әсәрләрендә йөзләрне, меңнәрне бергә туплый, аларның читкә таралу сәбәпләрен ачыкларга тырыша, бүтән халыклар арасында калуның уңай һәм тискәре якларын барларга, диаспораның михнәтләрен һәм бәлаләрен, өметләрен һәм теләкләрен белергә омтыла. Шундый омтылыш соңгы вакытта мине тагын да ераграк илләргә — Алмания, Болгария, Румыния, Төркиягә сәфәр чыгарды, шул сәяхәтләр нәтиҗәсендә яңа язмаларым борынлады.

Әмма хәзерге болгавыр заманда каләм әһеленең хәле бигрәк тә авырайды — әлеге сәфәр чыгымнарын бер өешма да күтәрергә теләми, язган әсәреңә түләүне дә кайгыртучы юк. Аннан да күңелсезе — иҗат җимешеңне тулы хәлдә чыгарырга бер басма да ашыкмый. Гәзит-журналларда өзек-төтек нәшер ителгән әсәрнең инде тәме дә, тәэсире дә ким була. Югыйсә алар җәмәгатьчелеккә тулы рәвешендә кирәк, моны укучылардан килгән хатлар да раслап тора.

«Йортә безне язмышлар»ның зур өзеге «Казан утлары»нда басылып чыккач, миңа байтак хатлар килде, шуларның һич югы берничәсе матбугатта бастыруга лаек шикелле. Үземне мактаган өчен түгел, укучыларның хисләре, фикерләре иҗтимагый әһәмияткә ия — алар татар аңында нинди яралар, сызланулар барлыгын, сәламәт тормышка ирешү өчен укучыларның нәрсә теләгәнлеген белү өчен дә кирәк. Тагын шуны күрү дә мөһимдер: милләттәшләребез никадәр типкегә эләксә дә, әллә кайларга чәчелсә-сибелсә дә, һаман тарихи ватаны белән бәйләнырга, Казаннан нур, рухи азык алырга омтыла. Туган әдәбиятыбызның таралыш мәйданы киң, күңелләребез берлеге нык икән. Ләкин без үзебезне артык юатырга да тиеш түгел: хат язучылар — нигездә, өлкәннәр...

«Йортә безне язмышлар» әсәре ваемлы милләттәшләребезнең ихлас теләктәшлеге, гайрәт күрсәтүе аркасында язылды. Бу уңайдан, мин үземне Алманиягә чакырып китергән, сәяхәт чыгымнарын үз өсләренә алган мөһаҗирләребезгә рәхмәтләремне белдерәм. Уйларыбыз, ниятләребез һәм гамәлләребез киләчәктә дә уртак булсын, чөнки без бары шулай гына татарны күтәрә һәм яшәтә алабыз.

Кечкенә хезмәтемне зур итеп кабул иткән, матур теләкләр теләгән укучыларыма чын күңелдән рәхмәтләремне юллыйм!

Тәүфикъ ӘЙДИ.

Хөрмәтле редакция!

Журналыгызның 1992 елның унберенче санында Тәүфикъ Әйдинең «Йортә безне язмышлар» сәяхәтнамәсен укыдым һәм сезгә шуның өчен олы рәхмәтемне житкерәсем килә. Дулкынландыргыч, тетрәндергеч язма ул.

Сугыш җиле кагылмаган, сугыш уты көйдермәгән адәм баласы бар микән соң ул безнең халыкта? Әле сабый гына булсак та, безнең йөрәкләр аша да узды ул афәт, язмышларга тирән моң-сагыш салды. Әтиләрне югалтудан туган күңел сызлавының әле дә басылганы юк. Катырак җил иссә дә, бәйрәм табыннары җәелсә дә, хәтернең төзәлмәс ярасы сыкрый. Инде ярты гасыр гомер узса да, барыбер көтәбез бит, алар хакында кай тарафтан бер-бер хәбәр килеп ирешмәсме, дип өмет итәбез.

Әйе, күп язылды матбугатта иленә хыянәт итүчеләр турында. Хәтеремдә, «Татарстан коммунисты» (№ 4, 1969) журналыннан алар хакында зур күләмле язманы укыгач, уйланып-борчылып, күңелемнән рәнҗеп йөргән идем. Кеше бит ул җир йөзендә ялгыз гына яшәми, бар аның якыннары, бар аның газизләре. Үзеннең бер газиз кешеңне шундый хурлыклы язмада очратып укы әле син. Йә ходаем, бу дөньяга ничек күтәрелеп карарга да, аннан соң ничек яшәргә? Хурлык тамгасын ябыштырганчы, тәэсирнең бу ягын да истә тотарга кирәк булгандыр ич?

Илдә власовчылар турында шомлы хәбәр таралганда миңа нибары алты яшь иде. Иртән уянам да күземне ачарга, башымны калкытырга куркып, әти дә шулар арасында булмады микән, дип сызланып ята идем. Әти бик гадел, дөрес күңелле, ышанычлы кеше булган. Сугыш беркемне дә аямады, исән калганнарын да төрле якка чәчте-таратты, әле сугыштан соң озак еллар дәвамында лекция-докладларда: «Чит илләрдә сугыштан калган йөз меңләп кешебез яши», дигән сүзләрне ишетергә туры килә иде. Ләкин без аларның ят җирдә ничек калуын, яшәвен һич тә белә алмый идек.

Менә шул йөз меңнәрнең кайберләрен эзләп табуыгыз һәм аларның хәлләренә кереп, язмышлары хакында шулай җылы хис белән язуыгыз өчен рәхмәт сезгә, хөрмәтле Тәүфикъ Әйди иптәш. Әтиемне юксынудан, гаҗизләктән сызлаган күкрәгемә куеп, елый-елый укыдым мин «Йортә безне язмышлар»ны.

Әсирләр тормышын чагылдырган җан тетрәткеч әсәрләр бар әдәбиятта. Ә менә мең үлемнән исән калып, ят илдә яшәргә мәҗбүр булган, анда да үзен яхшы яктан танытырга тырышкан, туган иленнән, якыннарыннан еракта каерылган канатлар белән гомер кичергән, ләкин кешелеген югалтмаган, хәтта шунда да халкына файда китерергә тырышкан милләттәшләребез турында минем әле берни дә укыганым юк иде. Туган әдәбиятыбызда бу тема бәлки әлек яктыртыла да алмагандыр. Ул гыйбрәтле хәлләр, ачы язмышлы ватандашларыбыз күңелдә үкенеч тә, теләктәшлек тә уята, уйландыра, аларның сабырлыгына, ныклыгына баш иясе дә килә.

«Йортә безне язмышлар»ның тулы нөсхәсен укыйсым килә: ул кайда, кайчан басылыр икән?

Авыр минутларыбызда көч-куәт өсти торган әсәрләр, аларны иҗат итүче язучыларыбыз бар әле, ярый! Шулар белән таныштырып баручы «Казан утлары» журналына, аның кадерле авторларына олы рәхмәтләремне, изге теләкләремне белдереп, сәламнәр юллап калучы

**Рәйсә ИДРИСОВА.**
Сарман.

Хөрмәтле Тәүфикъ туган!

Алман иленә баруыгыз хакында сәяхәтнамәгезне, укыдым. «Казан утлары»нда бер өлеше генә дөнья күрсә дә, ул бик матур тәэсир калдырды. Бик җентекләп, тәфсилләп, җанлы итеп язылган. Җиңел укыла, истә кала, әсирләргә мөнәсәбәтегез дөрес.

Әйе шул, сугыш кешеләрнең язмышларын сындырды, кайберәүләрне ерак-ерак илләргә дә илтеп ташлады. Әсирләрнең тормышлары белән бик шаярды, туып-үскән туфракларыннан аерды. Мәңге сагынып, бер күрергә зар булып яшәргә мәҗбүр итте. Аларның зур күпчелеге — Минһаҗ абзый кебек бичаралар. Сәбәпсез гаепләнүдән дә зур җәза юктыр адәм баласына бу дөньяда. Әлбәттә, хакыйкать чагыштырма рәвештә ачыла. Шуңа күрә ике якны да бик игътибар белән тыңлау, тикшерү мәҗбүридер, минемчә. Әйе, гаепсездән гаепләнүчеләр

алдында баш иеп гафу үтенү изге бурыч. «Йөртә безне язмышлар»ыгыз бик тирән мәгънәле, күпләрне уйландырыр ул.

«Себер үзебезнеке» дигән язмагызны да игътибар белән һәм яратып укып чыктым, якташларымны шулай җылы тойгылар белән тасвирлавыгызга чиксез куандым, рәхмәт сезгә!

Төрле илләрне гизеп, татар халкының мәнфәгате, аның ирекле булуы өчен көрәшегезне күреп сокланабыз һәм бу изге эштә уңышлар телибез.

Кайнар сәлам белән:

**Якуб ЗӘНКИЕВ,**
РСФСРның атказанган укытучысы.
Тубыл каласы.

Бик хөрмәтле Тәүфикъ әфәнде!

«Казан утлары»ның 1992 елгы унберенче санында «Йөртә безне язмышлар» сәяхәтнамәгез басылып чыгуын җаннан тәбрик итәбез. Аны укып, күп нәрсәләрне аңладык. Вә сезгә, куйган хезмәтләрегезгә, җаннан рәхмәт укырга бурычыбыз диеп калабыз.

«Казан утлары» мәҗмугасе киләчәктә дә Америкадан да күренерлек булып якты балкысын!

**Әмрулла вә Шәмсинур АГЫЙлар.**
Нью-Йорк, АКШ.

Хөрмәтле редакция!

Сезгә алман җиреннән бик күп сәлам. Ара ерак булса да, «Казан утлары» мәҗмугасе монда да килеп житә. Мин инде аны озак еллар алдырам, ватандашлар тормышы белән шуның аркылы танышып барам. Ләкин ул соңгы дәвердә безгә 4—5 ай кичегеп килә башлады.

Журналның былтыргы 11—12 саннарын берьюлы алгач, Т. Әйдинең «Алмания сәяхәтнамәсе» дип бирелгән әсәренә күзем төште. «Йөртә безне язмышлар»ны бер утыруда укып чыктым. Бик зур хезмәт, саваплы эш башкарган автор, бик күп рәхмәт яусын аңа. Әле хәзергәчә безнең хакта, ягъни әсирлеккә элөгеп, илгә кайта алмый калучылар хакында, мондый әтрафлы вә уңай фикер йөртүчеләр күренмәгән иде. Тәүфикъ Әйди рухыбызны-җаныбызны тынычландырырлык шифалы сүзләрне кызганмаган, безне ихлас күңелдән аңларга вә башкаларга да аңлатырга тырышкан.

Әмма аңлаучылар, аңларга теләүчеләр бар микән безне ватанда? Өстебезгә күп чүп өелде бит. Безне каралту, мәсхәрәләү, нахак яла ягулар, рухи кимсетүләр чиктән ашты бит. Сугыш беткәч илгә әйләнеп кайткан агайларга күрсәтелгән ышанмаучылык, кырын карау, рәнҗетүләр сезгә дә, безгә дә мәгълүм. Әсирлек коллыгыннан, үлем лагерьларыннан котылып ватаннарына кайтып егылучыларга шәфкать кулы сузылмады, язмышларына ташлама ясалмады. Язучы-журналистларыбыз да, кызганыч ки, бу күңелсез шаукымнан читтә калмадылар. Ярый инде, үткән эшкә салават, бүген берәүгә дә үпкәм юк, вакытында барына да түздек, хәзер дә түзәрбез. Бик күпләребез йөрәкләре рәнҗү тулы хис белән бу дөньядан аерылдылар, ә калганнарыбыз инде шулай ук картайды, хәтерләребез томанлы, фикерләребез буталчык.

Халкыбыздан кайберәүләр, безнең язмыш белән килешеп бетмәсә дә, һич югы бу әсәрдән азмы-күпме гыйбрәт алыр, үз тормышын башкаларныкы белән чагыштырып карар, бераз булса да күңел күзләре киңрәк ачылыр, бәлки.

Тәүфикъ Әйдигә кешелеклелеге һәм кыюлыгы, катлаулы мәсьәләләрне яңача анализлавы өчен тагын бер кат чиксез күп рәхмәтләремне белдерәм. Ирексездән мөһаҗир булган милләттәшләребезнең сынык күңелләрен аңлап эш иткән «Казан утлары» редакциясенә яңа иҗади уңышлар, муаффәкыятьләр телән:

**Әдһәм ФӘЙЗУЛ,**
Нюрнберг шәһәре, Алмания.

Хөрмәтле мөхәррир туган!

...1934 елда әнкәем мине укырга-язарга өйрәтте. Кулыма алган әлгәрегә китапларымның берсе Сөембикә хан турында иде. Казаннан алып киткәндә жырлаган жырының берсе әле дә хәтеремдә.

Аh бу көннәр килде башка,
Соң минем тәхтем кая?
Хан илә ханым булып
Торгандагы вакытым кая?

Шуннан соң әнкәем миңа Г. Тукайның «Шигырьләр» китабын бирде. Саф татар телендәге шушы китапны ул миннән көйләп укытыр иде. Менә шулай китапка мәхәббәтем уянды, гомерем буе әдәби әсәрләрдән аерылмадым. Татар телендә җиде еллык мәктәпне бетердем, татар язучылары әсәрләрен, «Казан утлары» журналын әлегә кадәр яратып укып киләм. Татарның яхшы якларын күп күрәм, башкорт булсам да, татарчага ят итеп карамыйм — мин моңа яшьтән өйрәтелмәгән. Салават Юлаев та халыкка чакыру хатларын татарча язган. Миңа да һәр ике тел анам теле кеби.

Соңгы дәверләрдә Башкортстанда башкорт милләтен саклауга игътибар артты. Аның көенечле сәбәбе — 70 ел дәвамында безнең кимүебез. Татарлар урыслашып югалса, башкортлар урыслашып та, татарлашып та югала, милләт һәлакәт юлында, димәк. Менә шуны кайберәүләр искә алырга теләми. М. Гафурины, Ш. Бабичны татар дип дәгъвалый. Бәлки андый галимнәргә «Агыйдел» журналы белән бәйләнешкә керергә кирәктер? Аңлатырлар иде! Юкса, сукыр үзенекен тукыр сыман килеп чыга...

Матбугатта татар-башкорт тарткалашуы ошамый миңа. Хасбулатов белән Ельцин талашсын, татар белән башкорт түгел.

Миңа 72 яшь инде, татарлар белән, яшьлегемдәгечә, һаман дус, тату яшисем килә.

Эшегездә уңышлар теләп калучы:

**Н. СОЛТАНОВ,**
Морак авылы, Күгәрчен районы
Башкортстан.

## РОССИЯ САЙЛАУЛАРЫ БЕЗДӘ БАРЫП ЧЫКМАДЫ

Билгеле булганча, 1993 елның 12 декабрендә Россия Дәүләт Думасына сайлаулар һәм Россия Конституциясе буенча референдум булып узды. Анда Татарстаннан барлык сайлаучыларның нибары 13,8 проценты гына тавыш бирде. Шулай итеп, бездә сайлаулар да, референдум да булмады, дип санала — чөнки җитәрлек тавыш җыелмады. Республикабызда яшәүче төрле милләт вәкилләре тагын бер мәртәбә гадел булмаган сәясәткә карата үзләренең бердәмлекләрен күрсәттеләр. Моны сайлаулар һәм референдум барышын күзәтергә җөмһүриятебезгә чит илләрдән һәм Россия Президенты аппаратыннан килгән махсус вәкилләр дә таныды. Танырга мәҗбүр булдылар. Шулай итеп, Татарстан халкы Россия Конституциясен кабул итмәде, Россия Дәүләт Думасына үз вәкилләрен җибәрмәде.

## ЕВРОПА ПАРЛАМЕНТЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ТАТАРСТАНДА

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев 7 декабрьдә Европа парламентының БДБ илләре белән элемтә комиссиясе рәисе Магдалина Хофф житәкчелегендәге делегациясен кабул итте.

Җөмһүриятебез Илбашы олы кунакларга Татарстан тормышындагы актуаль икътисади, социаль-сәяси аспектлар турында сөйләде. Россия Федерациясендә барган сәяси ызгышларга бәйсез рәвештә республикабызның позициясе нык булуын әйтте.

## «ЕВРОПАГА ТӘРӘЗӘ» АЧЫЛА БАРА

Татарстан Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров җитәкчелегендәге хөкүмәт делегациясе 5—12 декабрь көннәрендә Германия Федератив Республикасына һәм Швейцариягә визит белән барды. Рәсми хәбәрләргә караганда, ул «уңышлы һәм гаҗәеп нәтиҗәле» булган.

## УЛ — БЕЗНЕҢ КОМПОЗИТОРЫБЫЗ

3 декабрьдә Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Казан Кремлендә атаклы ватандашыбыз, дөньякүләм танылган композитор София Әсгать кызы Гобәйдуллинаны кабул итте.

Мәшһүр милләттәшебезгә яңа иҗат уңышлары теләп, җөмһүриятебез Илбашы аның симфоник һәм камера музыкасы фестивале Казанның һәм бөтен республиканың мәдәни тормышында зур вакыйга булуын ассызыклап билгеләп үтте.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ

2—5 декабрь көннәрендә Вашингтонның «Шератон» кунакханәсендә Бөтендөнья төрки халыкларының III конференциясе үткәрелде. Анда егермеләп илдән вәкилләр катнашты. Татарстаннан исә бергә җөмһүриятебезнең Югары Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиева, Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев килгән иде.

Конференциядә алар Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм алда торган проблемалар турында доклад ясадылар.

## ТУКАЙ ҖӘМГЫЯТЕ ОЕШТЫ

1993 елның декабрендә мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда олуг шагыйребез исемендәге җәмгыятьне оештыру җыелышы булды.

Җәмгыятьнең президенты итеп Татарстан Фәннәр Академиясенең әгъза-корреспонденты, филология фәннәре докторы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты — язучы һәм галим Нил Юзиев сайланды.

Яңа җәмгыять белән элемтәгә керергә теләүчеләргә аның адресы: 420000, Казан, Тукай урамы, 74 нче йорт. Эш телефоны: 37-42-63.

## БЕРДӘМЛЕККӘ ЧАКЫРУ

Татар һәм башкорт язучылары татар һәм башкорт халыкларына «Үзара дус-тату яшик, туганлык юлыннан бергә атлыйк!» дип махсус мөрәҗәгать белән чыктылар. Әлеге хатка — бердәмлеккә чакыруга — Башкортстанның күренекле язучыларыннан Зәйнәп Биишева, Назар Нәҗми, Мостай Кәрим, Муса Гали, Гайса Хөсәенов, Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин, Денис Бүләков (барлыгы 17 имза) Татарстаннан исә Гомәр Бәширов, Риза Ишморат, Әмирхан Еники, Әхсән Баян, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Мәдинә Маликова, Туфан Миңнуллин (барлыгы 18 язучы) кул куйган. Мөрәҗәгать һәр ике республиканың да үзәк газеталарында басылып чыкты, радио-телевидение тапшырулары аша яңгырады.

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫ СЪЕЗДЫ

Үткән елның 16 декабрендә Татарстан композиторларының VII съезды булып узды. Җөмһүриятебезнең композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәлимуллин ике съезд арасында башкарылган эшләр турында хи-

сап тотты. Съездда Татарстанның мәдәният министры М. Таишев катнашты һәм чыгыш ясады.

Съездның ҫештыру өлешендә Татарстан Композиторлар берлегенең яңа идарәсе һәм аның рәисе итеп Р. Кәлимуллин сайланды.

## МӨСЕЛМАН КАЛЕНДАРЕ

Татар тарихында беренче тапкыр булырак, күләме 500 биттән артыграк исәпләнгән мөселман календаре — «Мөселман җәдвәле» зур тираж белән басылып чыкты. Календарь һиҗри буенча 1414—1415 елларны, милади буенча 1994 елны үз эченә ала.

Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан чыгарылган ошбу зур хезмәттә Ислам дөньясы сүзлеге, гарәпчә язарга-укырга өйрәнү күнекмәләре, изге Коръәннән өзекләр, аларга аңлатмалар, Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәдисләре, файдалы киңәшләр, пәйгамбәрләр һәм татар ханнары тарихы, борынгы һәм бүгенге мәчетләребез турында язмалар һәм рәсемнәр, дини бәйрәмнәребез турында белешмәләр, намазны ничек уку кирәклеге турында киңәшләр, вәгазьләр урын алган.

Әлеге мөселман календаре Казанның Киров районындагы Печән базары мәчетендә сатыла.

## ХАЛЫК РӘССАМЫНА — МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ХӨРМӘТЕ

Ташкент каласында яшәүче күренекле милләттәшебезгә — рәссам Чыңгыз Әхмәровка, Җөмһүриятебез Президенты Минтимер Шәймиев Указы нигезендә, «Татарстанның халык рәссамы» дигән мактаулы исем бирелде.

## БЕРЕНЧЕ ЛАУРЕАТЛАР

«Туран» бәйсез культурология фонды 1993 ел өчен премияләрен тапшырды. Гранпризга «Казан татарларының декоратив-гамәли сәнгате» дигән альбом авторлары Г. Сөләйманова-Вәлиева һәм Р. Шаһиева лаек булды. Беренче премияләр рәсем остасы Н. Лотфуллинга (үлгәннән соң) һәм «Чыңгызхан» төркеме рәссамнарына бирелде. Махсус премияләр алучылар арасында милли мәдәният музее директоры Р. Закиров, сәясәтче-галим И. Таһиров, эшмәкәр В. Петухов һәм Татарстан Президенты М. Шәймиев бар.

## БТИҮ: ДҮРТЕНЧЕ КОРЫЛТАЙ

4—5 декабрь көннәрендә мәркәзебез Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең дүртенче корылтае булып узды. Чираттан тыш үткәрелгән әлеге форумда Татарстан, Россия, БДБ илләренең төрле төбәкләреннән килгән 400 ләп делегат катнашты.

БТИҮ тарафыннан ике корылтай арасында башкарылган эшләргә җентекле анализ ясалды, иҗтимагый үзәкнең яңа платформасы һәм Уставы кабул ителде.

БТИҮнең яңа Президенты итеп педагогия фәннәре кандидаты, Татарстан халык мәгарифе министрлыгы баш белгече, Татар милли университеты ректоры, «Мәгариф» ассоциациясе җитәкчесе Илдус Әмирханов сайланды.

## ГАДЕЛ КУТУЙНЫ ИСКӘ АЛУ

16 декабрьдә Г. Кариев исемендәге актерлар йортында язучы Гадел Кутуйның тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль тамаша булып үтте. Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники, күренекле режиссер-профессор Ширияздан Сарымсаков, әдипнең улы — шагыйрь һәм прозаик Рөстәм Кутуй, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин һәм башкалар үзләренең истәлекләре, фикерләре белән уртаклаштылар.

## ТАТАР ШАГЫЙРЕ — ЛАУРЕАТ

Швейцариянең Базель шәһәреннән куанычлы хәбәр килде. Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча Халыкара Совет (Ай-Би-Би-Уай) — ЮНЕСКОның информацион-консультатив органы — татар шагыйре Роберт Миңнуллинның «Дөньядагы иң зур алма» китабын Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы исемлеккә керткән, шагыйрьнең үзен Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы Диплом белән бүләкләгән. Роберт Миңнуллин шулай ук җиңүчеләргә дипломнар тапшыру тантанасында һәм Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча Халыкара Советның 24-нче конгрессында катнашу өчен рәсми чакыру да алды. Конгресс исә Испаниянең Севилья шәһәрендә 1994 елның октябрендә булачак.

## ТАТАР КИТАБЫ КӨННӘРЕ

8—10 декабрь көннәрендә Удмуртиядә «Татар китабы көннәре» үткәрелде. Аны Татарстан һәм Удмуртия мәдәният министрлыклары оештырган иде. Әлеге мөһим чараны үткәрүдә Татарстан китап нәшрияты җитәкчеләре, язучылардан Мөсәгыйт Хәбибуллин, Роберт Миңнуллин, Кыям Миңлебаев, Лена Шагыйрьҗан, Газинур Морат, республиканың милли, яшүсмерләр һәм балалар китапханәләре хезмәткәрләре катнашты.

«КамАЗ» машинасы белән Татарстаннан алып барылган татар әдәбияты китаплары бик күпләр күңеленә хуш килде.

«Татар китабы көннәре»ндә Ижау, Можга шәһәрләрендә, Татар иҗтимагый үзәгендә, авылларда, китапханәләрдә көтеп алынган очрашулар мавыктыргыч үтте.

## ЗУР СӘХНӘДӘ — ЯКТАШЫБЫЗ

11—12 декабрьдә Казан университетының «УНИКЕС» тамаша залында, Италия режиссеры белән бергәләп безнең режиссер В. Чеботарев куйган «Италия контракты» нәфис фильмын тәгъдим итү (презентация) булды. Фильмда төп рольне танылган җырчы, якташыбыз Ренат Ибраһимов башкара.

## ЯКТАШЛАРЫ ШАГЫЙРЬНЕ ОЛЫЛЫЙ

Минзәлә районы халык депутатлары Советы президиумы һәм район хакимияте танылган шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Марс Шабаевның 60 еллык юбилеен үткәрү буенча 1993 елның июль аенда ук махсус карар кабул иткән иде. Шул уңайдан район мәктәпләрендә, уку йортларында, китапханәләрдә шагыйрьнең иҗатын өйрәнү, аны пропагандалау оештырылды.

23—26 ноябрьләрдә М. Шабаев туган якларында булды. Шагыйрьнең иҗади очрашулары Югары Тәкермән, Кадрәк авылларында мәктәп укучылары, авыл хезмәтчәннәре белән, ә Минзәлә педагогия училищесында һәм сәнгать мәктәпләрендә исә шәһәр җәмәгатьчелеге, районның иҗат көчләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары һ. б. белән үткәрелде. Үзешчән сәнгать көчләре тарафыннан концертлар куелды.

## ҖЫРЧЫНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

13 декабрьдә Г. Камал театры бинасында Татарстанның атказанган артисткасы, М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Гөлзадә Сафиуллинаның 20 еллык сәхнә эшчәнлегенә багышланган иҗат кичәсе (бенефис) булды. Халкыбызның сайрар сандугачы булган ошбу җырчыны котларга бихисап тамашачылар, аның рухи остазлары Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров, Рафаэль Ильясов кебек сәхнә йолдызлары да килгән иде.

## АТАКЛЫ МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ ИСТӘЛЕГЕНӘ

29 ноябрьдә Казан шәһәренен Николаев урамындагы 5 нче йортка атаклы җырчы Рәшид Ваһапов истәлегенә мәрмәр такта кую тантанасы булды.

Кичен исә К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында мәшһүр артистны искә алу кичәсе уздырылды.

## УРАЛДА — ТАТАР ҖЫРЫ

Екатеринбург каласында күптән түгел «Урал җыры-93» фестивале булып узды. Анда 30 лап татар җырчысы катнашты.

Өч турда үткәрелгән бәйгедә беренче урынга Илдам Шәрипов (Екатеринбург), икенче урынга исә Төмән егете Рөстәм Русин белән Чиләбе кызы Сүрия Гималова чыкты. Өченче урында — Курган өлкәсе вәкиле Фирзиян Сөләйманов.

## ИЛДАР ИБРАҺИМОВ — ГРОССМЕЙСТЕР

ФИДЕ (Халыкара шахмат федерациясе) конгрессы 26 яшьлек Илдар Ибраһимовка халыкара гроссмейстер исемен бирде. Ул — җөмһүриятебездә әлеге югары дәрәҗәгә лаек булган икенче шахматчы. Берничә ел элек халыкара гроссмейстер исеменә Алисә Галләмова (Иванчук) лаек булган иде.



# «ТУРАН» ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Туран исеме каян туган?

Туран ул — төрки халыклар биләгән җирләр. Туран ул — гасырлар буена бөртекләп җыелган бәһасез хәзинәләрне бер кулга туплаган бөек хәтер. Ул хәзинә-байлыклар Тутанһамон төрбәсеннән яисә Пазырыктан табылган җәүһәрләргә, Күлтәгин һәм Таньюкук язмаларына гына тиң торырлык: ана — Идел буе Помпеясы — Болгар сәнгате, Истанбулның Күк иясенә табынган архитектурасы, казах тирмәсенең эчке бизәлеше, чуашның бизәкле чигеше, Дагыстанның алтын-көмеш чүкелмәләре, Әзәрбайҗанның келәмнәре, Урта Азияның миниатюралары, Туваның скульптуралары, башкортның агач әйберләре, Казан татарларының алтынлы нәкыш-чигүләре керә. «Туран» дигән сүзнең тагын бер мәгънәсе бар. Бу — викингларның Валгалласы, Тибетның Шамбаласы кебек, гаҗәеп муллыкка ирешкән әкияти илнең гамәлдә булмаган чагылышы: Евразия кыйтгаларында бөтен төркиләрне мәһабәт гөмбәз астына берләштергән бу мифик мәмләкәт — рухи бергәлекнең, камиллеккә ирешкән дәүләтле булуның сүнмәс хыялы.

Татарстанда оешкан «Туран» җәмгыяте — шушы олугъ Туранның тынгысыз кайтавазы... Ул Казан татарларының, «Идел-Урал» төбәгенең рухи мирасын барлауны, төрки халыклар дөньясының мәдәни үсешен яңа биеклекләргә алып чыгуны үзалдына максат итеп куя.

Бүгенге көндә җөмһүриятебез халыкара мәйданга чыга. Шушындый чорда безгә заман чагылышын үтемле чаралар белән тасвирлый торган сынлы-сурәтле сәнгатебезне калку итеп күрсәтә белергә кирәк.

Татарстан сәнгать хәятендә борынгы мираска таянып, Европа һәм Шәрык казанышларына кыйбла тотып, яңа сәләт ияләре — эре йолдызлар калыкты: суверенлык яулау өчен көрәш барган дәвернең бу яңа сәнгате — «Татарт» (1990—1993) иде.

«Татарт» — милли романтизм эстетикасына таянган шундый агым ул — монда тарихка, сәнгатьнең шигърияте карата капма-каршы фикерләр хөкем сөрә, мәдәниятебезнең бүгенгесе һәм үткәненә карата да юнәлешләр төрле: чынбарлык, абстрактлык, экспрессионизм, сюрреализм, неореализм, поп-арт һәм самими сәнгать.

Иҗатка ирек җилләре бәреп кергән бу дәвердә татарның декоратив һәм мөселман мәдәнияты казанышларына таянып, дөнья һәм совет авангарды ирешкән уңышларны туплап, сәнгатебездә татавангард (Чыңгыз хан исемендәге) дулкыны калыкты. Чыңгыз ханчылар, сәнгать офыкларын киңәйтеп, кайчандыр тыелып килгән темаларга тотындылар.

«Генезис», «Сәнаигы нәфисә» һәм «Чулпан-арт» дигән галереялар тотучы «Туран» җәмгыяте татарның сынлы-сурәтле сәнгатен бергә туплап күрсәтергә омтыла. Мәскәү, Уфа, С.-Петербург, Самара, Әстерхан, Казагыстан, Оренбурда яшәгән татар рәссамнары уртак иҗади хәзинәгә татар дөньясыннан шул төбәк чалымнарын да китереп кертәләр.

Чын рәссамнарның әсәрләрен туплау белән бергә, «Туран» җәмгыяте «сәнгати азык» җыюны да максат итеп куя. Шундыйлардан: алтын чигү, тиредән мозаика, агачтан кисеп эшләнгән һәм чүлмәктән коелган әйберләр, милли сандык, гармун, һәм келәмнәрне санап китәргә була.

Шулай итеп, «Туран» ул — татар мәдәниятендә иҗади акыл ияләренең бишеге генә түгел, ә торгынлык, басым ясау, кысуларга бирешми торган яңа омтылышлы сәнгать чишмәсе дә. «Туран» ул — татар мәдәниятенең өр-яңа йолдызлыклардан тупланган Киек каз юлы. «Туран» ул — киләчәкне сагынучы, үткәнне кайтаручы, мәңгелек хыялны — халыклар рухын мәдәни җирлектә якынайтучы чынбарлык тантанасы.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Равил Заһидулланың «Уку» дигән әсәре.

(«Туран» коллекциясеннән)

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган галим һәм язучы, Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Х. Хәсәнов.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосы

Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог